ТУФАН МИҢНУЛЛИН

# ПЬЕСАЛАР

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2021

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
М57

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы
Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе
һәм «Татнефть» хәйрия фондының «Рухият» программасы
ярдәме белән эшләнде.

**Миңнуллин, Т. А.**
М57 Пьесалар / Туфан Миңнуллин. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2021. — 654 б.
ISBN 978-5-298-04251-2

Китапка танылган драматург, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның төрле елларда язылган пьесалары тупланды.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6

ISBN 978-5-298-04251-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2021
© Миңнуллин Т. А., варислар, 2021
© Галиәхмәтова А. Ф., төзү, 2021

# ӘЛДЕРМЕШТӘН ӘЛМӘНДӘР

*(2 пәрдәле, 4 күренешле, пролог, интермедия һәм эпилоглы комедия)*

Күп йөргән, күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган, ләкин күңел көрлеген югалтмаган авылым картларына багышлыйм.

Катнашучылар:

Әлмәндәр — Әлдермеш авылы карты, 91 яшендә.
Искәндәр — Әлмәндәрнең өлкән малае, 70 яшендә.
Өммия — Искәндәрнең карчыгы, Әлмәндәрнең килене, 65 яшендә.
Хәмдебану — Әлдермеш авылы карчыгы, 70 яшендә.
Евстигней — Әлмәндәрнең Антоновка авылындагы «знаком»ы, 85 яшендә.
Гөлфирә — Әлмәндәр улының оныгы, 17 яшендә.
Йөзембикә — Әлмәндәрнең карчыгы, Гөлфирә яшендә.
Илсур — Әлдермеш авылының 5–6 яшьлек малае.
Мансур — Әлдермеш авылы егете, 18 яшендә.
Газраил — яше билгесез, ләкин карт икәне күренеп тора.
Әҗәл — ул да яшь түгел.
Фәрештә — Газраилнең секретаре.

## Пролог

Беренче пәрдә ачыла. Ут икенче пәрдәне яктырта. Анда Җир шарының ике түгәрәккә бүленгән картасы эленеп тора. Карта каршына, кулына күрсәткеч таяк тотып, Газраил баскан. Ул, авыз эченнән генә нindiдер аңлаешсыз бер көйне көйләп, картадан Әлдермеш авылын эзли. Таба алмагач, кинәт борыла да кесәсеннән телефон трубкасын тартып чыгара.

Газраил *(телефон трубкасына)*. Сезме? Минем янга керегез!

Ф ә р е ш т ә керә.

Ф ә р е ш т ә. Тыңлыйм сезне, Газраил әфәнде.
Г а з р а и л *(картага күрсәтеп).* Нәрсә бу?
Ф ә р е ш т ә. Җир өстенең картасы.
Г а з р а и л. Җир өстенең картасы булгач, кайда монда Әлдермеш?
Ф ә р е ш т ә *(картадан Әлдермеш авылын эзли).* Әлдермеш... Әлдермеш... Әлдермеш... Шәһәрме ул, авылмы?
Г а з р а и л. Илле йортлы авыл булырга тиеш.
Ф ә р е ш т ә. Әлдермеш... Әлдермеш... Ул авыл Европаның көнчыгышында яки Азиянең көнбатышында булырга тиештер. Әлдермеш... Әлдермеш... Менә ул! Менә ул Әлдермеш!
Г а з р а и л *(картадагы Әлдермешкә таягы белән төртеп).* Кара син аны, әкәянни, кайда качып яткан!
Ф ә р е ш т ә. Әкәянни түгел, Газраил әфәнде, окаянный.
Г а з р а и л. Күп белмәгез! Барыгыз, бер мең биш йөз илленче номерлы Әҗәлгә әйтегез, минем янга керсен.

Ф ә р е ш т ә чыгып китә. Бераздан Ә җ ә л керә.

Ә җ ә л. Мөмкинме?
Г а з р а и л. Кер әйдә. Хәлләрең ничек, Әҗәл?
Ә җ ә л. Ярыйсы.
Г а з р а и л. Эшсезлектән интекмисеңме?
Ә җ ә л. Тын алырга да вакыт юк, үзегез беләсез.
Г а з р а и л. Сиңа тагын командировкага китәргә туры киләчәк.
Ә җ ә л. Кай якка?
Г а з р а и л *(таягы белән картадагы Әлдермешкә төртеп).* Менә монда, Әлдермешкә!
Ә җ ә л. Анда кем бар?
Г а з р а и л. Әлмәндәр карт.
Ә җ ә л. Хәле начармыни?
Г а з р а и л. Киресенчә, җир җимертеп йөри.
Ә җ ә л. Алайса, нигә?..
Г а з р а и л. Тыңла. Мин бүген җир өстендәге адәм балаларының исемлеген карап утырдым. Кулыма Әлдермеш авылында яшәгәннәрнең һәм яшәүчеләрнең исемлеге эләкте. Шунда күрәм ки: Әлдермеш авылында

элек-электән туксаннан узып яшәгән берәү дә булмаган. Ә менә Әлмәндәр картка туксан бер. Ишетәсеңме, туксан бер! Нигә ул, бүтәннәрдән узып, бер ел артык яшәгән? Бу ни?! Миннән качып бер ел артык яшәргә аның ни хакы бар?! Кыскасы, хәзер үк Әлдермешкә юл тот. Ярты сәгать вакыт бирәм, Әлмәндәрне минем янга алып кил.

Ә ж ә л. Баш өсте. Әмер үтәлергә тиеш. Исеме ничек дидегез әле?

Г а з р а и л. Әлмәндәр. Әлдермештән Әлмәндәр.

Ә ж ә л. Биографиясе ничек?

Г а з р а и л. Картотека минем секретарем Фәрештәдә. Аңардан ал.

Ә ж ә л. Хушыгыз. Мин Әлдермешкә төшеп киттем.

Ут сүнә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Ут яна. Әлдермеш авылында Әлмәндәр картның ишегалды. Верстак. Верстак янында — ышкыланган, ышкыланырга әзерләнгән такталар өеме. Ишегалдына өйнең ян тәрәзәләре караган. Койма буенда — самолёт трабына охшатып эшләнгән баскыч. Баскыч өстендәге мәйданчыкка тәхеткә охшатып әйләнгеч кресло куелган. Ул креслога менеп утырсаң, авыл күренә. Әлмәндәр өе яныннан юл уза. Ул юлдан авыл халкы үтеп йөри. Койма, капка, тәрәзә наличниклары, баскыч төрле төсләргә буялган. Барысы да Әлмәндәр картның кулы белән эшләнгән. Ут янганда, Ә л м ә н д ә р к а р т верстак янында көйли-көйли такта ышкылый.

Ә л м ә н д ә р. Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә очмаска?
Тәүбә итсәң дә син, мин итмәдем
Чибәр-чибәр кызлар кочмаска.

*(Ышкылап бетергән тактасын верстакка сөяп куя да өйнең ишегалды ягына чыга торган тәрәзәсе янына килеп кычкыра.)* Әй, кем бар өйдә, чәй чыгарыгыз! *(Баскычтан менеп, креслога утыра, җырын дәвам итә.)*

Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Кай имәнгә кунып сайрадың?

*(Койма яныннан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар. Әлмәндәр аларның сәламен рәхәтләнеп кабул итә. Кайберәүләре белән сөйләшә.)* Исән бит әле, Сәйфулла... Рәхмәт... Утырырга дигәндә утырабыз да аны... Эшкә ашыгасыңмы?.. Карале, Сәйфулла, бригадир Гаптерине күрсәң әйт, Әлмәндәр абый сиңа ахмак дип әйтте, диген. Мин үз гомеремдә кешегә андый сүз әйтмәдем, менә бүген әйтәм. Ни өчен дисеңме? Үзе мине мыскыл итте. Эш бирми, син карт инде, рәхәтләнеп ял ит, ди. Сау бул, Сәйфулла, эшләрең уң булсын!

Ала карга дигән, әй, асыл кош...

Әйбәт, бик әйбәт, кызым. Һәй, Әлмәндәр бабаң әле синең туеңа барып чүгә-чүгә биячәк. Кияүгә чыгарга җыенмыйм дисеңме? Алай димә, кызым... Чишмәгә суга барасыңмы? Сау бул. Юлың уң булсын. Гомерең чишмә суы кебек ару булсын!

Ала карга дигән, әй, асыл кош...

*(Кинәт кемнеңдер килгәнен күреп, урамга арты белән әйләнеп утыра.)* Ә мин синең сәламеңне алмыйм. Син мине мыскыл иттең. Казанда укып кайткан да бригадир булган, имеш. Казанда укып кайткан булсам, мин әллә кем булыр идем. *(Кинәт урам якка әйләнеп.)* Ни дидең?.. Иртәгәме?.. Сарыклар абзарын ремонтларгамы?.. Рәхмәт, Габдрахман энем. Юкка гына Казанда укып кайтмагансың икән. Һәмишә шулай мәгънәле бул. *(Шатланыбрак җырлый башлый.)*

Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Кай имәнгә кунып сайрадың?
Син сайрамасаң да, мин сайрадым —
Чибәр-чибәр кызлар сайладым.

*(Урамда Хәмдебануны күреп.)* Хәмдебану... *(Тиз генә баскычтан төшеп, капканы ача.)*

Анда Хәмдебану карчык күренә.

Хәмдебану. Исәнлекме-саулыкмы, Әлмәндәр абый.

Ә л м ә н д ә р. Шәп бит әле, Хәмдебану. Кай якка таба теркелдисең?

Х ә м д е б а н у. Шул, теркелдәрлек кенә калды инде. Менә чыккан идем.

Ә л м ә н д ә р. Ишегалдына уз, Хәмдебану, сөйләшеп утырыйк. *(Хәмдебану ишегалдына кергәч, капканы яба да бикләп үк куя.)* Әйдә, түрдән уз, утыр.

Х ә м д е б а н у *(такталарны күреп)*. Үзең бер генә дә тик тормыйсың, Әлмәндәр абзый. Тагын ни ясарга җыенасың?

Ә л м ә н д ә р *(түбәтәен артка чигереп)*. Дача.

Х ә м д е б а н у. Ни дидең?

Ә л м ә н д ә р. Дача, Хәмдебану, дача! Казанга баргач, Искәндәр кызының кызы Казан читендәге бакчаларына алып барды. Шунда тактадан өй салганнар, шул «дача» дип атала, белдеңме?

Х ә м д е б а н у. Алай икән. Син дә шуны эшлим дисеңме?

Ә л м ә н д ә р. Ясыйм. Бакча уртасына дача ясап куям.

Х ә м д е б а н у. Ындыр табагы чаклы бу өегез кысанга киттемени?

Ә л м ә н д ә р. Китте. Килен явызланды. Картая башлады. Картайган саен явызлана. Булмады, малайның бәхете булмады, озын гомерле хатынга туры килде.

Х ә м д е б а н у. Алай димә, Әлмәндәр абзый, үзең дә Аллага шөкер.

Ә л м ә н д ә р. «Үзең дә...» Нәрсә үзем дә?.. Мин — ир кеше. Ир кеше, үз гомерендә ике хатын да җирләрлек яшәмәгәч, ир кеше буламы.

Х ә м д е б а н у. Әстәгъфирулла...

Ә л м ә н д ә р. Син курыкма, Хәмдебану. Мин ике генә дидем, өч димәдем. Син, Ходай кушса, озак яшәрсең. Нишләтим, Йөзембикә белән Фәхриҗамалның гомерләре кыска булды, берсе алтмышта, икенчесе җитмеш дүрттә дөнья куйдылар. Үзең беләсең, гаебем юк, үз әҗәлләре белән үлделәр... Инде менә болай, Хәмдебану, сиңа әйтергә күптән йөрим, ялгыз башың яшәве сиңа җиңел түгелдер... Әллә, мин әйтәм... Чык син миңа кияүгә...

Х ә м д е б а н у. Әстәгъфирулла...

Ә л м ә н д ә р. Өрмәгән җиргә дә утыртмам, җәй көннәре бакча уртасындагы дачада яшәрбез.

Хәмдебану. Килешмәгәнне... Олы башың белән әллә ниләр сөйләп утырасың, Әлмәндәр абзый. Җитмеш яшьлек карчыктан көлмәсәң...

Әлмәндәр. Көлмим мин, чынлап әйтәм, Хәмдебану. Ир башым белән килен кулына карап ята алмыйм ич инде мин. Җир җимертеп йөргән чагымда...

Хәмдебану. Кит, кит, Әлмәндәр абзый. Картая алмадың. Мин белә белгәннән авылның Шүрәлесе булдың.

Әлмәндәр. Шүрәле булып ни явызлык кылдым?

Хәмдебану. Явызлык кылдың димим, кеше көлдерден.

Әлмәндәр. Көлсә ни булган?..

Хәмдебану. Булмаса да...

Әлмәндәр. Син, Хәмдебану, тегеләй-болай дигән булып миннән гаеп эзләмә. Миннән дә әйбәтрәкне таба алмассың. Боргаланма, Хәмдебану.

> Чәчең бөдрә, чәчең көдрә,
> Көдерәсен җил өрә;
> Боргаланып йөргән булып,
> Кызлар үзен сөйдерә.

Хәмдебану. Әстәгъфирулла... Тфү, кешедән оят! *(Кинәт борылып, капкага таба атлый.)* Чакырып кертеп, рисвай итеп чыгармасаң... *(Капканы тарткалап.)* Кая, нәрсә соң бу?

Әлмәндәр. Бикләнгән ул, Хәмдебану.

Хәмдебану. Нишләгән тагын?..

Әлмәндәр. Бикләнгән, дим.

Хәмдебану. Ач, ач тизрәк!

Әлмәндәр. Нәрсә кычкырасың. Әйтмәк бар, көчләмәк юк. Хәзер элекке заман түгел, бар да үз иркеңдә. Теләмисең икән, дүрт ягың кыйбла. Үзеңә яхшылык эшләмәкче идем. *(Капканы ачып, Хәмдебануны чыгарып җибәрә. Сөйләнеп кала.)* Муладис карчык, нык тора.

Мансур тавышы: «Исәнмесез, Әлмәндәр бабай!»

Әлмәндәр. Исән әле, малай. Әйдә, кер.

Мансур керә.

Мансур. Кереп торырга вакытым юк. Әлмәндәр бабай, Гөлфирә кайтмадымы әле?

Әлмәндәр. Кем соң ул Гөлфирә?

Мансур. Көлмә инде, Әлмәндәр бабай.

Ә л м ә н д ә р. Көләм әле, малай. Гөлфирәнең кем икәнен әйтмәсәң, мин дә әйтмим.

М а н с у р. Синең онычың.

Ә л м ә н д ә р. Дөрес әйтмәдең, оныгымның кызы. Минем оныгымның кызы сиңа нигә кирәк?

М а н с у р. Нигә кирәк дип, болай гына.

Ә л м ә н д ә р. Бар, чыгып кит. Минем оныгымның кызы болай гына кирәк булгач, сөйләшеп тә тормыйм.

М а н с у р. Кайтмадымыни?

Ә л м ә н д ә р. Белмим.

М а н с у р. Әйт инде, Әлмәндәр бабай.

Ә л м ә н д ә р. Әйт, нигә кирәк?.. Яратам, шуңа кирәк диген, җебегән авыз... Кайтмады әле. Кайткач, үзем барып әйтермен.

М а н с у р. Сау булып тор, Әлмәндәр бабай.

Ә л м ә н д ә р. Исән бул, малай. *(Мансур чыгып киткәч, капканы яба да тәрәзә янына килә.)* Әй!.. Әй, дим. Нәрсә анда, әллә йоклап ятасызмы? Чәй чыгарыгыз! *(Җавап бирүче булмагач, тәрәзәне шакырга тотына.)*

Тәрәзә ачыла, анда — Ө м м и я.

Ө м м и я. Ни булды инде тагын?

Ә л м ә н д ә р. Әллә колагыгызга сумала сылап куйдыгызмы? Ярты сәгать кычкырам!

Ө м м и я. Йә, йә, эткәй, узынма. Нәрсә кирәк?

Ә л м ә н д ә р. «Нәрсә кирәк...» Чәй кирәк!

Ө м м и я. Самавыр кайнаган, өйгә кереп эч.

Ә л м ә н д ә р. Өйгә кереп эчәргә — беткән ди минем эшем. Мин бит сезнең кебек тик ятмыйм.

Ө м м и я. Кем кушкан сиңа... Кирәкле эш эшләп йөрмисең, такта әрәм итеп кенә йөрисең.

Ә л м ә н д ә р. Телеңә салынма. Килен булсаң, телеңне тый!

Ө м м и я. Җитәр, болай да кырык ел тел яшердем. Җүләр булганмын.

Ә л м ә н д ә р. Кырык ел сөйләмәгәнеңне ун елда чыгарып бетердең инде. Матри, килен!.. Мин кызсам...

Ө м м и я. Кызсам, дигән була... Кызып нишләрсең... *(Тәрәзәне ябып куя.)*

Ә л м ә н д ә р. Уңмады, уңмады малай. Әрәм үтте гумере малайның. Шулай... Чурту-матыр, дөбер-шатыр, үтте китте яшь гумер, диген. *(Верстак янына килә.)*

Чынаяк күтәреп, өйдән Өммия чыга.

Өммия. Кая куйыйм? Бал белән эчәсеңме, әткәй, вәринҗә беләнме?

Әлмәндәр. Китер монда.

Өммия чынаякны верстак өстенә куя.

Бал тирләтә килен, шикәр чыгар.

Өммия кереп китә.

Акылына килгән. Пәриләрен качырып тормасаң, хәзер базыналар.

Өммия, шикәр чыгарып, верстак өстенә куя да кереп китә.

Әллә кая югалма, кычкырырлык булмасын! *(Верстак өстенә утырып чәй эчә.)* Юк инде, үзеңнең хәләл хатының булмаса, юк инде. Чурту-матыр, Йөзембикә ясаган чәйне эчеп җибәргәч, өчәр көн айный алмый йөри идем.

Шулчак койма өстендә Илсурның чуалган чәчле башы күренә.

Илсур. Бабай, нихәл!

Әлмәндәр. А-а-а... Илсур килгән. Төш әйдә минем янга, агай-эне ак мыек.

Илсур. Төшмим.

Әлмәндәр. Ник төшмисең?

Илсур. Ату, канфит бирәсең.

Әлмәндәр. Бирсә ни...

Илсур. Мин аны ашыйм да, тешем авырта.

Әлмәндәр. Кер, канфит бирмәм.

Илсур капкадан керә дә туп-туры верстак янына барып, верстак өстенә менеп кунаклый.

Йә, Илсур, агай-эне, күрешеп җибәрик. Шапылдатып күреш. *(Кулын суза, Илсур аның кулына чәпелдәтеп суга.)* Менә шулай. Инде, кил, борыныңны сөртеп куйыйк. *(Күлмәк итәген әйләндереп, Илсурның борынын сөртә.)* Менә шулай. Юкса маңкалы борын белән йөрү егетләргә килешми, кызлар сөймәс үзеңне.

Илсур. Мин аны сөртәм, ул тагын чыга.

Әлмәндәр. Йә, нинди яңа җырлар өйрәндең?

Илсур *(кычкырып җырлап җибәрә)*.

Су буенда тал-тирәк,
Тал-тирәккә су кирәк;
Кыска буйлы егетләргә
Озын буйлы кыз кирәк.

Әлмәндәр. Шәп!

Илсур *(тагын да кычкырыбрак)*.

Аклы күлмәкләр килешми
Кия белмәгәннәргә;
Сөягеңне әрәм итмә
Сөя белмәгәннәргә.

Әлмәндәр. Әйбәт! Тагын, тагын.

Илсур. Тагын әле өйрәнгәнем юк.

Әлмәндәр. Киләсе юлы күбрәк өйрәнеп кил, ярыймы?

Илсур. Ярый.

Әлмәндәр *(тәрәзә янына барып)*. Килен! Әй, килен, сиңа әйтәм!

Өммия *(тәрәзәне ачып)*. Нәрсә инде тагын?

Әлмәндәр. Кашык белән бал алып бир.

Өммия. Үләм, тирләтә, диДең бит әле генә.

Әлмәндәр. Үземә түгел.

Өммия *(Илсурны күреп)*. Бетмәс монда алар. Бөтен авыл малае безнең ишегалдында.

Әлмәндәр. Әйткәнне тыңла.

Өммия. Канфит ярамаган, бигрәк тагын — бал.

Әлмәндәр. Канфит ашаса, теше авырта аның.

Өммия. Бал ашаса, эче авыртыр.

Әлмәндәр. Канымны кыздырасың, килен!

Өммия. Соң бит, әткәй...

Әлмәндәр. Әйткәнне эшлә!

Өммия югала да кашык белән бал алып килеп, Әлмәндәргә суза.

Әлмәндәр *(Илсур янына килеп)*. Яле, агай-эне, кабып җибәр әле.

Илсур. Кирәкми.

Әлмәндәр. Нәрсә «кирәкми»? Син алай тиз үпкәләүчән булма... Егет бул, кабып җибәр. Ач әле авызыңны. *(Илсур авызын ача, Әлмәндәр бал каптыра.)* Тәмлеме?

Илсур. Әһе.

Ә л м ә н д ә р. Әһе булмаска, бал ич ул. Инде болай эшлик, кашыкка сыланганын менә монда сылап куйыйк. Кабып йоткач тиз бетә, болай озак итеп ялап йөрисең. *(Кашыкка ягылган балны Илсурның ирен кырыйларына сылый.)* Инде, бар, иптәшләрең янына йөгер.

И л с у р. Рәхмәт, бабай. *(Ирен кырыйларын ялый-ялый чыгып йөгерә.)*

Ө м м и я *(Әлмәндәрнең кыланышларын тәрәзәдән карап торган)*. Сабый да сабый, син дә сабый.

Ә л м ә н д ә р. Синең кебек тумас борын картаймам инде. Җиде бала үстереп, балалар яратмыйсың. Алар булмаса, бу дөнья ни чуртыма... Чәең бетте, чәй чыгар.

Ө м м и я. Үләм, кай арада чүмереп бетердең? Мин сиңа афисәнке түгел!

Ә л м ә н д ә р. Телең тагын озынайдымы?..

Ө м м и я. Озынайса да, кыскарса да — үз телем.

Ә л м ә н д ә р. Үз телең түгел — шайтан теле.

Ө м м и я. Булсын. Үзеңдә дә сандугач теле түгел.

Ә л м ә н д ә р. Әрепләшмә, дим минем белән. Мин сиңа каената. Кара аны, килен, матри, мин кызсам...

Ө м м и я. Кызсам дигән була... кызып нишләтерсең?.. *(Тәрәзәне ябып куя.)*

Ә л м ә н д ә р. Вәт бит, ә! Чәтелдәп тора бит. Уңмады малай, уңмады. Үземдә булса... Юк инде, үземнән дә булмады, юаш булдым. Ни беренче хатынга, ни икенчесенә кизәнгәнем булмады.

Өйдән, кулына чынаяк тотып, И с к ә н д ә р чыга.

И с к ә н д ә р. Әй-яй, тынычлап ятып торырга да бирмисең, әти. Нәрсә инде син. Кереп эчсәң булмыймы?

Ә л м ә н д ә р. Булмый. Өстәл артында дөнья онытып чәй эчеп утырырга минем вакытым юк. Син эч чәйне яткан килеш.

И с к ә н д ә р. Беләсең ләбаса, мин авырыйм.

Ә л м ә н д ә р. Чирләшкә! Япь-яшь башыңнан... Җитмеш яшендә чирләп ята!

И с к ә н д ә р *(чынаякны Әлмәндәргә биреп)*. Мин күргәннәрне күрсәң... *(Утын пүләне өстенә утыра.)*

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә күрдең?

И с к ә н д ә р. Дүрт ел буе сугышта йөрдем.

Ә л м ә н д ә р. Харап икән. Мин монда дүрт ел буе синең биш ыштансызыңны ашаттым. Һәрберсе яәҗүҗ-

мәәҗүҗ кебек, балчыкка чыкканчы ашыйлар иде. Өч ел буе прсидәтел булып синең хатының ише зобанилар белән талаштым. Аларның һәрбересе ун нимечкә тора. Сугышта йөргән, имеш...

Искәндәр. Тәнем тулы яра эзләре.

Әлмәндәр. Җүләр. Пешмәгән, шуңа күрә яра. Кулыңда пушкы була торып яраланып ят, имеш. Япон сугышында кулымда мылтык кына иде, чурт та булмады. Синең чактагы сыман пушкы артында посып ятмый идек, штык тотып, японның өстенә бара идек.

Искәндәр. Ярый инде, синең белән бәхәсләшеп буламы...

Әлмәндәр. Бәхәсләшмә дә. Ник дисәң, үзең гаепле. Авырыйм дип өйдә ятасың. Чир ул яткан кешене эзләп йөри. Эшләгән кешедән курка. Ник дигәндә, ул аңа ябышып торалмый, тир белән юылып төшә. Бар, утырма күз көеге булып, кереп ят. Чынаякларны ала кер. Хатыныңа әйт, кичкә үзе кискән токмач белән итле аш пешерсен.

Искәндәр чынаякларны алып, әкрен генә өйгә кереп китә. Әлмәндәр аның артыннан карап кала.

Шулай... Чурту-матыр, Гитлер тәресе, әрәм итте әзмәвердәй малайларны. Чирләп ята торган кешеме. Җитмеш яшеңнән әҗәл көтеп ят инде.

Әкрен генә капка ачыла, аннан Әҗәл килеп керә.

Әҗәл. Әссәламегаләйкүм!

Әлмәндәр. Әлегә мәгаләйкүм. Әйдә, түрдән уз.

Әҗәл. Узарга туры килер. *(Әлмәндәр янына килеп.)* Әлмәндәр атлы карт син буласыңмы?

Әлмәндәр. Әлмәндәре мин булам, карты кайдадыр, белмим. Кем дип белим үзеңне, күргән-сөйләшкән кешем түгел, ахрысы.

Әҗәл. Иң әүвәл кул бирешеп күрешик, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Танымаган кешемә кул бирергә ашыкмыйм мин.

Әҗәл. Шулаймы... Ярый, алайса. Ишегалдында кеше-кара юкмы?

Әлмәндәр. Нәрсә син, ышпиун кебек каранасың? Кешедән яшерен эшем юк.

Әҗәл. Син ашыкма, Әлмәндәр. *(Боерган тавыш белән.)* Соравыма җавап бир!

Әлмәндәр. Күреп торасың лабаса, үзем генә.

Әҗәл. Бик яхшы. Кил әле якынрак, утыр минем янга. *(Бүкәнгә утыра.)*

Әлмәндәр *(якын килмичә)*. Кем син?

Әҗәл. Ашыкма, дидем. Утыр. *(Әлмәндәр урыныннан кузгалмагач, үзе Әлмәндәр янына бара.)* Эшне моннан башлыйк, Әлмәндәр. *(Кесәсеннән блокнот чыгарып карый.)* Әйе, исемең синең Әлмәндәр, атаңның исеме Җиһангир, бабаң Моратхуҗа атлы. Телисең икән, җиде бабаңа хәтле санап күрсәтә алам. Моннан өч көн элек сиңа туксан бер яшь тулган. Ике тапкыр өйләнгәнсең. Кыскасы, менә бу дәфтәргә синең бөтен гомерең тәфсилләп язып куелган.

Әлмәндәр. Әкәмәт... Кем соң син?

Әҗәл. Кул бирергә теләмәдең, Әлмәндәр, инде ашыкмыйча тыңла. Бабаң — кырыкта, атаң кырык биштә дөнья куйганнар. Син нишләп туксан бергә җиттең?

Әлмәндәр. Анда синең ни эшең бар?!

Әҗәл. Бар, Әлмәндәр. Барлыгын соңрак белерсең. Соравыма җавап бир!

Әлмәндәр. Бөтен гумеремне белгәч, анысын да үзең бел. Яшисем килде — яшәдем. Синең ни эшең бар?

Әҗәл. Ха! Яшисе килгән, имеш. Кемнең яшисе килми. Ләкин кеше мәңгелеккә килмәгән.

Әлмәндәр. Туктале, чурту-матыр, син монда... Бар, үтбәләвәй, эшемне калдырып йөрмә. *(Кулына ышкы ала.)*

Әҗәл *(Әлмәндәр кулындагы ышкыга тотынып)*. Мин шаярырга килмәдем, Әлмәндәр. Мин шаяра белмим.

Әлмәндәр аптырап Әҗәлгә карап тора да кинәт артка чигенеп куя.

Әллә таныдыңмы, Әлмәндәр?

Әлмәндәр. Күргәнем бар кебек.

Әҗәл. Ялгышмыйсың, Әлмәндәр. Без синең белән өч тапкыр очраштык, монысы дүртенчесе һәм соңгысы.

Әлмәндәр. Кем соң син?

Әҗәл. Мин сине күрүгә үк таныдым. Бераз үзгәргәнсең үзгәрүен, шулай да таныдым. Без синең белән беренче тапкыр бер мең тугыз йөз бишенче елда очрашкан

идек. Япон сугышы вакытында. Син яраланып ята идең, мин сине алып китәргә килдем. Син китәргә теләмәдең. Озак көрәштек. Яшь идең шул, көчле идең, мине ектың. Ачуым килде килүен, ләкин, нишләмәк кирәк, кире борылып китәргә туры килде. Хәтерлисеңме?

Әлмәндәр. Хәтерләмим.

Әҗәл. Яхшы. Икенче очрашу бер мең тугыз йөз унбишенче елны булды. Син урман эчендә бил тиңентен сазлыкка баткан идең, пленнан качып чыгуың иде. Мин килдем. Шунда син миңа әйттең, сазлыктан чыгыйм, алып китәрсең, дидең. Мин көттем, син чыктың. Һәм чыккач йөгердең, мине алдадың.

Әлмәндәр. Син...

Әҗәл. Өченче тапкырында, бер мең тугыз йөз утызынчы елда, колхоз төзеп йөргәнең өчен кемнәрдер сәнәк белән кадаганнар иде. Син урман сукмагында ята идең. Мин тагын килдем. Ләкин Евстигней исемле бер кеше килеп чыгып, сине минем кулдан тартып алды. Таныдыңмы инде?

Әлмәндәр. Син Әҗәлме?

Әҗәл. Нәкъ үзе!

Әлмәндәр. Ник килдең?

Әҗәл. Әҗәл кешеләр янына ни өчен килә?

Әлмәндәр. Мин сине чакырмадым.

Әҗәл. Теге чакларда да син мине чакырмаган идең.

Әлмәндәр. Мин бит яралы түгел, исән-сау.

Әҗәл. Менә монысы икенче мәсьәлә. Газраилдән качып кирәгеннән артыгын яшәгәнсең. Иң күп дигәндә, син туксанга гына җитәргә тиеш идең. *(Кесәсеннән кәгазь чыгарып.)* Менә шушы урынга кулыңны куй.

Әлмәндәр. Нәрсә ул?

Әҗәл. Повестка. Шуңа кулыңны куюың була, туп-туры безнең шеф Газраил янына юнәләсең.

Әлмәндәр. Сөйләмә юкны!

Әҗәл. Мин ялган сөйләмим. Куй кулыңны, вакытым тар. План үтисем бар. Бу юлы мине ега алмассың, алдатмам да, коткарып калучы да булмас. Кулыңны куй!

Әлмәндәр *(паузадан соң)*. Вакыт җитте дисеңмени?

Әҗәл. Әйе, җитте.

Әлмәндәр. Бик тиз була түгелме соң?

Әҗәл. Нинди тиз?! Туксан бергә җит тә, тиз, имеш.

Ә л м ә н д ә р. Ярый, уйлап карармын.

Ә җ ә л. Бернинди уйлау юк. Кулыңны куй. Минем белән бәхәсләшергә, тарткалашырга уйлама. Бер генә адәм баласының да мине җиңгәне юк. Галимнәр дә патшалар да — барысы да җиңелеп киләләр.

Ә л м ә н д ә р. Эшлисе эшләрем бар бит әле.

Ә җ ә л. Бер генә адәм баласының да дөньядагы эшне эшләп бетергәне юк. Әгәр бөтен эшне син эшләп бетерсәң, синнән соң килгәннәргә эш калмас иде. Эшсезлектән гаҗиз булган кешеләр акылдан язарлар иде.

Ә л м ә н д ә р. Менә хәзер үк дисеңмени?

Ә җ ә л. Бу нинди урынсыз сорау?! Әйтәм бит, вакытым юк. Бүтән җирләргә дә өлгерәсем бар.

Ә л м ә н д ә р. Алай икә-ән…

Ө м м и я *(тәрәзәне ачып)*. Әткәй, кер әле.

Ә л м ә н д ә р. Ни булды тагын?

Ө м м и я. Нигәдер Искәндәр авырайды.

Тәрәзә ябыла.

Ә җ ә л. Нинди карчык ул?

Ә л м ә н д ә р. Мине белгәч, аны да белергә тиешсең.

Ә җ ә л. Гафу ит, кызыксынганым юк әлегә.

Ә л м ә н д ә р. Киленем.

Ә җ ә л. Искәндәр дигәне малаеңмы? Чирлиме?

Ә л м ә н д ә р. Синең җилең кагылгандыр. *(Өйгә таба бара.)*

Аңа Әҗәл иярә.

Керәсе булма өйгә!

Ә җ ә л. Карап чыгыйм, бәлки, ярдәмем кирәктер.

Ә л м ә н д ә р. Бусагадан атлыйсы булма! Колагың ишетәме? Минем янга килгәнсең, мин чыкканны көт.

Ә җ ә л. Сүзеңне тыңлыйм, Әлмәндәр. Тик озаклама, чык.

Әлмәндәр кереп киткәч, ишегалды буйлап йөренә, Әлмәндәр таслап куйган такталарны әйләндереп-әйләндереп карый, әкрен генә тәрәзә янына бара, тәрәзәгә үрелеп, өй эчен күзли, ишек ачылганны сизеп, тиз генә тәрәзә яныннан китә. Ә л м ә н д ә р өйдән чыга.

Ә җ ә л. Йә, ничек?

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә «ничек»?

Ә җ ә л. Малаең Искәндәрнең хәле ничек, дим?

Ә л м ә н д ә р. Берни булмаган. Жибадур кебек таза кешегә ни булсын. Иркәләп үстердем малайны да хәзер иркәләнеп ята. Хатыны да үзенә тиң, чебен тимәс чер итәр.

Ә җ ә л. Алдашасың бит, дус кеше, күзләреңнән күреп торам.

Ә л м ә н д ә р. Күрсәң күрерсең инде, чутыр-матыр. Йөрисең эч пошырып. *(Верстак янына барып, ышкылый башлаган тактасын ышкыларга тотына.)*

Ә җ ә л. Нишләвең, Әлмәндәр, сөйләштек ич.

Ә л м ә н д ә р . Нәрсә сөйләштек? Чуртым да сөйләшмәдек. Син сөйләдең. Мин тыңладым.

Ә җ ә л. Мин чыкканны көт, дидең, кулыңны куй.

Ә л м ә н д ә р. Куярмын, ашыкма. Тотып тор тактаның теге башыннан.

Ә җ ә л. Син минем белән алай сөйләшмә. Ачуымны чыгарма. Ачуым яман минем, мине тыңламаганнарга рәхимсез мин.

Ә л м ә н д ә р. Күзең чыкмаган булса күр, җыенам бит.

Ә җ ә л. Үләргә җыенган кеше такта ышкыламый.

Ә л м ә н д ә р. Ахмак! Минем каберемә чардуган кирәк булачакмы? Чардуган корыр өчен такта кирәкме?!

Ә җ ә л. Анысы икенче эш, әйдә, тизрәк ышкыла.

Ә л м ә н д ә р. Туксан бергә җиткәч, тиз ышкылап булмый шул. Тот, дим тактаның теге башыннан.

Ә җ ә л. Мин монда такта башы тотарга килмәдем.

Ә л м ә н д ә р. Алайса, көт. *(Такта ышкылый, үзе җыр суза.)*

Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә үлмәскә?
Син тәүбә итсәң, мин дә иттем
Әҗәл дуска кулым бирмәскә.

Ә җ ә л. Сүзеңнең кинаясенә төшенмим.

Ә л м ә н д ә р. Сүз түгел бу — җыр. Җырның җыртыгы юк. *(Эшеннән туктап.)* Син җырлый беләсеңме?

Ә җ ә л. Ышкыла, туктама. Әйдә, әйттем бит, вакытым тар, болай да озак юандым.

Ә л м ә н д ә р. Ашыктырма, арыдым… Озак яши ала карга… Адәм баласына ала карга гумере дә кызганыч диген, ә!

Ә җ ә л. Анысы минем карамакта түгел.

Ә л м ә н д ә р. Карамак, карамак. Муеның сузып минем янга син килгәнсең ич әле.

Ә җ ә л. Мыскыл итми генә сөйләшүеңне үтенәм.

Ә л м ә н д ә р. Алла-а, бигрәк әдәпле.

Әҗәл. Чардуган тактасын ышкылавыңны дәвам итүеңне үтенәм.

Ә л м ә н д ә р. Ашыксаң, үзең ышкыла.

Ә җ ә л. Андый эш белән шөгыльләнгәнем юк.

Ә л м ә н д ә р . Өйрәнерсең.

Ә җ ә л. Бу нинди тупаслык? Онытма, син мине түгел, мин сине алырга килдем.

Ә л м ә н д ә р. Укаң коелмас. Син минем гумеремне өзәргә килгәнсең әле, бер дә танавымны җыермыйм. *(Такта ышкыларга керешә.)*

Ә җ ә л . Ә син нигә үзең эшлисең? Бүтәннәр эшләр иде чардуганыңны.

Ә л м ә н д ә р. Үз эшемне кешегә калдырганым юк.

Ә җ ә л. Карап-карап торам да, бик ни күренәсең...

Ә л м ә н д ә р. Ни күренәм?

Ә җ ә л. Бик ни. Бик алай нитмә, синең кебекләрне күргән мин.

Ә л м ә н д ә р. Мин дә сине күргән.

Ә җ ә л. Аһа! Ошый башладың әле син миңа, картлач. Кайберәүләр мине күргәч мәлҗерәп төшәләр. Кул куйганда куллары калтырый. Алып китүе дә кызык түгел. Күрәм, синең белән шактый ук кызык булачак. Болай булгач көтәм, әйбәтләп ышкыла чардуганыңның тактасын.

Ә л м ә н д ә р. Карылдап торма янымда, бар, урамга чыгып утыр!

Ә җ ә л. Юк, мин синең яныңнан китмим.

Ә л м ә н д ә р. Эшләгән кеше янында торганчы, пес иткән кеше янында тор.

Ә җ ә л *(авызын зур ачып, рәхәтләнеп көлә)*. Шәп! Күптән көлгәнем юк иде. Куеп тор эшеңне, Әлмәндәр, утыр яныма. Тагын көлдер мине.

Капка ачыла, Г ө л ф и р ә керә.

Г ө л ф и р ә. Дәү бабай, мин кайттым. *(Әлмәндәр ишетмәгәч.)* Дәү бабай, дим! Мин кайттым.

Ә л м ә н д ә р *(борылып карап)*. Ай, кызым кайткан. Кил әле монда, кил, кочакла дәү бабаңны.

Г ө л ф и р ә *(йөгереп килеп, Әлмәндәрне кочаклый)*. Кычкырам — ишетмисең.

Ә л м ә н д ә р. Әҗәлетдин бабаң белән сөйләшеп тора идек.

Г ө л ф и р ә. Кем соң ул?

Ә л м ә н д ә р. Бер юньсез нәрсә инде шунда.

Г ө л ф и р ә. Алай димә, дәү бабай. Син үзең әйтәсең: кешеләргә ямьсез сүз әйтергә ярамый, дисең. Мин кайтканга сөендеңме, дәү бабай?

Ә л м ә н д ә р. Белмим инде, кызым, кем күбрәк сөенгәндер.

Г ө л ф и р ә. Мин дә, син дә...

Ә л м ә н д ә р. Теге дә.

Г ө л ф и р ә. Бабай белән әби өйдәләрме?

Ә л м ә н д ә р. Өйдәләр, кызым, өйдәләр. Әтиеңнәр ни хәлдә?

Г ө л ф и р ә. Әйбәт. Сәлам әйттеләр. Сиңа бик матур күлмәк җибәрделәр.

Ә л м ә н д ә р. Рәхмәт, кызым. Бар, инде өйгә кер.

Г ө л ф и р ә йөгереп өйгә кереп китә.

Ә җ ә л. Чибәр кыз үсеп килә.

Ә л м ә н д ә р. Күзең салма, явыз. Сиңа минем кебек ямьсезләр дә җитеп арткан.

Ә җ ә л. Әлмәндәр, бер акыл өйрәтимме үзеңә?

Ә л м ә н д ә р. Кирәкми, үз акылым җиткән. Арттан кергән акыл җил белән кире чыга.

Ә җ ә л. Ярый соң, үзеңә кара. Кызык, әйеме, Әлмәндәр, берәүләр мине көтеп торалар, мин килмим. Син көтмәдең — мин килдем. Хикмәт шунда: чакырылмаган җиргә кешеләр дә соңга калмыйча килә.

Ә л м ә н д ә р. Такылдап утырма, чурту-матыр, килгән юлыңнан кире кит.

Ә җ ә л. Ничек инде «кит»?.. Ничек аңларга?

Ә л м ә н д ә р. Шулай. Кыягазыңа кул куймыйм. Газраилең үзе килсен.

Ә җ ә л. Алай булмый.

Ә л м ә н д ә р. Була. Минем анда барырга вакытым юк. Өйләнәсем бар.

Ә җ ә л. Нишлисең бар?

Ә л м ә н д ә р. Өйләнәсем.

Ә җ ә л *(тагын рәхәтләнеп көлә)*. Әкәмәт кеше син.

Ә л м ә н д ә р. Нигә авызыңны ерасың? Әгәренки дә беләсең килсә, сугышта югалган дүрт малаемның икесе өйләнмәгән иде. Үзем өчен бер өйләндем, бер малаем өчен икенче өйләндем, икенче малаем өчен тагын бер өйләнәсем бар. Ә син, тинтәк, җанымны сорап килгәнсең.

Ә җ ә л. Гафу ит, мин сорамыйм, Әлмәндәр, таләп итәм.

Ә л м ә н д ә р. Куркытты. Әлмәндәрнең мыегы да селкенмәде.

Ә җ ә л. Алайга китсә... *(Әлмәндәр өстенә килә.)*

Ә л м ә н д ә р *(такта күтәреп)*. Килеп кара!

Ә җ ә л *(туктап калып)*. Теге чакларда кызганмаган булсам...

Ә л м ә н д ә р. Кызганма идең...

Ә җ ә л. Әлмәндәр, кызмыйча гына, сабыр гына уйлап кара әле...

Ә л м ә н д ә р. Уйларга вакытым юк. Күтәр теге такталарны.

Ә җ ә л. Нишләтәбез?

Ә л м ә н д ә р. Такта ташыйбыз.

Ә җ ә л. Кая? Нәрсәгә?

Ә л м ә н д ә р. Төпченмә. Ташып бетергәч күрерсең.

Ә җ ә л. Вәт эләктем. *(Такталар күтәрә.)*

Ут сүнә.

## Икенче күренеш

Алма бакчасы. Бакча рәшәткә белән уратып алынган. Рәшәткә яныннан сукмак үтә. Сукмактан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар. Ә л м ә н д ә р җавап бирә. Әлмәндәр белән Ә җ ә л алачык ясыйлар. Әҗәл кадаклый, Әлмәндәр тактаны тотып тора.

Ә л м ә н д ә р. Кыздыр әйдә, Әҗәлетдин, кыздыр.

Ә җ ә л. Әйтмә шул сүзеңне.

Ә л м ә н д ә р. Әйтмә, җаным, шул сүзеңне,
Йөрәгемә ярамый.

Чүкеч сабын алай тотмыйлар, сарык, бармагыңа сугасың. Менә болай тот. Әйдә, әллүр.

Әҗәл, тырышып-тырышып, такта кадаклый.

Хәзер ничек, җайлымы, Әҗәлетдин?

Ә җ ә л. Эш түгел лә бу.

Ә л м ә н д ә р. Кәҗә маеңны чыгарамыни? Шулай ул. Ярый, ял итеп ал. Йә минем урынга үзең аягыңны сузарсың. Аннары җавап тот синең өчен теге дөньяда.

Ә җ ә л. Мин үлемсез. *(Кадаклаудан туктап, фәлсәфәгә бирелә.)* Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү – зур бәхет ул. Сез кешеләр шуңа бәхетлеләр. Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин – җимерүче.

Ә л м ә н д ә р. Җимермә, кем куша җимерергә!

Ә җ ә л. Дөнья шулай корылган, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Әйдә, ярар, кадакла.

Ә җ ә л. Ял итик бераз.

Берсе – букәнгә, икенчесе алачык идәненә утыралар.

Ә л м ә н д ә р. Алып китәм, дисең инде, ә?

Ә җ ә л. Шулай итәргә туры килә, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Хәзер үк, дисең инде, ә?

Ә җ ә л. Шулай булыр инде, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Әллә соң бераз көтәсеңме?

Ә җ ә л. Күпме?

Ә л м ә н д ә р. Илле ел.

Ә җ ә л. Шаярма, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Дөньясы бигрәк әйбәтләнде бит.

Ә җ ә л. Булмый.

Ә л м ә н д ә р. Хет ун ел.

Ә җ ә л. Булмый.

Ә л м ә н д ә р. Бер ел.

Ә җ ә л. Әйтәм бит, Әлмәндәр, булмый. Ярамый.

Ә л м ә н д ә р. Бер ай, бер атна...

Ә җ ә л. Булмаганны сөйләмә.

Ә л м ә н д ә р. Соң, явыз, минем оныкларым бар, оныкларымның уллары, улларының уллары бар. Мин үлгәндә алар минем янда булырга тиеш. Минем соңгы киңәшләремне ишетеп калырга тиешләр. Алар читтә, аларга хәбәр итеп өлгерергә кирәк.

Ә җ ә л. Телеграмма сук, бүген кайтып җитәрләр.

Ә л м ә н д ә р. Сиңа җиңел. Телеграмма сук, имеш. Синнән башка белмиләр ди. Алар бит хөкүмәт эшендә.

Әҗәл. Нәрсә, министр булып эшлиләрмени?
Әлмәндәр. Ахмак. Кем булып эшләүдәмени хикмәт. Эшләгән җирләрендә алар кирәк. Аларны эшләреннән аерырга ярамый. Мин үзем алар янына барырга тиеш.
Әҗәл. Гафу ит, алай булмаячак. Сиңа мин иң күбендә чардуганыңны эшләп бетерерлек кенә вакыт бирәм.
Әлмәндәр. Базардагы сыман сатулашма инде.
Әҗәл. Эшем күп бит, Әлмәндәр. Хуҗа әйтте, озаклама, тиз алып килеп җиткер, диде. Синең аркада шелтә аласым килми.
Әлмәндәр. Бар соң, кит, бүтән эшләреңне эшли тор, вакыты җиткәч килерсең.
Әҗәл. Һәркемнең үз нәүбәте, Әлмәндәр. Әйдә, тотындык, ләкин бу юлы син кадакла, мин такта тотып торам.
Әлмәндәр. Шулаймыни?.. Әйт әле, кәҗәгә алты яшь тулгач нишли?
Әҗәл. Бу нинди мәгънәсез сорау? Кәҗәнең монда ни катнашы бар?
Әлмәндәр. Җавап бир.
Әҗәл. Мин каян белим, кәҗә асраганым юк.
Әлмәндәр. Белмәсәң бел, кәҗәгә алты яшь тулгач, җиденче яшькә чыга.
Әҗәл. Әллә ни сөйлисең.
Әлмәндәр. Әйдә, кадакла.

Рәшәткә янына Мансур килә.

Мансур. Әлмәндәр бабай, Гөлфирә кайтмадымы?
Әлмәндәр. Нигә кирәк соң ул сиңа?
Мансур. Яратам, Әлмәндәр бабай.
Әлмәндәр. Шулаймыни? Кайтмады шул әле.
Мансур. Капкагызга нindидер бер кыз кереп китте ич.
Әлмәндәр. Минем оныгымның кызы нindидер бер кыз түгел.
Мансур. Кайттымыни, Әлмәндәр бабай?
Әлмәндәр. Кайтты шул, малай.

Мансур йөгереп узып китә.

Әҗәл. Кем ул?
Әлмәндәр. Нәрсә син кеше күргән саен төпченәсең?
Әҗәл. Таныша торыйм, кирәк булып чыгуы бар.

Ә л м ә н д ә р *(йодрыгын Әҗәлнең борын төбенә китереп)*. Менә бу биштән төргәнне күрәсеңме?

Ә җ ә л. Күрәм.

Ә л м ә н д ә р. Күрсәң, әйдә, кадакла.

Ә җ ә л. Сүз әйтергә дә ярамый, хезмәтчең итеп бетердең.

Ә л м ә н д ә р. Дөрес әйтәсең, яллатып эшләтәм. Хезмәтең өчен гумерем белән түлим ич.

Икесе дә торып эшкә тотыналар. Сүзсез генә бераз эшлиләр.

Ә л м ә н д ә р. Әйт әле дөресен, Әҗәлетдин, ни өчен мин синең кәгазеңә кулымны куярга тиеш?

Ә җ ә л. Әйттем ләбаса. Син бер ел артык яшәгәнсең. Газраилнең сезнең авыл өчен язган законын бозгансың.

Ә л м ә н д ә р. Шулаймы?

Ә җ ә л. Әлбәттә, шулай.

Ә л м ә н д ә р. Ярар, сезнеңчә булсын. Мин, чуртуматыр, сезнең законыгызны бозган булып чыгыйм ди. Ә синең Газраилең бер нәрсәне беләме?

Ә җ ә л. Ни-нәрсәне?

Ә л м ә н д ә р. Минем берсеннән-берсе таза биш малаем бар иде. Кырык беренче елда бишесе дә сугышка киттеләр. Дүртесе кайтмады. Иң олысына — утыз алты, иң кечесенә егерме яшь иде. Әгәр дә синең Газраилең безнең авыл кешеләренә туксаннан узарга рөхсәт бирми икән, нигә минем малайларымның туксанга җиткәнен көтмәгән?

Ә җ ә л. Анысы минем эш түгел бит, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Әһә, синең эш түгелме?! Китереп терәгәч, синең эш түгелмени?

Ә җ ә л. Сугышны адәм балалары үзләре чыгаралар.

Ә л м ә н д ә р. Адәм балалары түгел, адәм актыклары чыгара. Синең Газраилең ни өчен сугыш чыгаручыларның җанын алмый?

Ә җ ә л. Алды.

Ә л м ә н д ә р. Ничаклы яхшы кешеләрнең башына җиткәчме? Сугыш чыгарырга җыенуларын күрүгә үк муеннарын борырга иде аларның.

Ә җ ә л. Бик эчкәрегә кермә, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Кермәме?! Кермим алай булса, чыгам. Бар, Газраилеңә кайтып әйт, Әлмәндәргә үләргә иртәрәк, диген. Дүрт баласы яшәячәк гумерен яшисе бар әле аның,

диген. Киметеп санаганда йөз утыз ел. Мин нәфесле түгел, миңа тагын утыз-кырык ел җиткән. Шуннан соң килерсең. Дөрес әйтәмме?

Әҗәл. Соң, үзеңчә дөрестер дә инде ул... Әмма дә ләкин сабыр гына уйлап кара әле, Әлмәндәр. Тагын, әйтик, утыз ел яшәдең ди. Ул яшәүнең ни кызыгы? Кемгә кирәк син?

Әлмәндәр. Шаярма, Әҗәлетдин. Үзең ишеттең, присидәтел, лифкавай машинасы белән бакча янына туктап нәрсә диде? Печән өябез, нигә эскерт башында торырга чыкмадың, Әлмәндәр бабай, дидеме?

Әҗәл. Ул бит аны көлеп әйтте. Күреп тордың, елмайды.

Әлмәндәр *(көлеп)*. Тагын эләктең, Әҗәлетдин. Кеше мине күреп елмая икән, мин кирәк дигән була. Минем яннан елмаеп киткәч, бүтәннәр янында да елмая ул. Аның елмайганын күреп, бүтәннәр дә елмая. Минем аркада ничаклы кеше елмая. Шуннан соң кирәк булмыйммы инде мин?

Әҗәл. Өйләнәм диюең нәрсә инде? Туксан бер яшьлек картка кем чыксын?

Әлмәндәр. Чиләгенә күрә капкачы табыла.

Әҗәл. Ярый, табылсын да ди. Өйләндең дә ди. Ни кызыгы инде?

Әлмәндәр. Әй, агай-эне. Аның кызыгын өйләнгән кеше үзе генә белә.

Әҗәл. Мактанасың ла инде.

Әлмәндәр. Мактанса ни. Ир мактаныр, корал эшләр. *(Шак иттереп чүкеч белән кадакка сугып куя да.)* Әйдә, утыр, ял итеп алыйк.

Рәшәткә янына Илсур килә.

Илсур. Бабай, нихәл!

Әлмәндәр. А-а... Илсур. Кер әйдә, кер.

Илсур. Кермим, корт чага.

Әлмәндәр. Балыңны ялап бетердеңме соң?

Илсур. Бетте шул.

Әлмәндәр. Алайса, чакмый. Кер.

Илсур. Минем бал ашыйсым килми.

Әлмәндәр. Нәрсә ашыйсың килә?

Илсур. Алма. Өчне бир. Илдус белән Ринатка да.

Әлмәндәр. Нигә үзләре килмәде?

И л с у р. Вакытлары юк. Су буенда каз сугыштыралар.
Ә л м ә н д ә р. Хәзер, алай булса, хәзер. *(Түбәтәенә алма тутырып, Илсур янына бара да алманы Илсурның күлмәк итәгенә бушата.)*
И л с у р. Җырлыйммы?
Ә л м ә н д ә р. Ашыгасың бит.
И л с у р. Ә син нәрсә ясыйсың?
Ә л м ә н д ә р. Дача.
И л с у р. Нәрсәгә ул?
Ә л м ә н д ә р. Йокларга.
И л с у р. Төнлә дәме?
Ә л м ә н д ә р. Төнлә, билгеле. Көндез кеше йоклап ятамы?
И л с у р. Курыкмыйсыңмы?
Ә л м ә н д ә р. Нәрсәдән куркасың ди. Бар инде, йөгер, иптәшләрең көтәдер.
И л с у р. Рәхмәт, бабай! *(Чыгып йөгерә.)*
Ә л м ә н д ә р *(алачык янына килеп)*. Шуларны калдырып ничек инде якты дөньядан китәсең. Миннән башка нишләрләр? Укытып чыгарасы бар, өйләндерәсе бар...
Ә җ ә л. Бер айдан ук онытачаклар.
Ә л м ә н д ә р. Онытырлар микән?.. Онытсалар ни. Нишләтәсең, һәркемнең үз юлы. Шул юлдан барганда бүтәннәрне генә төртеп екмасын.
Ә җ ә л. Карале, Әлмәндәр! Син, чардуган корабыз, дидең, тагын алдаштың. Дача салып ятасың икән ич. Нәрсәгә ул, дип сорагач, йокларга, дидең.
Ә л м ә н д ә р. Тинтәк! Әҗәлнең ни икәнен белмәгән сабыйга каберем өстенә чардуган дип ничек әйтәсең. Мин сабыйлар белән сөйләшкәндә, син кысылма.
Ә җ ә л. Шунысы да аңлашылмый, чардуганны нигә бакчага корасың, зират бар.
Ә л м ә н д ә р. Үлмәс борын зират өстендә чардуган корганымны күрсәләр, кешеләр ни уйлар? Үзләре дә чардуган өчен такта ярдыра башларлар. Нигә аларны ашыктырырга.
Ә җ ә л. Һич кенә дә сүз табып булмый сиңа.
Ә л м ә н д ә р. Тапмасаң, тик утыр.
Ә җ ә л. Бик утырасы да бит... Нишләргә инде синең белән? Усаллансам, шык та итә алмыйсың алуын. Тик әллә нигә, усалланасым килми.

Ә л м ә н д ә р. Тукта!.. Хәмдебану килә. Миңа хатын булырга тиешле карчык. Син, Әҗәлетдин, читкәрәк авышып тор. Мин Хәмдебану белән сөйләшкәндә килеп комачау итмә. Мин сүземне сүз итәргә тиеш. Ризалыгын бирсен. Өйләнәмме, өйләнмимме — анысын күз күрер.

Ә җ ә л. Сабый булма, соңгы сәгатьләреңдә үзеңнән көлдермә.

Ә л м ә н д ә р. Юк, әлеге көнгә хәтле, шушы яшемә җитеп, сүземне аста калдырмадым. Хатын-кыздан көлдермәдем.

Ә җ ә л. Хәмдебану ризалыгын бирсә, минем кәгазьгә кулыңны куясыңмы?

Ә л м ә н д ә р. Карарбыз.

Ә җ ә л. Өзеп әйт, юкса комачаулыйм.

Ә л м ә н д ә р. Бәйләнчек эт булдың. Куйсам куярмын инде, чурту-матыр, мәтәлеп кит.

Ә җ ә л. Бар, алайса, тәвәккәллә.

Рәшәткә янында Х ә м д е б а н у күренә, Әлмәндәр рәшәткә янына килә.

Ә л м ә н д ә р. Хәмдебану!

Хәмдебану җавап бирми үтеп киткәч.

Хәмдебану, әллә үпкәләдеңме?

Х ә м д е б а н у *(борылып килеп)*. Үпкәләмәскә соң, Әлмәндәр абзый, тузга язмаганны. Үземнән үзем оялып йөрим. Андый сүзне ишетмәгәнемә утыз ел. Башка берәү шулай дип әйтсә, таяк белән башын бәреп ярыр идем.

Ә л м ә н д ә р. Миңа ник сукмадың?

Х ә м д е б а н у. Сүзләрең тозсыз булса да, эчеңдә явызлык юк синең, Әлмәндәр абзый.

Ә л м ә н д ә р. Рәхмәт сүзеңә, Хәмдебану. Телең бигрәк татлы инде, шундый әйбәт итеп әйттең. Миңа кияүгә чыгарга ризалыгыңны да бирсәң...

Х ә м д е б а н у. Син әле һәмишә...

Ә л м ә н д ә р. Кызма, кызма, Хәмдебану. Тозсыз сөйләсәм дә, юк сүз сөйләмим. Ниятем чын.

Х ә м д е б а н у. Бирермен менә ниятеңне таяк белән башыңа.

Ә л м ә н д ә р. Беренче тапкырында сукмагач, икенчесендә сукмассың инде.

Х ә м д е б а н у. Түзәрмен, түзәрмен дә...

Ә л м ә н д ә р. Түзәрсең, түзәрсең дә ризалыгыңны бер бирерсең, Хәмдебану. Ялгыз башка тормыш алып барулары читен.

Х ә м д е б а н у. Аллага шөкер, кешегә сынык сорап кергәнем булмады. Пинсем җитә.

Ә л м ә н д ә р. Шул пинсе түләп бозып бетерделәр карчыкларны. Тамагың ачыкса, үзең эзләп керер идең Әлмәндәрне.

Х ә м д е б а н у. Мыскыл итмә.

Ә л м ә н д ә р. Мыскыл итмим, кызганам, Хәмдебану.

Х ә м д е б а н у. Кызганма да. Кызганыч көнгә калганым юк.

Ә л м ә н д ә р. Калгач соң булыр. Хәзер картайдың, өч аяклап йөрисең. Чирләп китеп урын өстенә егылсаң, янында кем утырыр? Ярый ла Әҗәл тиз килсә. Килми интектерсә нишләрсең?

Х ә м д е б а н у. Куркытма. Заманасы ул түгел, ялгызымны калдырмаслар.

Бакча ягына Ө м м и я чыга. Хәмдебану белән Әлмәндәрнең сөйләшеп торганнарын күреп, колак сала.

Ә л м ә н д ә р. Бигрәк кире беткән хатын булдың. Өзеп әйтәсең инде, алайса? Миңа кияүгә чыкмыйм, дисең.

Х ә м д е б а н у. Әйттем бит, юк сүзне сөйләмә, Әлмәндәр абзый. Гумерең буе миңа бәйләндең. Башта бүтәннәргә димләдең, хәзер үзеңә. Шаярып әйтәсеңдер дисәм, чынлап икән.

Ә л м ә н д ә р. Яшьрәк чагыңда яшьрәкләр кирәк иде сиңа. Картайгач — мин дә бик әйбәт. Ныклап уйла, Хәмдебану.

Х ә м д е б а н у. Уйлыйсы-нитәсе юк. Үзеңнән биздерәсең килмәсә, бүтән бу сүзеңне сөйләмә, Әлмәндәр абзый. *(Кузгалып китә.)*

Ә л м ә н д ә р. Риза булсаң, килеп әйтерсең, ялынып бармам. Чынлап әйтәм, Хәмдебану. Бик ныклап уйла. *(Хәмдебану киткән якка карап кала. Өммиянең кычкырып көлеп җибәрүеннән сискәнеп китә.)*

Ө м м и я. И-и-и... И Аллам! И Ходаем! Үләм, үләм!.. Тагынниләр кыланырсың икән?

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә авызыңны ердың? Әллә тыңлап тордыңмы?

Ө м м и я. Үләм, үләм... Бөтен урамга шар ярып сөй-

ләшеп тора да, тыңлап тордыңмы, дигән була. Нәрсәгә такта турый, ни кыланырга җыена дисәм, башка чыгарга йөри икән. Үләм, үләм…

Әлмәндәр. Үлсәң үләрсең, мин үләргә җыенмыйм.

Өммия. Әйтәм, малаеңа кереп әйтәм, урамга чыгып кычкырам, белсеннәр кем икәнеңне.

Әлмәндәр. Нәрсә, нәрсә очынасың? Матри, килен!

Өммия. Әйтәм, Искәндәргә кереп әйтәм. *(Кереп китә.)*

Әлмәндәр *(аның артыннан кычкырып кала)*. Килен!

Әҗәл. Күрдеңме инде, Әлмәндәр?

Әлмәндәр. Нәрсә «күрдеңме», нәрсә син дә авызыңны ерасың?

Әҗәл. Көләләр үзеңнән, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Белмичә көләләр, аңламыйча көләләр.

Әҗәл. Аңламаслык берни дә юк. Көлдермә үзеңнән, әйдә, кулыңны куй да, китик тизрәк.

Әлмәндәр. Хәмдебану ризалыгын бирмәде, тыңлап тордың.

Әҗәл. Аның ризалык биргәнен көтсәң… Булмаганны өмет итмә.

Өммия, Гөлфирә, Искәндәр бакчага чыгалар. Гөлфирә Искәндәрне култыклаган, үзе көлә.

Өммия. Күрегез әнә, үзеннән сорагыз. Менә шушы урында унсигез яшьлек егетләр кебек сайрап торды.

Искәндәр. Әти, нишләвең инде тагын?

Әлмәндәр *(Өммия каршына атылып барып)*. Теңкәмә тидең, явыз килен!

Өммия. Үләм, үләм!.. *(Үзе Әлмәндәрдән кача.)*

Гөлфирә *(Өммияне куып йөргән Әлмәндәрне кочаклап алып)*. Дәү бабай, дәү бабай, ярамый.

Әлмәндәр. Җибәр, кызым. Азды, әбиең азды.

Гөлфирә. Ярамый, ярамый. Син бит бик акыллы, бик әйбәт дәү бабай. Әби ялгыша. Кил, утыр, тынычлан.

Өммия *(Гөлфирәгә)*. Син нәрсә аның сүзен сөйлисең? Кем ялгыша?

Гөлфирә *(Өммияне барып кочаклап)*. Юк, әбием, ялгышмыйсың, син дә дөрес сөйлисең. *(Әлмәндәрнең утырган урыныннан сикереп торганын күреп, аның янына килә.)* Юк-юк, дәү бабай, син бик әйбәт. Бөтенегез

дә бик әйбәт. Мин сезнең барыгызны да сагынып кайтам. Килегез, барыгыз да тезелешеп утырыгыз.

Өммия. Утырасым да килми. Үзе генә җитмәгән, безне адәм көлкесенә калдырырга җыена. Үләм, үләм... Өйләнәм, ди бит, өйләнәм, ди.

Гөлфирә. Өйләнсә ни булган?

Искәндәр. Син, кызым, тик тор. Син бернәрсә дә аңламыйсың әле.

Гөлфирә. Ничек инде аңламыйм! Бабай ялгыз яши. Өйләнсә, ни гаебе бар?

Өммия. Ничек «ялгыз яши»? Ә без?

Гөлфирә. Сез икәү. Бабай – синең картың, син – бабайның карчыгы. Дәү бабай ялгыз.

Әлмәндәр. Рәхмәт, кызым. Менә алар җитмештән узып та шуны аңламыйлар.

Искәндәр. Алай түгел ул, әти. Өйләнмәдең түгел, өйләндең. Әнкәй вафат булгач ун ел да йөрмәдең, өйләндең бит, сүз әйтмәдек.

Әлмәндәр. Кем әйтмәде? Хатының әйтмәдеме?

Өммия. Әйтмәдем, ул чакта тел яшерә идем.

Әлмәндәр. Иреңнең колак итен ашадың. Әллә мин ишетмәдемме?

Искәндәр. Ярый, анысы булган-беткән. Инде хәзер, йөз яшеңә җиткәндә.

Әлмәндәр. Син, малай актыгы, минем яшьне санама.

Гөлфирә *(Искәндәргә)*. Син, бабай, дөрес әйтмисең. Йөз яшеңә җиткәндә димә, йөз яшеңә дә җитмәгән килеш, диген. Сиңа, дәү бабай, чыннан да өйләнергә иртәрәк. Йөзгә җиткәч була.

Өммия. Котыртып утырма. Сиңа көлке. Әтиеңә хат язып җибәрермен менә. Монда кайтып дәү бабасын котыртып йөри, дип. Аның белән без изаланабыз, син түгел.

Искәндәр. Әти, әйдә әйбәтләп сөйләшик... Бүтән чакта синең сүздән чыкмыйбыз, безнең өйдә син хуҗа. Киленең Өммия дә синең каршыңда биеп тора. Ни әйтсәң, шуны тыңлый.

Әлмәндәр. Бик тыңлый инде, тыңлый хатының.

Искәндәр. Ярый, кызма. Өр-яңа такталарны турап, бер дә кирәкмәгәнгә бакча уртасына алачык корырга тотынганың өчен сүз әйтмәдек.

Ә л м ә н д ә р. Әллә әйтер идеңме?

И с к ә н д ә р. Тыңлап бетер инде.

Ө м м и я. Искәндәр авыру, нигә аны борчыйсың.

Ә л м ә н д ә р. Ата белән бала сөйләшкәндә син кысылма!

И с к ә н д ә р. Бар, Өммия, өйгә керегез. Без икәү генә сөйләшик.

Ө м м и я. Сине тыңлыймы ул?! Сине ул олы кешегә санамый.

Гөлфирә көлеп җибәрә.

Нигә бертуктаусыз көләсең? Сабый бала түгел, акыл керергә вакыт.

Г ө л ф и р ә. Кызык ич.

Ө м м и я. Сиңа кызык кына булсын.

Г ө л ф и р ә. Дөнья кызык булгач начармыни?

Ө м м и я. Дәү бабаң гомере буе кызык-кызык дип яшәде. Хәзер, күрәсең, нишли. Аңа кызык — безгә оят. Әйдә, керәбез.

Г ө л ф и р ә. Өйгә керәсем килми. Дәү бабай янында утырасым килә. Дәү бабай, синең яныңда утырыйммы?

И с к ә н д ә р. Гөлфирә, олылар әйткәнне тыңла.

Г ө л ф и р ә. Кайчан картаермын, мин әйткәнне дә тыңларлар иде. Әйдә, әбием. *(Өммияне култыклап ала.)*

Кереп китәләр.

И с к ә н д ә р. Менә шулай, әти.

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә «шулай»?..

И с к ә н д ә р. Шулай.

Ә л м ә н д ә р. Нәрсәнең шулай икәнен белмисең бит, улым. Хатының да әйтә, кызык-кызык дип кенә яшәде, ди. Кызыкның нәрсә икәнен белми, мәгънәсенә төшенми. Син дә аңа кушылып мине ачуланасың.

И с к ә н д ә р. Ачуланмыйм, әти.

Ә л м ә н д ә р. Ачулансаң да үпкәләмим. Дүрт энең дә кайтып, бишәүләп ачулансагыз, сөенер генә идем. Хәлең ничек?

И с к ә н д ә р. Юк ла инде, беткән.

Ә л м ә н д ә р *(кинәт үзгәреп)*. Зарланма! Зарланасы булма!

И с к ә н д ә р. Үзең сорыйсың бит.

Ә л м ә н д ә р. Яхшы диген. Көл! Җырла! Бие! «Шулай»ның мәгънәсе шунда, кызыкның да мәгънәсе шунда. Әгәр син зарлана дип мин зарлансам, син сукрана дип мин сукрансам ни була... *(Урыныннан торып.)* Бераз гына утырып тор.

И с к ә н д ә р. Кая барасың?

Ә л м ә н д ә р. Үзем беләм. *(Чыгып китә дә бераздан бер чирекле шешәне кочаклап керә.)* Кил ышыккарак.

И с к ә н д ә р. Ансыз гына сөйләшик.

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә сөйлисеңне беләм, минем ни әйтәсемне син дә беләсең. Әчегән бал эчеп, җырлашып утырсак, икебезгә дә шифасы тияр. Рамнарны кырып ясап куйган идем, өлгерүе җиткәндер. *(Алмагач ботагына элеп куйган кружканы алып, Искәндәр янына чүгәләп утыра.)* Теләсәң ни әйт, хатының усал. Шушы чиреклене өйгә керттерми бит тәки. Нәрсәсе бар инде. Бал бит бу, чын бал. Аракыны, үзең беләсең, үзем дә өйгә кертмәдем. *(Кружкага бал салып.)* Яле, тотып куй.

И с к ә н д ә р. Авырайтмас микән?

Ә л м ә н д ә р. Атаң кушкач авырайтмас.

Искәндәр балдан авыз итә дә кружканы Әлмәндәргә суза. Әлмәндәр кружкада калган балны эчеп бетерә.

Менә шулай, улым.

И с к ә н д ә р. Нәрсә шулай?

Ә л м ә н д ә р. Үләргә ашыкма, дим.

И с к ә н д ә р. Мин ашыкмыйм да бит...

Ә л м ә н д ә р. Ашыгасың. Син әле дүрт энекәшең өчен дә яшәргә тиеш. Кызык менә шунда була: сиңа Әҗәл килеп әйтә, Искәндәр, саубуллаш дөнья белән, ди. Барыбер зарланып ятасың, ди. Син үзең дә, болай интегеп яшәгәнче дип, риза буласың. Риза булмаска кирәк. Алдарга кирәк Әҗәлне.

И с к ә н д ә р. Алдарсың аны.

Ә л м ә н д ә р. Ә син алда. Җаен тап. Моның вакыты җиткән дип, Әҗәл килә. Куркыткан була. Ә син сер бирмисең. Ул синең белән мәшәкатьләнгән арада, көн үтә, бүтәннәр янына барырга соңга кала, синең аркада бүтәннәр дә озаграк яшәп кала. Менә шулай...

Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Кунган җирең кайсы имәндә?
Син башың исән дә, мин имәдем,
Башкаема хәсрәт килгәндә.

Кушылып җырла миңа, улым.

Искәндәр. Хәлем юк.

Әлмәндәр. Җырла!

Искәндәр. Ала карга дигән, әй, асыл кош... Булмый, әти.

Әлмәндәр. Пешмәгән арыш чумары! Боламык! *(Паузадан соң.)* Әй, улым... *(Өстеннән казакиен салып җиргә җәя.)* Таянып тор.

Искәндәр. Өйгә керим.

Әлмәндәр. Сөйләшмәдек бит әле, улым.

Искәндәр. Булды, әти, сөйләштек. *(Утырган урыныннан торырга азаплана, булдыра алмый. Әлмәндәр аңа ярдәм итмәкче булып кулыннан тота.)* Үзем. *(Көч-хәл белән торып, өйгә таба атлый.)*

Әлмәндәр. Хатыныңа әйт, бераздан миңа чәй чыгарсын. *(Искәндәр артыннан карап калып җыр суза.)*

Ала карга дигән, әй, асыл кош...

Әҗәл. Аңлашылды, Әлмәндәр.

Әлмәндәр. Ни аңлашылды, Әҗәлетдин?

Әҗәл. Үз хәйләңне үзең ачып бирдең. Һаман мине алдап йөртәсең. Килешми, Әлмәндәр. Яхшылыкка яманлык белән кайтарасың. Алайга китсә... Куй хәзер үк кулыңны. Куй, боргаланып маташма, картлач.

Әлмәндәр. Нәрсә җикеренәсең? Куймыйм дигәнем юк. Китер кәгазеңне.

Әҗәл *(кесәсеннән кәгазь алып, Әлмәндәр каршына җәеп сала)*. Аңлашылырлык итеп куй.

Әлмәндәр. Кайсы җиренә? Шушындамы?

Әҗәл. Шунда.

Әлмәндәр. Яза белмим бит мин, Әҗәл дус.

Әҗәл. Хәйләләмә. Председатель булып эшләдең.

Әлмәндәр. Соң, җаным-бәгырем, вакыты шундый иде.

Әҗәл. Кил, кулыңнан тотып яздырам.

Әлмәндәр. Орынма. Әлмәндәр дип искечә яза беләм. Тик аз гына сабыр ит, бал кабып куйыйк.

Әҗәл. Капмыйсың, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Балдан ни була?

Ә җ ә л. Өйрәнеп алдым мин сине. Бал кабам дип, этлек эшләргә җыенасың.

Ә л м ә н д ә р. Юк ла инде. Нәрсә син ул чаклы? Кил, утыр, торма каршымда тасраеп. *(Кружкага бал салып.)* Йә, тотып куй минем исәнлеккә.

Ә җ ә л. Юк, юк... Беренчедән, миңа ярамый, икенчедән, ничек инде синең исәнлеккә эчим ди? Мин бит синең янга исәнлек-саулык теләп килмәдем.

Ә л м ә н д ә р. Минем җаным өчен тот, алайса. Озакка сузма, кул да куясы бар.

Ә җ ә л. Шулай дисәң генә. *(Кружкадагы балны эчеп куя.)*

Ә л м ә н д ә р. Менә шулай. *(Үзенә дә салып эчә.)* Менә шулай. Ничек, әйбәтме?

Ә җ ә л. Беләм инде, син начар нәрсә эчмисең.

Ә л м ә н д ә р. Шулай шул. Тот тагын берәрне. Әйдә, бер утырган — бер гумер. Син мине бүтән күрмәячәксең. Сагынып сөйләрлек булсын.

Ә җ ә л. Аз гына сал.

Әлмәндәр салып бирә, Әҗәл эчә. Әлмәндәр дә салып эчә.

Ә л м ә н д ә р. Әйдә, хәзер рәхәтләнеп сөйләшеп утырыйк.

Ә җ ә л. Әйттем бит, этлек эшлисең, дип.

Ә л м ә н д ә р. Йә инде, Әҗәл дус. Күпкә түзгәнне азга түз инде. Җырлыйммы?

Ә җ ә л. «Ала карга дигән асыл кош»ны җырлама.

Ә л м ә н д ә р. Ошамыймыни?

Ә җ ә л. Әллә нинди, шомлы.

Ә л м ә н д ә р. Әһә, шомлыны син дә яратмыйсың икән. Аңламыйсың син, тиле, җырның ни икәнен. Әлмәндәрнең үз гумерендә шомлы җыр җырлаганы юк. Ярый, мәтәлеп кит, чурту-матыр, бүтәнне җырлыйм.

Мин җырлыймын бырдыйны —
Бырдый белән шырдыйны;
Мин җырлаганны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Йә, ничек?

Ә җ ә л. Ярый.

Ә л м ә н д ә р. Яраса тыңла.

Мин җырлыймын бырдыйны —
Бырдый белән шырдыйны;
Җырламас идем шырдыйны,
Тыңлаучысы шыр тиле.

Монысы ничек?

Әҗәл. Мин, Әлмәндәр, синең янга килгәннән бирле гел синең сүзеңнән чыкмый йөрим, әйеме? Син гел мине мыскыл итәсең, әйеме? Гел миннән көләсең, әйеме? Ярамый бит болай, агай-эне. Ярамый болай, Әлмәндәр дус. Яратам бит мин сине. Яратмаган кеше белән араны тиз өзәм мин.

Әлмәндәр кычкырып көлеп җибәрә.

Йә, нигә көләсең, ә, нигә көләсең?

Әлмәндәр. Көлке.

Әҗәл. Нәрсәсе көлке. Йә, нәрсәсе көлке инде?

Әлмәндәр. Үлемне әйтәм. Үлем көлке.

Әҗәл. Көлке түгел, Әлмәндәр дус.

Әлмәндәр. Көлке. Адәм баласы ыспутникка утырып җиде кат күктә җыр көйләп йөри, Газраилнең маңгаена чиертеп үтә, җиргә төшә дә юктан гына үлеп китә. Көлке булмый ни булсын. Эх, чурту-матыр, дөбер-шатыр... Миңа ярый да инде... Япь-яшь егетләр бит, жибадур кебек егетләр!.. *(Русча җырлап җибәрә.)*

Ассалуди, былгаруди
Гулять иттек кыз белән...

Аңлыйсыңмы: ассалуди, былгаруди. Беләсеңме син ул сүзне? Белмисең. Ә мин беләм.

Әҗәл. Яратам мин сине, Әлмәндәр дус. Валлаһи дип әйтәм, тимәс идем мин сиңа... Нишлим... Кил, Әлмәндәр дус, кочаклап үбим бер үзеңне.

Әлмәндәр. Анысы булмый, Әҗәлетдин.

Әҗәл. Яратмыйсың син мине, Әлмәндәр, беләм. Дошман күрәсең. Эх!.. *(Әлмәндәрнең казакие өстенә ава да гырлап йокыга китә.)*

Әлмәндәр, аның янына килеп, йоклаганмы-юкмы икәнен карый. Әҗәлнең йоклаганлыгына ышангач, казакиен тартып алып, шыпан гына бакчадан чыгып ычкына.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Интермедия

Прологтагы күренеш. Сәхнәдә Газраил белән Фәрештә.

Газраил. Бер мең биш йөз илленче номерлы Әҗәлдән хәбәр юкмы?

Фәрештә. Юк.

Газраил. Нишләп йөри ул? Унике сәгать вакыт үтте. Әлмәндәр һаман да исән. Нәрсә бу?

Фәрештә. Белмим. Бәлки, Әлдермеш авылын таба алмый йөридер.

Газраил. Юкны сөйләмәгез. Кесәсендә Җир өстенең картасы бар.

Фәрештә. Сез булып сез дә картадан Әлдермешне таба алмадыгыз.

Газраил. Күп белмәгез. Барыгыз, эшегездә булыгыз!

Фәрештә китә, Әҗәл керә.

Әҗәл. Мөмкинме?

Газраил. Һә, кайткан. Кайда Әлмәндәр?

Әҗәл *(башын аска иеп)*. Юк.

Газраил. Ничек «юк»?

Әҗәл. Кызгандым мин аны.

Газраил. Нәрсә-ә?!

Әҗәл. Кызгандым. Жибадур кебек тап-таза, менә дигән кеше.

Газраил. Нинди жибадур?

Әҗәл. Әлдермеш авылында «живодёр» дигән сүзне үзгәртеп, «жибадур» диләр. Ләкин яхшы мәгънәдә кулланалар. «Болото» дигән сүзне «мулата» диләр. «Во саду ли в огороде» дигән җырны «Ассалуди былгаруди» дип җырлыйлар.

Газраил. Син нәрсә лыгырдыйсың?

Әҗәл. Лыгырдамыйм, дөресен әйтәм. Әлмәндәр үзе җырлады. «Ассалуди былгаруди гулять иттек кыз белән» дип җырлады.

Газраил *(Әҗәл каршына атылып килеп)*. Син!.. Син Әлмәндәрне алып киләсе урынга җыр өйрәнеп яттыңмы?! Бу ни бу?! Нәрсә бу?! *(Шулвакыт телефон шалтыраган тавыш ишетелә. Газраил кесәсеннән*

*телефон трубкасын ала.)* Әйе, тыңлыйм. Хәзер. Шуны да миннән башка эшли алмыйсыз. *(Әҗәлгә.)* Беркая да китмичә шушында мине көтеп утыр. *(Тиз генә чыгып китә.)*

Фәрештә керә.

Фәрештә. Эләктеме?

Әҗәл. Булды бераз.

Фәрештә. Нигә соңладың?

Әҗәл. Син дә сорау алма әле.

Фәрештә. Ә мин беләм.

Әҗәл. Нәрсә беләсең?

Фәрештә. Син Әлмәндәр картны югалттың.

Әҗәл. Каян беләсең?

Фәрештә. Минем белмәгәнем юк.

Әҗәл. Кайда ул Әлмәндәр?

Фәрештә. Әйтимме соң?

Әҗәл. Нәрсә чытлыкланасың? Минем хәлне күреп торасың ич.

Фәрештә. Күреп торам. Мин күп нәрсәне күреп торам. Һәм... һәм шулар өчен син миңа бурычлы. Бүген кәгазьләрне актарып утырганда, синең тагын бер кыңгыр эшеңне күреп алдым. Моннан 70, 60 һәм 45 ел элек шеф сине өч тапкыр Әлмәндәр янына җибәргән булган. Син...

Әҗәл. Әкрен.

Фәрештә. Ни өчендер ул чакта бу этлегеңне Газраил сизми калган... Хәзер оныткан.

Әҗәл. Әкрен, дим.

Фәрештә. Курыкма, мин аңа әйтмәдем.

Әҗәл. Әйтергә иде.

Фәрештә. Мин әләкче түгел. Газраилгә баш бирергә теләмәвең өчен мин сине хөрмәт итәм.

Әҗәл. Рәхмәт. Хөрмәт иткәч әйт, кайда Әлмәндәр?

Фәрештә. Антоновка авылында. Евстигней исемле карт янында.

Әҗәл *(карта каршына барып, Антоновка авылын эзләп таба)*. Кара, карт төлке, кая сызган. Рәхмәт сиңа. Бу юлы ычкына алмассың, Әлмәндәр.

Фәрештә. Ни өчен син Әлмәндәр картны яклыйсың?

Әҗәл *(кинәт кызып)*. Яклыйм?.. Әйе, яклыйм! Хакым юкмы әллә?! Әгәр беләсең килсә, җанкисәгем, дөнья үлемнән генә тормый. Туйдым! Әгәр кулымнан

килсә, мин үзем Әлмәндәр урынында булыр идем. Без кемнәр синең белән? Үлемсез булуыбыздан ни мәгънә? Безнең бар белгәнебез: кайгы, хәсрәт, күз яшьләре.

Ф ә р е ш т ә. Оһо! Син үзгәреп кайткансың.

Ә җ ә л. Кызганычка каршы, үзгәрә алмыйм. Үзгәрә алсам, Әлмәндәр картны Газраил кулына бирмәс идем.

Ф ә р е ш т ә. Әлмәндәр дә Әлмәндәр, дисең. Кем соң ул? Галимме? Искиткеч бер ачыш ясаганмы? Танылган җырчымы?

Ә җ ә л. Юк.

Ф ә р е ш т ә. Әллә берәр футболистмы йә булмаса хоккеистмы?

Ә җ ә л. Юк.

Ф ә р е ш т ә. Әллә...

Ә җ ә л. Юк.

Ф ә р е ш т ә. Бәлки...

Ә җ ә л. Юк.

Ф ә р е ш т ә. Кем соң, алайса? Нәрсә эшләгән?

Ә җ ә л. Берни эшләмәгән. Гап-гади кеше. Ләкин гомере буе яшәүнең кадерен, тәмен белеп яшәгән кеше. Иң авыр чакларда да тормыштан ямь таба белгән, күңел көрлеген югалтмаган кеше. Ул — авылның шатлыгы, өмете. Аны күреп сөйләшкән кеше кайгысын оныта. Мин дә Әлмәндәр карт яшенә җитәрмен дип өметләнә. Азмы болар? Хәер, без нәрсә аңлыйбыз соң!

Ф ә р е ш т ә. Ә нигә аңларга? Аңламау, бәлки, хәерлерәктер.

Ә җ ә л. Бәлки, бәлки. Шулай да...

Ф ә р е ш т ә. Ләкин шуны бел: хуҗа бу юлы онытмаячак.

Ә җ ә л. Аңладым.

Ф ә р е ш т ә. Килә... Мин сине хөрмәт итәм, шуңа күрә кисәтергә уйладым. *(Чыгып китә.)*

Г а з р а и л *(керәп)*. Бар хәзер Әлдермешкә. Әлмәндәрсез борылып кайтсаң, күрсәтермен «ассадули былгаруди»еңны.

Ут сүнә.

## Өченче күренеш

Антоновка авылындагы Евстигней картның бакчасы. Пәрдә ачылганда, Евстигней умарта карап йөри. «Ястәгнәй! Знакум!» дигән тавышны ишетеп, битлеген күтәрә.

Әлмәндәр *(үзе күренми)*. Ястәгнәй! Знакум!

Евстигней. Кем ул анда?

Әлмәндәр. Кто такуй, знаешь? Не знаешь — маклашка дам.

Евстигней. Альмандар?

Әлмәндәр *(агачлар арасыннан килеп чыга)*. Знал, маклашка не дам. Гости пришул — чәй давай, дивка давай.

Евстигней *(битлеген җиргә куеп, Әлмәндәр каршына бара)*. Шайтан! Нихаль, Альмандар? Якши?

Күрешәләр.

Әлмәндәр. Хураша! Сам хураша?

Евстигней. Якши! Бик якши! Каян килдең?

Әлмәндәр. Деревня. Свая деревня. Тибя давна ни видал.

Евстигней. Якши! Бик якши! Айда, кил, утыр монда. Мин да уйлаган синга барырга. Вот умарта, бал киряк. Янгир бар, бал бар, куп бар. Син бал бар?

Әлмәндәр. Мнугы. Гуд хураша, дуж есть, сулныца есть, свиты мнугы, пчала туда-суда мнугы литит. Тибя кислый мюд есть? Меня есть. Әлмәндәр кислый мюд пил. Әҗәлдән бижал. Әжәл спал, Әлмәндәр Ястәгнәй знакум бежал.

Евстигней. Азяль? Кем Азяль?

Әлмәндәр. Смирт. Пришул. Гаварит, старик, давай. Әлмәндәр, давай. Туда-суда, умирать. Я тужы туда-суда. Бижал тибя. Писня пить будем, дивка гулять будем.

Евстигней *(көлеп)*. Балагур. Якши! Бик якши! Бал бар, Альмандар бар, Евстигней бар, карчык бар.

Әлмәндәр. Старуха ни нада, дивка давай. Три верст пришул, дивка нит — абратны бижать будем.

Евстигней. Ю-ук! Кунак! Дус! Альмандар дус! Знаком!

Әлмәндәр. Мнугы гуд знакум! Хураша знакум.

Евстигней. Айда, Альмандар, ызба кер.

Ә л м ә н д ә р. Ызба ни нады. Здич хураша. Старуха ни нады, чәй ни нады, кислый мед ни нады. Писня нады. Садис, писня пить будем. Ассалуди, былгаруди. Давай, Ястәгнәй. *(Җыр башлый.)*

Ассалуди, былгаруди...
Давай, Ястәгнәй.

Е в с т и г н е й *(җыр башлый, Әлмәндәр очынып тыңлый)*.

Во саду ли, в огороде
Девица гуляла.
За ней ходит, за ней ходит
Удалой молодчик,
За ней носит, за ней носит
Дороги подарки.

Ә л м ә н д ә р. Спасибо, Ястәгнәй. Рәхмәт. Рәхмәт. Яшәдек без, ә? Җырлап яшәдек. Сер бирмәдек. Күпме гумер бергә. Алтмыш ел, ә? Күршеләр, знакумнар. Хәтерлисеңме, болынга печән чабарга чыккач, җыелышып биегәндә, сезнең авылның Маручканы кочаклаган идем, шуннан минем Йөзембикәм, азгын дип, мине әрләгән иде. Хәтерлисеңме, безнең якка аклар килгәч, бергәләп урманда кызылларга кушылып киткән идек. Исеңдәме колхоз төзегәндә мине үлемнән коткарып калганың, хәтерлисеңме сугыш вакытында...

Е в с т и г н е й. Да, много прошло.

Ә л м ә н д ә р. Малы, Ястәгнәй. Бик әз. Яшисе килә, Ястәгнәй. Илле яшьтә булсаң иде хәзер, ә? Дөньясы бигрәк матур бит, Ястәгнәй. Китәсе килми. Әҗәл килде миңа, сизеп торам. Шуңа күрә синең яныңа чаптым, җәяүләп килдем, Ястәгнәй, саубуллашып кайтыйм дидем. Әҗәл килде.

Е в с т и г н е й. Ерунду не болтай, Альмандар.

Ә л м ә н д ә р. Ярунда түгел, сизенәм. Мин, үзең беләсең, шыңшып йөрергә яратмадым. Дөньядан ямь табып яшәдем. Авырлык килсә дә бирешмәдем. Җылап йөрүчеләрне җенем сөйми. Син мине зарлана дип уйлама. Исем дә китми, Әҗәл белән дә көлеп сөйләштем.

Е в с т и г н е й. Правильно, так и надо. Я тоже, знаешь, маху не давал. Жить будем еще, Альмандар.

Ә л м ә н д ә р. Шулай. Синең исән-сау йөргәнеңне күреп сөендем. Хәлләрең ничек соң, Ястәгнәй?

Евстигней. Дело молодое.

Әлмәндәр. Шулай, бирешмә, нык тор. Син миннән алты яшькә яшьрәк.

Евстигней. Молокосос.

Әлмәндәр. Валлаһи, дөрес! Әйдә җырлыйбыз.

Евстигней *(көйләп)*. Ала карга дигян, ай, асыл куш...

Әлмәндәр. Валлаһи шулай.

> Ала карга дигән, әй, асыл кош,
> Имән башларына ник кундың?
> Никләр кунганыңны да белмәгәч,
> Якты дөньяларга ник тудың?

Хәтерлисеңме, Ястәгнәй, синең Иваның белән минем Хәйретдиннең үле хәбәрләре бер көнне килде.

Евстигней. Да-а...

Әлмәндәр. Әйдә безгә киттек, Ястәгнәй. Куып йөрсен әле безне Әҗәл. Ул мине эзләп чыгып китәр, ә без рәхәтләнеп... Әйдә, мой дача гулять будем. Сад дача делал, гарадскуй дача.

Евстигней. Ю-ук, Альмандар. Син минеке кунак. Минеке избада йоклыйсын.

Әлмәндәр. Твая снаха ругать будет.

Евстигней. Ю-ук. Килин якши. Син яратам. Посиди немного, я скажу... *(Чыгып китә.)*

Әлмәндәр, Евстигнейның битлеген киеп, умарта янына килә дә хәле бетеп туктый. Әҗәл күренә.

Әҗәл. Шулай диген, Әлмәндәр. Качтым диген.

Әлмәндәр *(битлекне салып, җиргә утыра)*. Ни булды дисәм, син икәнсең әле.

Әҗәл. Әйе, мин фәкыйрегез. Әйттем бит мин сиңа, миннән качып котыла алмассың, дидем. Әйдә Әлдермешкә кайтабыз.

Әлмәндәр. Китер кәгазеңне, кул куйыйм, котылыйм син сабакыдан.

Әҗәл. Юк, Әлдермешкә кайтабыз башта.

Әлмәндәр. Ни аермасы бар?

Әҗәл. Син анда такта ышкылаттың, такта кадаклаттың. Исәп-хисапны шунда өзәрбез.

Әлмәндәр. Кайтырлык хәлем бетте.

Әҗәл. Хәйләләмә. Әйдә, Әлмәндәр, яхшылык белән.

Юк нәрсә өчен бозылышмыйк. Тор әйдә, минем өчен кайда кул куйсаң да барыбер, үзең өчен әйтәм. Туган-үскән нигезеңдә, үзең ясый башлаган алачыгыңда...

Әлмәндәр. Шулай димсең?.. Ястәгнәй чыксын инде, саубуллашып китим.

Әҗәл. Бәлки, кирәкмәс.

Әлмәндәр. Ни өчен?

Әҗәл. Ни өчен дип... Башың белән уйлап кара. Ул да яшь кеше түгел, син авырайганны күрер дә, кәефе китәр. Син бит кешеләрнең кәефләре кырылуын теләмисең.

Әлмәндәр. Шулай шул.

Әҗәл. Әйдә тор. Әкрен генә атлыйк. Нәрсә ул синең өчен өч чакрым ара. Сиңа җиңелрәк булсын өчен мин яныңнан бармам, читтәнрәк атлармын.

Әлмәндәр *(урыныннан торып)*. Бигрәк төче теллегә әйләнгәнсең.

Әҗәл. Төче телледән түгел. Качып киткәнеңә ачулансам да, сокланам мин сиңа. Туксан бер яшеңдә өч чакрым җиргә җәяүләп чыгып киткәнсең. Кайтасың барын да оныткансың. Йә, ничек, ярыйсыландымы хәлең? Бәлки, чыннан да, Ястәгнәй знакумың чыкканны көтәрсең? Берәр ат юнәтеп озатып куярлар.

Әлмәндәр. Юк, кеше борчырга яратмыйм. Әйдә.

Әкрен генә бакчадан чыгып китәләр. Евстигней керә.

Евстигней. Альмандар. Кайда син? Где ты? Шаярма, әй, балагур, шайтан!

Ут сүнә.

### Дүртенче күренеш

Әлмәндәр карт бакчасы. Эшләнеп бетмәгән алачык идәнендә Әлмәндәр белән Әҗәл утыралар. Вакыт төн. Әрәмәлек ягыннан гармунга кушылып җырлаган тавышлар ишетелә.

Әҗәл. Ятып ял итеп ал, Әлмәндәр. Шактый юл үттең, арыгансыңдыр.

Әлмәндәр. Акылың алтын икән. Ял итеп ал дигән булып мәңгелеккә йоклатырга җыенасыңмы?

Әҗәл. Нәрсә инде син. Кем дип беләсең мине ул кадәр. Син генә ул алдашасың, мин гадел эш йөртәм.

Кулыңны куймаган килеш сиңа орынаммы... Синең өчен эләгәчәк миңа. Ләкин барыбер соңгы төнеңне үзеңә бирәм.

Әлмәндәр. Маташтырма.

Әҗәл. Валлаһи, билләһи. Төнлә алып китмим сине. Таң атканда, кояш чыгар алдыннан, көн уянганда. Күңелең гел яктыда булгач, үлемең дә яктыда булсын. Ә бүген төнлә син теләгән нәрсәңне эшли аласың.

Әлмәндәр. Җәйге кыска төндә ни эшләп булсын. Ашап туймаганны, ялап туеп булмас.

Әҗәл. Уйла. Үкенечләрең калмыймы?

Әлмәндәр. Юк. Мин кылган эшләремә үкенмәдем. Эшләргә ниятләгән эшемне ахырына җиткезеп туктадым. Ярты юлда менә шушы алачык кала, тагын... тагын... Дөнья кала. Төзелеп бетмәгән дөнья кала. Төзеп бетерәсе иде. Кешеләр үлсәләр дә, ичмасам, минем яшемә җитеп, үз үлемнәре белән үлсеннәр иде. Уттан кырылмасыннар иде.

Әҗәл. Нәрсә әле син мескенләнеп коелып төштең, Әлмәндәр? Шундый күңелле иде синең белән, кинәт сүндең. Салындырма борыныңны, җебемә, чурту-матыр. Тор әйдә, алачыгыңны кадаклап бетерәбез.

Әлмәндәр. Төнлә шакылдау килешми. Кешеләр йоклый.

Әҗәл. Нишләргә соң инде синең белән?

Әлмәндәр. Китер, кәгазеңне.

Әҗәл. Әлмәндәр...

Әлмәндәр. Китер, диләр.

Әҗәл. Нигә инде... Мин үзем әйтеп торганда...

Әлмәндәр. Белеп тор, мин кул куйдырдым, Әлмәндәрне җиңдем дип мактанасы булма, үзем куям.

Әҗәл. Хет өйдәге улың, килекең, оныгың белән саубуллаш.

Әлмәндәр. Йокылары бүленмәсен.

Әҗәл. Ярый соң, алайса, әйтмәк бар, көчләмәк юк. Соңыннан миңа үпкәләмә. *(Кәгазь белән карандашны Әлмәндәргә суза.)* Әлмәндәр, кызганам мин сине, валлаһи, кызганам. Сиңа ярдәм итәсем килә, ничек ярдәм итәргә белмим. *(Кинәт бер фикергә килә.)* Таптым! Таптым, Әлмәндәр дус! Син исән калачаксың!

Әлмәндәр *(кәгазьне атып бәреп)*. Әйт тизрәк!

Әҗәл. Искәндәр! Улың Искәндәр! Фамилиягез бер, исемнәрегез охшаган. Абайламас Газраил. Сизмәслек

итеп эшләрмен. Искәндәр үзе дә Әҗәл көтеп ята. Керим мин аның янына, кул куйдырып чыгыйм.

Әлмәндәр *(сикереп торып)*. Ни диден? Ни диден син, явыз?! Минем бердәнбер улыма? *(Әҗәлнең якасына ябыша.)*

Әҗәл. Нишлисең, җибәр!

Әлмәндәр. Син Әлмәндәр картны?

Әҗәлне күтәреп алып җиргә сыламакчы була. Әҗәл бирешми. Көрәшәләр. Икесе дә егылып җирдә әүмәкләшәләр. Ниһаять, икесенең дә хәле бетә, бер-берсенә аркаларын терәшеп ял итәләр.

Әҗәл. Әйтерсең мин үзем өчен.

Әлмәндәр. Дәшмә!

Әҗәл. Синең өчен бит, яшисең килә бит.

Әлмәндәр. Дәшмә, дим!

Әҗәл. Дәшмим, чурту-матыр, мәтәлеп кит. Ике тиенлек тә акылың юк. «Ала карга» дип җырлап йөрергә генә беләсең. Аңарга китсә, ала карга асыл кош та түгел әле.

Әлмәндәр. Булмасын. Ул — җан иясе.

Әҗәл. Аның кемгә кирәге бар?

Әлмәндәр. Дөньяда булгач, кирәге бардыр.

Пауза.

Әҗәл. Гафу ит, Әлмәндәр. Мин Искәндәрне исеңә төшереп ялгышканмын. Синең Әлмәндәр икәнеңне онытып җибәргәнмен. Әй дөнья, дөнья... Ассалуди, былгаруди... Карале, Әлмәндәр, теге Ястәгнәй ничек булыр? Синең урынга батмасмы?

Әлмәндәр кинәт Әҗәлгә таба борыла. Әҗәл егылып китә.

Әлмәндәр. Тагын башладыңмы?

Әҗәл *(артка чигенеп)*. Булды, булды. Дәшмим, дәшмим. Зинһар, кызма. *(Җирдә яткан кәгазьне алып.)* Ярар, синеңчә булсын. Бөтенесе син дигәнчә булсын, мә. Мә карандаш.

Әлмәндәр кәгазьне, карандашны алып, кул куярга җыенганда, бакча рәшәткәсе янына Гөлфирә белән Мансур килеп туктыйлар. Мансур Гөлфирәгә якын килми, читтә басып тора.

Әлмәндәр, кул куярга онытып, аларны күзәтә башлый.

Мансур. Гөлфирә, сез нигә безнең авылда тумаган икән?

Гөлфирә. Әллә нинди сораулар бирәсез сез, Мансур.

Мансур. Ярамыймыни?

Гөлфирә. Үзегез ничек уйлыйсыз соң?

Мансур. Мин уйламыйм.

Гөлфирә. Уйламагач, андый сорау бирмәгез.

Мансур. Авылда шулай инде. Сорауны уйлап торып бирмиләр. Тоталар да әйтәләр. Шәһәрдә генә уйлаган булалар. Уйлап, әйтерсең бездән артык җирләре бар. Алар да ике аяклы, без дә ике аяклы.

Гөлфирә. Тавык та ике аяклы, каз да ике аяклы.

Мансур *(көлеп)*. Эләктереп ала беләсез сез.

Әлмәндәр. Син дә эләктереп ал, пешмәгән. Авызың ачып торасың. Бүтән чакта бик егетләнәсең бит.

Әҗәл. Тукта, Әлмәндәр, тыңлыйк.

Әлмәндәр. Кыз белән егет сөйләшүе сиңа ник кирәк?

Әҗәл. Кызык бит. Сөйләшүләре ни белән бетәр икән?!

Гөлфирә. Сез нигә уеннан киттегез?

Мансур. Сез дә киттегез бит.

Гөлфирә. Мин нишләмәм. Миңа дәү бабай әйтте, озак йөрмә, сәгать ун тулганчы, матри, өйдә бул, диде.

Әлмәндәр. Кара курнус борынны, ничек алдаша.

Мансур. Әлмәндәр бабай өйдә юк. Аны күрдем мин, Антоновка авылына бара иде. Ул анда барса, ике-өч көнсез кайтмый, беләм.

Әлмәндәр. Муладис!..

Мансур. Ул миңа әйтте, Гөлфирәң кайтты, диде.

Гөлфирә. Ничек «Гөлфирәң»?

Әлмәндәр. Сынаттың, егет.

Әҗәл. Тик кенә утыр инде.

Әлмәндәр. Ничек тик утырыйм, оныгымның кызы ич ул.

Мансур. Белмим инде, Әлмәндәр бабай шулай диде.

Гөлфирә. Моның өчен эләгәчәк аңарга. Ярый, сау булыгыз, Мансур, минем йокым килә.

Мансур. Егетләр белән сөйләшкәндә «йокым килә» дип әйтергә ярамый.

Гөлфирә. Ни була?

Мансур. Әдәпсез була, некультурный була. Авыл кызлары алай дип әйтмиләр.

Г ө л ф и р ә. Алайса, авыл кызлары янына барыгыз.

М а н с у р. Нигә алай авыл кызлары дип мыскыл итебрәк әйтәсез?

Г ө л ф и р ә. Нәрсә миңа бәйләнәсез? Кайткан саен бәйләнәсез.

М а н с у р. Сезнең белән сөйләшәсем килгәнгә. Шуңа күрә авылга кайтканыгызны көтеп кенә торам.

Г ө л ф и р ә. Әллә «яратам» дип әйтергә уйлыйсызмы?

М а н с у р. Уйламыйм. «Яратам» дип әйтер өчен нигә уйлап торырга. «Яратмыйм» дип әйтер өчен уйларга кирәк.

Г ө л ф и р ә. Кызык икән. Нигә алай?

Ә л м ә н д ә р. Безнең замандагыча сөйләшмиләр шул болар. Сөйләшүләре тәмле.

Ә җ ә л. Нәрсәсе тәмле инде, кырт та мырт.

Ә л м ә н д ә р. Бөтен хикмәт шунда. Безнең яшь чакта без генә сөйли идек. Хатын-кызның теле кияүгә чыгып ун елдан соң гына ачыла иде. Төннәрен кочаклаганда да түшәк читенәрәк авышалар иде, куркалар иде. Курыккан хатын-кызны кочаклауның ни тәме бар. Кочагыңа үзе шуып керсен ул. Теле белән ачуланган булсын.

Ә җ ә л. Карт азгын син, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Ту-ты.

Г ө л ф и р ә. Нигә алай? Әйтегез инде, ник дәшмисез?

М а н с у р. Әйтәм, миңа «син» дип дәшсәгез әйтәм.

Г ө л ф и р ә. «Сез» дип үзең башладың?

М а н с у р. Мин культурныйрак чыксын дип әйткән идем.

Г ө л ф и р ә *(көлеп)*. Үләм! Көлеп үләрсең синең белән.

М а н с у р. Менә болай ул, Гөлфирә. «Яратам» дип әйтер өчен уйларга кирәкми. Чөнки күңелеңдәген әйтәсең. «Яратмыйм» дип әйтер өчен уйларга кирәк. Чөнки уйламый әйтеп ташлап ялгышуың бар. «Яратмыйм» дип бер әйткәч, «яратам» дип әйтергә соң була.

Г ө л ф и р ә. «Яратам» дип әйтеп тә ялгышырга мөмкин.

М а н с у р. Күңел беркайчан да ялгышмый.

Г ө л ф и р ә. Лекцияң өчен рәхмәт, истә тотармын. Син кайчан әле армиягә китәсең?

М а н с у р. Нигә алай сорыйсың?

Г ө л ф и р ә. Авылга кайткач, үзем генә рәхәтләнеп йөрер идем.

М а н с у р. Быел котыласың, ике елдан тотыласың.

Г ө л ф и р ә. Ике елдан соң мин авылга кайтмыйм.

М а н с у р. Кая барасың?

Г ө л ф и р ә. Быел укырга керәм. Студент булгач, җәй көне студотряд белән китәм.

М а н с у р. Укырга керә аласыңмы соң?

Г ө л ф и р ә. Мин бит син түгел. Минем бөтенесе дә бишле.

Ә л м ә н д ә р. Үземә охшаган, мактанырга ярата. Шулай, кызым, сер бирмә. Дәү бабаң сер бирмәде дөньясында.

М а н с у р. Син, Гөлфирә, миннән котылам, дисең. Үзең мине күргәч сөенәсең.

Г ө л ф и р ә. Каян беләсең?

М а н с у р. Мансур сизә ул. Авылга да син мине сагынып кайтасың.

Г ө л ф и р ә. Менә бусы ялган!

М а н с у р. «Ялган» дип әйтергә ашыкма, Гөлфирә, «чын» дип әйтәсең бар.

Г ө л ф и р ә. Кара син нинди!

М а н с у р. Мин шундый. Элек кенә оялчан идем. Хәзер... *(Көйләп.)* «Менә без дә үсеп җиттек, әни». Армиягә китәбез. Армия оялчан егетләрне яратмый. Син ачуланма мине «сагынып кайтасың» диюемә. Аның ни гаебе бар. Мин дә бит сине сагынып көтеп торам. Күңелең мин сагынганны сизә.

Г ө л ф и р ә. Үләм, үләм!..

М а н с у р. Син нигә безнең авылда тумаган икән, дип әйткән идемме?

Г ө л ф и р ә. Әйткән идең.

М а н с у р. Безнең авылда туган булсаң, безнең авылда үскән булсаң, гел бергә булган булыр идек. Мин армиягә киткәндә, кулъяулык чигеп бирер идең...

Г ө л ф и р ә. Үләм!.. Хәзер кулъяулык чикмиләр авылда да.

М а н с у р. Син чигәр идең, Гөлфирә.

Ә л м ә н д ә р. Дөрес! Чигәр иде. Әгәр дә мин чынлап торып яратсам, комнан бау ишәр идем.

Ә җ ә л. Иштеңме соң?

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә «иштеңме»?

Ә җ ә л. Ятратканың булмадымыни?

Ә л м ә н д ә р. Аны әйтәсең икән. Комнан бау ишеп азапланырга әллә мин җүләрме. Кыйбла җиленә сәнәк

белән кадаучы түгел мин. Бау ишмәдем, Искәндәрем тугач, Йөзембикәмә бишек ясап бирдем. Кулыма балта да тотып караганым юк иде, ясаган бишегем сандугач оясы булды.

Г ө л ф и р ә. Мансур... Син... Син нигә миңа... «яратам» дип әйтмисең?

М а н с у р. Син «яратмыйм» дип әйтерсең дә...

Г ө л ф и р ә. Ә мин алай дип әйткәнче уйлап карармын.

М а н с у р *(Гөлфирәне кочагына алып)*. Яратам, Гөлфирә.

Ә л м ә н д ә р *(куанычыннан нишләргә белми)*. Үбешегез инде, хәерсезләр. Аның ни ояты бар?!

Ә җ ә л. Әкрен, әкрен, Әлмәндәр. *(Гөлфирә белән Мансур үбешкәнне күреп.)* Эх, нигә мин дә кеше булып яралмаган икән!

Г ө л ф и р ә *(Мансурдан читкәрәк китә)*. Чыннанмы, Мансур?

М а н с у р *(бар көченә кычкырып)*. Яратам! Я-ра-та-а-а-ам!

Г ө л ф и р ә. Нишлисең, җүләр!

М а н с у р *(җырга күчеп)*.

Уфа тараклары белән
Күңелле чәч таравы;
Үзәкләремне өзәдер
Бер елмаеп каравы.
Уфа тараклары таптым
Агыйдел буйларыннан;
Гомеремнең буйларына
Китмәссең уйларымнан.

Г ө л ф и р ә. Нишлисең, Мансур?! Кешеләр ишетә.

М а н с у р. Беркем дә юк, Гөлфирә, дөньяда без икәү генә.

Ә л м ә н д ә р *(Гөлфирә белән Мансур ишетерлек итеп)*. Ә мин?! Мине кая куясыз. Мин бар, мин — шаһит!

М а н с у р белән Г ө л ф и р ә Әлмәндәр тавышын ишетеп сызалар. Әлмәндәр тураеп бакча уртасына баса.

Ә мин?! Мин бар дөньяда! Мин исән! Кит, Әҗәл. Китеп тор янымнан! Эх!.. *(Мансур җырлаган көйгә җырлап, бакча буйлап йөренә.)*

Уфа тараклары белән
Кем чәчләрен тараган;
Фани дөнья авыр, диләр,
Кем күтәреп караган.
Уфа таракларым җуйдым
Чәчләрем тараганда...

Бакчага Өммия чыга. Аптырап, Әлмәндәргә карап тора. Әлмәндәр, җырын дәвам итеп, аның каршына бара.

И туган-үскән илләрем,
Чит җиргә караганда.

Өммия. Әллә инде акылың ук җиңеләйдеме, Ходаем?! Өйдә югыең лабаса, Антунга китте, дигәннәрие. Кай арада кайтып җиттең? Булсаң да булырсың икән!

Әлмәндәр. Кушылып җырла миңа, килен.

Өммия. Әстәгъфирулла. *(Тиз генә кереп китә.)*

Әлмәндәр. Надан! *(Алачык янына бара-бара сөйләнә.)* Дөнья ямен аңламый. Ябь-яшь башларыннан йоклап яталар. Эх, егерме генә елга яшь булсам! *(Алачык идәненә утырып.)* Утыз гына елга. Кырык... Илле... Алтмыш... Җитмеш...

Алмагач арасыннан көянтә-чиләк күтәргән Йөзембикә чыга. Ул төсе, буе, тавышы белән Гөлфирәгә охшаган. Киеме генә башка.

Әлмәндәр. Йөзембикә!

Йөзембикә *(туктап кала, йөзен яулыгы белән каплый)*. Кем ул?

Әлмәндәр. Мин бу, Йөзембикә, Әлмәндәр.

Йөзембикә. Басма өстендә нишләп утырасың, Әлмәндәр?

Әлмәндәр. Айны саклыйм.

Йөзембикә. Айны? Аны урлыйлармыни? Ул бит еракта, аңа кемнең кулы җитсен?

Әлмәндәр. Җирдәге айны. Иңбашларына көянтәчиләкләр аскан айны саклыйм, Йөзембикә.

Йөзембикә. Әллә минеме?

Әлмәндәр. Син аймыни?

Йөзембикә. И хәсиятсез. Кит, юл өстендә утырма.

Әлмәндәр. Китмәсәм нишләтерсең?

Йөзембикә. Суга төртеп төшерермен.

Әлмәндәр. Аннары тартып алырсың да бауга элеп киптерерсең.

Й ө з е м б и к ә *(көлеп)*. Тиледер син, иеме? Төнлә берүзең басма өстендә утырасың.

Ә л м ә н д ә р. Син дә берүзең чишмәгә килгәнсең ич. Төн дип тормагансың.

Й ө з е м б и к ә. Көндезләрен вакытым юк.

Ә л м ә н д ә р. Минем дә вакытым юк.

Й ө з е м б и к ә. Минем әти сине мактый. Ун кеше өчен эшли, ди. Печән чапканыңны карап торган.

Ә л м ә н д ә р. Алай булгач, эш пешә икән.

Й ө з е м б и к ә. Нинди эш?

Ә л м ә н д ә р. Сиңа яучы җибәрсәм, әтиең ык-мык килеп тормас.

Й ө з е м б и к ә. Минем әти яучыларны яратмый, кызларым үзләре теләгәннәргә барсыннар, ди.

Ә л м ә н д ә р. Алай булгач, бигрәк тә җайлы. Көзгә туй ясарбыз.

Й ө з е м б и к ә. Мин сиңа барырга җыенмыйм да.

Ә л м ә н д ә р. Нигә?

Й ө з е м б и к ә. Син әллә нинди. Сиңа ышанып булмый. Син авылдагы бөтен кызларга да күз кысасың.

Ә л м ә н д ә р. Аның хәйләсе бар, Йөзембикә. Бүтән кызларга мин күз кыскан булып бер күзем белән генә карыйм, сиңа ике күземне тутырып карыйм.

Й ө з е м б и к ә. Миңа ник алай карыйсың?

Ә л м ә н д ә р. Бүтән кызлар сарык кебек. Үз күләгәләреннән үзләре өркеп, өерләре белән йөриләр, син берүзең, кәҗә кебек, берәүгә дә исең китми, туры басып, урамның уртасыннан йөрисең.

Й ө з е м б и к ә. Әти шулай өйрәтә. Ходай ир балалар насыйп итмәгән, кызларым җебегән булмасын, ди. Беркемнән дә бер сүз әйттермәм, ди.

Ә л м ә н д ә р. Шуның өчен сиңа «ирдәүкә» дип әйтәләрме?

Й ө з е м б и к ә. Әйтсеннәр. Исем дә китми.

Ә л м ә н д ә р. Кил, минем янга утыр, Йөзембикә.

Й ө з е м б и к ә. Ник?

Ә л м ә н д ә р. Су анасының чәч тараганын карарбыз.

Й ө з е м б и к ә. Кешеләр күрсә...

Ә л м ә н д ә р. Син курыкмыйсың ич.

Й ө з е м б и к ә. Мин үзем генә булганда курыкмыйм.

Ә л м ә н д ә р. Берәрсе сүз әйтеп карасын, җиде бабасына «Иман шарты» укытырмын... Нигә көләсең?

Й ө з е м б и к ә. Син усал түгел.

Ә л м ә н д ә р. Сиңа усаллар кирәкмени?

Й ө з е м б и к ә. Кирәкми. Усаллар кирәкми. *(Әлмәндәргә якын килмичә генә алачык идәненә утыра.)*

Пауза.

Ә л м ә н д ә р. Ай нигә якты, беләсеңме, Йөзембикә?

Й ө з е м б и к ә. Белмим, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Болытлар ышкылып йөреп шулай ялтыратып бетергәннәр аны.

Йөзембикә рәхәтләнеп көлә.

Йолдызлар нигә җемелди, беләсеңме?

Й ө з е м б и к ә. Белмим.

Ә л м ә н д ә р. Басма өстендә Мәкәрҗә чиләге кебек матур кыз утыра, кем икән ул дип, күзләрен кысып-кысып карыйлар.

Й ө з е м б и к ә. Тиле-миле!

Пауза.

Әлмәндәр, без олыгайгач та Ай шул урында торыр микән?

Ә л м ә н д ә р. Юк.

Й ө з е м б и к ә. Кая китә?

Ә л м ә н д ә р. Мин аны алып төшеп, үзебезнең өй кыегына кадаклап куям.

Й ө з е м б и к ә. Алай итмә, Әлмәндәр. Бүтәннәргә дә кирәк ич Ай.

Ә л м ә н д ә р. Ярый, алайса, тимәм, урынында торыр.

Й ө з е м б и к ә. Без картаербыз микән, Әлмәндәр?

Ә л м ә н д ә р. Мескеннәр генә картая.

Й ө з е м б и к ә. Без үләрбез микән, Әлмәндәр?

Ә л м ә н д ә р. Таптың сөйләшер сүз.

Й ө з е м б и к ә. Ни сөйләшик соң?

Ә л м ә н д ә р. Мескеннәр генә үлә.

Й ө з е м б и к ә. Ходай язганнан узып булмый.

Ә л м ә н д ә р. Белмим ни язгандыр, мин укый белмим.

Й ө з е м б и к ә. Алай димә, Әлмәндәр.

Ә л м ә н д ә р. Нәрсә остабикә булып утырасың, чурту-матыр.

Й ө з е м б и к ә. Ни дигән сүз ул «чурту-матыр»?

Ә л м ә н д ә р. Әти Антун урысыннан өйрәнеп кайткан. Ачу килгәндә әйтә торган сүз, ди.

Й ө з е м б и к ә. Ачуланма инде, Әлмәндәр. Миңа ул сүзне әйтмә.

Ә л м ә н д ә р. Ачуны китермәсәң әйтмәм.

Әтәч кычкырган тавыш.

Й ө з е м б и к ә *(торып)*. Таң әтәчләре кычкыра.

Килгән ягына борылып китә башлый. Әлмәндәр, көлә-көлә, утырган урыннан тора.

Й ө з е м б и к ә *(борылып)*. Нигә көлеп каласың, Әлмәндәр?

Ә л м ә н д ә р. Су алырга оныттың.

Й ө з е м б и к ә. И синең белән... Чык басмадан.

Ә л м ә н д ә р. Ә син минем яннан үтеп кит.

Й ө з е м б и к ә. Басма тар, егылам.

Ә л м ә н д ә р. Мин тотып калырмын.

Й ө з е м б и к ә. Әйем.

Ә л м ә н д ә р. Куркак.

Й ө з е м б и к ә. Син үзең куркак. *(Алачык идәненә баса.)* Кулың белән кагылма, ярыймы?

Идән буйлап атлый, Әлмәндәр идән читендә басып тора. Йөзембикә үткәндә, бер аягына гына басып, Йөзембикәне уздырып җибәрә.

Ә л м ә н д ә р. Тизрәк тутыр чиләкләреңне, аягым арыды.

Й ө з е м б и к ә т а в ы ш ы. «Тилеләнмә, егыласың».

Шул сүзне генә көткәндәй, Әлмәндәр чайкалып китә. Бакчага Ө м м и я белән И с к ә н д ә р чыгалар.

Ө м м и я. Күр, үз күзләрең белән күр.

Ә л м ә н д ә р. Күрәм, Йөзембикә, күрәм.

И с к ә н д ә р *(Әлмәндәр янына килеп)*. Әти...

Ә л м ә н д ә р *(ике аягына басып, текәлеп, Искәндәргә карап тора)*. Улым, синме соң бу?

И с к ә н д ә р. Мин, әти, мин...

Ә л м ә н д ә р. Мин әле әниең белән сөйләшеп утырдым.

Ө м м и я. И Ходаем, шул гына җитмәгән иде.

Ә л м ә н д ә р. Килен, син дә мондамыни?

Ө м м и я *(куркыбрак)*. Монда, әткәй, монда.

Ә л м ә н д ә р. Ачуланма инде, килен.

Ө м м и я. Ачуланмыйм, әткәй, ачуланмыйм.

Ә л м ә н д ә р. Авыр сүз әйтеп күңелеңне рәнҗеткәнем булмады бит, килен. Ачуланганда да яратып, үз итеп ачуландым.

Ө м м и я. Шулай, әткәй, шулай...

Ә л м ә н д ә р. Әй телең, килен. Бигрәк тәмле. Сандугач кебек сайрыйсың. Шундый телне кырык ел миннән яшереп яшәдең.

И с к ә н д ә р. Әти, өйгә керик.

Ә л м ә н д ә р. Минем белән әрепләшү синең үзеңә дә дөнья рәхәте бит, килен. Синең юньсез ирең көн озынына өч сүз дә әйтми. Ә хатын-кыз сөйләшмичә тора алмый. Дөрес әйтәмме, килен?

Ө м м и я. Хак, әткәй, хак сөйлисең. *(Искәндәргә шыпырт кына.)* Малайларга, кызларга хәбәр итәргә кирәк.

Ә л м ә н д ә р. Ни сөйләшәсез, килен?

Ө м м и я. Сине мактыйбыз, әткәй.

Ә л м ә н д ә р. Шулай дөрес. Юкса, кара аны, матри, килен. Килегез, тезелешеп утырыйк әле. *(Алачык идәненә утырып.)* Улым, син – уң ягыма, килен, син сул ягыма утыр.

Ө м м и я. Утырабыз, әткәй, утырмыйбызмы соң.

Утыралар. Өммия шикләнебрәк кырыйгарак утыра.

Ә л м ә н д ә р. Якынрак кил, килен. Менә шулай. Күрәсезме, балалар, таң ата. Озакламый кояш чыгар. *(Искәндәргә.)* Син нигә өстеңә кимәдең? Таң атканда салкын була. *(Өстеннән казакиен салып, Искәндәр иңенә яба.)*

Ө м м и я. Авырткан җирең юктыр бит, әткәй?

Ә л м ә н д ә р. Йөрәгем урынында түгел. Кош булып очып йөри.

Ө м м и я. Алай икә-ән. Болай кайда утырганыңны, нишләп йөргәннәреңне беләсеңме соң?

Ә л м ә н д ә р. Килен, бар әле, Хәмдебануны чакырып кер.

Ө м м и я. Хәмдебануны?.. Йоклыйдыр ул, әткәй.

Ә л м ә н д ә р. Таң атканда йоклап яталармы?

Ө м м и я. Анысы шулай да. Син дә ятып тор... Җиңеләеп китәрсең.

Ә л м ә н д ә р. Әйткәнне тыңла, килен.

Ө м м и я. Искәндәр, нишлим?

И с к ә н д ә р. Бар, чакыр!

Ө м м и я. И Ходаем... *(Бакча капкасына бара. Анда Гөлфирә белән Мансурны очрата.)* Кайда йөрисең син бу вакытка чаклы? Дәү бабаң...

Г ө л ф и р ә. Нишләгән?..

Ө м м и я. «Нишләгән, нишләгән»... Акылы җиңеләйгән. Бар, Хәмдебану әбиеңне чакыр!

Г ө л ф и р ә. Нигә?

Ө м м и я. Белмисезмени, өйләнәм дип саташа бит. Үләм, Ходаем, адәм көлкесенә калып бетәбез. Вакытында үлә белмәсәң, шулай инде ул. Бар инде, күңеле булсын.

Ә л м ә н д ә р. Килен, үзеңә кушкан йомышны бүтәннән эшләтмә.

Ө м м и я. Үләм. Колагын кара син аның. И Ходаем... *(Китә.)*

Г ө л ф и р ә *(тиз генә бакчага керә, Әлмәндәр янына килә)*. Дәү бабай...

Ә л м ә н д ә р. Сөйгән егетең нигә кермәде?

Г ө л ф и р ә. Дәү бабай...

Ә л м ә н д ә р. Бар, алып кер.

Г ө л ф и р ә. Анда беркем дә юк, дәү бабай.

Ә л м ә н д ә р. Алып кер.

Гөлфирә, бакча капкасына барып, Мансурны чакырып кертә. М а н с у р кыюсыз гына Әлмәндәр янына килә.

Ә л м ә н д ә р. Ник алай, әйбер урлаганда тотылган сыман киләсең?

М а н с у р. Исәнмесез, Әлмәндәр бабай! Исәнме, Искәндәр бабай!

Ә л м ә н д ә р. Исән булмый нишлик. Ничек дидең әле, дөньяда без икәү генә, дидеңме? Шәп әйттең, муладис! Кара аны, арагызга өченче кешене кертмә, колагың борып өзәрмен. Менә, Искәндәр улым, оныгыңның кияве шушы егет була. Белә идеңме?

И с к ә н д ә р. Әти...

Ә л м ә н д ә р. Әй, сиңа сүз әйткән мин җүләр. *(Гөлфирәгә.)* Дәү әниеңә охшагансың икән син, кызым, бәхетле булырсың. Кил, утыр яныма. Син, кияү... Мансурмы әле исемең?

М а н с у р. Мансур.

Ә л м ә н д ә р. Илсур атлы энең дә бармы әле синең?

М а н с у р. Бар.

Ә л м ә н д ә р. Кайда ул?
М а н с у р. Йоклыйдыр.
Ә л м ә н д ә р. Алып кил.
М а н с у р. Мондамы?
Ә л м ә н д ә р. Алып кил, дигәч, монда була инде.
Г ө л ф и р ә. Дәү бабай...
Ә л м ә н д ә р. Йокысыннан уяна алмаса, күтәреп алып кил. Бар инде, бар. Егет кеше ике әйткәнне көттерми.

М а н с у р чыгып китә.

И с к ә н д ә р. Әти, өйгә керик.
Ә л м ә н д ә р. Бакчага кунаклар чакырдым, өйгә кереп качыйммы? Дөрес бит, кызым?
Г ө л ф и р ә. Дәү бабай, син кыланасыңмы?
Ә л м ә н д ә р. Ни диден?
Г ө л ф и р ә. Син кыланасың гына бит, әйеме?
Ә л м ә н д ә р. Дәү бабаң гумере буе кыланчык булды, кызым.

Бакча капкасы янында — Х ә м д е б а н у белән Ө м м и я.

Ө м м и я. Нишләтәсең инде, Хәмдебану. Элек тә тулы түгел ие, хәзер булганы да чыгып беткән. Оят инде, оят.
Х ә м д е б а н у. Хәерле булсын.
Ә л м ә н д ә р. Килгәч нигә керми торасың, Хәмдебану?!
Х ә м д е б а н у. Керәм, Әлмәндәр абзый, керәм.

Ө м м и я белән алачык янына киләләр.

Ә л м ә н д ә р. Йоклый идеңме, Хәмдебану?
Х ә м д е б а н у. Юк, Әлмәндәр абзый, уянган идем.
Ә л м ә н д ә р. Бер ялгызың күзгә йокы кермидер шул. Менә мин дә йоклый алмыйм.
Х ә м д е б а н у. Йокларсың, Алла боерса.
Ә л м ә н д ә р. Йокларбыз, диген, Хәмдебану.
Х ә м д е б а н у. Әй Алла...
Ө м м и я. Сөйләмә дә инде.
Ә л м ә н д ә р. Кияүгә чыкмыйм дисең инде, алайса, Хәмдебану?
Х ә м д е б а н у. Чыгарбыз, Әлмәндәр абзый, чыгарбыз.
Ә л м ә н д ә р. Кемгә?
Х ә м д е б а н у. Кемгә дип... Әй Алла... Исән-сау терел дә, чыгарбыз.
Ә л м ә н д ә р. Мин авырумыни?

Х ә м д е б а н у. Юк, Әлмәндәр абзый, Алла сакласын.

Ә л м ә н д ә р *(кинәт көлә башлый. Көлеп туктагач).* Әй килен, килен. Каенатаңны ничек чирләтергә белми аптырыйсың ла инде. Авырмыйм мин, Хәмдебану, таптаза мин.

Х ә м д е б а н у. Шулай булмый соң... Шулай, Әлмәндәр абзый.

Ә л м ә н д ә р. Кил әле, утыр әле яныма. Кит, улым, читкәрәк, кыз белән егет сөйләшкәнне тыңлап утыру — гөнаһ. Утыр, Хәмдебану, курыкма, тимим.

Х ә м д е б а н у. Утырам, Әлмәндәр абзый, нидән курыкыйм. *(Утыра.)*

Ә л м ә н д ә р. Әгәренки кулым белән ялгыш кагылсам, колак төбемә утыртырсың, ярыймы. Теге вакытта түбән очның Бозау Закирга суккан шикелле итәрсең. Хәтереңдәме?.. Егерме биш яшеңдә ирсез калып берәүне дә якын җибәрмәдең шул. Һаман бер ялгызың. Үзсүзле хатын булдың, Хәмдебану. Димләп карадым, гумереңне заяга үткәрмә, интекмә дип, бүтәннәргә димләп карадым, ачуланган чакларым булды. Сүземне тыңламадың. Үземә кияүгә чык дип бәйләндем — ачуландың. Рәхмәт, рәхмәт, Хәмдебану, сынатмадың. Ирең мәрхүмне рәнҗетмәдең. Әгәренки мин хөкүмәт башында торсам, синең кебекләргә мидал бирер ием. Ишетәсеңме, Гөлфирә кызым?

Өй ягыннан бакчага Е в с т и г н е й чыга.

Е в с т и г н е й. Альмандар, ай, Альмандар!..

Ә л м ә н д ә р. Здич мин, Ястәгнәй.

Е в с т и г н е й *(алачык янына килеп).* Син — шайтан, Альмандар. Кая качтың? Бакча чыгам — син юк. Аптыраш. Бригадирга барам, ат бир, әйтәм, Альмандар барам. Начар, Альмандар. Дус качкан, начар. Килям. Ызба керәм — юк. Тыңлыйм — гур-гур-гур — син тавыш.

Ә л м ә н д ә р. Садис, Ястәгнәй. Малы-малы балакыем. Сын, сноха, дучка, Хәмдебану сидим балакыем, хураша. День идет, сулныцы идет.

Е в с т и г н е й *(башкаларга).* Якшимисиз?

Ө м м и я. Зрастуй, Ястәгнәй дәдәй. Старик ни слушай. Маклашка давай. Один сад ходит, писнә пают. *(Гөлфирә көлгәнне күреп.)* Нигә көләсең?

И с к ә н д ә р. Сөйләшә белмәсәң, тик тор, Өммия!

Ө м м и я. Сез генә оста инде.

Е в с т и г н е й. Ничево! Якши, якши, килин. *(Әлмәндәр янына утырып.)* Ну, как кайткан? Мин курыккан.

Ә л м ә н д ә р. Хураша, Ястәгнәй. Ассалуди, былгаруди. Спасибы.

Йоклаган И л с у р н ы күтәреп, М а н с у р керә. Бакчага кергәч уятырга тырыша.

М а н с у р. Уян диләр! *(Колагын уып.)* Уян!

Илсур тиберченә.

Ә л м ә н д ә р. Тимә! Ник тиясең малайга?

М а н с у р. Уянмый ич.

Илсурны җиргә бастыра. Илсур җиргә утыра, күзләрен уа.

Ә л м ә н д ә р. Кешене шулай уяталармы, кит яныннан. *(Илсур каршына тезләнеп.)* Нәрсә, йоклаулары бик тәмлемени? Йокла, йокла.

Илсур, күзләрен ачып, Әлмәндәргә карап тора.

Таныдыңмы? Мин ич бу. Канфит кирәкме?

И л с у р. Кирәкми.

Ә л м ә н д ә р. Бал ашыйсың киләме?

И л с у р. Ю-ук.

Ә л м ә н д ә р. Алма биримме?

И л с у р. Бирмә.

Ө м м и я. Интектермә инде баланы.

Ә л м ә н д ә р. Илсур, мин китәм бит.

И л с у р. Кая?

Ә л м ә н д ә р. Әллә кая, бүтән кайтмыйм.

И л с у р. Китмә!

Ә л м ә н д ә р. Уянсаң китмим.

И л с у р. Мин йокламыйм.

Ә л м ә н д ә р. Менә муладис. Яле бер җырлап җибәр.

И л с у р. Җырлыйсым килми.

Ә л м ә н д ә р. Мин җырлыйммы соң?

И л с у р. Җырла.

Ә л м ә н д ә р *(көйләмичә генә)*.

Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Безнең башлар балык түгел,
Куырып ашамаслар.

И л с у р *(елмаеп)*. Алай түгел.

Ә л м ә н д ә р. Ничек соң?

И л с у р. Беләсең. Юрый-марый гына кыланасың.

Ә л м ә н д ә р. Кыланмыйм инде. Оныткнмын. Шуңа күрә сине чакырып китердем.

И л с у р. Көләсең.

Ә л м ә н д ә р. Көлмим ич инде.

И л с у р *(көйләмичә генә)*.

Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

Ә л м ә н д ә р. Муладис! Әйдә, хәзер көйләп…

И л с у р. Алма бир!

Ә л м ә н д ә р. Алмамы? Бирәм. Ал үзең өзеп.

И л с у р. Син үзең бир.

Ә л м ә н д ә р. Үземме? Хәзер, хәзер… *(Якындагы алмагачтан алмалар өзеп, Илсур алдына өеп куя.)* Менә… Булдымы?

И л с у р. Булды. *(Җырлый.)*

Без андый малай түгел лә,
Без мондый малай түгел.

Илсурга Әлмәндәр кушыла.

Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

Әлмәндәрнең күзе алмагач артында басып торган Әҗәлгә төшә.

Ә л м ә н д ә р. Яле, Илсур, тагын берне сыздыр. «Шырдый»ны…

И л с у р. Мин җырлыймын бырдыйны,
Бырдый белән шырдыйны.
Мин җырлаганны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Илсур җырлаганда, Әлмәндәр Әҗәл янына бара. Әҗәлнең кулыннан кәгазь-карандаш алып, кәгазьне Әҗәлнең сыртына җәеп, кул куя.

Җырның соңгы ике юлын кабатлап җырлап, алачык янына килә.

Ә л м ә н д ә р. Мин җырлаганны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Ут сүнә.

## Эпилог

Пролог һәм интермедиядәге күренеш. Сәхнәнең бер ягыннан — Газраил, икенче ягыннан Әҗәл чыга.

Газраил. Кайда Әлмәндәр?
Әҗәл *(кәгазьне сузып)*. Алыгыз, сезнеңчә булды.
Газраил. Кайда үзе?
Әҗәл. Алгы бүлмәдә утыра.
Газраил. Алып кер.

Алгы бүлмәдә Фәрештәнең чәрелдәп кычкырганы ишетелә һәм Газраил кабинетына Фәрештә атылып килеп керә.

Газраил. Ни булды?
Фәрештә *(кытыкланып)*. Ул, ул мине кочаклый.
Газраил. Кем?
Фәрештә. Карт.
Әҗәл. Карт түгел, Әлмәндәр. Әлдермештән Әлмәндәр.

Алгы бүлмәдән Әлмәндәрнең «Бырдый белән Шырды»е яңгырый.

Пәрдә.

# АК ТӘҮБӘ, КАРА ТӘҮБӘ

*(Ике пәрдәле, дүрт күренешле тамаша)*

Катнашучылар:

Ризван<br>
Низам<br>
Заһир } — студентлар.<br>
Гомәр.<br>
Тәнзилә.<br>
Алинә — авылда клуб мөдире.<br>
Нәҗми — гармунчы егет.<br>
Дамирә — Низамның сөйгән кызы, студентка.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Тар гына елганың яшел үләнле яры. Юан гына ике тирәк үсеп утыра. Елга аша басма салынган. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда, Ризван, Низам, Заһир зур гына чатырның соңгы бавын казыкка бәйләп торалар. Гомәр бер читтәрәк, берүзе ике тирәк арасына гамак бәйләп маташа. Өч егет чатыр бавын бәйләп куялар да Гомәрнең азапланганын күзәтәләр.

Ризван. Аерым хуҗалыкка дөнья көтүләре һәрвакытта да авыр булган.

Низам. Коллективтан аерылганны аю ашаган.

Заһир. Ялгыз башка кайда да бер —<br>
Таң ата да кич була.

Гомәр эндәшми генә бәйләвен дәвам итә.

Ризван. Һәрбер хуҗалык үзе өчен генә тырышканга, крестьян восстаниеләре җиңелүгә дучар булган.

Н и з а м. Бөтен коллектив — уң якка, ул берүзе — сул якка...

З а һ и р. Ялгыз башың, түгелер яшең,
Кемнәр булыр юлдашың?

Гомәр гамакны бәйләп бетерә дә, гамак өстенә менеп, аякларын бөкләп утыра.

Р и з в а н. Тәхеткә үзе менеп утырган бер генә патшаның да уңышка ирешкәне булмаган.

Н и з а м. Гамак өстендә берүзең солтан булганчы, палатка эчендә коллективның олтаны бул.

З а һ и р. Өскә менгән — егылып төшкән, толып төшеп башын тишкән.

Г о м ә р *(тирәк ботагында эленеп торган гитараны кулына алып, кылларын чиртә)*.

Көлегез, көлегез,
Файдасы юк — белегез.

Р и з в а н. Оппортунист!

Н и з а м. Ренегат!

З а һ и р. Индивидуалист!

Г о м ә р. Көнләшегез, туң күчәннәр!

Н и з а м. Бик исебез китте, әйеме, кызлар?

Р и з в а н. Вакытны уздырмыйк. Килегез, тезелегез!

Сәхнә алдына килеп басалар.

Р и з в а н. Антның текстын укыйбыз. «Без, Төзелеш академиясенең дүртенче курс студентлары, җәйге каникулыбыз вакытында, аерым бригада оештырып, авылда Культура сарае төзелешенә эшләргә килдек».

Г о м ә р *(гамак өстеннән)*. Ха-ха!

Р и з в а н
Н и з а м } Шабашкага килдек.
З а һ и р

Р и з в а н. Без шабашниклар түгел, намус белән акча эшләүчеләр. Без — Низамов Ризван, Рамазанов Низам, Закиров Заһир тантаналы рәвештә ант итәбез: эшләү чорында бөтен ихтыяр көчебезне бары тик эшкә генә тупларга, бары тик башкарылачак эш турында гына уйларга. Бу максаттан читкә тайпылуларга юл куймаска.

Г о м ә р. Ха-ха!

Ө ч е г е т *(Гомәр ягына борылып)*. Нәрсә «ха-ха»?

Гомәр. Бирелгән антыгыз ха-ха булачак!

Ризван. Болай булмый. Әйдәгез, шул карганың оясын туздырабыз, очсын безнең яннан.

Өчәүләп Гомәр янына бармалар.

Өч егет *(берьюлы)*. Очып кит безнең яннан, эзең булмасын!

Гомәр. Кая телим, шунда кунам. Мин — ирекле кош. Кошларга тимәгез, балалар, табигатьне яратыгыз!

Ризван. Алайса, телеңне тый!

Гомәр. Аңлашылмый, әфәнделәр!

Заһир. Ә нәрсә аңлашылмый?

Гомәр. Сез мәхәббәт дигән бөек хисне ваклыйсыз. Гашыйк булу, имеш, эшкә комачаулый. Ялгышасыз, әфәнделәр. Тормышның үзәге — мәхәббәт!

Низам. Дөрес түгел! Мәхәббәт кешене акылдан яздыра. Гашыйк булган кеше төн йокламый. Йокламаган кеше ябыга. Ябык, хәлсез кешедән нинди эш көтмәк кирәк.

Гомәр. Дөньядагы барлык гашыйклар ябык, хәлсез дип әйтергә телисеңме, Заһир әфәнде?

Заһир. Без бит, мәхәббәт кирәкми, димибез, Гомәр... Без вакытлыча...

Ризван. Туктагыз! Димәк, болай: антның текстын кабул итәбез һәм ант итәбез.

Өч егет *(берьюлы)*. Ант итәбез, ант итәбез, ант итәбез!

Гомәр. Әфәнделәр! Ашыгасыз, әфәнделәр! Антыгызның шарты юк. Антын бозган кешене нишләтмәкче буласыз?

Ризван. Безгә шарт кирәкми.

Гомәр. Шартсыз ант булмый, әфәнделәр. Телисезме, мин сезгә ярдәм кулымны сузам? Антын бозган кешегә җәзаны үзем билгелим.

Низам. Нишләтерсең икән, Гомәр?

Гомәр. Мин рәхимсез булачакмын! Ризамы?

Низам. Ризван, нишлибез?

Ризван. Курыкмаска! Сер бирмәскә!

Гомәр. Димәк, өчегез дә риза?

Заһир. Мин риза.

Гомәр. Син, Низам?

Низам. Беткән баш беткән!

Г о м ә р. Син, Ризван?

Р и з в а н. Мин дәшмим.

Г о м ә р. Дәшмәү – ризалык билгесе, Аллага тапшырыгыз.

Н и з а м. Инде нишлибез, Ризван?

Р и з в а н. Палатка тирәсен бау белән әйләндереп алабыз, безнең территориягә бер кыз да аяк басмаска тиеш.

Чатыр эченнән бау алып чыга. Өчәүләп бау сузалар. Гомәрнең гамагы янына җиткәч туктыйлар.

Н и з а м. Гомәрне нишләтәбез, үзебезнең территориягә кертәбезме?

Р и з в а н. Үзенең мәхәббәте белән читтә калсын.

Г о м ә р *(гамак өстенә басып)*. Калырмын да! Йөрәгемдә ут янганда, тәнемдә җан барында беркайчан да, теләсә нинди очракта да һәр минутта, һәр секундта кызлар сөюдән туктамам, йөрәгем утына су сипмәм. Беләгемнең көче – эш өчен, йөрәгемнең хисе – мәхәббәт өчен!

Р и з в а н. Суз бауны!

Гомәрнең «биләмәсе»н кырыйда калдырып, бауны суза-суза, сәхнәдән чыгып китәләр. Гомәр кулына гитарасын алып җыр суза.

Г о м ә р. Күңелдә җыр туа,
Күңелгә нур тула,
Талларда
Таңнарда
Сандугач сайраса, моңланса;
Сандугач кунармы талларга,
Сандугач сайрармы таңнарда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

Ө ч е г е т, бауны сузып бетереп, сәхнәгә керәләр.

Н и з а м *(Гомәргә)*. Җырлыйсың, ә?

Г о м ә р. Җырлыйм.

Р и з в а н. Үзең генә җырлыйсың?

Г о м ә р. Икәү. Кулымда җан дустым – гитара бар. *(Җырын дәвам иттерә.)*

Юл чыгу читен лә,
Юлыңның чигендә,
«Кил» диеп елмаеп,

Бәхетең чакырып тормаса;
Бәхет соң буламы дөньяда,
Дөньяда яшәүдән ни файда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

Р и з в а н. Ә без өчәү булгач гитарасыз да җырлыйбыз. Әйдәгез, җырларга!

З а һ и р. Кайсы җырны?

Р и з в а н. Үзебезнең гимнны. Килегез!

Сәхнә алдына киләләр, тезләнәләр.

Башладык. Үзем башлыйм.

Беләктә көчебез барында,
Эшлисе эшебез барында,
Онытып дөньяда барын да,
«Эш» диеп әйтәбез тагын да.

Б е р г ә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

Н и з а м. Зөһрәләр безгә һич кирәкми,
Ләйләләр безгә һич кирәкми,
Тышаулап куябыз йөрәкне,
Җигәрбез эшкә без беләкне.

Б е р г ә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

З а һ и р. Эш кенә тормышның тоткасы,
Эш кенә дөньяның ноктасы;
Куертмыйк мәхәббәт боткасын,
Йөрәкләр ял итсен, йокласын.

Б е р г ә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

Г о м ә р. Аккомпаниатор җитми, әфәнделәр. Миннән башка барыбер эшегез барып чыкмас.

Н и з а м. Чыкмаса чыкмас, ялынып бармабыз.

Р и з в а н. Болай сөйләшәбез: Гомәр Шәйхетдинов белән араны өзәргә, һичнинди мөнәсәбәткә кермәскә, соравына — җавап, җавабына сорау бирмәскә! Чөнки ул әлеге көнгә кадәр безнең белән дус булып йөреп, бүген безгә хыянәт итте. Әйдәгез, палатка эчен тәртипкә китерәбез.

Өчәүләп чатыр эченә кереп китәләр. Т ә н з и л ә керә.

Т ә н з и л ә. Хәерле кич, Гомәр!

Г о м ә р. Хәерле кич, мадемуазель!

Т ә н з и л ә. Урнашып беттегезме?.. Син ял йортына килгән кебек.

Г о м ә р. Көндез эштә, төн гамакта яшәп гомер итәбез.

Т ә н з и л ә. Калган өчегез кайда?

Г о м ә р. Чатыр эчендә.

Т ә н з и л ә. Бу бау ни өчен?

Г о м ә р. Сере бар.

Т ә н з и л ә. Кыланасыз, егетләр! Башкалар белән бергә авылда яшәсәгез ни була?

Г о м ә р. Кызык булмый.

Т ә н з и л ә. Сез монда кызык эзләргә килдегезмени?

Г о м ә р. Эшләрбез, иптәш мадемуазель! Эштән соң калган вакыт та бар. «Көндез эштә, кич клубта комсомолка Гөлсара» дип җырлаган безнең әбиләр, иптәш мадемуазель!

Т ә н з и л ә. Нәрсә мине үртисең?

Г о м ә р. Ничек үртим? Әллә син мадемуазель түгелме?

Т ә н з и л ә. Минем исемем дә бар. *(Баудан атлап үтмәкче була.)*

Г о м ә р. Ярамый, Тәнзилә!

Т ә н з и л ә. Нигә ярамый?

Г о м ә р. Бауның теге ягына кызлар аяк басмаска тиеш.

Т ә н з и л ә. Монысы тагын нинди уен?

Г о м ә р. Уен түгел, чын. *(Кычкырып.)* Әй, әфәнделәр, тирмәгезнең дивары янында — сыйнфый дошманыгыз.

Чатырдан берәмләп е г е т л ә р чыга.

Т ә н з и л ә. Хәерле кич, егетләр!

Е г е т л ә р. Хәерле кич!

Т ә н з и л ә. Нинди уен уйлап чыгардыгыз? Мине Гомәр бауның теге ягына кертми.

Р и з в а н. Гафу ит, Тәнзилә, бу очракта ул дөрес эшләгән.

Н и з а м. Гомәрнең бердәнбер дөрес эше.

З а һ и р. Без ант иткән идек, Тәнзилә!

Т ә н з и л ә. Ант? Нинди ант?

Г о м ә р. Гашыйк булмаска, бер генә кызга да күз салмаска, чибәрләр очраса да, сер бирмәскә ант иттеләр.

Р и з в а н. Без монда эшләргә ялландык, кызлар артыннан чабарга түгел.

Н и з а м. Бу авылда чакта беләгебезнең көче, йөрәгебезнең хисе эш өчен генә сарыф ителергә тиеш.

Т ә н з и л ә. Шулаймыни?

З а һ и р. Шулай иде шул, Тәнзилә. Шулай бит, Ризван?

Р и з в а н. Әйе, шулай.

Т ә н з и л ә. Тилермәгез, егетләр!

Р и з в а н. Гафу ит, Тәнзилә! Без тиле түгел, без акча эшләргә килдек.

Н и з а м. Эш турында онытып, төн йокламый кызлар артыннан чапсак, икенче көнне эленке-салынкы эшләсәк ни була?

Т ә н з и л ә. Ләкин...

Р и з в а н. Нәрсә «ләкин»?..

Н и з а м. Нигә «ләкин»?..

Т ә н з и л ә *(көлеп)*. Ярый, әйдә кыланыгыз... Тик озакламый су буена төшегез. Авыл яшьләре анда кичке уенга җыела. Танышырбыз, дуслашырбыз.

Р и з в а н. Гафу ит, төшә алмыйбыз.

Н и з а м. Без коллектив биюләр, танцы-манцылар, дискотека-мискатека белән мавыкмаячакбыз. Көз көне чебешләрне санагач биербез.

Т ә н з и л ә. Шаярмагыз инде, егетләр!

Р и з в а н. Без монда шаярырга килмәдек. Һәм син дә анда-монда йөрмә. Син — безнең бригада члены. Безнең аш пешерүчебез. *(Тәнзиләгә сырты белән борылып баса.)*

Н и з а м. Безнең поварыбыз! *(Ризванча эшли.)*

З а һ и р. Шулай сөйләшкән идек шул, Тәнзилә. *(Теләр-теләмәс кенә борыла.)*

Т ә н з и л ә. Кыланчыклар! Онытмагыз су буена төшәргә. *(Көлә-көлә чыгып китә.)*

Г о м ә р. Дөрес! Шулай! Нык торыгыз, әфәнделәр! Әмма дә ләкин шунысы бар, Заһирга читен булачак.

З а һ и р. Ә ни өчен миңа?

Г о м ә р. Язган шигырьләреңне кемгә укырсың? Аларны бит Тәнзиләдән башка беркем тыңламый.

Н и з а м. Әйт, Заһир, түзәрмен, диген.

Г о м ә р. Әйтә күрмә, Заһир.

Р и з в а н. Әйт, түзәрмен, диген.

З а һ и р. Түзәрмен... Тырышырмын.

Низам белән Гомәр көлеп җибәрәләр.

Р и з в а н. Көлүне туктатыйк! *(Чатырга кереп китә.)*

Аңа Низам белән Заһир иярә.

Г о м ә р. Көлүне туктатыйк, иптәшләр, комедия башлана. *(Көянтә-чиләк күтәреп узып баручы Алинәне күреп ала.)* Авыл кызына ялкынлы сәлам!

А л и н ә *(туктап)*. Нәрсә-ә-ә?

Г о м ә р. Авылның чибәр кызына ялкынлы сәлам! Мыскыл итеп әйтмим. Мин үзем дә авыл малае. *(Гамактан сикереп төшеп, Алинә каршына баса.)* Исәнмесез! Минем исемем — Гомәр, фамилиям — Шәйхетдинов.

А л и н ә. Булса ни?!

Г о м ә р. Сезнең авылга культура учагы кабызырга килдек. Культура йорты салачакбыз.

А л и н ә. Салсагыз ни?!

Г о м ә р *(Алинәнең бер дә исе китмәвенә аптырап)*. Киләсе елда яңа Культура йортына танцыга йөрерсез.

А л и н ә. Йөрсә ни?!

Г о м ә р. Туктагыз әле, нәрсә һаман ни дә ни. Елгага кер чайкарга төштегезмени?

А л и н ә. Төшсә ни?!

Г о м ә р. Нәрсә сез мине үртәгән сыман сөйләшәсез?

А л и н ә. Сөйләшсә ни?!

Г о м ә р. Һе... Менә тутый кош. Һаман бер сүзне тукый.

А л и н ә. Тукыса ни?!

Г о м ә р *(ачуы чыгып)*. Туктатуыма гафу итегез! Юлыгызны дәвам итегез!

А л и н ә. Итсә ни?! *(Китми. Гомәргә туп-туры караган килеш кузгалмый да)*.

Г о м ә р. Сау булыгыз, дим.

А л и н ә. Дисәгез ни. *(Һаман китми. Селкенми дә.)*

Г о м ә р *(аптыраганнан көлеп җибәрә)*. Менә каптым.

А л и н ә. Капсагыз ни?!

Г о м ә р. Ярый, ярый, ни, ни, ни. Аңлашылды. Ни икәне аңлашылды. Тик тора белмәсәң, шулай була ул, Гомәр дус.

А л и н ә. Булса ни?!

Г о м ә р *(кычкыра)*. Китегез, китегез моннан тизрәк. *(Ашыга-ашыга, гамагына менеп утыра.)*

Алинә һаман да, кузгалмыйча, Гомәргә карап басып тора. Гомәр дә аңа карап куя.

А л и н ә. Шуннан ни?

Г о м ә р. Уф! *(Капланып ята.)*

Алинә һаман китми. Гомәр башын күтәреп караганда да басып тора. Башка түзәр хәле калмагач, Гомәр, гамактан төшеп, чатыр артына кача. Шуннан башын сузып Алинәне күзәтә. Алинә һаман китми.

*(Чатыр янына утырып, үз-үзенә сөйләнә.)* Кирәк бит, кемгә эләктем бит, тилегә юлыктым бит. *(Башын сузып карый, Алинәнең һаман да китмәгәнен күргәч, чатыр артыннан чыгып, янына килә дә үгетләгән тавыш белән сөйләнергә тотына.)* Бар, сеңлем, кайт инде, әти-әниең көтәләрдер.

А л и н ә. Көтсәләр ни?!

Г о м ә р. Көтсәләр ни дип, алай ярамый, сеңлем! Үзеңне эзләп чыгарлар. Егетләр янында басып торганыңны күреп ачуланырлар. Син акыллы кыз бит, бар инде, кайт. Син бит абыйлар әйткәнне тыңлыйсың, әйеме? Мин синең абыең. Бар, сеңлем, бар!

А л и н ә. Барса ни. *(Борылып китеп бара.)*

Г о м ә р *(җиргә утырып)*. Уф! Йа Тәңрем, мең рәхмәт сиңа! Чибәрлекне өеп биргән үзенә.

А л и н ә яңадан әйләнеп керә. Керә дә Гомәр каршына баса. Торараш булып каткан Гомәр, телсез калып, Алинәгә карап тора.

А л и н ә *(чиләк-көянтәсен җиргә куеп, гамак янына килә. Андагы гитараны кулына ала)*. Бу ни? *(Гомәр җавап бирмәгәч.)* Бу ни?

Пауза.

Бу ни?

Г о м ә р *(чыгырыннан чыгып)*. Автомобиль!

А л и н ә *(гитараның кылларына чиртеп куя да кычкырып көлеп җибәрә. Көлеп туйгач)*. Йә, ни әйтергә теләгән идегез миңа, Гомәр абый Шәйхетдинов? Безнең авылда Культура йорты саласыз инде, шуннан ни? Ша-

башниклар инде сез. Шуннан ни? Шуны әйтер өчен туктаттыгызмы инде? Сөйләгез, тыңлыйм сезне, Гомәр абый Шәйхетдинов. Авыл кызын шаккатырырга уйладыгыз инде, ә? Гамак бәйләп куйдыгыз инде тирәккә? Гитара чиертә беләсез инде. Йә, чиртеп күрсәтегез, ничегрәк чиртәсез икән?

Гомәр *(ниһаять, исен җыеп)*. Сез... кем?

Алинә. Авыл кызы. Исемем — Алинә, фамилиям — Шәйхетдинова.

Гомәр. Ничек «Шәйхетдинова»? Мин — Шәйхетдинов.

Алинә. Мин — Шәйхетдинова.

Гомәр. Юк, мин — Шәйхетдинов.

Алинә. Сез — Шәйхетдинов, мин — Шәйхетдинова. Шәйхетдин исемле кешеләр сезнең авылда гына түгел. Бәлки, сез миңа туган тиешледер? *(Гитара уйнап, чит телдә бер җыр җырлап ала. Гитараны үз урынына куеп, көянтә-чиләкләрен алып китә башлый.)*

Гомәр *(аның артыннан барып)*. Туктагыз әле!

Алинә. Туктамаса ни?! *(Чыгып китә.)*

Гомәр. Кем булды соң бу? Нәрсә булды соң бу?

Чатыр ишегендә өч баш күренә.

Ризван. Тешебезне кысып түздек, иптәш Шәйхетдинов.

Низам. Һәрнәрсәнең чиге була, ялгыз булсаң да, коллективны хөрмәт итәргә кирәк.

Ризван. Мәҗбүр итәрбез.

Низам. Узган-барган кызга җүләрләр генә гитара чиртеп кала.

Заһир. Гомәр, ә нигә син ул кызга кычкырдың? Авыл кызына кычкырып, безнең дәрәҗәне төшермә.

Ризван. Кычкырасың килсә, палатка яныннан читкәрәк алып китеп кычкыр.

Низам. Һәм, гомумән, кызлар белән сөйләшәсең килсә, басма өстендә сөйләш.

Гомәр. Туктагыз әле, болай да башым әйләнгән.

Өч егет өчесе дә чатыр эченнән чыгып, Гомәр каршына басалар.

Ризван. Искитәрлек берни дә юк. Муен тотрыксыз булгач, баш әйләнә инде ул.

Низам. Менә безнең башлар әйләнми.

Гомәр. Кызы чибәр, әфәнделәр.

Заһир. Чибәрләр күп булыр. Әйеме, Ризван?

Ризван. Әйе. Иртәгә эш башлыйбыз. Кызлар турында уйларга түгел, йоклау ягын уйларга кирәк.

Гомәр. Мин ант итмәдем.

Низам. Алайса, безгә комачаулама.

Гомәр. Юкка без сине бригадир иттек, Ризван, приказ биреп җаннарын алырсың инде. Начальник булырга бигрәк яратасың.

Ризван. Юк-бар сүзләрне тыңламаска! Йокларга!

Низам. Йокларга!

Заһир. Йокларга!

Гомәр. Карагыз әле безнең Тәнзиләгә, басма өстендә кем белән басып тора?

Заһир *(атылып, Гомәр янына килә)*. Кайда?

Гомәр. Качтылар. Очты Тәнзилә.

Ризван. Заһир! Гомәр Шәйхетдинов сүзенә игътибар итмәскә! Йокларга!

Низам. Тузга язмаган сүзләргә колак салмаска! Йокларга!

Заһир. Әйе, йокларга... *(Теләр-теләмәс кенә чатыр ягына борыла.)*

Иңенә тальян гармун аскан Нәҗип керә.

Нәҗип. Исәнмесед! *(Ул Мөслим ягы диалектында сөйләшә.)*

Гомәр. Исән бед!

Нәҗип. Үдебеднең як егете дә бар икән. Кайсы авылныкы, апаем?

Гомәр. Миндәлә.

Нәҗип. Әйбәт. Беднең районнан кала әйбәт кешеләр Миндәләдә. Клуб салырга килдегедмени беднең авылга?

Гомәр. Клуб түгел – Культура сарае.

Нәҗип. Сәхнәле булса, клуб була инде ул. Исемең ничек, апаем?

Гомәр. Гомәр.

Нәҗип *(Заһирга)*. Ә синең?

Заһир. Заһир.

Нәҗип *(Низамга)*. Ә синең?

Низам. Габделмиңлемөхәммәт.

Нәҗип. Андый исем булмый. Мин алдашкан кешеләрне яратмаем, апаем. Аркам кычыта башлай.

Г о м ә р. Низам ул.

Н ә җ и п. Низам? *(Низамга.)* Мине дуракка санама, ярыймы, апаем. Сигез класс бетергән. *(Ризванга.)* Ә син ни исемле?

Р и з в а н. Нигә кирәк ул?

Н ә җ и п. Әйтәсең килмәймени?

Р и з в а н. Килми.

Н ә җ и п. Килмәй икән – әйтмә. Безнең авылда яшисең бар, апаем.

Г о м ә р. Үзегез ни исемле соң?

Н ә җ и п. Нәҗип. Фермада эшләем мин. Җәен көтү көтәм, кышын тирес түгәм. *(Гомәрнең гитарасын кулына алып.)* Бу каз муенында кайсыгыз уйный?

Г о м ә р. Мин.

Н ә җ и п. Яхшы уйнайсыңмы?

Н и з а м. Яхшы.

Н ә җ и п. Синнән сорамаем, апаем, уйнаучыдан сораем. *(Гомәргә.)* Яле, уйнап күрсәт!

Р и з в а н. Низам! Заһир! Йокларга! Гомәр, бернинди уйнау юк, без йоклыйбыз.

Н ә җ и п. Нәчәлник мәллә син, апаем, кыланган буласың. *(Гомәргә.)* Уйнап күрсәт.

Р и з в а н чатыр эченә кереп китә. Низам белән Заһир кызыксынып калалар.

Уйнап күрсәт, мин барында курыкма. Районга – глава, авылга мин хуҗа.

Г о м ә р. Нинди көйне уйныйм?

Н ә җ и п. «Гөлҗамал»ны.

Г о м ә р. Аны белмим шул.

Н ә җ и п *(куанып)*. Әһә, белмәйсең. Ә мин беләм. *(Гармунын кулына алып, уйнап җырлый.)*

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер-җеп эрлиләр.
Энҗе-мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Булдымы?

Г о м ә р. Булды.

Н ә җ и п. Әйдә, син дә булдыр.

Г о м ә р. Алай тиз генә булмый ул.

Н ә җ и п. Булмаймы? Уйна мин белмәгән көеңне.

Г о м ә р. Туктагыз әле...

Н ә җ и п. Туктамаем. Уйна! *(Низам белән Заһирга.)* Уйнасынмы?

Н и з а м. Уйнасын, уйнасын.

Н ә җ и п *(Заһирга)*. Нигә син уйнасын дип әйтмәйсең, апаем?

З а һ и р. Уйнасын.

Н ә җ и п *(Гомәргә)*. Уйна!

Г о м ә р. Әкәмәт! *(Әлегә хәтле ишетелмәгән яңа көйне уйный.)*

Н ә җ и п *(бераз вакыт колагын салып тыңлап торгач)*. Тукта!

Гомәр туктый.

*(Шул көйне гармунда уйный.)* Булдымы? Әйдә миңа кушыл.

Икәүләп уйнагач.

Кайда синең каз муеныңның тавышы? Гармун бугазлап ташладымы? Егет булсаң, дыңгылдатма бу каз муеныңны, гармунга өйрән. Гармун орып бирә синең бу каз муеныңны. Дөресме?

Н и з а м. Дөрес, дөрес!

Н ә җ и п *(Заһирга)*. Син нигә дөрес дип әйтмәйсең, апаем?

З а һ и р. Һәр инструментның үз урыны.

Н ә җ и п. Струмент, струмент... Ышкы да струмент, өтергә дә струмент, бу да струмент. Гармун струмент түгел, гармун ул — гармун. Алинә дә шул каз муенында уйнавы белән мактанган була. Шуны кулларына тоталар да әллә кем булалар. *(Еларга җитешеп.)* Минем күзем төшеп йөргән кыз каз муенын уйнаучы синең кебек шабашникка ияреп китте. Алты ел, сүз әйтергә дә оялып, яратып йөрдем. Уналты яшемнән егерме икегә хәтле. Алты ел тәрәзә төпләреннән гармун уйнап уздым — сизмәде. Иярде дә китте. Сезнең кебек берәү өченче ел сыерлар абзары салырга килде дә, каз муенын уйнап, Гөлнарны иярттеп китте. Эх! *(«Авыл көе»нә сыздырып җибәрә.)*

Гармун бәләкәй булса да,  
Әйтә ул кирәкләрен.  
Сикер дә төш, чум суларга,  
Янса яшь йөрәкләрең.

Шаярмагыз, апайлар, шаярмагыз гармун белән. Бернәрсә белән дә шаярмагыз. *(Кинәт борылып чыгып китә.)*

Пауза.

Н и з а м *(кинәт көлеп җибәрә)*. Шаярмагыз, кызлар!

Г о м ә р. Ни булды соң бу? Каян килеп чыкты?

Р и з в а н *(чатыр эченнән)*. Йокларга!

З а һ и р. Шаярмагыз, ди. Мәгънәсе бар бугай бу сүзнең?..

Н ә җ и п *(яңадан әйләнеп кереп)*. Безнең авылда бер кыз бар. Хәзер минем күзем аңа төшеп йөри. Карагыз, апайлар, әгәр дә башын әйләндерсәгез, барыгызны бергә өеп куеп ярам. *(Чыгып китә.)*

Н и з а м. Күрдеңме, Заһир, мәгънәсен? Ишеттеңме, Гомәр? Шаярма, дидеме сиңа?

Р и з в а н *(чатыр ишегеннән башын тыгып)*. Йокларга!

Г о м ә р. Миңа нәрсә, сез нишләрсез? Син нишләрсең, Низам? Кызлар күрсәң, күзләрең зырылдап әйләнә башлый.

Н и з а м. Сер бирмәбез дошманга. *(Чатырга кереп китә.)*

Г о м ә р *(Заһирга)*. Ә син?

З а һ и р. Син Тәнзиләне чынлап күрдеңме? Егетләр белән идеме?

Г о м ә р. Кызлар белән басма өстендә йөрмәс инде.

Р и з в а н *(чатыр эченнән)*. Йокларга!

З а һ и р. Йөрсен. Анысы аның эше. *(Чатырга кереп китә.)*

Гомәр, гамакка менеп утырып, гитара чиртеп, «Гөлҗамал» көен уйнап азаплана. Т ә н з и л ә керә.

Т ә н з и л ә. Кайда егетләр?

Г о м ә р. Йоклыйлар.

Т ә н з и л ә. Ничек «йоклыйлар»?

Г о м ә р. Ничек йоклаганнарын белмим, Тәнзилә, кереп карамадым.

Т ә н з и л ә. Син гитараңны әйбәт уйныйсың, Гомәр, ләкин сөйләшкәндә тапкырлыгың җитеп бетми.

Г о м ә р. Ягъни мәсәлән?

Т ә н з и л ә. Әллә алар чынлапмы?

Г о м ә р. Чынлап, Тәнзилә.

Т ә н з и л ә. Арттырып җибәрәсез. Син аларга кушылмадыңмы?

Г о м ә р. Кушылмадым. Программалары белән килешеп бетмим.

Т ә н з и л ә. Әйдә, алайса, су буена.

Г о м ә р. Мин бит шигырь язмыйм, Тәнзилә.

Т ә н з и л ә. Гомәр, әгәр минем белән болай сөйләшсәң, мин, гомумән, синең белән сөйләшмәячәкмен.

Г о м ә р. Тәүбә, тәүбә, Тәнзилә.

Т ә н з и л ә. Әйдә. Анда синең гитараң кирәк.

Г о м ә р. Булмый.

Т ә н з и л ә. Нигә?

Г о м ә р *(чатырга күрсәтеп)*. Аларны ташлап китә алмыйм. Программалары белән килешмәсәм дә, мин алар компаниясендә. Алар барса барам, бармаса — юк.

Т ә н з и л ә. Юкка сезгә иярдем, ахрысы. Күңелсез сезнең белән. *(Чыгып китә.)*

Г о м ә р. Күрдегезме, әфәнделәр, кадеремне белегез, мин дә сезнең белән калдым. Йоклагыз, матурларым. Хәзер мин сезгә бишек җыры җырлыйм.

Әлли-бәлли итәрләр болар,
Черем итеп китәрләр болар,
Ниләр эшләп бетәрләр болар,
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.
Тавыклар да йокламый әле,
Балыклар да йокламый әле,
Халыклар да йокламый әле,
Сез тынычлап йоклагыз, яме.
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.

Гитара аскан А л и н ә керә, Гомәрнең бишек җырын тыңлап тора.

А л и н ә. Абыйга ялкынлы сәлам!

Г о м ә р *(куанып, Алинә каршына килә)*. А-а-а, Алинә! Сәлам, Алинә!

А л и н ә. Абыемның тавышы әйбәт булмаса да, ярыйсы икән. Нишләп әле су буена бармыйсыз? Әйдәгез!

Г о м ә р *(чатырга күрсәтеп)*. Менә саклыйм.

А л и н ә. Нәрсә соң анда?

Г о м ә р. Минем егетләр. Алар кич җиткәч беркая да чыкмаска, кызлар күзенә күренмәскә ант иттеләр.

А л и н ә. Оялчаннармыни?

Г о м ә р. Түгел дә... Авыл кызларының берәрсе гашыйк итеп куймагае дип куркалар.

А л и н ә. Хәзердән үк йокларга яткан егетләр кемгә кирәк?!

Г о м ә р. Кирәкми дә бит... Ә мин ант итмәдем, Алинә, аны-моны уйлый күрмәгез. Әгәр дә сез тагын бер тапкыр «әйдә су буена» дип әйтәсез икән, мин барам.

А л и н ә. Рәхмәт инде. Саклагыз — урламасыннар. *(Китә башлый.)*

Г о м ә р. Алинә, ташлап китмәгез. Әйдә дип әйтмәсәгез дә барам. Сезнең белән җир читенә чаклы барырга риза.

А л и н ә. Минем беләнме?

Г о м ә р. Сезнең белән.

А л и н ә. Безнең беләнме, минем беләнме?

Г о м ә р. Синең белән, Алинә.

А л и н ә. Нигә?

Г о м ә р. Ахмак җавап ишетергә теләмәсәгез, андый сорау бирмәгез.

А л и н ә. Нигә минем белән?

Г о м ә р. Әйттерәсез ич инде, Алинә! «Гашыйк булдым» дип әйттерәсез.

А л и н ә. Миңамы?

Г о м ә р. Сезгә.

А л и н ә. Безгәме, миңамы?

Г о м ә р. Сиңа, Алинә!

А л и н ә. Ни өчен?

Г о м ә р. Уф!.. Бая да аптырашта калдырдыгыз, бу юлы да.

А л и н ә. Ни өчен миңа гашыйк булдыгыз?

Г о м ә р. Чөнки, чөнки... Сез, беренчедән... беренчедән, чибәр.

А л и н ә. Минме?

«Чибәр» сүзен ишеткәч, Н и з а м чатыр ишегеннән башын суза.

Г о м ә р. Сез!

А л и н ә. Безме, минме?

Г о м ә р. Син, Алинә!

А л и н ә. Әйдәгез, абыем, су буена, миннән дә чибәррәкләр белән таныштырам.

Алинәне күзәтеп торган Н и з а м чатыр ишегеннән чыга, киерелә-сузыла, күзләрен уган була, янәсе, яңа гына йокыдан уянган.

А л и н ә. Әнә егетләрегез уяна башлады.

Н и з а м. Гафу итегез, кызлар бар икән. Гомәр, сәгать ничә?

Г о м ә р. Сиңа сәгать нәрсәгә? Кер дә ят, үзем уятырмын.

Н и з а м. Тартырга биреп тор әле, Гомәр?

Г о м ә р. Тартмаганымны беләсең.

Н и з а м. Шулаймыни? Ташладыңмыни? *(Якынрак килеп, сиздермәскә тырышып, Алинәгә карый.)* Әйдә, син дә йокла, Гомәр, кызлар бетмәс монда. Хатыныңа ишетелсә, әйбәт түгел. Ни карадың, дип, мине дә ачуланыр.

А л и н ә. Без өйләнгән егетләрдән дә курыкмыйбыз. Институтта укып, исәнләшә дә белмисез икән.

Н и з а м. Гафу итегез, исәнмесез! *(Чатырга кереп китә.)*

А л и н ә. Бигрәк мут күзле егет. Миңа карап сине күрә торган.

Г о м ә р. Алинә, сез аның сүзенә ышандыгызмы? Юри ул.

А л и н ә. Ышансам да курыкмыйм, Гомәр абый бәгырем! Мин сезгә үлеп гашыйк булдым. Әйдәгез, парлап уйныйк, егетләр-кызлар биесен-җырласын.

Г о м ә р. Баш өсте, Алинә, әйтегез генә.

Икәүләп гитара чиртә-чиртә чыгып китәләр. Чатыр ишегендә — Н и з а м башы. Ул чатыр эченә карап сөйли.

Н и з а м. Менә шул егет белән юньле эш майтарып кара син. *(Чатырдан ук чыгып.)* Китте. Иярде дә китте.

З а һ и р *(чатырдан чыгып)*. Ул китсә китәр, син нәрсә һаман йокламыйсың? Йокыга гына китеп барганда уяттың.

Р и з в а н. Алдашма, ичмасам. Сезнең белән берләшүемә үкенә башладым. Җитди егетләр түгел сез.

З а һ и р. Нигә алай дисең инде, Ризван, сүзебездә торабыз ич.

Р и з в а н. Торырга азапланасыз. Үзегезне үзегез мәҗбүр итәсез. Ә күңелегез... Алай ярамый, иптәшләр. Боздан — салкын, корычтан нык булырга кирәк. Миннән үрнәк алыгыз.

З а һ и р. Синең характерың нык шул, Ризван.

Р и з в а н. Син дә үзеңне шулай тәрбиялә.

Гармун, гитара уйнаган, җырлаган тавышлар ишетелә.

Н и з а м. Әллә ни чибәр дә түгел үзе.
Р и з в а н. Кем?
Н и з а м. Гомәр танышкан кыз.
Р и з в а н. Гомәргә тагын чибәрләр!
Н и з а м. Ә үзе сөйкемле. Әллә соң антыбызны иртәгәдән башлыйбызмы, егетләр?
З а һ и р. Чыннан да... Ә, Ризван?
Р и з в а н *(ачуланып)*. Барыгыз! Теләсәгез нишләгез. Сез мине белмисез, мин — сезне. Эх сез! Җебегәннәр, штрейкбрехерлар! Бер төнгә түзмәделәр. Ант итәләр, имеш. Менә ышан сезгә. Барыгыз!
З а һ и р. Ачуланма инде, болай гына әйттек.
Н и з а м. Сине сынар өчен генә, Ризван.
Р и з в а н. Мин сыналган. Үзегезне сынагыз. *(Чатырга керә башлый.)*
Н и з а м. Тукта инде, Ризван. Бүгеннән үк үпкәләшкәч ни була? Әйдәле, алай эшләмик әле. Без без булып калыйк әле. Йокы алдыннан гимныбызны кабатлыйк та дуслар булып йокыга китик әле. Яле... Бер! Ике! Өч!
Н и з а м *(җыр башлый, аңа Ризван белән Заһир кушыла.)*

Эш кенә тормышның тоткасы,
Эш кенә дөньяның ноктасы,
Куертмыйк мәхәббәт боткасын,
Йөрәкләр ял итсен, йокласын.
Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

П ә р д ә.

## Икенче күренеш

Вакыт кич. Р и з в а н белән З а һ и р эштән кайтып керәләр. Арыганнар. Ял итеп алырга җиргә утыралар.

З а һ и р. Куллар эштән бизгән булган, һаман өйрәнеп җитә алмый.
Р и з в а н. Әйе.

З а һ и р. Әле дә ярый йокыбыз туйганчы йоклап барабыз эшкә. Әйеме, Ризван?

Р и з в а н. Әйе.

З а һ и р. Эшләр болай барса, күп эш эшләячәкбез. Культура йортының нигезе әзер. Нигез булса, калганы эшләнә. Нигезе нык булсын. Биесеннәр бездән соң килгән буыннар без салган нигездә. Тыпыр-тыпыр биергә бетон нигезләр кирәк, бетон нигезләр өстендә...

Р и з в а н. Сөйләнми генә утыр әле.

З а һ и р. Нигә?

Р и з в а н. Күрмисеңмени? Арыдым. Юкка алындык. Каникул ял итәр өчен. Бай малайлары диңгез ярында ята, без ишәк кебек...

З а һ и р. Син чынлапмы, Ризван?

Р и з в а н. Мин уйнап сөйләшә белмим.

З а һ и р. Үзең эшләп тапкан кадерлерәк була, ди минем әби. Өстәвенә чыныгабыз. Менә кара минем кулларга...

Р и з в а н. Ярый, әйдә коенырга киттек.

З а һ и р. Дөрес! Арыганга гына шулай сөйләшәсең. Су кергәч җиңеләеп китәрсең.

Бауда эленеп торган сөлгеләрне, киемнәрне алып, китәргә җыеналар. Ризван кемнедер күреп туктап кала.

Р и з в а н. Нишли ул Низам? Кем алдында шулай бөтерелә?

З а һ и р. Алинә ул. Авыл кызы.

Р и з в а н *(кычкырып)*. Низам!.. Әйтеп тормасаң, хәзер читкә тайпылырга торасыз. Ә син ул кызның исемен каян беләсең?

З а һ и р. Ничек инде белмәскә, үзе әйтте ич. Кызлар исемен белергә дә ярамыймыни?

Р и з в а н. Ярамый. Бары тик эш турында гына.

З а һ и р. Тәнзилә белән ярыймы, Ризван?

Р и з в а н. Исемен белергә ярый. Тик янына йөрергә ярамый.

Н и з а м керә.

Ни сөйләштегез? Ни йомышың калган ул кызда.

Н и з а м. Ике атна түздек бит инде, Ризван.

Р и з в а н. Без монда ике атнага килмәдек. Антны да ике атнага бирмәдек. Ике ай. Онытма, ике ай!

Н и з а м. Үзе бит, бәйләнә!

Р и з в а н. Кемнең бәйләнгәнен күреп тордык без. Ал сөлгеңне, киттек.

Китәргә кузгалалар. Г о м ә р кайта.

Г о м ә р *(көйләп)*. Ашыкмагыз, сабыр итегез, бераз гына мине көтегез.

Р и з в а н. Көтмәскә! Аның үз юлы, безнең үз юлыбыз.

Н и з а м. Безнең үз юлыбыз. Киттек.

Г о м ә р. Ашыкмагыз! Яңа хәбәр! Бүген бәйрәм. Ризван әфәнденең тууына егерме бер яшь тулу хөрмәтенә кичке ашка Тәнзиләнең хәҗәйкәсе бәлеш пешерә.

Н и з а м. Бә-ә-леш! Ризван, туган көнең икәнне нигә әйтмәдең?

Г о м ә р. Өч ел бергә укып беркемгә әйтмәгән. Тәнзилә сизеп алган.

Р и з в а н. Без монда бәйрәм итәргә килмәдек.

З а һ и р. Бәйрәм итмәсәк тә, котлар идек.

Р и з в а н. Кирәкми.

Н и з а м. Кирәкмәгәч кирәкми, кызлар. Ризван өчен мине котлагыз. Ризван — тыйнак кеше. *(Гомәргә күз кысып.)* Котла, Гомәр! Мин — Ризван.

Низам Ризван позасын алып баса. Гомәр тирәккә эленеп торган сумкасыннан бер бит кәгазь алып, укыган булып сөйли.

Г о м ә р. Хөрмәтле вә гыйззәтле Ризван иптәш Низамов, моннан егерме бер ел элек дөньяга килеп, сез дөньяны һәм безне бәхетле иттегез. Сез әле бәләкәй чакта ук, тәпи-тәпи атлап киткәнче үк, дүрт аяклап мүкәләп йөреп, дөньяны, тормышны өйрәндегез.

Н и з а м. Сабыр ит, Гомәр. *(Тиз генә чатырга кереп китә дә аннан бер бит кәгазь алып чыга. Шул кәгазьгә карап.)* Рәхмәт, иптәшләр! Дәвам итегез.

Г о м ә р. Сез мәктәпкә укырга кергәндә үк тыйнак идегез. Үзегезнең шәхесегезне укытучының борынына төртмәдегез. Киресенчә, укытучының борын астына — беренче партага утырдыгыз.

Н и з а м *(кәгазьгә карап)*. Рәхмәт, иптәшләр!

Г о м ә р. Шулай тыйнак булып белем тавына күтәрелдегез. Төзелеш академиясенә кердегез, һәм менә сезнең тыйнаклыгыгыз сезне безнең белән бергә шабашниклык

итәргә алып килде. Сез, Ризван иптәш, эштә дә тыйнаклык күрсәтәсез.

Низам. Рәхмәт, иптәшләр!

Ризван *(Гомәр каршысына килеп)*. Шуның белән ни әйтергә телисең?

Гомәр *(Ризваннан читкәрәк тайпылып)*. Сез пунктуаль һәм принципиаль кеше буларак...

Ризван *(Низам каршысына килеп)*. Шуңа кушылып, шуның җырын җырларга тотындыңмы?

Низам. Рәхмәт, иптәшләр!

Ризван *(җирдә тәгәрәп көлгән Заһир янына килеп)*. Син нигә көләсең, кемнән көләсең?

Заһир. Дөрес! Билләһи, дөрес, Ризван. Син бит бөтен сүзеңне кәгазьгә карап сөйлисең.

Ризван. Эх сез! *(Тиз генә чыгып китә.)*

Заһир. Юкка үпкәләттек.

Гомәр. Бар, йөгер тизрәк, күз яшьләрен сөрт.

Заһир. Нигә алай дисең инде, Гомәр?

Гомәр. Аның каршында биеп торасың бит. Шагыйрь чыкмаячак синнән.

Низам. Умыртка сөягең йомшак.

Тәнзилә керә.

Заһир. Исәнме, Тәнзилә!..

Тәнзилә. Сез әле һаман юынмадыгызмыни?

Гомәр. Юынмадык шул әле, мадемуазель.

Тәнзилә. Бәлешләр өлгерә, сез һаман юк. Әйдә, тиз генә җырны кабатлап алыйк.

Гомәр. Юынмаган килешме?

Тәнзилә. Өлгерерсең.

Гомәр. Бар, алайса, Заһир, төшә тор. Бар инде, нәрсә дөньяңны оныттың. *(Заһир киткәч.)* Син, Тәнзилә, нигә Заһирның сәламен алмадың? Тәнзилә, Заһир белән сезнең мөнәсәбәтләр ничек?

Тәнзилә. Нинди мөнәсәбәт?.. Җырны кабатлыйбыз.

Гомәр. Аралар ничек, дим? Яратасыңмы син аны?

Тәнзилә. Башка әйтер сүзең юкмы?

Гомәр. Ярата ул сине.

Тәнзилә. Информацияң өчен рәхмәт. Әйдә, ал гитараңны.

Гомәр. Син миңа җыр яздырып интектерәсең, ә Ризванның исендә дә юк. Бернинди туган көн юк, ди.

Т ә н з и л ә. Аның ничек әйтүендә эшебез юк, коллектив аны котларга тиеш. Традиция. Димәк, болай: беренче булып сүзне мин алам. Барыбыз исеменнән дә сүз белән котлыйм. Аннан — җыр, без икәү. Башла.

Гомәр гитарасын алып уйный.

*(Җырлый.)*

Ризванның туган көнендә
Көлеп чыкты кояш та,
Ризванның туган көнендә
Матур сайрады кош та.
Ризванга бүген егерме бер —
Йөзгә чаклы яшәсен!
Ризванга шуны телибез —
Яшен булып яшьнәсен!

Сүзләре бигрәк мәгънәсез инде.

Г о м ә р. Мин бит шагыйрь түгел, Заһирга кушарга иде.

Т ә н з и л ә. Син юри шулай язгансың. Яратмыйсың син Ризванны.

Г о м ә р. Ә син яратасыңмы?

Т ә н з и л ә. Бик яратам. Бар, йөгер.

Г о м ә р. Кара аны, Тәнзилә, әгәр дә Заһирны бүтәнгә алыштырсаң...

Т ә н з и л ә. Нишләтерсең?

Г о м ә р. Үземнеке итәрмен.

Т ә н з и л ә *(ачуланып)*. Беләсеңме нәрсә, дустым...

Г о м ә р. Бетте, бетте, шаярдым.

Т ә н з и л ә. Шаяруның да мәгънәсе була. Шаярырга остарып киттегез әле.

Г о м ә р. Заһир шаярмый.

Т ә н з и л ә. Шаярмаганын үз теле белән үзе әйтсен. *(Чыгып китә.)*

Г о м ә р. Әйтер, Алла боерса.

Ризванның туган көнендә
Көлеп чыкты кояш та,
Ризванның туган көнендә
Матур сайрады кош та...

Г о м ә р җырлап чыгып китә. З а һ и р керә.

З а һ и р. Тәнзилә!..

Т ә н з и л ә. Әйе...

З а һ и р. Тәнзилә!..

Т ә н з и л ә. Әйе...

З а һ и р. Тәнзилә, әгәр дә минем туган көнем булса, син бәлеш пешерер идеңме?

Т ә н з и л ә. Ризванга бәлешне мин пешермәдем. Мин яшәгән фатирның хуҗабикәсе Галия апа пешерде.

З а һ и р. Ә син бәлеш пешерә беләсеңме?

Т ә н з и л ә. Миңа әйтерлек бүтән сүзең юк мәллә?

З а һ и р. Бар да бит.

Т ә н з и л ә. Булса – әйт!

З а һ и р. Күптәннән әйтәсем килеп йөрим.

Т ә н з и л ә. Бүген әйт.

З а һ и р *(як-ягына каранып)*. Мин әйтсәм, син мин әйткәнне Ризванга әйтмәссеңме? Без бит ант иттек.

Т ә н з и л ә. Алайса, антыңны бозма инде.

З а һ и р. Бозмыйча да ярамый. Синең үзеңне генә кайчан күрәм әле. Әйтеп каласым килә. Мин сине яратам бит, Тәнзилә!

Т ә н з и л ә. Мин куркакларны яратмыйм шул, Заһир!

З а һ и р. Юк, мин куркак түгел, Тәнзилә, оялчан гына.

Т ә н з и л ә. Мин оялчан түгел. Күрсәт миңа палаткагызның эчен. *(Бауны атлап, палаткага таба китә.)*

З а һ и р. Тәнзилә... Тәнзилә, зинһар өчен, чык аннан!

Т ә н з и л ә. Курыктыңмыни?

З а һ и р. Курыкмадым. Ләкин ант иттем бит.

Т ә н з и л ә. «Яратам» дип әйтеп антыңны боздың.

З а һ и р. Әйе, боздым, анысын әйтми түзалмадым. Бусы бит... Зинһар өчен, чык инде аннан. Егетләрдән яхшы түгел. Ризван бит безнең әллә нинди.

Т ә н з и л ә. Алайса, Ризванга аңлат мәхәббәтеңне. Киттем, бәлеш ашарга килегез. *(Китә башлый.)*

З а һ и р. Тәнзилә!..

Т ә н з и л ә. Иярмә. Мин ияреп йөрүчеләрне яратмыйм. Үземнең ияреп йөрисе килә.

З а һ и р. Сиңа ияреп йөрү рәхәт миңа.

Т ә н з и л ә. Үзеңне бозау дип хис итәсеңме? *(Чыгып китә.)*

З а һ и р. Тәнзилә!.. *(Тәнзиләгә ияреп чыгып китә.)*

А л и н ә керә. Гомәрнең гитарасын алып чирткәли.
Р и з в а н керә.

Алинә. Исәнмесез! Хәерле кич!

Ризван. Нигә кешенең гитарасын рөхсәтсез алдыгыз? Куегыз урынына. Һәм, гомумән...

Алинә. Гомумән, сез сәламгә каршы сәлам бирмәдегез.

Ризван. Исәнмесез! Сез үзегезне ямьсез тотасыз.

Алинә *(чиртүдән туктап)*. Гафу итегез, ничек ул «ямьсез»?

Ризван. Мин әйттем, калганын үзегез аңлагыз.

Алинә. Гафу итегез, аңлый алмыйм. Сез ямьсез сүз әйттегез, анысын аңладым, ни өчен әйттегез – аңламадым.

Ризван. Сез нишләп әле бу тирәдә чуаласыз? Монда килеп йөрергә миннән сезгә рөхсәт юк!

Алинә. Гафу итегез, мин бу авылда эшлим, әнә шул өйдә фатирда торам, чишмәгә – суга, елгага су керергә төшәм, сукмак сезнең палатка яныннан үтә.

Ризван. Беләм. Сез клуб мөдире булып эшлисез, клубта утырыгыз. Сукмактан үткәндә туктап тормагыз.

Алинә. Шулай укмыни? *(Бауны атлап керә.)*

Ризван. Бауның теге ягына чыгуыгызны үтенәм.

Алинә. Әгәр чыкмасам?..

Ризван. Кабатлап әйтәм, үзегезне ямьсез тотасыз. *(Чатыр эченә кереп китә.)*

Алинә. Гафу итегез! *(Гитараны чиртеп, җырлап җибәрә.)*

Үзегез дә белми, сизми генә
Күңел кылларыма чирттегез:
Күңелемдә яңа бер көй туды –
Гафу итегез!
Чәнечкеле сүзләрегез белән
Йөрәгемә чәнчеп үттегез;
Яраланган йөрәк дәва көтә –
Гафу итегез!

Ризван *(чатырдан чыгып)*. Тагын бер кат әйтәм, сез үзегезне ямьсез тотасыз. Әгәр дә шаярырга телисез икән, бауның теге ягына чыгыгыз да Гомәр кайтканын көтегез. Шаярырга ул ярата.

Алинә. Ә миңа Гомәр белән шаяруы күңелсез.

Ризван. Һәм, гомумән, безнең Низамны тынычлыкта калдырыгыз.

Алинә. Низамның ни катнашы бар?

Ризван. Мин беләм, мин күрдем. Сезне күргәч,

Низам үзгәрде, һәм сез, шуңардан файдаланып, Низам белән берничә тапкыр сөйләштегез, елгада бергә йөздегез.

Алинә. Ә сез?

Ризван. Нәрсә мин?

Алинә. Сез мине күргәч үзгәрмәдегезме?

Ризван. Юк.

Алинә. Кызганыч.

Ризван. Кызганыч, ләкин факт.

Алинә. Сез шулай ук таш йөрәклемени?

Ризван. Бу очракта, әйе.

Алинә. Кайсы очракта?

Ризван. Сезнең белән очрашкан чакта.

Алинә. Мин сезгә аз гына да ошамыйммыни?

Ризван. Бу очракта — юк.

Алинә. Хәерле булсын. Бәлки, чыннан да, мин үземне ямьсез тотканмын. Сезнең янга ялынып килгән кебек килеп чыккандыр. Әйе, әйе, мин, ниһаять, аңладым, болай ярамый икән, килешми икән. Ләкин минем бүтән чарам юк. Чөнки мин сезне уйлап төн йокыларымны йоклый алмый башладым, ә сез мине күрмисез дә. Гафу итегез, бүтән мин сезне борчымам, янармын, көярмен — сиздермәм. Әмма сез дә, тупас сүзләр әйтеп, мине мыскыл иттегез.

Ризван. Мин мыскыл итәргә теләмәдем.

Алинә. Мин дә үземне ямьсез тотарга теләмәгән идем.

Ризван. Ярый, алайса, тупас сүзләрем өчен гафу итегез.

Алинә. Юк, сез гафу итегез. Ә сез кая барырга болай киендегез?

Ризван. Бүген минем туган көнем.

Алинә. Котлыйм, бәхетле булыгыз!

Ризван. Рәхмәт!

Алинә. Сез нигә миңа шулай текәлеп карыйсыз?

Ризван *(як-ягына каранып ала)*. Чөнки сез чибәр.

Алинә. Шуннан ни мәгънә? Сезнең өчен барыбер бит.

Ризван. Сез — кызыклы, сез — серле.

Алинә. Рәхмәт! Сез шулай кичләрен беркая да бармый палаткагызда йоклап ятасызмы?

Ризван. Ант иттек.

Алинә. Ә төннәрен су буенда шундый рәхәт. Әнә

елганың теге борылышында минем яраткан басмам бар. Кайвакыт шунда төшәм дә бер ялгызым уйланып утырам. Бер ялгызым. Гомәр, Низам кебекләрне яратмыйм мин, алар җилбәзәкләр. Төпле, акыллы кешеләр белән сөйләшеп утырасым килә. Җилбәзәклек минем үземдә дә җитәрлек.

Ризван. Әйе, җилбәзәклек кызларга килешсә дә, егетләргә килешми.

Алинә. Димәк, сез миңа ачуланмыйсыз?!

Ризван *(елгага карап)*. Ә елганың ул борылышы чыннан да матур.

Алинә. Төнлә күрсәгез иде сез аны!

Ризван. Искиткеч матур урын. *(Низам килгәнне күреп.)* Гафу итегез, зинһар, бауның теге ягына чыгыгыз, Низам кайтып килә.

Алинә *(бауны атлап чыгып)*. Мин бүген дә яраткан басмама төшеп утырам.

Ризван. Мине бүген котларга тиешләр.

Алинә. Озак буласызмы анда?

Ризван. Озак түгел. Сау булып торыгыз. *(Китә башлый.)*

Алинә. Елганың теге борылышында...

Ризван чыгып китә. Низам керә.

Низам. А-а, Алинә! Малинә!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Алинә;
Күзләре — кара карлыган,
Иреннәре — малинә.

Кемне көтәсез?

Алинә. Ни өчен әле мин егетләр көтеп утырырга тиеш? Үтеп барышлый гитараны күрдем дә туктадым. Гитара күрсәм, тыныч кына узып китә алмыйм.

Низам. Ә мин сезне күрсәм, тыныч кына үтеп китә алмыйм.

Алинә. Сөйләгән буласыз инде, ышана дип уйлыйсыздыр.

Низам. Менә монысы дөрес. Ышанмагыз сез миңа. Ышаныгыз дип әйткәнем дә юк. Ышанычлы түгел мин. Ләкин мин сезгә ышанам. Ышанам, нишләтим? Азмыдыр, күпмедер вакыт үтәр, һәм сез миңа ышанырсыз дип ышанам.

А л и н ә. Ышанмаучыларыгыз миннән башка да бардыр әле.

Н и з а м. Бардыр, әлбәттә. Нигә алдашыйм. Ләкин кирәгеннән артык ышансалар да әйбәт түгел, күңелсез. Кызлар — егетләргә, хатыннар — ирләренә, карчыклар картларына аз гына шикләнеп карарга тиешләр. Чөнки алай-болай булса, көтелмәгән булмасын.

А л и н ә. Ә егетләр — кызларга?..

Н и з а м. Монда инде икенче мәсьәлә. Кызлар, хатыннар, карчыклар ышанычлы булырга тиеш. Менә мин шундыйны эзлим.

А л и н ә. Таба алганыгыз юкмы?

Н и з а м. Әлегә юк дисәм, ни диярсез?

А л и н ә. Алай икән, диярмен.

Н и з а м. Шуннан?

А л и н ә. Эзләвегезне дәвам итегез.

Н и з а м. Дәвам итәм һәм сезгә ышанам.

А л и н ә. Димәк, без табышканбыз. Мин сезгә ышанмыйм, сез миңа ышанасыз. Инде нишләргә?

Н и з а м. Кичләрен очрашырга.

А л и н ә. Сез бит кызлар белән сөйләшмәскә ант иткәнсез. Ант белән шаярмыйлар.

Н и з а м. Мәхәббәт мәсьәләсендә бер адәм заты да антында тормаган, нигә мин генә тормыш законын бозарга тиеш әле?

А л и н ә. Димәк, ант мәсьәләсендә дә ышанычсыз.

Н и з а м. Ант белән антның аермасы бар.

А л и н ә. Минемчә, юк.

Н и з а м. Бәхәсләшмик, Алинә, юк өчен. Конкрет сөйләшик: сез минем белән очрашырга ризамы? Калганы минем эш.

А л и н ә. Болай да очрашып торабыз ич.

Н и з а м. Мондый очрашу нәрсә ул! Көпә-көндез — унлаган күз карап торганда. Икәү генә калып сөйләшәсе килә.

А л и н ә. Мин риза.

Н и з а м. Әллә?

А л и н ә. Мәллә.

Шулвакыт, «Низам!» дип кычкырып, Д а м и р ә керә. Керә дә Низамның кочагына ташлана.

Д а м и р ә. Сагындыңмы мине, Низамчик? Мин сине шундый сагындым. Машинам чокырга төшеп баткач, җәяү йөгердем.

Н и з а м. Дамирә... Син ни әле... Тукта әле...

Д а м и р ә *(Алинәне күреп)*. Ә бу кем?

Н и з а м. Ул ни... Алинә...

Д а м и р ә. Нишләп йөри ул монда?

А л и н ә. Мин Низамның миңа мәхәббәт аңлатканын тыңлап торам.

Д а м и р ә. Нәрсә-ә-ә? Низам, ни сөйли ул?

Н и з а м. Ни... Тукта әле син, Дамирә... Ни бит... Болай ул...

Ут сүнә.

### Өченче күренеш

Шул ук урын. Вакыт төн. Ризванның туган көненнән таралганнар. Өч егет үз территорияләрендә утыра. Г о м ә р гамак өстендә гитара чиртә.

Р и з в а н. Йокларга!

З а һ и р. Утырыйк әле бераз, төне матур.

Р и з в а н. Иртәгә эшкә.

З а һ и р. Туктале, Ризван!

Р и з в а н. Йокларга!

Н и з а м. Дөрес. Әйдәгез. Антны бозарга ярамый.

Беренче башлап чатыр эченә Н и з а м кереп китә. Аңа Р и з в а н белән З а һ и р иярә. Гомәр әкрен генә гитара чиртүен дәвам итә. Кинәт гармун тавышы ишетелә. Гармунын тартып уйнап, Н ә җ и п килеп керә.

Н ә җ и п *(җырлый)*.

Аклы күлмәк кияр идем,
Акка кара төшмәсә.
Гомерлеккә сөяр идем,
Күзең ятка төшмәсә.
Көмеш саплы алтын пәке
Сынды гөлләр кисәндә;
Өзелә лә үзәкләрем,
Таң җилләре искәндә.

*(Уйнавыннан, җырлавыннан кинәт туктап, Гомәргә карап тора.)*

Г о м ә р. Егетләр йоклый, Нәҗип абый!

Нәҗип. Бу чактан йоклыйлармы? Менә мин бөтенләйгә йокламаем. Шушыннан туп-туры көтүгә. Нигә син уйнамыйсың?

Гомәр. Каз муенына кая инде тальян белән ярышырга.

Нәҗип. Һе, белдеңме инде?

Гомәр. Белдем. Әкренрәк сөйләш, Нәҗип абый.

Нәҗип. Син минем янга төшеп утыр.

Гомәр гамактан төшә.

Ә син нигә йокламыйсың?

Гомәр. Үзең әйтмешли, сәгать унда кем йокларга ята?

Нәҗип. Бер кызны көтәсеңме?

Гомәр. Кайсы кызны?

Нәҗип. Бер кыз сезнең янга килеп йөри.

Гомәр. Алинәме?

Нәҗип. Исемен әйтмәем. *(Җиңен сызганып.)* Менә бу беләкне күрәсеңме?

Гомәр. Күрәм, Нәҗип абый.

Нәҗип. Әгәр дә ул кызның башын әйләндерсәгез, муеныгызны сугып сындырырмын.

Гомәр. Алай ук димәгез инде.

Нәҗип. Сындырам. Алты ел күзем төшеп йөргән кызны алып киттегез.

Гомәр. Без түгел бит.

Нәҗип. Барыбер. Сезнең иш.

Гомәр. Алты ел күзегез төшеп йөргән, шул хакта үзенә әйткән идегезме соң?

Нәҗип. Кемгә?

Гомәр. Кызга.

Нәҗип. Әйтмәдем. Нигә әйтәем, тәмен югалтып...

Гомәр. Монысына да әйткәнегез юкмы?

Нәҗип. Әйтмәем. Үзе белсә белсен, әйтмәем.

Гомәр. Үзләре белмиләр шул алар, Нәҗип абый. Ничә яшь соң сезгә?

Нәҗип. Утыз.

Гомәр. Картаеп барасыз икән шул...

Нәҗип. Утыз яшь — егетнең өлгергән чагы, күмере төшкән чагы.

Гомәр. Алай булгач, күзегез төшкән кызга әйтегез дә өйләнегез. Юкса, чыннан да, алып китүләре ихтимал.

Н ә җ и п. Яратканымны үзе сизсә өйләнәем.

Г о м ә р. Тагын утыз ел егет булып йөриячәксез.

Н ә җ и п. Йөресен. Каз муенын уйнап караеммы?

Г о м ә р. Рәхим итегез! *(Гитараны Нәҗипкә бирә.)*

Н ә җ и п. Син Алинә кебек «рәхим итегез» дип сөйләшәсең икән. *(Гитара кылларын чиртә, ләкин көй чыгара алмый.)* Булмай. Өйрәт мине уйнарга.

Г о м ә р. Сез яратмыйсыз ич гитараны.

Н ә җ и п. Ә мин өйрәнәем дә ташлаем.

Г о м ә р. Бүген соң, иртәгә иртәрәк килерсез.

Н ә җ и п. Әйдә минем белән су буена.

Г о м ә р. Анда ни бар?

Н ә җ и п. Гармун уйнап, җырлап йөрибез.

Г о м ә р. Бүген булмый.

Н ә җ и п. Сау бул! *(Гармунын уйнап чыгып китә.)*

Гомәр гамакка менеп ята. Чатыр ишегендә Н и з а м күренә, йомшак кына басып бау янына килә, атлап чыга.

Г о м ә р. Низаметдин, кая юл тоттың?

Н и з а м. Тс-с! *(Гомәр янына килә.)* Май кап!

Г о м ә р. Каптым. Кая барасың?

Н и з а м. Эшләр кәкәйләнде бит әле. Дамирә килеп төште. Адресны да бирмәгән идем. Эзләп тапкан.

Г о м ә р. Хәзер нишләргә җыенасың?

Н и з а м. «Нишләргә, нишләргә...» Ул Алинәләрдә, аңлашырга кирәк ич.

Г о м ә р. Кызлар белән сөйләшмәскә дип биргән антың бар.

Н и з а м. Ризван булма әле син дә. Аның йокыга киткәнен көтеп тә ничаклы вакытым үтте.

Г о м ә р. Ләкин, Ризваннан ычкынсаң да, миннән ычкына алмассың.

Н и з а м. Чынмы?

Г о м ә р. Чын.

Н и з а м *(көлеп)*. Свинҗә син, Гомәр.

Г о м ә р. Антын бозган – хыянәтче.

Н и з а м. Зурга җибәрмә. Мин шаярдым гына ул чакта, беләсеңме, шаярдым. Бу җүләрләр нишләрләр икән дип шаярдым. Үзең дә күреп тордың, сөйләшкәндә дә, җырлаганда да сул күзем гел көлеп торды.

Г о м ә р. Барыбер җибәрмәячәкмен.

Н и з а м. Әй, аңа калса, бик исем китте. Нишләтә аласың?

Г о м ә р. Ризванны уятам.

Н и з а м. Димәк, сатасың? Бергә укып йөргән курсташыңны, дустыңны, аягын-кулын бәйләп, сөйгән кызыннан аерып алып, шул бюрократ Ризванга сатасың?

Г о м ә р. Анда Заһир да бар.

Н и з а м. Димәк, сине үлеп яраткан Низамны шагыйрь булырга хыялланып йөрүче мәҗнүнгә — Заһирга сатасың?

Г о м ә р. Көлдермә, Низам. Үтмәс товар сатып йөрергә әллә мин җүләрме.

Н и з а м. Ярый, уят. Уянып нишләтә алалар? Китәм дә барам.

Г о м ә р. Антын бозган кешегә җәзаны мин бирәчәкмен, Низам. Мин рәхимсез!

Н и з а м. Гомәр?! Алай димә инде, Гомәр. Егет бул инде, Гомәр. Ризванга исем дә китми, синнән куркам. Җибәр инде. Хәзер әйләнеп кайтам. Дамирәгә аңлатам да кайтам. Яратам мин аны, беләсеңме!.. Харап итмә мине. Үтермә мәхәббәтебезне, Гомәр, коткар.

Г о м ә р. Ярый, алайса, бер юлга...

Н и з а м. Рәхмәт, Гомәр. *(Китәргә җыена.)*

Г о м ә р. Тукта!

Н и з а м *(Гомәр янына юргалап килеп)*. Нәрсә, Гомәр?

Г о м ә р. Күрә торып антыңның бозылуын теләмим.

Н и з а м. Гомәр?..

Г о м ә р. Ашыкма. Бар, кереп ят, мин йоклагач китәрсең.

Н и з а м. Алай итмә инде, Гомәр. Телисеңме, мин сине тирбәтеп йоклатам. Ят, Гомәр, ят. *(Гомәрне гамагына яткыра.)* Йом күзеңне. Менә шулай. Әлли-бәлли ит. Тәмле-татлы төшләр күр. *(Гамакны тирбәтә.)*

Г о м ә р. Әкрен, егасың.

Н и з а м. Яп авызыңны, йом күзеңне. Әлли-бәлли. *(Көйләп.)*

Сарыклар да йоклады инде...

Г о м ә р. Бозма мин чыгарган җырны. Сарыклар түгел, тавыклар.

Н и з а м. Ярый, ярый, тавыклар.

Тавыклар да йоклады инде.

Г о м ә р. «Йоклады инде» түгел, «йокламый әле».

Н и з а м. Аңладым.

Тавыклар да йокламый әле,
Балыклар да йокламый әле,
Халыклар да йокламый әле,
Син тынычлап йокларсың, яме.
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.

Гомәр, булдымы?

Г о м ә р. Булды.

Н и з а м. Йокыга киттеңме?

Г о м ә р. Киттем.

Н и з а м. Мин дә киттем. *(Чыгып йөгерә.)*

Гомәр башын күтәреп, аның артыннан карап кала, чатыр ишегендә Ризванны күреп, гырлый башлый. Ризван, як-ягына карангалап, бау янына килә. Алинә күрсәткән елга борылышына карый. Бауны атлап чыга.

Г о м ә р *(башын күтәреп)*. Ризван, кая юл тоттың?

Р и з в а н *(каушабрак калган)*. Син нишләп йокламыйсың?

Г о м ә р. Йоклаган идем — уяттың.

Р и з в а н. Низам кайда?

Г о м ә р. Чатырга бергә кереп киттегез.

Р и з в а н. Ул юк.

Г о м ә р. Алайса, белмим.

Р и з в а н. Беләсең.

Г о м ә р. Белсәм беләмдер.

Р и з в а н. Кай якка китте?

Г о м ә р. Нигә миннән сорау аласың әле? Син кем дә мин кем.

Р и з в а н. Анысын киләчәк күрсәтер. *(Китәргә җыена.)*

Г о м ә р. Күрсәтүен күрсәтер, әмма син урыныңа кереп ят.

Р и з в а н. Нәрсә-ә?

Г о м ә р. Кереп ят, төнгә каршы чыгып китмә кызлар эзләп.

Р и з в а н *(югалып кала)*. Син мине кем дип беләсең?

Г о м ә р. Кемлегеңдә эшем юк, ант иткәнеңне күреп тордым.

Р и з в а н. Мин Низамны алып кайтам.

Г о м ә р. Сабый түгел, үзе дә кайтыр.

Ризван. Кайчан?

Гомәр. Бүген булмаса, иртәгә.

Ризван. Иртәгә соң була. Антын бозып өлгергәнче алып кайтырга кирәк.

Гомәр. Бәлки, ул кызлар янына китмәгәндер?

Ризван. Шигем бар.

Гомәр. Алайса, үзем алып кайтам.

Ризван. Юк, нишләп йөргәнен мин үзем күрергә тиеш. *(Горур гына атлап чыгып китә.)*

Гомәр, гамак өстенә басып, аның кай якка киткәнен карап кала. Тәнзилә үтеп бара.

Гомәр. Тәнзилә! *(Тәнзилә эндәшмәгәч, гамактан төшеп, Тәнзилә артыннан китә. Бераздан кире йөгереп кереп, чатыр янына килеп кычкыра.)* Заһир, чык әле!

Заһир *(чатырдан чыгып)*. Нигә?

Гомәр. «Нигә, нигә...» Тәнзилә су буена төшеп китте, берүзе.

Заһир. Ярамый.

Гомәр. Колак кагасың Тәнзиләдән. Әнә хәзер үк... Монда туктап та тормады, сөйләшмәде дә... Ни өчен дисеңме? Синең аркада. Бәлешне ашап бетерүгә, йокларга вакыт, дип, кайтып киттегез.

Заһир. Ризван бит.

Гомәр. Ризван... Ул үзе юк, син чатырда.

Заһир. Ул Низамны алып кайта.

Гомәр. Ул Низамны тапканчы, син Тәнзилә белән сөйләшеп өлгерәсең.

Заһир. Нәрсә сөйләшим?

Гомәр. И-и Алла! Яратам мин сине, Тәнзилә, диген.

Заһир. Әйттем инде.

Гомәр. Кайчан?

Заһир. Бүген.

Гомәр. Нәрсә ди?

Заһир. Ияреп йөрмә, ди.

Гомәр. Бозау син.

Заһир. Тәнзилә дә шулай ди.

Гомәр. Бар. Куып тот та әйт, «мин бозау түгел, үгез» диген.

Заһир. Кызларга «мин үгез» дип әйтеп булмый инде.

Гомәр. Ярый, берничек тә әйтмә. Тик минем ачуымны чыгарып йоклап ятма.

З а һ и р. Йокламыйм мин.

Г о м ә р. Нишлисең соң?

З а һ и р. Уйланам. Тыңла әле, Гомәр, бер шигырь яздым, ничек?..

Г о м ә р. Тыңламыйм. Тәнзилә тыңласын...

З а һ и р. Әллә ниндиләр сез. *(Читкә китә.)*

Г о м ә р *(аның янына килеп)*. Йә-йә, үпкәләмә. Әйдә.

З а һ и р. Кая?

Г о м ә р. Баргач күрерсең. *(Заһирны кулыннан сөйрәп алып чыгып китә.)*

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Дүртенче күренеш

Су буе. Таллык. Басма. Д а м и р ә керә. Аңа Н и з а м ияргән.

Н и з а м. Дамирә, алай итмә инде. Ну бит инде. Алай ярамый бит инде. Йә инде, мәрхәмәтле бул инде. Яратмасаң да, кешене хөрмәт итәргә кирәк ич инде.

Д а м и р ә. Син әле кешемени?

Н и з а м. Белмим, Дамирә. Син кем дисәң, шул булам. Телисеңме, эт баласы булып артыңнан ияреп йөрим. Ышан, әйтмәдем мин Алинәгә яратам дип. Сынап кына карадым мин аны. Син беләсең бит инде.

Д а м и р ә. Беләм мин сине, бик яхшы беләм. Кызлар күрсәң, күзләрең акая.

Н и з а м. Чибәр кызлар күп булганга мин гаепле түгел бит инде, Дамирә. *(Җырга күчә.)*

Җемелдәп-җемелдәп яналар
Галәмдә хисапсыз йолдызлар;
Ни өчен йөрәгем бер генә,
Ни өчен күп икән бу кызлар?
Йолдызлар якында, еракта,
Арада иң якын йолдыз бар;
Якында, еракта кызлар күп,
Йөрәккә иң якын бер кыз бар.

Уйныйк әле, җырлыйк әле,
Көлик әле кыз чакта;
Килен булгач көлдермәсләр,
Утыртырлар почмакта, —

дип җырлаганнар әбиләребез дә. Ул син, Дамирә, син!

Дамирә. Ышанмыйм!.. Ышанмыйм мин сиңа.

Низам. Гаебем юк, Дамирә.

Дамирә. Ышанмыйм!..

Низам. Телисеңме, ант итәм?

Дамирә. Көнгә әллә ничә ант итәсең.

Низам. Сиңа биргән антым берәү генә. Телисеңме, каршыңа тезләнәм? Низамның адәм хурына калып, мескенләнеп тезләнеп торуын телисеңме? Тезләнәм.

Дамирә. Ышанмыйм.

Низам. Дамирә!.. Ышана идең бит миңа. Нишләдең син, нишләдең?! Кемнәр синең йөрәгеңдә шик уятты?!

Дамирә. Кызлар егетләргә ышанмаска тиеш, дип әйтә идең, дөрес икән.

Низам. Җүләр ни сөйләмәс. Җүләр бит мин, шыр тиле. Шул тилелегем аркасында Ризванга ияреп юри генә ант иттем. Ризванның ачуын чыгарыр өчен, аңардан көләр өчен, юри Алинә белән сөйләштем. Болай буласын белгән булсам... Икенче тапкыр... Ак тәүбә, кара тәүбә... *(Еламсыраган тавыш белән.)* Дамирә!..

Дамирә *(еларга җитешеп)*. Нәрсә, Низам?..

Низам. Дамирә!..

Дамирә. Низам!..

Низам. Дамирә!..

Дамирә. Низам!..

Низам. Гафу итәсеңме?

Дамирә. Белмим.

Низам. Бел инде, Дамирә.

Дамирә. Казанга кайткач сөйләшербез, Низам.

Низам. Ай-яй-яй-яй-яй!..

Дамирә. Озакмыни?

Низам. Бик озак, Дамирә. Аңарчы үләм мин.

Дамирә. Үлмисең, Низам... Син егетләргә биргән антыңда тор, Низам. Бер кыз белән дә сөйләшмә, бер кызга да карама. Кич җиткәч, палатка эченнән чыкма.

Низам. Көләсеңме?

Дамирә. Чынлап әйтәм.

Н и з а м. Әгәр чынлап әйтсәң, синеңчә эшләрмен, Дамирә. Чатыр эчендә гел сине генә уйлап ятармын. Әгәр дә син тагын килсәң нишләрмен?

Д а м и р ә. Бүтән килмәм.

Н и з а м. Үзем барырмынмы?

Д а м и р ә. Хатлар гына язарсың. Синең хатларыңны уку рәхәт булыр.

Н и з а м. Рәхмәт, Дамирә!

Р и з в а н керәп карап тора.

Үбәргә рөхсәт итмисең инде, әйеме, Дамирә?

Д а м и р ә. Әйе.

Н и з а м. Дөрес эшлисең, Дамирә. Синең урыныңда мин дә нәкъ менә синеңчә эшләр идем. Үбәргә дип үрелсәм, Казанга кайткач, дип әйтер идем. Казанга кайткач, әйеме, Дамирә? Күрешкәннең беренче көнендә үк.

Р и з в а н. Иптәш Рамазанов!..

Н и з а м. Ризван?.. Ә, Ризван... Хәерле кич, Ризван!

Р и з в а н. Хәерле төн!.. Эләктеңме?

Н и з а м. Эләктем, Ризван. Менә таныш бул – Дамирә. Ә бу – Ризван. Исәнләш, Дамирә, Ризван белән. Исәнмесез, Ризван, диген.

Д а м и р ә. Исәнмесез, Ризван!

Р и з в а н. Исәнмесез!.. Ала-ай...

Пауза. Өчесе дә бер-берсенә карашып торалар.

Н и з а м *(ниһаять, түзмичә кычкырып җибәрә)*. Әйтсәң әйт инде сүзеңне, Ризван.

Р и з в а н. Бер сүз дә әйтмим әлегә.

Н и з а м. Әйдә, алайса, Дамирә, тизрәк китик.

Р и з в а н. Кая?

Н и з а м. Кая дип... килгән бит... Ерак араларны якын итеп. Озатып куярга кирәк ич инде.

Р и з в а н. Шулаймыни?

Н и з а м. Шулай икәнен күреп торасың.

Р и з в а н. Яхшы. *(Дамирәгә.)* Сез чыгып торыгыз. Ә син, Низам, калып тор.

Н и з а м *(борылып керәп)*. Нәрсә инде тагын?!

Р и з в а н. Ашыкма.

Н и з а м. Китә бит. Әйт тизрәк сүзеңне.

Р и з в а н. Китсә, эзләп табарсың. Шулай диген, ә?

Н и з а м. Шулай инде, шулай. Шулай икәнен күреп торасың. Юкка утырдым синең арбаңа. Әгәр дә мәгәр икенче тапкыр... Ак тәүбә, кара тәүбә...

Р и з в а н. Ашыкма... Гафу итәм. Соңгы тапкыр.

Н и з а м. Соңгы тапкыр.

Р и з в а н. Заһир белмәсен.

Н и з а м. Белмәс.

Р и з в а н. Гомәр сизмәсен.

Н и з а м. Сизмәс.

Р и з в а н. Ычкын.

Н и з а м. Ычкынам. *(Чыгып йөгерә.)*

Р и з в а н *(як-ягына каранып)*. Басмасы шушы, Әсмасы кайда? Кара, кызык сүз килеп чыкты. Басма, Әсма. Басмасы, Әсмасы. Басмасы шушы, Әсмасы кайда? *(Ләззәтләнеп көлә.)* Юморны аңламыйсың дип көлгән булалар. Аңлыйм бит. Юморны аңламаган кеше шундый сүз уйлап таба аламы? *(Такмаклап.)* Басмасы, Әсмасы, басмасы, Әсмасы... *(Кинәт җитдиләнеп, тирә-ягына каранып тора. Басмага кереп, яр өстен күзәтә. Тәнзилә үтеп барганны күреп, аны чакырып ала...)*

Т ә н з и л ә. Йокларга дип кайтып киткән идегез ич.

Р и з в а н. Йоклаучылар да бар.

Т ә н з и л ә. Ә син нигә монда?

Р и з в а н. Минем нигәдер йокым килми. Туган көнемдә йоклап яту ничектер килешми дә.

Т ә н з и л ә. Аңламассың сине... Нигә чакырдың?

Р и з в а н. Яр буйлап үзеңә генә йөрү күңелсездер дип уйладым.

Т ә н з и л ә. Минем күңелемне ачарга теләмисеңдер ич?

Р и з в а н. Юк, үз күңелемне ачарга телим.

Т ә н з и л ә. Шулаймыни? *(Ризванга төбәлеп карап тора.)*

Р и з в а н. Нигә шулчаклы текәлеп карыйсың?

Т ә н з и л ә. Синең кемлегеңне беләсем килә. Ничә ел бергә укып, аз гына да белмәгәнмен.

Р и з в а н. Серле кеше мин, Тәнзилә.

Т ә н з и л ә. Бүтәннәр йоклый дисең инде?

Р и з в а н. Кайберәүләр йокламый. Низам, мәсәлән.

Т ә н з и л ә. Гомәр белән Заһир йоклыймы?

Р и з в а н. Гомәрне белмим, Заһир йоклый.

Т ә н з и л ә. Аны йоклатып качтыгызмы?

Р и з в а н. Йоклаган йоклый, йокламаган йокламый.

Т ә н з и л ә. Нинди афоризм! Йә, ни сөйләшәбез?

Р и з в а н. Индеме? Инде сөйләшәбез шул хакта... Әгәр дә синең минем белән сөйләшәсең килсә.

Т ә н з и л ә. Ни өчен сөйләшмәскә?

Р и з в а н. Син миңа бераз көлебрәк карыйсың бит.

Т ә н з и л ә. Ничек «көлебрәк»?

Р и з в а н. Ничек икәнен аңлатып бирә алмыйм. Көлебрәк, мыскыл итебрәк. Янәсе, мин синең өчен икенче сорт.

Т ә н з и л ә. Мин кешеләрне сортларга аермыйм.

Р и з в а н. Беләм, мин барысын да күзәтеп йөрим. Еш кына миннән көләләр, ләкин мине белми көләләр, көлгән кешеләр бервакыт үзләре дә белерләр.

Т ә н з и л ә. Сөйләмә юкны, Ризван, кем синнән көлсен!

Р и з в а н. Көләләр. Бер сүз әйтсәм, син дә көләчәксең.

Т ә н з и л ә. Мәсәлән?

Р и з в а н. Мин сине яратам, дисәм... Әнә, әйтәм бит, көләсең.

Т ә н з и л ә. Көлмим ич.

Р и з в а н. Авыз читең белән сиздермичә көләсең.

Т ә н з и л ә. Кызык кеше икәнсең. Яратканыңны әлегә хәтле сизгәнем юк иде.

Р и з в а н. Ә мин сиздермичә яратам.

Т ә н з и л ә. Рәхмәт! Синнән ул сүзне ишетү – куанычлы хәл, Ризван. Тарих моны онытмас, алтын хәрефләр белән язып куяр. Ләкин син кызлар белән сөйләшмәскә ант иткән кеше бит, Ризван.

Р и з в а н. Әйе, иткән кеше.

Т ә н з и л ә. Ә үзең сөйләшәсең.

Р и з в а н. Сөйләшү белән сөйләшүнең аермасы бар. Әгәр дә мин синең белән сөйләшер өчен сине махсус эзләп йөрсәм, антымны бозган булыр идем. Бу – очраклы сөйләшү.

Т ә н з и л ә. Мәхәббәт сөйләрлек булгач очраклы сөйләшү буламы?

Р и з в а н. Була. Мин бит «мәхәббәт» сүзен телгә алмадым, «яратам», дисәм, дип кенә әйттем. Шуны белеп торсаң, бүгенгә шул җитә. Калганын киләчәк күрсәтер.

Т ә н з и л ә. Бар икән күрәселәр!..

Р и з в а н. Әйе, бар. Җитди сөйләшүгә әзер тор, Тәнзилә.

Т ә н з и л ә. Баш өсте, тәкъсир! Җитди кеше белән җитди сөйләшергә туры килер. Тик Заһир белән нишләрбез икән соң, ул да бит мине ярата.

Р и з в а н. «Яратам» дип әйткәне бармы?

Т ә н з и л ә. Әлегә юк югын. Ләкин...

Р и з в а н. Димәк, мин беренче әйттем. Монысы — бер. Икенчедән, Тәнзиләне бер генә егет яратырга тиеш дигән закон юк.

Т ә н з и л ә. Әмма минем берәүне генә яратырга хакым бар.

Р и з в а н. Кемне дип сорамыйм, киләчәк күрсәтер.

Т ә н з и л ә *(Гомәр килгәнен күреп)*. Әнә Гомәр сине эзләп чыккан.

Р и з в а н. Гомәр?.. Тәнзилә, мин сине күрмәдем. *(Китәргә җыена.)*

Т ә н з и л ә. Ничек инде күрмәдең?

Р и з в а н. Күрдем, ләкин күрмәдем. Аңладыңмы?

Т ә н з и л ә. Аңламадым.

Р и з в а н. Миңа моннан тиз генә китәргә кирәк.

Т ә н з и л ә. Юк инде, чакырып алдың да хәзер качасыңмы?

Р и з в а н. Ярый, ярый, күрдем. Ләкин очраклы гына. Мин сиңа «яратам» дип әйтмәдем. Аңладыңмы?

Т ә н з и л ә. Аңламадым.

Р и з в а н. Гомәр белмәсен, Гомәр сизмәсен. Теле озын.

Г о м ә р керә.

Г о м ә р. Исәнмесез! *(Тәнзиләгә.)* Хәерле төн, Низам!

Р и з в а н. Низам түгел ул, Тәнзилә.

Г о м ә р. Шулаймыни? Син Низамны эзләргә киткән идең ич.

Р и з в а н. Без очраклы очраштык.

Т ә н з и л ә. Һәм Ризван миңа «яратам» дип әйтмәде.

Р и з в а н. Әйтмәдем дә. Әгәр дә Низамны күрсәгез, әйтегез, кайтып йокласын. Мин аны эзләүне дәвам итәм. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Г о м ә р. Әллә ниләр эшләнә бу дөньяда. Тәнзилә белән төн уртасында Ризван басма өстендә басып тора дисәләр, үлсәм дә ышанмас идем.

Т ә н з и л ә. Инде ышанырсың.

Г о м ә р. Ярый, ышанырбыз. Ләкин хәзергә шул урыннан кузгалмый тор.

Гомәр тиз генә чыгып китә дә Заһирны җитәкләп керә.

Мин Низамны эзләргә чабам. Мин әйләнеп килгәнче, Тәнзиләне шуннан җибәрмә. Аңа әйтәсе бер-ике сүзем бар. *(Чыгып китә.)*

Озын пауза. Тәнзилә чыгып китә башлый.

Заһир *(исенә килеп)*. Китмә инде, Тәнзилә.

Тәнзилә. Китсә ни булган?

Заһир. Гомәр җибәрмәскә кушты.

Тәнзилә. Ә син җибәрмә.

Заһир. Тотып тора алмыйм ич инде сине.

Тәнзилә *(Заһир каршына тасраеп килеп баса)*. Элек, ичмасам, шигырь укый идең. Инде анысын да оныттыңмыни? Гомерең буе кушканны гына эшләсәң, нишләрсең соң син? Ничек яшәрбез соң без синең белән?

Заһир. Ничек дидең, Тәнзилә?

Тәнзилә. Берни дә әйтмәдем.

Заһир. Яшәрбез, дидең. Яшәрбез булгач, бергә яшәү була түгелме соң? Бергә. Икәү. Гомер буе. Уйлап әйттеңме, Тәнзилә, уйнап әйттеңме?

Тәнзилә. Мин дә синең кебек сүзләрнең кирәген сайлый беләм.

Заһир. Рәхмәт!

Тәнзилә. Нигә рәхмәт, нәрсәгә рәхмәт?!

Заһир. Сүзләрнең матурын сайлый белүеңә рәхмәт.

Тәнзилә. Син... син бит шигырь язасың, телеңә бер дә матур сүз килмимени?

Заһир. Минем күңелем тулы матур сүзләр.

Тәнзилә. Шуларның берсе минем өчен кызганычмыни?

Заһир. Түгел, Тәнзилә. Мин аларның барысын да сиңа әйтер идем.

Тәнзилә. Әйт соң, кайчаннан бирле көтәм.

Заһир. Көтәм?.. Рәхмәт, Тәнзилә. Мин алай дип уйламаган идем.

Тәнзилә. Ничек яшәрбез без синең белән?

Заһир *(шигырь укый)*.

Күңелемнең кыллары бар тибрәнмәгән,
Кылларында көйләрем бар көйләнмәгән,
Сүзләрем күп, серләрем бар сөйләнмәгән,
Шау чәчәкле җәйләрем бар җәйләнмәгән...

Т ә н з и л ә. Ничек итеп яшәрбез без синең белән?
З а һ и р. Йөрәгемдә сагыш түгел, көн дә бәйрәм –
Ярсуларым уйный анда әйлән-бәйлән,
Юлларымның очы әле төйнәлмәгән,
Хисләремнең тезгеннәре бәйләнмәгән.

Т ә н з и л ә. Ничек итеп яшәрбез без синең белән?! Сокланам мин сиңа, Заһир, һәм куркам. Саксыз кыланып, синең күңелеңне ватармын дип куркам.

Пауза.

З а һ и р. Тәнзилә!..

Т ә н з и л ә. Нәрсә, Заһир?

З а һ и р. Юк-юк... Ярамый. Ярамый, Тәнзилә!

Т ә н з и л ә. Нәрсә ярамый, Заһир?

З а һ и р. Антны бозарга ярамый.

Т ә н з и л ә. Нинди ант? Бүтәннәргә кушылып, ни эшләгәнеңне белмичә эшләү ант буламы? Низам белән Ризван шаярганга син чынлап ышангансың.

З а һ и р. Ант белән шаярып буламы?

Т ә н з и л ә. Булмый.

З а һ и р. Димәк...

Т ә н з и л ә. Димәк, икенче тапкыр ант иткәндә, ни өчен ант иткәнеңне белеп итәрсең. «Ант» сүзенең мәгънәсен аңлап эшләрсең.

З а һ и р. Ләкин... Ләкин мин ант иттем.

Т ә н з и л ә. Син аны төштә күрдем дип исәплә.

З а һ и р. Юк, төштә түгел, өндә. Үз телем белән...

Т ә н з и л ә. Алайса, безнең бу сөйләшү төшеңдәдер...

З а һ и р. Юк-юк!

Г о м ә р тамак кыргалап керә.

Г о м ә р. Йә, ничек, Заһир дус, шигырь языламы?

З а һ и р. Языла, Гомәр, языла.

Г о м ә р. Язганнарың Тәнзиләгә ошыймы?

Т ә н з и л ә. Бик ошый.

Г о м ә р. Бик әйбәт. Инде, Заһир, бар, Тәнзиләңне озатып куй да монда кил.

З а һ и р. Нигә килим?

Г о м ә р. Һай, сорау бирмәсеннәр иде дөньяда. Кушканны эшлә.

Т ә н з и л ә. Исеңдә тот, Гомәр, Заһир хәзер сез кушканны гына эшләмәячәк.

Гомәр. Шулаймыни?.. Бик яхшы. Минем күптәнге хыялыма син ирешкәнсең, Тәнзилә. Әмма бу юлы Заһирның сине озатып монда әйләнеп килүе кирәк.

Тәнзилә. Әгәр мин кайтырга теләмәсәм?

Гомәр. Тагын да әйбәтрәк. Барыгыз, култыклашып әнә теге урыннарда йөреп торыгыз. Мин сызгырган тавышны ишетүгә, чабышып монда килерсез. Зинһар өчен, нигә дип сорамагыз. Уңышлар телим.

Заһир белән Тәнзилә чыгып китә. Гомәр басма өстенә кереп аякларын бөкләп утыра да гитара чиртә. Ризван керә.

Ризван. Низамны тапмадыңмы, Гомәр?

Гомәр. Таптым бит, әй.

Ризван. Кайда?

Гомәр. Палаткада йоклап ята.

Ризван. Булмас.

Гомәр. Булган шул менә. Сиңа да вакыт. Каңгырып йөрмә.

Ризван. Хәзер кайтам. Гомәр, сез миннән көләсез, әйеме? Юморны аңламый, дисез. Беләсеңме, бүген мин юмор сүз уйлап чыгардым.

Гомәр. Яле, яле?..

Ризван. Басмасы бар, Әсмасы юк.

Гомәр. Ничек, ничек?

Ризван. Басмасы бар, Әсмасы юк. Уңышлы юмор бит, әйеме?

Гомәр. Шаккаткыч! *(Кычкырып көлә башлый, аңа Ризван кушыла. Гомәр, көлүеннән кинәт туктап.)* Әйдә кайтабыз, юморист.

Ризван. Кая?

Гомәр. Кайда яшәгәнеңне оныттыңмы әллә?

Ризван *(үз халәтенә кайтып)*. Онытмадым. Мин әле кайтмыйм.

Гомәр. Антыңны бозасыңмы?

Ризван. Антның монда катнашы юк. Үземнең туган көнемдә басма өстендә ялгызым гына уйланып утырырга хакым бар.

Гомәр. Утыр, алайса. Мин кайтам, йокым килә. *(Чыгып китә.)*

Ризван басма өстендә бөеренә таянып басып кала. Алинә керә.

Алинә. Ялгышмагансыз. Басманы эзләп тапкансыз.
Ризван. Эзләмәдем, үзе очрады.
Алинә. Юлыгызга чыгып ятканмыни?

Ризван җавап бирми. Пауза.

Ризван. Төн бик матур.
Алинә. Искиткеч!..
Ризван. Елга да бик матур.
Алинә. Гаҗәеп!..
Ризван. Йолдызлар да бик матур.
Алинә. Сөйлисе дә юк.

Пауза.

Ризван. Сез курыкмыйсызмы?
Алинә. Нәрсәдән?
Ризван. Нәрсәдән түгел, кемнән!
Алинә. Кемнән?
Ризван. Миннән.
Алинә. Ни өчен?
Ризван. Төн бит.
Алинә. Булса ни?
Ризван. Аулак урын бит.
Алинә. Булса ни?
Ризван. Һе...
Алинә. Нәрсә «һе»?
Ризван. Мин килдем бит.
Алинә. Күреп торам.
Ризван. Сезнең чакыруыгыз буенча килдем.
Алинә. Мин сезне чакырмадым.
Ризван. Сез нәрсә мине ахмакка саныйсыз? Мин намёк белән сөйләшкәнне аңлыйм.
Алинә. Шулай укмыни?
Ризван. Әйе. *(Алинәнең кулын тота.)*
Алинә. Нишлисез?
Ризван. Кулыгызны тотам.
Алинә. Ни өчен?
Ризван. Бу нинди тиле сорау. Шуны да белмәскә...
Алинә. Чынлап та белмим. Йөрәк тибешемне тыңлар өченме?
Ризван. Сезнең йөрәк тибешегез миңа нигә кирәк? Мин врач түгел. Төшенегез, әгәр мин сезнең кулыгызны тотам икән, бу – мәхәббәт аңлату билгесе. Аңладыгызмы, ниһаять?

А л и н ә. Аңладым, ниһаять. Сез булмасагыз, белми үләсем икән. Инде нишлибез?

Р и з в а н. Мәхәббәт турында җитди итеп сөйләшәбез. Аңлагыз, мин шаярып сөйләшмим. Әгәр дә мин ни дә булса әйтәм икән, бу — чын. Һәм мин сүзләремне чын итеп кабул итүләрен таләп итәчәкмен. Аңлашыламы?

А л и н ә. Аңлашыла. Ләкин, ялгышмасам, сез мәхәббәт турында сөйләшмәскә ант иткәнсез.

Р и з в а н. Антны мин иткән, сез түгел. Нигә борчыласыз?

А л и н ә. Болай гына әйтүем.

Р и з в а н. Болай гына әйтү өчен нигә сүз әрәм итәргә.

А л и н ә. Алайса, дәшмим.

Р и з в а н. Дәшмәгез һәм мин сөйләгәнне генә җитди итеп аңлагыз. Димәк, болай...

Кинәт Нәҗип гармунының әче итеп кычкырган тавышы ишетелә. Н ә җ и п үзе дә күренә. Ризван куркуыннан басма читенә үк чигенә.

Н ә җ и п *(басма янына ук килеп)*. Эләктеңме, апаем? Теге юлы берәвегез ычкынды, бу юлы ычкына алмассың. Алинә, мин алар кебек матур итеп сөйләшә алмыйм. Турыдан-туры ярып әйтәм: чык басмадан.

А л и н ә. Нәҗип абый, нишләвегез бу?

Н ә җ и п. Мин Нәҗип абый түгел, миңа әле утыз гына яшь. Сиңа егерме. Чык басмадан. Беркая да китмәенчә янымда тор. Мине тиң күрмәсәң дә, мин әйткәннәрне бу юлы тыңла. Яратмасаң, соңыннан әйтерсең.

Алинә басмадан чыга. Ризван да кузгала.

Н ә җ и п. Ә син, апаем, селкенмә.

Р и з в а н. Шаярмагыз.

Н ә җ и п. Шаярмаем, апаем. Сиңа бу якка юл юк. Теге якка йөзеп чык.

Р и з в а н. Мин — сезнең авылга Культура йорты салырга килгән кеше. Мине хөрмәт итүегезне үтенәм.

Н ә җ и п. Культура сараен басма өстендә төнлә салмыйлар. Сикер суга.

Р и з в а н. Алинә, әйтегез аңа, шаярмасын.

Н ә җ и п. Мин хәзер беркемне дә тыңламаем. Чум суга!

Р и з в а н *(кычкырып)*. Мин йөзә белмим.

Н ә җ и п. Кычкырма, апаем, мин курыкмаем. Районга – глава, авылга мин хуҗа. Йөзә белмәгәч, басма өстенә кермиләр аны. Сикер, чум! *(Әкрен генә басмага керә.)*

Р и з в а н. Килмә, батып үлсәм, судка бирәчәкмен, җавап бирәчәксең, закон нигезендә.

Н ә җ и п. Әһә, шүрләдеңме? Әйт, Нәҗип абзыкаем, исән-сау җибәрсәң, Алинәнең кырына да килеп карамам, диген. Ак тәүбә, кара тәүбә, диген.

Р и з в а н. Ак тәүбә, кара тәүбә...

Н ә җ и п. Инде хәзер шул тәүбәңне җыр белән әйт.

Р и з в а н. Җырлый белмим.

Н ә җ и п. Суга төртеп төшерсәм өйрәнерсең. Йә... башла! *(Гармунын тартып җибәрә.)*

Р и з в а н *(бераз аптырап тора да җиңел генә котыла алмаячагын аңлап җырлый башлый)*.

Былтыр җуйган балдагымны
Быел таптым утлыктан;
Җырлыйсым килеп җырламыйм,
Җырлыйм чарам юклыктан.

Н ә җ и п. Шулай, шулай, апаем. Кычкырыбрак. *(Үзе җырлап җибәрә.)*

Агыйделнең аръягында
Төшеп калды галушым;
Тагын берне җырлап җибәр,
Ишетелсен тавышың.

Р и з в а н. Уфа безгә ерак түгел,
Телефон алдырмагыз;
Җырла диеп, җыр җырлатып,
Тавышсыз калдырмагыз.

Г о м ә р керә. Керә дә ике бармагын авызына тыгып сызгыра. Шуны гына көткәндәй, Д а м и р ә н е җитәкләп, Н и з а м пәйда була.

Н и з а м *(белмәгәнгә салынып)*. Ни булды, ә, ни булды? Йокларга яткан җиремнән сызгырып уяттыгыз.

Р и з в а н. Әй сез! Алыгыз бу мир үгезен юлымнан. Ул мине суга батырырга теләде.

Н ә җ и п. Тик тор, апаем! *(Егетләргә.)* Алинә белән сөйләшеп торганда эләктердем мин аны. *(Гомәргә кулын сузып.)* Тот Нәҗип абзыкаеңның кулын, дөрес

әйткәнсең, алдамагансың. Тач шушы урында басып торалар иде.

Р и з в а н. Иптәш Шәйхетдинов, бу этлекне, димәк, син эшләдең?! Без синең белән аерым сөйләшербез. *(Басмадан чыгарга килә.)*

Н ә җ и п. Кузгалма, апаем, урыныңа бас!

Р и з в а н. Белеп торыгыз: безнең бригадада сатлыкҗан иптәш Шәйхетдинов яши. *(Тәнзилә белән кергән Заһирга мөрәҗәгать итеп.)* Син дә ишет, Заһир, Гомәргә безнең коллективта урын юк... Әйе, диген.

Г о м ә р. Антыңны син боздың, Ризван.

Р и з в а н. Мин бозмадым, боздырдылар. *(Алинәгә күрсәтә.)*

А л и н ә *(көлеп)*. Кем миңа мәхәббәтен җырлады?

Т ә н з и л ә. «Яратам» дип миңа кем әйтте, Ризван?

Р и з в а н. Әһә, син дә миңа каршы, Тәнзилә... Ярый, ярый... Көлегез миннән. Мин антымны боздым, суга сикерәм, батып үләм. Тик минем белән бергә Низам да, Заһир да антларын боздылар. Низам, Заһир, рәхим итегез минем янга!

Н и з а м. Дөрес, Ризван. Мин һәрвакытта синең белән. Бәхил бул, Дамирә! *(Басмага кереп, Ризван янына баса.)* Заһир, рәхим ит!

Т ә н з и л ә. Заһир антын бозмады.

З а һ и р. Яклавың өчен рәхмәт, Тәнзилә. Тик мин алар янында булырга тиеш.

Т ә н з и л ә. Син миңа «яратам» дип әйтмәдең бит.

З а һ и р. Телем әйтмәсә дә, күңелем сөйләде. Күзләреңә карап тордым. *(Ризван белән Низам янына кереп баса.)*

Г о м ә р. Шагыйрь чыгачак синнән, Заһир. *(Егетләргә.)* Йә, нишлибез, әфәнделәр?

Н и з а м. Суга сикерәбез, батып үләбез.

Г о м ә р. Ашыкмагыз, әфәнделәр! Шарт буенча, җәзаны мин билгелим. Суга чумып котылмакчы буласызмы? Ә Культура йортын бүтәннәр төзеп бетерсенме? Ашыкмагыз, шаярмагыз! Кисәттем мин сезне. Мин рәхимсез, дидем, җәза каты булачак, дидем. Инде шаярмыйча тыңлагыз. *(Житди тонга күчеп.)* Без, гомумән, шаярырга яратабыз. Шаянлык, җорлык, әлбәттә, кеше өчен тормышта кирәк нәрсә. Бик кирәк! Ләкин без чамадан да чыгып китәбез бугай. Онытылып китеп изге хисләр, изге

сүзләр белән шаярабыз. Нәтиҗәдә хисләребез тупаслана, бөек сүзләр арзаная, үзебез вакланабыз. Мәхәббәт, Ватан, Ант! Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатырга җыенмыйм. Без аларны беләбез, бәлки, аңлыйбыздыр да. Ләкин... ләкин... Шаярган арада бераз гына, аз гына булса да уйланып куйыйк. Ант... Күпме бөек җаннар гомерләре бәрабәренә шушы изге сүзгә турылыклы булып калганнар! Бернинди дә җәза бирмим мин сезгә, дуслар! Без бит шаярдык кына, бары тик шаярдык кына. Ак тәүбә, кара тәүбә. *(Шаян тонга күчә.)* Йөзләрегез нигә җитдиләнде, әфәнделәр? Нигә боегып калдыгыз? Әйдәгез әле, без бит яшьләр, безгә боегу килешми. *(Гитарасын чиртә. Җыр башлый. Аңа бүтәннәр кушыла.)*

Күңелдә җыр туа,
Күңелгә нур тула,
Талларда
Таңнарда
Сандугач сайраса, моңланса;
Сандугач кунармы талларга,
Сандугач сайрармы таңнарда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

П ә р д ә.

# КАНКАЙ УГЛЫ БӘХТИЯР

*(Тарихи драма)*

Ике бүлектә, унике күренештә

Фәнни консультант — тарих фәннәре кандидаты Сәләм Алишев.

Катнашалар:

Бәхтияр Канкаев — Пугачёвның полковнигы. 30–35 яшьләрендә.
Нурсолтан — 20–22 яшьләрендә.
Емельян Пугачёв — 31–32 яшьләрендә.
Әбүбәкер Теләчев — Бәхтиярның секретаре (писарь).
Кинҗә Арсланов — Пугачёв штабында югары совет члены.
Иван Белобородов — Пугачёвның атаманы.
Абдулла Мостаев — Пугачёвның подполковнигы.
Шигаев — Пугачёв штабында дәүләт хәрби коллегиясе члены.
Гаврила Лихачев — Бәхтияр отрядында йөзбашы.
Мортаза.
Василий.
Ертык чикмән.
Кызыл ыштан.
Мескен бүрек.
Арадан берәү.
Арадан икенче.
Екатерина II — императрица. 44–45 яшьләрдә.
Потёмкин Григорий — кенәз, генерал-поручик. 34–35 яшьләрдә.
Ханбик — авыл бае.
Мулла.
Симез адәм.
Җәза отряды офицеры.
Лашманчылар, чапкыннар, сугышчылар, теләнчеләр, базар халкы, хор.

Вакыйга 1773–1774 елларда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Х о р. Тып-тып тояк тавышын
Тыңлап үскән баладыр,
Урал тауның сагышын
Җырлап үскән баладыр,
Акбүз атта барадыр
Канкай углы Бәхтияр.
Кара кошны атарга
Җәя белән ук алган,
Пайтәхетне ватарга
Ядрә белән туп алган,
Яу ияртеп кузгалган
Канкай углы Бәхтияр.

Пәрдә ачыла. Сәхнәдә — урман аланы. Кич. Учак яна. Учак тирәсендә л а ш м а н ч ы л а р. Араларында — П у г а ч ё в. Ул бер читкәрәк урнашкан да ашап утыра. Тынлык.

— Бүген кайсы көн?

— Кем белә. Көне түгел — ае, елы онытылган. Җәекышы буталган. Кайсы көн булса да барыбер.

П у г а ч ё в. Мең дә җиде йөз җитмеш өченче ел. Егерме бишенче июль.

— Бу дөньяда бездән дә артык михнәт күргән адәмнәр бар микән? Урман, урман. Җир йөзендә урмансыз җир юк микәнни?! Безгә анда урын юк микәнни?! Лашманчы булып үләргә язган микәнни? Яланаяк җиргә басып сука артыннан йөрисем килә, җир сөрәсем килә.

М о с т а е в. Җылама, ачуны китереп. Бар, сөр, чәч, үстер! Үстергәнеңне боярлар ашар.

— Ашасыннар, тамаклары тыгылсын! Агач астында калып үләсем килми. Әй, кодрәтемнән килсә, кулыма балтамны алыр идем дә дөньясындагы урманнарны, авылларны, калаларны тетеп чыгар идем, кешеләрен тунар идем, берәүсен дә калдырмас идем.

М о с т а е в. Безне дәме?

— Барыгызны да, барысын да. Иң соңынтын үз муеныма чабар идем.

П у г а ч ё в. Кешеләрнең ни гаебе бар?

— Син тик тор. Ашарыңа бирделәр, тыгын. Син —

сукбай. Сиңа барыбер. Бүген монда килеп теләнәсең, иртәгә – тегендә.

Пугачёв *(сикереп торып)*. Мин теләнмәдем. Биргән ризыгыңны кызгансаң ал.

Мостаев. Йә, җитте. Урыныңа утыр, мосафир. Ачуын кая чыгарырга белмәгәннән кычкыра ул.

Пугачёв утыра.

Син дә утыр, Шәрифҗан. Син кычкырганга карап дөньясы төзәлмәс. *(Паузадан соң.)* Син, мосафир, үзеңне кай яктан дидең?

Пугачёв. Җаек ягыннан.

– Ул да Рәсәй җиреме?

– Рәсәй булмый ни булсын. Бөтен дөнья Рәсәй.

Мостаев. Анда ничек тормышлар?

– Майлы ботка ашыйлар, ди. Яхшы булса, монда килеп адашып йөрмәс иде.

– Менә Ырынбур ягында әйбәт, ди. Моннан киткән татарлар рәхәтләнеп сәүдә итеп яшиләр, ди.

Пугачёв. Кем әйтте?

– Ишеттем.

– Син күргәнеңне сөйлә, тыңкыш танау. Кайда да бер кояш.

Пугачёв. Кайда да бер патша.

Мостаев. Дөрес әйтә. Кайда да бер патша. Патшасы начар. Менә нәрсәдә хикмәт. Яңа патша кирәк.

– Каян аласың ул яңа патшаны?

– Усак агачыннан юнып бирермен.

Көлешәләр.

Мостаев. Авызыгызны ермагыз. Питыр Өченче дигән патша исән, ди бит. Әби патша аны кара халыкны яклаган өчен үтертмәкче булган. Ул качып котылган, ди. Боерган булса, Питырбурга барыр да янә патша булып утырыр. Син, мосафир, күп йөргән адәм, дөресме шул, ишеткәнең бармы?

Бәхтияр Канкаев керә.

Бәхтияр. Әссәламегаләйкем, җирдәшләр!

– Вәгаләйкүмәссәлам.

Бәхтияр. Мин – мосафир. Ут күрдем дә туктадым.

– Монда туктаучы син генә түгел.

Б ә х т и я р. Сез лашманчылармы?

М о с т а е в. Лашманчылар. Үзең кем?

— Нәрсә сорап торасың, мосафир, диде. Хәзер дөньясы тулы мосафир. Бөтенесе кая барып бәрелергә белмичә адашып йөриләр. Утыр. Синең дә ашыйсың киләме? Соңга калдың. Умачны синнән алда килгәне чөмереп бетерде.

Бәхтияр Пугачёвка карап ала да учак янына чүгәли.

Б ә х т и я р. Эшләрегез ничек, җирдәшләр?

— Шуны сорар өчен төнлә йөрисеңме?

Б ә х т и я р. Хәл белешү гаеп түгел.

М о с т а е в. Лашманчының хәле билгеле. Кулыннан — балта, җилкәсеннән бүрәнә төшми.

Б ә х т и я р. Кая барсаң — шунда зар, хәл сорасаң — уфтану... Алабуга моннан ерактамы, кардәшләр?

М о с т а е в. Утыз чакрым чамасы.

— Нәрсә син монда килеп төпченәсең?! Юлыңда бул!

— Син, Шәрифҗан, эт кебек өреп кенә торасың.

— Ачуны китермәсеннәр. Йөрәкне тырнамасыннар. Мосафир икән, юлларында булсыннар.

Б ә х т и я р. Мин сиңа тимәдем бит, кардәш.

— Тиеп кара, йә, тиеп кара. Кырам, бетерәм! *(Балтасын алып, алан буйлап чабып йөри.)* Кырам, бетерәм!

М о с т а е в. Шәрифҗан!.. Шәрифҗан, ташла балтаңны!

Пугачёвтан башкалар барысы да урыннарыннан торалар. Бәхтияр Шәрифҗанга каршы бара.

— Барма, харап итә... Ул акылын җуйган.

Бәхтияр Шәрифҗан янына барып, балтаны тартып ала да читкә ыргыта. Ш ә р и ф җ а н үкереп елап чыгып йөгерә.

М о с т а е в. Әйдәгез, үзен үзе харап итмәсен.

Л а ш м а н ч ы л а р Шәрифҗан артыннан чыгып китәләр. Бәхтияр учак янына килә.

П у г а ч ё в. Кыю кеше икәнсең. Күрешергә кулыңны суз.

Б ә х т и я р. Син кем?

П у г а ч ё в. Синең кебек үк юлаучы.

Б ә х т и я р. Юлың кая?

П у г а ч ё в. Оренбург ягына. Синең?

Б ә х т и я р. Кунгур өязенә. Бу якларга ничек килеп чыктың? Белгәнемчә, Ырынбур еракта.

П у г а ч ё в. Казан каласында читлектә идем — читлекләре тар булды. Шундый иркен дөнья барында тар читлеккә бөркет ничек сыйсын. Тау бөркете кыя эзли, дала бөркете даласына оча. Син дә читлектәнме?

Б ә х т и я р. Миңа дигән читлек ясалмаган.

П у г а ч ё в. Бу заманда читлек ясау авыр эш түгел. Барып эләккәнеңне сизми дә калырсың. Күреп торам, безнең язмышлар уртак.

Б ә х т и я р. Каян беләсең?

П у г а ч ё в. Ишетеп тордың — балта күтәргән кеше әйтте — дөньясы тулы мосафир, кая барып бәрелергә белмичә адашып йөриләр, диде.

Б ә х т и я р. Мин адашмадым. Мин эзлим.

П у г а ч ё в. Нәрсә эзлисең?

Б ә х т и я р. Хаклык.

П у г а ч ё в. Таптыңмы соң?

Б ә х т и я р. Юк.

П у г а ч ё в. Юк. Эзләп табылмый ул хаклык. Хаклыкны эзләмиләр, туган. Хаклыкны тартып алырга кирәк.

Б ә х т и я р. Кемнән?

П у г а ч ё в. Кем урлаган — шуңардан. Ишеткәнең юкмыни, халык нәрсә сөйли. Пётр Өченче дигән патша исән, дип сөйли. Үлгәненә ун ел — халык ышанмый. Екатерина патша Пётр Өченче дигән патшаны үтертмәкче булган, ди. Кара халыкны яклаганы өчен. Пётр Өченче качып котылган, ди. Яңадан тәхетен даулый, ди. Бәлки, хаклыкны, безнең бәхетебезне Екатерина патша урлагандыр? Урлагандыр да боярларга саткандыр?

Б ә х т и я р. Син әкәмәт кеше булып чыктың.

П у г а ч ё в. Кайда гына, кайларда гына булмадым мин, нужаларның ниндиләрен генә күрмәдем. Өстем ялангач, тамагым ач булды, төрмәләрдә күпме көн үткәрдем. Бер Ходаем үзе генә белә. Моның чиге-ахыры булырга тиеш. Бөтен Россиядә мескен кара халык рәнҗетелә, талана. Кая барсаң — шунда зар, хәл сорасаң — уфтану. Чиге булырга тиеш... Барасыңмы минем белән?

Б ә х т и я р. Кая?

П у г а ч ё в. Миңа кыю юлдаш кирәк. Син татармы?

Б ә х т и я р. Татар.

П у г а ч ё в. Оренбург ягында татарлар күп.

Б ә х т и я р. Туган ягымны сагындым.

П у г а ч ё в. Хуш, алайса, миңа вакыт. Юлым озын. Хаклыкны эзләмиләр, туган, тартып алалар. Аның өчен бөркет йөрәкле булырга кирәк. Мәрхәмәтле Алла бөркетне очар өчен яраткан, аның урыны кояш астында. Бөркеткә очар өчен үз даласы кирәк. Очар-очар да кунар әле ул. Сау бул, егет. Күрешергә кулыңны суз.

Күрешәләр.

Исемең кем?

Б ә х т и я р. Бәхтияр Канкай углы.

П у г а ч ё в. Хуш, Бәхтияр Канкай углы. *(Китә.)*

Б ә х т и я р. Исемеңне әйтмәдең!

Җавап урынына хатын-кызның әче итеп кычкырган тавышы ишетелә. Аланга Н у р с о л т а н йөгереп керә. Аның артыннан Х а н б и к чыга. Ханбиккә М о р т а з а ияргән. Ханбик Нурсолтанга ташлана, Нурсолтан, җирдә яткан күсәкне күтәреп, аңа кизәнә.

Н у р с о л т а н. Килмә!

Күтелмәгән бу хәлдән Ханбик чигенеп куя.

Х а н б и к. Йа Хода. Ни кылана бу мәхлук? Азма, явыз, яман булыр! Мортаза! Тот тизрәк!

Н у р с о л т а н. Китегез! *(Күсәкне күтәргән килеш чигенә.)*

Х а н б и к. Кыланма, бәндә баласы! Мортаза, ал күсәген!

М о р т а з а. Ташла күсәгеңне, Нурсолтан!

Нурсолтан чигенүен дәвам итә. Ләкин урман эченә кереп китәргә өлгерми, абынып егыла. Ханбик аның өстенә ташлана, кызны тукмарга тотына.

Н у р с о л т а н *(тарткалаша, җан ачысы белән кычкыра)*. Җибәрегез!.. Җибәрегез!..

Х а н б и к. Оятсыз мәхлук!.. Тот кулыннан, Мортаза, сөйрә!

М о р т а з а. Әйдә, Нурсолтан!

Кыйналган Нурсолтанны ике кулыннан сөйрәп алып китә башлыйлар. Шулчак аларның каршына Бәхтияр килеп баса.

Б ә х т и я р. Әссәламегаләйкем! Ни кыланасыз, кардәшләр?!

Х а н б и к. Син кем?!

Б ә х т и я р. Иң элгәре биргән сәламемне ал.

Х а н б и к. Кит юлдан!

Б ә х т и я р. Минем сукмак шуннан уза, сезнең юлыгыз кайда? Киек ауларга чыккансыз дисәм, кулыгызда киек түгел. Кем ул?

Х а н б и к. Анда синең ни эшең бар?

Б ә х т и я р. Сорыйм икән – эшем бар. Җавап алмый китә торган гадәтем юк.

Х а н б и к. Кем син?

Б ә х т и я р. Шушы җирнең баласы. Сез кемнәр вә тоткан киегегез кем? Күрсәтегез, карыймчы. *(Нурсолтан янына килә. Нурсолтанның йөзенә карый.)* Асылзатны эләктергәнсез. Исемең кем, асылзат?.. Ә нигә ул дәшми? Җибәрегез аның кулларын.

Х а н б и к. Әй, йолкыш, син узына башладың. Башың исән чакта югал!

Б ә х т и я р. Минем башым авыррак, күтәрә алмассыз, кардәшләр. Җибәрегез. Аучылармы дисәм, газраилләр икәнсез ләбаса.

Х а н б и к. Нәрсә карап торасың, бир кирәген, Мортаза!

Нурсолтанның кулларын ычкындырып, Бәхтияр өстенә киләләр. Бәхтияр бер селтәнүдә икесен ике якка аудара.

М о р т а з а. Качкын! Юлбасар! *(Сикереп торып качмакчы була.)*

Бәхтияр аны эләктереп ала. Ханбикнең дә якасы Бәхтияр кулында.

Б ә х т и я р. Танышуыбыз күркәм булды, инде җавап бирегез, кем ул җирдә җансыз яткан асылзат? Кем?!

М о р т а з а *(Ханбиккә күрсәтеп)*. Ул аның хатыны.

Б ә х т и я р. Хатын кеше өйдә утыра. Ул нигә урманда? Хатын кешенең ире берәү була. Сез нигә икәү?

М о р т а з а. Мин аның ялчысы.

Б ә х т и я р. Ялчы булсаң, хуҗаңнан узып сөйләмә. *(Ханбиккә.)* Син нигә дәшмисең?

Х а н б и к. Ул минем хәләл малым. Мин аны сатып алдым. Җибәр җиләнне, якасын ертасың.

Нурсолтанның торып утыруын күреп, Бәхтияр Ханбик белән Мортазаны җибәрә дә Нурсолтан янына килә. Нурсолтан аны күргәч, кычкырып җибәрә.

Ханбик *(Нурсолтан янына килеп)*. Тор, мәхлук, кайт өйгә.

Нурсолтан *(йөзен яшереп)*. Кит!.. Китегез!..

Ханбик. Кемгә әйтәләр!

Нурсолтан. Үтер! Үтерегез! Җаным шәһит китәр. Бу дөньядагы тәмугта янганчы, теге дөньяның җәннәтенә китсен җаным. Мәңге сиңа буласым юк.

Ханбик. Үкермә, җирбит.

Бәхтияр *(Ханбиккә)*. Хәләл дигәнең хәрәм булган түгелме соң, җирдәш? Сатып алган малыңның күз яшьләре бүтән адәм балаларының күз яшьләре кебек үк пакь.

Ханбик. Ояты юк аның, ир өеннән качып китте.

Бәхтияр. Хатын кеше оятын җуйса, ир гаепле.

Нурсолтан. Мин аның хатыны түгел.

Ханбик. Тик тор димен, тый телеңне!

Бәхтияр, тезләнгән җиреннән кинәт торып, Ханбик каршына баса. Ханбик чигенеп куя.

Бәхтияр. Курыкма, җирдәш. Сатып алган малың түшәгеңдә ничә төн йоклады?

Ханбик. Анысы сиңа нигә кирәк?

Бәхтияр. Җавабың бир!

Мортаза. Алып кайткан көнендә үк чыгып качты.

Ханбик. Син, бүкән, тик тор!

Бәхтияр. Ул мал өчен күпме тәңкә түләдең?

Ханбик. Нигә кирәк?

Бәхтияр. Җавабың бир.

Ханбик. Ун тәңкә.

Бәхтияр. Мин сиңа ун тәңкә бурычлы. Форсат чыккач түләрмен. Өеңә кайт, җирдәш. Карышма, газиз җаның ун тәңкәдән кыйммәтрәктер. Йә, хуш иттек.

Ханбик. Хатыным нишли?

Бәхтияр. Мин сатып алгач, ул синең хатының буламы?! Сөйләшергә вакытым тар, юлыңда бул. Әй, ялчы, ияр хуҗаңа!

Ханбик әкрен генә чигенә дә, бераз киткәч, «Каравыл, таладылар!» дип кычкырып чыгып йөгерә. Аңа Мортаза иярә. Бәхтияр Нурсолтан янына килә.

Бәхтияр. Әлеге кылган эшем яман булса, кичерә күр. Әйткән сүзләреңнең хаклыгына, күз яшьләреңнең пакьлегенә ышанып шулай эшләдем. Күңелемдә яман уй юк.

Нурсолтан. Син кем?

Бәхтияр. «Бәхтияр» дип әйтә иде атай. «Канкай углы» дип әйтәләр иде авылдашлар. Торган урыным җир өсте, барыр юлым җир чите. Син үзең кем баласы?

Нурсолтан. Актау авылыннан. Атым – Нурсолтан. Юкәче Бигеш атлы ирнең хатыны идем. Ханбиккә бурычлы булды ирем. Бурычы өчен мине бирде. Ирем – яхшы кеше, Ханбик явыз.

Бәхтияр. Хатынын саткан ир яхшы буламы?

Нурсолтан. Гайре чарасы булмады. Мин аңа яманлык теләмим. Рәнҗетми иде мине. Комсыз Ханбик хатыннардан туймады.

Бәхтияр. Ходай сиңа чибәрлекне мул биргән. Кайсы ир кызыкмас. Хатын-кызның ни икәнен белмәгән мин буйдак та сине күргәч...

Нурсолтан *(читкә тайпылып)*. Алла хакы өчен...

Бәхтияр. Өрекмә, асылзат, мин җанвар түгел.

Нурсолтан. Син качкынмы?

Бәхтияр. Юк. Юлаучы.

Нурсолтан. Качкыннар күбәйде, дип сөйли ирем. Безнең авылдан да берәү, солдат хезмәтеннән качып, урманнарда көн күрә, дип сөйлиләр. Син бу якныкымы?

Бәхтияр. Ерактан.

Нурсолтан *(кинәт исенә төшеп)*. Ай, Ханбик кешеләр җыеп монда килер.

Бәхтияр. Авылыгыз еракмы?

Нурсолтан. Авылдан чыккач ярты көн йөгердем.

Бәхтияр. Инде ни эшләргә җыенасың, кай якка юл тотмакчы буласың? Ирең янына кайтасыңмы?

Нурсолтан. Ханбик барыбер алып китәчәк. Хәзер төннең кай вакыты?

Бәхтияр. Таң атар чак җиткәндер.

Нурсолтан. Урман артында Дүрттүбә авылы. Анда – минем әниемнең туганнары.

Бәхтияр. Ханбик аннан тапмасмы?

Нурсолтан. Яшерерләр. Мин китим. Рәхмәт сиңа, юлаучы.

Бәхтияр. Минем атым Бәхтияр.

Нурсолтан. Рәхмәт сиңа, Бәхтияр. Ходай Тәгалә юлларыңны уң итсен.

Бәхтияр. Амин, юкәче Бигеш хатыны Нурсолтан. Илтеп куйыйм дисәм, барыр җиремә ашыгам. Илтеп куй дисәң, вакыт табармын.

Нурсолтан. Рәхмәт. Бу урманда мин адашмыйм. Ай гына батмасын. *(Китә башлый да яңадан Бәхтияр янына килә.)* Батыр йөрәкле, пакь күңелле ирләр беткән бу заманда син очрагач, хәсрәтләрем кимегәндәй булды. Бердәнбер байлыгым — муенымдагы мәрҗәнем. Ал шуны. Дәшми ал. *(Муеныннан мәрҗәнен салып бирә.)*

Бәхтияр *(мәрҗәнне алып)*. Асылзатлар сатылган бер заманда сатылырга теләмәгән хатынга ни бүләк итим? *(Киеменнән бер төймә өзеп бирә.)* Ал шуны. Күңелемне гашыйк иттең.

Нурсолтан. Сөйләмә андый сүзләр. Мин — ир хатыны.

Бәхтияр. Ханбик сиңа ир түгел, үзең әйттең. Юкәче Бигеш сиңа тиң түгел — монысын мин әйттем. Хуш, асылзат! Мин мосафирны догаңнан калдырма. Хуш!

## Икенче күренеш

1773 елның көзе. Красноуфимск тирәсендәге бер авылның базар мәйданы. Базарның кызган чагы. Сатучылар, алучылар бергә болгана. Саилчеләр хәер сорана.

— Алача, алача!.. Кемгә алача?! Ыштан итеп тексәң, ун елга чыдый, күлмәк итсәң, йөз елга түзә.

— Әй, знакум, падхади!.. Дарма-шарма — карабодай ярма.

Василий *(җирән сакаллы теләнче)*. Подайте, подайте!..

— Комач, комач!.. Ун тиенгә бер колач!..

— Кая тыкшынасың, әллә күзең чыкканмы?!

— Чово орёш?..

— Бирермен мин сиңа арыш...

— Кайда арыш, кемдә арыш?..

— Әтәч сатам, алыгыз — йомыркасыз калмас тавыгыгыз...

— Балаларым ач, хатыным ач, кызганыгыз...

— Ач хатынга ник өйләндең?..
— Авызыңны ерма, иртәгә син дә шушында утырырсың.
— Әссәламегаләйкүм, кордаш.
— Вәгаләйкүмәссәлам. Янында кем?
— Башкорт адәме. Белешем. Базарга килгән, сөйләшергә теле юк.
— Кискәннәрмени?
Башкорт башын селки.
— Батырша заманындамы?
Башкорт башын селки.
— Алай икә-ән.
— Карале, кордаш, ниндидер манифис чыккан, ди. Ишетмәдеңме, күрмәдеңме?
— Ишетмәдем, күрмәдем. Син ишеттеңме, Канкайның углы кайткан, ди.
— Кайсы Канкай?
— Иштуган сотнясындагы көрәшче Канкайны беләсеңдер.
— Йә-йә, углына ни булган иде?
— Кәтәни алпавытының утарына ут төртеп качкан иде.
— Йә-йә, ишеттем. Шул кайткан диме?
— Кайткан, ди. Кеше талап йөри, ди.
— Алланың биргәненә шөкер, таларлык малым юк. Манифис турында ишетмәдең инде, алайса?
— Юк. Нинди манифис ди соң?
— Яңа падишаһ килеп чыккан, ди. Татарларга җир бирәм дип әйтеп әйткән, ди.
— Булмаганны сөйләмә.
— Булган, ди, шул менә. Бөтен тирә-якта сөйлиләр.
— Ходай бирсен, илгә җиңеллек килсен.
— Яңа падишаһ булса килә инде ул, кордаш.
— Киндер мае, киндер мае!.. Кемгә кирәк киндер мае?!

Б ә х т и я р керә. Өсте-башы җыйнак. Базарны күзәтә.

— Агай-эне, тоз сатмыйсыңмы?
Б ә х т и я р. Ни дидең?
— Тозың юкмы, дим.
Б ә х т и я р. Патша тозны базарда саттырмый. Белмисеңмени?
— Әкрен инде, кычкырма, май кап.

— Мөселман кардәшләр, балаларым, хатыным ач.
— Алача, алача! Кемгә кирәк алача?!

Алача сатучы үтеп киткәч, Әбүбәкер Теләчев керә. Мулла киеменнән. Бәхтиярны күреп, аңа текәлеп карап тора.

Теләчев. Бәхтияр! Син түгелме соң бу?
Бәхтияр. Әбүбәкер?..
Теләчев. Мин шул. Саумы, исәнме, Бәхтияр?! Йә Алла, сине күрмәгәнгә ничә ел! Кайларда, нишләп йөрисең?
Бәхтияр. Син әкренрәк.
Теләчев. Нигә әкрен?
Бәхтияр. Болай гына. Могтәбәр кешеләргә кычкырып сөйләү килешми. Үзең ни саулыкта?
Теләчев. Аллага шөкер!
Бәхтияр. Бу якларга ничек килеп чыктың? Ялгышмасам, Карыгый авылы моннан ат белән өч көнлек юл.
Теләчев. Хәтерлимсең Нуриәхмәт атлы шәкертне, ул да бит шушы якныкы, аның янына килдем дә базарга кереп чыгыйм дидем. Нуриәхмәт мөгаллимлек итә бит, беләсеңдер.
Бәхтияр. Белмим.
Теләчев. Әллә аның белән дошманлаштыгызмы? Синең турыда аңардан сораган идем, ул да, белмим, диде. Кайларда соң үзең, кем?
Бәхтияр. Син мулла булдыңмы?
Теләчев. Аллага шөкер, мәхәллә тотабыз.
Бәхтияр. Морадыңа ирешкәнсең.
Теләчев. Аллага шөкер, ул кадәресе булды. Инде менә зур эш белән йөрим, Бәхтияр, мәдрәсә ачып җибәрергә җыенам. Хәтереңдәме, әйтә идем: укып чыгып, хәзрәтнең фатихасы белән мәхәллә ала алсам, авылымның балаларын гыйлемле итәр идем, дип сөйләнә идем. Аллага шөкер, күпләрне хәреф танырга өйрәттем, инде мәдрәсә ачып та җибәрсәм, халыкка бер файдам тияр иде. Ләкин акчам җитешми дә, Зирекле хәзрәте бу эшемне хуплап бетерми. Мулла икәнлегеңне онытып, мужикка әйләнеп барасың, ди. Кара халык белән күп аралашсаң, үзең дә томана булырсың, ди. Кара халык та үзебезнең мөселман лабаса. Аңа да гыйлем кирәк. Аллаһы Тәгалә каршында барыбыз да тигезләр. Син нихәл соң, син, Бәхтияр? Бик зиһенле идең бит син.

Б ә х т и я р. Синнән уздырып булмады. Әнә хәзер дә кара халыкны агартырга йөрисең. Әй, хыялый бәндә! Дөньясы – төннексез кара мунча. Мичендә нәҗес яна, идәннәре пычрак. Ишеген җен-пәриләр каравыллый. Ә син ләүкә астына намазлык җәяргә җыенасың.

Т е л ә ч е в. Ни сөйлисең син, Бәхтияр?

Б ә х т и я р. Шуны сөйлим, авылыңа кайт та мужиклардан алган сәдакаңа шөкрана кылып яшә. Яисә минем мәдрәсәмдә хәлфә бул.

Т е л ә ч е в. Нинди мәдрәсә?

Б ә х т и я р. Җен-пәриләргә «Иман шарты» укытырга ниятлим. Тик әлегә хәлфәләр җитешми.

Т е л ә ч е в. Сүзләреңнең кинаясенә төшенмим.

Б ә х т и я р. Үзем дә төшенмим, Әбүбәкер мулла. Кулым зиһенемнән алда йөри. Мәгълүм булсын, мин син белгән шәкерт түгел.

Т е л ә ч е в. Ничек «түгел»?

– Балаларым ач, хатыным ач.

Б ә х т и я р. Бар, юлыңда бул, мулла. Дога кылганда минем исемне дә телгә ал. Тик ясин чыгарга ашыкма.

Т е л ә ч е в. Туктале, Бәхтияр...

Б ә х т и я р. Бәхтияр исеме бу якларда куркыныч, Әбүбәкер, кычкырып әйтмә. Зыяны үзеңә тияр.

Т е л ә ч е в. Йа Алла, аптыраштa калдырдың ласа.

Б ә х т и я р. Шулай, Әбүбәкер мулла, шәриктәш. Кеше берне уйлый, дөнья аны икенче төрле итә.

– Балаларым ач, хатыным ач.

Б ә х т и я р *(теләнче янына килеп, ачу белән)*. Син нәрсә һаман бер сүз тукылдыйсың?

– Ач булгач нишләтим.

Б ә х т и я р. Үз тамагың тукмы?

– Үзем дә ач. Каян алыйм?! Җирем юк, ясак сорыйлар.

Б ә х т и я р. Син бирмә.

– Бирмәс идең дә – кыйныйлар.

Б ә х т и я р. Кыйнатма. Сиңа берне суксалар, син икене сук.

– Әстәгъфирулла. *(Чигенеп утыра.)*

Б ә х т и я р *(Теләчевкә)*. Мулла, бармы тиенең, бир шуңа, тамагы тыгылсын.

Т е л ә ч е в. Алар базарда күп булыр, Бәхтияр, барысына да тиен җиткереп булмас.

Б ә х т и я р. Миңа әҗәткә бир, бер очрашканда түләрмен.

Т е л ә ч е в. Йа Алла, дөнья тулы хәерче. *(Чапан кесәсеннән акча алып теләнчегә бирә.)*

— Аллаһы Тәгалә вә...

Б ә х т и я р *(теләнчегә)*. Бар, хатыныңны, балаларыңны ашат. *(Теләнче киткәч.)* Үкенмә, Әбүбәкер мулла, син шулар өчен мәдрәсә ачарга җыенасың түгелме соң?

Т е л ә ч е в. Әллә нишләгәнсең син, Бәхтияр.

Б ә х т и я р. Үзең әйттең, дөньясы тулы хәерче, дидең. Сөенерлек ни сәбәп бар. Яңа патша чыккан, ди, ниндидер манифис язган, ди, ишеткәнең юкмы? Син мулла кеше, андый нәрсәләр сезгә тиз җитә.

Ә б ү б ә к е р. Юк сүз ул, юк сүз. Дөрес түгел, хак түгел. Кемдер язып тараткан. Ялган манифис.

Б ә х т и я р. Укыганың бармы?

Ә б ү б ә к е р. Авылга кемдер алып кайткан иде. Әби патшага каршы котырткан гөнаһлы сүзләр. Таларга, үтерергә кушкан.

Б ә х т и я р. Кемне таларга, кемне үтерергә?

В а с и л и й. Подайте, подайте, Христа ради, подайте!

Б ә х т и я р. Бир шуңарга бер тиен, колак төбендә акырмасын.

Т е л ә ч е в. Ни сөйлисең, Бәхтияр, урыска хәер бирергә...

Б ә х т и я р. Урысның тамагы юкмыни?

Т е л ә ч е в. Юк, юк. Үз мөселманыбызга бирдем, урыска урыс бирсен, гөнаһлы итмә.

Б ә х т и я р *(Василийга)*. Подожди. *(Як-ягына карана да үтеп баручы яхшы гына киенгән бер кешене күреп, аның каршысына чыга.)* Әссәламегаләйкем, бай.

— Вәгаләйкемәссәлам. Кем дип әйтим, танымыйм.

Б ә х т и я р. Күрешеп танышыйк. *(Байның кулын тотып кыса, бай кычкырып куя.)* Әкрен. Бусы баласы, мичтә ята анасы. Янчыгыңда күпме акча бар?

— Әстәгъфирулла...

Б ә х т и я р. «Әстәгъфирулла»сы соңыннан. Янчыгыңда күпме акча бар? Әллә телең йоттыңмы?

— Бер тиен юк.

Б ә х т и я р. Синдә булмагач, кемдә булсын! Чыгар!

Бай калтырана-калтырана янчык чыгарып Бәхтиярга суза. Бәхтияр янчыкны ачып акча ала да янчыкны байга кайтарып бирә.

Ике тиен генә алдым, җирдәш, үпкәләмә. Үземә түгел. Юлларың хәерле булсын, базарың уңсын. Тавышыңны базарда чыгарма, өеңә кайткач туйганчы кычкырырсың. Базарда кычкырсаң, өеңдә кычкыра алмассың. Сау бул.

Бай карана-карана чыгып китә. Бәхтияр Василий янына килеп тиенне бирә.

Бери!.. Уходи...

Василий акчаны алмый торгач.

Ал!

Василий акчаны алып, Бәхтиярга карый-карый, бер читкә авыша да Бәхтиярны күзәтә.

Теләчев *(тәмам аптырап төшкән)*. Нишләвең бу синең, Бәхтияр?! Йа Алла, йа Алла... *(Чигенә-чигенә чыгып китә.)*

Бәхтияр янына Василий килә.

Василий. Син кем?
Бәхтияр. Кемлегемдә ни эшең бар, юлыңда бул.

Шулчак мәйданга бер кешегә ияреп зур гына төркем чыга. Алдан килүченең кулында кәгазь.

— Укы, кычкырып укы.

Алдан килүче туктап кала.

— Җәмәгать, укый белмим. «Манифис» дип язылганын көчкә таныдым.
— Кем укый белә.
— Бир монда!

Төркем янына Бәхтияр килә. Алдан килүченең кулыннан кәгазьне тартып ала.

— Нишлисең?
Бәхтияр. Кычкырма. *(Кәгазьгә күз йөртеп чыга.)*
— Укый белсәң, кычкырып укы.
— Туктагыз инде, өелмәгез.
— Нәрсә өелмә, безнең дә ишетәсе килә. Укы!

Бәхтияр *(әкрен генә укый башлый)*. «Мин, – барча аксөякләр вә гади халыкның, төрле өлкәләр вә илләрдәге җан ияләренең ирекле хөкемдары...»

– Ишетелми.

– Кычкырып укы!

Бәхтияр *(кычкырыбрак укый)*. «...бөтен Русиянең бөек, гали императоры Пётр Фёдорович, – үземнең падишаһ хәзрәтләрем тарафыннан расланган, махсус указымнан тикшереп белмәк вә инанмак өчен, тугры вә ихлас күңел илә торып хезмәт итмәк вә сугышмак өчен үз кулымнан вә үз телемнән ошбу бөек язуны бирдем.

Минем тарафтан олуг императордан мәрхәмәт алыгыз: казаклар вә калмыклар вә татарлар. Кайсылары миңа, император галиҗәнаплары падишаһ Пётр Фёдоровичка гаепле булган булсалар, мин государь Пётр Фёдорович бөтен гаепләрегезне кичерәм. Газиз җаны белән тугрылыклы булган кешеләр өчен, әлбәттә, ярлыкагучы булырмын – җирегезне вә суыгызны, вә байлыгыгызны, вә утыгызны, вә кырыгызны, вә агачыгызны, вә дары, вә акча, вә кургашын, вә икмәк, вә тоз, вә башкалары белән».

Арттан тавыш. Эй ты, говори по-русски.

Бәхтияр. По-татарски написано.

Тавыш. Переводи.

Тавышлар. Укы әйдә, туктама. Урыс өчен чыккан манифест түгелдер ул. Урыс болай да начар яшәми.

– Каян беләсең?! Бөтенебезгә дә бер патша.

– Тик кенә торыгыз, укып бетерсен!

Бәхтияр *(манифестны укый)*. «Кемдер бояр кулында вә крестьян залим кулында җәбердә булса, бу көннән минем тарафтан азат ителә, шулай ук зинданда булучы ирекка чыгарыла.

Кемнәрдер буйсынудан баш тартсалар, каршылык күрсәтсәләр, вә бояр, вә йанарал, вә майур, вә капитан вә башкалары – барысының башы кисүле, малы талаулы булсын. Бервакытларны алар сезне ашадылар, таладылар, минем газиз колларымны ирексез вә ихтыярсыз иттеләр, хәзер үзләрен чабыгыз, иллә мәгәр, баш салганга кадәр. Әгәр миңа буйсынсалар, хилаф түгелдер. Мине танып, тугры юлда булып, сугышкан вә хезмәт иткән кешеләргә тимәссез. Кем дә кем баш тартса, аларны асачакмын, кисәчәкмен.

Инанмак өчен мин Пётр Фёдорович үз кулымны куйдым. Пётр Өченче дигән исем белән».

Т а в ы ш л а р. Күрсәт, кулын күрсәт.

Б ә х т и я р. Менә карагыз. *(Манифестны баш очына күтәреп күрсәтә.)*

Т а в ы ш л а р . Афәрин!.. Ходай кушсын!..

Шулвакыт таланган б а й белән П р и с т а в керәләр.

— Әнә ул, әнә шул талады.

П р и с т а в *(Бәхтияр янына килеп)*. Син!.. Карак! *(Бәхтиярга кизәнә.)*

Бәхтияр аның кулын эләктереп ала да үзенә суга. Пристав егыла. Халык гөжләп куя. Аптырап калган Пристав әкрен генә тора.

Тынлык.

Т а в ы ш л а р. Кач! Кач!..

Бәхтияр халык арасына кереп чума.

П р и с т а в. Тотыгыз! Җибәрмәгез! *(Бәхтияр артыннан бармакчы була.)*

Халык аның юлын бүлә.

## Өченче күренеш

Е к а т е р и н а II нең ял бүлмәсе. Екатерина ялгызы. Ул кемнедер көтә. П о т ё м к и н керә. Уң күзе кара ефәк тасма белән бәйләнгән.

Е к а т е р и н а *(Потёмкин каршына барып)*. Григорий Александрович!

П о т ё м к и н *(тез чүгеп)*. Мәрхәмәтле анабыз, сезнең чакыруыгыз буенча көне-төне кудым, һәм менә мин сезнең каршыгызда.

Е к а т е р и н а. Торыгыз, князь. *(Потёмкинны култыклап торгыза.)* Сезне күрүемә шатмын. Сез минем алда түгел, мин сезнең алда тезләнергә тиеш.

П о т ё м к и н. Ни сөйлисез, мәрхәмәтле императрица?!

Е к а т е р и н а. Нигә? Россия хакимәсенең алдыгызда тезләнеп торуын күрү бәхет түгелмени?

П о т ё м к и н. Сезнең чакыруыгызны ишеткәч, мин чиктән тыш шатландым, государыня, һәм борчылдым. Сезгә кирәк булуым мине шатландырды, ә инде сугыш кырыннан чакырып алуыгыз юкка гына түгелдер дип борчылдым.

Е к а т е р и н а. Сез ялгышмагансыз, генерал, сез миңа кирәк. Сез миңа бик кирәк. Григорий Александрович буларак та, генерал буларак та. Сезнең акылыгыз, сезнең көчегез миңа кирәк. Күрәсездер, сезнең кирәклегегез минем йөземә чыккан. Ябыктым, сулдым, ямьсезләндем.

П о т ё м к и н. Сез һәрвакыттагыча гүзәл!

Е к а т е р и н а. Алдашмагыз, Григорий Александрович. Үз хәлемне үзем беләм. Мин — хатын-кыз. Ә күпме хәсрәт кичерәм, никадәр көч түгәм, ничаклы авыр йөк күтәрәм. Төркия белән сугыш дәвам итә, княгина Тараканова дигән бер дама үзен Пётр I нең кызының кызы дип, мәрхүм Пётр I не абыем дип игълан итеп, Россия тәхетен даулый. Ул хакта бөтен Европа сөйли. Һәм шуларның барысы өстенә бу афәт. Россиянең көнчыгышында ниләр эшләнгәне турында сез хәбәрдардыр дип уйлыйм.

П о т ё м к и н. Әйе, государыня. Бу чыннан да афәт һәм бик куркыныч афәт.

Е к а т е р и н а. Ниндидер бер казак, самозванец... Коралы юк, өйрәтелгән армиясе юк. Генерал Карны тар-мар итеп ташлады, полковник Чернышевның 2200 кешелек армиясен туздырып, үзен асып куйды. Польшада тәртип урнаштырган генерал Бибиков та әлегә куанычлы хәбәр җибәргәне юк. Самозванец Пугачёвка, аның иярченнәренә каршы сугышкан армия белән теләсә кайсы дәүләтне яулап алып булыр иде.

П о т ё м к и н. Самозванецның көче нәрсәдә, государыня, шуны белергә кирәк.

Е к а т е р и н а. Бибиков яза. Пугачёв үзе куркыныч түгел, кара халыкның баш күтәрүе куркыныч, ди. Урал заводларында фетнәчеләр, Казан губернасы бунтчылар белән шыгрым тулы. Уралдан Нижний Новгородка чаклы кара халык айкала, князь. Казан губернаторы фон-Брандның язуына караганда, татарлардан җыйган сугышчылар йөзәрләп, меңәрләп самозванец ягына чыгалар. Отрядларга, командаларга оешып, безгә каршы сугышалар. Аларның башлыкларына Пугачёв полковник дәрәҗәсе бирә. Коточкыч хәл бу, князь. Бу Төркия белән

сугыштан куркынычрак. Киңәшчем булыгыз, Григорий Александрович. Мин сезгә ышанам. Әгәр сүзләрегез чын булса, сез миңа гүзәл дисез. Ул гүзәллек сезнең алда. Ул ярдәмгә мохтаҗ.

Потёмкин. Государыня...

Екатерина. Миңа Европа алдында оят. Европада бу хакта шаулыйлар, газеталарда язалар. Бездән көләләр.

Потёмкин. Тынычланыгыз, государыня.

Екатерина. Европа бу хәлне аңламый. Бу тарихта беренче мәртәбә. Бунтлар элек тә булган. Ләкин бу — акыл белән уйланган бунт. Самозванец үзен «патша» ди. Ул патшаның үз дәүләте бар. Ул дәүләтнең халкы аңа ышана, аңа табына. Чөнки ул патша кара халыкка безгә караганда күбрәк нәрсә вәгъдә итә. Пугачёв берәү — башлары меңәү. Пугачёв үзе Дон казагы, ә иярченнәре кемнәр? Йөз меңләгән руслар, татарлар, башкортлар һәм башка халыклар. Алар бердәм. Алар бердәм булып тәхет өстенә киләләр.

Потёмкин. Иртәгә үк хәрби коллегияне җыярга кирәк, государыня. Әгәр сез миңа ышанасыз икән...

Екатерина. Мин сезгә ышанам, Григорий. Каты куллы булуыгыз өчен мин сезне ачуланмам. Мин үзем, беләсез, табигатем белән нечкә күңелле... *(Кинәт Потёмкинга төбәлеп карап.)* Ышанмыйсызмы?

Потёмкин. Аллам сакласын!

Екатерина. Әмма мин мәрхәмәтсез дә була алам. Бу очракта сезнең дә мәрхәмәтсез булуыгызны телим. Минем империямдәге агачларның исәбе-хисабы юк. Кирәк икән — барысын да кисеп дар агачлары ясагыз. Һәрбер хәшәрәткә — унар дар агачы. Далаларда, юлларда дар агачларыннан урманнар калкып чыксын. Сезнең исемне ишеткән һәр хәшәрәтнең куркудан йөрәге ярылсын. Һәм сез бүләкнең зурысына лаек булырсыз.

Потёмкин. Мин шат, государыня.

Екатерина. Ә мин сезне сагындым, Григорий Александрович... Көньяк кояшы сезгә килешкән. Сез мәһабәт.

Потёмкин. Государыня...

Екатерина. Тыңлыйм, сөеклем.

Потёмкин. Чит илләрдән килгән илчеләргә әйтергә кирәк, газеталарында бунт турында азрак язсыннар. Үзләренең вазифаларын гына үтәсеннәр. Россия эшенә тыкшынмасыннар. Үзебезнең чиребезне үзебез дәваларбыз.

Е к а т е р и н а. Аңлаешсыз кешеләр сез руслар. Үзегезне бөек милләт дип атарга яратасыз. Ә шул «бөек милләт», вәхшиләр белән кулга-кул тотынып, ниндидер бер каракны патша дип танып, бунт чыгара. Бу үзе вәхшилек. Вәхшиләр белән вәхшиләр генә дус була ала. О, юу-ук! Россияне вәхшиләрдән арындырыр өчен мең еллар вакыт кирәк. Милли горурлыгыгызга кагылган булсам, гафу итегез, князь.

П о т ё м к и н. Сез хаклы, сез, әлбәттә, хаклы. Бу бунтның яманлыгы, куркыныч булуы да шунда. Ышаныгыз, государыня, Россияне фетнәчеләрдән арындыруны рус офицерлары озакка сузмаслар, вәхшиләр белән кылыч һәм камчы телендә сөйләшерләр.

## Дүртенче күренеш

Сәхнәдә — җәза отрядының дистәләгән солдаты. Сәхнәне аркылыга бүлеп тезелешеп басканнар да каршыларында яткан кешеләрне камчы белән суктыралар. Прожектор уты яктысында камчыларның уйнаганы гына күренә. Камчылар чыжлавыннан башка тавыш юк. Б е р о ф и ц е р кылычы белән дирижёрлык итә. Сәхнәгә ашыгып Т е л ә ч е в керә, офицер янына килә.

Т е л ә ч е в. Офицер хәзрәтләре!..

Офицер аны ишетми, кылыч белән селтәнүен дәвам итә.

Офицер хәзрәтләре!..

О ф и ц е р *(селтәнүен дәвам итеп, Теләчевкә карый)*. Ни әйтергә телисез, мулла?

Т е л ә ч е в. Ярамый болай, килешми. Мин сезгә әйттем, бу авылда фетнәчеләр юк. Гаепсез халыкны нигә кыерсытасыз?

О ф и ц е р. Кара халыкның бер мәкале бар, мулла: «Чүлмәк сатучы малайны чүлмәкне ватудан элек кыйнарга кирәк, чүлмәк ватылгач, кыйнауда ни мәгънә».

Т е л ә ч е в. Зинһар, туктатыгыз. Кыйналган кеше үзенең ни өчен кыйналуын белергә тиеш.

О ф и ц е р. Сез аларга аңлатырсыз.

Т е л ә ч е в. Сәбәпсезгә кыйналган кеше явызлана, усаллана.

Офицер. Читкәрәк китегез, мулла. Кылычка якын тормагыз. Тимер сузыла, беләсездер.

Теләчев *(читкәрәк китеп)*. Йа Хода! Нинди дөнья бу, нинди дөнья?! Нигә бу чаклы кансыз бу адәм балалары?! Шушы киң җиһанга нигә сыешмыйлар? Кыямәт көне җиткәнне дә көтмичә, җир өстендә мәхшәр ясыйлар.

Атлар чапкан, кычкырган тавышларны ишетеп туктап кала. Офицер да кылычын селтәүдән тукты
й, солдатлар кулында камчылар күтәрелгән килеш кала. Тавышлар якыная. Ут сүнә. Ут янганда, сәхнәдә Теләчевтән башка беркем юк. Ул әүвәлге хәлендә басып тора.

Бәхтияр керә.

Бәхтияр *(Теләчевне күреп)*. Әссәламегаләйкем, мулла.

Теләчев. Ә?

Бәхтияр. Әссәламегаләйкем, дим.

Теләчев. Кит!.. Кит!..

Бәхтияр. Онытып өлгердеңме? Мин бу, Канкай углы Бәхтияр! Кунак ит – килдем.

Теләчев. Монда сиңа хәтле дә кунаклар булды. Барысы да синең аркада.

Бәхтияр. Ничек минем аркада?

Теләчев. Исемең тирә-якка таралган, үзеңнең башкисәр булуың җитмәгән, кара халыкны котыртасың. Синең аркада халык кыйнала.

Бәхтияр. Ә син нигә кыйнатасың? Үз мәхәлләңнең халкы, яклар идең.

Теләчев. Кит, явыз! Кит, башкисәр!

Бәхтияр. Син алай йөрәкләнмә, Әбүбәкер мулла. Мин явыз да, башкисәр дә түгелмен. Без олуг импиратыр әгъзам падишаһ Питыр Фидрувич хәзрәтләренә хезмәт кылучы палкавай старшина Бәхтияр Канкай булабыз. Ышанмасаң, Питыр Фидрувич хәзрәтләренең үз кулыннан бирелгән указын күрә аласың. Анда язылган, палкавай старшина Бәхтияр Канкай диелгән, олуг импиратыр хәзрәтләренә баш салган төрле җенесле халайыкларны алып бергә йөрергә, диелгән.

Теләчев. Халык кемгә баш салырга белми. Бер илдә ике падишаһ, кайсына баш салсын.

Бәхтияр. Белә. Халыкның үз патшасы бар. Ул – олуг импиратыр Питыр Фидрувич хәзрәтләре. Халык телендә аның исеме генә.

Т е л ә ч е в. Без әлегә Әби патша Екатерина хәзрәтләрен падишаһ дип беләбез.

Б ә х т и я р. Әби патша — сатлык патша. Ул боярларга сатылган. Питыр Фидрувич — яхшы патша. Ул кара халыкны яклый. Хәер, син бит кара халык түгел, син аларны агартучы. Кара халыкны җиргә салып суктырганда, син сөенеп torгансың.

Т е л ә ч е в. Яла ягасың, нахак сөйлисең. Аллаһы Тәгалә, мәхәллә халкы шаһит...

Б ә х т и я р. Ишеттем: гаебең юк. Гаебең булса, мин синең белән сөйләшеп тормас идем. Сезнең йөзбашыгыз гаепле булгач, башсыз килеш агач ботагында эленеп тора.

Т е л ә ч е в. Сөйләп торма, кансызлыгың дан алган.

Б ә х т и я р. Кансызларга кансыз булачакмын. Импиратыр Питыр Фидрувич хәзрәтләренең әмерен җиренә җиткерү юлында кем дә кем каршылык кыла — аямаячакмын. Минем атаемны кызганмадылар, таладылар, җиреннән кудылар. Мин ул талаучының утарын яндырдым. Качтым, нужа чиктем, бәгырем катты, төннәрен юлбасарлыкта йөрдем. Инде көн килде. Үзебезнең падишабыз исән калган. Ул безгә җир-су бирә, түләүләрдән коткара.

Т е л ә ч е в. Кан тәме сеңгән җир, кан төсе иңгән су!.. Йа Хода, балаларыбыз канына җыйган ризыклары белән, эчкән сулары белән кеше каны керә. Алардан ни мәрхәмәт көтмәк кирәк.

Б ә х т и я р. Син белгәнне мин дә беләм, Әбүбәкер Теләч углы. Кылыч булган җирдә кан түгелә. Ләкин ул кан изге эш өчен түгелә. Сиңа да сүзем шул: изгелек кыласың килсә, миңа кушыл.

Т е л ә ч е в. Йа Хода!..

Б ә х т и я р. Мин беләм, синең күңелең мәгърифәт юлында. Кулларың кылыч түгел, әфтияк тотарга өйрәнгәннәр. Мин синең кулыңа кылыч бирмәм. Миңа синең гыйлемең кирәк. Писарем булырсың. Минем командада илле дистә кеше. Илле дистә бик кечкенә сан. Халыкны күбрәк җыйнау өчен аларга хәбәр салу кирәк. Син хәбәр язарсың. Халык хәбәр көтә. Импиратыр Питыр Фидрувич хәзрәтләренә рапорт язу эше дә синдә булыр. Татарлардан падишаһка килгән рапорт надан кул белән язылса, ояты безгә булыр. Муллалыгыңны куеп торырсың. Әгъзәм падишаһыбыз үз тәхетенә кире кайткач, ул

сиңа мәхәлләнең яхшысын бирер, мәдрәсәңне ачарга акчаны да кызганмас.

Теләчев. Йа Алла, ни сөйләвең...

Бәхтияр. Төрле халыклар безгә үзе теләп килә. Син дә үзең теләп риза булсаң, мең шөкер. Риза булмасаң, рәнҗемә. Баш салмаганнарны баш салдырганда төрле хәлләр була.

Теләчев. Гөнаһлы бәндә, гөнаһларың болай да күп, гөнаһ җыйма...

Бәхтияр. Мин бәндә түгел – кеше. Минем гөнаһларымны да син санама, җавабын үзем бирермен. Син ризамы, шуны әйт. Мин ике сөйләмим, Әбүбәкер мулла.

Ашыгып, Василий керә.

Василий. Полковник! Бер отряд килеп чыкты. Башлыклары сине эзли.

Бәхтияр. Монда алып кил. *(Василий чыгып киткәч.)*
Таныдыңмы үзен? Син тиенеңне кызганган теләнче. Мине эзләп табып, аягыма егылды. Сугышканда берүзе ун кешегә тора.

Абдулла Мостаев керә.

Мостаев. Миңа палковой старшина Бәхтияр Канкай углы кирәк.

Бәхтияр. Без булабыз.

Мостаев *(Бәхтиярны танып)*. Юлаучы?! Мосафир! Менә Ходаның рәхмәте! *(Күрешергә кулын суза.)*

Бәхтияр *(күрешкәч)*. Кичерә күр, туган, сине таный алмыйм.

Мостаев. Абдулла мин, Мостай углы. Хәтереңдәме? Урманда... Лашманчылар... Син безнең янга туктадың. Шәрифҗанның балтасын алдың.

Бәхтияр. Урман хәтеремдә, ләкин синең йөзне хәтерләмим, кичер. Йә? Бу якларга ничек килеп чыктың?

Мостаев. «Яңа патша» дигән сүз дөрес булды бит. Без дә яуга чыктык. Баштарак Мамадыш янында пулкувник Мәсәгут Гумәров командасында йөрдем. Ул җиңелгәч, качып котылдым. Лашманчыларны җыйдым да бу якларга юл тоттым. Патшабыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре Урал ягында, диделәр.

Бәхтияр. Отрядыңда ничә кеше?

Мостаев. Ике йөздән артык. Әгәр мәслихәт күрсәгез, сиңа кушылыр идек. Синең отрядыңның даны еракта йөри.

Бәхтияр. Ишетәсеңме, Әбүбәкер Теләч углы?!

### Бишенче күренеш

1774 елның язы. Бәхтияр отрядының лагере. Төн. Бәхтияр белән Теләчев керәләр. Аларга каршы Василий килә. Үтеп китә.

Бәхтияр. Бәчели! *(Василий туктагач.)* Биргән сәламеңне ишетмәдем.

Василий. Кичер, полковник, күрмәдем. Үземне үзем сүгеп бара идем.

Бәхтияр. Ни өчен?

Василий. Әлеге дә баягы үзең beләсең. Анасының җиде бабасын... Шушы башың белән кулыңны сузып теләнеп йөр, имеш, ә?

Бәхтияр. Үтте бит ул чакларың, хәзер теләнмисең.

Василий. Юк, үтмәде, өч ел теләнгәнемнең үчен алып бетермәдем әле. Питербургка җитеп, Катьканың бугазын чәйнисем бар.

Бәхтияр. Син сактамы, Бәчели?

Василий. Сакта. Мин сакта вакытта шикләнмә, полковник. Килеп карасыннар Катька караклары, аналарының җиде бабаларының әбиләрен... ат итеп җигәрмен... *(Китә.)*

Әбүбәкер. Йа Хода! Җанвар бит бу.

Бәхтияр. Җанвар, Әбүбәкер. Бүре! Сарык чакларын искә төшереп, сүгенеп йөри.

Әбүбәкер. Бүре... Бүреләргә каршы бүреләр. Адәм балалары кайда? *(Җыр ишетеп туктап кала.)*

Агачка сөялгән Ертык чикмәнле сугышчы җырлый.

Хура в™рман кашлать, каш-каш кашлать,
Тав™лл™ љил килсе тухсассан,
Хура хал™х шавлать, шав-шав шавлать
Ирекленсе кана пурнастан.

Бәхтияр белән Теләчев җырлаучы янына киләләр.

Б ә х т и я р. Җырың кайсы телдә, җирдәш?

Е р т ы к  ч и к м ә н. Үзебезнең телебездә, полковник.

Б ә х т и я р. Телең кайсы халыкныкы?

Е р т ы к  ч и к м ә н. Чуваш булабыз, полковник.

Б ә х т и я р. Җырыңның мәгънәсе ни?

Е р т ы к  ч и к м ә н. Урман турында. Давыл килсә, кара урман шаулый, ирек даулап, кара халык шаулый.

Б ә х т и я р. Кешеләр кайда дигән идең, Әбүбәкер. Күрдеңме? Моңнары, телләре бар. Төрле халыкларның телләре төрле, уйлары бер... Кара урман шаулый...

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә.
Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым пар каен...
Аерылмаек, дускаем.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Дус-иш кирәк, Әбүбәкер. Авылыңнан алып киткәнемә айдан ашты. Карышмыйча хезмәтеңне кылдың. Карадың, күрдең. Күңелеңне ачар чак җитте. Китәргәме, калыргамы ниятең? Китәм дисәң — тотмыйм. Әйт сүзеңне.

Т е л ә ч е в. Сүзем шул: син кыю кеше, Бәхтияр. Анысы яхшы. Әмма шунысы яман: син аяусыз, усал.

Б ә х т и я р. Бөтен кеше синең кебек юаш булса, яхшы булыр иде дә, усаллар күп. Усалларга усал мин.

Т е л ә ч е в. Кеше аяусыз булырга тиеш түгел. Кеше мәрхәмәтле булырга тиеш. Сиңа гозерем шул: мин янында булганда, усаллык кылма. Бүре булма. Күңелемнең катылануын теләмим.

Б ә х т и я р. Бу сүзләрең белән ни әйтергә уйладың? Минем белән калырга теләвеңне белдердеңме?

Т е л ә ч е в. Хәерле булсын... Син ниндидер указ язарга дигән идең.

Б ә х т и я р *(Теләчев каршына тезләнеп)*. Әбүбәкер! Димәк, син каласың?! Үзең теләп? Бу яхшылыгыңны мәңге онытмам. Син мине аңладың. Сүз бирәм, вәгъдә, синең күңелеңне рәнҗетмәм. *(Тиз генә сикереп торып.)* Ә указ мондый булачак. Әби патша каракларыннан арынган җирләрдәге сотникларга, старшиналарга! Үз хәлләре турында, шунда яшәүче халыкларның хәле турында безгә рапурт язып торсыннар. Әгәр дә мәгәр

халыкны кысу хакында яман хәбәр ишетсәк, бездән дә, падишаһымыздан да мәрхәмәт булмаячак.

Атлар чапкан тавыш ишетелә. Бер сугышчы керә.

Сугышчы. Пулкувник агай, гулувный атаман Белобарудов килә.

Ул арада Белобородов үзе дә керә. Бәхтияр аңа каршы бара.

Белобородов. Пикетларың оста куелган, полковник. Хәтта мин үзем сокландым. *(Теләчевкә күрсәтеп.)* Бу кем?

Бәхтияр. Яңа писер. Теләч углы Әбүбәкер.

Белобородов *(Теләчевкә)*. Бөек государьга турылыклы хезмәт итүегезне телим. *(Бәхтиярга.)* Мин ашыгам, Бәхтияр. Сине күреп китәр өчен юлымнан борылдым, командам юлын дәвам итә.

Бәхтияр. Юлыгыз кая?

Белобородов. Бөек государь Магнитныйда. Ул үзенә кушылырга боера.

Бәхтияр. Бөек падишаһны күрү бәхетенә ирешер көннәр килеп җиттемени, атаман?

Белобородов. Миңа шулай, сиңа иртәрәк. Минем уйлавымча, государьның юлы Казан өязе аркылы Мәскәүгә. Сиңа күбрәк гаскәр җыйнарга кирәк. Мин уйлыйм, әгәр государь Казанга юл алса, сиңа да гаскәрең белән Казан өязенә чыгу өчен әмер булыр. Бу якларда бригадир Салават Юлаев белән Канзафар Усаев кала. Ишеттеңме, Канзафар Усаев та бөек государьның боерыгы белән бригадир чины алды. Исән бул, Бәхтияр, озакламый күрешергә язсын.

Бәхтияр. Юлларың уң булсын, атаман. *(Белобородов чыгып киткәч.)* Ишеттеңме, Әбүбәкер. Бөек падишаһыбыз Казанга юл тота. Без дә Казан өязенә юл алабыз. Казанны күрәсе көннәребез бар, Казаннан – Мәскәү якын.

Ут сүнә.

### Алтынчы күренеш

Ханбикнең өе. Чылбыр белән богауланган Н у р с о л т а н. Ишек ачыла, анда М о р т а з а күренә.

М о р т а з а. Нурсолтан... *(Нурсолтан эндәшмәгәч, өй эченә үтә.)* Нурсолтан... Син мине ачуланма, Нурсолтан. Минем бер мыскал да гаебем юк. Мин дә синең хөкемеңдә, йортым-җирем, яклардай кешем юк. Син үзең дә гаепле, Бигеш өенә кайтмаска иде, Дүрттүбәдә качып ятарга иде.

Н у р с о л т а н. Яңа патшаның әтрәтләре бу якка килеп чыккач, Ханбик авылдан качкан, диделәр. Шуны ишеткәч кайттым.

М о р т а з а. Качкан иде шул. Отряд башлыгы Мухай Сәгыйтов эзләде, таба алмады. Отряд җиңелгәч, яңадан кайтты Ханбик. Бөтен ачуын миннән алды. Камчы белән суктырды.

Н у р с о л т а н. Икебезнең дә язмышыбыз кара. Син дә мәхлук, мин дә мескен. Нишлим, Ходай хатын-кыз итеп яраткан. Ир затыннан булсам, синең кебек мәхлук булмас идем.

М о р т а з а. Нишләр идең, Нурсолтан? Бигеш абый да ир кеше, ул да бернишли алмый.

Н у р с о л т а н. Алмый шул, бернишли алмый. Каһәр суккан язмыш.

М о р т а з а. Ул хәтле кайгырмыйк әле, Нурсолтан. Хәбәрләр йөри. «Питыр Фидрувич дигән патша җиңелгән» дигән сүз ялган, ди. Ул тагын яуга күтәрелгән. Әгерҗе, Тирсә якларына Бәхтияр атлы кеше килеп чыккан, падишаһның пулкувнигы, ди, янында зур гаскәре, ди.

Н у р с о л т а н. Кем дидең?

М о р т а з а. Бәхтияр дигән кеше, ди, байларны кыра, ди.

Н у р с о л т а н. Чын микән, дөрес микән, Мортаза?!

М о р т а з а. Дөрестер. Сизеп торам, Ханбик тагын качып китәргә җыена. Тарантасны майлап куярга кушып, ашыгып чыгып китте.

Н у р с о л т а н. Еракка китте микән?

М о р т а з а. Белмим. Нигә алай сорадың, Нурсолтан?

Н у р с о л т а н. Атларны җик, Мортаза. Ханбик кайтып өлгергәнче... Аңлыйсыңмы? Мине чылбырдан ычкындыр. Әгерҗе ерак түгел. Ишетәсеңме, Мортаза?! Әгерҗе ерак түгел! Син егет кеше бит, Мортаза!

Ашыгып, Ханбик керә.

Ханбик *(Мортазага)*. Син, йолкыш, монда нишлисең?

Мортаза *(Нурсолтанга ымлап)*. Аны саклыйм.

Ханбик. Бар, тиз атларны җик.

Мортаза. Кая барабыз?

Ханбик. Кушканны эшлә.

Мортаза чыгып киткәч, Нурсолтан янына килә, Нурсолтан читкә поса.

Ханбик. Кара-кара күзләрен, оятсыз. Нигә качмыйсың, ә, нигә качмыйсың? Җир тишегеннән эзләп табармын. Шунда бәйләнгән килеш, коры сөяккә калдырырмын, оятсыз. Гомердә булмаганны кыланып мине адәм рисваена калдыруың өчен җелегеңне корытырмын. *(Чылбырдан тартып, Нурсолтанны үзенә таба китерә.)*

Нурсолтан *(кычкырып)*. Бәхти-я-әр!..

Ханбик. Ни дисең?.. Кем дидең?.. Кем ул Бәхтияр? Сиңа аны кем әйтте? Әйт, юлбасар турында кемнән ишеттең?! *(Тиз генә ишеккә бара, ишекне ачып кычкыра.)* Мортаза!

Мортаза керә.

Син сөйләдеңме?

Мортаза. Нәрсәне, Ханбик агай?

Ханбик. Бәхтияр дигән исемне беләсеңме?

Мортаза. Кем дидең, Ханбик агай?

Ханбик. Бәхтияр.

Мортаза. Бәхтияр, Бәхтияр… Белмим, Ханбик агай.

Ханбик. Җиктеңме атларны?

Мортаза. Юк әле.

Ханбик. Тиз бул! *(Мортаза чыгып киткәч.)* Син, оятсыз, әле богаулы килеш әллә ниләр ишетеп… Күрсәтермен мин сиңа «Бәхтияр».

Чылбырны сәке йөзлегеннән суырып алып, Нурсолтанны ишеккә таба сөйри. Шулчак тышта атлар чапкан тавыш, шау-шу, Мортазаның кычкырганы ишетелә. Ханбик тәрәзәгә ташлана. Анда кемнедер танып алып, сәкедән шуып төшә, сәке астына үрмәли. Ишектән Бәхтияр, Мортаза керәләр.

Мортаза. Мин сине танып алдым, агай, мин сине шунда ук танып алдым. Минем гаебем юк.

Бәхтияр *(читкә поскан Нурсолтан янына килеп карап тора)*. Нурсолтанмы?

Нурсолтан эндәшми.

Син ич бу, Нурсолтан. Таныйсыңмы мине? Нигә дәшмисең? *(Мортазага.)* Аңа ни булган?

Мортаза. Белмим, агай, Ханбик...

Бәхтияр. Кайда Ханбик?

Мортаза. Белмим, агай. Монда калган иде. Чыкканы күренмәде. *(Эзләнә. Сәке астындагы Ханбикне күреп читкә сикерә.)* Ул анда.

Бәхтияр *(сәке астына карап)*. Ханбик, чык!

Ханбик сәке астыннан чыккач.

Әссәламегаләйкем, Ханбик. Язмыш безне тагын кавыштырды. Таныйсыңмы? *(Мортазага.)* Син монда тор. Әгәр дә мәгәр... Ботыңнан асып куярмын. *(Телсез калган Ханбикне сөйрәп чыгып китә.)*

Мортаза. Әллә танымадыңмы, Нурсолтан? Хәтерлисеңме, исеңдәме?

Нурсолтан бер сүз эндәшми. Тәрәзә янына бара, урамга карый. Ханбикнең ачы итеп кычкырганы ишетелә. Нурсолтан тагын өй почмагына сыена. Бәхтияр керә.

Мортаза. Агай, мине үзеңә ал.

Бәхтияр *(Мортазага игътибар итмичә, Нурсолтан янына бара)*. Курыкма, Нурсолтан. Ханбик юк. Таныдыңмы инде мине? *(Куеныннан Нурсолтан бүләк иткән мәрҗәнне чыгарып.)* Бу – синең бүләгең, Нурсолтан, нигә син дәшмисең? Курыкма, син иректә. Мин – импиратыр Питыр Фидрувичның пулкувнигы. Кара халыкны талаучыларга каршы яу чыктым.

Нурсолтан. Кулларымны ычкындыр.

Бәхтияр. *(Нурсолтанның кулларыннан чылбырны алып)*. Ханбик ничек эзләп тапты?

Нурсолтан. Фәрештәләр хәбәр иттеме сиңа? Мең рәхмәтләр сиңа, изге кеше.

Ут сүнә.

## Җиденче күренеш

Ханбикнең өе. Сәке өстендә — Бәхтияр Канкаев, Әбүбәкер Теләчев, Абдулла Мостаев.

Бәхтияр. Бер урында озак торып симерәбез түгелме, җәмәгать?

Мостаев. Гаскәр җыябыз, Бәхтияр. Бу — зур эш, падишаһымызга олуг армия кирәк.

Бәхтияр. Син, Абдулла, һәрчак миңа каршы сөйләргә яратасың. Падишаһымызның миңа атап язган указын мин дә укыдым, олуг армия җыю турындагы фикерне әйтеп падишаһка үзем рапорт язганымны онытмадым. Мин ул хакта әйтмим. Җыелган армия ни дә булса эшләргә тиеш. Әгәр армия эшсез торса, ул бозыла. Падишаһка кеше саны кирәкми, сугыша белә торган гаскәр кирәк. Сугышырга кеше сугышып кына өйрәнә. *(Теләчевкә.)* Тагын күпме кеше килде?

Теләчев *(кәгазьгә карап укый)*. Пашкино авылыннан 2 кеше, Иванайдан 6 кеше, Мишәбаштан 5, Шумбут аракы заводыннан 15, Катмыштан 11, Кече Шөннән…

Бәхтияр. Син миңа җәмгысын әйт.

Теләчев. Җәмгысы буладыр 380 кеше.

Бәхтияр. Аз.

Теләчев. Пудпулкувник Рахманкулдан хәбәр килеп җитмәде.

Бәхтияр. Рахманкулга әйтеп яз, хәбәрен җибәреп торсын, аның кайда, нишләп йөргәнен без белергә тиеш. Сиңа, Абдулла, кечкенә команда алып, Кама аръягына кичәргә кирәк булыр. Үзеңә отрядны шунда җыйнап, кичүләрне күзәтчелеккә алырсың. Падишамызның Казанга бара торган юлын ворлар отряды бүлмәсен.

Мостаев. Бүген үк китәргәме?

Бәхтияр. Бүген үк түгел, хәзер үк.

Мостаев. Баш өсте. *(Урыныннан тора.)*

Бәхтияр. Отрядыңда тәртип булырга тиеш, онытма.

Мостаев. Син мине рәнҗетәсең, Бәхтияр. Мин дә бит пудпулкувник чинын йөртәм.

Бәхтияр. Син — пудпулкувник. Мин — өлкән пудпулкувник… Йә, чиннар бүлешмик. Үпкәләмә. Уртак эштә үпкәләү булмаска тиеш. Кисәтүнең зыяны тимәс. Үзең белән иң ышанычлы кешеләреңне ал. Сау бул, Абдулла. Исәнлектә күрешергә язсын.

М о с т а е в. Амин. Атна-ун көннән хәбәр җибәрермен.

М о р т а з а килеп керә.

М о р т а з а. Бәхтияр агай...

Б ә х т и я р. Нәрсә, Мортаза, тагын рәхмәт укырга кердеңме?

М о р т а з а. Юк, Бәхтияр агай.

Б ә х т и я р. Мин сиңа Бәхтияр агай түгел, пулкувник хәзрәтләре. Төшендеңме?

М о р т а з а. Төшендем, Бәхтияр агай... Анда бер мулла килгән. Сине эзли.

Б ә х т и я р. Бар, әйт, керсен.

М о с т а е в. Мин китим.

Б ә х т и я р. Ашыкма, күрик, нинди мулла икән.

Чапан-чалмадан м у л л а керә.

М у л л а. Әссәламегаләйкем!

Б ә х т и я р. Вәгаләйкемәссәлам, хәзрәт. Түргә үтегез.

М у л л а *(түргә узып)*. Безгә Бәхтияр атлы кеше кирәк иде, шушы өйдә, диделәр.

Б ә х т и я р. Ул кеше без булабыз, хәзрәт. Ни йомыш?

М у л л а. Йомышны әйтер алдыннан утырып дога кылыйк. *(Дога кылганнан соң, Теләчев белән Мостаевка күрсәтеп.)* Боларны кемнәр дип белик?

Б ә х т и я р. Монысы — Әбүбәкер дигән кеше, монысының исеме — Абдулла.

М у л л а. Бәрәкалла. Мөселманнардыр, шәт. Юкса безгә әйткәннәр иде: Бәхтияр үз янында кяферләрне йөртә, дигәннәр иде.

Б ә х т и я р. Алары да күп, хәзрәт. Дөнья булгач бергә йөрергә туры килә. Без бит мәчеттә утырмыйбыз.

М у л л а. Шулаен шулайдыр да, зур гөнаһ бит.

Б ә х т и я р. Нишләмәк кирәк, хәзрәт. Мөселманнарга да, кяферләргә дә бер Алла. Гөнаһ булса, җавабын теге дөньяда бирербез. Йомышыгызны әйтегез, хәзрәт.

М у л л а. Кяфер сүзләр сөйләмә, кем, Бәхтияр. Ишетүемчә, үзең укымышлы кеше.

Б ә х т и я р. Аллага шөкер. Коръән-хафиз булмасак та, ипилек-тозлык беләбез. Йомышыгызны әйтмәдегез, хәзрәт. Әллә рәнҗеттеләрме үзегезне?

М у л л а. Рәнҗедем, Бәхтияр. Үзем өчен түгел, синең өчен, Бәхтияр улым. Үзең яшь кеше икән. Мөселман

балаларының адашып йөрүенә, кяфергә ияреп, динебезне мыскыл итеп йөрүегезгә рәнҗедем.

Бәхтияр. Төшендеребрәк сөйләгез, хәзрәт. Кяфер дигәнегез кем?

Мулла. Ырынбур ягыннан чыккан юлбасар.

Бәхтияр. Падишаһымыз әгъзам Питыр Фидрувич хәзрәтләрен әйтәсезме, хәзрәт?

Мулла. Падишаһ түгел ул — мәлгунь. Безнең падишаһымыз берәү генә. Ул — Әби патша, могтәбәр Екатерина хәзрәтләре.

Бәхтияр. Сез, хәзрәт, Питыр Фидрувич хәзрәтләре турында сөйләгәндә, яман сүзләр әйтмәгез.

Мулла. Ташлагыз бу эшегезне, балалар, кайтыгыз хак юлга. Иярмәгез кяфергә.

Мостаев. Хәзрәт, Әби патша да мөселман түгел бит.

Мулла. Мөселман булмаса да, аның күңеле туры. Безгә күпме яхшылыклар кылды. Чукындыруны бетерде.

Мостаев. Питыр Фидрувич хәзрәтләре дә безне чукындырмый.

Мулла. Син тик тор, кем... Без Бәхтияр белән сөйләшәбез. Син — томана адәм, дин эшен белмисең.

Бәхтияр. Хәзрәт, Абдулла Мостаев — укымышлы кеше. Ә писеребез Әбүбәкер — Коръән-хафиз.

Мулла. Йа Хода, Коръән-хафиз башың белән... Ахырзаман җитүедер. Муллаларыбыз азынып бетте.

Бәхтияр. Хәзрәт, токкан мәхәлләгез кай тирәдә?

Мулла. Әлхәмделиллаһ, Казанның үзендә... Бозылып эштән чыкканчы ташлагыз бу эшегезне, иярмәгез кяфергә.

Бәхтияр. «Кяфер» сүзен куегыз, хәзрәт. Казаннан кайчан чыктыгыз? Казан ни хәлдә?

Мулла. Алланың биргәненә шөкер. Бар мөселманнар Екатерина хәзрәтләре саулыгына изге догада. Сез генә адашып йөрисез.

Бәхтияр. Безнең ишетүебезчә, Казандагы кара халык падишаһымыз Питыр Фидрувич...

Мулла. Падишаһ түгел ул, түгел!

Бәхтияр. Тыңлап бетерегез, хәзрәт. Казандагы кара халык бөтен Русиянең хөкемдары рәхимле импиратыр әгъзам Питыр Фидрувич хәзрәтләренең килгәнен көтә.

Мулла. Хак сүз түгел, ялган сүз!

Бәхтияр. Без, мөселманнар, хәзрәтләр әйткән сүзгә

инаныргa күнеккәнбез. Хак сүзләр генә сөйлиләр дип беләбез.

Мулла. Бәрәкалла, хак сүз.

Бәхтияр. Сез, хәзрәт, Казаннан чыкканнан бирле күп кешеләрне күргәнсездер. Әлеге сүзләрегезне аларга сөйләгәнсездер дип ышаныйк.

Мулла. Сөйләдек. Безнең эшебез – халыкка туры юл күрсәтү.

Бәхтияр. Төшендек, хәзрәт. Инде безгә шуны төшендерегез, хәзрәт. Без монда адашып йөреп томаналанып беткәнбез. Әгәр дә без сез әйткән туры юлга кермәсәк, әгәр кыек юлда йөргәндә безне вафат кылсалар, теге дөньяда безне тәмуг көтәме?

Мулла. Мәңгелек тәмуг.

Бәхтияр. Әгәр дә кыек юлда йөрүчеләр сезне вафат кылсалар, теге дөньяда сезне җәннәт көтәме?

Мулла *(шикләнеп)*. Ниятең ни?

Бәхтияр. Ниятем шулдыр, хәзрәт, без, тәмугны үзебезгә калдырып, сезне җәннәткә кертәсебез килә. Сезгә шәһит китәргә туры килмәгәе.

Мулла. Уен-көлке заманы түгел.

Бәхтияр. Абдулла, йорт тирәсендәге башкорт, татарларны өйгә керт. *(Мостаев чыгып киткәч.)* Сез, хәзрәт, сөйлисе сүзләрегезне халыкка сөйләрсез. Аларның күңелләре саф, сезне күбрәк аңларлар.

Теләчев. Бәхтияр... Нишләргә җыенасыз?

Бәхтияр. Шымчылык – зур гөнаһ, Әбүбәкер.

Өйгә сугышчылар кереп тула.

Бәхтияр. Хәзрәт, сез башлыйсызмы, безме?.. Безгә башлау хәерлерәк булыр... Җәмәгать! Мөселманнар! Казан дигән каладан безгә олуг кунак рәхим итте. Без аны сәлам биреп каршы алдык, түребездән урын бирдек. Тыңладык. Безгә ул үзен мулла дип танытты. Соңра шунысы мәгълүм булды: мулла дигәнебез шымчы булып чыкты.

Мулла. Бинахак...

Бәхтияр. Ашыкма, хәзрәт. Без аның мулла икәненә ышанабыз. Тик шунысы яман: мулла кешенең вор боярларга сатылып шымчы булуы күңелләребезне тырный. Чын муллалар импиратыр әгъзам Питыр Фидрувич хәзрәтләре юлында йөриләр. Хәзрәт безне, кяфер-

ләргә ияргән бозык кешеләр, ди. Үзе ул кяферләрнең шымчысыдыр. Алар ризыгын җыядыр. Кара халыктан талап алынган ризыкны җыядыр. Сез, хәзрәт, бу халыкны юлдан язган, денсезләр, имансызлар, гөнаһка баткан кешеләр дип уйлыйсыздыр. Юк, алар саваплы эш эшләп йөриләр. Алар да сезнең кебек намаз укып намазлык өстендә утырырга телиләр. Тик әлегә аларның вакыты юк, намазлык алырга рәтләре юк, аларга тамак туйдырырга кирәк, боярларга налог түләргә акча табарга кирәк. Сез, хәзрәт, елына бер ай ураза тотасыз, бу халык елына унике ай ураза тота. Шулай булгач, кем гөнаһлы да кем саваплы? Дөрес сөйлимме, җәмәгать?!

Т а в ы ш л а р. Дөрес!.. Хак!.. Асып куярга кирәк аны!..

Б ә х т и я р. Нишләтергә кирәген үзегез беләсездер, җәмәгать. Бу вор боярлар шымчысын сезнең хөкемгә тапшырам.

М у л л а. Нишләвегез?! Ярамый!..

Б ә х т и я р. Алыгыз!

С у г ы ш ч ы л а р  м у л л а н ы сөйрәп алып чыгып китәләр. Тышта шау-шу.

Б ә х т и я р. Юлыңда бул, Абдулла.

М о с т а е в китә.

Т е л ә ч е в. Йа Хода...

Б ә х т и я р. Кызганасыңмы?

Т е л ә ч е в. Биргән вәгъдәңдә тормадың, Бәхтияр.

Б ә х т и я р. Күңелең рәнҗедеме?

Т е л ә ч е в. Хәерле булсын!

Б е р е н ч е  ч а п к ы н керә.

Б е р е н ч е  ч а п к ы н. Пулкувник Канкай углы Бәхтияр кайсыгыз буладыр?

Б ә х т и я р. Без булып торабыз. Кем син, әйтер сүзең ни?

Б е р е н ч е  ч а п к ы н. Шанлы император Пётр Фёдорович хәзрәтләренең чапкыны булабыз. Император Мамадышның уртасында утыра. Полковнигы Канкай углы Бәхтиярны отряды белән күрергә боерыгы бар.

Б ә х т и я р. Сүзеңне аңладык. Бүген юлга чыгарбыз. *(Чапкын чыгып киткәч.)* Әбүбәкер, йөзбашларына

әйт, җыена башласыннар. Патша хәзрәтләре каршына буш кул белән бару килешмәс, Ханбикнең малларын төясеннәр. *(Чыгып барган Теләчевне туктатып.)* Нурсолтанны үзем белән алырга уем бар.

Теләчев. Син каршы әйткәнне яратмыйсың.

Бәхтияр. Акыллы сүз булса тыңлыйм.

Теләчев. Ул – ир хатыны.

Бәхтияр. Калдырырга ихтыярымнан килми, Әбүбәкер. Гыйшкым акылымнан көчлерәк.

Теләчев. Кеше акылыннан көчле дөньяда берни юк.

Бәхтияр. Син гашыйк булып карамаган.

Теләчев. Минем ике балам үсә, Бәхтияр. Үзләрен һәм аларның аналарын көн саен төшемдә күрәм.

Мортаза керә.

Мортаза. Бәхтияр агай, Нурсолтан сине чакыра.

Бәхтияр. Кайда ул?

Мортаза. Келәттә.

Бәхтияр. Бирегә керсен. *(Мортаза чыгып киткәч.)* Син мине ачуланма, Әбүбәкер мулла. Нурсолтанны үземнән калдыра алмыйм.

Теләчев. Үзеңә кара. Мин сүземне әйттем. *(Чыгып китә.)*

Мортаза белән Нурсолтан керәләр.

Бәхтияр *(Мортазага)*. Кит! *(Нурсолтанга.)* Нурсолтан, асылзат. Мине чакыргансың. Әйтер сүзең күңелемә шифа булсын.

Нурсолтан. Син, Бәхтияр, Ханбик авызыннан мине үзеңә тоткын итәр өчен тартып алдыңмы?

Бәхтияр. Тоткын итәр өчен түгел, хатын итәр өчен.

Нурсолтан. Хатынны сак астында тотмыйлар.

Бәхтияр. Сак астында түгел, Нурсолтан. Үз иркендә.

Нурсолтан. Алай булгач, нигә өемә җибәрмисең?

Бәхтияр. Синең өең юк. Падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре Мамадышта. Хәзер шунда китәбез, никахымызга аның фатихасын сорарга җыенам.

Нурсолтан. Йа Тәңрем! Егерме ике яшемдә кемгә генә хатын итмәделәр. Мондый яман язмыш нигә минем башыма җибәрелгән! Минем никахлы ирем бар, Бәхтияр!

Б ә х т и я р. Хатынын саткан ир…

Н у р с о л т а н. Әйтмә алай дип, язмыш…

Б ә х т и я р. Нинди язмыш? Бүтәннәр үзләрен, хатыннарын, балаларын рәнҗеткәннәргә каршы яу чыкканда, юкәче Бигеш юкә каезлый.

Н у р с о л т а н. Бөтен кешегә дә Ходай Тәгалә синеке кебек батыр йөрәк бирмәгән. Бигеш — эшләр өчен яратылган кеше.

Б ә х т и я р. Эшләп ни кылды?

Н у р с о л т а н. Анысында аның гаебе юк.

Б ә х т и я р. Сынау килгәндә ир була алмаган мәхлукның гаебе булмыймы? Күреп тордың, мин аның белән сөйләштем, ишетеп тордың, ул сине талак кылды.

Н у р с о л т а н. Куркуга төшкән кеше ни әйтмәс.

Б ә х т и я р. Мин аны куркытмадым.

Н у р с о л т а н. Сине пулкауник дип йөртәләр. Ул сүздән кем курыкмас.

Б ә х т и я р. Янә әйтәм, Нурсолтан, куркак иргә син хәрәм.

Н у р с о л т а н. Җибәр мине, Бәхтияр. Миңа бер яхшылык кылдың, яхшылыгың яманлыкка әйләнмәсен.

Б ә х т и я р. Нурсолтан, минем йөрәгем тимер, сине күргәч эреде, мин — вор боярларның башын кискән адәм, синең каршыда ялынып торам.

Н у р с о л т а н. Шуңа күрә мин сиңа исемең белән Бәхтияр дип эндәшәм, сине ничә айлар хәтеремдә сакладым.

Б ә х т и я р *(кычкырып)*. Шулай булгач ни кирәк, тискәре җан?!

Н у р с о л т а н. Кычкырма, Бәхтияр. Кычкырып куркытасың, куркытып биздерәсең. Күңеле бизгән, тәне тартмаган хатын сиңа нигә кирәк?

Б ә х т и я р. Тәнең тартмаса да, юкәче Бигешне сөйлисең.

Н у р с о л т а н. Ул — минем никахлы ирем.

Б ә х т и я р. Һаман бер сүзне тукыйсың. Ул «талак» диде, без никахлы булырбыз.

Н у р с о л т а н. Син дә бер сүзне тукыйсың, Бәхтияр.

Б ә х т и я р. Болай булгач, Ханбикне мин юкка астырганмын. Интек идең гомереӊ буе шуның белән.

Н у р с о л т а н. Бу сүзләрең йөрәгемне рәнҗетте, Бәхтияр.

Бәхтияр. Бар, кит!

Нурсолтан. Өемә җибәрәсеңме?

Бәхтияр. Күземә күренмә!

Нурсолтан. Хода юлларыңны уң итсен, Бәхтияр. Хуш, батыр ир. Рәнҗемә. Синең белән болай итеп сөйләшкәнмен икән, ул сине үз иткәнгә. Мине рәнҗетмәячәгеңә күңелем ышанганга. Әгәр беренче булып син очраган булсаң, мин Ходайга рәхмәт укып туймас идем. Йөрер сукмакларыңны чәчем белән себерер идем. Хуш. *(Китә башлый.)*

Бәхтияр. Тукта!

Нурсолтан. Йа Алла!..

Бәхтияр. Мортаза! *(Мортаза кергәч.)* Бу хатынны илтеп куй юкәче Бигешнең өенә.

Нурсолтан. Безнең авыл моннан ерак түгел, Бәхтияр.

Бәхтияр *(Мортазага)*. Илтеп куй! Әйт юкәче Бигешкә, хатыныңның Бәхтияр абзый белән кылган гөнаһысы юк, диген. Янә өстәп шуны әйт, әгәр бу хатынга тел тидерсә, рәнҗетсә, өенә үзем барып, үзе каезлаган юкәсе белән усак агачына асып куярмын. Юлыңда бул. Без – Мамадышта. Куып җит.

Мортаза белән Нурсолтан китә башлыйлар.

Бәхтияр. Туктагыз! *(Тегеләр туктагач, куеныннан мәрҗәнне алып Нурсолтанга ыргыта.)* Ал! Ул минем йөрәгемне көйдерә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хор. Юллар бергә килгәнгә,
Ике батыр дус булган,
«Уң кулым син» дигәнгә,
Күңелләре хуш булган,
Пугачауга кушылган
Канкай углы Бәхтияр.

## Сигезенче күренеш

Мамадышта — Пугачёвның штабы урнашкан өйнең болдыры. Болдырда Пугачёв, Кинҗә Арсланов, Иван Белобородов басып торалар.

Кинҗә. Карашыңыз уйчан, галиҗәнап, сезне нидер борчый, ахры?

Пугачёв. Безнең уйны син беләсең, Кинҗә.

Кинҗә. Алда — Мәскәү...

Пугачёв. Мәскәүгә юл Казан аркылы. *(Белобородовка.)* Атаман, син ни әйтәсең?

Белобородов. Казан — каты чикләвек.

Пугачёв. Ватылмаган чикләвек юк...

Белобородов. Шулай да... Чүлмәк Казанга бәрелеп чыдармы?

Пугачёв. Синең башың чүлмәк булса, безнең башыбыз чүлмәк түгел, атаман. Исеңдә тот һәм рәнҗемә. Безнең егерме меңлек гаскәребез бар.

Кинҗә. Һәм ул сәгать саен арта тора.

Белобородов. Егерме мең күп, әлбәттә. Ләкин ничәсе сугыш һөнәрен белә? Бәлки, бераз сабыр итәргәдер?

Пугачёв. Син аларны сугыш һөнәренә өйрәтмәкче буласыңмы, атаман? Гомерең җитәрме? Син өйрәткәнне этләр көтеп торырлармы? Михельсон эт үкчәгә басып килә.

Белобородов. Ни боерасыз?

Пугачёв. Бүген хәрби коллегияне җыярга кирәк, Кинҗә. Фикерегез анык булсын. Әлегә безнең сүзебез шул: озак көтәргә ярамый. Казанда безне көтәләр, үзегез шаһит — аннан кешеләр килә. Салаваттан ни хәбәр бар?

Кинҗә. Әлегә юк, галиҗәнап. Башкорт җирендә яраларын дәвалыйдыр.

Пугачёв. Яз үзенә — гаскәр җыйсын, монда килергә ашыкмасын. Канзафарга да шулай языгыз. Алар анда да бик кирәк. *(Белобородовка.)* Полковник Бәхтияр Канкай углын син бик мактадың, атаман, чынмы, әллә безнең күңелебезне күрер өченме?

Белобородов. Сүземдә шигегез булса, Бәхтиярның эшләгән эшләрен үзегез беләсез.

Артта тавыш.

Пугачёв. Ни бар анда?

Кинҗә *(баскычтан төшеп карап)*. Ниндәйдер гаскәр килә.

Белобородов (баскычтан төшеп карап). Ат өстендә – Бәхтияр Канкаев. Ни боерасыз, галиҗәнап?

Пугачёв. Каршы ал, атаман, монда алып кил. Кинҗә, әйт, утырырга урын әзерләсеннәр. Монда, болдырда.

Белобородов китә. Кинҗә өйгә керә. Өйдән тәхет алып чыгалар, аңа келәм җәяләр. Пугачёв утыра. Белобородов белән Бәхтияр, Теләчев керәләр. Теләчев арттарак кала. Бәхтияр, бер-ике баскыч өскә менеп, Пугачёв каршына тезләнә.

Пугачёв. Тор, полковник, хуш килдең.

Бәхтияр *(башын күтәреп)*. Бөек падишаһымыз, бар гаскәремез илә сезнең мәрхәмәтегезгә өмет баглап каршыңызга тезләндек. Сезне атамыз дип таныган хәлдә, сезгә озын вә озын гомерләр теләдек.

Пугачёв. Ярлыкадым. Гаскәреңдә корал күпме?

Бәхтияр. Корал аз, падишаһ, кешеләр меңнән артык. Төрле халайыклардан җыелган. Янә тагы да пудпулкувник Абдулла Мостай углы Кама аръягында тора, Рахманкул Дусли углын Шумбут аракы заводына җибәрдек.

Пугачёв. Тупларың ничә?

Бәхтияр. Өч чуен, бер лафетсыз бакыр туп.

Пугачёв. Төшендек. Бер сорау, полковник Бәхтияр Канкай углы. Син безне государь дип таныдың, аның аягына башыңны ордың, нигә баш киемеңне салмадың? Безнең аңлавыбызча, бу – государьны хөрмәтләмәү, аңа баш бирмәү.

Бәхтияр. Кичерегез, бөек падишаһымыз, татарның кәләпүше башыннан башы белән бергә генә салына.

Пугачёв. Ни өчен?

Бәхтияр. Безнең башлар кырулы, бөек галиҗәнап, кәләпүшне салсак, суык тия.

Пугачёв көлә. Аңа бүтәннәр кушыла.

Пугачёв. Җавабың тапкыр, полковник, кичерәбез. Кинҗә, Канкай углына түрдән урын күрсәт.

Кинҗә *(Бәхтияр янына килеп)*. Әссәламегаләйкем,

Бәхтияр туган! Без Кинҗә атлы буламыз. Башкорт иленнән. Ишеткәнеңез бардыр.

Б ә х т и я р. Вәгаләйкемәссәлам, мулла. Сезне күрү безгә зур куаныч. Исемегез – халык арасында. Гомерегез озын булсын.

К и н җ ә. Амин. Әйдәңез, рәхим итеңез. *(Бәхтиярны култыклап, өскә алып менә, Пугачёвның уң ягына бастыра.)*

П у г а ч ё в. Атаман Белобородов сине күккә чөеп мактый, Канкай углы. Һәм без ышанабыз. Бүгенге көндә татарлар минем гаскәремнең яртысы. Уннан артык полковнигым татар. Алар минем арка терәгем. Киләчәктә дә шулай булыр дип уйлыйбыз. Без сезне өлкән полковник иттек, указны алдыгызмы?

Б ә х т и я р. Шатлыгымыз эчкә сыймый, бөек падишаһ. Сезнең акылга манчылган указларыгыз күк йөзендәге ай булып безнең юлларымызны яктырта.

Пугачёв, башын күтәреп, Бәхтиярга карап ала, һәм икесенең дә күзләре очраша. Бәхтияр чигенеп куя.

П у г а ч ё в. Нәрсәдәндер өректең, ахры, полковник?

Б ә х т и я р. Күзләрем...

П у г а ч ё в *(аны бүлдереп)*. Күзләреңнең Казан ягына төбәлгәнен әйтмәсәң дә беләбез, Канкай углы. Әмма Казанны алу мәҗлесендә күңел ачарга әлегә сиңа насыйп булмаячак. Син гаскәреңне безгә тапшырасың да үзең монда каласың. Яңадан гаскәр җыясың.

Б ә х т и я р. Колагым сүзләрегезне тыңлый, күзләрем...

П у г а ч ё в *(Кинҗә белән Белобородовка)*. Кинҗә, атаман! Полковникның үзенә генә әйтәсе сүзем бар.

К и н җ ә һәм Б е л о б о р о д о в өйгә кереп китәләр.

П у г а ч ё в *(Теләчевкә күрсәтеп)*. Кемең?

Б ә х т и я р. Писер.

П у г а ч ё в. Китсен.

Б ә х т и я р *(Теләчевкә)*. Әбүбәкер, отряд янына бар. Кешеләрне ашату хәстәрен күр.

Т е л ә ч е в китә.

П у г а ч ё в. Тыңлыйм, полковник. Күзләрең ни күрә?

Б ә х т и я р. Кичерегез, шигем бар.

П у г а ч ё в. Телең «государь» дип әйтергә онытты, полковник. Әйт шигеңне.

Б ә х т и я р. Без бөек падишаһымыз дип баш орган кешенең йөзе безгә таныш.

П у г а ч ё в. Кем ул?

Б ә х т и я р. Минем фигылем, табигатем алдашуларны кичерә алмый. Күңелендә шик-шөбһә булган кешенең йөрәгенә курку оялый.

П у г а ч ё в. Государьның полковнигы күңелендә шик йөртә икән, государь кылычка тотына.

Б ә х т и я р. Мин сезнең хөкемдә. Ләкин...

П у г а ч ё в. Ләкин, полковник, миңа синең гомереӊ кирәк. Бөркетләр дөньяда болай да аз. Нигә аларның башын кисәргә? Әгәр инде бөркет дигәнебез карга булса, һәм ул карга булып карылдаса... Максатың ни, полковник? Ни өчен яуга чыктың?! Әгәр государьны яклап кына булса, государьны ни өчен яклаганың аңламасаң, государь сиңа тиешле хөрмәтен күрсәтер, тик беркайчан да Канкай углы Бәхтияр дип әйтмәс.

Б ә х т и я р. Зиһенем чуалды.

П у г а ч ё в. Чуалган зиһенеңне чишәр өчен мин сиңа вакыт бирәм, полковник. Ләкин без вакытның кадерен белергә өйрәнгән. *(Кискен борылып, өйгә кереп китә.)*

Б ә х т и я р *(ялгызы)*. Бөек падишаһымыз Питыр Фидрувич... «Максатың ни? Ни өчен яуга чыктың?.. Бөтен Россиядә мескен кара халык рәнҗетелә, талана... Чиге булырга тиеш... Минем тарафтан мәрхәмәт алыгыз: казаклар, вә калмыклар, вә татарлар... Максатың ни? Җирегезне вә суыгызны ярлыкагучы булырмын...»

К и н җ ә керә.

К и н җ ә. Падишаһ хәзрәтләре полковник Канкай углын уйландырырлык сүз әйткәнме?

Б ә х т и я р. Уйлану адәм баласына хас нәрсәдер, мулла.

К и н җ ә. Әлбәттә, әлбәттә.

Б ә х т и я р. Ишетүебезчә, сез — падишаһымызның уң кулы. Әгәр безгә дә белергә яраса, әйтегезче, мулла, максатыгыз ни? Ни өчен яуга күтәрелдегез?

К и н җ ә. Патша хәзрәтләренең уң кулы берәү генә түгел. Ишеткәнсеңдер, татарлардан Идыр Мәхмүтев, Садыйк Сеитов та Югары совет әгъзалары. Без янә Канкай углы Бәхтиярны да падишаһымызның уң кулы дип таныйбыз. Бу сөальләргә җавапны ул үзе дә белә дип фараз кылаек.

Б ә х т и я р. Без падишаһымыз манифесында күңелләргә хуш сүзләрне укыдык.

К и н җ ә. Күңелегезгә хуш сүзләр нидән гыйбарәт?

Б ә х т и я р. Җир, су...

К и н җ ә. Безнең дә максатымыз шулдыр, Канкай углы. Җир, су... Әмма ләкин оныттыңыз, адәм баласына иң кирәге – ирек. Ирек!.. Җан ирege, рух ирege. Җанга ирек булмаса, һай авыр, Бәхтияр туганым. Минем җирем дә, суым да бар иде, тамагым тук иде. Рухыма ирек җитми иде, читлектәге кош кеби иде. Әгәр дә син бүтәннәр кеби үк Адәм илә Хәваның газиз баласы булып та, сиңа үги балага караган кебек кимсетеп карасалар, кыерсытсалар, телеңне киссәләр, динеңне-иманыңны таптасалар, тамак хәсрәте онытыла, туганым.

М о р т а з а керә, Бәхтиярны күреп, йөгереп, аның янына килә.

М о р т а з а. Бәхтияр агай, килеп җиттем.

Б ә х т и я р. Минем янда кеше бар, сәламең бир, туң авыз.

М о р т а з а *(Кинҗәгә)*. Әссәламегаләйкем, агай... *(Бәхтиярга.)* Нурсолтан да килде.

Б ә х т и я р. Кичерә күрегез, мулла... *(Мортазаны читкәрәк алып китеп.)* Кайда ул?

М о р т а з а. Теләч абзый янында калдырдым.

Б ә х т и я р. Сөйлә.

М о р т а з а. Авылга кайттык. Юкәче Бигеш өенә кердек. Мин әйттем, хатыныңны китердем, дидем. Син әйткәннәрне әйттем, «асып куям» дип әйтте Бәхтияр абзыкаем дигәч, коты ботына төште, Нурсолтанга күрсәтте: ул минем хатыным түгел, диде, «талак» дип әйттем, диде, өемнән чыгып кит, дип, Нурсолтанны куды, Нурсолтан белән без чыгып киттек, Нурсолтан елады, мин сөендем, әйдә Бәхтияр абзыкаем янына, дидем, бармыйм, диде, барасың, дидем, бармыйм, диде, барасың, дидем. Ул да мине куып җибәрер, ди. Бәхтияр абзыкаем куып җибәрми, дидем, ул синең өчен үлә, дидем. Кулыннан тоттым да алып килдем, үзе килде, карышмады. Өеннән чыгып киткәндә юкәче Бигешкә яман сүзләр әйтте Нурсолтан, өеннән чыккач елады.

Б ә х т и я р. Анысын сөйләдең.

М о р т а з а. Юлда мин аңа мәзәк сөйләдем, көлде,

валлаһи дип әйтәм, көлде. Патша хәзрәтләрен күрдеңме, Бәхтияр агай?

Б ә х т и я р. Син, мокыт, һәмиш миңа агай дисең.

М о р т а з а. Пулкувник хәзрәтләре, күрдеңме? Миңа да күрергә насыйп булыр микән?

Б ә х т и я р. Бар, Нурсолтан янында бул. *(Мортаза чыгып чапкач, Кинҗә Арсланов янына килә.)* Кичерегез, мулла, сүзегезне бүлдек.

К и н җ ә. Иртәгә чаклы сөйләшергә вакыт булыр дип уйлаек. Нурсолтанны кем дип беләек?

Б ә х т и я р. Минем кәләшем. Никахлашырга падишаһымызның фатихасын сорарга уем.

К и н җ ә. Ай-һай, Бәхтияр. Яу вакытында андый эшләрне падишаһ өнәп бетерер микән.

Б ә х т и я р. Аягыгызга баш орам, мулла. Олуг падишаһымыз сезнең сүзләрегезгә колак салыр. Минем өчен сорагыз.

Өйдән П у г а ч ё в чыга. Бәхтияр Пугачёвка карап тора да, баш киемен салып, Пугачёв каршына тезләнә.

Б ә х т и я р. Әгъзам падишаһымыз бөек галиҗәнап...

П у г а ч ё в. Тор, полковник. Кинҗә, Канкай углы Бәхтиярның тамагы тукмы?

К и н җ ә. Галиҗәнап, Канкай углының сездән түбәнчелек илә сорый торган гозерен сезгә җиткерергә рөхсәт итегез. Әгәр фатихагызны бирсәгез, аның никахлашуга уе бар.

П у г а ч ё в. Кем белән? *(Бәхтиярга.)* Кайда кәләшең, полковник?

Б ә х т и я р. Командам янында.

П у г а ч ё в. Болай уйлыйк, Кинҗә. Әгәр дә кәләш матурлыгы белән Канкай углының батырлыгына тиң булса, фатихабызны бирербез. Государьны туйга чакырырга онытмасалар, туй итәрбез. Алып кил кәләшеңне, полковник.

Ут сүнә.

### Тугызынчы күренеш

Сигезенче күренештәге болдыр. Тәхетендә Пугачёв утыра. Янында Кинҗә Арсланов, Белобородов, Югары совет, Хәрби коллегия членнары, Бәхтияр Канкаев һәм Нурсолтан. Факеллар яна. Туйның кызган чагы. Менә бер төркем сугышчылар — руслар — болдыр янына килеп кияү белән килен хөрмәтенә җыр башлыйлар.

Вьётся, вьётся, стелется,
Вьётся, вьётся, стелется
По лугам трава шелковая,
По лугам трава шелковая.
Мил со милою сходятся,
Мил со милою сходятся.
Целуются, милуются,
Целуются, милуются...

Руслар җырлап үтәләр, аларны марилар алыштыра.

Суан толеш — соет толеш,
Путат пеле шыл кулеш;
Путат пеле шылым шолташ
Артанат пеле пу кулеш,
Артанат пеле пу погашыже.
Ончылно шогышо удер кулеш,
Ончылно шогышо удержо — лай
Сагус марийым йодалеш...

Мариларны чувашлар алыштыра.

Туй, туй, туй теше,
Туй, туй, туй теше.
Пурнас йытта ветерсе,
Парапан туса килтемер.
Пат-пат, параппан!
Пат-пат, параппан!
Сок парапаан мен калать.
Вуник туя кайрам, тет,
Кун пеккине курман, тет.
Ой, йой, ой-йорах...

Болдыр янына татарлар килә.

Ужикәрәм, бужикәрәм,
Болыт тамырланадыр;
Кыз куенына кергән чакта,
Егет сабырланадыр.
Келәтеңнән башкынасын
Болыт белән япканнар;
Ни гаебеңне тапканнар —
Кыз янына япканнар...

Пугачёв. Шигаев! Әйт, тагын бер мичкәне ватсыннар.

Белобородов. Галиҗәнап, таң беленүгә, поход чыгабыз.

Пугачёв. Атаман! Халык күңел ача, ачсын. Казанга җиткәнче айнырлар. Шигаев, әйт!

Шигаев *(алга чыгып)*. Тыңлагыз! Бөек государь сезгә тагын бер мичкә бал бүләк итә... Тәгәрәтегез мичкәне!

Шау-шу башлана. Берничә кеше мичкә тәгәрәтеп чыгара. Халык мичкә артыннан ияреп чыгып китә.

Пугачёв. Полковник Бәхтияр Канкай углы, туең үзеңә ошыймы?

Бәхтияр. Мәрхәмәтле падишаһымыз...

Пугачёв. Рәхмәтең кирәкми. Тик шуны бел: Канкай углы, мондый бәхет минем һәр полковнигыма эләкми. Шуны да бел: иртәгә хатыныңны авылга илтеп куй. Кайтканыңны шунда көтсен. Минем полковникларым сугышка хатыннары белән йөрмиләр. Инде тагын хатыныңның йөзен күрдек, полковник, тавышын ишетәсебез килә.

Бәхтияр. Әгъзам падишаһымыз, ул ояла.

Пугачёв. Кемнән?

Бәхтияр. Бөек падишаһ алдында кайсы татар хатыны авызын ачарга базган.

Пугачёв. Без татар хатыннарын беләбез, Канкай углы. Татар авылы Каргалыда безне хатын-кызлар баш иеп каршыладылар, җырлап-биеп озаттылар.

Бәхтияр. Сезнең сүзегез, галиҗәнап, безнең өчен әмер. Падишаһымызның әмере үтәлергә тиеш. Нурсолтан!

Нурсолтан Бәхтиярның колагына нидер әйтә.

Б ә х т и я р. Кичерегез, падишаһ, мулла барында хатын-кызга җырлау тыела, гөнаһ.

П у г а ч ё в. Кем ул мулла? *(Кинҗәгә карап.)* Синме, Кинҗә? Без сине башкортларның старшинасы дип белә идек, соңра полковник чины бирдек.

К и н җ ә. Укымышлы кешеләргә мөселманнар «мулла» дип эндәшәләр, галиҗәнап. Курыкма, кызым, без син уйлаган мулла түгелбез.

П у г а ч ё в. Шулай да син өйгә кереп тор, Кинҗә.

К и н җ ә. Баш өсте. *(Өйгә кереп китә.)*

П у г а ч ё в. Хатыныңның теләген үтәдек, полковник. Инде безнең теләгебез үтәлсен.

Нурсолтан Бәхтиярның колагына нидер пышылдый, ике арада тавышсыз бәхәс.

Б ә х т и я р. Кичерегез, бөек падишаһ, аңа минем сүзем үтми, ул җырларга теләми.

Пугачёв кинәт сикереп тора. Барысы да нидер көтеп үрә каталар, тынып калалар. Пугачёв Нурсолтан каршына килә, Бәхтияр араларына кереп өлгерә.

П у г а ч ё в *(усал)*. Канкай углы! Патша әмереннән йөз чөерергә батырчылык кылган хатын-кызлар дөньяга сирәк туа. *(Тиз генә өйгә кереп китә дә, аннан затлы киемнәр күтәреп чыгып, Нурсолтан алдына ташлый.)* Алсын, бездән бүләк. Әгәр болар аз икән, син сугышта затлырак бүләкләр табарсың һәм безнең исемебездән хатыныңа бүләк итәрсең.

Кинәт артта тавыш куба, ишегалдына х а л ы к т ө р к е м е кереп тула. Алда и к е к а з а к бер симез адәмне сөйрәп алып киләләр. Болдыр янына җиткәч, әлеге адәмне җиргә ташлыйлар.

П у г а ч ё в. Кем?!

Б е р е н ч е к а з а к. Без пикетта идек. Моны качып барганда тоттык.

П у г а ч ё в. Кем?

Б е р е н ч е к а з а к. Кем икәнен әйтмәде. Җиккән атлары яхшы токымлы, өстендәге киемнәре затлы, үзе симез.

П у г а ч ё в *(симез адәмгә)*. Кем син?.. Җавап бир, синең каршыңда бөтен Русиянең государе Пётр Өченче басып тора.

С и м е з  а д ә м. Син государь түгел, син — юлбасар, син — карак...

П у г а ч ё в. Шигаев, хөкемеңне чыгар.

Ш и г а е в. Атларын бирегә китерергә, киемен — ялангачларга, үзен — иблис кочагына.

Симез адәмне сөйрәп китәләр.

П у г а ч ё в *(Бәхтиярга)*. Туеңа тагын бер бүләк. Кара халыкның канын эчеп күбенгән кандаланың әҗәленнән дә зуррак бүләк юк.

Б е л о б о р о д о в. Таң сызылып килә, галиҗәнап.

П у г а ч ё в. Күзең үткен, акылың салкын синең, атаман... Казанга!.. Казанга!..

Баскычтан йөгереп төшеп китә. Аңа бүтәннәр иярә. Шаушу. Атлар кешнәгәне, тояк тавышлары ишетелә. Болдырда Бәхтияр белән Нурсолтан, ишегалдында Теләчев, Мортаза, тагын бер-ике кеше кала.

Б ә х т и я р. Йә, ни дисең, Әбүбәкер?!

Т е л ә ч е в. Сөбханалла! Бу дәрьяны туктатыр көч җиһанда бар микән.

Б ә х т и я р. Юк, Әбүбәкер. Бу дәрья — мәңге кипмәс дәрья. Ул дәрьяны дистә меңләп елга, чишмә туендыра. Ул чишмәләрне ачучылар — без. Тагын гаскәр җыйнарга кирәк, Әбүбәкер.

Ут сүнә.

## Унынчы күренеш

Бәхтияр Канкаев отрядының лагере. Б ә х т и я р һәм Т е л ә ч е в бер читтәрәк Пугачёвның хәрби коллегиясенә хат язалар. Бәхтияр әйтеп тора, Теләчев яза.

Б ә х т и я р. Рәхимле падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләренең Вуянный коллегиясенә пулкувник Бәхтияр Канкай углындан бәндәчелек илә рапорт.

Кайсы ошбу сәфәремездә тапдык ошбу Казан өязенең җенесле халайыкларыны, кайсылар, безнең каршымызда күз яшьләрен түгеп, «рәхимле падишаһымыз һәм шәфкатьле атамыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре күп-күп

йыллар вә озын гомерләре сау вә сәламәт улсын» дип теләк телиләр.

Һәм бу заманда каршымызда йөгерүче гаскәремез алты йөздән артыктыр. Бер үк анларның эчендә киемсез һәм атсызлар вә коралсызлар бардыр. Юлымыз өстендә йакын торучы боярларның үзләрендән калган мал вә хайваннарын аламыз, хәзинәгә тапшырмак хакында... Һәр тарафларга пикит каравылларына командалар йибәрәмез, дошманнар хәбәрен белер өчен дип. Һәм йәнә Иделләрдәге барча пыравузларны иллешәр кешеләр йибәреп каратамыз, вурлар партиясенең хәбәрләре бар өчен. Бетте.

Т е л ә ч е в. Сәнә 1774, ийүлнең 14 көне.

Б ә х т и я р. Кичекмәстән җибәрергә кирәк. Әллә үзебезгә барып кайтасы?.. Казанны күрәсе килә, Әбүбәкер. Үзебезнең Казанны, этләрдән арынган Казанны.

Т е л ә ч е в. Казаны Казан, Бәхтияр, Мәскәү, Питырбур нишләр?

Б ә х т и я р. Алары да алыныр, Әбүбәкер.

Т е л ә ч е в. Алынырмы?..

Б ә х т и я р. Шигең бармы?

Т е л ә ч е в. Юк дип әйтсәм ялган булыр.

Б ә х т и я р. Дәлилең ни?

Т е л ә ч е в. Дәлилем юк, күңелемдә шигем бар.

Б ә х т и я р. Аңламыйм мин сине, Казан алынганга шатланасы урынга, күңелеңдә шик йөртәсең. Илебездә – ирек, өебездә нигъмәт булса, ни кирәк. Бүген без үз иркебездә – анысы да олы бәхет.

Т е л ә ч е в. Бүген ирекле булу бәхеттер. Киләчәктә зиндан көткәнен сизеп яшәү дә бик авыр.

Б ә х т и я р. Әбүбәкер, син сөйләгән сүзләрне башкадан ишетсәм, ул сүзләрне сөйләүчегә яман булыр иде. Сине үзем эзләп таптым. Әмма шунысы да мәгълүм: мин сиңа кайтып китәргә рөхсәт бирдем. Ирекнең кадерен, тәмен, ләззәтен татып өлгергән кеше зиндан турында уйлыймы?

Т е л ә ч е в. Бәхетле кеше син, Бәхтияр, зиһенең һәрдаим ачык, икеләнүләрнең ни икәнен белмисең!

Б ә х т и я р. Алай димә, мулла. Мин дә адәм баласы. Абдулла Мостайдан ни өчендер хәбәр юк.

Т е л ә ч е в. Сугышып яткан чагыдыр.

Б ә х т и я р. Шуран перевозын сакларга кирәк. Берәттән керәшен Гирачемга боерык җибәрергә онытмыйк,

уяу булсын. *(Teләчев кәгазь ала, язарга әзерләнә; Бәхтияр әйтеп тора.)* «Пулкувник Бәхтияр Канкай углыннан бирелде приказ сән Гирачем Сабай углына. Чистай кичүенә сәкез авылдан — һәрвакытта даимчелек илән унбиш кеше тормак үзләренә кичүдә. Ошбу эш тапшырылды Көчек авылының Мәнди Туктамыш углына, һәрвакытда яхшыдан һәм ямандин хәбәр булса, юкарыда язылган Гирачемга рипуртавайт итмәгә. Бу мәзкүр сәкез авыл җәмәгатьләренә пухут сорап һичкемне рәнҗетмәскә». Һәр ике язуны илтер өчен чапкын җибәр, Әбүбәкер.

Т е л ә ч е в китә. Бәхтияр ялгызы. Нурсолтанның җыры ишетелә. Ут агачка сөялеп җырлап торучы Нурсолтанга төшә.

Н у р с о л т а н җ ы р ы:

Өзелеп-өзелеп китә үзәгем,
Әле дә сабыр башкынаем, түзәмен.
Уф дип әйтсәм, аурый башларым,
Аурый башым, түгелә яшьләрем.

Иртә генә торып тышка чыксам,
Кара урман шаулый җил белән;
Маңгайга ла язган язмышларны
Сыпырып ташлап булмый җиң белән.

Җыр барышында Бәхтияр, Нурсолтан янына килеп, Нурсолтанның җырлавын тыңлап тора.

Б ә х т и я р. Уйларың кайларда, асылзатым, Нурсолтаным? Җырның моңлысын сайлап алып җырлыйсың.

Н у р с о л т а н. Падишамызга җырлый алмаган җырымны җырлыйм. Өеннән куып чыгарылган эт сыман озак йөрербезме, Бәхтияр?

Б ә х т и я р. Нигә андый сүзләр, Нурсолтан?

Н у р с о л т а н. Хатының иттең, оя корырга вакыт җитмәдеме?

Б ә х т и я р. Ашыкма, Нурсолтан, шундый оябыз булыр.

Н у р с о л т а н. Син һаман вәгъдә итәсең.

Б ә х т и я р. Мин сиңа оя вәгъдә итмәдем, асылзат. Мин сиңа мәңгелек гыйшкымны вәгъдә иттем. Кил кочагыма, ямьсез уйларыңны куй. *(Нурсолтанны кочагына*

*ала.)* Син нигә патша хәзрәтләре бүләк иткән асыл киемнәрне кимәдең?

Н у р с о л т а н. Кеше киемен кияргә тәнем тартмый, Бәхтияр. Кайчан үзең эшләп алырсың миңа яңа күлмәк, шунысын киярмен.

Б ә х т и я р. Явыз хатын булырсың син, Нурсолтан.

Н у р с о л т а н. Үзең сайлап алдың. Утыз яшеңнән ашканчы мине көткәнсең. Үзең әйттең.

Б ә х т и я р. Юк, болай булгач, мин сине берәр авылда калдырам. Патша хәзрәтләренең сүзенә каршы килеп, мин сине үзем белән йөртәм, ә син...

Н у р с о л т а н. Мин калмыйм. Гомерем буе тагылып йөриячәкмен үзеңә. Мин күрәсен әллә кем күрмәс. Тәкъдирдә язылганнан яманы булмас.

Б ә х т и я р. Әгәр дә кодрәтемнән килсә, мин сине иргегет итәр идем, Нурсолтан. Дөньясын айкар идең син.

Н у р с о л т а н. Айкар идем, синнән ким булмас идем. Син миңа әйт, Бәхтияр, бу айкавыңның очы-кырые булачакмы?

Б ә х т и я р. Патша хәзрәтләре Казанда.

Н у р с о л т а н. Әйдә, без моннан китик, Бәхтияр.

Б ә х т и я р. Кая?

Н у р с о л т а н. Бер тыныч урын тап. Күңелем сизә, мин япа-ялгызым, тол калачакмын.

Б ә х т и я р. Сөйләмә андый сүзләр, акылсыз хатын.

Н у р с о л т а н. Калачакмын, Бәхтияр. Бигешкә мин иярләшкән идем, аердылар. Күңелемне син яуладың, хәерлегә түгел.

Б ә х т и я р. Хәерлегә булыр, Нурсолтан. Синең кебек гүзәл, синең кебек кыю балалар үстерербез.

Н у р с о л т а н. Туктаусыз кыйналган хатыннан нинди бала, Бәхтияр. Булмас инде ул.

Б ә х т и я р. Син яманлык юрама, Нурсолтан. Яманлык юрамасаң да килә. Син көл.

Н у р с о л т а н. Көлүнең ни икәнен белмәдем.

Б ә х т и я р. Өйрәнербез, асылзат. Сине җылатканнар җылаганда без көләбез. Каерылган канатлар төзәлгәч, без көләрбез, Нурсолтан. Адәм баласы җылар өчен генә түгел, көләр өчен дә яратылган.

Кинәт бер төркем сугышчыларның кычкырып көлгәннәре ишетелә.

Ишетәсеңме, көләләр. Бәлки, иртәгә үләрләр, тик бүген көләләр. Алар бүген иректә. Көлгән өчен камчы белән сuктыручы юк. Син адәм баласы түгел, син хайван дип мыскыллаучы юк.

Көлү дәвам итә. Ут яктысы түгәрәкләнеп утырган сугышчылар төркеменә төшә. Түгәрәк уртасында — Мортаза. Ул биек кенә төп башында аякларын бөкләп утыра.

Василий. Карагыз, җәмәгать, ярты грошка ярамый торган йолкыш иде Мортаза. Хәзер кем булды?! Алла урынында утыра. Молодец, Мортаза!

Мортаза. Бәчели дәдәй, җәмәгать, патша гына булыймчы. Ходай Тәгалә булып кылансам, гөнаһысын кая куярмын?

Тавышлар. Әйдә, әйдә!.. Гөнаһысы уртак!..

Арадан берәү *(Мортазага)*. Төш аннан. Азындыгыз. Тәһарәтсез башың белән...

Мескен бүрек. Син тик тор, абзый. Гөнаһтан курыксаң карама... Безгә теге дөньяда барыбер тәмуг. Монда көлеп калыйк. Мортаза, башла!

Мортаза. Алайса, Аллага тапшырдык, гөнаһысы уртак.

Тавышлар. Уртак!.. Уртак!..

Арадан берәү. Йа Хода, ахырзаман. *(Борылып утыра.)*

Мортаза. Кемнән башлыйбыз? Бәчели дәдәй, кил.

Василий *(Мортаза каршына килеп)*. И Тәңрем, мин синең янга килгән идем.

Мортаза. Ни өчен?

Василий. Оҗмахка керәсем килә.

Мортаза. Син кем?

Василий. Үзеңнең урысың.

Мортаза. Әйдә кер, пумушнигым булырсың.

Көлешәләр. Василий төп янына сузылып ята. Мортаза каршына Ертык чикмәнле сугышчы килә.

Ник килдең?

Ертык чикмән. Оҗмахка керәсем килә.

Мортаза. Син кем?

Ертык чикмән. Чувашың.

Мортаза. Әйдә, табак-савыт юарсың.

Ертык чикмән. Юк, мин андыйга риза түгел.

Мортаза. Нишләтим соң сине?
Ертык чикмән. Бүтән эш тап.
Мортаза. Әйдә, алайса, яңабаштан.
Ертык чикмән *(читкә китә дә Мортаза каршына әйләнеп килә)*. Оҗмахка керәсем килә.
Мортаза. Син кем?
Ертык чикмән. Чувашың.
Мортаза. Әйдә, булырсың йөзбашым.
Ертык чикмән. Амин. *(Җиргә сузылып ята.)*

Мортаза каршына Кара сакаллы сугышчы килә.

Мортаза. Син кем?
Кара сакал. Керәшен.
Мортаза. Бизәфчәкевә керәсең.
Арадан берәү. Йа Хода!

Мортаза янына Кызыл ыштанлы сугышчы килә.

Мортаза. Ник килдең?
Кызыл ыштан. Оҗмахка керәсем килә.
Мортаза. Син кем?
Кызыл ыштан. Чирмешең.
Мортаза. Чирмешең... Чирмешем... Әйдә, сиңа рөхсәт бирмешем.

Көлешәләр. Мортаза янына Мескен бүрекле килә.

Мортаза. Ә син ник килдең?
Мескен бүрек. Оҗмахка керәсем килә.
Мортаза. Син кем?
Мескен бүрек. Татарың.
Мортаза. Кит! Ботыңнан тотып атарым.

Көлешәләр.

Арадан берәү *(сикереп торып)*. Йа Хода! *(Мортазага килеп ябыша.)* Төш, явыз, төш, бинамаз! *(Мортазаны төп башыннан сөйрәп төшерә.)*

Мортаза көлә-көлә чыгып йөгерә. Шулвакыт Кызыл ыштанлы сугышчы сикереп тора да биергә тотына. Бүтәннәр кычкырып аны хуплыйлар. Биюче арып туктый. Кулларын җәеп, чалкан ята. Халык көлешә.

Василий. Әй син! Хәлсез алаша! Бик тиз арыдың.
Кызыл ыштан. Ә син үзең биеп кара. Кеше биегәнгә сакал сыпырып тору җиңел ул!

В а с и л и й. Биедем дигән була, карачкы. Син бит аягыңны җирдән бер карыш та күтәрмәдең.

К ы з ы л  ы ш т а н. Безнең бию шундый.

М е с к е н  б ү р е к. Чирмешкә аягын күтәреп биергә ярамый.

В а с и л и й. Нигә?

М е с к е н  б ү р е к. Аягын күтәргәнне Питырбурдагы патша күреп алса, беләсеңме ни була? Әле син чирмеш башың белән аягың күтәреп биеп йөрисеңме дип, иманын укыта аның патша.

К ы з ы л  ы ш т а н. Дөрес түгел. Немка Катядан курыкмыйм мин. *(Сикереп торып, әле бер аягын, әле икенче аягын күтәреп.)* Менә берсе, менә икенчесе, менә икесе бергә.

В а с и л и й. Дөрес! Курыкма, туган! Анасының җиде бабасының сигезенче әбисен ярык тигәнәгә салып аягын кытыклагыры. Ул курыксын. Безнең патшабыз Пётр Фёдорович булганда аяк күтәрергә куркып торыргамы?! Эх! *(Биеп китә. Әллә ниләр кыландырып бии. Төркемгә якынлашып килгән Мортазаны күреп.)* Әй, Муртаза шайтан, кил тизрәк, дәдәеңә ярдәм ит.

М о р т а з а. Ярамый, Бәчели дәдәй. Кайгым зур.

В а с и л и й *(биюдән туктап)*. Ни булды? Мортазага кем тиде?!

М о р т а з а. Яңа хәбәр ишетмәдегезмени?

В а с и л и й. Тагын ни кыландырырга чамалыйсың, шайтан?

М о р т а з а. Бу юлы юк. Яман хәбәр. *(Кычкырып еларга тотына.)*

Аны уратып алалар.

— Нәрсә бар?..

— Әйт тизрәк...

— Юри кылана ул...

М о р т а з а. Кыланмыйм, җәмәгать. Питырбурдан хәбәр килде. Казан губернатыры әле генә үзе килеп миңа сөйләде. Ишеттеңме, Мортаза, ди, Әби патшаның хәлләре мөшкел, ди, йокысы качкан, ди, бик куркыныч төш күрдем, Мортаза килеп өшкерсен, дип әйтеп әйткән, ди. Хәер-фатихагызны биреп, җибәрәсезме мине, җәмәгать, Питырбурга?

К ы з ы л  ы ш т а н. Әби патшаның күргән төше ниндирәк булган, Мортаза?

М о р т а з а. Бәчели атлы җирән сакаллы бер сөйкемсез адәм кочаклаган, ди үзен. Кочаклаганда сакалы белән муенын тырнаган, ди.

Көлешәләр.

В а с и л и й. Ах, шайтан! Аякларың эт арбасына тәртә булгыры! *(Мортазаны куып китә. Куып җитеп эләктерә дә төркем янына алып килә.)* Әйтегез, нишләтим?

М о р т а з а. Тимә, Бәчели дәдәй. Мин юри әйттем. Сөйкемсез адәм син түгел, син бик чибәр. Сакалың да матур. Сөйкемсез адәм... *(Арадан берәүгә күрсәтеп.)* Әнә ул. Әби патшаны ул кочаклаган.

А р а д а н  б е р ә ү. Хасиятсез кеше син, Мортаза энем.

М о р т а з а. Кем хасиятсез? Мин кочакламаган Әби патшаны, син кочаклаган.

А р а д а н  б е р ә ү. Нишләп мин марҗа кочаклыйм ди, әлхәмделиллаһ, үз Мәрфугам бар.

А р а д а н  и к е н ч е *(сикереп торып)*. Марҗага ни булган?

А р а д а н  б е р ә ү. Ул безнең дин кешесе түгел.

А р а д а н  и к е н ч е. Сезнең дин кешесе булмагач начармыни? Эх син, басурман.

А р а д а н  б е р ә ү *(арадан икенченең каршына барып)*. Син нәрсә дисең?!

А р а д а н  и к е н ч е. Нәрсә ишеттең — шуны әйттем.

А р а д а н  б е р ә ү. Юк, син әйт, нәрсә дисең?

А р а д а н  и к е н ч е. Басурман дидем!

А р а д а н  б е р ә ү. Басурманмы? Син безне мыскыл итәсеңме? Ах син, кяфер!

Билбауга кыстырган балтасын тартып ала. Арадан икенче дә пычагын суырып чыгара.

— Шаярмагыз!
— Туктагыз.

Ләкин Арадан берәү белән Арадан икенче аларны тыңламыйлар, бер-берсенә кара-каршы киләләр. Тавыш куба. Тавышны ишетеп, Т е л ә ч е в, Б ә х т и я р, Л и х а ч е в керәләр.

Б ә х т и я р *(сугышучылар янына үтеп)*. Нишлисез? Туктагыз!.. *(Сугышучылар арасына кереп, аларны аера.)* Ни булды?

Арадан берәү. Татарларны ул «басурман» дип әйтте.

Арадан икенче. Әйттем шул. Ә син нигә безнең хатыннарны мыскыл иттең? Нигә «кяфер» дип акырдың?

Бәхтияр. Василий, ни булды?

Василий. Уеннан уймак чыкты, полковник.

Бәхтияр. Бу уен түгел, Василий. Җәнҗал чыгаручыларны монда китерегез.

Арадан икенче белән Арадан берәүне Бәхтияр каршына китерәләр.

Бәхтияр. Нишләтим соң томана сарыкларны? Берберегезне үтерер өчен яу чыктыгызмы? *(Лихачев янына килеп.)* Гаврила, сиңа тапшырам, син хөкем ит.

Лихачев. Мин бөек государь Пётр Фёдорович гаскәренең, полковник Бәхтияр Канкаев отрядының сотнигы Гаврила Лихачев әмер бирәм: отрядта җәнҗал чыгарган бу адәмне һәм бу адәмне унар камчы белән сыйларга... Син... син... Әмерне үтәгез! Карышсалар, тагын унар камчы өстәргә.

Сугышучыларны алып китәләр.

Бәхтияр *(Теләчевкә)*. Әбүбәкер, гаскәргә әйтер сүзем бар.

Теләчев. Җәмәгать, тыңлагыз! Олуг император Питыр Фидрувич хәзрәтләренең өлкән пулкаунигы Бәхтияр Канкайның сезгә әйтер сүзе бар.

Бәхтияр. Җәмәгать! Олуг падишаһымыз әгъзам Питыр Фидрувич хәзрәтләренең һиммәтле гаскәре! Безки падишаһымыз тарафыннан пулкувник итеп куелган һәм дә сезләр тарафыннан башлык итеп танылган Бәхтияр Канкай углының сезләргә әйтер сүзе шулдыр, мәгълүм булсын, колакларыңыз ишетсен, без ворлар командасы түгел. Без – падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре өчен изге юлга сәфәр чыккан бер атаның балаларымыз. Атамыз Питыр Фидрувичның могтәбәр кулындагы бармакларымыз. Күктә йолдызлар бар, янә ай бар. Без – йолдызлар, падишаһымыз Питыр Фидрувич – ай. Йолдызларның яхшысы юк, яманы юк. Аларның барчасы ай тирәсендә ялтырап яналардыр. Олуг падишаһымыз барчабызны тигез күрә, барчабызга да аермаенча җир, су, урман ярлыкый. Ирек ярлыкый. Янә дә шуны әйтәм, үзләрегез дә беләсез, сугышка бергә янәшә йөрисез,

бергә ризык җыясыз, кемнәр бар сезнең арада? *(Кызыл ыштанлы сугышчыга.)* Син кем? Син үзең, синең атаң һәм анаң нинди телдә сөйләшә?

Кызыл ыштан. Чирмеш.

Бәхтияр *(Ертык чикмәнлегә)*. Син кем?

Ертык чикмән. Чуваш.

Бәхтияр *(өченче сугышчыга)*. Син кем? Син үзең, синең атаң һәм дә анаң нинди телдә сөйләшә?

Сугышчы. Вотяк.

Бәхтияр. Күзләреңез күрәдер, колакларыңыз ишетәдер. Барчабыз бер җирнең балалары. Безнең сотнигыбыз Гаврила Лихачев урыс, бездә пулкавай старшина булып чирмеш Байки Туйкиев торды, сотник булып вотяк Илья Богданов торды, сотник булып чуваш Борис Савельев торды... Могтәбәр Салават башкорт иленең баласы. Канзафар Усаев татар углы. Алар олуг падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләренең фатихасы илә бригадир чины алып меңләгән халык илә падишаһымыз Питыр Фидрувич хәзрәтләре өчен батырлык кылып йөриләр. Янә тагын шуны хәтереңездә тотыгыз һәм аң булыңызлар, головной атаман могтәбәр Белобородовның указын. Әгәр дә мәгәр кем дә кем тәртипсезлек кылса, ул һич кызганмыенча камчы белән суктырыладыр, әгәр урыс булса, урыс һәм дә татар командасы катнашында, татар булса, татар һәм дә урыс командасы катнашында. Башка халайыклар да шулай ителәдер. Олуг падишаһымыз импиратыр әгъзам Питыр Фидрувич хәзрәтләре үзенең гаскәре илә Казан каласында торган бу көндә безгә болай эшләү килешмидер. Озак булмас, Мәскәү каласында олуг падишаһымыз аягына баш орырга да безләргә насыйп булыр. Сүземне колакларыңыз ишеттеме?

Тавышлар. Ишетте.

Бәхтияр. Күңелләреңез ишеттеме?

Тавышлар. Ишетте.

Бәхтияр. Алайса, сүзем бетте.

Икенче чапкын керә. Бәхтияр янына килә.

Икенче чапкын. Пулкувник әфәнде. Мин пудпулкувник Абдулла Мустаев отрядыннан килгән чапкынмын. Китергән хәбәрем күңелсез. Пудпулкувник Абдулла Мустаев отряды җиңелде.

Бәхтияр. Ничек? Кайчан?

И к е н ч е  ч а п к ы н. Граф Меллин командасы белән сугышта, Шуран перевозында җиңелүгә дучар булды.

Б ә х т и я р. Мостай үзе кайда?

И к е н ч е  ч а п к ы н. Калган кешеләре белән чигенә.

Ө ч е н ч е  ч а п к ы н керәп, Бәхтияр янына килә.

Ө ч е н ч е  ч а п к ы н. Полковник хәзрәтләре, Иске Җөри авылы янында безгә каршы җибәрелгән отряд барлыгы беленде. Бу якка таба килә.

Б ә х т и я р. Әбүбәкер, йөзбашларына әйт, поход чыгабыз! Гаврила, синең отрядың алдан бара, хәстәрен күр! *(Икенче чапкынга)*. Пудпулкувникка әйт, безгә кушылсын! *(Өченче чапкынга.)* Пикитларга хәбәр бир, уяу булсыннар!

И к е н ч е һәм Ө ч е н ч е  ч а п к ы н чыгып китәләр.
Командалар яңгырый, походка әзерлек башлана.

Ут сүнә.

## Унберенче күренеш

Сәхнәдә – Е к а т е р и н а II белән Г р и г о р и й  П о т ё м к и н. Икесенең дә кулларында – бокаллар. Артта – бал мәҗлесе.

Е к а т е р и н а. Сез тумыштан меланхолик, князь. Бүгенге мәҗлестә, минемчә, шат булырга сәбәп бар.

П о т ё м к и н. Ләкин...

Е к а т е р и н а. Явыз тотылды, бу сезнең өчен дә шатлык түгелмени?

П о т ё м к и н. Шатлык, әлбәттә...

Е к а т е р и н а. Шулай булгач?

П о т ё м к и н. Явыз тотылды, аның башы киселер, ләкин...

Е к а т е р и н а. Сезгә тагын ни җитми?

П о т ё м к и н. Явыз тотылды, чир калды. Берничә баш киселер, миллион баш исән. Степан Разинның да башы киселгән иде. Россиянең бу төзәлмәс чир белән чирләве бүгенге шатлыгыма күләгә булып төшә, сөрем булып куна.

Е к а т е р и н а. Бүген фәлсәфә көне түгел, князь.

П о т ё м к и н. Кичерегез. Мин Россиянең киләчәге өчен борчылам. Безнең дворяннарның йөрәгенә курку оялады. Ул курку буыннан-буынга күчәчәк. Ә фетнәчеләр токымында үзләренә ышаныч арта барачак.

Е к а т е р и н а. Куегыз фәлсәфәгезне, Григорий, минем бүген уйлыйсым килми, күңел ачасым килә.

П о т ё м к и н. Күңел ачарга иртәрәк түгелме, государыня? Фетнә дәвам итә. Башкисәр башкорт Салават Юлаев Себер юлында хәрәкәт итә, Казан тирәсендә һаман да тыныч түгел. Яшерен комиссиянең хәбәр итүенә караганда, самозванец кулыннан полковник дәрәҗәсе алган Канкаев дигән ниндидер юлбасарның шактый зур һәм көчле бандасы бар.

Е к а т е р и н а *(ачуланып)*. Миңа нишләргә кушасыз, князь? Утырып җыларгамы? Әгәр сез Россиянең киләчәге өчен миннән күбрәк борчыласыз икән, әгәр Россиянең киләчәге куркыныч астында икән, әгәр фетнә дәвам итә икән, мин сезгә зур шатлык һәм бәхет бүләк итә алам. Сез, генерал-поручик, юлга әзерләнә аласыз. Үзегез әйткән башкисәр башкорт Юлаев белән полковник дәрәҗәсе алган Канкаевны тотып башларын кисегез. Фельдмаршал дәрәҗәсенә күтәрелерсез.

П о т ё м к и н. Кичерегез, государыня, мин сезнең кәефегезне бозарга теләмәгән идем.

Е к а т е р и н а. Әлегә мин сезнең бүтән теләгегезне күрмим, князь. Усал кеше сез. Сездә рәхим-шәфкать хисе юк. *(Бокалын куеп, утыра.)*

П о т ё м к и н. Зинһар, гафу итегез.

Е к а т е р и н а. Мин сез уйлаганча ук җилбәзәк түгел һәм сез уйлаганча ук ахмак та түгел, исегездә тотыгыз. Россия белән идарә итү авыр. Анда йөз төрле тел, йөз төрле халык, барысы да вәхши. Иң начары, аларда вәхшиләрчә дуслык. Хәтта дин дә аларны аера алмый. Буйсындырып кара ул халыкны үзеңә. Россия – бунтлар, фетнәләр иле. Сез, князь, шуны яхшы белгән хәлдә, бүгенге шатлыклы көнемдә минем җанымны әрнетәсез. *(Кульяулыгын күзенә китереп.)* Хатын-кыз булуым хөрмәтенә кызганыр идегез, ичмаса.

П о т ё м к и н *(Екатеринаның каршына тезләнеп)*. Мәрхәмәтле...

Е к а т е р и н а. Сез хаклы, Григорий, Россия чирле.

Россия генә түгел, бунт чире Европага тарала. Беләсегез килсә, ул чирдән Россияне дәвалап була. Аның өчен, самозванец таләп иткәнчә, җирне, суны, ирекне сезнең кулдан тартып алып кара халыкка бирергә кирәк. Сез шуңа ризамы, князь Потёмкин Григорий Александрович? Күпме җирегез бар, бирәсезме?.. Юк! Нигә, алайса, минем каршымда фәлсәфә сатасыз?!

Потёмкин. Мин гафу үтендем, государыня, һәм мең тапкыр гафу үтенергә әзер.

Екатерина. Әлбәттә, гафу итәмен. Нишлим, каты бәгырьле була белмим. *(Кыланчыкланып.)* Утырыгыз яныма.

Потёмкин Екатеринага бокалын алып бирә.
Үзе баскан килеш тора.

Утырыгыз. *(Потёмкин утыргач.)* Ни өчен күтәргән идек бу бокалны?

Потёмкин. Сезнең шәфкатьле булуыгыз, гаепleләрне гафу итә белүегез өчен эчәргә рөхсәт итегез.

Екатерина. Юмаларга оста сез, Григорий. *(Эчемлектән авыз итеп куя.)* Безне югалтканнардыр, князь... Ой, башым әйләнеп китте. Фамилиясе ничек дидегез әле?

Потёмкин. Кемнең?

Екатерина. Казан губернасындагы сез әйткән теге юлбасар полковникның!

Потёмкин. Хәтерем ялгышмаса, Канкаев.

Екатерина. Татармыни?.. Үҗәт халык. Һич тик тора белмиләр. Кайда бунт, кайда фетнә — алар шунда. Казанда булганда, мине татарлар яши торган бистәгә алып барганнар иде. Шундагы бер татар кызы истә калган. Каршыма китерделәр, бер сүз дәшми, каш астыннан гына сөзеп карый. Кап-кара күзләрендә — усаллык, нәфрәт. Мин ул карашны күтәрә алмадым, төне буе күземә йокы кермәде. Мин аңладым, Григорий, ул халыкны чукындырып буйсындырырга тырышу зур ахмаклык булган.

Потёмкин. Сез үзегез фәлсәфәгә бирелдегез, государыня.

Екатерина. Ах, гафу итегез. Усал сез, князь, ялгышны тиз күреп аласыз. Киләчәктә дә шулай эшләгез. Икәүдән-икәү калгач, мин аз гына күңелсезләнсәм дә кисәтегез. Гафу итегез, теге юлбасарның исеме тагын хәтеремнән чыкты.

П о т ё м к и н. Канкаев.

Е к а т е р и н а. Җәза отрядлары ни карый?! Әрәмтамаклар, эшлексезләр, җилкуарлар!..

Ут сүнә.

## Уникенче күренеш

Нократ елгасы ярындагы урман аланы.
Б ә х т и я р һәм Т е л ә ч е в.

Б ә х т и я р. Сизәсеңдер, Әбүбәкер, эшләребез шәптән түгел, без камалышта. Башларыбызның исән чыгуы икеле.

Т е л ә ч е в. Ни әйтергә теләвең, Бәхтияр?

Б ә х т и я р. Ул-бу булса, кичер мине.

Т е л ә ч е в. Ни өчен?

Б ә х т и я р. Авылыңнан, өеңнән сине мин аерып алдым.

Т е л ә ч е в. Үкенәсеңме?

Б ә х т и я р. Мине каһәрләвеңне теләмим.

Т е л ә ч е в. Без — өлкән кешеләр, Бәхтияр, сабыйлар сүзен сөйләшмик. Үлемнән өстен кешенең туганы юк.

Б ә х т и я р. Үлемнең мәгънәлесе, мәгънәсезе бар. Ни өчен үлгәнеңне белми үлү — мәгънәсез үлем.

Т е л ә ч е в. Син кылган эшләрең өчен үкенәсең, ахры?

Б ә х т и я р. Юк, Әбүбәкер! Зиһенем — аек, мәсләгем туры булды. Кеше икәнемне аңладым. Бер ел буе тезләнми яшәдем. Әҗәл килсә, аның алдында да тезләнмәм. Синең өчен, минем белән бергә йөргән кешеләр өчен ут йотам.

Т е л ә ч е в. Бәхтияр туганым. Туктат сүзеңне. Ничәмә айлар буе үзең белән ризык җыйган кешеләрне кимсетмә.

Б ә х т и я р. Ничә айлар мин сине һәм аларны алдадым. Бөек падишаһымыз, дип әйтә килдем. Ә ул падишаһ түгел иде, Әбүбәкер.

Т е л ә ч е в. Мин аны белдем.

Б ә х т и я р. Белдең? Кайчан?

Т е л ә ч е в. Синең туең көнендә.

Б ә х т и я р. Ничек?

Т е л ә ч е в. Кара халык туй иткәндә, ул туйның түрендә кайсы патша утырган?

Бәхтияр. Кичер, Әбүбәкер, сиңа ышанмавым өчен кичер. Күңелем сизеп, сине юлдашым итеп сайлаганмын.

Теләчев. Бу мәҗлес түгел, Бәхтияр, бер-беребезне макташудан мәгънә юк. Син – полковник. Сиңа үлем турында уйларга ярамый. Мин дә теге дөньяга китәргә ашыкмыйм. Исеңдәме, син әйткән идең, кулыңа кылыч тоттырмам, дигән идең.

Бәхтияр. Әйттем һәм сүземдә тордым.

Әбүбәкер. Сүзеңне кире ал, Бәхтияр. Кулыма кылыч алыр көн җиткәнен сизәм. Кылыч бир син миңа. Билеңдә – ике кылыч, берсе миңа тиештер. Ир-егетләр каны коелганда читтән карап тора алмыйм.

Бәхтияр. Көткән сүземне әйттең, Әбүбәкер. Мең рәхмәт. Рәхим ит, туганым. Сиңа бүләк итәрмен дип саклап йөрдем. *(Кылычын салып бирә.)*

Әбүбәкер. Янә сүзем. Син – полковник. Камалыштан котылуның чарасын күр.

Бәхтияр. Киңәшең бир, Әбүбәкер.

Теләчев. Каршыбызда – Нократ суы.

Бәхтияр. Аръягында – кара урман.

Нурсолтан йөгереп керә.

Нурсолтан. Бәхтияр! Бәхтияр! Кач! Кач! Сине тотып бирәләр.

Бәхтияр. Ни сөйлисең, Нурсолтан?

Нурсолтан. Кач! Кешеләрең арасында язу йөри. «Бәхтияр Канкаевны тотып бирсәгез, гөнаһларыгыз кичерелә. Юкса барыгызның да башлары кисүле» диелгән. Харап буласың, Бәхтияр.

Бәхтияр. Тукта, сабырлан.

Нурсолтан. Юк! Ю-ук!!! Кач! Мине үтереп кач. Әнә киләләр, киләләр!

Аланга төркем-төркем булып сугышчылар җыела.
Нурсолтан Бәхтиярны гәүдәсе белән каплый.

Килмәгез!.. Килмәгез!!.

Бәхтияр *(Нурсолтанны читкә этеп)*. Кит, Нурсолтан!

Нурсолтан. Юк, җибәрмим. *(Бәхтиярга асылына.)*

Бәхтияр *(йөгереп килеп җиткән Мортазага)*. Мортаза, алып кит!

Мортаза Нурсолтанны читкәрәк алып китә. Тынлык.
Нурсолтанның үксеп елавы гына ишетелә.

Б ә х т и я р. Әбүбәкер, сиңа иң соңгы гозерем: Нурсолтанны онытма. *(Сугышчылар каршына бара.)* Җәмәгать! Уеңыз, ниятеңез безләргә билгеле. Шуны беләңезләр: без сезне гаепләмибез. Авыр юлда юлдашларым булдыңыз, үзләреңезне аямаенча сугыштыңыз. Сезләргә рәхмәтемнән гайре сүзем юк. Мин сезләрнең иркендә. Ләкин шуны әйтәм: мин сезләрне үз янымда ирексезләп тотмадым. Максатым изге булды. Җир юклыктан, су юклыктан интеккән, ирек юклыктан тыны кысылган кара халыкны – сезләрне яклап яу чыктым. Һәм кылган эшләремә бер кәррә дә үкенмим. Әгәр Бәхтиярның үлеме йөзләрне әҗәлдән коткара икән – монысы минем өчен зур бәхеттер.

В а с и л и й *(алга чыгып)*. Полковник, син сөйләгәнне без аңламыйбыз. Уегыз, ниятегез билгеле дип әйттең, сиңа нәрсә билгеле? Ачыклап әйт. Бәхтиярның үлеме, дидең. Нинди үлем? Аңлатып әйт.

Б ә х т и я р. Безне камаган ворлар командасы сездән Бәхтиярның башын сорый, дөрес түгелме?

В а с и л и й. Дөрес. Менә ул язу. Анда ни язылганын укып бирделәр. Мин яза белмим, телем белән әйтәм. Бәхтиярның башы бирәү генә, ул безнең үзебезгә дә бик кирәк. Кем дә кем минем сүзгә ышанмый, минем яныма килсен. Йә, кем монда теләнче булырга тели, килегез, әбиегезнең җиде бабасын!.. Йә, кемгә бер тиен кирәк, кем Бәхтияр башы белән сату итәргә җыена, кил!.. Бирәү дә дәшми, полковник. Бу халык синең яныңа баш сорап түгел, әмер сорап килде. Әмер бир, полковник. Кулыбыздагы сөңгеләр синең әмерне көтә.

Б ә х т и я р. Җәмәгать...

Т а в ы ш л а р. Әмер бир, әмер бир!

Бәхтияр. Җәмәгать! Җирдәшләр! Кардәшләр! *(Җиргә тезләнеп башын ия дә тиз генә торып баса.)* Кардәшләр! Сезләрдән яшерен серебез юк. Ворлар командасына каршы барып, аларны куарлык көчебез әзәйде. Безгә көч җыярга кирәк. Аның өчен каршыбызда – Нократ суы, аръягында – кара урман. Шунысы мәгълүм: Нократ янында да ворлар, сугыш бик яман булачак.

Т а в ы ш л а р. Әмер бир! Әмер бир!

Б ә х т и я р. Әбүбәкер!

Теләчев, ашыгып, Бәхтияр янына килә.

Әбүбәкер, тәвәккәлләдек. Әмерне бирәм. Ләкин сугыш бик яман булачак. Исәнлектә очрашырга насыйп булмаса, бәхил бул.

Т е л ә ч е в. Яман булмаган сугыш юк, Бәхтияр. Әмереңне бир.

Б ә х т и я р. Җәмәгать! Әмерне тыңлаңызлар. Каршымызда — Нократ суы, аръягында — кара урман. Изге сәгатьтә! *(Кылычын югары күтәрә.)*

Ут сүнә.

Х о р. Тып-тып тояк тавышы
Тынгы бирми бер көн дә,
Чыгарылган хөкем дә.
Тотып бирми беркем дә,
Йөри халкы иркендә
Канкай углы Бәхтияр.

П ә р д ә.

# МОҢЛЫ БЕР ҖЫР

*(Ике пәрдәле публицистик драма)*

Катнашалар:

Муса Җәлил.
Шагыйрь.
Гайнан Кормаш
Абдулла Алиш
Әхмәт Симаев
Гариф Шабаев
Абдулла Батталов
Фуат Булатов
Зиннәт Хәсәнов
Фуат Сәйфелмөлеков
Әхәт Аднашев
Сәлим Бохаров — җәлилчеләр.
Ана.
Ланфредини — Италия гражданины.
Розенберг — рейхсминистр.
Шәфи Алмас — Идел-Урал Штаты «президенты».
Хаин.
Палач.

## Беренче пәрдә

Залда ут сүнә. Сәхнә кап-караңгы. Тынлык. Бер прожектор әкренләп яктырта башлый, яктылыгы сәхнә алдында басып торучы Шагыйрьнең залга төбәлгән уйчан йөзенә төшә.

Шагыйрь *(үзалдына)*.

Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып…
Гомрем минем моңлы бер җыр иде…
Сөям диеп кызга үрелгәнче,
Сөрт борныңны, егет, элгәре.

Сөрт борныңны, егет…
Әкияттәге серле йомгак булып
Тәгәрәде тормыш сукмагым…
Кызлар, төнлә йөрмәгез!
Коймадан сикермәгез!
Тагын әллә ни ертып,
«Мода» дия күрмәгез…
Гомрем минем моңлы бер җыр иде…
Моңлы бер җыр…

Шагыйрь сәхнәгә борыла. Музыка башлана. Музыка белән бергә яктылык та арта төшеп, сәхнәне урталай бүлеп куйган төрмә рәшәткәсен яктырта. Музыка көчәя. Шагыйрь төрмә рәшәткәсен урталай ярып эчкә үтә. Һәм сәхнәдә хыялында терелтә башлаган Муса белән очраша. Музыка кинәт туктый. Тынлыкта Шагыйрь хәрәкәтсез басып торган Муса янына килә.

Исәнмесез, Муса абый… *(Паузадан соң.)* Муса абый дип гади генә эндәшкәнемә гаҗәпләнмәгез. Сезгә шулай дип эндәшәсем килә. Исәнмесез, Муса абый… *(Муса эндәшмәгәч.)* Алайса, рәсмирәк яңгыраса да, Муса Җәлил дип мөрәҗәгать итәм. Исәнмесез, Муса Җәлил. *(Җәлил эндәшмәгәч.)* Бәлки, сез Гумеров фамилиясенә ияләшкәнсездер, Җәлил икәнлегегезне һаман да белдерергә теләмисездер. Исәнмесез, Муса Гумеров.

Муса. Сезгә ни кирәк?

Шагыйрь *(шатланып)*. Ниһаять, эндәштегез. Саумысыз, Муса абый… Муса Җәлил… Муса Гумеров…

Муса. Сез кем?

Шагыйрь. Исемемне әйтсәм дә белмәссез. Мин сезгә таныш түгел. Әгәр дә үземне шагыйрь дип таныштырсам гаепләмәгез.

Муса. Шагыйрь?

Шагыйрь. Шагыйрь – бөек сүз. Бәлки, андый сүзгә лаек та түгелмен. Шагыйрь дигән изге исемне йөртер өчен сез булырга кирәктер?

Муса. Комплиментларны хатын-кызларга әйтәләр… Сез кем?

Шагыйрь. Гафу итегез. Мин шигырьләр язам, язганнарым басыла.

Муса. Сезгә ни кирәк, шигырьләр язучы егет?

Шагыйрь. Мин сезне эзләп килдем.

Муса. Кайдан?

Шагыйрь. Казаннан.

М у с а. Казаннан? *(Шагыйрьнең йөзенә текәлеп карап.)* Ка-зан-нан? *(Йөзе ачылып китеп.)* Туган илдән? *(Кинәт шикләнеп.)* Миннән сезгә ни кирәк? Йомышыгыз нәрсәдә?

Ш а г ы й р ь. Шикләнмәгез, Муса абый... Муса Гумеров... Муса Җәлил...

М у с а. Ә нигә миңа шикләнергә? Миңа үлем карары чыгарылган. Үлем алдыннан кем белән сөйләшкәнемне мин белергә тиеш.

Ш а г ы й р ь. Кем белән булса да барыбер түгелмени? Аңа карап гомерегез озынаймый.

М у с а. Әй сез, шигырьләр язучы, тизрәк йомышыгызны әйтегез, минем вакыт санаулы. Һәм, гомумән, сез монда ничек керә алдыгыз? Сезне кем җибәрде?

Ш а г ы й р ь. Хыялның керә алмаган җире юк.

М у с а. Хыял?

Ш а г ы й р ь. Сезнең янга хыялым алып килде, Муса абый... Мин сезне хыялымда терелттем. Сез — шагыйрь, хыялның ни икәнен яхшы беләсез. Без, кешеләр, хыялда һәм төшебездә дөньяда үзләре булмаганнар белән дә очраша алабыз.

М у с а. Димәк?..

Ш а г ы й р ь. Сезнең белән сөйләшәсе сүзләрем, сезгә бирәсе сорауларым күп. Мин ул сорауларга җавап табарга тиеш.

М у с а. Хыял... Аңлыйм, шигърият, сәнгать шартлылыкны кабул итә. Мин дә шигырьләремдә еш кына Туган илгә кайтып киләм. Димәк, сез киләчәктән килдегез?

Ш а г ы й р ь. Сезнең өчен — киләчәк, минем өчен бүгенге заман. Илдә ниләр бар, дип сораган идегез. Тагын сорагыз...

М у с а *(паузадан соң)*. Мин кем... анда?

Ш а г ы й р ь. Бәлки, башта ил турында сөйләргәдер?

М у с а. Анысын беләм.

Ш а г ы й р ь. Беләсез?

М у с а. Туган илемнең киләчәген белмәсәм, мине монда үлем җәзасына хөкем итмәсләр иде. Илемнең киләчәгенә ышануымны гафу итмәделәр палачлар. Кызганыч, Туган илемдә кем булачагымны белә алмый дөньядан киттем. Әйтегез, мин кем анда?

Ш а г ы й р ь. Шагыйрь һәм герой.

М у с а. Ачыграк әйтегез.

Ш а г ы й р ь. Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил һәм Советлар Союзы Герое Муса Җәлилов.

М у с а. Әгәр дә сез, Шагыйрь, мине хыялыгызда терелткән икәнсез, минем белән шаяру өчен түгелдер дип өметләнәм.

Ш а г ы й р ь. Ышаныгыз, Муса абый. Ант итәм. Антның ни икәнен сез беләсез.

М у с а. Димәк, шигырьләрем Туган илгә кайтып җитте? Димәк, миңа ышандылар?

Ш а г ы й р ь. Илдә сезнең шигырьләрне укымаган кеше юк. Гомер юлыгыз өйрәнелгән.

М у с а. Мондагысы дамы?

Ш а г ы й р ь. Әйе. Германия дә инде башка Германия.

М у с а. Мин аның шулай буласына ышандым, Шагыйрь. Шигырьләремнең генә илгә кайтып җитүенә өметем аз иде. Димәк?.. Укы, Шагыйрь, әгәр алдашмасаң, минем тоткынлыкта язганнарымнан бер генә строфаны булса да укы.

Ш а г ы й р ь. Әкияттәге серле йомгак булып,
Җырым калды сүтелеп юлымда.
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда.

М у с а *(әсәрләнеп)*. Рәхмәт! Рәхмәт, туган! Димәк?! *(Рәшәткәләргә тотына-тотына, сәхнә буйлап йөри.)* Ишетәсезме?! Ишетәсезме?! Киләчәк буын шагыйре минем шигыремне яттан сөйли. Ишетәсезме?! Кемнәр миңа ышанмаган иде, ишетегез! Муса исән! Исән Муса Җәлил! *(Шагыйрь каршына тезләнеп.)* Рәхмәт, дустым.

Ш а г ы й р ь. Нишлисез? Мин сезнең алда тезләнергә тиеш.

М у с а. И-их, туган!.. Тезләндерергә теләделәр — тезләнмәдем. Рөхсәт ит, ятып ауныйм каршыңда. Укы, Шагыйрь, авырсынмасаң укы тагын... Бер генә юл.

Ш а г ы й р ь. Күрше кызы Хәдичә,
Шулай гадәттәгечә,
Озак йөреп бакчада,
Кичегеп кайтты кичә.

Муса *(аптырап-шатланып)*. Аны да беләсез?! *(Дәвам итә.)*

Каравылчы карт аның
Ишетмәгән кайтканын...

Күз алдына китерәсезме, туган?.. Кыз койма аша сикерә. Күлмәк итәге, кадакка эләгеп, шытырдап ертыла. Күз алдына китерәсеңме, кызның төп-төз, ап-ак ботлары ертык итәктән ялт-йолт күренеп кала. Кайсы ир күреп сокланмас. Матур кызларга ертык итәк тә килешә. Әгәр дә шундый мода чыкса, мин, мәсәлән, һич кенә дә каршы килмәс идем. Рәхмәт сиңа, Шагыйрь дустым. Үзең ниләр язасың? Сөйлә берсен.

Ш а г ы й р ь. Сезгә укырлык шигырьләрем юктыр минем.

М у с а. Татар шагыйрьләре шулай инде алар, һәрвакыт кирәгеннән артык тыйнак булдылар. Киләчәк шагыйрьләренең укымаслык шигырь язуларына ышанмыйм мин. Укы, оялма. Тыңлыйсым, ишетәсем килә. Уегызда, күңелегездә ни икән, беләсем килә.

Ш а г ы й р ь. Кичерегез, Муса абый, сезгә укырлык шигырь яза алсам укырмын. Бу юлы мәҗбүр итмәгез.

М у с а. Мәҗбүр? Шагыйрьләр телендә андый сүз буламы? Ә без бер-беребезгә укый идек. Җыелышып укый идек. Арада пешеп җитмәгән шигырьләр дә булгандыр, барыбер укый идек. Дуслар... Исәннәрме алар минем дуслар? Сөйлә, Шагыйрь. Кызганма вакытыңны. Ил турында, туганнар, дуслар турында сөйлә. Ишетеп китим...

Музыкаль пауза. Ут сүнеп ала. Музыка акрыная.

Рәхмәт, туган. Тагын ниләр сорыйм икән? Җыр яратасыңмы, Шагыйрь?

Ш а г ы й р ь. Тыңларга яратам.

М у с а. Минем кебек, алайса. Кеше җырлаганны гына тыңларга димәгән. Мәҗлесләрдә сузып торып җибәрә идек, начар җырлыйсың дип, куып чыгарганнары булмады. Әйдә, башладык.

Ш а г ы й р ь *(тирә-якка каранып)*. Биредә... Әллә ничек...

Муса. Җырга төрмә юк, Шагыйрь. *(Әкрен генә җыр башлый.)*

Аңа Шагыйрь дә кушыла.

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгърем,

Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин.
Таң атканда уянырмын,
Җилкәмә шәл салырмын.
Таң шикелле балкып
Тиздән кайтыр булсаң,
Каршы чыгып алырмын.

*(Муса җыр барганда сәхнә алдына килә. Җырның соңгы юлын музыкасыз гына кабатлый.)* Каршы чыгып алырмын... Сез бераз гына ялгышкансыз, Шагыйрь дустым. Хыялыгызда терелткәнсез икән, очрашу урыны итеп төрмә камерасын түгел, чәчәкле болынны сайларга иде.

Шагыйрь. Гафу итегез, сезне нәкъ шушында очратасым килде.

Муса. Фашист төрмәләрен күргәнегез бармы сезнең?

Шагыйрь. Рәсемнәрдә генә.

Муса. Шуңа күрә ул сезгә кызыктыр. Экзотика. Күрмәгәннең күрәсе килә. Тик белергә тиеш сез — кабер белән төрмәне күрмәгән кешенең дә күрергә теләге юк.

Шагыйрь. Кичерегез...

Муса. Зарар юк. Сез миңа шатлык алып килдегез. Сез алып килгән шатлык чәчәкле болында, бәлки, бу чаклы ук татлы булмас иде.

Шагыйрь. Муса... Сезгә шатлык алып килүем белән мин бәхетле. Тик сезне эзләвемнең тагын бер сәбәбе бар.

Муса. Тыңлыйм, Шагыйрь дустым.

Шагыйрь. Мин сезнең турыда язарга уйлыйм.

Муса *(паузадан соң)*. Ничек итеп һәм кем итеп?

Шагыйрь. Герой итеп һәм Шагыйрь итеп. Мин аңа лаек түгел дисәгез, тыйнаклык булмас — кылану булыр. Халык сезне шулай итеп таныган һәм шулай да. Сезнең турыда романнар, пьесалар, поэмалар, гыйльми хезмәтләр язылган, фильмнар куелган.

Муса. Ул хәбәрегез өчен дә рәхмәт. Әмма, туган, адәм баласы ул шундый җан иясе: барыбер мин аңа лаек микән дип уйлаячак. Ул кылану түгел, аңлагыз.

Шагыйрь. Бу хакта бүтән сөйләшмибез. Язылган, димәк, лаек. Миңа сезнең белән язылачак әйбер турында сөйләшергә кирәк. Әлегә хәтле язылганнарга тел-теш

тидерергә җыенмыйм. Мин аларны сокланып укыдым. Ләкин мин үзем Муса Җәлил образын иҗат итәргә уйлыйм.

М у с а. Миннән ни таләп ителәә инде? Сезне шаккатырырлык берәр батырлык эшләргә тиешме мин?

Ш а г ы й р ь. Зинһар, көлмәгез. Шагыйрьне шагыйрь аңларга тиеш. Аңларга тырышыгыз мине. Мин сезнең киңәшегезгә мохтаҗ. Мин сезне әлегә чаклы язылганча итеп язасым килми. Язылганнарны кабатлаудан ни мәгънә? Ә менә ничек язарга — белмим.

М у с а. Белмәгәч язмагыз.

Ш а г ы й р ь. Мин язарга тиеш. Ул — минем вөҗданым, намусым эше. Язар өчен мин бер сорауга җавап табарга тиеш. Нәрсәдә сезнең бөеклегегез? Сез — бөек, анысы бәхәссез. Әмма нинди көч сезне бөек иткән? Сез — гапгади адәм баласы. Шул ук вакытта гадилекнең чиген узып бөеклеккә ирешкән зат. Гадилекне һәм бөеклекне ничек бәйләргә? Ничек сурәтләргә?

М у с а. Беләсезме, Шагыйрь дустым, мин мәдрәсәдә укыганда мөгаллимнәр дә ашыйлар микән дип аптырый идем. Чөнки алар минем өчен җир кешеләре түгел сыман иде. Әүлиялар иде алар минем өчен. Үсә төшкәч ачыкланды — ашыйлар икән һәм адәм балаларына хас бүтән эшләрне дә эшлиләр икән.

Ш а г ы й р ь. Мин сездән әүлия ясарга җыенмыйм. Сез аңлагыз мине, аңларга тырышыгыз. Ярдәм итегез. Сезне аңлыйсым килә. Җаныгызны, рухыгызны аңларга телим. Сезне бөеклеккә күтәргән көчнең сере кайда? Шуны эзләп азапланам. Үземне сезнең урынга да куеп карадым. Ләкин барыбер очына чыга алмадым. Сез эшләгән эшләрнең кайберләрен эшләргә дә буладыр. Ләкин төрмәдә үлем җәзасы көткәндә ничек инде шаян шигырь язып утырырга мөмкин? Палач балтасы астына башны салганда ничек елмаерга мөмкин? Аңлый алмыйм мин боларны, Муса абый, акылыма сыймый.

М у с а. Акылыгызга сыймаган әйбер турында язмагыз.

Ш а г ы й р ь. Мин язарга тиеш.

М у с а. Акылга сыймаган нәрсәләр турында язу — алдашу. Үзеңне һәм кешеләрне алдау.

Ш а г ы й р ь. Сез миңа ярдәм итегез, аңлатыгыз.

М у с а. Сезгә ничә яшь?

Ш а г ы й р ь. Егерме биш.

М у с а. Егерме биш?! Биргән сорауларыгызга караганда, мин сезне унбиш яшьтә дип уйлаган идем.

Ш а г ы й р ь. Ләкин…

М у с а. Безгә хушлашырга вакыт.

Ш а г ы й р ь. Муса абый… Муса Җәлил… Аңлатыгыз… Нигә эндәшмисез? Үтенәм сездән! Мин язарга тиеш.

М у с а югала.

Муса абый! Мин җавап табарга тиеш, ишетәсезме?! *(Сәхнә алдына килеп.)* Табарга тиеш.

Шулчак Л а н ф р е д и н и пәйда була. Килеп, Шагыйрьнең иңенә кулын куя. Шагыйрь тиз генә аңа борылып карый.

Л а н ф р е д и н и. Мин – Рениеро Ланфредини. Италия гражданины. Муса Җәлил белән үлемгә хөкем ителгәннәр камерасында бергә утырдык. Сез мине исегезгә төшердегез, һәм мин килергә кирәк дип санадым.

Ш а г ы й р ь. Синьор Ланфредини, ярдәм итегез миңа. Сөйләгез миңа Җәлил турында.

Л а н ф р е д и н и. Муса Җәлил турында язганнарым сездә басылып чыкты. Укыгансыздыр.

Ш а г ы й р ь. Әлбәттә. Сез «Татарлар елмаеп үлделәр» дип язгансыз, моны ничек аңларга?

Л а н ф р е д и н и. Туры мәгънәсендә. Төрмә рухание падре Юрытко үз күзләре белән күргәнне миңа сөйләде. Җәза урынына алып килгәндә Муса Җәлилнең иптәшләренә карап елмайганын үзе күргән падре Юрытко. Иптәшләре Мусага елмаеп җавап биргәннәр.

Ш а г ы й р ь. Үлем алдыннан елмаюны мин аңлап бетермим.

Л а н ф р е д и н и. Мин дә аңлап бетермәдем. Падре Юрытко үзе дә гаҗәпләнгән иде. Бәлки, ул елмаю берсен берсе юату булгандыр. Үлемгә хөкем ителгәннәр юатуга мохтаҗ була бит.

Ш а г ы й р ь. Үлем алдыннан елмаю өчен ниндидер… көч кирәк…

Л а н ф р е д и н и. Ниндидер түгел, илаһи көч кирәк. Сез дингә ышанмыйсыздыр, шуңа күрә ул сүзне әйтергә яхшысынмыйсыздыр. Муса да атеист иде, әмма без уртак тел таба идек.

Ш а г ы й р ь. Синьор Ланфредини, кайдан килгән Мусага һәм аның көрәштәшләренә андый көч? Кичерегез, Ходайдан дип әйтсәгез, ышанмаячакмын.

Л а н ф р е д и н и. Мин сезне ышандырырга җыенмыйм да. Атеистлар белән бәхәскә кермим… Мин үлем камерасында Алладан ярдәм сорап, коткаруын үтенеп яшәдем. Муса яза иде. Көчле рухлы кеше иде ул. Төшенкелеккә бирелеп, кылган эшләре өчен үкенгәнен хәтерләмим. Үкенмәү зур батырлык сорый. Муса үткәннәр турында түгел, киләчәк турында күбрәк сөйли иде. Хәтта ул миннән итальян телен өйрәнде. Үләсе кешегә нигә кирәк тел өйрәнү? Киләчәк белән яшәде ул.

Ш а г ы й р ь. Каян килгән аңа көчле рух?

Л а н ф р е д и н и. Кеше – серләр хәзинәсе.

Ш а г ы й р ь. Сез аны күргән. Аңлатыгыз.

Л а н ф р е д и н и. Әйе, мин аны озак вакыт күрдем, ләкин, дөресен әйтәм, сезнең соравыгызга җавап бирә алмамдыр. Мин үзем дә аңа гаҗәпләнә идем.

Ш а г ы й р ь. Мусаның көрәштәшләре аңлата алырмы?

Л а н ф р е д и н и. Бәлки. Шәхесне дөрес бәяләүче шәхес үзе түгел, аның кылган эшләрен күргән, белгән кешеләр. Аның иптәшләре дә көчле рухлылар иде. Елмаю алар өчен, ихтимал, гадәти эштер, әмма мин үзем җәза алдыннан елмая алмас идем. Шулай да сезгә бер киңәшем бар.

Ш а г ы й р ь. Зинһар, әйтегез, синьор Ланфредини.

Л а н ф р е д и н и. Муса һәм аның иптәшләренең көчен, ул көчнең чыганагын белергә теләсәгез, аларны үлемгә хөкем итүчеләр белән сөйләшегез. Алар белергә тиеш. Әгәр дә бер кеше икенче кешене үлемгә илтә, үлемгә хөкем итә икән, ул аның кем икәнлеген бик яхшы белгәнгә шулай эшли, аңардан курка.

Ш а г ы й р ь. Ләкин… ләкин бу фәлсәфә берьяклы.

Л а н ф р е д и н и. Кызганычка каршы, мин сезгә башкача ярдәм итә алмыйм. *(Югала.)*

Ш а г ы й р ь *(Ланфредини сүзләрен кабатлый)*. Әгәр дә бер кеше икенче кешене үлемгә илтә, үлемгә хөкем итә икән, ул аның кем икәнлеген яхшы белгәнгә шулай эшли. Мусаны үлемгә илтүчеләр, хөкем итүчеләр…

Сәхнәдә рейхсминистр Розенберг кабинеты пәйда була. Ш а г ы й р ь шул кабинетка кереп карап йөри дә урындыкларның берсенә утыра. Түрдәге өстәлгә карап тора. Өстәл артында Р о з е н б е р г күренә. Шагыйрь белән Розенберг берара бер-берсенә карап утыралар.

Ш а г ы й р ь. Гаҗәпләнмәгез, Альфред Розенберг. Сакчыларыгызны чакырырга да ашыкмагыз — алар кермәячәк. Без икәүдән-икәү генә. Очрашуыбызның сәбәбе — мин сезне хыялымда терелттем. Сезне күрәсем килгәнгә түгел, сорыйсы сорауларым бар. Шуны да белегез: сез минем белән сөйләшергә мәҗбүр булачаксыз. Сөйләшмәү сезнең ихтыярда түгел.

Р о з е н б е р г. Сез кем?

Ш а г ы й р ь . Мин — Советлар Союзы гражданины... Нигә чыраегызны сыттыгыз, ошамыймы?

Р о з е н б е р г. Сиңа миннән ни кирәк?

Ш а г ы й р ь. Доктор Розенберг! Сез үзегезне югары культурага ия дип саный идегез. Кешегә «син» дип төртеп сөйләү сезгә килешми.

Р о з е н б е р г. Кеше? Синме кеше? Сезме кешеләр? Кыргый җанварлар иле Россиядә — кешеләр... *(Шашып көлә.)*

Ш а г ы й р ь. Көлеп бетердегезме, рейхсминистр?

Р о з е н б е р г. Кешеләр... О-о, бөек Алла, үзен яраткан җир йөзен нинди мәсхәрәгә дучар иттең? Һәрбер бөҗәк, һәрбер унтерменш үзен кеше дип атый... *(Үксеп еларга тотына.)*

Ш а г ы й р ь. Җылап бетердегезме, рейхсминистр? Инде сорауларыма җавап бирергә әзерләнегез.

Р о з е н б е р г *(үзен үзе кулга алып)*. Бирегез сорауларыгызны. Бөек немец халкы кыргый азиатлар каршында җавап тотар көнгә калган икән, сорагыз.

Ш а г ы й р ь. Немец халкы белән үзегезне бутамагыз, фашист Розенберг.

Р о з е н б е р г *(«сез» сүзенә басым ясап)*. Сезне ни кызыксындыра?

Ш а г ы й р ь. Ни түгел — кем. Сез — фашистлар оккупацияләгән Көнчыгыш өлкәләрнең рейхсминистры. Бәлки, аны беләсездер. Очрашкан булуыгыз да ихтимал.

Р о з е н б е р г. Кем ул?

Ш а г ы й р ь. Муса Җәлил. Шагыйрь.

Р о з е н б е р г. Муса Җәлил... Шагыйрь?.. Күргәнем, ишеткәнем булмады.

Ш а г ы й р ь. Уйлап карагыз, бәлки, хәтерегезгә төшерерсез.

Р о з е н б е р г. Ә ул нишләгән?

Ш а г ы й р ь. Фашизмга каршы көрәшкән.

Розенберг. Бөек Германиянең дошманнары арасында шагыйрьләр булуы да ихтимал, бөтенесен кем хәтерләп бетергән. Бөек Германиянең рейхсминистры ниндидер шагыйрьләр белән очрашып, салонда шигырьләр тыңлап утырган дип уйласагыз — ялгышасыз. Сездә шагыйрь дип аталганнар, безнең өчен...

Шагыйрь. Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләрен Германиянең Империя суды хөкем итә. Ялгышмасам, Империя суды теләсә кемне хөкем итеп вакланмагандыр.

Розенберг. Сез ялгышмыйсыз. Империя суды бөек Германиягә каршы зур җинаять ясаган кешеләрне генә хөкемгә тартты. Кем дидегез исемен шагыйрегезнең?

Шагыйрь. Муса Җәлил...

Розенберг. Муса... Җәлил... Юк, хәтерләмим... Күрәсең, җинаяте чыннан да зур булган.

Шагыйрь. Батырлыгы.

Розенберг. Вәхшиләрнең батырлыгы цивилизациягә ирешкән раса алдында һәрвакыт җинаять. Вәхшиләрнең батырлыгы кешелек дөньясының үсешен тоткарлый. Вакытлыча тоткарлый, әлбәттә, әмма тоткарлый. Әйе, Россия һәм андагы вәхшиләрнең батырлыгы цивилизация өчен бик кыйммәткә төште. Бөек Германия, бөек немец расасы алга баруыннан вакытлыча булса да туктап калды. Менә кайда фаҗига! Һәрбер вәхши, һәрбер унтерменш, дөньяга туу белән үк, батырлык эшләргә өлгергәнче үтерелә, юк ителә барырга тиеш иде. Вәхшиләрнең үрчүе тарих өчен афәт.

Шагыйрь *(утырган урыныннан сикереп торып)*. Сез!.. Югары раса вәкиле фашист Альфред Розенберг! Басыгыз! Мин сезгә боерам! Сезнең тарафтан юк ителергә тиешле бер «вәхши» сезгә боера — басыгыз!

Розенберг *(урыныннан торып)*. Кызганычка каршы, мин сез кушканны үтәргә тиеш. Хыялыгызда сез минем белән теләсә ни эшли аласыз.

Шагыйрь. Кыланмагыз, Розенберг. Нюрнберг процессы хыял түгел иде. Тормышның үзе иде. Сез анда хөкем карарын басып тыңладыгыз. Цивилизация!.. Тарих!.. Кинооператорлар сезнең кыяфәтегезне тарихта калдырыр өчен кинога төшерергә тотынгач, сез объективка артыгыз белән борылдыгыз. Нәрсә, вәхшиләрне санга сукмавыгыз идеме? Әллә экрандагы вәхши йөзегезгә миллионнарның нәфрәт белән каравыннан курык-

тыгызмы? Сезнең хәтерегез кыска — сез Муса Җәлилне хәтерләмисез. Сез «бөек идеяләр» белән мәшгуль идегез. Ә милли легионнар? Шулар арасында татар легионы. Ул бит сезнең идея, Розенберг. «Вәхшиләр»дән легион төзеп маташу ахмаклык түгел идемени?

Розенберг. Ул безнең ялгышыбыз иде.

Шагыйрь. Ә «вәхшиләр» ялгышмадылар. Үзләренең Ватанына каршы корал күтәрмәделәр. Сез аларны вәхшилеккә өндәдегез, аларның намусы вәхшилекне кабул итмәде.

Розенберг. Сезгә миннән ни кирәк?

Шагыйрь. Муса Җәлил һәм аның кебек батырларның батырлыгы нәрсәдә? Ул батырлыкның чыганагы кайда?

Розенберг. Сез мине ахмаклыкта гаепләдегез. Димәк, сез үзегезне акыллыга саныйсыз. Үз соравыгызга үзегез җавап табарга тиеш.

Шагыйрь. Мин сездән ишетергә телим.

Розенберг. Менә анысы инде чын ахмаклык.

Шагыйрь. Бәлки. Кешеләрнең батырлыгы турында уйланганда сезне искә төшерүем ахмаклыктыр. Нюрнбергтагы Халыкара Трибунал карары буенча сезне дар агачы янына алып килгәч, сез калтырандыгыз, соңгы сүзегезне дә әйтә алмадыгыз. Ләкин мин сезне барыбер сорауларыма җавап бирергә мәҗбүр итәм. Әйтегез, сез вәхши дип уйлаганнар ни өчен сездән көчлерәк булып чыктылар? Расалар мәсьәләсендә үзен теоретик дип санаган доктор Розенберг ул хакта уйлангандыр бит.

Розенберг. Күрәм, син... Гафу итегез, сез шактый ук үҗәт. Әйе, үҗәтлек — вәхшиләргә хас сыйфат. Үҗәтләр һәм фанатиклар. Кызганычка каршы, фанатиклар кайвакыт уңышка ирешәләр. Без Россия кыргыйларының фанатизмын дөрес бәяләп бетермәдек. Бер дистә фанатикны юк итеп була, «ватан» сүзе белән барлы-юклы акылы агуланган ике йөз миллион фанатикны юк итәргә, күрәсең, әзер булмаганбыз.

Шагыйрь. Димәк, шагыйрь Муса Җәлилнең батырлыгы — фанатизм?

Розенберг. Фанатиклар шагыйрендә фанатизм бациллалары күбрәк була. Канәгатьме сез минем җавабымнан? *(Югала.)*

Шагыйрь. Фанатизм?.. Муса Җәлил фанатик?..

Л а н ф р е д и н и күренә.

Л а н ф р е д и н и. Юк, ул фанатик түгел иде, фанатизм аңа чит нәрсә иде. Аек акыллы, ни кылганын, ни эшләгәнен белеп эшли иде ул... Юк, ул фанатик түгел иде. Фанатиклар герой була алмыйлар. Рухы көчле иде Җәлилнең.

Ш а г ы й р ь. Кызын, әнисен, хатынын искә төшереп сөйләгәндә күзләренә мөлдерәмә яшь тула иде, дип язасыз. Көчле рухлы кешенең, җәзага барганда елмая алган адәм баласының җылавы ничектер сәер.

Л а н ф р е д и н и. Мин җылый иде дип язмадым. Җылау — йомшаклык билгесе. Нечкә күңелле, рухы көчлеләрнең күз яше тышка агып чыкмый. Нечкә күңелле, көчле ихтыярлы иде Муса, фанатик түгел иде.

Ш ә ф и  А л м а с  т а в ы ш ы. Фанатик иде Мусагыз!..

Ш ә ф и  А л м а с күренә.

Л а н ф р е д и н и. Түгел, түгел!.. Мең тапкыр кабатлый алам.

А л м а с. Саташканнар иде алар барысы да...

Л а н ф р е д и н и. Алла исеме белән ант итәм... *(Югала.)*

Алмас Шагыйрь янына килә.

Ш а г ы й р ь. Танымыйсызмы?

А л м а с. Танымыйм шул. Кем сез?

Ш а г ы й р ь. Мин Казаннан.

А л м а с. Казаннан?.. *(Текәлебрәк карый.)*

Ш а г ы й р ь. Таныргa азапланмагыз. Сез мине белмисез, мин сезне ишетеп беләм. Мин сезне хыялымда терелттем.

А л м а с. Кем инде мин сезнең хыялыгызда?

Ш а г ы й р ь. Оешмаган Идел-Урал Штатының сайланмаган президенты.

А л м а с. Ә нигә аны мыскыллап, көлеп әйтәсез?

Ш а г ы й р ь. Чөнки без аны көлеп искә алабыз.

А л м а с. Кем инде ул сез?

Ш а г ы й р ь. Бүгенге Казанда яшәүчеләр. Мин, мәсәлән.

А л м а с. Син кем соң?

Ш а г ы й р ь. Шагыйрь.

А л м а с. Аңлашылды болай булгач.

Ш а г ы й р ь. Нәрсә аңлашылды?

А л м а с. Җәллад Сталинны мактап такмак язучы.

Ш а г ы й р ь. Мин андый шигырь язмадым.

А л м а с. Үлеп өлгермәсә, язган була идең... Миннән сиңа ни кирәк?

Ш а г ы й р ь. Сез Муса Җәлилне фанатик дидегез.

А л м а с. Сез барыгыз да фанатиклар. Потка табынучы мәҗүсиләр. Син коммунистмы?

Ш а г ы й р ь. Коммунист.

А л м а с. Алласыз мескеннәр. Саташканнар. Милләтсез, кыйбласыз кыргыйлар.

Ш а г ы й р ь. Муса — татар шагыйре.

А л м а с. Татар булгач, татар өчен көрәшергә кирәк. Ул үз гражданнарын җәзалап үтерүче илне ватаным дип атады. Аны ят иткән ил белән горурланды. Шул кыргыйлар иле өчен үлде.

Ш а г ы й р ь. Ул антына тугрылыклы калды. Гитлерга синең сыман сатылмады.

А л м а с. Сиңа ничә яшь?

Ш а г ы й р ь. Егерме биш.

А л м а с. Иң элек борыныңны сөртергә өйрән. Аннан соң сатылу турында акыл сатарсың. Сез сатылмадыгыз, әлбәттә. Сез саттыгыз гына. Милләтне саттыгыз.

Ш а г ы й р ь. Сүзегезне үлчәп сөйләгез. Без синең ише сәүдәгәр түгел.

А л м а с. Әйе, мин — сәүдәгәр. Мин кызыл мал белән сәүдә итәм. Сез — милләт белән.

Ш а г ы й р ь. Милләт турында кайгыру өчен сәүдәгәр булу гына җитми.

А л м а с. Кайгыртырга тиешле кешеләрнең җанына, йөрәгенә йон үскәч, изге эшкә сәүдәгәрләр алына.

Ш а г ы й р ь. Димәк, Муса Җәлил фанатик, саташкан.

А л м а с. Совет власте дип саташкан.

Ш а г ы й р ь. Батыр түгел идемени?

А л м а с. Саташкан кеше үз сүзеннән кайтмый торган була. Сүзем юк — йөрәкле кеше иде Муса. Бүтәннәре дә йөрәкле иде. Әрәм булдылар.

Ш а г ы й р ь. Илне сатсалар, исән калган булырлар идеме?

А л м а с. Нинди ил? Сталин ни, Гитлер ни. Икесе дә бер. Милләт турында уйларга иде, милләт турында.

Шуның өчен шәһит китәргә иде. Бар, кит киләчәгеңә, йөрмә монда иснәнеп. Милләткә кабер казучылар. Кыйбласызлар. Юлбасарлар илен ватан дип атаучылар.

Шагыйрь. Җитте! Югал күз алдымнан!

Алмас. Югалам. Сез дә югалачаксыз. Эзләп таба алмаслык итәчәкләр сезне. Улларыгыз — урыс, кызларыгыз марҗа булачак. *(Югала.)*

Шагыйрь уйланып сәхнә алдына килә башлый. Шулчак әкрен генә «Сибелә чәчәк» көе яңгырый. Шагыйрь туктап кала. Көй көчлерәк яңгырый. Шагыйрь ашыгып көйнең кай тарафтан ишетелгәнен эзли. Көй төрмә рәшәткәсе артында яңгырый икән. Тонык яктылык эчендә, рәшәткә артында — җәлилчеләр. Шагыйрь рәшәткә янына килә. Көй җырга әйләнә — җәлилчеләр җырлый.

Гөлбакчага керәмсең,
Гөлбакчага керәмсең лә,
Гөл чәчәген өзәмсең.
Өзелгән гөл чәчәге күк,
Аерылуны сизәмсең?
Сибелә чәчәк, җилләр лә искәндә,
Өзелә үзәк, исләремә төшкәндә.

Шагыйрь рәшәткәләрне каерып ача. Сәхнә яктыра төшә. Сәхнәдә Абдулла Алиш, Гайнан Кормаш, Абдулла Батталов, Фуат Булатов, Әхмәт Симаев, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Фуат Сәйфелмөлеков, Әхәт Аднашев, Сәлим Бохаров, түгәрәкләнеп утырган килеш, «Сибелә чәчәк»не җырлыйлар. Бер читтәрәк Муса Җәлил утыра. Кулында — карандаш белән бәләкәй генә блокнот. Шагыйрь Муса янына килә. Көй әкрен генә дәвам итә.

Шагыйрь. Гафу итегез, Муса абый... Мин тагын сезнең янга килдем.

Муса. Эшләр ничек, киләчәк егете?

Шагыйрь. Яза алмыйм. Гафу итегез...

Муса. Яза алмаган өчен нигә миннән гафу үтенәсез?

Шагыйрь. Беләсез, сезнең турыда язарга алынган идем. Язганнарымны ертып ташлый барам. Коры сүзләр генә, хис юк.

Муса. Була андый чаклар. Димәк, сез әзер түгел. Акылыгыз эшли, йөрәгегез тик тора.

Шагыйрь. Юк-юк. Мин нишләргә белмим, бәргәләнәм.

М у с а. Бәргәләнү — егет эше түгел.

Ш а г ы й р ь. Сез менә язасыз. Үлем карары чыккан, палачның балтасы күтәрелгән — язасыз. Мин иҗат йортларына, санаторийларга барып язып карыйм — чыкмый.

М у с а. Әллә урыннарны алыштырабызмы? Бәлки, чыгар?

Ш а г ы й р ь. Шаяртмагыз. Әллә вакландык микән без, Муса абый? Бәлки, без рухыбыз белән, иманыбызның ныклыгы белән сездән бик түбәндер? Сезне бөек иткән көч бездә юктыр? Уйлануларыбыз да чын түгелдер, кылану гынадыр? Әллә соң безгә ваемсызлык, үшәнлек чире йоктымы? Кеше рухының көчен, кешенең иле, халкы алдындагы иң изге бурычларын аңламас хәлгә җиттекме? Яшәүнең мәгънәсе тарайдымы? Сезнең фидакярлеккә авыз ерыбрак карарга өйрәндекме? Тормыштан кәмит эзләргә генә күнегеп барабызмы? Яшәү бит бүген дә җиңел түгел, яшәү бервакытта да җиңел булмаячак. Тормыш бездән дә көн саен имтихан ала. Сездәге рух булмаса, бөек имтихан алдында каушап калмабызмы?

М у с а. Ничаклы сорау.

Ш а г ы й р ь. Мин ул сорауларга җавапны сезнең тормыштан эзлим.

М у с а. «Без» дип сөйләдегез, кемнәр соң, ул «без»?

Ш а г ы й р ь. Безнең буын.

М у с а. Буын исеменнән сөйләргә ашыкмагыз. «Мин, мин, мин» дип шапырынучыларга — көлеп, без, без, без диючеләргә шикләнебрәк карыйм мин. «Без, без, без» дип такмакта гына әйтәләр. Хәтерлисезме: без, без, без идек, без унике кыз идек…

Ш а г ы й р ь. Мин сезнең турыда язарга тиеш, Муса абый!

М у с а. Тиеш дип саныйсыз икән, языгыз.

Ш а г ы й р ь. Ләкин…

М у с а. Ләкин дисез икән, язмый торыгыз.

Ш а г ы й р ь. Кызык сез…

М у с а. Шундый инде мин.

Ш а г ы й р ь. Уйлыйм, эзләнәм, эзләнгән саен…

М у с а. Тагын эзләнегез…*(Язуын дәвам итә.)*

Ш а г ы й р ь. Сез, яшисем килә, дип яздыгыз…

М у с а. Яздым. *(Язганын укый.)*

Юк, үләсем килми минем бер дә,
Бик яшисем килә.

Яшисем килә. Кемнең соң яшисе килми? Гомер бер генә бирелә бит. Кояшлы, Айлы җир өстендә, якты дөньяда яшәп каласы килә. Бер генә көн булса да яшәп каласы килә. Яшәүдән дә рәхәтрәк ни бар? Яшисем килә, дустым. Ярты гына сәгать булса да Иделгә карап торасым, зәңгәр суында битемне юасым, комында ятып ауныйсым килә. Ун гына минут булса да каләмдәш дусларым уртасында утырасым, аларның тавышларын ишетәсем килә, парк аллеясы буйлап тәкәббер генә атлап баручы яшь бер сылудан «Исемең ничек, чибәрем?» дип сорыйсым килә. Ашыкмый гына, Кремль курантларының сукканын тыңлап, Кызыл мәйданнан узасым килә. Яшисе килә, дустым, яшисе килә. Төшләремдә мин һәрвакыт киң болын, чәчәк диңгезен, нәни кызымны күрәм.

Ш а г ы й р ь. Сез яши ала идегез.

М у с а. Ничек?

Ш а г ы й р ь. Ул дәһшәтле елларда гомерегезне саклап калу өчен мөмкинлекләр бар иде.

М у с а *(торып, Шагыйрьнең каршына баса)*. Мәсәлән?.. Бәлки, мин шыр чыккан җүләрмендер. Яле, өйрәтеп карале, киләчәктән килгән шигырь язучы, мин ничек гомеремне саклап кала идем?

Ш а г ы й р ь. Гафу итегез, илне сату бәрабәренә димим. Сезгә фронтка китмичә тылда калырга мөмкин иде, фронтта да тынычрак урын таба ала идегез. Вариантлар бар иде.

М у с а. Эх син, егет, егеткәй. Әзмәвердәй буй үстереп… Вариант!.. Вөҗдан, намус бер генә бит ул, энекәем, вариантлар юк. Миңа комачауламагыз, эшем бар. *(Утыра. Блокнотына ашыгып нидер яза.)*

Ш а г ы й р ь. Муса абый…

М у с а. Комачауламагыз.

Шагыйрь бер-берсенә сыенып утырган Алиш белән Кормаш янына килә. Аларның җырын, сөйләшкәннәрен тыңлап тора.

Гөлбакчага кердем мин,
Гөлбакчага кердем мин лә,
Гөл чәчәген өздем мин.

Өзелгән гөл чәчәге күк
Аерылуны сиздем мин.
Сибелә чәчәк, җилләр лә искәндә,
Өзелә үзәк, исләремә төшкәндә…

К о р м а ш. Нигә бу кайгылы җырны җырлыйбыз, Алиш абый?

А л и ш. Кайгылы түгел, Гайнан, моңлы. Җырның кайгылысы булмый, моңлысы гына була.

К о р м а ш. Моңлы дигән сүз кайгылы дигән сүздер инде ул.

А л и ш. Юк, Гайнан. Моңы булган кеше – бәхетле кеше. Бәхетле кеше кайгылы була алмый.

К о р м а ш. Рәхәт сезнең белән, Алиш абый, күңелне ял иттererлек сүзләр сөйлисез. Шулайдыр… Сез дөрес әйтәсездер, кешене моң яшәтәдер. Без бит кайгырып утырмыйбыз, димәк, җырыбыз да кайгылы түгел. Алиш абый, кинәт минем күңелемдә бер шик туды.

А л и ш. Нинди шик, Гайнан?

К о р м а ш. Фашистлар үзләренең ялгышларын төзәтмәсәләр ярар иде дим.

А л и ш. Нинди ялгыш?

К о р м а ш. Фашистлар безне үлем җәзасына хөкем итеп ялгыштылар.

А л и ш. Ни сөйлисең, Кормаш?

К о р м а ш. Әйе, әйе. Ялгыштылар. Әгәр дә фашист суды эшләгән эшләребезне вак итеп күрсәтеп, безне юри генә акласа, аклаулары турында язып чыксалар һәм безне иреккә җибәрсәләр, ни булыр иде?

А л и ш. Без көрәшебезне дәвам итәр идек.

К о р м а ш. Көрәшергә ирек бирмәсәләр? Әгәр без – фашист суды тарафыннан акланган кешеләр – исән-сау илгә кайтсак, кешеләрнең йөзенә ничек күренер идек? Аларны фашист суды аклады, дип төртеп күрсәтерләр иде безгә.

А л и ш. Әллә ниләр уйлап чыгарасың, Гайнан.

К о р м а ш. Мин күптән уйланам бу хакта. Ялгышларын төзәтмәсеннәр иде фашистлар. Безне аклый күрмәсеннәр иде. Минем өчен иң зур хурлык шул булачак. Без эшләгән эшләрне юкка чыгару булачак бит бу, Алиш абый. Янәсе, сезнең көрәшегез чүп тә түгел. Акыллары җитмәде фашистларның. Җәзаның иң авырын уйлап

таба алмадылар. Төзәтмәсеннәр иде ялгышларын. Әйдәгез әле, җырлыйк әле, Алиш абый!

Гөлбакчага керәмсең,
Гөлбакчага керәмсең лә,
Гөл чәчәген өзәмсең…

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәдә Шагыйрь ялгызы.

Шагыйрь. Иртә торсам да көтәм,
Кичен ятсам да көтәм,
Сезнең өчен ут йотам, –
Уйлап карагыз, балам.

Мусаның әнисе Рәхимә Җәлилованың балаларына язган шигъри хаты. Ана… Җәлилне дөньяга бүләк иткән Ана. Үз баласын анадан да яхшырак кем белә!

Сәхнәдә Мусаның әнисе пәйда була. Аңа 50–55 яшьләр. Ул әкрен генә үзе язган шигъри хатны көйләп укый.

Ана. Иртә торсам да көтәм,
Кичен ятсам да көтәм,
Сезнең өчен ут йотам, –
Уйлап карагыз, балам.
Көн дә иртә торамын,
Хатыгызны көтәмен,
Юксынып, аһ итәмен, –
Уйлап карагыз, балам.

Шагыйрь. Саумысыз!

Ана. Саумы-сәламәтме, балам?!

Шагыйрь. Мин сезгә ничек эндәшергә дә белмим.

Ана. «Рәхимә әбекәй» дип әйтсәң килешер, бәбкәм.

Шагыйрь. Юк, мин сезгә алай гади итеп эндәшә алмыйм.

Ана. Син үзең кем соң, балам?

Шагыйрь. Киләчәктән килдем сезнең янга.

А н а. Алай икән. Йомышың ни иде соң, бәбкәм?

Ш а г ы й р ь. Сез — Муса Җәлилне дөньяга бүләк иткән Ана.

А н а. Бүләк иттем дә менә, күрә алмый тилмерәм.

Ана күңеле — балада,
Бала күңеле — далада.
Шул сүз әле чамада, —
Уйлап карагыз, балам.

Үсәләр дә китеп югалалар, үсәләр дә китеп югалалар.

Ш а г ы й р ь. Балаларыгыз югалмады, бөек Ана.

А н а. Кайтмыйлар бит.

Ш а г ы й р ь. Исәннәре илгә хезмәт итә. Киткәннәре якты эз калдырып китте.

А н а. Муса улым кайларда йөри, белмисеңме?

Ш а г ы й р ь. Халык күңелендә. Сез дөньядан иртәрәк киттегез. Мусаның бөеклеккә ирешкәнен күрә алмый киттегез.

А н а. Рәхмәт әйт үзләренә, балам. Ил алдында әтиләрен, әниләрен хур итмәгәннәре өчен рәхмәт әйт.

Ш а г ы й р ь. Сөйләсәгез иде миңа Муса турында, бөек Ана.

А н а. Ни сөйлим... Тапкач та ак биләүләргә биләдем, күкрәк сөтемне имездем.

Ш а г ы й р ь. Сез аңа бөеклеккә юл күрсәткәнсез.

А н а. Юлны Ил күрсәтте аларга, балам. Мин бары тик, яхшы булыгыз, матур торыгыз, дип кенә әйтә килә идем.

Ш а г ы й р ь. Дәвам итегез. Сөйләгез Муса турында.

А н а. Ни сөйлим... Тапкач та ап-ак биләүгә биләдем, күкрәк сөтемне имездем.

Ш а г ы й р ь. Сез аны Илгә турылыклы булырга өйрәткәнсез.

А н а. Илгә турылыклы булырга аларны Ил өйрәтте, балам. Мин аларга, матур яшәгез, яхшы булыгыз, дип кенә әйтә килдем.

Ш а г ы й р ь. Дәвам итегез... Дәвам итегез, бөек Ана. Сөйләгез Муса турында.

А н а. Ни сөйлим... Тапкач та ап-ак биләүгә биләдем, күкрәк сөтемне имездем. Инде менә бер күрергә тилмерәм.

Ш а г ы й р ь. Телисезме, бөек Ана, мин сезне улыгыз белән күрештерәм.

А н а. Кайсы ана үз баласын күрәсе килмәс.
М у с а *(күренеп)*. Әнкәй…
А н а. Синме, Муса улым?
М у с а. Мин, әнкәй. *(Кинәт югала.)*
А н а. Улым…
Ш а г ы й р ь. Гафу итегез, бөек Ана. Күрештерәм, дидем. Күрешкәч сөйләштерергә сүзләр табалмыйм. Урынсыз сүз кулланып рухыгызны рәнҗетүдән куркам.
А н а. Минем өчен сүзләр эзләмә, бәбкәм, һәр ананың үз баласына гына әйтерлек үз сүзләре бар.
М у с а *(күренеп)*. Әнкәй…
А н а. Синме, Муса улым?
М у с а. Мин, әнкәй…
А н а. Улым…
М у с а. Әнкәй!
А н а. Чәчләреңне нигә агарттың, улым?
М у с а. Чәч агарыр өчен дә коелыр өчен инде ул, әнкәй.
А н а. Һаман шаянлыгыңны ташламагансың. Олы кеше бит инде син.
М у с а. Дөньясында уйнап-көлеп яшәгез, дип әйтә идең.
А н а. Җилбәзәк булырга өйрәтмәгәнмендер бит?
М у с а. Юк, әнкәй.
А н а. Кулыңа ни булды?
М у с а. Нишләгән?
А н а. Сул кулың күтәрелми түгелме соң?
М у с а. Кайвакытта кулларның күтәрелмәве яхшы ул, әнкәй. Куллары күтәрелү аркасында харап булганнарны күргәнем бар.
А н а. Дөресен әйт, нишләттең?
М у с а. Ялгыш егылдым… Син борчылма, озакламый төзәлә ул.
А н а. Алдыңа карап йөр дип күпме әйттем.
М у с а. Һәрвакыт алга карап йөрдем, әнкәй, артка караганым булмады.
А н а. Күлмәгеңнең якасы нишләп ертылган?
М у с а. Ертылмагандыр.
А н а. Алдашма. Кем ямады? Яканы шулай ямыйлармыни?
М у с а. Ямау түгел ул, әнкәй. Хәзер модасы шундый. Көяз бит мин, беләсең.

А н а. Миннән нидер яшерәсең, улым. Сине ниндидер бөеклеккә ирешкән, диделәр.

М у с а. Бөеклекнең ни икәнен белеп бетермәгәннәр әйтә аны, әнкәй.

А н а. Әллә нишләгәнсең син.

М у с а. Синең улың Мусага охшамаганмы әллә, әнкәй?

А н а. Охшавын охшаган да. Шулай да әллә ничек.

М у с а. Кеше үзгәрми тормый.

А н а. Ярый да яхшы якка үзгәрсәң.Ниләр эшләп йөрисең дип төпченмим. Үзең беләсеңдер. Бер-ике сүз әйтсәм, акыл өйрәтә дип ачуланма.

М у с а. Әнкәй…

А н а. Яхшы бул, матур яшә.

М у с а. Рәхмәт, әнкәй.

А н а. Илеңне, телеңне, халкыңны, моңыңны онытма. Үз моңын оныткан бүтәннәр моңын ишетми башлый. Иманыңнан яза күрмә. Боларны мин сиңа әйтәм, син бүтәннәргә әйт. Бүтәннәр үзләреннән соң килгәннәргә әйтеп калдырсын.

М у с а. Рәхмәт, әнкәй.

А н а. Язасыңмы?

М у с а. Язам, әнкәй.

А н а. Укып күрсәтәсеңме соң?

М у с а. Тик син борчыла күрмә, әнкәй, шигыремдә «үлем» дигән сүз бар.

А н а. Укы.

М у с а. Ничә тапкыр синең тырнагыңнан
Котылдым мин, үлем.
Беттем дигән чакта, тормыш тагын
Сузды миңа кулын.
Синең белән ләкин тартышудан
Һич бизмәде күңлем.
Батырам дигән саен, мин упкынның
Эченәрәк кердем.
Синең белән уйнау, беләм, үлем,
Күңелле эш түгел.
Җирдә тыныч, гамьсез көн итүдән
Бизәрмени күңел?
Мине әллә яшәү биздердеме,
Бу бунтарьлык нигә?
Юк, үләсем килми минем бер дә,
Бик яшисем килә.

Шигырьне Шагыйрь дәвам итә. М у с а һәм А н а югалалар.

Ш а г ы й р ь. Давыллардан әгәр читтә булсаң,
Шундый тыныч, аулак.
Юк, мин килдем сиңа давыл аша,
Чын тормышны даулап.
Әле менә тагын килеп ләктем
Синең тырнагыңа.
Богау салды җәллад бу җырларны
Язган кулларыма.
Нишлисең бит, бөек хаклык юлы
Шундый тайгак булгач?
Көрәшчегә бары җиңү яки
Үлем генә юлдаш.
Тиздән сүнәр, сүнгән йолдыз кебек
Соңгы яшәү көчем.
Үләм, ләкин бөек хаклык өчен,
Илем, халкым өчен...
Юк, үләсем килми минем бер дә,
Бик яшисем килә.

Әйе, кемнең яшисе килми. Яшәү белән үлем. Яшәү белән үлем.

Х а и н пәйда була. Як-ягына каранып тора.

Әй син, Хаин!

Х а и н. Сез миңа эндәшәсезме?

Ш а г ы й р ь. Әйе, сиңа... Якынрак кил.

Х а и н *(шикләнеп)*. Ә ни өчен мин якынрак килергә тиеш?

Ш а г ы й р ь. Синең яныңа минем барасым килмәгәнгә.

Х а и н. Сез кем?

Ш а г ы й р ь. Кемлегемне дә сиңа әйтергә теләмим. Сине беләм — шул җиткән.

Х а и н. Мине кайдан беләсез? Кем әйтте?

Ш а г ы й р ь. Сорауларны син миңа түгел, мин сиңа бирәм.

Х а и н *(куркып)*. Рәхим итегез, рәхим итегез...

Ш а г ы й р ь. Исемең дә билгеле, фамилияң дә, әтиеңнең исеме дә. Тик мин аларның берсен дә атамыйм. Синең исемне, фамилияңне йөрткән кешеләрне рәнҗетәсем килми. Мин сине сатлык җан дип атарга уйлаган идем,

«җан» сүзен кызгандым, куркак димәкче идем дә, «хаин» сүзе исемә төште. Сиңа шул исем ятышлырак тоелды. Ризамы андый исемгә?

Хаин. Күреп торам, минем ризалыгым сезгә кирәкми. Ләкин соравым өчен гафу итегез, төшенеп бетә алмыйм, мин ничек биредә?

Шагыйрь. Мин сине терелттем.

Хаин *(шатланып)*. Терелттегез? Рәхмәт сезгә! Минем шундый яшисем килгән иде. Һич кенә үләсем килмәгән иде. Яшисем килгән иде...

Шагыйрь. Куанма, Хаин, хыялымда гына терелттем.

Хаин. Хыялда?.. *(Уйланып тора да тагын шатлана.)* Барыбер рәхмәт сезгә. Димәк, мине искә төшергәнсез. Онытылырмын дип курыккан идем.

Шагыйрь. Кызганычка каршы, онытып булмый, онытырга ярамый. Синең кебекләр җир өстендә йөрмәсен өчен, сине искә төшереп торырга мәҗбүр кешеләр.

Хаин. Сез мине хөкем итәргә терелттегезме? Мине белгәч, мине бер тапкыр хөкем иткәннәрен дә беләсездер.

Шагыйрь. Беләм.

Хаин. Мине үлем җәзасына хөкем иттеләр.

Шагыйрь. Беләм.

Хаин. Ә минем шундый да яшисем килгән иде... Аңламадылар. Карамагыз миңа җирәнеп — үзем теләп килмәдем, чакырып алдыгыз. Нидер сорарга теләгән идегез, сорагыз.

Шагыйрь. Син Муса Җәлилне беләсеңме?

Хаин. Тагын... Тагын шул... Күпме сорарга мөмкин?

Шагыйрь. Беләсеңме?

Хаин. Беләм! Беләм!! Беләм!!! Барысын да беләм!.. Суд каршында сөйләдем, бөтенесен дә сөйләп бирдем, инде ни кирәк? Бер җинаять өчен ике тапкыр хөкем итмиләр.

Шагыйрь. Синең кебекләр мәңгелек суд каршында мәңге җавап тотачаклар. Кешеләр исән чакта сине хөкем итүдән туктамаячаклар. Саттым да оттым, тотылдым да җәзасын алдым, диючеләр ялгышалар. Син истерикага бирелмә. Мин синнән, Муса Җәлилне ничек саттың, дип сорамыйм. Ни өчен сатканың да билгеле.

Хаин. Бәлки, әйтерсез, ни өчен.

Шагыйрь. Өч тиенлек жаныңны саклап калыр өчен.

Х а и н. Гафу итегез. Табигать кешегә җан өләшкәндә миңа өч тиенлеген, сезгә ун тиенлеген бирми. Аның алдында барыбыз да тигез. Үз җанымның бәясен үзем генә беләм. Минем җаным үзем өчен бик кыйммәт. Шулай булгач нигә аны сакламаска. Әйтегез, кем сакламый җанын? Сезме? Берәүнең дә үләсе килми. Җанымны саклаган өчен мине берәүнең дә гаепләргә хакы юк.

Ш а г ы й р ь. Кара син, нинди дә була аласың икән.

Х а и н. Сез уйлаганча ук ахмак түгелмени? Тимәгез минем җаныма. Сатканмын икән җанымны — үземнеке. Һәркем үз җанын үзенчә сата. Сатылмаган адәм баласы юк бу җирдә. Чөнки дөнья — базар, базарда — сәүдә.

Ш а г ы й р ь. Син нәрсә, Мусаны сатылды димәкче буласыңмы?

Х а и н. Сатылган иде. Ниндидер идеяләргә сатылган иде. Ил, ватан, халык, туган җир... Барысы да ялган идеяләр. Адәм баласын алдар өчен уйлап чыгарылган идеяләр. Мин алданмадым. Сатканмын икән җанымны, иң кадерле нәрсә — яшәү бәрабәренә саттым. Сатылырга калган җанны ничек сатсаң да барыбер. Файда гына китерсен.

Ш а г ы й р ь. Кызык фәлсәфә. Ил, Ватан, Халык — синең өчен аңлаешсыз төшенчәләр, күрәсең. Аны аңлар өчен хаин түгел, кеше булырга кирәк. Ләкин Туган җир — конкрет. Синең кендегеңнең каны тамган җир.

Х а и н. Мин аны хәтерләмим.

Ш а г ы й р ь. Туган җиреңнең суын эчкәнең хәтерлисеңдер.

Х а и н. Су кайда да су.

Ш а г ы й р ь. Әмма син, Хаин, сугыштан соң качапоса булса да шул Туган җиреңә кайттың.

Х а и н *(паузадан соң)*. Шуңа күрә оттырдым.

Ш а г ы й р ь. Юк, сине барыбер тотарлар иде.

Х а и н. Озаграк яшәп калган булыр идем. Ә шулай да мин сезнең Мусаларыгыз, Кормашларыгыз, Алишларыгыздан күбрәк оттым — күбрәк яшәп калдым.

Ш а г ы й р ь. Куркып, дерелдәп яшәүдән ни мәгънә...

Х а и н. Ничек кенә булса да яшәү яшәү инде ул. Тик кызганыч, дөньяда җанның бәяләре үзгәрде. Германия җиңгән булса... Муса Җәлил дә сез бәяләгәнчә булмас иде. Югыйсә кай җире артык иде аның миннән?

Ш а г ы й р ь. Әллә Мусаны үзең белән тиң саныйсыңмы?

Х а и н. Ә нигә? Ул шигырь язды, минем бүтән нәрсәгә сәләтем булгандыр.

Ш а г ы й р ь. Муса — бөек. Син…

Х а и н. Кешене очраклы хәл бөек итә. Германия җиңгән булса, минем алда тезләнүчеләр дә аз булмас иде.

Ш а г ы й р ь. Бер мең дә тугыз йөз кырык өченче елда фашистларның җиңүенә ышандыңмы?

Х а и н *(паузадан соң)*. Мин бернигә дә ышанмадым.

Ш а г ы й р ь. Буталасың бит, Хаин. Сүзләреңнең җебе юк.

Х а и н. Сезнеңчә шулайдыр… Сез миңа теләсә ни әйтә аласыз. Эх, күрсәткән булыр идем мин сезгә җепнең кайда икәнен. Сез аны муеннарыгыздан капшап табар идегез. Минем каршымда әтәчләнәсез дә, анда кикригегез тиз шиңәр иде. Хәзер сезгә әтәчләнүе җиңел. Сезнең кебек калай әтәчләрнең әҗәл алдында шыңшыганнарын күргән кеше мин. Сугышка күкрәк кагып киттеләр дә, үлемне күргәч, куллары күтәрелде. Берәүнең дә үләсе килми.

Ш а г ы й р ь. Булды, Хаин!.. Җитте!.. Югал!..

Х а и н. Куасыз? Чакырып китердегез дә куасыз?

Ш а г ы й р ь. Мин — ахмак, сине искә төшереп соравыма җавап тапмакчы идем. Хаиннан нинди җавап көтеп була. Кит!.. Югал!.. Тик шуны ишетеп югал. Синең вак җаның беркайчан да Мусаның олы җаны белән янәшә булмас. Әйе, Мусаны да, сине дә үлем җәзасына хөкем иттеләр. Икегез дә суд каршында басып тордыгыз. Муса — фашистлар суды каршында, син — Ил, Ватан, Халык, Туган җир суды каршында. Бәлки, болар синең өчен барыбердер. Ләкин Муса һәм аның көрәштәшләре үлемгә аягүрә бардылар, син үлемне күреп шыңшыдың, елан шикелле боргаландың. Син дошманның көчлесе дә була алмадың, хәшәрәт. Сатылганнар үлә белми үлә. Аларның үлеме дә җирәндерә. Югал!

Х а и н. Кумагыз мине. Зинһар өчен, аз гына торыйм. Сүгегез, типкәләгез, тик кумагыз. Яман килеш булса да хәтерегездә аз гына яшәп калыйм. Яшисем килә минем. *(Шагыйрьнең аягына егылып.)* Сорагыз, сорауларыгыз бардыр, бетмәгәндер. Бөтенесенә дә җавап бирәм. Сорагыз… Бер генә сорау… Тик бер генә сорау…

Шагыйрь. Кит!.. Кит!..

Хаин. Телисезме, мин сезгә сез көткән сүзләрне әйтәм. Дөресен әйтәм. Алдаштым, алдаштым гына мин. Әлегә хәтле әйткән сүзләремә ышанмагыз... Дөресен сөйләп бирәм. Көнләштем мин алардан. Мусадан, Кормаштан — барысыннан да көнләштем. Аларның көченнән көнләштем. Алар сөйләсә — тыңлыйлар иде, алар җыр башласа — күтәреп алалар иде алар җырын. Мин белми идем бүтәннәр тыңларлык сүз, бүтәннәр кушылырлык җыр белми идем. Җырым юк иде, моңым юк иде. Шуның өчен мин үч алдым. Дөньяларның болай буласын белгән булсам, түзгән булыр идем — дәшмәгән булыр идем. Яшәгән булыр идем. Яшисем килә. Йә, тагын ни ишетергә телисез? Тагын ни әйтим? Әйтеп торыгыз миңа — сүзләрегезне кабатлармын. Тик кумагыз гына... Кусагыз да, исемемне атап куыгыз, исемемне ишетеп калсыннар. Мин дә яшәдем бит дөньяда. Минем дә исемем бар... Күрәм, сез мине тыңларга теләмисез. Сез мине күрмисез дә... Сез мине онытып та өлгердегез... Ә минем яшисем килә... Яшисем килә...

Шагыйрь. Кит, Хаин, югал.

Хаин. Яшисем килә.

Шагыйрь. Югал. Сине искә төшергәнем өчен үземнән үзем җирәнәм. Аралагыз, аралагыз мине Хаиннан. *(Кычкырып.)* Муса! Муса абый!..

Муса *(пәйда булып)*. Ир-егет бул, киләчәкнең шигырь язучысы! Сатлык җаннарны танырга өйрән. Өйрәнерлек гыйбрәтләр бар, беләсең.

Шагыйрь. Беләм. Ләкин барыбер куркам. Торыгыз минем янымда, Муса абый, рухыгызга сыеныйм.

Муса. Ишетәсеңме? Егетләр җырлый.

Җәлилчеләрнең җыры ишетелә. Җыр барышында җәлилчеләр үзләре дә күренә.

Урманнарга керсәң, сызгырып кер,
Селкенмәгән агач калмасын;
Урамнарда йөрсәң, өздереп йөр,
Сокланмаган кеше калмасын.

Йә, ничек, туган? Яле, кушыл безнең җырга.

Иптәшләренә кушылып җыр башлый, аңа Шагыйрь дә кушыла.

Бурый да гына бурый кар яуса да,
Боекмыйдыр болан баласы;
Бер генә дә нужа күрмәенчә,
Ир булалмый ата баласы.

Муса белән Шагыйрь янына Ланфредини килә.

Л а н ф р е д и н и. Безнең җырлар кебек моңлы сезнең җырларыгыз, Муса.

М у с а. Моңсыз халык юктыр ул, Рениеро.

Л а н ф р е д и н и. Әйе, әйе... Әгәр дә исән-сау калсак, мин сезне үз илемә — Италиягә кунакка чакырачакмын. Туган илемнең җырларын бергәләп тыңларбыз. Дусларым белән таныштырырмын. Ул Советлар Союзы гражданины шагыйрь Муса Җәлил, диярмен. Төрмәдә, үлем җәзасы көткәндә итальянча сөйләшергә өйрәнде, диярмен. Миннән өйрәнде, диярмен.

М у с а. Исән чыгарбыз дисеңме?

Л а н ф р е д и н и. Алланың кодрәте киң, Муса.

М у с а. Алланың кодрәте киңдер. Ләкин, гафу итегез, Рениеро, мин — материалист. Фашистның коммунистны исән калдыруына ышанмыйм. Беркайчан да ышанмадым. Мин үзем дә фашистны исән калдырмас идем. Үз-үзеңне юатудан мәгънә юк.

Л а н ф р е д и н и. Шулай да...

М у с а. Мине бер генә нәрсә борчый: илемнең солдаты буларак бурычымны ахырынача үтәп бетереп булмады.

Л а н ф р е д и н и. Сез тыйнак кеше...

М у с а. Юк. Бу мәсьәләдә мин тыйнак түгел. Көрәшмәдем димим, көрәштем. Әмма мин үземне зуррак көрәшкә әзерләгән идем. Фашизм чыелдап җан биргәндә, терелә күрмәсен дип, янында автомат тотып торырга тиеш идем мин. Фашизмның дөмеккәнен үз күзем белән күрдем дип, ура кычкырырга әзер идем.

Л а н ф р е д и н и. Сез кычкыра аласыз. Сезнең аңа хакыгыз бар. Без падре Юрытко белән сезне бик еш искә алабыз. Ул да сезгә соклана. Мин — Аллага ышана торган кеше, Муса. Догаларым белән тәңрегә мөрәҗәгать иткәндә, мин аңардан сезнең өчен дә мәрхәмәтлелек сорыйм. Исән калдыр аларны да, дип ялварам.

М у с а. Рәхмәт, Рениеро. Тик ул, кызганычка каршы... Гафу итегез, мин сезнең алда аңа тел тидерергә базмыйм. Шулай да...

Л а н ф р е д и н и. Аңлыйм.

М у с а. Үлемнән курыкмыйм мин. Бу буш сүз түгел. Куркыныч хәлләргә очраган чакларда, мин үлем турында котым очып уйлап утыруымны белмим. Үлем турында уй килә икән, үлемнән соң да яшәү бар бит әле дип фикер йөртәсең. Мин, гафу итегез, теге дөньяны әйтмим. Халык күңелендә, халык аңында яшәүне әйтәм. Менә анысы – чын яшәү. Үтерсен әйдә мине фашист. Ләкин ул ялгыша. Үтерелгән шагыйрь тере шагыйрьдән куркынычрак була.

Җәлилчеләр төркеменнән Абдулла Батталовның «Муса абый!» дигән тавышы ишетелә. Муса төркем янына килә.

Б а т т а л о в. Муса абый, Алиш абый мине обижайт итә.

М у с а. Ничек?

Б а т т а л о в. Мин көлкеле анекдот сөйлим, ә ул көләргә теләми.

А л и ш. Адаш, беренчедән, мәзәгең көлкеле түгел. Икенчедән, биредә мәзәк сөйләшеп утыруны урынсыз дип саныйм.

Б а т т а л о в. Беренчедән, мәзәгем көлкеле иде. Икенчедән, дөньяга бераз гына елмаеп карарга кирәк. Мыек астыннан елмаеп карарга кирәк, әйеме, Муса абый?

С ә й ф е л м ө л е к о в. Үлемгә дәме?

М у с а. Үлемгә дә, Фуат.

Б а т т а л о в. Во! Бервакыт бер балта остасы өенә елап кайткан. «Канатым, ни булды?» – дип сораган хатыны. «Иртәгә иртүк патшага мин алты йөз илле мең пот йомычка илтеп бирергә тиеш. Илтмәсәм, ул минем башымны чаптырачак», – дигән балта остасы. «Аптырама, – дигән аңа хатыны. – Иртәгә яңа көн туа, бүген рәхәтләнеп күңел ачыйк, кунак чакырыйк», – дигән. Кунаклар чакырып, рәхәтләнеп җырлаганнар, биегәннәр болар. Рәхәтләнеп ятып йоклаганнар. Иртән иртүк боларны патшаның ялчысы уяткан. Балта остасы, башы киселәсен уйлап, тагын елый башлаган. Шулвакыт патшаның ялчысы әйткән: «Тизрәк гроб яса, патша үлде», – дигән. Во! *(Кычкырып көлеп җибәрә, аңа бүтәннәр дә кушыла.)*

Ш а б а е в. Гитлер үләр дип ышанасыңмы, Баттал?

Б а т т а л о в. Үләр дип ышанмыйм, үтерәчәкләренә

ышанам. Сез беләсез бит инде, мин — ышанучан кеше. Минем ышанучан булуым аркасында менә монда эләктек.

Муса. Баттал, сөйлә әле теге анекдотыңны.

Батталов. Нишләтим, мине кешеләргә ышанырга өйрәттеләр. Кемнең сатлык җан, кемнең чын кеше икәнен аера белмим. Кеше булгач, минем өчен барысы да яхшы. Минем бит үземә дә ышандылар. Сез дә ышандыгыз. Бәлки, ышанмаска кирәк булгандыр.

Муса. Баттал!..

Батталов. Ышану начар түгел бит ул, әйеме, Муса абый? Кешеләргә ышанмыйча подлецлар гына үлә.

Хәсәнов. Сөйләмәгез үлем турында...

Муса. Бер хатын иренә әйтә икән: «Юат әле шул баланы, җылаганын күрәсең», — ди икән. «Үзең юат», — дигән ире. «Ул бала минеке генә түгел, синеке дә», — дип әйткән, ди, хатын. «Син үз өлешеңне юат, минем өлешем җыласа да ярый», — дигән ир кеше.

Көлешәләр.

Булатов. Мин кызымның җылаганын хәтерләмим. Минем күз алдымда ул һәрвакыт көлеп тора.

Шабаев. Бервакытны минем кызым Лилия җылап утыра. Нигә җылыйсың, кызым, ни булды, дим. Мин үләрмен кебек тә, бөтен морожныйларны бүтәннәр ашап бетерер кебек, ди.

Хәсәнов. Сөйләмәгез үлем турында.

Симаев. Сездә генә булды кызлар. Әнә Алиш абыйның ике егете бар, алай да мактанмый. Хатын-кызлар шикелле, балаларын макташып утыралар. Менә сез шуны әйтегез, теге дөнья әйбәтме, монысымы?

Батталов. Тегесе, кәнишне. Начар булса, аннан кире кайтучылар булыр иде.

Алиш. Туктатыгыз мәгънәсез шаяртуыгызны.

Муса *(Алиш янына килеп)*. Алиш, һәрвакыттагыча, сабыр бул. Беләсең, безнең нервылар нык булырга тиеш.

Алиш. Соңгы сәгатьләребездә сөйләшер өчен җитди сүзләребез дә бардыр лабаса.

Муса. Без аларны әйттек, Абдулла.

Алиш. Инде җүләр сатарга да ярый дисеңме?

Муса. Эш беткәч уйнарга ярый, Абдулла.

Алиш. Мин уйнарга теләмим, Муса.

Муса. Кирәк. Аңлыйсыңмы, кирәк! Без хәзер ун-

берәү утырып, безне көткән үлем турында чынлап сөйләшә башласак, беләсеңме ни буласын. Безне иң зур сынау көтә. Шуның алдыннан рухыбыз ял итеп алырга тиеш. Кормаш, күптән концерт караган юк.

Кормаш. Була ул. Рәхим итегез. Халык соравы буенча, концертыбызны башлап җибәрәбез. Симай, минем янга.

Симаев *(Кормаш янына барып басып).* «Борча». Егет рolендә — Әхмәт Симаевский, кыз ролендә — Гайнания Кормашевская.

Батталов. Борча ролен Плетцензее төрмәсенең атказанган артисты Абдулла Батталов башкара.

Симаев. Җанкай белән икәү җитәкләшеп
Су буеннан үтеп барабыз.
Җанкай сарыша миңа, адым саен
Якынлаша бара арабыз.
Бара торгач, мамык кулы белән
Ул билемнән минем кочаклый.
Уйламаган идем сукыр бәхтем
Тулып ташар, диеп, бу чаклы.
Борным тукмак минем, битем шадра,
Ничек шулай матур күренәм?
Яратадыр, ахры, дип уйлыйм да
Үбәргә дип аңа үреләм.
Нәкъ шул мәлне сул як кабыргамны
Кемдер чеметә кебек сизелә.
Мин уянып китәм, татлы төшем
Иң кызыклы җирдә өзелә.
Сул кабыргам әрни, ни бар диеп,
Мин култыкка тыгам сул кулны.
Мине шулай тешләп уятучы
Борча икән, каһәр суккыры.
Ни әйтәсең инде шушы хәлгә,
Гомергә бер шундый төш күрәм,
Аны да бит борча тешләп боза,
Әллә юри, әллә үч белән?!

Шигырь укылып, уйналып беткәч, кул чабалар. «Автор! Автор!» — дип кычкыралар. Муса, кыланып, реверанслар ясап баш ия.

Аднашев. Кызлар кочаклау дигәннән, әле дә хәтеремдә...

К о р м а ш. Истәлекләр белән шөгыльләнмибез. Мемуарларны картайгач язарбыз. Ә хәзер барыгыз да уенга. Концертыбызның чираттагы номеры — «Кап та коп!» Җыелыгыз минем тирәгә.

М у с а *(бер читтә гыйбадәт кылучы Ланфрединига)*. Рениеро, килегез безнең янга.

Ланфредини җәлилчеләр янына килә.

К о р м а ш. Башладык.

Бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш өскә бастырып тезәләр дә кулларын бергәләп күтәреп-төшереп, такмак әйтәләр.

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Базга төштек, бал ашадык,
Келәткә кердек, май ашадык.
Өйгә мендек, өйрә эчтек,
Коега төштек, су эчтек,
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык.
Кап та коп, кара Якуп,
Авызыңны ач та йом!

Барысы да авызларын йомып сүзсез калалар. Ш а г ы й р ь уйнаучылар янына килә.

Ш а г ы й р ь. Гафу итегез, батырлар. Чынбарлыктан мин ерак киттем. Мин беләм, сезгә бер камерада бергә булырга туры килмәгән. Җәзаларга гына сезне бергә алып барганнар. Хыялымда мин сезне бергә җыйдым. Барыгызга берьюлы карыйсым килде. Бәлки, сез бу мәзәкләрне сөйләмәгәнсез, бу уенны уйнамагансыз, бәлки, кычкырып көлмәгәнсез дә... Ләкин сез соңгы минутыгызны көтеп, боегып та утырмагансыз. Сез яшәвегезне дәвам иткәнсез. Яшәү тәмен югалтмаган кеше уен-көлкедән дә баш тартмый. Бәлки, мин ялгышамдыр?

Б а т т а л о в *(Шагыйрь янына килеп)*. Канатым, нигә син эш эшләгән кешеләргә мишәйт итеп йөрисең?

Җәлилчеләр Батталов янына җыелалар.

К о р м а ш. Яле, Баттал дус, дәшмичә түзә алмаганың өчен җәзасын таты әле.

Б а т т а л о в . Мин гаепле түгел. Дәшмичә булдыра алмадым.

К о р м а ш. Акланма.

С и м а е в. Әйтеп җибәр әле, канатым… кемнәрнең өй башына пес иттең?

Б а т т а л о в. Минме?

С и м а е в. Син.

Б а т т а л о в. Шәфи Алмасның.

К о р м а ш. Шәфи Алмасның өендә ничә кеше бар?

Ш а б а е в. Асрауларын санасаң, унбишләп…

Б а т т а л о в. Алдашмагыз.

К о р м а ш. Сөйләшмә. И башыңны. Башладык.

Б а т т а л о в. Юк инде, башны имибез. Башны без ике очракта гына иябез: сөзәргә уңай булсын өчен һәм кисәргә җайлы булсын өчен. Менә сезгә маңгай — рәхәтләнегез.

Батталовның маңгаена берәм-берәм чиртәләр.

Б у л а т о в. Ярасыз бит егетнең маңгаен, җәмәгать.

Б а т т а л о в. Ярылсын әйдә, барыбер киселәсе баш. Берәрегез минем кулга эләгеп карасын. Әйдәгез тагын.

Кулларын тотышалар.

М у с а *(Шагыйрьгә)*. Безнең белән уйнарга теләмисеңме?

Ш а г ы й р ь. Рөхсәт итәсезме соң? Арагызга кертәсезме?

М у с а. Мондый уен вакытында шагыйрьләр һәрвакыт уртада була.

Ш а г ы й р ь. Мин үземне аңа лаек түгел дип уйлыйм.

М у с а. Мескенләнмә син. Мондагылар мескеннәрне яратмыйлар.

Ш а г ы й р ь. Мин мескенләнмим. Уйланам.

С и м а е в. Кирәгеннән артыгын уйлау зарарлы, эш эшләргә вакыт калмый. Уйланучылар күбәйгән саен, эшләүчеләр кими бара.

А л и ш. Әхмәт, тупас сөйләшмә. Киләчәк кешеләренең күңеленә тупас сүзләр кунмасын. Күңелләре тупасланмасын киләчәк кешеләренең.

С и м а е в. Мин тупас сүз әйтмәдем, мин шаярттым гына.

М у с а *(Шагыйрь янына килеп)*. Әйдә инде. Кешеләр уйнаганда читтә тору килешми. Кара син аларга. Алар-

ның күбесе синнән яшь. Бу егетләр белән, кулга-кул тотынышып «без, без, без идек» дип кабатласаң, әллә ниләр эшләп була. *(Шагыйрьне уйнаучылар янына алып килә.)*

Уен башлана. Такмакны әйтеп, авызларын йомалар. Пауза. Тынлык. Тынлыкта Әхәт Аднашевның сагынулы тавышы ишетелә.

Аднашев. Әле дә хәтеремдә — дала тып-тын иде. Дала төнге йокысыннан уянып кына ята иде. Алсуланып кояш чыгып килә. Түгәрәк күл өстендә — түп-түгәрәк ак болыт. Киттем шул ак болытка карап. Тып-тын. Кинәт күл яныннан, ак болыт эченнән җыр яңгырады. Казах җыры. Казах кызы җырлый иде. Моңлы бер җыр.

Әкрен генә казахның «Гүлдарайым» көе туа. Җәлилчеләр Аднашев янына җыелалар. Аднашев хәтерләвен дәвам итә.

Әле дә ул җыр минем күңелемдә тирбәлеп тора.

Җаз шыкты жадыратып майдың айын,
Әнине шыркай китте Гүлдарайым.
Шыгады ашы даусым әнге бассам,
Карагым, сени есиме алган сайын.
Ахау, Гүлдарайым,
Күн мен Аем,
Ошарга канатым жок —
Не кылайын!

Әле дә хәтеремдә...

Кормаш. Кемнәр өй башына кундың, Аднаш?

Аднашев. Ә?

Кормаш. Кемнәр өй башына кундың?

Муса. Кормаш, борчыма аны.

Кормаш. Уенның тәртибе бар, Муса абый.

Аднашев. Мин үзебезнең өй башына кундым.

Симаев. Өегездә кемнәр бар?

Аднашев. Әнием. Әнием бар минем. Әтием. Абыйларым, апаларым. Үзем белән ун кеше.

Батталов. Шундый итеп әйтәсең, чиртүе дә уңайсыз.

Аднашев. Ә сез чиртегез. Әле дә хәтеремдә...

Шулвакыт әче итеп кычкырган тавыш ишетелә. Барысы да рәшәткә янына җыелалар. Тавыш әкренәя-әкренәя сүнә. Ланфредини тезләнеп гыйбадәт кыла башлый.

А л и ш. Алып киттеләр. Җанварлар!

М у с а *(Кормашка)*. Кормаш, егетләрне кара. *(Алишны култыклап алып.)* Алиш... Абдулла... Тынычлан... Ярамый. Ишетәсеңме, ярамый...

Икенче берәүнең җан ачысы белән кычкырганы яңгырый. Шагыйрь тавыш килгән якка омтыла. Җәзалау бүлмәсенә керә. Гильотина. Аның янында П а л а ч басып тора.

П а л а ч *(Шагыйрьне күреп, ашыгып янына килә, палачларча җитезлек, осталык белән Шагыйрьне эләктереп ала, кулларын артка каерып бәйли, күзләрен бәйләп куярга да өлгерә)*. Рәхим итегез, хөрмәтлем.

Ш а г ы й р ь *(кычкырып)*. Җибәр!

П а л а ч. Монда эләккәнне җибәрмиләр, хөрмәтлем.

Ш а г ы й р ь. Җибәр! Мин үлемгә хөкем ителмәгән.

П а л а ч. Ничек «ителмәгән»? Ә нигә бирегә кердегез?

Ш а г ы й р ь. Мин күз алдыма гына китердем. Китаплардан укып кына җәзалау процессын күз алдыма китердем. Җибәр! Мин боерам!

П а л а ч *(Шагыйрьнең күзләрен чишеп)*. Күз алдына? Бу процесс белән шаярмыйлар, хөрмәтлем. Күз алдыгызга сез палачны түгел, чибәррәк кызларны китерегез.

Ш а г ы й р ь. Миңа син кирәк. Чиш кулларымны. Миңа синең белән сөйләшергә кирәк.

П а л а ч. Палач белән сөйләшмиләр. Ул — бик күңелсез гәптәш. Аңа боералар гына. Без — боерганны үтәүчеләр.

Ш а г ы й р ь. Мин боерам! Минем сорауларыма җавап бир!

П а л а ч *(Шагыйрьнең кулларын чишә)*. Сораулар... Баш өсте. Рәхим итегез, узыгыз, утырыгыз. Йомшак креслолар юк биредә, гафу итегез. Сез кем дип сорап тормыйм, ул минем вазифама керми. Мине кешеләрнең кемлеге кызыксындырмый. Безгә киселгән баш исәбеннән түлиләр. Кем башы ул, күпме акыл җыерчыгы бар ул башның миендә — безнең өчен барыбер. Бәлки, ул ахмак баштыр, бәлки, бозыктыр, бәлки, дөньяның бөтен акылын үзенә җыйган баштыр — безнең өчен аның бәясе өч йөз марка. Тыңлыйм сезне, хөрмәтлем. Сез як-ягыгызга каранмагыз, утырыгыз. Нигә алай карап торасыз?

Ш а г ы й р ь. Син кыяфәтең белән кешегә охшагансың.

П а л а ч *(тәмләп көлә)*. Мин ул сүзне көткән идем, хөрмәтлем. Тормышны начар белгән кешеләр безнең турыда ул сүзне еш әйтәләр. Ә менә минем бәләкәй генә, сөйкемле генә кызым бар. Ул андый сүзне әйтми. Ул миңа «әтием», ди, «тәтием», ди. «Дөньяда синнән дә яхшы беркем юк», ди. Мин аңа эштән кайтканда уенчыклар алып кайтам.

Ш а г ы й р ь. Эш? Син кеше җәзалауны эш дип атыйсыңмы?

П а л а ч. Ә сез ни дип атар идегез? Эш, хөрмәтлем, эш. Гап-гади эш. Кемдер балта белән агач юнып тамак туйдыра, кемдер каләм кыштырдатып акча юнәтә. Мин баш кисеп — ни аерма бар? *(Көлеп.)* Безнең семья, хөрмәтлем, гаҗәеп семья. Минем хатыным бала тудыру йортында акушерка булып эшли. Кешегә туарга ярдәм итә. Мин аның эшен юкка чыгара барам. Гаҗәеп семья. *(Көлә.)* Һәм без искиткеч тату яшибез. *(Көлә.)* Телисезме, мин сезгә гильотинаның ничек эшләгәнен күрсәтәм.

Ш а г ы й р ь. Кирәкми.

П а л а ч. Кызганыч. Гаҗәеп машина. Цивилизация җимеше. Гинеколог галимнәр кешене тудыру процессын мөмкин булганча гадиләштерергә һәм җиңеләйтергә тырышалар, баш ваталар. Уңышка бик акрын ирешәләр. Үтерү процессы, киресенчә, көннән-көн, елдан-ел гаҗәеп тизлек белән камилләшә. Гаҗәеп машина.

Ш а г ы й р ь. Син кырык дүртенче елны хәтерлисеңме?

П а л а ч. Мең тугыз йөз кырык дүртме?

Ш а г ы й р ь. Әлбәттә.

П а л а ч. Хәтерлим. Ул елны минем беренче улым туды.

Ш а г ы й р ь. Егерме бишенче августны?

П а л а ч. Нәкъ егерме бишенче августта туды минем улым. Хәтеремдә: мин аның әнисенә истәлек итеп тугыз йөз маркага брошка бүләк иттем.

Ш а г ы й р ь. Тугыз йөз марка... Киселгән өч баш.

П а л а ч. Әйе. Арзанрак булды бүләгем. Ләкин, беләсез, бүләкнең бәясенә карамыйлар. Хәтеремдә минем ул көн, хәтеремдә. Ул көнне без акчаны шактый күп эшләдек. Киселгән баш шактый күп иде. Шулар арасында ниндидер татарлар диделәр. Унбер баш. Өч мең дә өч йөз марка.

Ш а г ы й р ь. Тукта!

П а л а ч. Нигә кычкырасыз, хөрмәтлем? Килешми сүз саен кычкыру. Мин бит сезне хөрмәт итеп сабыр гына сөйләшәм. Мин дә хөрмәткә лаектыр дип уйлыйм.

Ш а г ы й р ь. Кешеләрнең башын марка белән бәяләүче…

П а л а ч. Яхшы. Мин бер сүз дә эндәшмәячәкмен. Үзегез сөйләшергә теләдегез, мин түгел. *(Пауза.)*

Ш а г ы й р ь. Мин шул унбернең эзләре буенча килдем. *(Палач эндәшми.)* Сөйлә миңа алар турында. *(Палач эндәшми.)* Мин сиңа әйтәм!

П а л а ч. Ә сез тәрбиясез, хөрмәтлем. Кемдер сез, белмим, әмма тәрбиясез. Бик күпләрне үләренә бер секунд калганда күргән кеше мин. Әйе, әйе! Бу бәхет бик азларга эләгә. Кешенең тууы, яшәве – ноль! Кешенең бөеклеге – аның үлеме. Кемнең кем икәнен beләсең килсә, үләренә бер секунд кала күр. Гильотина пычагы астына кергәнче үк үлгәннәре була. О-о, мин хәтерлим егерме бишенче августны… Мең тугыз йөз кырык дүртенче елның егерме бишенче августын яхшы хәтерлим. Күпләрнең хәтерендә калгандыр ул көн. Сөйләделәр, шаккатып сөйләделәр – бу бүлмәгә керер алдыннан унбер кешенең унбере дә бер-берсенә карап елмаешканнар. Бер кешенең үлем алдыннан елмаюы – чүп, акылдан язган кеше дә елмая. Унбер кешенең елмаюы – гаҗәеп гүзәл мизгел. Аның өчен искиткеч зур көч кирәк, ышаныч кирәк, хөрмәтлем. Үлгәннән соң да яшәячәгеңә ышаныч кирәк. Алар кычкырмадылар. Ә сез кычкырасыз. Әгәр дә сезгә үлем янаса, сез чәбәләнер идегез, селәгәеегезне агызып җылар идегез. Менә шулай, хөрмәтлем.

Ш а г ы й р ь *(паузадан соң)*. Ничек уйлыйсың инде, нигә елмайганнар алар? Нигә кирәк булган?

П а л а ч. О-о, бу – философия. Кеше психологиясенең философиясе. Бу – бөек идея! Башны маркага бәяләвемә үпкәләдегез. Нәрсә ул баш? Җир йөзендәге бөтен хәшәрәтнең дә башы бар. Баш – чүп ул. Ә менә андагы идея! Кызганычка каршы, аны кисеп булмый. Бернинди гильотинаның да пычагы үтми идеяне кисәргә. Менә алар шуны аңлаганнар. Елмаю аша бер-берсенә шуны аңлатканнар. Мин бу турыда озак уйландым, хөрмәтлем. Биологик үлем алар өчен бер материянең икенче төрле материягә әйләнүе генә. Идея кала, идея яши – менә нәрсәдә хикмәт.

Ш а г ы й р ь. Син — философ, күрәм...

П а л а ч. Мин бит кеше башы белән эш итәм, хөрмәтлем... Бүтән сорауларыгыз юкмы?

Ш а г ы й р ь *(сәхнә алдына килеп)*. Сорауларым юк югын. Ләкин... Ә нигә «ләкин»? Әле мин һаман да икеләнәммени? Язарга кирәк. Ләкин булдыра алырмынмы? Йоклаган күңелләрне сискәндереп уятырлык, Мусаларның бөеклегенә тиң әсәр иҗат итәргә көчем җитәрме? Булдыра алмам кебек. Әмма тырышырга кирәк, язарга кирәк, язарга кирәк! *(Сәхнәдә пәйда булган Муса һәм аның көрәштәшләренә мөрәҗәгать итеп.)* Муса абый, бирегез миңа фатихагызны. Бирегез миңа фатихагызны, батырлар!

Б о х а р о в. Кирәкми!

М у с а. Сәлим.

Б о х а р о в. Кирәкми, Муса абый. *(Шагыйрьгә.)* Язмагыз минем турыда, исемемне телгә алмагыз.

М у с а. Сабыр...

Б о х а р о в. Киләчәктәгеләр белмәсеннәр минем булганымны. Мин бар идем кайчандыр, хәзер — юк. Һәм киләчәктә дә булмавымны телим. Мин намусым, вөҗданым кушканны көчемнән килгәнчә эшләдем — калганы нигә кирәк. Мин әйбәт идем дип, киләчәк буыннан хөрмәт теләнергә җыенмыйм.

К о р м а ш. Буталма, Бохаров. Син — совет солдаты.

Б о х а р о в. Әйе, мин — илемнең гади солдаты. *(Шагыйрьгә.)* Калганнар үзләре хәл итсен, минем турыда язмагыз. Исемемне телгә аласыз икән, сугыш кырында ятып калган миллионнарның барысын да санап чыгыгыз. Берсен дә калдырмагыз. Минем алардан аермам юк! Бәлки әле, алар күбрәк лаеклыдыр.

М у с а. Тынычлан, Сәлим. Кызган кеше сүзен уйлап бетермичә әйтүчән була. Син беләсең, бирედә киләчәктән хөрмәт теләнүчеләр юк. Теләнү хәерчеләргә хас. Сүз киләчәкнең почёт тактасыннан урын сорау яки премия дәгъва итү турында да бармый. Сүз яшәвебез һәм, ниһаять, үлемебез белән киләчәк буын алдында хөрмәт казану турында бара. Кеше киләчәк өчен яши. Мин, мәсәлән, үзем үлгәч тә минем турыда хөрмәт белән сөйләүләрен, үрнәк итеп сөйләүләрен телим. Югыйсә нигә кеше исемен йөртергә? Эзсез югалу өчен нигә туып торырга?

Б о х а р о в. Сез — шагыйрь.

М у с а. Без барыбыз да кешеләр. Юк, егетләр, без көрәштек тә үлдек, шуның белән вәссәлам булырга тиеш түгел. Киләчәк буын безне белергә тиеш. Мине дә, сине дә, Әхәт, Кормаш, Алиш, Симайларны — барыбызны да. Яу кырында һәлак булганнарны да, барысын да... Без бередә унберәү генә. Ләкин без — халкыбызның вәкаләтле вәкилләре. Шуны онытмасыннар киләчәк буын кешеләре. Үткәннәрнең үрнәгендә киләчәк туа. *(Шагыйрьгә.)* Яз, Шагыйрь дустым. Уйлагансың икән безнең турыда язарга, яз. Бу теләнү түгел — боеру. Ватан, халык алдында биргән антларына турылыклы калганнарның боерыгы. *(Аднашевка.)* Ә син, Әхәт, елмай. Елмаегыз, егетләр. Киләчәк шагыйре күз алдына без һәрвакыт елмайган килеш килеп басыйк. Дошманнар да безнең иелгән башыбызны күреп сөенмәсен, елмаюыбыз төшләренә кереп, куркып уянсыннар. Яле, Баттал, ничек әле?.. Без, без, без идек, без унике кыз идек...

Аерым бер көйгә «Без, без, без идек...» кабатлана башлый. Аны өзеп, репродуктордан «Муса Җәлил!» дигән тупас тавыш яңгырый.

М у с а. Йә, бәхилләшик, Шагыйрь дустым.

Ш а г ы й р ь. Үлгәннәр белән генә бәхилләшәләр. Сез безнең күңелләрдә һәрвакыт исән.

М у с а. Рәхмәт, туган.

«Муса Җәлил» дигән тавыш кабатлана. Муса китәргә кузгала.

Ш а г ы й р ь. Муса абый... Тагын бер генә сүз әйтеп китегез, Муса абый.

М у с а. Безнең өчен дә яшәгез, туган. Мәгънәле итеп яшәгез. Яшәвегезнең мәгънәсе булмаса, безнең үлемнең дә мәгънәсе булмаячак. *(Яктылыкка кереп югала.)*

«Гайнан Кормашев» дигән тавыш яңгырый.

Ш а г ы й р ь. Гайнан...

К о р м а ш. Соңгы минутта ялгышларын төзәтмәсеннәр иде фашистлар... *(Муса киткән якка китеп югала.)*

«Абдулла Алиш» дигән тавыш яңгырый.

Ш а г ы й р ь. Алиш абый...

А л и ш. Ишетәсезме, нинди моңлы җыр. Моңлы җыр — кайгылы, хәсрәтле җыр түгел.

«Сибелә чәчәк» көе яңгырый. Алиш китә.

Тавыш җәлилчеләрне саный тора, алар Муса, киткән якка китеп, яктылыкка чумалар. Муса һәм җәлилчеләрне «Сибелә чәчәк» көе озата бара. Сәхнәдә ялгыз калган Шагыйрь сәхнә алдына килә. Килгәндә Муса Җәлилнең «Җырларым» шигыренең соңгы строфасын укый.

Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә
Һәм үләргә кыю ир булып.
Гомрем минем моңлы бер җыр иде,
Үлемем дә яңрар җыр булып.

П ә р д ә.

# ӘНИЛӘР ҺӘМ БӘБИЛӘР

*(Драматик хикәя)*

Ике пәрдәдә

Ана —
Бөек исем,
Нәрсә җитә ана булуга…

*Һ. Такташ*

Консультант врачлар: *Миңгалиева Ләйсән Миңлеәхмәтовна, Җәләева Лениза Шакировна*

Катнашалар:

Гөлфинә — 45 яшьтә.
Валентина — 30 яшьтә.
Алтынчәч — 32 яшьтә.
Дилемма — 20 яшендә.
Баш врач — өлкән яшьтәге ханым.
Айзарә Әхәтовна — палата врачы, 50 яшьләрендә.
Нина — сестра, 19 яшьтә.
Исемсез хатын — 30 тирәләрендә.
Вазыйфа — Дилемманың каенанасы.
Римма — Дилемманың әнисе.
Бала тирбәтүче ике Ана. (Мөмкинлек булса, аларның санын арттыру отышлырак булмасмы?)

Вакыйга безнең заманда шәһәрдәге бала тудыру йортларының берсендә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бала тудыру йортында бала тапкан аналар палатасы. Коридорның да бер өлеше һәм врач кабинеты күренә. Тирә-як ап-ак. Аклык бу очракта медицина фәнендә кабул ителгән гигиена

билгесе булу белән бергә яктылык символы да. Якты дөньяга гөнаһсыз нарасыйлар килгән урын. Кеше туган җир. Сәхнәнең ике ягында ике бишек эленгән. Ак төс фонында алар төрле төсләргә буялган, бизәкле булулары белән игътибарны җәлеп итеп торалар. Ике бишек янында ике Ана утыра. Вакыйгада катнашучылардан аермалы буларак, аларның киемнәре бишекләр шикелле үк бизәкле, чәчәкле. Бүтәннәрнең киемнәре, әлбәттә, ак төстә. Пәрдә ачылганда, бишекләр янындагы ике Ана, бишек җырын җырлап, бишекләрне тирбәтәләр.

Әлли-бәлли-бәллием,
Йокла, балам, нәнием,
Тәмләп йокла, бәбием,
Сакта тора әниең.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Беренче Ана. Йокла, улым, батырым.
Икенче Ана. Йокла, кызым, матурым.
Икәү бергә. Йокла, минем бергенәм.
Чәчәк кенәм, гөл генәм.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.
Йөрәгемнең парәсе,
Ике күзем карасы,
Мәхәббәтем чаткысы,
Күңелемнең яктысы.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Җырны ике Ана сүзсез генә дәвам итәләр. Шул җыр белән бала тапкан аналар палатасы яктыра. Вакыт иртә. Аналар йокыдан уянып, юынып, ясанып, балаларын имезергә китергәнне көтәләр. Алтынчәч белән Валентина караватларында утырып торалар. Дилемма яткан. Гөлфинә аяк өстендә.

Гөлфинә *(Дилемма караваты янына килеп)*. Тор әйдә, кызым, тор. Синең яшьтә озак яту килешми. *(Дилемма борылып яткач.)* Бигрәк иркә семьяда үскәнсең, ахрысы, авыр булыр яшәве. *(Алтынчәч янына килә.)* Нихәл соң, Алтынчәч?

Алтынчәч. Яхшы.

Гөлфинә. Исемең бигрәк матур инде.

Алтынчәч. Үзем ямьсез, әйеме?

Г ө л ф и н ә. Ямьсез дип инде... Бер дә ул хәтле ямьсез түгел. Матурлык ул туйда гына кирәк. Үзеңә ишең табылган бит әле. Балагыз бар. Ямь шул була инде, Алтынчәч айналаем.

А л т ы н ч ә ч. Безнеңчә каян беләсез?

Г ө л ф и н ә. Казахчамы? Белмим, Чимкентка кунакка барган идек тә, шунда бер казах апасыннан ишеттем. Бигрәк матур сүз — айналаем. Матур сүзләрне яратам мин, Алтынчәч... Бер киңәш биримме, Алтынчәч? Син һәрвакыт елмаеп йөр, елмайганда син бик чибәрләнәсең. Ямьсез дип әйткәннәренә ышанма, бик ямьле, бик матур син, айналаем.

А л т ы н ч ә ч *(елмаеп)*. Рәхмәт.

Г ө л ф и н ә *(караватында мышык-мышык елап утыручы Валентина янына килә)*. Ни булды, Валентина, нигә җылыйсың?

В а л е н т и н а. Куркам.

Г ө л ф и н ә. Нидән?

В а л е н т и н а. Әгәр дә минем сөтем җитмәсә? Ул ачтан үлсә? Юк, ул үлсә, мин дә яшәмәячәкмен. Ул — минем соңгы өметем.

Г ө л ф и н ә *(көлеп)*. Тукта, тиле. Тапкансың җылар нәрсә! Җиңел котылганыңа сөенеп, көлеп кенә йөрергә кирәк сиңа. Җылап бала үстереп булмый ул, җаным. Көлеп йөр, balaң да синнән көләргә өйрәнсен.

В а л е н т и н а. Карагыз әле минем күкрәкләргә. Бик бәләкәйләр бит. Ничек аның сөте җитсен?!

Г ө л ф и н ә. Алай димә, Валентина. Тфү, тфү, күз тимәсен, бу имиләрдән колын имезергә була. Мин беренчемне тапканда бөтенләй юк иде әле имием. Эзләре генә бар иде. Әле дә хәтеремдә, өйләнешеп беренче йоклаган төнне Зарифулла, минем ирем инде, тотмакчы була имиемне, кулы шуа да китә тегенең, шуа да китә. Менә шул имиләрне, Валентина җаным, унбер бала имеп үстеләр. Уникенчесе монда керергә көтеп тора. Улларым Газинур Гафиятуллин кебек, кызларым Галиябанудан ким түгел. Әле район больницасында табып шундыйлар. Казан больницасында тапсам, нинди булмаслар иде. Менә шуңарга күрә, уникенчесе тагын да шәбрәк булсын дип, Казан роддомына килдем. Зарифулла әйтә, алмыйлар сине, син анда учётта түгел, ди. Ашыкма, мин әйтәм. Табар чагым җиткәнне чамаладым да сеңелләремә килдем.

Тулгак тота башлагач, «Скорый помощь»ка шылтыраттылар да… алмый нишләсеннәр. Туам дигән баланы кире кертеп булмый ич.

Дилемма. Туктап торыгыз әле әзрәк кенә.

Гөлфинә. Ни дидең, сеңлем?

Дилемма. Бик күп сөйлисез!

Гөлфинә *(Дилемма янына килеп)*. Балтун инде мин шулай, тел бистәсе. Зарифулла да шуның өчен әрли үземне. Нишлисең, синең сыман, бер-беребезгә сырт куеп ятсак та күңелле булмас иде. *(Алтынчәчкә.)* Шулай бит, айналаем?

Алтынчәч. Шулай.

Гөлфинә *(Алтынчәч янына килеп)*. Син үзең Казанда торасыңмы соң, Алтынчәч?

Алтынчәч. Юк, Ульбада.

Гөлфинә. Ульба? Кайда соң ул?

Алтынчәч. Казахстанда.

Гөлфинә. И-и-и! Монда ничек килеп эләктең?

Алтынчәч. Шулай туры килде инде. Мәскәүгә бара идем, апаларга.

Гөлфинә. Ирең беләме соң монда тапканыңны?

Алтынчәч. Юк.

Гөлфинә. Хәбәр иттер, ятмасын дөньясын онытып. Туганнарың бармы соң Казанда?

Алтынчәч. Юк.

Гөлфинә. Пәрәмәч! Ничәнче балаң?

Алтынчәч. Беренче.

Гөлфинә. Ничә яшь соң үзеңә?

Алтынчәч. Утыз ике.

Гөлфинә. Кияүгә соң чыктыңмыни?

Алтынчәч. Әйе, соң. Ямьсез бит мин — алучы булмады.

Гөлфинә. Алай димә. Әйтмә алай дип. Бала тапкан хатын ямьсез булмый. Юкны сөйләмә икенче тапкыр, Алтынчәч, риза-бәхил түгел.

Алтынчәч. Кызым да ямьсез булыр микән? Малай булуын теләгән идем.

Гөлфинә. Хәзер малайның, кызның аермасы юк. Хәзер барысы да үз бәхетләре белән туалар. Әнә минекеләр тупырдап торалар. Унике булдылар бит, малай җаным, унике. Бик күп инде, әйеме?

Валентина. Күп түгел, Гуля апа. Мин егермене табар идем.

Гөлфинә. Егермегә хатын-кызның чыдамы җитсә дә, гомере җитмидер ул, Валентина. Хатын-кызның гомере кыска бит ул.

Валентина. Без җиде ел көттек. Ой, белсәгез… Саша, мин, Сашаның әтиләре, минекеләр — барыбыз да көттек. Бармаган больница, күренмәгән доктор калмады. Җиде ел! Саша белән икәүләп сүзләрнең ниндиләрен генә ишетмәдек. Ой-ой!.. Буйга узгач ничек сакладык без аны, Гуля апа!..

Гөлфинә. Шуңа күрә зур булып туган да инде ул.

Валентина. Өч кило да алты йөз илле грамм.

Гөлфинә. Артык зур булып туганны врачлар яратып бетерми шул.

Валентина. Яшәр микән? Ой, куркам… Белсәгез курыкканымны. Яшәр микән, Гуля апа?

Гөлфинә. Мондагылар җыелып туена барабыз әле малаеңның, чакырсаң.

Валентина. Чакырам, Гуля апа, барыгызны да чакырам. Шундый туй булыр, шундый туй булыр!.. Ой, кызлар!.. Кызлар! Белмисез шатлыгымны, белмисез куанганымны! Аны бары тик җиде ел бала көткән хатын-кыз гына аңлый. Балам бар бит минем, улым бар! Исеме Саша булачак. Әтисе дә Саша, улым да Саша! Александр Александрович. Ой, ничек яратам мин аның әтисен, кызлар! Сез күз алдына да китерә алмыйсыз, ничек мин аны яратам!

Гөлфинә. Безнең дә иребез бар. Яратмасак, шул ирдән уникe бала тапмас идек.

Ишек төбенә Исемсез хатын килеп, сөйләшкәнне посыбрак тыңлап тора.

Валентина. Сез бәхетле, Гуля апа. Уникe балагыз бар.

Гөлфинә. Нәселебез шундый инде. Мин үзем, Зарифулланың җиле тиеп китсә дә, балага узам. Тик менә сеңлебез генә, Казанга китте дә ире белән икәүләп бер баланың күзенә карап торалар.

Валентина. Юк, юк! Мин!.. Менә күрерсез!..

Гөлфинә. Була, була… Бер юлы ачылгач, була инде ул, Валентина. Бигрәк матур исем инде «Валентина». Марҗа булган булсам, мин үземә Валентина куштырган булыр идем. Син, Валентина, миңа «Гуля» димә инде, ярыймы?! Үз исемем белән әйт, ярыймы?!

В а л е н т и н а. Әйтүе читен бит.

Г ө л ф и н ә. Бер дә кыен түгел. Гөл-фи-нә. Гөл, гөл, гөл... цветок, цветок... Беләсеңме цветокны? Менә шул инде. Финәсен үзем дә белмим. Гөлфинә.

В а л е н т и н а. Гульфина. Гульфина апа.

Г ө л ф и н ә. Менә. Менә бит, менә. Онытма гына инде хәзер. Гөлфинә нәрсә ул, менә авыр исемнәр була ул. Әйткәндә телең сынарлык. Сугыш вакытында безнең авылга эвакуирынныйлар килгән иде. Безгә дә бер семья урнашкан. Мин аларны бик аз гына хәтерлим. Әни сөйли: бик тиз бер-беребезгә ияләштек, ди. Сөйләшергә дә өйрәндем, ди. Тик менә бабайларының гына исемен әйтә алмый изаландым, ди. Үзебезчә «Самат бабай» дип әйткән идем дә, пажалысты үз исемем белән әйтегез инде, дип әйтә, ди, бабай. Язып алып ике ай ятладым, ди, әни әйтә, көчкә өйрәндем, ди. Миңа әйткән иде, мин дә әйтә алмадым. Әкрен генә иҗекләп кенә әйтеп була, бергә җыеп тиз генә әйтеп булмый. Яле, син әйтә алырсың микән, Валентина? Са-му-ил Со-ло-мо-но-вич.

В а л е н т и н а. Самуил Соломонович.

Г ө л ф и н ә. Синең телең килешеп тора шул андый исемнәргә. Һәр халыкның үз теле шул. Шуңа күрә әйбәт тә. Бөтенесе дә матур. Валентина, милый мой, дорогой. Кара нинди матур сүзләр. «Валентина җаным» дисәң дә рәхәт бит.

Д и л е м м а. Ой! Перестаньте, ради бога.

Г ө л ф и н ә. Дәшмим, дәшмим, сеңлем, ачуланма, зинһар... Ә синең исемең ничек, сеңлем?.. *(Дилемма эндәшмәгәч.)* Казан роддомының шул инде аның, районда булса... Өченче баламны тапканда Малаевка авылының бер хатыны белән бер караватта яттык. Рәхәтләндек кенә сөйләшеп. *(Ишек төбендәге Исемсез хатынны күреп, янына килә.)* Карап-карап торам да, ни кермисез, ни китмисез. Йә кереп утырыгыз, йә...

Х а т ы н. Миңа анда керергә ярамый.

Г ө л ф и н ә. Нишләп ярамасын ди! Монда барыбыз да бертигез.

Х а т ы н. Мин бүтән отделениедән.

Г ө л ф и н ә. Булсагыз ни! Бездә йогышлы авырулар ятмый. Сезнең палатагыз кайда соң?

Х а т ы н. Аста.

Г ө л ф и н ә. Анда нинделәр ята?

Х а т ы н. Минем кебекләр.

Г ө л ф и н ә. Сез нинди соң?

Х а т ы н. Баласыз хатын.

Г ө л ф и н ә. Балагыз булмыймыни? Әйтәм аны... Ә сез бер дә кайгырмагыз. Балалардан кем рәхәт күргән. Интегеп, азапланып үстерәсең, үстерәсең дә... Әнә безнең күрше Хәдичә апа малайлары кайсы кая таралышып бетте, адреслары да билгесез.

Коридордан А й з а р ә Ә х ә т о в н а килә.

А й з а р ә *(Исемсез хатынга)*. Сез тагын биредә? Соңгы тапкыр кисәтәм, әгәр тагын бу отделениегә керсәгез...

Х а т ы н. Китәм, китәм... *(Югала.)*

А й з а р ә *(Гөлфинәгә)*. Ә сез монда нишләп торасыз? Керегез палатагызга.

Г ө л ф и н ә. Балам булмый, ди.

А й з а р ә. Булмаса, сез табып бирмәкче буласызмы?

Г ө л ф и н ә. Юатырга кирәк бит кешене.

А й з а р ә. Юатырга... Ятыгыз урыныгызга. *(Палатага керә.)*

Г ө л ф и н ә *(аңа иярә)*. Сез – врач кеше, алай дип әйтү сезгә килешми.

А й з а р ә. Аларга монда кереп йөрергә рөхсәт ителми, аңлыйсызмы? Сезгә дә теләсә кайда йөрергә ярамый.

Г ө л ф и н ә. Харап икән. Тегеләй ярамый, болай ярамый. Кешенең авыр хәсрәте бар. Җаны үрсәләнәдер, аңа сөйләшеп җиңеләергә кирәк.

А й з а р ә. Биредән чыккач иркенләп сөйләшерсез.

Г ө л ф и н ә. Аны кайчан күрәм мин.

А й з а р ә. Йә, йә, булды, тынычланыгыз. Ул хатынга сез дә, без дә ярдәм итә алмыйбыз. Моннан ун ел элек аборт ясаткан ул. Беренче баласына. Шуннан бүтән балага узмаган. Ул вакытта врачларны тыңламаган. Хәзер йөри. Без нишли алабыз, йә? Бирегез әле кулыгызны. *(Гөлфинәнең пульсын тыңлаганнан соң.)* Яхшы. Тик шулай да бик күп йөрмәгез. *(Валентина янына килеп.)* Йә, сезнең хәлләр ничек?

Г ө л ф и н ә. Курка ул.

А й з а р ә *(Валентинага)*. Нидән?

В а л е н т и н а. Сөтем җитәр микән?

А й з а р ә. Җитмәсә әйтерләр. Борчылмагыз. Барысы да яхшы булыр. *(Дилемма янына килеп.)* Бүген тордыгызмы әле?

Д и л е м м а. Юк.

А й з а р ә. Бераз йөрергә кирәк.

Д и л е м м а. Йөрергә ярамый миңа.

А й з а р ә. Нигә?

Д и л е м м а. Шулай. Сез врач — сез белергә тиеш. Олы корсаклы булып каласым килми.

А й з а р ә. Ай-яй, күп беләсез! *(Гөлфинәне күрсәтеп.)* Әнә бу апага карагыз, унике бала анасы — талчыбыгы кебек зифа.

Г ө л ф и н ә. Безнең бит май җыеп ятарга вакыт юк.

Д и л е м м а. Гомумән, әйтегез аларга. Миңа дәваланырга, ял итәргә кирәк, ә биредә базар.

А й з а р ә *(хатыннарга)*. Нигә шулчаклы тавышланасыз?

В а л е н т и н а. Кем тавышлана? Безме? Без сөйләшәбез генә, Айзарә Әхәтовна.

А й з а р ә. Әкренрәк сөйләшергә кирәк.

Г ө л ф и н ә *(Валентинага әкрен генә)*. Чебен тимәс чер итәрләр командасыннан икән теге.

А й з а р ә *(Алтынчәч янына килеп)*. Ә сез ничек?

А л т ы н ч ә ч. Яхшы.

А й з а р ә. Молодец. Йөрергә ашыкмагыз, сезгә иртәрәк әле.

А л т ы н ч ә ч. Әйтегез әле, кызлар әтиләренә охшыйлармы, әниләренәме?

А й з а р ә. Ә сез кемгә охшавын теләр идегез?

А л т ы н ч ә ч. Миңа түгел. Күреп торасыз. Ямьсез бит мин.

А й з а р ә. Кем әйтте аны сезгә?

А л т ы н ч ә ч. Минем яныма бер егет тә якын килмәде.

А й з а р ә. Димәк, җүләрләр.

Г ө л ф и н ә. Мин дә шулай дидем. Нәрсәгә сиңа егетләр, ирең булгач...

А й з а р ә *(Гөлфинәгә)*. Утырыгыз урыныгызга. Бөтен җиргә өлгерәсез, бөтенесен күрәсез, бөтенесен ишетәсез сез.

Г ө л ф и н ә. И күңелсез сезнең Казаныгызда, район больницасында рәхәтләнеп йөри идем.

Тышта ирләр тавышы ишетелә.

В а л е н т и н а *(тәрәзә төбенә менеп баса да форточкадан кычкыра)*. Саша!.. Сашенька!.. Мин бу!

Бу мин! Таныйсыңмы мине?! Ә?.. Яхшы! Борчылма, Сашенька!

Айзарә *(Валентина янына килеп)*. Төшегез хәзер үк.

Валентина. Доктор... Айзарә Әхәтовна... Зинһар өчен, пожалуйста... Саша килгән бит, Сашенька... Бер генә сүз әйтәм... *(Форточкага башын тыгып.)* Саша-а!.. Син мине яратасыңмы, Са-ша-а?

Айзарә. Әйткәнне аңлыйсызмы-юкмы?

Валентина *(тәрәзә төбеннән төшә-төшә)*. Аңлыйм, доктор, аңлыйм. *(Айзарә Әхәтовнаны кочаклап.)* Ой, белсәгез иде, доктор, белсәгез иде!.. Безнең бакчабыз бар, Айзарә Әхәтовна, чәчәкләр күп. Мин сезгә чәчәкләр китерәм әле. Барыгызга да, барыгызга да...

Айзарә. Яхшы, яхшы... Китерерсез. Тик тынычланыгыз. Тынычрак булырга кирәк, бала ашатасыгыз бар.

Валентина. Булды, булды, доктор. Ни әйтсәгез дә тыңлыйм. *(Караватына барып утыра.)*

Айзарә. Менә нәрсә, кадерле әниләр, форточка ирләр белән сөйләшү өчен уелмаган. Әгәр дә тагын шулай кылансагыз, кадаклап куячакбыз. Өйләрегезгә кайткач сөйләшерсез. Аңлашыламы?

Валентина. Аңлашыла, доктор, аңлашыла.

Гөлфинә. Өйгә кайткач ирләр белән сөйләшергә вакыт буламыни ул... Кешенең ирләре ир төсле. Безнеке йөридер чабып.

Айзарә. Йә, ярый... Тик, зинһар, әкренрәк... *(Чыгып китә.)*

Балаларның елаганы ишетелә. Арбага шул елакларны төяп, сестра Нина керә.

Нина. Ягез әле, апалар, алыгыз әле елакларыгызны. Тик сабыр, сабыр... Кабаланмыйча гына. *(Балаларны аналарына өләшә, Валентинага.)* Баланы алай кысып тотмыйлар, күрсәттем бит мин сезгә.

Валентина. Йә төшеп китәр.

Нина. Китми. Әнә апага карагыз. *(Алтынчәчкә.)* Башта ашатыгыз, нәрсә эзлисез аның битендә? Алар әлегә барысы да бертөсле.

Валентина. Түгел... Минеке...

Нина. Сөйләшмәгез. *(Дилеммага.)* Ә сез нигә ашатмыйсыз?

Д и л е м м а. Ашатырмын, борчылмагыз.

Н и н а. Мине борчылыр өчен укыттылар. *(Арбаны алып чыгып китә.)*

Бала имезгәндә генә була торган илаһи тынлык урнаша. Ул тынлыкны балаларның дәррәү елап алуы гына бозгалый. Ут бишек тирбәтүче ике Ананы гына яктырта. Алар үз җырларын дәвам итәләр.

Б е р е н ч е  А н а. Сайрар кошлар тынып калган,
Исәр җилләр ялга талган:
Изге тынлык бу дөньяда –
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.

И к е н ч е  А н а. Ага сулар тып-тын гына,
Тып-тын урман тыңлап тора:
Изге мизгел бу дөньяда –
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.

Б е р г ә. Атмый торсын атар туплар –
Дөрләмәсен хәтәр утлар,
Тынлык кирәк бу дөньяга –
Бала имезә Ана,
Бала имезә Ана.

Җырның соңгы юлларында сестра Н и н а тамаклары туеп, тынып калган балаларны төяп чыгып китә. Палата эче, коридор яктыра.

Г ө л ф и н ә. Бик үзсүзле булыр, ахры...

В а л е н т и н а . Каян беләсез аны, Гульфина апа?

Г ө л ф и н ә. Белмәскә... Мин аларның кайсы нинди буласын карынымда ятканда ук беләм. Нурисламым селкенеп тә карамады, хәзер дә йокы ярата. Әлфиям гел тибенеп торды, хәзер дә өстендә юрганын тотмый, Фәритем кыбырсына да кыбырсына иде, һаман утырган урынында тик кенә утыра алмый – боргалана...

А л т ы н ч ә ч. Ә минем кызым үземә охшамаган. Аның сеңлесенә охшаган. Ә ул чибәр. Аңарга сокланмаган егет юк.

В а л е н т и н а. Минеке нәкъ минем каенанам. *(Тавыш ишетеп, кинәт тәрәзәгә ташлана.)* Ой, кызлар, килегез әле, килегез. Бер көтү. Минекеләр. *(Тәрәзә төбенә менеп, форточкадан кычкыра.)* Әни-и!.. Исәнме, әнием!

Исәнмесез, Антонина Сергеевна! *(Хатыннарга карап.)* Минем каенанам. *(Урамга.)* Борчылмагыз... Искиткеч!.. Алдым, барысын да алдым... Антонина Сергеевна, оныгыгыз сезгә охшаган. Честное слово. Ә?.. Юк, юк, нормально... Сашаны ач йөртмәгез. Саша, тәмле ашаталармы сине? Кара аны, ач йөрмә.

Гөлфинә *(Валентинаның итәгеннән тартып)*. Валентина, сора әле, безнеке күренми микән шунда. Зарифулла күренми микән?

Валентина. Хәзер, хәзер, Гуля апа... Әйе, Саша, Зарифулла күренмиме анда? Ә?.. Гуля апаның ире.

Гөлфинә. «Гөлфинә» диген, Валентина, «Гуля» дигәнне аңламый бит инде ул Зарифулла.

Валентина. Әйе, Саша! Гульфина апаның ире анда булса, әйт, Гульфина апа сине эзли диген. Ә?.. *(Гөлфинәгә.)* Нindirәк соң ул, Гульфина апа?

Гөлфинә. Авыл кешесе әллә каян танылып тора инде. Кара чәчле булыр. Мыегы бар. Борынының сул канатында бәләкәй генә миңе дә бар. Уң кулын болгап йөрер. Керфекләре озын. Уртача буйлы. Өстенә ни кигәндер — белмим инде.

Валентина. Әй, Саша, әйбәтләп тыңла. Кара чәчле, борынында миңе бар, озын керфекле, уртача буйлы, уң кулын болгап йөри. Аңладыңмы? Аңладыңмы, Сашенька? Тапсаң, шушы тәрәзәгә килсен. Әнә, әнә шул син басып торган җиргә килсен. *(Кинәт Гөлфинәгә таба борылып.)* Гульфина апа! Карале, теге түгелме?

Гөлфинә *(тәрәзәдән карап)*. Шул, үзе, алабай. *(Валентина янына менеп баса. Алар хәзер икәүләп бер-берсен бүлешә-бүлешә сөйләшәләр.)*

Валентина. Саша! Саша! Кирәкми. Әнә ул үзе.

Гөлфинә. Зариф, чукынчык, нишләп йөрисең? Ә? Авылда әллә эшең беткәнме монда йөрмәсәң. Ә?.. Ни булсын ди миңа. Ничек эзләп таптың?.. Передача алып килдеңме?.. Балалар ни хәлдә?..

Валентина. Саша!.. Әни!.. Чәчәкләр алып килегез!.. Күп итеп чәчәкләр алып килегез. Ә?.. Озакламыйм... Әйтәм бит, барысы да нормально.

Гөлфинә. Зарифулла, мине ишетәсеңме? Гөлсинә сыерны сауганда үзең дә карап тор, сыерның гадәтен беләсең. Айраттан хат юкмы? Айдарны кара, су буена төшмәсен. Казларны алып кайтып ябарга онытмагыз.

В а л е н т и н а. Саша, ак күлмәгең гардеробның антресолендә. Безне алырга килгәндә галстук тагып кил.

Г ө л ф и н ә. Зарифулла, Зарифулла... Бар, кайт, монда болганып йөрмә, сүз әйтмәсеннәр. Уракка төшмәдегезме әле? Карап йөрт комбайныңны. Быелтыр да өч көн ремонтлап яттың.

В а л е н т и н а. Антонина Сергеевна...

Г ө л ф и н ә. Зарифулла, дүрт көннән чыгам. Килеп йөрмә, үзем кайтырмын.

В а л е н т и н а. Әни!..

Г ө л ф и н ә. Зарифулла, чукынчык, тукта, кая чабасың?

В а л е н т и н а. Әни!..

Г ө л ф и н ә. Зарифулла...

С е с т р а Н и н а керә.

Н и н а. Әй сез, төшегез әле аннан тизрәк!

Г ө л ф и н ә. Ярый, бар инде, бар, Зарифулла. *(Тәрәзә төбеннән төшеп, тәрәзәдән карап тора.)*

Н и н а. Кемгә әйтәләр. *(Валентинаның итәгеннән тарта.)*

В а л е н т и н а. Саша!.. Әни!.. Антонина Сергеевна! Сау булыгыз. *(Төшә.)*

Н и н а. Әгәр дә ачык форточка янында торып күкрәкләрегезгә салкын тидерсәгез... Бала-чага түгел бит инде сез, әйткәнне тыңларга кирәк. Врачка әйтәм.

Г ө л ф и н ә. Врач үзе дә белә инде. Миңа салкын тими ул, сеңлем.

Н и н а. Соңгы тапкыр кисәтәм.

В а л е н т и н а. Зинһар, гафу итегез.

Н и н а *(Дилемма янына килеп)*. Сез нигә балагызны ашатмадыгыз?

Д и л е м м а. Каян беләсез?

Н и н а. Белмәсәм, мин биредә эшләмәс идем. Нигә ашатмадыгыз?

Д и л е м м а. Нигә әле сез минем белән андый тонда сөйләшәсез?

Н и н а. Мин нормаль тонда сөйләшәм. Сез балагызны ашатмагансыз. Мин сәбәбен белергә тиеш.

Д и л е м м а. Минем күкрәкләрем авырта.

Н и н а. Врач беләме бу турыда?.. Нигә эндәшмисез?.. *(Дилемма эндәшмәгәч.)* Яхшы. Мин хәзер үк врачка әйтәм. *(Чыгып китә.)*

Г ө л ф и н ә. Син, сеңлем, алар белән матуррак сөйләш. Алар синең балаңны караучылар ич. Нәрсә, әллә имиләреңнең башы ярылганмы? Бала тапканчы белмисең шул ул нишләргә кирәген. Аны угалап, массаж ясап торырга кирәк. Әллә нинди әле син, сеңлем. Әллә бер зур начальникның баласымы? Безне санга сукмавыңмы?

В а л е н т и н а. Без биредә барыбыз да аналар.

Г ө л ф и н ә. Дөрес әйтә Валентина, монда бөтенебез бертигез. Ачылып китеп сөйләшсәң, без дә каршыңда көлеп торыр идек. Алай ярамый.

Д и л е м м а. Сөйләп бетердеңме?

Г ө л ф и н ә. Юк әле.

А й з а р ә Ә х ә т о в н а белән Н и н а керәләр.

Н и н а. Мин үлчәп карадым, Айзарә Әхәтовна, бала ашатылмаган.

А й з а р ә *(Дилеммага)*. Күрсәтегез әле күкрәкләрегезне. *(Караватка иелеп, Дилемманың күкрәкләрен карый.)* Икесе дә нормаль. Ничек авырталар? Имезгәндәме? Һәрвакытмы?

Д и л е м м а. Һәрвакыт.

А й з а р ә. Ягез әле, карыйк тагын бер мәртәбә.

Д и л е м м а. Карадыгыз — җитәр.

А й з а р ә. Гафу итегез, мин белергә тиеш.

Д и л е м м а. Белегез, алайса, авыртмыйлар.

А й з а р ә. Авыртмыйлар? Нигә, алай булгач?..

Д и л е м м а. Кирәкми.

А й з а р ә. Ничек «кирәкми»?

Д и л е м м а. Теләмим.

А й з а р ә. Ачыграк итеп әйтегез.

Д и л е м м а. Теләмим имезергә.

А й з а р ә. Ни өчен?

Д и л е м м а. Теләмим — бетте-китте. Нигә бәйләнәсез?

А й з а р ә. Сабыррак, сабыррак. Әйдәгез, җайлап кына сөйләшик. Мин бит сезнең палатагызның врачы, шуңа күрә мин белергә тиеш. Тиешме? Ни өчен балагызны имезергә теләмисез?..

Пауза.

Д и л е м м а. Миңа ул кирәкми.

Әлегә хәтле сөйләшкәнне дикъкать белән тыңлап утырган өч хатын — Г ө л ф и н ә, В а л е н т и н а, А л т ы н ч ә ч — аягүрә басалар.

А й з а р ә *(хатыннарга).* Утырыгыз, ханымнар. Сабыр. *(Дилеммага.)* Сәбәбе җитдиме?

Д и л е м м а. Җитди.

А й з а р ә. Ирегез бармы?

Д и л е м м а *(паузадан соң).* Юк. Юк минем ирем.

Бишек тирбәтүче Аналар бишек җырын башлыйлар.

Әлли-бәлли бәбкәсе,
Көйләр көйли әнкәсе,
Әнкәсенең янында
Бәбкәсенең әттәсе.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Палата яктырганда, Айзарә Әхәтовна да, Нина да юк. Алтынчәч караватында елап утыра. Аның ике ягына Гөлфинә белән Валентина утырганнар.

Г ө л ф и н ә. Алтынчәч, айналаем, бәгырь кисәгем, тукта. Йә, нигә, нигә инде җылыйсың?

В а л е н т и н а. Алтынчәч, милая, хорошая...

Г ө л ф и н ә. Ул бала безгә дә кызганыч. Нишләтик соң инде? Алданалар шул. Хатын-кыз алданыр өчен яратылгандыр инде.

В а л е н т и н а. Җылама, Алтынчәч, күрерсең, барысы да яхшы булыр. Кызып китеп кенә ул. Тынычланыр, уйланыр, барысы да яхшы булыр. Җылама инде, югыйсә мин дә җылый башлыйм. Бөтен кеше өчен дә җылап бетереп булмый ич инде. Без үзебез дә аның белән сөйләшербез.

Г ө л ф и н ә *(Алтынчәч елаудан туктагач).* Менә шулай. Сабырлык — сары алтын. Сездә дә шулай диләрме?

А л т ы н ч ә ч. Әйе...

В а л е н т и н а. Ә балаларга сездә ничек иркәләп дәшәләр, Алтынчәч?

А л т ы н ч ә ч. Колынчагым... Чырагым... Балапаным... Кымбатым...

Г ө л ф и н ә. И-и-и, кара ничаклы матур сүзләр...

А л т ы н ч ә ч. Күп алар.

В а л е н т и н а. Ә бездә — соколик ты мой, золотце мое, солнышко мое, сынуля, дочурка, лапочка, ненаглядный, ненаглядная...

Г ө л ф и н ә. Бигрәк тә күп инде матур сүзләр. Матур сүзләрне яратам шул мин. Бәгырь кисәгем, багалмам, йөрәк маем, матурым, тәтием, күземнең карасы, алтыным, көмешем, сандугачым, карлыгачым, гөлкәем… Шундый сүзләрне әйтергә тилмерүчеләр дә бар бит дөньяда. Әйтергә теләмәгәннәр дә бар.

А л т ы н ч ә ч. Барыбер ул хаклы түгел. Хаклы түгел! Кемдер теләмәгән дип кенә ана үз баласыннан баш тартырга тиеш түгел. Бала өчен ата җаваплы түгел, ана җаваплы. Ананың хакы юк. *(Караватында яткан Дилеммага карап.)* Хакың юк. Кемнеңдер үчен баладан алырга хакың юк.

Г ө л ф и н ә. Алтынчәч…

А л т ы н ч ә ч. Тыймагыз мине, юатмагыз. Мин барыбер аңа әйтәсемне әйтәм. Ул аңларга тиеш. *(Дилеммага.)* Хакың юк синең. Табигать сиңа олы бәхет биргән. Бала табу бәхетен биргән. Син рәхмәт әйтәсе урынга…

Г ө л ф и н ә. Йә инде, йә. Шаярта гына бит ул. *(Дилеммага.)* Юри генә бит син, сеңлем, әйеме?

Дилемма эндәшми. Дөресрәге, хатыннарның сүзләрен ишетми дә ул, ишетергә дә теләми… Ул күптән инде мондый карарга килгән, теләсә нинди гаепләү сүзләрен ишетергә әзер.

А л т ы н ч ә ч. Шаяртмасын да. Бала шаяра торган нәрсә түгел. Уенчык түгел ул. Уенчыкны да ташлап калдырмыйлар юньле кеше балалары. Ире юк, имеш. Минем дә ирем юк. Ләкин баламның атасы бар. Егетләр карамады миңа, кулымнан тотып сөям дип әйткән кешем булмады. Кияүгә алырга да теләмәделәр. Картаеп барганымны аңлагач, берәвесенә үзем ялындым. Бала анасы ит мине, дидем. Бу дөньядан бала анасы булып китәсем килде. Көлде генә ул берәү миннән, ышанмады чынлап әйткән сүзләремә, бәлки, курыккандыр да. Икенчесенә ялындым. Йөземә карарга курыксаң, төнлә кил, караңгыда йөземне күрмәссең, дидем. Бала табасым килә, дидем. Синең балаң икәнен берәүгә дә әйтмәм, дип ант иттем, еладым. Көлмәде ул миннән, аңлады мине. Мең-мең рәхмәтләр яусын аңа, ул мине бәхетле итте. Мин — ана, минем балам бар. Миннән соң да минем каным аңарда калачак, җанымның бер өлеше аңарда булачак. Минем балам минем күкрәк сөтемне имгәндә миннән дә бәхетле кем бар дөньяда! Ничек син?.. Җаның ничек чыдый?..

В а л е н т и н а *(елап җибәреп)*. Юк, мин ышанмыйм моңа. Теләсәгез нишләтегез, мин ышанмыйм. Ышанырга да теләмим.

Г ө л ф и н ә. Ягез, булды. Дөнья күрмәгәнсез әле сез. Бер дә ишеткәнегез юк мәллә? Ятыгыз урыннарыгызга. Ятасыгыз килмәсә, коридорда йөрегез. Нәрсә икәүләп ташландыгыз кешегә? Кешене сүгү җиңел ул. *(Дилемма караваты янына утырып.)* Нәрсә, алдандыңмыни, сеңлем? Син бик бетеренмә. Нишләтәсең инде хәзер. Боларга ачуланма да. Алар сине якын итеп кенә ачуланалар. Йә, торып утыр. Сеңлем тәмле күчтәнәчләр керткән, әйбәтләп сөйләшә-сөйләшә ашыйк. Җиңеләеп китәрсең. Сөйләш син, хәсрәтеңне эчеңә җыеп барма. Имез син балаңны. Алырсыңмы, алмассыңмы, башта имез. Аннан соң үзең дә тагын бер кат уйларсың. Иргә исең китмәсен. Ир-ат ир-ат инде ул. Ишегалдындагы әтәч кебек. Балаңны күргәч, ул да әле икенчерәк уйлар. Нәрсә, өйләнгән нәрсә идемени? Әтиең-әниең бармы соң?

Д и л е м м а. Китегез.

Г ө л ф и н ә. Кит дигәч... Китәрмен. Без монда гомер буе ятмыйбыз, күп булса, атна-ун көн. Яныңа килгәннәрне куарга ашыкма. Юкса килүче дә булмас. Ялгыз башың нишләрсең? Тор әйдә, тор, киреләнмә. Әдрисен әйт сине алдаган мәлгуньнең, без аңа хат язып салыйк... Яшь әле син, күп нәрсәне белмисең. Менә мин төннәрен уянып китәм дә балаларымның барысының да башларыннан сыйпап чыгам. Ә сыйпарлык кешең булмаса...

Д и л е м м а. Китегез, дидем.

Г ө л ф и н ә. Бәгырең каткан синең, җанкисәгем. Авыр булачак. Үзеңә дә, бүтәннәргә дә. Бәгыре каткан кеше куркыныч бит ул, сеңелкәем. Изгелек тә эшли алмый ул, эшләгән изгелекнең дә кадерен белми. Балаңның рәнҗүеннән курык, ичмасам. Ананың рәнҗүе – балага, баланың рәнҗүе анага төшә ул, дип әйтә минем әни. *(Айзарә Әхәтовнаның кергәнен күреп.)* Менә әле сөйләшәбез, иптәш врач, бик матур гына сөйләшәбез.

А й з а р ә *(Дилеммага)*. Нигә алдашасыз, Менгличева? Ирегез бар бит сезнең... Нигә эндәшмисез?

Д и л е м м а. Нигә сез миннән сорау аласыз?

А й з а р ә. Мин сезнең врачыгыз.

Д и л е м м а. Врач булсагыз, үз эшегез белән шөгыльләнегез. Сорау алу сезнең эш түгел.

А й з а р ә. Сез, ирем юк, дидегез. Сезнең ирегез бар. Законлы ирегез бар... Нигә эндәшмисез? *(Кызыксынып тыңлап торган хатыннарга.)* Мөмкин булса, беразга гына чыгып торыгыз әле, ханымнар. *(Хатыннар чыгып киткәч.)* Сезнең законлы ирегез бар, Менгличева.

Д и л е м м а. Әйе, бар. Шуннан?

А й з а р ә. Сез аның белән бергә торасыз.

Д и л е м м а. Әйе, торабыз.

А й з а р ә. Нигә алдашырга?

Д и л е м м а. Анысы минем эш.

А й з а р ә. Сезнең баланы алырга теләмәвегезне ирегез беләме?

Д и л е м м а. Үзеннән сорагыз.

А й з а р ә. Ул командировкада.

Д и л е м м а. Ул студотрядта. Сезгә бездән ни кирәк?

А й з а р ә. Миңа сездән берни дә кирәкми, иптәш Менгличева. Мине сезнең балагызның язмышы борчый.

Д и л е м м а. Нигә сез аңа борчыласыз?

А й з а р ә. Баланың әнисе борчылмый икән, кемдер борчылырга тиеш ич инде. Мин аңламыйм сезне, Менгличева.

Д и л е м м а. Аңлашылмаслык ни бар? Баланы алмаячакмын. Һәм минем ирем дә, законлы ирем дә шул ук фикердә.

А й з а р ә. Ни өчен?

Д и л е м м а. Әлегә безгә бала кирәкми. Ул безгә комачаулый.

А й з а р ә. Ничек?

Д и л е м м а. Бала карарга безнең вакытыбыз юк. Безгә икебезгә дә укып бетерергә кирәк.

А й з а р ә. Әниләрегез бармы?

Д и л е м м а. Без аларга бурычлы булырга теләмибез. Икебез дә.

А й з а р ә. Алайса, нигә балага узарга иде?

Д и л е м м а. Ул безнең ялгышыбыз.

А й з а р ә. Нигә абортка кермәдегез?

Д и л е м м а. Беренче баланы төшерткәннән соң икенче балага узмавыгыз ихтимал, диделәр. Кем белә, бәлки, безгә киләчәктә бала кирәк булыр.

А й з а р ә. Шундый тыныч сөйләшәсез!..

Д и л е м м а. Ә нигә аһылдарга?.. Артык эмоция сәламәтлеккә зарарлы.

А й з а р ә. Сүз сезнең балагыз турында бара.

Д и л е м м а. Аңлыйм. Беләм.

А й з а р ә. Аңлап бетермисез, сеңлем.

Д и л е м м а. Сез нәрсә?.. Сеңлем дә сеңлем. Әйттеләр бит сезгә — бала безгә кирәкми. Кемгә кирәк, шул алсын. Минем... Безнең бернинди дә претензиябез юк һәм булмаячак та.

А й з а р ә. Ирегезне чакырып кайтарырга туры килер.

Д и л е м м а. Файдасы булмаячак. Без икебез дә принципиаль кешеләр.

А й з а р ә. Әниләрегез белән сөйләшәчәкбез.

Д и л е м м а. Сөйләшегез. Телиләр икән — алсыннар. Тик безгә претензияләре булмасын.

А й з а р ә. Коточкыч! Мондый хәлне беренче тапкыр очратам.

Д и л е м м а. Тагын очратырсыз да икенче булыр... Нигә карап торасыз? Оялтырга теләпме? Юкка тырышасыз.

А й з а р ә. Сез укыган институтка хәбәр итәчәкбез.

Д и л е м м а. Без ул вариантны да уйладык. Без җинаять эшләмибез. Аборт ясатып үтергәнгә хөкем итмиләр, ә моның өчен нигә хөкем итәргә тиешләр? Ни аермасы бар?

А й з а р ә *(кыза төшеп)*. Кем карарга тиеш сезнең балагызны? Уйладыгызмы шул хакта? Кем карарга тиеш?

Д и л е м м а. Кабатлап әйтәм: кемгә кирәк, шул карар. Андыйларны карый торган махсус урыннар бар.

А й з а р ә. Дәүләт җилкәсенә?

Д и л е м м а. Дәүләтнең җилкәсе юк. Дәүләт үзе кешеләр җилкәсендә утыра. Дәүләткә хезмәт итәргә кешеләр кирәк. Кирәк икән — үстерсен.

А й з а р ә. Иманыгыз бармы сезнең?

Д и л е м м а. Мин ул сүзне аңламыйм.

А й з а р ә. Бишек җыры беләсезме сез?

Д и л е м м а. Безгә аны өйрәтмәделәр.

А й з а р ә. Сез бит ана!

Д и л е м м а. Мин хатын-кыз гына. Ул миңа корсакта чакта ук ят иде.

А й з а р ә. Кеше исемен йөртәсез бит сез!

Д и л е м м а. Кеше исемен йөртүчеләр миллиард белән исәпләнә. Барысы да сез күз алдына китергәнчә түгелдер. Сез тормышны үзегезчә күрәсез, мин — үземчә. Мин бит,

нигә минемчә уйламыйсыз, дип бәйләнмим, нигә сез үз рецептыгыз белән миңа бәйләнәсез?

Айзарә. Туктагыз әле, бәлки, сез чынлап түгелдер, ә? Болай гынадыр, безне сынап карау өчен генәдер?

Дилемма. Ә нигә сезне сынарга? Ул минем вазифама керми. Шулай ук мине сынау да сезнең эш түгел. Мин ничек телим, шулай яшим.

Айзарә. Әгәр мин үзем теләгәнчә эшләсәм, сезне моннан типкәләп чыгарыр идем.

Дилемма. Чыгарыгыз. Булдыра алсагыз.

Айзарә. Кызганычка каршы, гуманность дигән нәрсә бар дөньяда. Кешелеклелек бар.

Дилемма. Әйе, бар. Кызганычка каршы...

Айзарә. Ичмасам, имезә торыгыз. Чыкканда алмассыз.

Дилемма. Сез врачлар телендә сөйләшмисез, авыл апасы кебек сөйләшәсез. Нигә миңа аны имезергә? Ярамый миңа аны имезергә. Иятләшмәсен... мин арыдым, миңа ял итәргә кирәк. Мәсьәлә ачык. Калганын үзегез хәл итәрсез.

Айзарә. Бәлки уйларсыз, ә, сеңелкәем, бәгырькәем. Карале, күзләремә карале. Күңелеңнең бер почмагында, бәлки, миһербан очкыны калгандыр? Карале күзләремә. *(Дилемма эндәшмәгәч, әкрен генә урыныннан тора да ишеккә юнәлә.)*

Аны коридорда хатыннар каршы алалар.

Валентина. Доктор...

Айзарә. Барыгыз, керегез. *(Кабинетына уза. Хәле бетеп урындыкка утыра.)*

Сестра Нина керә.

Нина. Айзарә Әхәтовна... Сезгә ни булды, Айзарә Әхәтовна? Нигә шулай карап торасыз, Айзарә Әхәтовна?

Айзарә. Йөргән егетең бармы синең, Ниночка?

Нина. Нигә сорыйсыз, Айзарә Әхәтовна?.. Бар.

Айзарә. Әйбәтме?

Нина. Кайсы мәгънәдә?

Айзарә. Ниночка, әйтмә шул кайсы мәгънәдә дигән мәгънәсез сүзне.

Нина. Гафу итегез, яратамы дип сорыйсызмы? Кем белә инде аны.

А й з а р ә. Ә кем белергә тиеш?

Н и н а. Мин, билгеле.

А й з а р ә. Ошыймы сиңа монда?

Н и н а. Кайсы мәгънәдә, Айзарә Әхәтовна?.. Гафу итегез, Айзарә Әхәтовна, ошамаса, эшләмәс идем. Ничаклы бала, бәхетле аналар.

А й з а р ә. Ә бәхетсезләре? Ә бәхетле булырга теләмәгәннәре?

Н и н а. Тормыш бит, Айзарә Әхәтовна. Төрлесе була... Бәхетлеләр күбрәк...

А й з а р ә. Бишенче палатадагы Менгличевага баласын кертмәгез.

Н и н а. Яхшы, Айзарә Әхәтовна.

А й з а р ә. Туктагыз әле, бәлки, алып керергәдер, ә? Бәлки... Ничек уйлыйсыз, Ниночка?

Н и н а. Белмим.

А й з а р ә. Ә кем белергә тиеш?

Н и н а. Сез әллә нинди, Айзарә Әхәтовна.

А й з а р ә. Мин ул хатын белән сөйләштем...

Н и н а. Ә нигә аның белән сөйләшеп торырга.

А й з а р ә. Кеше ич ул.

Н и н а. Кеше? Кеше андый булмый, Айзарә Әхәтовна.

А й з а р ә. Нинди була?

Н и н а. Кеше төсле була.

А й з а р ә. Әнисен чакыртыгыз әле аның. Иренең әнисен дә.

Н и н а. Яхшы, Айзарә Әхәтовна.

А й з а р ә. Син бишек җыры беләсеңме, Ниночка?

Н и н а. Кайсы мәгънәдә?.. Гафу итегез...

А й з а р ә. Ярый, калдыр мине үземне генә. Әз генә ял итим.

Н и н а чыгып китә. Ишектә Г ө л ф и н ә күренә.

Г ө л ф и н ә. Керергә ярыймы соң?

А й з а р ә. Ни бар?

Г ө л ф и н ә. Болай гына иде...

А й з а р ә. Керегез соң, алайса, болай гына.

Г ө л ф и н ә *(кереп, утырып)*. Эчем пошып китте әле менә.

А й з а р ә. Нидән?

Г ө л ф и н ә. Нидән дип... Әллә ничек бит.

А й з а р ә. Нәрсә «әллә ничек»?

Г ө л ф и н ә. Бөтен җирдә дә шулай микән?

А й з а р ә. Ничек?

Г ө л ф и н ә. Беләсез ич инде.

А й з а р ә. Барыгыз, кереп ятыгыз. Сез һәрвакыт аяк өстендә. Өзлегеп китсәгез...

Г ө л ф и н ә. Өзлексә тагы. Кызык та түгел.

А й з а р ә. Биредә кәмит күрсәтмиләр бит.

Г ө л ф и н ә. Күрсәтәләр икән шул менә. Авылга кайтып сөйләсәм, ышанмыйлар инде.

А й з а р ә. Авылда бөтенесе әйбәтмени?

Г ө л ф и н ә. Төрлесе бар да, болай ук түгел инде барыбер. Ирләр кайда да азгын инде, хатын-кызның болай булганы юктыр.

А й з а р ә. Яхшылары күбрәк кенә түгел, бик күп. Шуңарга күрә мондый хәл куркыныч булып тоела да. Ияләшмәсәк иде. Ирсез бала үстерүгә инде ияләштек, күнектек; ирсез бала тапканнарның балаларын алмавына ияләшеп барабыз. Ә монда... Ирле-хатынлы икесе дә салкын акыл белән... Монысына да ияләшсәк, кем булабыз инде без, балаларыбыз кем була?..

Г ө л ф и н ә. Шулай шул.

А й з а р ә. Бишек җырларын онытып барабыз.

Г ө л ф и н ә. Шулай шул... Онытып барабыз икән шул... Авыр инде сезгә дә монда эшләве, әйеме? Үзегезнең балаларыгыз бармы соң?

А й з а р ә. Бар.

Г ө л ф и н ә. Берәү генәме?

А й з а р ә. Өчәү.

Г ө л ф и н ә. Анысы яхшы икән әле.

А й з а р ә. Кем белә инде. Улым, кызым дип башларыннан сыйпарга вакыт та юк. Чабабыз да чабабыз.

Г ө л ф и н ә. Баштан сыйпар өчен күп вакыт кирәкми анысы. Гел сыйпап торганны да яратмый бала-чага. Күңелең изгедә булса, тоя ул бала-чага әнисенең күңелен. Әтисен дә шулай.

А й з а р ә. Шулайдыр. Сезнең тәҗрибә зуррак.

Г ө л ф и н ә. Кеше булсыннар иде инде, ил алдында оятка калдырмасыннар иде. Үзең генә белсәң ул, авыр булса да түзәсең, менә ил сөйләсә балаңны хурлап, анысын күтәреп булмыйдыр. Олы малайга әтисе Зарифулла әйтә әле беркөн, кара аны, әгәр кешеләр алдында яманатың чыкса, сиңа бер сүз әйтмим, үзем басу капкасына чыгып

асылынам, ди... Көлеп кенә йөрисе урынга, әллә нинди күңелсез нәрсәләр сөйләшеп утырабыз, әйеме?.. Карагыз әле, аны бездән чыгарсагыз яхшы булыр иде.

Айзарә. Кая чыгарыйк? Бөтен палаталарда да сезнең кебек кешеләр.

Гөлфинә. Шулаен шулай да. Мин үзем болай түзем халык та, икебез бик ни бит. Бала дигән нәрсә аларга бигрәк кадерле. Ул-бу булып куймагае дип куркам.

Ашыгып, Валентина килеп керә.

Валентина. Доктор!.. Әйдәгез тизрәк... Алтынчәч!.. Алтынчәч!..

Барысы да ашыгып палатага юнәләләр.
Бишек җыры дәвам итә:

Әлли-бәлли, бәбием,
Кая киткән әниең?
Мәми алырга киткән,
Әз генә көт, нәнием.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

Палата эче яктырганда, палатада Гөлфинә, Валентина, Алтынчәч һәм сестра Нина. Дилемма юк. Караватында яткан Алтынчәчкә Нина яңа гына укол кадаган.

Нина *(Гөлфинә белән Валентинага)*. Әкренрәк йөрегез, йокласын.

Гөлфинә. Баласын үзем имезим, сеңлем, сөтем җитәрлек минем.

Нина. Ятыгыз урыныгызга, ач булмас.

Гөлфинә. Ятам, сеңлем, ятам. *(Караватына барып ята. Нина чыгып киткәч.)* Менә күрдеңме инде, Валентина. Бик артык нитәргә ярамый. Үз нервыңа үзең баш булырга кирәк.

Валентина. Алтынчәчнең баласы кызганыч.

Гөлфинә. Яле, син юкны сөйләмә. Монда баланы ачтан үтерәләр димени. Үзе дә бик әйбәт булыр. Үтә, диде бит врач.

Валентина. Барысы да шул кабахәт аркасында...

Гөлфинә. Булды дим, җитте.

Пауза. Тышта ир-атның кычкырган тавышы ишетелә.

В а л е н т и н а. Саша... *(Торып тәрәзә янына бара. «Тавышланырга ярамый» дигәнне кулы белән ишарәләп аңлата. Саша аңламагач, тәрәзә төбенә менеп, форточкадан башын тыгып аңлата.)* Сашуля! Бездә йоклыйлар... Бар, җаным, кайт. Яхшы. Бөтенесе дә яхшы. *(Тәрәзә төбеннән төшеп.)* Ачуланмагыз инде, Гульфина апа. Килгән бит.

Г ө л ф и н ә. Менә кызык, нигә ачуланыйм.

Валентина урынына барып ята. Д и л е м м а керә. Форточканы ябып куя да ята. Валентина торып форточканы ача.

Д и л е м м а. Ябыгыз. Сквозняк.

Г ө л ф и н ә. Нинди сквозняк булсын. Алтынчәчкә һава кирәк.

Д и л е м м а. Ябыгыз, диләр. *(Тора башлый.)*

В а л е н т и н а. Килеп кенә кара. Хәзер форточкадан тотып ыргытам. Синең сасыңны иснәп ятарга монда, поганая!

Д и л е м м а. Замолчи!

В а л е н т и н а. Вот я замолчу тебе, стерва!

Г ө л ф и н ә. Валентина, кемгә әйтәләр!.. *(Дилеммага.)* Әйтеп торалар бит сиңа. Күреп торасың Алтынчәчнең хәлен.

Дилемма җәймәсенә бөркәнеп ята. Гөлфинә торып Валентина янына килә, караватының читенә утыра.

Син сүгенмә, Валентина, ямьсез сүзләр әйтмә.

В а л е н т и н а. Ул гына аз әле аңа.

Г ө л ф и н ә. Барыбер кирәкми. Кешене ямьсез сүз әйтеп төзәтеп булмый. Аннары, синең ул сүзләреңне улың ишетеп ята... Әйе, әйе, ишетми димә, күңеле белән ишетә ул. Бала ул синең ни уйлаганыңа хәтле ишетеп ята. Тәмсез телле хатыннарның балалары да тәмсез телле була.

В а л е н т и н а. Сезнең бер дә сүгенгәнегез юкмы?

Г ө л ф и н ә. Юк.

В а л е н т и н а. Эштә дәме?

Г ө л ф и н ә. Барыбер инде ул. Эштә ни, өйдә ни.

В а л е н т и н а. Әй, безнең эштә! Ике сүзнең берендә...

Г ө л ф и н ә. Бездә дә инде анысы. Сыер саудым мин унике ел. Сүгенәләр. Хатын-кызлар сүгенә, Валентина җаным. Тик торганнан сүгенә. Сыерны да сүгә, сөт алырга килгән шофёрны да сүгә. Өенә кайткач та сүгенә.

Әллә нинди сүгенү сүзләре беләләр, матур сүз белмиләр. Әнә врач әйтеп торды: бишек җырларын онытып барабыз, ди. Шунда эчемнән генә оялып куйдым. Минем дә байтактан җырлаганым юк икән бишек җырын. Гел җырлап тормасаң, онытыла шул ул. Син бишек җыры беләсеңме, Валентина?

Валентина. Бишек җыры?.. Бишек җыры... Белмим бит, Гульфина апа.

Алтынчәч. Ә мин беләм...

Гөлфинә. Менә уяттык та... *(Алтынчәч янына килеп.)* Син йокла, Алтынчәч айналаем, йокла... Телемне тыя алмыйм шул, телемне.

Алтынчәч. Мин йокламый идем. Сөйләшегез, мин сезне тыңлап ятыйм.

Гөлфинә. Юк инде, юк, сестра сөйләшмәскә кушты.

Алтынчәч. Минем сезне тыңлыйсым килә.

Валентина *(Алтынчәч янына килеп)*. Куркыттың бит, Алтынчәч. Яхшымы инде хәзер?

Алтынчәч. Сөйләшегез.

Гөлфинә. Сөйләш дигәндә сүзен дә табып булмый бит ул. Менә әле хәлең яхшыргач, синнән бишек җырыгызны җырлатабыз. Авылга отып алып кайтам. Аптырасыннар әле балалар.

Валентина. Мин дә Сашага әйтәм, язып алып килсен.

Дилемма урыныннан торып чыгып китә.

Гөлфинә. Түзмәде. Башына уй керә башлады, ахрысы. Борсалана. Без әле бергәләп юри ул барында өчәүләп бишек җыры җырларбыз. Әйтте диярсең, үкереп җылаячак. Аннары «китерегез минем баламны» диячәк. Җырның шунысы яхшы — үзәккә барып кадала. Бервакыт безнең авылда мондый хәл булган. Бер кыз төбәлеп әнисенә карап тора икән. Нигә шулай карап торасың, кызым, дип сораган әнисе. Синнән туганыма хурланып карап торам, дигән кыз. Шул көнне авылга концерт килгән икән. Шунда бер җырчы бик моңлы итеп «Әнием, күз нурым» дигән җырны җырлаган. Шул җырны тыңлаганнан соң, теге кыз клубта җылап җибәргән. Өйләренә кайткач, әнисен кочаклап, әнием, күз нурым, гафу ит мине, дип җылаган. Аннары соң күрше авылда — Салтыкта болай булган...

Гөлфинә сөйли, безгә аның ни сөйләгәне ишетелми. Коридорда Исемсез хатын пәйда була. Палатада сөйләшкән сүзне тыңлап тора. Сестра Нина килгәнне күргәч, качмакчы була да, кире уйлап, Нинаның каршына килә.

Нина. Тагын сез?! Бүген үк бездән чыгып китәсез. Кисәтеп арыдым.

Хатын. Зинһар, тавышланмагыз инде. Бер генә нәрсә сорыйм.

Нина. Сорамагыз да, тыңламыйм да. Хәзер үк чыгып китегез.

Хатын. Сестра...

Нина. Чыгып китегез! *(Коридордан килүче Айзарә Әхәтовнага.)* Айзарә Әхәтовна, мин берни эшли алмыйм. Милиция чакыра алмыйм бит инде.

Айзарә. Кем җибәрә соң аны монда?

Нина. Кем белә. Ничә тапкыр әйттем. Без белмибез, диләр.

Хатын. Иптәш врач... Зинһар өчен...

Айзарә. Әйткәнне аңлыйсызмы сез, юкмы?

Хатын. Аңлыйм. Зинһар өчен, тыңлагыз мине. Әз генә.

Айзарә. Йә, тыңлыйм, тыңлыйм. *(Кабинетка уза. Исемсез хатын аңа ияреп керә.)* Йә, тыңлыйм. Нинди кеше соң сез, әйтеп торалар лабаса. Йә, сөйләгез.

Хатын. Гинекология бүлегеннән мин.

Айзарә. Беләм.

Хатын. Балам юк минем. Дәваланам.

Айзарә. Беләм.

Хатын. Мин белмәдем. Яшь идем әле. Аборт ясатырга куштылар. Шулай туры килде. Врачлар әйтте — тыңламадым. Ышанмадым. Яшь идем әле мин. Бүтән булмады. Балам юк минем.

Айзарә. Ә мин нишли алам?

Хатын. Бала кирәк миңа. Ярдәм итегез.

Айзарә. Ярдәм?.. Нинди ярдәм?

Хатын. Бала кирәк миңа!

Айзарә. Әйттегез.

Хатын. Аерылышабыз, ди, ирем. Мин аны яратам. Мин ансыз тора алмыйм. Башта аборт ясатырга үзе кушты, хәзер, аерылышабыз, ди. Бала кирәк миңа, ди. Бала кирәк миңа.

Айзарә. Аңладым бит инде, җанкисәгем. Берни дә эшли алмыйм бит мин сезгә.

Х а т ы н. Эшли аласыз. Мин ишеттем.

А й з а р ә. Нәрсә ишеттегез?

Х а т ы н. Теләсәгез, эшли аласыз.

А й з а р ә. Әйтегез соң, ничек эшли алам?

Х а т ы н *(колагыннан алтын алкаларын, бармакларыннан йөзекләрен салып өстәлгә, Айзарә алдына куя)*. Мәгез, алыгыз.

А й з а р ә. Нәрсә болар?

Х а т ы н. Алыгыз, сезгә. Тик, зинһар, ярдәм итегез.

А й з а р ә. Җыеп алыгыз әле боларны. Һәм, барыгыз, чыгып китегез. Барыгыз, күземә күренмәгез.

Х а т ы н. Туктагыз әле.

А й з а р ә *(урыныннан торып)*. Мин сезгә әйттем.

Х а т ы н *(алка, йөзекләрне алып)*. Ярый, ярый, ачуланмагыз. Тик ярдәм генә итегез. *(Айзарәнең каршына тезләнеп.)* Ярдәм итегез миңа. Миңа әйттеләр. Өйрәттеләр. Роддомнан бала алып чыгып була, диделәр. Мин иремне алдадым. Балага уздым, дидем. Роддомга бала табарга керәм, дидем. Ул әлегә командировкада. Ул командировкада чакта кердем. Ярдәм итегез миңа!

А й з а р ә. Кызганычка каршы, мин сезгә берничек тә яр-дәм и-тә ал-мыйм.

Х а т ы н. Аласыз. Мин барысын да беләм. Баласын алмый, диделәр. Бирегез миңа шул баланы.

А й з а р ә. Торыгыз. Яле, торыгыз, тор. Утырыгыз. Тынычланыгыз. Хәзер инде мине тыңлагыз. Тыңлый аласызмы мине?

Х а т ы н. Тыңлыйм.

А й з а р ә. Алкаларыгызны, йөзекләрегезне киегез.

Х а т ы н. Киям, киям…

А й з а р ә. Менә шулай. Инде менә болай: кем сезгә әйткәндер артык бала бар дип, белмим. Әмма булган очракта да болай гына җиңел генә эшләнми ул. Бала бит, адәм баласы! Монда итәк астыннан гына алыш-биреш итәргә сорочи базары түгел.

Х а т ы н. Әйттеләр, мөмкин, диделәр.

А й з а р ә. Кем әйткән, шул килеп безне өйрәтсен, ничек эшлиләр икән. Менә мин сезгә әйтәм: сезгә бала биргән очракта да сезнең бала түгеллеген ирегез белергә тиеш.

Х а т ы н. Ул белергә тиеш түгел. Ул риза булмаячак. Мин аңарга әйттем, бала алыйк, дидем, риза булмады.

А й з а р ә. Башкача мөмкин түгел. Закон бар.

Х а т ы н. Ярдәм итегез.

А й з а р ә. Нинди кеше соң сез?.. Мин сезгә әйтеп торам.

Х а т ы н. Ярдәм итегез. *(Җан ачысы белән кычкырып.)* Бала кирәк миңа! Миңа бала кирәк!.. Бала кирәк!..

Ике Ана бишек җырын дәвам итәләр:

Йөрәгемнең парәсе,
Ике күзем карасы,
Мәхәббәтем чаткысы,
Күңелемнең яктысы.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү...

Шушы көй белән беренче пәрдә тәмамлана. Шушы ритмда залдагы утлар кабына.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге күренеш. Сәхнәнең ике ягындагы ике бишек кенә өскәрәк күтәрелгән. Хәер, алар, адәм баласының күренми, сизелми генә үсеп әниләреннән аерылганын хәтерләтеп, спектакль дәвамында әз-әзләп кенә күтәреләләрдер. Бишек тирбәтүче и к е  А н а бишек җырын дәвам итәләр:

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам-багалмам,
Үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры,
Күчәрсеңме син?
Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем,
Яшәрсеңме син?
Әнием, диеп, кадерлем, диеп,
Сандугачкаем,
Дәшәрсеңме син?
Гомрең сукмагын зур юллар буйлап,

Өмет йолдызым,
Үтәрсеңме син?
Илеңнең данын,
Намус, Вөжданын,
Балам, әй, дәвам
Итәрсеңме син?

Коридор әкренләп яктыра. Сестра Н и н а тамаклары тук балаларны палатадан төяп алып чыга. Аңа В а л е н т и н а иярә.

Н и н а. Сез кая?

В а л е н т и н а. Озатып куям.

Н и н а. Ни өчен?

В а л е н т и н а. Ул-бу булмагае.

Н и н а. Ни булсын ди аларга? Мин алар өчен сездән күбрәк җавап бирәм.

В а л е н т и н а. Сашенькага карап кына калыйм инде.

Н и н а. Имезгәндә карамадыгызмыни?

В а л е н т и н а. Эх, Ниночка, аңа карап туеп буламыни. Сезнең әле балагыз юк... белмисез.

Н и н а. Бала уенчык түгел. *(Арбасын этеп китә.)*

В а л е н т и н а *(палатага кереп)*. Бигрәк кырыс бу Нина.

Г ө л ф и н ә. Шулай тиештер аңа. Роддомдагы бөтен хатыннар белән кочаклашып йөри алмый ич. Аңа эш эшләргә кирәк. Син, Валентина, аның кырыслыгын әйтмә, балаларны ничек итеп тотуын кара. Мин үз баламны да алай матур итеп тота алмыйм.

А л т ы н ч ә ч. Рәхә-әт.

В а л е н т и н а. Нәрсә рәхәт, Алтынчәч?

А л т ы н ч ә ч. Сезгә дә шулаймы, бала имгәч, җанга рәхәт.

В а л е н т и н а. Сиңа да шулай, да? Минем тәннәрем рәхәтләнеп, җиңеләеп китә. Менә хәзер мин җип-җиңел. Әйдәгез, кызлар, хәзер утырып ашыйбыз. Сезнең дә ашыйсыгыз киләме, ә минем һаман тамак туймый.

А л т ы н ч ә ч. Минем ашыйсым килми.

В а л е н т и н а. Алдашма, Алтынчәч. Син, беләм, юри генә. Нигә ояласың? Минем мондагы передачаны ашап бетererлек түгел. Килегез, Гульфина апа. Графиня Гульфина, кушать подано.

Г ө л ф и н ә. Графиня ничек дип әйтә инде?

В а л е н т и н а *(графиня булып)*. Мерси.

Г ө л ф и н ә *(графиня булып)*. Мирси. Алтынчәч, подходи.

А л т ы н ч ә ч. Мин графиня түгелмени?

В а л е н т и н а. Син – княгиня, Алтынчәч.

Г ө л ф и н ә. Кайсысы зур соң аларның?

В а л е н т и н а. Кем белә инде анысын. Эх, рәхәт, кызлар!.. Эшлисе юк, ашап кына ят, ә? Шулай да эшемне сагынам.

А л т ы н ч ә ч. Кем булып эшлисең, Валентина?

В а л е н т и н а. Штукатур-маляр.

Г ө л ф и н ә. Сагынырлык эш икән шул.

В а л е н т и н а. Алай димәгез, Гульфина апа, һәр эшнең үз матурлыгы бар. Эшемнән дә бигрәк бригададагы иптәш кызларымны сагындым. Менә бусы алар күчтәнәче. Нигә туктадың, Алтынчәч? Оялма инде, аша.

Г ө л ф и н ә. Казахларда аша димиләр, җиең, җиең, диләр.

В а л е н т и н а. Җиең, җиең, Алтынчәч.

А л т ы н ч ә ч. Миңа чыннан да җитте. Рәхмәт.

Ашаганда хатыннар караватында китап укып яткан Дилеммага карап-карап алалар. Гомумән, Дилеммага аларның берсе дә битараф түгел. Бу юлы Гөлфинә Дилемма ягына карый да Валентинага пышылдый.

Г ө л ф и н ә. Чакырмыйбызмы?

В а л е н т и н а. Китабын укысын.

Г ө л ф и н ә. Аңламыйдыр ул, мондый чакны укып була димени?

В а л е н т и н а. Ничек кенә аңлый әле... Булды. Безнең бригадир Соня апа әйтмешли, алла акбар. Хәзер нишлибез? Ятып йоклыйбызмы?

Г ө л ф и н ә. Ашагач ук йокларга ярамый, диләр. Алтынчәчнең бишек җырын өйрәнәсебез бар. Таралыр вакыт җитә.

В а л е н т и н а. Ну, Сашага эләгәчәк, һаман алып килми. Алтынчәч, давай.

А л т ы н ч ә ч. Ярый микән соң монда?

Г ө л ф и н ә. Монда да бишек җыры җырларга ярамагач... Әйдә.

А л т ы н ч ә ч *(казах халкының бишек җырларыннан берсен әкрен генә көйли)*.

Көзимнең агы, карасы,
Җүрегимниң парасы.
Дуние камды ойлатпас,
Көңилимниң данасы.
Әлди, балам, әлди.
Айналаен, шырагым,
Көлге биткен корагым,
Җагамдагы кондызым,
Әйдеги жолдызым.
Әлди, балам, әлди.
Айналайын балам-ай,
Айналсын сенен анаң-ай,
Әлдилеп сени сүйгендә
Ананың болар күңили җай.
Әлди, балам, әлди.

Гөлфинә. Үзәкләрне өзеп ала шул.

Валентина. Кем булып эшлисең син, Алтынчәч?

Алтынчәч. Балалар бакчасында тәрбияче идем.

Гөлфинә. Күренеп тора шул.

Валентина. Нигә «идем» дисең, Алтынчәч?

Алтынчәч. Хәзер эшләмим. Дүрт ай. Беленә башлагач киттем.

Валентина. Беленсә ни…

Гөлфинә. Алай димә, Валентина. Кеше бит ул, беләсең, бигрәк тә хатын-кыз, аны-моны уйлап тормый, әйтә дә сала. Син берәүдән дә курыкма да, оялма да, Алтынчәч. Син бит аны зина кылып тапмаган.

Алтынчәч. Әни җылады.

Гөлфинә. Әниләр җылый инде ул, нишләтәсең. Аңлагач җыламас әле. Син бит инде уналты-унҗиде яшьлек кыз түгел.

Валентина. Кызык бу тормыш дигәнең, әйеме? Ишетеп, тыңлап, күреп торасың… Безнең бригадада гел хатын-кызлар. Утырып сөйләшәбез дә кайвакыт, үзебез шаккатабыз. Барысына да «ирләр гаепле»!

Гөлфинә. Ничек «ирләр гаепле»?

Валентина. Ир кешеләр бетеп бара бит, Гульфина апа. «Мурзилка» журналына бесплатное приложение булып кына яшиләр. Кемне генә тыңласаң да, шуны әйтә. Безнең Соня апа да әйтә, ирләргә ышаныч юк, ди. Ертыгыма ямау булыр дип чыккан буласың кияүгә, аннары гомер буе интегәсең исерек ир тәрбияләп, ди.

Гөлфинә. Кем соң инде ул Соня апа дигәнең?

Валентина. Безнең бригадир.

Гөлфинә. Шулай бик күп беләмени?

Валентина. Аның инде пенсиягә чыгарга вакыты җитә. Күргән инде дөньяны. Ире бик эчә.

Гөлфинә. Эчерткәч эчә инде.

Валентина. Әле, җитмәсә, балаларны ятим итеп ташлап чыгып китәләр, ди.

Гөлфинә. Чуртым да белми синең Соня апаң, Валентина, милый мой, дорогой, әйбәт хатынны ире ташлап китми.

Валентина. Ничек кенә китә әле. Минем иптәш кызым бар иде, искиткеч иде. Аны ташлап, бер юньсезгә өйләнде ире.

Гөлфинә. Синең Сашаң сине ташламаган бит. Ничә ел балагыз булмаган, алай да ташлап китмәгән. Эчми дә дисең үзен.

Валентина. Саша кебекләр сирәк. Саша ул минем бәхетемә туры килгән.

Гөлфинә. Әй, Валентина, милый мой, дорогой! Син Саша бәхетенә туры килгәнсең. Синең иптәш кызың синең өчен искиткеч булгандыр да, ире өчен искиткеч булмагандыр. Ирләр алар, Валентина, хайван терлеге белән бер. Вакытында ашатып-эчертеп, тамак астын кашып торсаң, артыңнан ияреп йөри. Менә сыерны гына ал син, тпри-тпри-тпри дип сыйпап, алдына печән салсаң, он болгатып җылы су эчерсәң, күзләрен мөлдерәтеп мөгрәп кенә тора. Җиленен җылы су белән юып, йомшак чиста сөлге белән сөртсәң, сауганда тибенми, сөтне дә күп бирә. Әгәр дә инде, башың беткере, муеның астыңа килеп сынгыры, дип, чыбык белән кыйнасаң, көтүдән кайтып капкадан чабып керми инде ул. Куып кайтарырга туры килә. Эт булып эт тә ашатмыйча, пшул дип кычкырсаң, капка астыннан күршеләр ишегалдына кереп тавыкларга изгәнне ашап йөри.

Валентина *(рәхәтләнеп көлеп)*. Саша, Сашуля, тпри-тпри-тпри!

Алтынчәч. Ирләр матурларны эзлиләр, Гөлфинә апа.

Гөлфинә. Юк, айналаем Алтынчәч... Беләсең килсә, ирләр эзләми хатын-кызны, без эзлибез аларны.

Валентина. Дөрес түгел, Гульфина апа. Мин, мәсәлән, үзем эзләмәдем.

Г ө л ф и н ә. Шулай тоела гына ул. Мин дә менә, Зарифулла, Зарифулла дип кычкырып, Зарифулланы эзләп йөрмәдем. Зарифуллага бер карагач, күңелем Зарифулланы эзләгәнен сизеп алдым да әйләндердем дә куйдым Зарифулланың башын үземнең якка.

В а л е н т и н а. Ничек, Гульфина апа, ничек?

Г ө л ф и н ә. Зарифулла Мөршидә исемле кыз артыннан йөри иде, миңа борылып та карамый. Ә Мөршидә бүтәнне эзли. Шуннан мин Зарифулланың йомшак ягын сизеп алдым да... Бии белми ул, җырлый да белми. Үзенең биисе дә килә, җырлыйсы да килә. Клубта вечерларда Зарифулла бии башласа да, җырлый башласа да, кызлар моңардан көләләр. Мөршидә кушылып көлә. Шуннан мин Зарифулла үгез кебек үкереп җырлый башласа, кушылам да китәм, Зарифулланың җырлый белмәгәне сизелми дә — минем тавыш матур да, көчле дә. Биергә дә Зарифулланы чакырам, ул аю кебек әйләнгәндә мин моның тирәсендә күбәләк шикелле бөтереләм. Менә без ничә ел инде Зарифулла белән авызга авыз куеп яшибез, Мөршидә ирдән иргә йөри.

А л т ы н ч ә ч. Сез бит чибәр дә, Гөлфинә апа.

Г ө л ф и н ә. И Алтынчәч. Нинди чибәр булыйм?! Кылыч борын, иләк авыз, акай күз — нинди чибәр булыйм. Менә син үзеңне үзең ким санап юкка йөрисең, хатын-кызның чибәрлеге йөзендә түгел, айналаем, хәйләсендә. Мин чибәр дип көзгегә карап тор. Чибәр икәнлегеңә ышансаң, бүтәннәр дә ышана. Үзең ышанмагач, бүтәннәр ничек ышансын?! Менә мин авызымны бәләкәй итеп күрсәтер өчен бөреп йөрмим. Күзләремне акайтып, авызны җырып елмаеп җибәрәм, Зарифулла авызга кереп китәрдәй булып сокланып карап тора.

В а л е н т и н а. Ә минем Саша мороженое ярата. Яратканын сиздермәскә тырыша. Мин юри мороженое саткан җирдән үткәндә, Саша, мороженое алыйк әле, дип ялынам. Миңа ала бу, үзенә алмый. Үзеңә дә ал, дип бәйләнәм, аңа да алдыртам. Мыекларын ялый-ялый кимерә Саша мороженоены. Ә мин мороженое яратмыйм, шулай да яраткан булып кыланам.

Г ө л ф и н ә. Менә, менә, менә... Хәйләкәр төлке. Саша мине ярата, дигән була. Ничек яратмасын мондый хатынны! Әйтәм бит, ирләр алар сабый бала белән бер. Без яхшы булсак, алар яхшы, без начар булсак, алар

начар. Дөньяның тоткасы — хатын-кызда. Патшалар да хатыннары сүзеннән чыкмаган. Хатыны әйткән икән мондый закон чыгар дип, икенче көнне үк патша шундый закон чыгарган. Без дип, ирләр түш кенә киереп йөри, эшләүчеләре без аның.

Валентина *(патша хатыны булып уйнап күрсәтә)*. Саша, Александр Борисович, шундый закон чыгар!..

Гөлфинә. Алай түгел, Валентина, кычкырып түгел, кычкырганны яратмый ир-ат. Җайлап кына, йокларга яткач, ул сине кочакларга үрелгәндә...

Валентина, Алтынчәч көләләр.

Алтынчәч. Шундый итеп сөйлисез, Гөлфинә апа...

Гөлфинә. Ышанмыйсызмы? Әйт әле, синең кызыңның атасы өйләнгән кешеме? Әйт инде, әйт, нәрсәсе оят аның.

Алтынчәч. Юк.

Валентина. Алай булгач, нигә сиңа өйләнмәде?

Алтынчәч. Ничек инде өйләнсен, ул чибәр, яшь. Мин үзем дә аңа чыкмас идем.

Гөлфинә. Нишләп?

Алтынчәч. Монысы өчен дә рәхмәт.

Гөлфинә. Әй син, тиле, тиле, тиле... Бигрәк тәртипле шул сезнең халык. Давай, чык син аңа кияүгә!

Алтынчәч. Сез нәрсә?..

Гөлфинә. Валентина белән тотынсак, каршыңа килеп тезләнәчәк.

Валентина. Гульфина апа, чыннан да, әйдәле...

Гөлфинә. Эшлибез, Валентина, эшлибез. Безгә ул нипочем. Әйбәт кешеме үзе болай?

Алтынчәч. Ничек дип әйтергә...

Гөлфинә. Аракы эчәме?

Алтынчәч. Эчә бугай...

Гөлфинә. Күп эчәме?

Алтынчәч. Исерек чагын еш күрәм.

Валентина. Алайса, кирәкми... Син балага узганда исерек түгел идеме?

Алтынчәч. Юк. Анысын мин беләм. Миңа сәламәт бала кирәк.

Гөлфинә. Эчүен дә ташлатабыз без аның. Конфет суырып йөри торган итәбез. Ирләрне төзәтүе җиңел ул.

Ирләрнең азгынын да төзәтеп була. Менә хатын-кыз азса, син әйтмешли, Валентина, алла әкбәр, бетте дөнья, атом бомбасы да кирәкми. Ник дигәндә, ир кеше нишләгәнен белмичә аза, хатын-кыз белеп аза, акыл белән, усаллык белән. *(Дилемма ягына.)* Менә аның урынында ир кеше булсамы? Җил ягына салам кыстырыбрак сөйләшсәң, үз баласын гына түгел, бүтәннәрнекен дә җыеп алып чыгып китәчәк. Бу — юк.

Валентина. Ире белән сөйләшеп ич алар.

Гөлфинә. Ире белән бу сөйләшкән, бу котырткан.

Дилемма *(сикереп торып)*. Туктыйсыңмы син, юкмы? *(Гөлфинә каршына килеп.)* Син!..

Валентина *(аның юлына аркылы төшеп)*. Якын килмә!

Дилемма *(Валентина аша Гөлфинәгә)*. Ты!.. Свинья!.. Рожай своих поросят и копайся в навозе, меня не трогай!

Валентина *(Дилемманы ишеккә таба кысрыклап)*. Нәрсә дидең син аңа, ә, нәрсә әйттең?..

Гөлфинә. Валентина, кирәкми. Кирәкми, Валентина...

Айзарә Әхәтовна кереп, Валентина белән Дилемма арасына баса.

Айзарә. Нишлисез сез, туктагыз хәзер үк!

Валентина. Чыгарыгыз аны моннан. Соңгы тапкыр әйтәбез, чыгарыгыз. Югыйсә үзегезгә начар булачак. Министрны чакыртабыз.

Айзарә. Тынычланыгыз!

Валентина. Юк, без тынычланмыйбыз. Һаман бер сүз — тынычланыгыз.

Айзарә. Сабыр. Зинһар өчен, сабыр булыгыз. *(Валентинаны култыклап караваты янына алып килеп утырта.)* Сез бит өлкән кешеләр. Аңлагыз безне дә. Без бит сезне аңларга тырышабыз.

Валентина. Юк, сез аңламыйсыз. Ул безнең барыбызны да неврастеник итеп бетерә.

Айзарә. Йә-йә, булды, булды. *(Гөлфинәгә ишарәләп.)* Менә бу апагыздан үрнәк алыгыз.

Гөлфинә. Минем аркада килеп чыкты ла. Ялгыш ычкынып китте.

Валентина. Гаепләмәгез үзегезне, Гульфина апа.

Айзарә. Булды, дидем. Валямы әле исемегез?
Валентина. Валя.
Айзарә. Сезнең бала имезәсегез бар, Валечка. *(Алтынчәч янына килеп.)* Йә, сезнең хәлләр ничек?
Алтынчәч. Яхшы.
Айзарә. Молодец. Барысы да яхшы булыр.
Дилемма *(ишек төбеннән)*. Выпишите меня. Мин сәламәт.
Айзарә. Сез сәламәт, анысына шигем юк... Бүген баш врач кайтты — хәл итәр.

Ике Ана бишек җырын дәвам итәләр.

Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем,
Яшәрсеңме син?
Әнием, диеп, кадерлем, диеп,
Сандугачкаем, дәшәрсеңме син?

Врач кабинеты актыра. Анда — баш врач Зәйтүнә Закировна һәм Айзарә Әхәтовна.

Баш врач. Сез беләсез, Айзарә Әхәтовна, без андый эшне эшли алмыйбыз.
Айзарә. Аңлыйм.
Баш врач. Аңлагач, шул. Бала үз анасы белән чыгарга тиеш. Яхшылап сөйләштегезме?
Айзарә. Сөйләшмәгән кая. Бераз гына да йомшамый.
Баш врач. Сәбәбе дә җитди түгел югыйсә.
Айзарә. Бөтен куркынычы да шунда шул. Иренә хәбәр иттергән идек, студотрядта, ди, кайтып тормаган. Телеграмма җибәргән, Дилемма ничек тели, шулай булсын, дигән.
Баш врач. Исеме Дилеммамыни?
Айзарә. Әйе.
Баш врач. Һе. Тапканнар исемне дә. Баланың әбибабалары ничек?
Айзарә. Сез кайтканны көттек, Зәйтүнә Закировна. Бүген чакырттык, килерләрме-юкмы?..
Баш врач. Көтелмәгән хәлләр белән очраша башладык бит әле, Айзарә Әхәтовна... Бер балага урын табылыр. Табылып тора. Тәрбияләнер дә. Тик, ничек кенә тәрбияләнсә дә, ятимлек ятимлек инде. Ничек кенә булса да, ятим балада психологик дефект була. Чөнки тәрбия-

челәр дә, бүтәннәр дә аңарга ятим итеп кызганып карыйлар. Кеше шуңарга өйрәнә, гомер буе үзен кызганганнарын таләп итә. Яисә, киресенчә, кызганган кешеләрне күралмый, рәхимсез, миһербансыз була. Ата-анасы үлгән ятимнәр бер хәл, бүгенге көндә күпме ата-аналы ятимнәр. Һәм без шулардан шәфкать көтәргә тиеш. Каян килеп чыкты бу кешеләрдә шундый җавапсызлык? Юк, нәрсәдер эшләргә кирәк. Ничек инде ул сау-сәламәт ир белән хатын балаларын алмыйлар? Ни өчен алмаска тиеш? Алмасалар, нигә закон алдында җавап бирмиләр?

Сестра Нина керә.

Нина. Гафу итегез, Менгличеваның каенанасы килде.

Баш врач. Керсен.

Нина чыгып китә, Вазыйфа керә.

Вазыйфа. Исәнмесез.

Баш врач. Исәнмесез. Утырыгыз... Сез Менгличева Дилемманың каенанасымы?

Вазыйфа. Шулайдыр.

Баш врач. Ничек «шулайдыр»?

Вазыйфа. Ну, каенанасы.

Баш врач. Менгличевамы фамилиягез?

Вазыйфа. Юк, Садриева Вазыйфа. Фамилиясен үзгәртмәгән ул.

Баш врач. Киленегезме?

Вазыйфа. Килен түгел ул миңа. Мин аны признавать итмим.

Баш врач. Ничек итмисез? Улыгызны балагыз дип таныйсыздыр ич?

Вазыйфа. Анысын таныйм да...

Баш врач. Менгличева Дилемма – сезнең улыгызның законлы хатыны.

Вазыйфа. Булмагае...

Баш врач. Алай икән... Ә соң сез киленегезнең бала тапканын беләсезме?

Вазыйфа. Ишеткән идем.

Баш врач. Нигә, бергә яшәмисезмени?

Вазыйфа. Юк. Квартирага чыктылар.

Баш врач. Ярый. Ә киленегезнең үз баласын алырга теләмәгәнен беләсезме?

В а з ы й ф а. Ничек инде «алырга теләмәгәнен»?

Б а ш  в р а ч. Шулай. Сезнең улыгызның хатыны үзенең һәм сезнең улыгызның баласын, ягъни сезнең оныгыгызны үзенә алырга теләми. Миңа бала кирәкми, ди.

В а з ы й ф а. Кирәк булмагач, нигә тапкан соң?

Б а ш  в р а ч. Анысы икенче мәсьәлә. Киленегез баласын имезми.

В а з ы й ф а. Ничек имезсен — змия ич ул.

Б а ш  в р а ч. Туктагыз әле. Ярый, киленегез змея, ягъни елан, ди, ә улыгыз? Ул да ризалык биргән бит.

В а з ы й ф а. Баланы алмаскамы?

Б а ш  в р а ч. Әйе.

В а з ы й ф а. Өйдә юк, диләр ич аны.

Б а ш  в р а ч. Элегрәк килешкәннәр, һәм улыгыз телеграмма да җибәргән.

В а з ы й ф а. Чүпрәк ич ул.

Б а ш  в р а ч. Улыгызмы? *(Вазыйфа эндәшмәгәч.)* Инде нишлибез, Вазыйфа ханым?

В а з ы й ф а *(паузадан соң)*. Мин нишлим? Бездә эшең юк, кысылма, диделәр, теләсәләр нишләсеннәр.

Б а ш  в р а ч. Ләкин бала бит сезнең оныгыгыз!

В а з ы й ф а. Булмагае...

Б а ш  в р а ч. Бәлки, сез баланы алырсыз?

В а з ы й ф а. Нишлим ди мин аның белән?

Б а ш  в р а ч. Ирегез бармы сезнең?

В а з ы й ф а. Булса ни. Ул җебегәннең ирлеге. Бала белән ул түгел бит, мин мучиться ителәсе.

Б а ш  в р а ч. Тагын балаларыгыз бармы сезнең?

В а з ы й ф а. Монысыннан да гарык.

Б а ш  в р а ч. Вазыйфа ханым, әгәр дә сезгә шушы хәлне сөйләсәләр, сез ышаныр идегезме?

В а з ы й ф а. Кайсы хәлне?

Б а ш  в р а ч. Бер ир хатынының үз баласын алырга теләмәвен, иренең шуңа ризалык бирүен, ир анасының шулай сөйләшеп утыруын...

В а з ы й ф а. Ә мин нәрсә сөйләшкән ул хәтле? Өйләнмә аңа, дидем.

Б а ш  в р а ч. Сез киленегезне күптән белә идегезмени?

В а з ы й ф а. Белмәскә! Әнисе — ата спекулянт. Ирен куып чыгарып, типтереп яшәде.

Б а ш  в р а ч. Үзегез кайда эшлисез?

В а з ы й ф а. Нәрсәгә кирәк ул сезгә? Кайда эшләсәм дә эшлим.

Б а ш  в р а ч. Бала кызганыч бит, Вазыйфа ханым.

В а з ы й ф а. Алар кызганмаганны, нигә мин кызганыйм.

Б а ш  в р а ч. Соңыннан үкенәчәксез бит.

В а з ы й ф а. Үкенәсен үкенгән инде. Бу бозауны тапканга да үкенеп бетә алмыйм.

Б а ш  в р а ч. Алар әле яшьләр, күп нәрсәне аңлап бетермиләр.

В а з ы й ф а. Аңламасалар... Үзләренә кирәкне бик аңлыйлар. Беләм мин ул юха җыланны, алмыйм дигән булып, баланы юри безгә ыргытмакчылар. Без карап үстерсен, янәмәсе. Ыргытмый гына торсыннар әле. *(Кәҗә тоягы күрсәтеп.)* Менә аларга. Тапкан готовый нәнкә. Белә ул безнекенең җебеп төшәсен.

Б а ш  в р а ч. Кем инде ул сезнеке?

В а з ы й ф а. Кем булсын — ирем. Монда да ризык төяп килмәкче. Җибәрдем ди! Ашамый гына торсын әле. Әнә спекулянт әнисе ашатсын.

Б а ш  в р а ч. Киленегезне күреп сөйләшергә теләмисезме?

В а з ы й ф а. Минме?.. Анымы?! Мин аны оҗмахта очратсам да, аңардан качып, тәмугка керәчәкмен.

А й з а р ә. Сезнең кайчан да булса җылаганыгыз бармы?

В а з ы й ф а. Ничек инде ул җылаганым бармы?

А й з а р ә. Кешеләрнең берәр кайгысын, фаҗигасен ишетеп, йөрәгегез әрнеп.

В а з ы й ф а. Кеше кайгысымыни монда! Үземнеке җитәрлек. Малаем шуңа өйләнгәч, җылый-җылый күз яшьләрем кипте, күңелем катты.

Б а ш  в р а ч. Анысы бит аның фаҗига түгел, Вазыйфа ханым.

В а з ы й ф а. Сезгә әйтүе җиңел. Сезгә моннан тизрәк куып чыгарырга гына кирәк, котылырга гына кирәк.

Б а ш  в р а ч. Безнең урында сез нишләр идегез?

В а з ы й ф а. Милиция чакырып, сөйрәп чыгарып аттырыр идем. Баласы белән бергә.

Б а ш  в р а ч. Димәк, бала сезгә дә кирәкми?

В а з ы й ф а. Юк, кирәкми.

Б а ш  в р а ч. Бәлки, яхшылабрак уйларсыз?

В а з ы й ф а. Уйлыйсы-нитәсе юк. Ул бит мәче баласы түгел. Үлеп-нитеп китсә, булыр аннары. Юри үтергәннәр дип, судтан судка йөртерләр. Әнисе алсын да карасын, акчасы күп.

А й з а р ә. Сезнең юкмы?

В а з ы й ф а. Ниемә дип сез миңа каныктыгыз әле? Юк дигәч, юк. Әйткән сүземнән кире кайтканым да юк, кайтмыйм да, кайтачак та түгел. Хет асыгыз, хет кисегез. Синсез яшибез, диделәр, минсез яшәсеннәр.

Балалар елаган тавыш ишетелә.

Б а ш в р а ч. Ишетәсезме?

В а з ы й ф а. Чукрак түгел.

Б а ш в р а ч. Ашыйсы килгән нарасыйлар җылый. Аларны әниләре янына алып баралар. Тиздән алар тамаклары туеп тынып калырлар, рәхәтләнеп йокларлар. Ә сезнең оныгыгыз…

В а з ы й ф а. Нәрсә дип әле сез… *(Урыныннан тора.)*

Б а ш в р а ч. Юк. Сез утырыгыз. Тыңлагыз әз генә. Тыңлагыз, тыңлагыз.

Вазыйфа утыра. Тыңларга мәҗбүр. Ике Ананың җыры.

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам-багалмам,
Үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры,
Күчәрсеңме, син?

Палатада Валентина, тәрәзә төбенә басып, форточка аша Саша белән сөйләшә.

В а л е н т и н а. Саша!.. Такси белән килдеңме? Автобус белән?.. Молодчина. Хәзер җыена башлыйм. Ә?.. Алай тиз генә булмый әле ул. Көт. Китмә. Нәрсә-ә?.. Ничек икәнен астагы дежурныйдан сора. Ә?.. Әйтәм. Әйтәм. *(Борылып.)* Гульфина апа, Алтынчәч, Саша сезгә сәлам әйтә.

Г ө л ф и н ә. Сора әле, Зарифулла күренмиме?

В а л е н т и н а. Зарифулла абый күренмиме? Ә?.. Ничек инде кайсы Зарифулла?! Белмисеңмени? Гульфина апаның ире. Юк?.. *(Борылып.)* Юк, ди, Гульфина апа.

Г ө л ф и н ә. Нишләп йөри икән инде, әйтеп җибәрдем ич сеңелгә. Күрсен дә торсын, килеп алмыйча чыкмыйм.

В а л е н т и н а. Сашенька, яратасыңмы мине? Мин дә сине яратам, Сашенька. Ә?.. Юк, менә алмыйсың. Не дури, егылып төшәрсең. Бар, кит тизрәк, миңа җыенырга кирәк. Кит, дим... Ну, Саша, миленький... *(Сашага кул болгап, тәрәзә төбеннән төшә. Бишек җырын көйләп, палата буенча йөри.)*

Баю-баюшки, баю,
Не ложися на краю,
Придёт серенький волчок
И утащит за бочок...

*(Туктап караватка утыра да.)* Йә, кызлар, утырышыгыз. Присядем, друзья, перед дальней дорогой, пусть лёгким окажется путь... Эчемдә шатлыгым да чиксез, сездән аерылганда җылыйсым да килә. Очрашырбыз микән без тагын?

Г ө л ф и н ә. Унөченчесен табарга килсәм генә инде...

В а л е н т и н а. Килегез, Гульфина апа. Шушы палатада очрашабыз. *(Алтынчәчкә.)* Син... Син күңелсезләнмә, боекма, Алтынчәч, менә күрерсең, барысы да яхшы булыр. Минем адрес синдә бар. Хат язышыйк.

Айналайын балам-ай,
Айналсын сенен анаң-ай...

Менә күрерсең!.. Мин сиңа иң-иң изге теләкләр телим!

А л т ы н ч ә ч. Сиңа да, Валентина. Рәхмәт сиңа!

Г ө л ф и н ә. Алтынчәчкә бер дога өйрәттем әле, Валентина. Шул доганы эчтән генә укып Оралбаена карап торса...

А л т ы н ч ә ч. Гөлфинә апа...

В а л е н т и н а. Яле, яле, Гульфина апа... Карале боларга, миннән качып дога өйрәнеп яталар. Хәзер үк миңа да өйрәтегез.

Г ө л ф и н ә. Синең каратасы егетең юк, Валентина, синеке мәңгелеккә караган.

В а л е н т и н а. Тфү, тфү диегез, Гульфина апа.

Г ө л ф и н ә. Тфү, тфү...

В а л е н т и н а. Әйтегез инде доганы.

Г ө л ф и н ә. Күзең төшкән егеткә карап торасың да эчеңнән генә болай дисең.

Талкыга салып талкырмын,
Кояшың булып балкырмын,
Килегә салып төярмен,
Сагышка салып сөярмен, —

дисең. Ябыша да кала егетең. Зарифуллага шулай әйттем мин... Килми әле чукынчык.

Н и н а *(ишектән карап)*. Васильева, җыеныгыз.

В а л е н т и н а. Ой, кызлар, елыйсым килә... Гульфина апа, милый мой, дорогой. Яратам мин сезне, Гульфина апа!

Г ө л ф и н ә. Йә, ярый. Өчәүләп тезелешеп бераз тын гына утырыйк та...

Тезелешеп тын гына утыралар. Ике Ананың җыры аларның тынлыгын саклый.

Ике кулын куеп алар тезләренә,
Утырышып бер ял итеп алалар да,
Тагын эштә, тагын шөгыль, мең мәшәкать...
Исән-саулык телик әле аналарга,
Озын гомер телик без аларга.
Баласының йөргән юлы йөзләрендә,
Алар гаме яллар иткән арада да.
Һаман сагыш, һаман борчу, мең төрле уй...
Сабырлыклар телик әле аналарга,
Түземлекләр телик без аларга.

Җырның соңгы юлларында урыннарыннан торып палатадан чыгалар, коридордан үтәләр. Врач кабинеты актыра. Анда — Дилемманың әнисе Р и м м а һәм б а ш   в р а ч   З ә й т ү н ә   З а к и р о в н а.

Б а ш   в р а ч. Рәхим итегез, утырыгыз.

Р и м м а. Римма Әүхәдиевна мин.

Б а ш   в р а ч. Бик яхшы. Римма, Дилемма — кызыклы исемнәр.

Р и м м а. Миңа әти кушкан, кызыма — үзем. Сез Зәйтүнә Закировна бит, әйеме?

Б а ш   в р а ч. Әйе.

Р и м м а. Сезнең исем Казанда данлыклы, Зәйтүнә Закировна. Әле үзем киләм, үзем уйлыйм, андый зур кеше белән ничек сөйләшермен инде, дим. Ялгыш сүз ычкындырсам ачуланмассыз инде, Зәйтүнә Закировна.

Б а ш   в р а ч. Ә сез ычкындырмаска тырышыгыз.

Р и м м а. Шулаймы?.. Сүз минем кызым Дилемма турындадыр инде, әйеме?

Б а ш  в р а ч. Әйе. Сезнең кызыгыз Дилемма турында.

Р и м м а. Бәгырь кисәгем. *(Елап җибәрә.)*

Б а ш  в р а ч. Сез нигә җылыйсыз?

Р и м м а. Ничек инде җыламаска, Зәйтүнә Закировна. Бердәнбер кызым бит ул минем. Ике яшеннән алып берьялгызым үстердем.

Б а ш  в р а ч. Әтисе нишләде?

Р и м м а. Юньсез булып чыкты, кабахәт. Куып чыгардым. Николай Павлович, Николай Павлович дип кенә тордым үзенә, барыбер кадеремне белмәде. Мин аңа, Николай Павлович, дидем, ул миңа, химера, диде. Түздем, түздем дә, эзең булмасын, сатана, дидем.

Б а ш  в р а ч. Кызыгызның бала тапканын белдегезме?

Р и м м а. Ничек инде белмәскә, ничек инде белмәскә, Зәйтүнә Закировна...

Б а ш  в р а ч. Кызыгызның хәлен белергә килдегезме?

Р и м м а. Бик килер идем дә, кертмиләр бит аның янына, Зәйтүнә Закировна.

Б а ш  в р а ч. Котлап язу җибәрмәдегезме? Күчтәнәч тә китермәдегезме?

Р и м м а. Монда ашатырга тиешләрдер ич.

Б а ш  в р а ч. Кызыгыз баласын алырга теләми, беләсезме? *(Римма тагын елап җибәргәч.)* Туктагыз. Беләсезме, дип сорыйм мин сездән.

Р и м м а. Аның белән сөйләштем инде мин монда кергәнче үк. Тыңлыймыни алар безне. Үзсүзле ул. Башына бер уй керсә...

Б а ш  в р а ч. Тагын сөйләшеп карагыз... Нигә эндәшмисез?

Р и м м а. Тагынмы?

Б а ш  в р а ч. Тагын.

Р и м м а. Шушындамы? Чакырып китерәсезме?

Б а ш  в р а ч. Ерак түгел бит.

Р и м м а. Тик үзегез чыгып китмәгез, ярыймы?

Б а ш  в р а ч. Нигә?

Р и м м а *(паузадан соң)*. Куркам мин аңардан.

Б а ш  в р а ч *(ишек артына)*. Бишенче палатадан Менгличеваны чакырыгыз.

Р и м м а. Сез миңа ничек сөйләшергә икәнен өйрәтеп куегыз, Зәйтүнә Закировна.

Б а ш  в р а ч. Кызыгыз белән сөйләшерлек тә сүзегез юкмыни?

Р и м м а. Ул ике сүз әйтә дә, мин утырып җылыйм. Ә ул җылый да белми, көлә дә белми.

Б а ш  в р а ч. Нигә өйрәтмәдегез соң көләргә?

Р и м м а. Көлеп тумаган баланы ничек өйрәтәсең.

Б а ш  в р а ч. Туганда җылагандыр ич, нигә оныткан?

Р и м м а. Шундый бала инде.

Б а ш  в р а ч. Шундый бала булмый, андыйларны үстерәләр.

Р и м м а. Мине гаеплисезмени? *(Дилемма кергәч, аның каршына барып.)* Дилемма, кызым...

Д и л е м м а. Чего тебе?

Р и м м а. Әнә Зәйтүнә Закировна сөйләшергә куша.

Д и л е м м а. Ну и сөйләшегез.

Б а ш  в р а ч. Утырыгыз, Менгличева.

Д и л е м м а. Нигә миңа утырырга? Минем аның белән сөйләшерлек сүзем юк.

Б а ш  в р а ч. Әниең бит...

Д и л е м м а. Ну и что!

Р и м м а. Менә шундый инде ул, Зәйтүнә Закировна.

Д и л е м м а. Ничек «шундый»? А сама какая? *(Баш врачка.)* Выпишите меня. А то үзем китәм. *(Чыгарга борыла.)*

Б а ш  в р а ч. Ашыкмагыз, утырыгыз.

Д и л е м м а. Мин әйттем.

Б а ш  в р а ч. Ни әйтим сезгә? Сеңлем дияргә телем бармый. Гражданка Менгличева, сезнең каршыгызда – сезне унсигез ел буе тәрбияләгән әниегез...

Д и л е м м а. Тәрбияләгән?!

Б а ш  в р а ч. Ашатып, эчертеп, киендереп үстергән...

Д и л е м м а. Ну и что?!

Б а ш  в р а ч *(паузадан соң)*. Барыгыз, гражданка Менгличева. Бүген сезне чыгарырлар. *(Дилемма чыгып киткәч.)* Ана белән кыз. Шуның өчен, менә шуның өчен яшәдегезме инде сез? Күңеллеме сезгә?

Р и м м а. Әйттем бит мин.

Б а ш  в р а ч. Китәргә мөмкин сезгә, Римма Әүхәдиевна. *(Римма китмәгәч.)* Китәргә мөмкин, дидем.

Р и м м а. Мине гаепләп каласызмы, Зәйтүнә Закировна?

Б а ш  в р а ч. Ә сез кемне гаепләр идегез? Китәргә мөмкин.

Р и м м а. Баланы нишләтәсез инде?

Б а ш в р а ч. Анысы сезнең кайгы түгел. Кызганычка каршы, сез дә, сезнең кызыгыз да безнең җәмгыятьнең члennары. Үз ялгышын җәмгыять үзе төзәтергә мәҗбүр.

Р и м м а. Баланы миңа алырга ярыймы? Закон кушамы?

Б а ш в р а ч. Закон рөхсәт итә. Ләкин без аны сезгә бирмибез.

Р и м м а. Нигә?

Б а ш в р а ч. Кешеләр арасына бер имгәк үстереп җибәргәнегез дә бик җиткән. *(Римма елый башлагач.)* Кыланмагыз, гражданка. Чынлап елаган аналарның күз яшьләрен пычратмагыз. Сугыш вакытында Ил, Ватан өчен башларын салган балалары өчен елаган аналар рухын рәнҗетмәгез.

Р и м м а төзәтенеп чыгып китә. Кертмәскә тырышкан Айзарә Әхәтовнаны этеп җибәреп, И с е м с е з х а т ы н атылып керә.

Х а т ы н. Мин риза. Риза мин. Ирем дә алырга риза. Бирегез безгә аны!

И к е А н а җ ы р ы:

Гомерең сукмагын зур юллар буйлап,
Өмет йолдызым,
Үтәрсеңме син?
Илеңнең данын,
Намус, Вөжданын,
Балам, әй, дәвам
Итәрсеңме син?

Палатада — Г ө л ф и н ә белән А л т ы н ч ә ч.
Гөлфинә тәрәзәдән карап тора.

Г ө л ф и н ә. Бу ниткән эш инде? Зарифулланың вакыты булмаса, сеңлем килергә тиеш ич инде. Врачлардан оят. Бүген киләм, дип язган иде ич сеңлем. Менә шулай инде ул, Алтынчәч айналаем, башны ташка орсаң да баш ярыла, ташны башка орсаң да баш ярыла. Кайтып кына җитим, күрсәтәм бу Зарифуллага. Тагын шул комбайнын ремонтлап ятадыр. Урак өсте җитсә, комбайн ремонтлаудан арынмый. Председателе дә бирми бит шуңа яңа комбайн.

А й з а р ә Ә х ә т о в н а керә.

А й з а р ә. Йә, ничек, матурларым?

Г ө л ф и н ә. Килмиләр, Айзарә җаным. Сеңлем килергә тиеш иде. Ишек төбендә күренмиме шунда?

А й з а р ә. Күренсә, хәбәр итәр иде. Сез борчылмагыз. Килерләр.

Г ө л ф и н ә. Зарифулла килә алмый инде ул — эше тыгыз. Урак өсте бит. Сеңлем менә нишләп килми икән?

А й з а р ә *(Алтынчәч янына килеп)*. Сез?

Г ө л ф и н ә. Без аның белән сөйләштек, Айзарә Әхәтовна, бер дә борчылмагыз. Аларда бит тәртип хатын-кыз мәсьәләсендә бездәгедән катырак. Әнисенә хат та язып салган идек — җавап юк. Үпкәләве бетеп җитми торгандыр. Әлегә безгә кайтып торабыз. Колхозда какраз кеше җитешмәгән чак. Бездә ясле дә, бакча да бар. Эшли торыр. Өй иркен. Аннан, әнисеннән хат килгәчтенме, болаймы, баласы үсә төшкәч, үзе карар. Бала әйберләрен башта ук монда бирдем, ди, торалардыр ич?

А й з а р ә. Кая китсеннәр, әлбәттә, тора.

Г ө л ф и н ә. Ну бу сеңелне! Бала кадерен беләмени ул. Көлеп ятадыр әле, үзе дә чыгар дип уйлыйдыр.

А й з а р ә. Борчылмагыз, зинһар, уынмагыз. Вакыт иртә.

Г ө л ф и н ә. Чыннан да, әйеме, Айзарә? Килерләр әле. Бу караватларга нигә кертмисез соң әле?

А й з а р ә. Сез чыкканны көтик инде.

Г ө л ф и н ә. Менә әйтәм бит. Ачуланмагыз инде, хәзер килеп җитәрләр... Менә шулай булсын иде ул, әйеме! Мин көтеп торыйм, торыйм иде дә, минекеләр килгәнче, Алтынчәчнең Оралбае килсен дә чыксын иде! Мин килде-ем, Алтынчәч, дип, тәрәзәгә кычкырсын иде. Оралбай исемле Алтынчәч кызының этисе. Бик әйбәт егет, ди, Алтынчәч әйтә. Әкиятләр нигә чын булмый икән ул, Айзарә Әхәтовна?

А й з а р ә *(Алтынчәчнең башыннан сыйпап)*. Кем белә, бәлки, булган хәлләрне әкият итеп сөйлиләрдер кешеләр. *(Алтынчәчкә.)* Бер дә борчылмагыз, барысы да сез уйлаганча булыр.

С е с т р а Н и н а керә.

Н и н а. Калаубекова, сезгә килгәннәр. *(Алтынчәчкә язу бирә.)*

Г ө л ф и н ә. Әстәгъфирулла дип әйтер иде, Валентина булса. Укы, укы тизрәк, Алтынчәч айналаем.

Алтынчәч, нишләргә белми, язуны кулында тотып тик тора.

Айзарә. Сабыр, сабыр. Тынычланыгыз, Алтынчәч. Менә шулай, шулай.

Гөлфинә. Бир, Алтынчәч, үзем укыйм.

Алтынчәч. Үзем. *(Язуны сакланып кына ача, укый.)*

Гөлфинә. Оралбаймы, Алтынчәч бәгырь кисәгем?

Алтынчәч *(паузадан соң)*. Апа белән җизни.

Гөлфинә. Җыен инде тизрәк. *(Айзарә Әхәтовна белән Нинага.)* Җыештырыгыз инде аны, нәрсә карап торасыз.

Айзарә. Кабаланмагыз, диләр сезгә.

Гөлфинә. Кабаланмасам, унике баланы табып бетерергә ничек вакыт җиткерим ди мин. Күреп торасыз лабаса, Алтынчәч үзе бернишли алмый. Алтынчәч, борчылма. Борчылма, Алтынчәч.

Нина. Шактый ук үзәккә үттегез сез минем, апа. Бераз гына утырып торырга буладыр бит.

Гөлфинә. Сагынырсыз әле, Нина, сагынырсыз. Әнә теге караваттагы кебекләр күбрәк кергәләсә сагынырсыз. Киләле, кочаклыйм әле бер үзеңне. *(Нинаны кочаклап.)* Икенче малаема хатын булып киләсеңме безгә?

Нина. Берсекөнгә көтегез.

Гөлфинә *(көлеп, Нинаның аркасыннан сөя дә тәрәзә янына килә)*. Күренмиләр чукынчыклар. *(Кинәт кычкырып җибәрә.)* Киләләр!.. Берәү, икәү, өчәү, дәртәү, бишәү, алтау. Алтысы үземнеке. Җиденчесе үземнең Зарифулла, сигезенчесе сеңлем, тугызынчысы кияү. Барысының да кулында чәчәк. *(Айзарә Әхәтовна белән Нинага.)* Чәчәкләре сезгәдер инде ул. *(Караватка утыра да кинәт елап җибәрә.)*

Айзарә. Менә инде тагын! Көлеп йөрдегез, йөрдегез дә...

Алтынчәч. Гөлфинә апа...

Нина. Комедия...

Гөлфинә. Карагыз әле, китмәделәр микән?

Нина *(тәрәзәдән карап)*. Торалар тезелешеп.

Гөлфинә. Кыр казлары кебекме?

Нина. Юк, солдатлар кебек.

Гөлфинә. Айзарә җаным, әйтим инде шуларга бер сүз.

А й з а р ә. Ярый, әйтегез.

Г ө л ф и н ә *(тәрәзә төбенә менеп, форточкадан кычкыра)*. Зарифулла! Ишеккә барыгыз, ишеккә... *(Күз яшьләрен сөртә-сөртә, тәрәзә төбеннән төшә.)* Айдарның борынын да сөртмәгәннәр.

Н и н а. Булдымы? Әйдәгез!

Палатадан чыгалар. Коридордан үткәндә,
Б а ш в р а ч очрый.

Б а ш в р а ч. Киттегезме, гүзәлкәйләр? Хәерле юл!

Г ө л ф и н ә.
А л т ы н ч ә ч. } Бик зур рәхмәт сезгә! *(Китәләр.)*

Б а ш в р а ч. Айзарә Әхәтовна, килгәннәр бит.

А й з а р ә. Кемнәр, Зәйтүнә Закировна?

Б а ш в р а ч. Менгличеваның каенанасы, улы белән...

Аларның сөйләшкәнен ашыйсылары килгән балаларның елау тавышы баса. Ике бишек яңадан аска төшә. Ике Ана, аларны тирбәтеп, бишек җырын дәвам итәләр:

Әлли-бәлли, бәллием,
Йокла, балам, нәнием,
Тәмләп йокла, бәбием,
Сакта тора әниең.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү,
Әлли-бәлли, бәлли-бәү.

П ә р д ә.

# МУЛЛА

*(Драматик хикәят)*

Катнашалар:

Әсфәндияр — мәдрәсә тәмамлаган яшь мулла.
Самат — эшмәкәр.
Мөслимә — авыл карчыгы.
Вәлиәхмәт Габделәхәтович.
Чуртыш авылы кешеләре.
Бәдретдин (Бәрттин).
Налимә, Гөлназ — Чуртыш авылы кызлары.
Сәлахетдин — Чуртыш авылы мулласы.
Лемур — җирле үзидарә рәисе.
Әмир — участок милиционеры.
Илдар, Вилдан, Илдария — Мөслимәнең шәһәрдән кайткан оныклары.
Эльбрус — Чуртыш авылы егете.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Саматларның авылдагы өе. Самат белән Әсфәндияр керәләр.

Самат. Менә, хәзрәт, сиңа өй. Бөтен нәрсәсе бар. Газ, су кергән. Мебель дә җитәрлек. Бу — безнең әтиләрнең өе. Әнкәй үлгәч, әтине үзебезгә алып килдек. Бу — сиңа. Дөресрәге, мәчеткә. Әгәр безнең авылда төпләнергә җыенасың икән, үзеңнеке булыр. Акча сорамыйм.

Китәсең икән, өйне ничек алган булсаң, шулай калдырып китәсең. Тик киткәнеңне миңа белдер.

Әсфәндияр. Зур авыл.

Самат. Элек тагын да зур иде. Тарала. Авыл зур, ләкин тәртип юк. Сине эзләп табуым да, беләсең, шуның өчен. Монда, әйткәнемчә, мулла бар. Ләкин тәртип юк. Мәчет салдыр, диделәр. Салдырдым. Йөрүче юк. Мулла үзе дә мәчетне гает көннәрендә генә ача, диләр. Формаль якларын мин мөфти белән, тиешле кешеләр белән сөйләшермен, кыскасы, бу авылның хуҗасы – син.

Әсфәндияр. Авыл советлары, колхоз бардыр бит.

Самат. Идарә итә алмый торган үзидарә бар, колхоз юк. Аның урынына нәрсәдер оештырдылар бугай. Кыскасы, син – хуҗа.

Әсфәндияр. Алай булмыйдыр ул.

Самат. Булдырсаң була. Булдыра алмасаң, кит, гаепләмәм.

Әсфәндияр. Сез шундый итеп тасвирладыгыз авылны, монда кешеләр түгел, ниндидер иблисләр яшидер сыман.

Самат. Иблисен белмим, шайтаннар җитәрлек. Хуҗа бул. Үзидарә дә, колхоз урынына калган нәрсәнең председательләре дә синнән куркып торсыннар.

Әсфәндияр. Куркытып кешене иманга китереп булмый.

Самат. Ничек икәнен үзең карарсың, өйрәтеп тормыйм. Өйләнгәнче-ниткәнче сиңа бит ашарга пешереп, өй җыештырып торырга да кеше кирәк. *(Тәрәзәдән карый да, ачып.)* Мөслимә апа! Кер әле, Мөслимә апа!.. *(Әсфәндиярга.)* Бик чиста апа. Авылга килгән нәчәлстводы ул ашата. Борчылма, хезмәт хакың җитәрлек булыр, сәдака хисабына гына яшәтмәбез, ә сәдаканы мәчет файдасына ал. Бирсәләр, әлбәттә. Өйрәнсеннәр сәдака бирергә. Өйрәт. *(Мөслимәгә.)* Мөслимә апа, менә мәчеткә мулла алып кайттым.

Мөслимә. Әстәгъфирулла! *(Әсфәндиярны карыйтикшерә.)*

Самат. Мондый чакта «әстәгъфирулла» димиләр, Мөслимә апа, «сөбханалла» диләр.

Мөслимә. Бигрәк яшь күренә түгелме соң?

Самат. Сиңа гына яшь күренә ул. Мәдрәсә тәмамлаган белемле хәзрәт ул. Исеме – Әсфәндияр.

М ө с л и м ә. Сәлахетдинне кая куясыз соң?

С а м а т. Теләсә, Әсфәндияр янында йөрер. Сиңа шуны әйтергә чакырдым, Мөслимә апа. Хәзрәтебез әле өйләнмәгән, егет кеше. Ул монда яшәячәк. Аны ашатып, өен җыештырып, керләрен юып торырга хатын-кыз кирәк. Син күршедә генә. Бер көтү малай үстердең. Нәрсәнең ничек икәнен беләсең. Әсфәдиярны сиңа тапшырам. Акчаң җитәрлек булыр.

М ө с л и м ә. Туктале, акча дип... Казан кешесеме соң син, улым?

Ә с ф ә н д и я р. Әйе, мин Казанда үстем.

М ө с л и м ә. Шәһәр кешесенә ошап булыр микән соң?

С а м а т. Ошарсың. Бал-май эчендә үскән малай түгел. Ятим. Әби-бабайларының пенсиясенә үскән.

М ө с л и м ә. Белмим инде тагын. Син әйткәч, каршы килеп булмас инде. Рәхмәт инде сиңа, авылны онытмыйсың. Күперебез юк иде, күперле иттең. Ярар, Винирага да әйтермен. Ач тормас, Алла боерса. Берәр кыз да табып бирербез. Тик менә рәтле-юньле кыз гына калмады авылда. Хисмәтуллада бар иде, ул да аракы эчә башлаган, хәерсез. Унҗидесе дә тулмаган килеш.

Ә с ф ә н д и я р. Авыл кызы эчәме?

М ө с л и м ә. Авылныкы шул. Ярый, борчылма, Самат. Синең сүзеңне аяк астына салмабыз. Чыгыйм әле мин, казлар карарга чыкканыем. Кичен безгә генә кереп ашар инде, алайса. *(Китә.)*

С а м а т. Ишеттеңме, хәзрәт?

Ә с ф ә н д и я р. Авылны мин башкачарак күз алдына китерә идем.

Ишекне киң итеп ачып, В ә л и ә х м ә т керә.
Аңа Б ә д р е т д и н ияргән.

В ә л и ә х м ә т. Мине эзләмиләр икән, димәк, мин кирәкмим. Казан байларына сәлам бирдек! Бәрттин, исәнләш!

Б ә д р е т д и н. Әссәламегаләйкем!

В ә л и ә х м ә т. Менә шулай. Син, Бәрттин, беркайчан да исәнләшергә онытма. Исәнмесез, Самат Закирович!

С а м а т. Исәнмесез!

В ә л и ә х м ә т. Бу егетне кем дип белик?

С а м а т. Ул – безнең авылның мулласы.

Вәлиәхмәт. Мулла?! Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала? *(Саматка.)* Син алып кайттыңмы?

Самат. Әйе, мин.

Вәлиәхмәт. Әллә мөфти дә булып алдыңмы?

Самат. Синең белән акыл сатарга минем вакытым юк, Вәлиәхмәт.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт түгел, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Самат *(Бәдретдингә)*. Ә син нәрсә көпә-көндез эчеп йөрисең?

Вәлиәхмәт. Төнлә эчсә, аның эчкәнен кем күрә, әйеме, Бәрттин?

Бәдретдин. Шулай, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт *(Әсфәндиярга карап торып)*. Мулла... Әйе, муллалар күбәйгән саен, гөнаһлылар арта. Исемегез ничек?

Әсфәндияр. Әсфәндияр.

Вәлиәхмәт. Мин — Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт Габделәхәтович Әхмәтгалиев. Кайчандыр шушы авылдан сөрелгән Мөхәммәтгали мулланың оныгы. *(Бәдретдингә күрсәтеп.)* Менә бу мәхлук минем бабамны сөргән һәм мәчет манарасын кискән бәндәнең оныгы. Әйе, диген, Бәрттин!

Бәдретдин. Әйе, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Вәлиәхмәт *(Саматка күрсәтеп)*. Менә бусы да минем бабамны, ягъни шушы авыл мулласын сөргән һәм мәчет манарасын кискән адәми затның оныгы.

Самат. Җитте инде, Вәлиәхмәт!

Вәлиәхмәт. Син мине туктатма, Самат! Мин синең офисыңда утыра торган хезмәткәр түгел. *(Әсфәндиярга.)* Самат әфәнде бабасының гөнаһларын юар өчен авылда мәчет салдырды. Бәрттин, кил әле монда?! *(Бәдретдин килгәч.)* Бу мәхлук бабасының гөнаһларын юып йөри. Минем акчага. Үз акчасы юк. Нәселләре белән хәерчеләр һәм теләнчеләр. Дөрес әйттемме, Бәрттин?

Бәдретдин. Дөрес, бик дөрес, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт. Үзе адашасы килгән кешегә юл күрсәтергә кирәкми. Киттек, Бәрттин! Сине күрергә килгән кеше үзен күрсәтергә дә килә. *(Кырт борылып, ишеккә таба атлый.)*

Самат. Вәлиәхмәт, туктагыз әле?!

В ә л и ә х м ә т. Туктадык.

С а м а т. Миннән курыкмасагыз да, сез канатыгызны бигүк җәймәгез, ярыймы!

В ә л и ә х м ә т. Бөркет канатын җәймәсә, җиргә мәтәлеп төшә.

В ә л и ә х м ә т чыгып китә. Аңа Б ә д р е т д и н иярә.

С а м а т *(Әсфәндиярга)*. Бу кеше белән сак бул. Бабасы Магнитогорскига сөрелгәч, шунда туып үскән кеше ул. Биш ел элек авылга кайтты. Берүзе яши. Өе тулы китап. Коръәнне яттан белә, диләр. Эчми, тартмый, бүтәннәрне эчертә. Авылда кибет ачкан. Кибетендә аракыдан башка нәрсә юк, диләр. Тәүлек буе сату итә. Каратэ буенча разряды бар бугай. Үзе әйтте. Дөресмедер, анысын белмим. Ярый, мин китәм. Телефон номерын беләсең. Сиңа бер үтенечем — зарланма. Зарланганнарны, елак-мескеннәрне яратмыйм.

## Икенче күренеш

Вакыт кич. Әсфәндияр намазлык өстендә ястү намазын укый. С ә л а х е т д и н керә. Ишек төбендә Әсфәндиярның намаз укып бетергәнен көтә.

С ә л а х е т д и н *(Әсфәндиярның намазлыкны җыйганын күреп)*. Әссәламегаләйкем!..

Ә с ф ә н д и я р. Вәгаләйкемәссәлам! Түрдән узыгыз, бабай!

С ә л а х е т д и н *(түргә узып утыра, дога кыла)*. Ишеттем дә менә килдем әле. Мин бу авылда мулла булып торам. Самат яшь мулла алып кайткан, диделәр. Шулай тиештер. Үзе салдырган мәчет. Сәлахетдин атлы мин. Мәдрәсә-фәлән бетергәнсеңдер инде.

Ә с ф ә н д и я р. Әйе.

С ә л а х е т д и н. Хәзерге мәдрәсә бетергәннәр ваһһабистлар була инде ул. Без дә болай, Аллага шөкер, «Әлхәм» белән «Колһуалла»ны беләбез. Кирәк чакта ясинны да чыгабыз. Үлем-китем булганда, үзебезчә җирлибез дә. Болай зарланмыйлар иде. Сәдака дигән нәрсә юк инде.

Ә с ф ә н д и я р. Сезне аракы эчә, дип сөйлиләр.

С ә л а х е т д и н. Самат әйткәндер инде. Кем эчми инде хәзер. Без бит фронтта эчәргә өйрәнгән халык. Унҗиде дә тулмаган иде сугышка киткәндә. Сәгать саен үлем. Ул яшьтә, үлем күреп торып, әллә ниләр эчәрсең. Эчелә инде. Бүтән кешесе табылмагач, алындым инде. Аллага шөкер, мәетне дога укып озатабыз. Син инде монда кирәкмәгәнне тыңлап йөрмә. Үз эшеңне бел. Авылга үзең сыман ваһһабистларны җыя күрмә.

Ә с ф ә н д и я р. Кем соң ваһһабист?

С ә л а х е т д и н. Кем булсын, шул тиррур ясаучы инде. Өйләр шартлатып йөрүче. Хәер, авылда шартлатырлык өе дә калмады инде. Бетә инде авыл.

Ә с ф ә н д и я р. Нигә бетә соң ул?

С ә л а х е т д и н. Кирәкмидер инде өстәгеләргә. Шәһәр кирәк булгач төзиләр бит. Авыл белән нишлисең. Җир сукалап интеккәнче, сатасың да аласың ризыкны Американдан. Монда бер тавык боты ашар өчен ел буе интегәсең. Шәһәрдә саттың да алдың Америка ботын. Рәхәтләнеп кимер… Болай, мәет юарга җирәнмисеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Юып караганым юк.

С ә л а х е т д и н. Авылда мулла мәет юганда гына кирәк инде ул. Җирәнсәң, ул эшне миңа калдыр. Мин өйрәнгән. Әз-мәз акчасы да шул үлем-җитем булганда гына килә. Казанда ясин чыкканга ике йөз сум бирәләр, ди. Без монда егерме тәңкәгә эшлибез.

В ә л и ә х м ә т керә.

В ә л и ә х м ә т. Әссәламегаләйкем! Нәрсә, сәдака бүлешәсезме?

Ә с ф ә н д и я р. Кеше өенә рөхсәт сорап керергә кирәктер.

В ә л и ә х м ә т. Рөхсәт сорап нәчәлство янына гына керәләр. Түрә булырга җыенмыйсыңдыр ич?

Ә с ф ә н д и я р. Әдәп дигән нәрсә бар. Сез бит мулла оныгы. Ул әдәпсез булмагандыр.

В ә л и ә х м ә т. Оһо! Бабайлар ялгышын оныклар төзәтә.

Ә с ф ә н д и я р. Бабагыз ялгышканмыни?

В ә л и ә х м ә т. Ялгышкан. Кара мужикның аңгыра башына аң кертергә тырышкан. Шуның өчен мужиклар аны авылдан сөргәннәр. Алачыкта туган алга чыкмый. *(Сәлахетдингә.)* Ә син монда нишләп утырасың?

Сәлахетдин. Килдем әле менә.

Вәлиәхмәт. Йөрмә монда. Яшисең килсә, үләргә өйрән.

Сәлахетдин. Син дә мәңгелеккә килмәгән, Вәлиәхмәт! Кайттың да монда...

Вәлиәхмәт. Кайтып нишләдем? Әйтеп бетер, кайтып нишләдем?

Сәлахетдин. Авылга хуҗа булдың.

Вәлиәхмәт. Булдым. Сарык көтүе көтүчесез булмый.

Сәлахетдин. Мыскыл итмә инде ул кадәрле.

Вәлиәхмәт. Итәм. Сез мыскыл ителергә яратылган. Сез бетәргә тиеш. Бер югалган оят табылмый. Мин сезнең авылыгызга ясин чыгарга кайттым.

Сәлахетдин. Ярый, китим инде мин, кем...

Әсфәндияр. Әсфәндияр...

Сәлахетдин. Әйе, Әсфәндияр. Ә син, Вәлиәхмәт, бик азынма. Кешегә ясин чыгу җиңел нәрсә түгел ул. *(Китә.)*

Әсфәндияр. Нигә сез шундый усал?

Вәлиәхмәт. Усал гына түгел, явыз.

Әсфәндияр. Минем янга шуны исбатларга килдегезме? *(Паузадан соң.)* Нигә шулай текәлеп карап торасыз?

Вәлиәхмәт. Өйрәнәм. Мин бит психолог. Синең кем икәнлегеңне күзеңә карап беләсем килә.

Әсфәндияр. Белдегезме соң?

Вәлиәхмәт. Чамаладым. Куркак малай түгел син. Тәвәккәл күренәсең. Казандагылар белән ызгышырлыгың бар. Югыйсә анда власть белән бәлеш төбен бүлә алмый интегәләр.

Әсфәндияр. Бүлешер власть монда да бар шикелле.

Вәлиәхмәт. Мондамы власть? Бер яртыга социализмны саттылар, ике яртыны куйсаң, капитализмны сатачаклар. Үз җирен сатып эчкән мужикта нинди власть...

Әсфәндияр. Ә сез?

Вәлиәхмәт. Мин власть түгел.

Әсфәндияр. Әлегә мин сездән башка властьны күргәнем юк. Мин дә бит психолог. Имам-хәзрәтләр психология фәнен белергә тиешләр. Уйлавымча, бу авылга бүген сез хуҗа.

Вәлиәхмәт. Шуннан?..

Ә с ф ә н д и я р. Шуннан шул. Сездәге властьны мин алырга телим. Сез авылны бетерергә, ясин чыгарга кайткан, мин аны яшәтергә килдем.

В ә л и ә х м ә т. Әй сабый, сабый... Мәеткә аспиринның файдасы юк, энекәш. Әгәр проблема ясинда гына булса. Авылның хуҗасы мин түгел. Авылның хуҗасы — азгынлык, бозыклык, имансызлык. Мин шуларны күреп куанучы гына.

Ишек шакыйлар.

Ә с ф ә н д и я р. Керегез!

Н а л и м ә керә. Кулында — бидон.

В ә л и ә х м ә т. Әнә хуҗаларның берсе.

Н а л и м ә. Нәрсә булган? Нигә ыржаясың?

В ә л и ә х м ә т. Прости, тётка, ыржаймыйм, яратып әйтәм.

Н а л и м ә *(бидонын идәнгә куеп)*. Кем диден? Нинди праститутка мин сиңа, ә? Күрсәтермен мин сиңа праститутканны! Авызыңа берне тондырырмын! Тешләреңне җыеп ала алмассың!

В ә л и ә х м ә т. Яле, тондырып кара.

Налимә, кизәнеп, Вәлиәхмәтнең битенә суга. Вәлиәхмәт аптырап кала.

Нишлисең син? Нишлисең син, ә? *(Налимәнең җилкәсеннән эләктереп ала.)*

Н а л и м ә. Җибәр!.. Җибәр!..

Ә с ф ә н д и я р *(Налимәне Вәлиәхмәт кулыннан аерып ала. Вәлиәхмәткә)*. Чыгып китегез!

В ә л и ә х м ә т. Вот кабахәт, әтисе кебек кешегә суга.

Ә с ф ә н д и я р. Чыгып китегез, Вәлиәхмәт Габделәхәтович! Үтенеп сорыйм.

В ә л и ә х м ә т. Вот кабахәт!.. *(Чыгып китә.)*

Н а л и м ә. Күрсәтермен мин сиңа праститутка. *(Муенын тотып.)* Буып үтерә язды, заразы.

Ә с ф ә н д и я р. Башлап үзегез суктыгыз бит.

Н а л и м ә. Әйтмәсен теләсә нәрсә. Рәтле сүзе юк. Өе тулы китап. Үзен тагын мулла оныгы, диләр. Вәт хәшәрәт, нәрсә ди, ә! Кеше әллә нәрсә уйлар. *(Стенадагы көзге янына килеп чәчен төзәтә.)* Кара син

аны... *(Бидонны кулына алып.)* Менә Мөслимә апа аш җибәрде. *(Кесәсеннән төенчек алып.)* Ипие монда. Кайда икән боларның савыт-сабалары. *(Шкафтан тәлинкәләр, кашыклар табып ала.)* Бөтенесе бар, берсен дә алмаганнар. Самат абыйдан куркалар, бүтән булса, әллә кайчан чистартып чыгарлар иде.

Әсфәндияр. Урлашалармыни авылда?

Налимә. Кайда урлашмыйлар соң?! Урлыйлар да сатып эчәләр. *(Тәлинкәгә аш сала-сала.)* Бар, кулыңны ю. Кранда су бар. Сөлге шунда. *(Кулларын юып килгән Әсфәндиярга.)* Утыр, бисмилләңны әйт тә аша. «Бидонны алып чык» диде Мөслимә апа. *(Урындык алып, ишек янына барып утыра.)* Аша, оялма.

Әсфәндияр *(өстәл янына утырып)*. Сез кем?

Налимә. Ничек «кем»? Налимә!

Әсфәндияр. Мөслимә апаның кеме?

Налимә. Кеме булсын, күршесе. Аша әйдә, аша, оялма. *(Әсфәндиярның ашау рәвешен күзәтеп тора.)* Син чынлап та мулламы?

Әсфәндияр. Ә нигә?

Налимә. Сакалың да юк. Сакалсыз мулла булмый инде.

Әсфәндияр. Аның каравы түбәтәем бар.

Налимә. Түбәтәйне хәзер бөтен кеше кия инде.

Әсфәндияр. Каты суктыгыз теге кешегә. Үтерүегез мөмкин.

Налимә. Үтерерсең аны.

Әсфәндияр. Өлкән кешенең йөзенә сугу кыз кешегә килешми.

Налимә. Нинди өлкән кеше? Очраганда беренче сүзе – «кайчан үләсең инде?». Бөтенесе курка аңардан, мин генә курыкмыйм.

Әсфәндияр. Кыз кешегә сугышу барыбер килешми.

Налимә. Кызлар диеп торсаң монда.

Әсфәндияр. Кулыгыз да саллы, ахрысы.

Налимә. Сабан туенда гер күтәрәм, кул көрәштерәм.

Әсфәндияр. Ничә яшь соң үзегезгә?

Налимә. Нигә кирәк ул сиңа?

Әсфәндияр. Болай гына. Бик яшь күренәсез.

Налимә. Кара моны. Олылар кебек сөйләшеп утырган була. Үзең әле миннән дә яшьтер. Озак ашыйсың икән син.

Ә с ф ә н д и я р. Ризыкны хөрмәт итәргә кирәк.

Н а л и м ә. Озак ашапмы?

Ә с ф ә н д и я р. Тиз ашасаң, тәмен белеп өлгереп булмый.

Н а л и м ә. Барыбер бер корсакка керә инде ул. Сине монда Самат абый алып кайттымы?

Ә с ф ә н д и я р. Юк, Путин җибәрде.

Н а л и м ә. Нәрсә-ә-ә-ә?

Ә с ф ә н д и я р. Ә нигә?

Н а л и м ә. Урыс ич ул мулла җибәрергә... И-и, котыртып утырган була...

Ә с ф ә н д и я р. Чынлап. Чуртыш авылы кешеләре мәчеткә йөрми икән, барып кайт әле, ди.

Н а л и м ә *(көлеп)*. Дурак! Миннән көлгән була.

Ә с ф ә н д и я р. Чынлап менә.

Н а л и м ә. Син мәчеткә йөрттерәсеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Йөрмәсәләр, хәбәр ит, милиция җибәрттерәм, диде.

Н а л и м ә. Бик исләре китә безнең авылда милициягә. Учаскавай үзе безнең авыл малайлары белән эчеп йөри.

Ә с ф ә н д и я р. Бер дә аек кеше юк мәллә районыгызда?

Н а л и м ә. Бар да инде ул. Күбесе эчә шул.

Ә с ф ә н д и я р. Сез дә эчәсезме?

Н а л и м ә. Минме? Дурак! Нишләп мин эчим. Сүзеңне үлчәп сөйлә.

Ә с ф ә н д и я р. «Дурак» сезнең яраткан сүзегезме әллә?

Н а л и м ә. Әйтелә инде шунда. Ачуланма тагын.

Ә с ф ә н д и я р. Исемегез ничек әле?

Н а л и м ә. Ничек булсын, Налимә.

Ә с ф ә н д и я р. Матур исем.

Н а л и м ә. Әти кушкан инде — Галимә, Сәлимә, Налимә... Аша инде тизрәк.

Ә с ф ә н д и я р. Булды бугай бу. Рәхмәт сиңа, Налимә.

Н а л и м ә. Аминыңны тот. *(Әсфәндиярның эченнән генә дога укыганын дикъкать белән күзәтә.)* Ә син нәрсә укыдың?

Ә с ф ә н д и я р. Әлхәмделиллаһи әлләзи вә тәгамәнә, вәсаканә, вәҗәгаләнә минәл мөслимин. Биррәхмәтикә, Ярабби. Аллаһы әкбәр.

Н а л и м ә. Матур икән. Миңа да язып бирерсең. Ату, мин битне генә сыпырып куям. *(Өстәлдәге табак-*

*савытны җыештырганда, Әсфәндиярның күзләрен күреп туктап кала.)* Нишлисең, ә? Нигә шулай карап торасың?

Әсфәндияр. Чибәр сез, Налимә!

Налимә. Алай итеп карама бүтән. Ату, ашарга кертмим. *(Табак-савытларны кухня ягына алып чыгып китә.)*

Бәдретдин керә.

Бәдретдин. Әссәламегаләйкем!

Әсфәндияр. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, түрдән узыгыз, Бәдретдин абзый! *(Бәдретдиннең кеткелдәп көлгәненә гаҗәпләнеп.)* Нигә көләсез?

Бәдретдин. Түрдән уз, дисең бит... *(Паузадан соң.)* Баш авырта, берәр нәрсәң юкмы?

Әсфәндияр. Нинди нәрсә?

Бәдретдин. Нинди нәрсә, дип... Зарифулла абыйның әче балы була иде. Калмады микән? Баш авырта.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт Габделәхәтовичта юкмыни?

Бәдретдин. Ул минем ишеләргә бирми.

Әсфәндияр. Сез кем соң?

Бәдретдин. Кем дип, алкашлар инде без...

Налимә *(кухня ягыннан чыга. Бәдретдинне күреп)*. Син монда нишләп йөрисең, алкаш? Бар, барбар, йөрмә монда. *(Бәдретдинне төрткәләп чыгарып җибәрә.)*

Әсфәндияр. Нигә аны куасыз?

Налимә. Йөрмәсен. Ияләштермә. Куып чыгара алмассың.

Әсфәндияр. Бу бит сезнең өегез түгел.

Налимә. Булмаса тагын. Син әле аларны белеп бетермисең. Юаш булсаң, өстеңә менеп атланалар. Тфү, заразы. Сасытып чыгып китте.

Әсфәндияр. Ул бит сездән өлкән кеше.

Налимә. Нәрсә һаман өлкән дә өлкән. Өлкән дип, әллә алдына тезләнимме? Сау бул, иртәгә керермен. Нәрсә кертим?

Әсфәндияр. Ни булса да ярый.

Налимә. Мөслимә апа әйтә, муллалар бәлеш ярата, ди... Ашагач укый торган доганы язып бирергә онытма. *(Чыгып китә.)*

## Өченче күренеш

Шул ук өйдә Мөслимә, Налимә, Гөлназ. Мөслимә утырып тора, кызлар өй җыештыралар.

Мөслимә. Мин чыгыйм, кызлар! Бөтен җирне әйбәтләп сөртеп чыгыгыз. Тормаган өйгә тычкан да ияләшкәндер. Исе сизелә.

Налимә. Карале, Мөслимә апа, моның өчен безгә түлиләрме соң?

Мөслимә. Кем түләсен, савабы булыр.

Налимә. Савабы дип, ничә ел бушка эшләтәләр.

Мөслимә. Бушка эшләүнең нәрсә икәнен белмисез әле сез. Менә без эшләдек ул бушка. Элек тә акча түләмәделәр. Хәзер дә, хезмәт хакыгыз әз булган дип, пинсәне тиенләп кенә бирәләр. Өйрәнә тор, ияләшә тор бу өйгә. Бәлкем әле, шуңа кияүгә дә чыгып куярсың. Өйләнмәгән, ди. Төс-кыяфәте дә Алланың биргәненә шөкер. Абыстай булып йөрерсең.

Налимә. Кит әле. Абыстай дип ул хәтле... Син кушканга гына эшлибез.

Мөслимә. Кайтып җитмәсә, ачкычын ишек өстенә куярсыз. *(Чыгып китә.)*

Гөлназ. Карале, малай, урынын кызлар кебек җыештырган. Прастыйналары чиста. Казаннан алып килгәндер инде.

Налимә. Кәнишне! Монда кем әзерләп торсын аңа.

Гөлназ. Бигрәк яшь күренә, әйеме?

Налимә. Күз читләрендә җыерчыклар күренә инде, бигүк яшь түгелдер.

Гөлназ. Көләч кешеләрнең күз кырыенда җыерчыклар була, ди.

Налимә. Миннән көлгән була. Путин җибәрде, ди. Шәймиев дисә, бер хәер.

Гөлназ. Шәймиев тә мулла җибәреп ятмый инде. Ул главаларны гына җибәрә. Боларның башлыгы мөфти дигән кеше.

Налимә *(караватка авып)*. Шушында мулла хатыны булып ятсаң, ә!

Гөлназ. Тор, бөгәрлисең. Кайтып керсә...

Налимә. Кайтып керсә, яныма ятар. Ят әле син дә, ике кеше сыя микән?! *(Гөлназны кулыннан тартып*

*яткыра, кочаклый.)* Кайттыңмы, җаным-бәгърем, муллакаем!

Гөлназ. Алай көлмә мулладан, гөнаһ булыр.

Налимә. Мулладан көлгәннең гөнаһысы юк, Алладан көләргә генә ярамый.

Гөлназ. Тор әйдә, сөртеп чыгыйк.

Шулчак азан тавышы яңгырый. Кызлар, сикереп торып, тәрәзәне ачып тыңлыйлар.

Налимә. Карале, җырлаган кебек...

Гөлназ. Үзе микән ул?

Налимә. Кем булсын инде тагын. *(Тыңлыйлар.)* Кара, бер җырга охшаган бит. *(Азаннан соң укылган дога аһәңенә кушылып көйли.)*

Гөлназ. Безнең татар теле укытучысы Зәки абый, Мөхәммәд пәйгамбәр татар булган, дип әйтә иде бит, дөрестер, ахры, иеме?

Налимә. Аңа бөтенесе дә татар инде. Иван Грузный гына урыс. Әйдә киттек. Догасын укып бетергәч кайтыр.

Гөлназ. Кайтса соң...

Налимә. Әй, көтеп торган кебек. Болай да инде... Кичә ашарына керткән идем. Күзенә ялгыш караган идем, сихерле. Кочагына кергәнеңне сизми дә калырсың. Илбрүснең күзе оятсыз. Ыржаеп көлә, барыбер кызлыгыңны мин алам, ди. Бирделәр ди, көтеп тор. Кагылып кына карасын, Казандагы дәү абыйның мылтыгы белән маңгаена терәп атармын. Син беләсеңме, «яратам» дип миннән әйттермәкче була, үзе әйтми. Ничә кызның башына җитте инде, хайван.

Гөлназ. Җиткергәч җитәләр инде. Синең белән миңа җитмиләр бит.

Налимә. Җитмиләр дә... Кыз килеш картаеп та инде... Синеке килеп йөриме әле?

Гөлназ. Килә дә. Куркытканнар әле теге бандитлар. Безнең авыл кызы янына килеп йөрмә, үтерәбез, дигәннәр.

Налимә. Вәт заразы, паразитлар. Үзләре дә алмый, бүтән авылга да бирмиләр.

Гөлназ. Шундый нәрсә уйлап чыгарганнар, ди. Чит авылга кияүгә чыгарга җыенсаң, башта үзебезнең авыл егете белән йоклыйсың, дип әйтәләр, ди.

Налимә. Сиңа әйттеләрме?

Г ө л н а з. Әйткәннәре юк та. Әгәр бездән качып чыксаң, иреңне имгәткәнче кыйныйбыз, инвалид ир белән яшәрсең, дип әйтәләр, ди... Әйдә, караватастын гына сөртәбез дә... *(Караватастына иелә. Аннан гантельләр тартып чыгара.)* Налимә, нәрсәләр бу?

Н а л и м ә. Куй урынына, кирәк әйбердер.

Г ө л н а з. Гер дә бар монда, Налимә.

Н а л и м ә. Яле, яле... чынлап гер бит бу, ике потлы. *(Күтәреп карый.)* Әллә спортсмен микән? Юри генә мулла булып йөридер әле.

Ә с ф ә н д и я р кайтып керә. Н а л и м ә гер күтәргән килеш, тораташ булып катып, Әсфәндиярга карап тора. Аннан, герне атып бәреп, чыгып йөгерә. Аңа Г ө л н а з да иярә. Әсфәндияр гер, гантельләрне карават астына урнаштыра. С ә л а х е т д и н керә.

С ә л а х е т д и н. Керергә ярыйдыр бит?!

Ә с ф ә н д и я р. Әлбәттә, ярый, исәнмесез!

С ә л а х е т д и н. Әссәламегаләйкем! *(Утырып дога кылгач.)* Түбән очның Әйзенхауыры үлгән.

Ә с ф ә н д и я р. Кем?

С ә л а х е т д и н. Шундый исемле кеше инде. Кушаматы бугай инде. Исеме белән әйтүче юк. Ниндидер ярамаган нәрсә эчеп үлгән. Уксус диме шунда. Миңа килгәннәр. Мин инде синнән узып... «Ю» дисәң, юармын анысы.

Ә с ф ә н д и я р. Эчеп үлгән дисезме?

С ә л а х е т д и н. Шуның белән кырыла инде халык... Нәрсә әйтәсең?..

Ә с ф ә н д и я р. Нәрсә әйтәмме? Мин, Сәлахетдин абзый, эчеп үлгән кешегә ясин чыкмыйм.

С ә л а х е т д и н. Догасыз китсен дисеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Догасыз яшәгән бит.

С ә л а х е т д и н. Догасыз дип... ул гына да гаепле түгел инде аңа. Заманасы догасыз булгач. Яши белеп яшәмәгән икән, җәзасын тегендә алыр. Ходай үзе белер.

Ә с ф ә н д и я р. Бөтен эшне Ходайга тапшырсак, без нәрсәгә кирәк соң? Без – Ходай язганны халыкка җиткерүчеләр. Безнең сүзгә колак салмыйлар икән, димәк, Ходай язганга каршы бармакчылар. Мин исерткеч эчеп үлгәннәргә һәм үз-үзләренә кул салган мордарларга ясин чыкмыйм.

С ә л а х е т д и н. Алай миһербансыз булырга ярамый.

Ә с ф ә н д и я р. Ә сез миһербанлы яшисезме соң? Килгәнемә ике көн, әллә ниләр ишетеп бетердем инде. Иң миһербанлы затыбыз — Аллаһы Тәгалә, әмма ул да тәмуг яраткан. Кешеләр моны белергә тиеш.

С ә л а х е т д и н. Ваһһабист дигәч тә, алай ук булырга ярамый. Син — килгән кеше. Без монда бергә яшәгән. Яманы да, яхшысы да үзебезнеке. Тормыш син дигәнчә генә бармый инде ул.

Ә с ф ә н д и я р. Мин дигәнчә түгел, Ходай кушканча барырга тиеш.

С ә л а х е т д и н. Ходае да инде аның ияләшкәндер. Карап тора бит... Алайса, үзем юып, үзем озатам инде.

Ә с ф ә н д и я р. Карагыз үзегезгә. Әмма минем фатихам юк. Исәннәр гыйбрәт алып, нәтиҗә ясасыннар.

С ә л а х е т д и н. Ясамый, улым, ясамый. Берәүсе эчеп үлә, икенчесе шуның мәете өстенә эчеп килә.

Ә с ф ә н д и я р. Сез үзегез дәме?

С ә л а х е т д и н. Син, малай, алай итеп сөйләшмә. Уйлаганыңның һәрберсен кычкырып әйтү егетлек түгел. Мин эчәм икән, бисмилла әйтми генә эчәм. Шуны да бел: беркайчан да исергәнче эчкәнем юк. Рәнҗеттең, энем!

Ә с ф ә н д и я р. Гафу итегез! Мин сезне рәнҗетергә теләмәдем.

С ә л а х е т д и н. Теләмибез дә бит...

Л е м у р белән Ә м и р керәләр.

Л е м у р. Керергә ярыйдыр бит.

Ә с ф ә н д и я р. Рәхим итегез!

С ә л а х е т д и н *(Әсфәндиярга)*. Алайса, синең рөхсәтең белән озатам?..

Л е м у р. Кемне озатасың, Сәлахетдин абый?

С ә л а х е т д и н. Ишеткәнсеңдер, Әйзенхауыр үлгән.

Л е м у р. Нигә син йөрисең анда? Син хәзер мулла түгел инде.

Ә с ф ә н д и я р. Барыгыз, Сәлахетдин абзый! *(Сәлахетдин чыгып киткәч.)* Рәхим итегез, узыгыз! Тик татар өенә аяк киемнәрен салып керәләр.

Лемур, ишек янына барып, аяк киемен сала.

Ә м и р. Панимаешь, миңа аякны, фуражканы салу не положено. И минем ботинкалар чиста да. Младший лейтенант Хабриев. Участковый.

Ә с ф ә н д и я р. Бик яхшы, утырыгыз. Әсфәндияр Әхмәтҗанов.

Л е м у р. Үзидарә председателе Лемур Сафиуллин. Үзегез килмәгәч, менә үзем килдем.

Ә с ф ә н д и я р. Лемур, дидегезме?

Л е м у р. Лемур! Ә нигә?

Ә с ф ә н д и я р. Маймыл исеме түгелме соң ул?

Ә м и р *(шаркылдап көлеп)*. Точно! Так... *(Өй эченә күз йөртеп чыгып.)* Документлар бардыр инде сезнең?

Л е м у р. Әйттем бит инде, Самат Закирович алып кайтты.

Ә м и р. Самат Закирович понятно. Но документлар булырга тиеш. Положено. О назначении муллой, например.

Л е м у р. Туктале, Әмир, әйтеп торалар бит сиңа.

Ә м и р. Падажди, падажди, Лемур.

Ә с ф ә н д и я р. Ызгышып китмәгез тагын. Икегез дә салып алган.

Ә м и р *(паузадан соң)*. М-да... Значит, так... Значит, документлар в порядке. Яхшы. А то монда кайталар разный шантрапа. Кайсы законный переселенес, кайсы незаконный переселенес. Разбирайся тут... Кайсы үлгән чёрт знает што эчеп. За всех отвечай... *(Лемурга.)* Мин сиңа точно әйтәм, хатыны гаепле монда. Ул белгән, что муж будет искать. Специально уксусны аракы бутылкасына салып куйган. Айзынхауыру что? Тапкан и эчкән, и вообще. Из-за бабы пьют мужики.

Ә с ф ә н д и я р. Ә сез ни өчен эчәсез? Вәлиәхмәт Габделәхәтович сыйлагангамы?

Ә м и р. Какой Валиахмат?

Ә с ф ә н д и я р. Сезнең кебекләр өчен кибет тота бит. Көне-төне аракы сата.

Л е м у р. Аның рөхсәте бар кибет тотарга.

Ә с ф ә н д и я р. Сезгә барысы да законно. Закон нигезендә эчәсез.

Л е м у р. Ты не очень-то выступай, братан!

Ә с ф ә н д и я р. Я вам не братан. Зарубите на носу.

Л е м у р *(урыныннан торып)*. Киттек, Әмир.

Ә м и р. Чё ты?

Л е м у р. Киттек, дим.

Ә м и р. Чё ты? Куда ашыгасың. Ну подох и подох ваш Айзынхауыр. Туда и ему дорога. *(Әсфәндиярга.)*

Значит, не братан. Давай, давай наводи монда порядок. Лемур – маймыл, значит? Обизияна. *(Шаркылдап көлә.)* Чё ты тут, Лемур, будь хозяином. Досиделся, понимаешь.

Лемур. Әмир, кит-те-ек...

Әмир. Ярый, ярый... значит, документлар порядкада? Пашли, значит. *(Чыгып китә.)*

Лемур *(чыга-чыга)*. Ачуланмагыз! Гафу итегез! *(Чыгып китә.)*

### Дүртенче күренеш

Җәйге төн. Әсфәндияр капка төбендәге утыргычта төнге авылны тыңлап утыра. Кайдадыр адашып калган сарык бәрәне кычкыра, кайдадыр эт өреп куя. Кайдадыр транзистор акырталар. Мәче башлы ябалакның ухылдап алганы да ишетелә. Ут яктысы урамга төшкән. Урамнан узучыларга Әсфәндияр күренми дә диярлек. Урамнан өч-дүрт малайны Мөслимә куып алып кайтып бара.

Мөслимә. Шушы вакытка хәтле йөрмәсәгез, дуңгызлар! Иртән уятып булмый. *(Малайлар көлешкәч.)* Ермагыз авызыгызны. Кайттылар да монда Казаннарыннан, дуңгыз көтүчесе ясап бетерделәр әбиләреннән. Вилдан! Куда пайдуш! Өйгә кайт!

Вилдан. Ну, бабушка!..

Мөслимә. Бирермен мин сиңа бабушка, ристан!

Вилдан. Дау ани, рано еще...

Мөслимә. Бирермен мин сиңа раныңны. *(Илдарга.)* Син зур бит инде, нигә ияртеп чыгып китәсең? Син хуҗа бит, алар – кунак.

Вилдан. Мы тоже хуҗа. Синең внуки.

Мөслимә. Күрсәтермен внукиеңны. Мулла абыегызга әйтермен дә...

Вилдан. Ул нишләтә, дау ани?

Мөслимә. Нишләтергә белер. Чөкиләрегезне кисәр.

Вилдан. Нәрсә ул чөки?

Мөслимә. Атла аягыңны. Кяфер булып беттеләр. Илтәм дә бирәм әниегезгә.

Илдария. Илтмә, бабушка! Илтмә, дау ани!

Мөслимәнең кайсы кулына, кайсы итәгенә асылынып, чыгып китәләр. Вәлиәхмәт белән Бәдретдин узып бара.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт, салып бир инде бераз гына?

Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт түгел. Иләктән — чиләкне, бизәктән тизәкне аерырга өйрән.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, салып бир бераз гына?

Вәлиәхмәт. Әле яңа гына эчтең.

Бәдретдин. Әз саласың бит, тел очына да йокмый.

Вәлиәхмәт. Тезләнеп сора. Тормыш ул — Сабан туе, Бәрттин! Кемдер көрәшә, кемдер чүлмәк вата, кемдер шуларны күреп кызык таба.

Бәдретдин *(Вәлиәхмәт алдына тезләнеп)*. Әз генә салып бир. Үләм бит.

Вәлиәхмәт, кесәсеннән шешә белән стакан алып, стакан төбенә аракы сала.

Вәлиәхмәт. Мә, лыкын! Үләр өчен егетлек кирәкми, үлә белеп үләргә егетлек кирәк.

Бәдретдин. Әз бит бу. Өстә инде бераз?

Вәлиәхмәт. Нәфес — нәфислекнең дошманы, Бәрттин!

Берничә тамчы аракы өсти. Бәдретдин тәмләп эчә. Вәлиәхмәт шешә белән стаканны кесәләренә тыгып куя.

Бәдретдин. Рәхмәт, Вәлиәхмәт! Әзрәк булды инде...

Вәлиәхмәт. Исерәсең килсә, аракы эчмә, гашыйк бул. Иртүк өйгә килеп керәсе булма, ботыңны сугып сындырырмын. Теге ташны күрәсеңме? Тәгәрәтеп китер шуны! *(Бәрттин тәгәрәтеп китергән ташка утырып.)* Җырла «Герман көе»н!

Бәдретдин. Әз генә салып бир?!

Вәлиәхмәт. Җырла! Күп итеп салырмын.

Бәдретдин *(моңлы тавыш белән җырлый)*.

Атландым атның биленә,
Киттем Герман иленә:
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде тузаннар;
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Вәлиәхмәт. Җырла, ник туктадың?
Бәдретдин. Атландым атның биленә,
Киттем Герман иленә:
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Вәлиәхмәт. Син, бөҗәк, бу тавыш белән театрда җырларга тиеш идең. Син шуны әрәм итеп... Мә, эч, тыгын! *(Аракы салып бирә.)* Бабаң – кабахәт, атаң – хәшәрәт, үзең – тизәк. *(Бәдретдинне тибеп ега.)*

Әсфәндияр түзми, торып болар янына килә.

Әсфәндияр. Нишлисез сез?

Вәлиәхмәт. Ә-ә-ә, сез мондамыни? Өр шуңа эт булып, Бәрттин!

Әсфәндияр *(үзенә өргән Бәдретдинне торгызып, өстен каккалый)*. Бар, абзый, кайтып йокла.

Вәлиәхмәт. Өстен кагасыз, ә? Җирәнмисез.

Әсфәндияр. Ул җирәнгеч, ә сез аңардан да җирәнгечрәк!

Вәлиәхмәт. Сүзеңне үлчәп сөйлә. Телеңне тешләвең бар. Син, акыллы булсаң, тизәктән бизәк ясарга алынма.

Әсфәндияр. Кеше тизәк түгел!

Вәлиәхмәт. Бу авылда кешеләр яшәми.

Әсфәндияр. Бәлки, сезнең бабагыз да сезнең кебегрәк булгандыр. Шуңа куганнардыр.

Вәлиәхмәт. Әй син!.. *(Сугарга кизәнә.)*

Әсфәндияр аның кулын тотып ала. Вәлиәхмәт, Әсфәндияр кулының көчле икәнен сизеп, каратэ алымын куллана, ләкин үзе сырты белән килеп төшә. Сүзсез генә күтәрелә. Әсфәндиярга карап тора да китеп бара. Әсфәндияр ташны күтәреп алып юл өстеннән читкә алып куя да урынына барып утыра. Налимә белән Гөлназ үтеп бара.

Налимә. Вәт заразы, тәки бәйләнә бит. Син мулла өенә кереп йөрисең икән, ди. Керсә, аның ни эше бар, хайван! Бик исе китте ди ул мулланың безнең ишеләргә. Кичә миңа әйтә, үзең шундый чибәр, шундый сылу,

ямьсез сүзләр кушып сөйләшмә, ди. «Дурак» дигәнне дә ошатмаган, «заразы» дигәне дә ярамый. Ул Илбрүскә «заразы» дими ни дисең инде?

Г ө л н а з. Өендә берүзе ничек утыра икән? Клубка барырга ярамыйдыр инде аларга, иеме? Тәрәзәсеннән карыйк, нишли икән?

Н а л и м ә. Кит әле, егетләр тәрәзәсеннән карап йөрергә теге...

Г ө л н а з. Нинди егет булсын, мулла ич ул.

Н а л и м ә. И, дурак! Муллаларның да егетләре була инде.

Г ө л н а з. Тот та, алайса, кияүгә чык шуңа.

Н а л и м ә. Кит әле, нишләсен ул минем белән. Укып та булмады, Казанга китеп тә булмады. Шул Илбрүсләр кала инде. Ярый ла синең егетең бар.

Г ө л н а з. Килмәде бит әле бүген.

Н а л и м ә. Әйдә, чыннан да карыйк әле, нишләп утыра икән.

Әсфәндияр яшәгән өйнең капкасына таба атлыйлар. Налимә Әсфәндиярны күреп ала.

Бәтәч! *(Баскан җирендә катып кала.)*

Ә с ф ә н д и я р. Хәерле кич, кызлар! *(Китәргә борылган кызларга.)* Качмагыз инде. *(Туктап калган кызлар янына килеп.)* Минә сезнең тавышны ишеттем дә чыктым әле.

Н а л и м ә. Нәрсә сөйләшкәнне дә ишеттеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Нәрсә турында сөйләштегез соң? Кызларның сүзе серле була бит ул... Төнлә авылыгыз бигрәк матур.

Н а л и м ә. Авылыгыз, ди. Авылыбыз, диген. Хәзер синең авыл да инде ул.

Ә с ф ә н д и я р. Әйе шул. Бигрәк матур.

Н а л и м ә. Нәрсәсе матур инде?

Ә с ф ә н д и я р. Мин кичә сандугач сайраганны тыңладым.

Н а л и м ә. Таңнан уяныпмы?

Ә с ф ә н д и я р. Гөлназ нигә сөйләшми?

Н а л и м ә. Аның йөргән егете бар, ярамый.

Ә с ф ә н д и я р. Сезнең юкмы?

Н а л и м ә. Юк шул әлегә. Киттек, Гөлназ!

Ә с ф ә н д и я р. Ашыкмагыз инде. Минем үземә генә күңелсез.

Н а л и м ә. Күңелсез дип... Клубка барырга кирәк.
Ә с ф ә н д и я р. Анда күңеллеме?
Н а л и м ә. Күңелле дип... Селкенәбез дә таралабыз инде. Җыен бала-чага белән.
Ә с ф ә н д и я р. Егетләр юкмыни?
Н а л и м ә. Аларның егетлекләре! Киттек, Гөлназ!
Ә с ф ә н д и я р. Гөлназның китәсе килми. Сез тарткалыйсыз.
Н а л и м ә. Кем тарткалый, калсын.
Г ө л н а з. Үзең кал, ярыймы. *(Китеп бара.)*
Ә с ф ә н д и я р. Сез кайтмагыз инде. Бераз утырыйк.
Н а л и м ә. Нишләп?
Ә с ф ә н д и я р. Тыңлап.
Н а л и м ә. Нәрсәне?
Ә с ф ә н д и я р. Дөньяны.
Н а л и м ә. Һе... Кызык икәнсең син... Мин өйрәндем теге доганы.
Ә с ф ә н д и я р. Сез җырлый беләсезме?
Н а л и м ә. Юк. Мин тыңларга гына яратам. Минем дәү әтием матур җырлый, әнием дә. Минем колакка аю баскан. Мин синең җырлаганыңны гел тыңлыйм.
Ә с ф ә н д и я р. Кайчан?
Н а л и м ә. Мәчеттәге радиодан.
Ә с ф ә н д и я р. Җыр түгел бит ул, азан.
Н а л и м ә. Җыр кебек инде. Мөслимә апа әйтә, сиңа егерме ике яшь, ди.
Ә с ф ә н д и я р. Дөрес әйтә. Сезгә ничә?
Н а л и м ә. Егерме тула көзгә.

Урамнан үтеп барган Э л ь б р у с Налимәнең кулыннан эләктереп ала да сөйрәп алып чыгып китә. Анда — кычкырышкан тавышлар. Налимәнең чырылдап кычкырганы ишетелә. Ә с ф ә н д и я р йөгереп чыгып китә. Налимәне күтәреп алып керә.

Ә с ф ә н д и я р. Налимә, Налимә!..

Налимә дәшә алмый. Сыны каткан.

Налимә!.. *(Налимәне кочагына алып.)* Йә, йә... Тынычлан!..
Н а л и м ә *(телгә килеп)*. Эчемә сукты, заразы.
Ә с ф ә н д и я р. Әйтмәгез, әйтмә андый сүзне.
Н а л и м ә. Авырта.
Ә с ф ә н д и я р. Районга шылтыратыйк.

Н а л и м ә. Кирәкми. *(Сулкылдап.)* Син мине кыйнаттырма, ярыймы? *(Әсфәндиярның кочагына сыенып.)* Кыйнаттырма! Син көчле бит. Син спортсмен бит.

Ә с ф ә н д и я р. Йә, йә, тынычлан, тынычлан!..

Н а л и м ә. Син минем абыем бул, абыйлыларга тимиләр.

Ә с ф ә н д и я р. Ярый, ярый, тынычлан!

М ө с л и м ә *(кереп)*. Ни булды монда?

Н а л и м ә. Мөслимә апа, минем эчемә суктылар.

М ө с л и м ә. И Ходаем! Кайсысы инде тагын?

Н а л и м ә. Илбрүс!

М ө с л и м ә. Хәерсез! Бер ел да юк бит төрмәдән чыкканына. Әйдә кайтабыз.

Н а л и м ә. Йөри алмыйм, Мөслимә апа, авырта.

М ө с л и м ә. Милитсия чакырырга кирәк мөртәткә.

Н а л и м ә. Кирәкми, кирәкми.

М ө с л и м ә. Кирәкми, димә. Үтереп ташлар.

Н а л и м ә. Кирәкми, кирәкми. Хәзер бетә авыртуы, туктый.

## Бишенче күренеш

Әсфәндияр яшәгән йортның өй эче. Караватында, чишенмәгән килеш, Ә с ф ә н д и я р ята. С а м а т кергәнне күреп, торып утыра.

С а м а т. Нәрсә, эш беттемени, хәзрәт?

Ә с ф ә н д и я р. Әссәламегаләйкем, Самат абый!

С а м а т. Сәлам, сәлам! *(Кул биреп күрешә.)* Нәрсә, кәеф юграк мәллә?

Ә с ф ә н д и я р. Болай гына...

С а м а т. Болай гына булса ярый. Ияләшеп беттеңме инде?

Ә с ф ә н д и я р. Мондыйга иялəшеп булмый. Иялəшергә Ходай язмасын!

С а м а т. Шулайдыр. Сәлахетдин абыйны утыртып кайттым. Мактый үзеңне. Халыкны клубка җыеп вәгазь укыгансың. Мәчеткә җыярга иде.

Ә с ф ә н д и я р. Мәчет клуб түгел бит.

С а м а т. Вакыты-вакыты белән клуб булса да ярый. Иялəшсеннәр, үз итсеннәр.

Ә с ф ә н д и я р. Юк, йөрмиләр. Берничә малай-шалай кызык итеп килгәли.

С а м а т. Бик әйбәт. Башта кызык итеп килсеннәр. Аннан инде... Тормыш яклары ничек, җайлымы?

Ә с ф ә н д и я р. Мөслимә апа үз баласы кебек карый.

С а м а т. Өйләнеп җибәр. Күзең төшкән кыз юкмы соң әле?

Ә с ф ә н д и я р. Бөтен авылларда да шулай микән, Самат абый? Монда бит... Болай булмый бит. Яшәү түгел бит бу.

С а м а т. Без мактап язган авыл юк ул бүген.

Ә с ф ә н д и я р. Мин авылның элеккесен дә, хәзергесен дә белмим. Элеккесен мактыйлар, ләкин ун-унбиш ел эчендә генә кешеләр болай үзгәрә алмый.

С а м а т. Азыныр өчен кешегә күп вакыт кирәкми.

Ә с ф ә н д и я р. Хайван хәленә төшкән Бәдретдин, ерткыч җанварга әверелгән Вәлиәхмәт абыйлар...

С а м а т. Мин сиңа тагын өсти алам... Моннан егерме чакрымдагы татар авылында фахишә. Акчага... Бөтен авыл белә. Йөриләр.

Ә с ф ә н д и я р. Алып китегез мине моннан...

С а м а т. Йә, йә! Теге, эчеп үлгәннең җеназасына бармый дөрес эшләгәнсең. Киләчәктә дә йөрмә. Тик кисәтеп куй, ни өчен бармаганыңны ачык белсеннәр. Кунакка чакырсалар, бар... Аракылысына барма. Әйдә, мәчетне карап кайтыйк. Намаз вакыты да җитә.

Чыгып китәләр. Тастымалга төрелгән ризыклар күтәреп, М ө с л и м ә белән Н а л и м ә керәләр.

М ө с л и м ә. Гел ташып ашатып булмас. Газлары, сулары бар. Шушында гына әзерлик. Минем балалар белән вакытым юк, сиңа кала инде.

Н а л и м ә. Мин оялам, Мөслимә апа.

М ө с л и м ә. Нидән? Кемнән?

Н а л и м ә. Әллә ни уйлавы бар. Нигә бу гел монда чуала дип...

М ө с л и м ә. Уйласа тагын. Ипләбрәк карасын. Карамаслык түгел. Менә күлмәк киеп, яулык бәйләгәч тагын да чибәрләнеп киттең. Яшең унбиштә түгел, вакытында оя кормасаң, йөрерсең карт кыз булып. Үзе өчен саклап калган ул сине. Кара син явызны, теге Илбрүсне әйтәм. Хатын-кызның эченә сугарга ярыймы соң! Бала ярала

торган урын бит ул. Аныкы шикелле аракы тутыра торган корсак түгел. Оялма, син үз эшеңне эшлә. Караса карый, карамаса, аның эше. Ошатасыңдыр бит үзен.

Н а л и м ә. Ошый инде, ничек ошамасын.

М ө с л и м ә. Бик әйбәт. Мәхәббәт ул ошаудан башлана. Син, егерме яшеңә җитеп, мәхәббәтнең ни икәнен дә белмисең. Мин аны унҗиде яшемдә татыдым... Киттем. Оялма. *(Чыгып китә.)*

Налимә урын-җирләрне рәтли. Әсфәндиярның мендәрен иснәп-иснәп карый. Азан тавышын ишетеп, Әсфәндиярның намазлыгын ала, идәнгә җәеп шунда чүгәли дә ул язып биргән доганы укый.

Н а л и м ә. Әлхәмделилләһи әлләзи вә тәганәмә, вәсаканә, вәҗәгаләнә минәл мөслимин. Бирәхмәтикә йа әрхәмәр рахимиин. Аллаһы әкбәр. *(Намазлык өстенә, бер иелеп, бер торып, һаман шул доганы укый. Азан тавышы туктагач, намазлыкны җыеп куя да көйли-көйли табын әзерли.)*

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең, кайларга шул?
Ниләргә сабыр итмисең
Тагын бер-ике айларга?
Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең, күпкәме?
Әллә айга, әллә елга,
Әллә мәңгелеккәме?
Китәм, дисең, китәм, дисең...

Л е м у р белән Ә м и р керәләр.

Л е м у р *(Налимәгә)*. Син нишлисең монда?

Н а л и м ә. Исәнмесез! Мөслимә апа ашатырга кушты.

Л е м у р. Самат абый кайда?

Н а л и м ә. Әсфәндияр белән мәчеткә кереп баралар иде. Ишетмәдегезмени дога укыганнарын?

Л е м у р. Нишлибез, Әмир? Шунда керәбезме?

Ә м и р. Чыгарлар әле.

Л е м у р. Чыгарлар әле, димә, Самат абый бит ул.

Ә м и р. Беләм инде, беләм. Крутойларны синнән күбрәк күргән.

Л е м у р. Самат абый крутой түгел. Ул – бизнесмен.

Ә м и р. Бизнесменнарын да күргән.

Л е м у р. Син күргәннәр бит ул вак-төяк. Моны Казанда да беләләр. Телевизорда күрсәттеләр.

Ә м и р. Ну и что?!

Л е м у р. Әй-й-й, ну и что, дип торма инде. Шулар тирәсендә ялманып йөрисең.

Ә м и р. Но-но-но! Син ялманмыйсың что ли?

Л е м у р. Шулай инде, акчаң булмаса, ялманасың инде.

Ә м и р. Син аңардан иномарка машина сора. Үзидарәнең авторитетын күтәрергә, диген. Сорап барасың, панимаешь, районга берәр нәрсә, иномаркага утырып… Главаның күзе акая.

Л е м у р. Әйдә, керик мәчеткә.

Ә м и р. Анда керсәк, опять ботинка салдыралар. Ә минем носкиның үкчәсе тишек.

Л е м у р *(көлеп)*. Син Самат абыйдан носки сора.

Ә м и р. Син над милицией көлмә. Без булмасак, сине өч көн дә тотмыйлар. Понял? Яшисең монда, панимаешь, суслик кебек. Кругом безобразие.

Л е м у р. Безобразиене син карыйсың инде.

Ә м и р. Карыйм мин Малаевка Маринасы белән кайсы посадкага кереп киткәнеңне.

Л е м у р. Тавышланма инде.

Ә м и р. Вот и тавышланма.

С а м а т белән Ә с ф ә н д и я р кайталар.

Л е м у р. Исәнмесез, Самат Закирович! Машинагызны күрдек тә… *(Әмиргә күрсәтеп.)* Бу…

С а м а т. Беләм. Хәлләр ничек соң, иптәш лейтенант? Тәртипме?

Ә м и р. Так точно, товарищ…

С а м а т. Ефрейтор. Армиядә мин ефрейтор идем. Нигә ишек төбендә торасыз, түргә узыгыз.

Лемур белән Әмир, аяк киемнәрен тиз-тиз генә салып, түргә узалар.

С а м а т *(урындыклар биреп)*. Утырыгыз.

Налимә кухнядан поднос белән чәй күтәреп чыгып өстәлгә куя да яңадан кереп китә. Самат, аны күзе белән озатып калып, Әсфәндиярга карый.

Ә с ф ә н д и я р. Күрше кызы ул.

С а м а т. Их, күрше кызлары — йөрәгемнең сызлавы. *(Әмир белән Лемурга.)* Ничек соң, егетләр?!

Л е м у р. Яхшы, Самат Закирович! Менә күперебез җимерелде әле.

С а м а т. Акча кирәкме?

Л е м у р. Кирәк инде.

С а м а т. Мәчеткә йөрисезме?

Л е м у р. Мәчеткә? Мәчет дәүләттән аерым бит, Самат Закирович!

С а м а т. Син нәрсә, дәүләт булдыңмыни?

Л е м у р. Эш шундый бит инде безнең.

С а м а т. Нинди эш?

Л е м у р. Нинди эш дип... Вакыт та җитми.

С а м а т. Кая куясыз соң ул вакытны?

Л е м у р. Табыла инде эш.

С а м а т. Шулайдыр. Мәчеткә эшлексезләр генә йөриләр. Менә син дәүләт инде, Лемур энекәш. Әйт әле син, дәүләттән ни өчен акча аласың? Ә сиңа ни өчен түлиләр, иптәш лейтенант?

Ә м и р. Мы выполняем то, что предписано.

С а м а т. Татарча белмисеңмени?

Ә м и р. Беләм.

С а м а т. Белгәч, нигә азапланасың? *(Лемурга.)* Авылдагы тәртиптән син канәгатьме?

Л е м у р. Ә нәрсә, Самат Закирович?

С а м а т. Канәгатьме, дип кенә сорыйм.

Л е м у р. Яшибез.

С а м а т *(Әмиргә)*. Ә син?

Ә м и р. Нормально.

М ө с л и м ә керә.

М ө с л и м ә *(ашыгып)*. Әсфәндияр, кил әле! *(Әсфәндиярның колагына пышылдый.)*

С а м а т. Исәнме, Мөслимә апа! Нәрсә анда серләшәсез?

Ә с ф ә н д и я р. Бәдретдин абый үлгән. Асылынып.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Алтынчы күренеш

Мәчет эче. Ахшам вакыты. Әсфәндияр белән Сәлахетдин намаз укыйлар. Илдар, Вилдан, Илдария, йөгереп кереп, алар янына чүгәлиләр. Өлкәннәр эшләгәнне кабатлыйлар. Үзара төртешеп алырга да өлгерәләр.

Сәлахетдин *(намаз төгәлли)*. Ярый, мин ашыгыйм әле, малайлар кайтабыз дигәннәрие. Сау булып тор. *(Чыгып китә.)*

Әсфәндияр *(балаларга)*. Ә сез нихәл? Нигә соңга калдыгыз?

Илдария. Илдар аягын юмады.

Илдар. Юмадымы, юмадымы? Менә кара!

Илдария. Дәү әни ачулангач юдың. Грязными ногами в мәчет нельзя. Әйе бит, Әсфәндияр абый?

Әсфәндияр. Әйе, мәчеткә чиста тән, чиста күңел белән керергә кирәк. Кичә өйрәткәннәрне онытмадыгызмы?

Вилдан. Мин беләм. Лә илахы иллә Аллахы...

Әсфәндияр. Әйе, Лә илаһу, иллә Аллаһу, Мөхәммәде рәсүлуллаһу. Алладан башка Алла юк. Ә Мөхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәсәллам аның илчесе. Онытмагыз, кем дә кем «мин — Алла» дип мактана икән, ул — ялганчы. Алладан башка Алла юк. Аннан инде сезнең әниләрегез, әтиләрегез, әби-бабаларыгыз...

Илдария. Вилдан, намаз укыганда, бисмилла, бисмилла, дип кенә торды. Мин, Аллакбәр, Аллакбәр, дип укыдым. Илдар дөрес укымый бит, әйеме?

Вилдан. Тик тор диләр сиңа, дура!

Әсфәндияр. Нигә алай дип әйтәсең сеңлеңә.

Вилдан. Чё она хатын-кыз башы белән... *(Илдариягә.)* Тебе вообще мәчеткә керергә ярамый, белдеңме? Бабам, мәчеткә керергә ярамый, диде, әйе бит, Әсфәндияр абый?

Әсфәндияр. Нигә ярамасын?

Илдар. Минем әти әнигә әйтә: «Син минем кабыргадан яралган, — ди. — Ачуымны китерсәң, кире тыктым куйдым булыр урынына, — ди. — Ходай сезне мәчеткә кертергә дә кушмаган», — ди.

Ә с ф ә н д и я р. Әтиләр дә кайвакыт ялгыша. Барыгыз, икенче килгәндә, бүтән малайларны алып килегез. Футбол уйнарбыз.

В и л д а н. Мәчеттә что ли?

Ә с ф ә н д и я р. Мәчет янында нинди матур урын бар. Ярый, барыгыз.

И л д а р. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!

И л д а р и я. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!

В и л д а н. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!

Ә с ф ә н д и я р *(Лемур кергәнне күреп, елмаеп)*. Намазга соңга калдыгыз.

Л е м у р. Син инде мине ачуланма. Булмый миннән. Ну картларны китерәм. Кәлимулла абыйга да әйттем. Хәлиулла абыйга да әйттем. Әгәр мәчеткә йөрмәсәгез, миңа йомыш белән килмәгез, дидем. Телгә остарып беттеләр. Синең нигә кирәгең бар, зирна бирмисең, салам бирмисең, диләр. Ә Самат абый мине тәнкыйтьли. Нишләтә алам мин аларны?

Ә с ф ә н д и я р. Мәчеткә куып китермиләр.

Лемур. Килмәгәч куасың инде. Самат абый әйтте бит.

Ә с ф ә н д и я р. Самат Закирович куып китерергә кушмады.

Л е м у р. Нишләтим мин аларны тагын. Тагын бер-ике картка әйтеп карармын.

Ә с ф ә н д и я р. Кирәкми, йөрмәгез. Йа Хода, кешеләр…

Л е м у р. Кешеләр шул. Йөзәр грамм салып бирәләр, дисәң, киләләр. Белмим, кая барадыр дөньясы?! Син миннән көләсең, исемемне маймыл исеме, дисең. Бәлкем, шулайдыр. Анысында минем гаебем юк. Бүгенге эшемнең рәте-чираты булмаганга да гаебем зур түгел. Җитешмәгән якларым бардыр, гаебем юк. Кем мин авылда? Нишли алам мин хәерче авылда? Бетәргә хөкем ителгән авылда нишли алам? Власть, диләр. Кайда ул власть?! Ярдәме тимәгән властьны кем санга суксын?! Син мине бик ачуланма инде, хәзрәт. Син килгәч, ничектер әллә ни булды әле. Үземнең кирәгемне сизә башладым кебек. Кыен, бик кыен.

Ә с ф ә н д и я р. Бергәләп тырышыйк.

Л е м у р. Әйе, әлбәттә. Рәхмәт сиңа! Вәлиәхмәт абыйга да әйттем, төнлә аракы саттырма кибетеңдә, дидем. Вон отсюда, ди. Мин нинди власть, шуңа көчем җитмәгәч…

Вәлиәхмәт керә.

Вәлиәхмәт. Керергә ярыйдыр бит?

Әсфәндияр. Әлбәттә!

Вәлиәхмәт. Ә син монда нишләп йөрисең, муниципаль берәмлек?

Лемур. Исәнмесез, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Вәлиәхмәт. Исән! Бар, йөрмә буталып эшләгән кешеләр арасында. *(Лемур чыгып киткәч, бусагага утыра да Әсфәндиярга карап тора. Шактый озак паузадан соң.)* Нихәл!

Әсфәндияр. Сезнекеннән яхшырак.

Вәлиәхмәт. Нәрсә, минем хәлем начармыни?

Әсфәндияр. Бәдретдин абый юк бит.

Вәлиәхмәт *(сикереп тора да яңадан утыра)*. Ызгышырга килмәдем.

Әсфәндияр. Безнең ызгышканыбыз юк шикелле.

Вәлиәхмәт. Шулайдыр. *(Паузадан соң.)* Дөрес эшләде Бәрттин. Аңарга бүтән төрле үлем килешми дә иде. Табигать законы – көз артыннан кыш килә. Хайванның кешегә әйләнгәнен күргәнем юк, кешенең хайванга әверелгәнен күреп торабыз.

Әсфәндияр. Кем турында әйтәсез?

Вәлиәхмәт. Мин хайван түгел, мин – җанвар! Ерткыч җанвар! Хайваннарны ашаучы җанвар!..

Әсфәндияр *(паузадан соң)*. Түргә узыгыз. Олы кешегә бусагада утыру килешми.

Вәлиәхмәт. Мәчеттә минем урыным бусагада. Мәчет – минем өчен изге йорт. Сезгә генә ул – балаган.

Әсфәндияр. Абзый кеше, ызгышырга килмәдем, дидегез. Әйдә, бер-беребезне мыскыл итми генә сөйләшик. Күреп торам бит: күңелегезне бушатырга килгәнсез.

Вәлиәхмәт. Шулай ук күренеп торамыни?

Әсфәндияр. Тора. Җаныгыз бәргәләнә.

Вәлиәхмәт *(кычкырып)*. Юк! Юк ул миндә җан. Җансыз бәндә мин. Җансыз җан иясе. Җан дигән нәрсә күптән инде адәм балаларын ташлап качты. Кешеләр Газраилнең килгәнен көтмичә үк җан бирәләр. Җаннарын саталар. Бәрттин дөрес эшләде. Нигә ул ит гәүдәсен күтәреп йөрергә. Ә мин куркак. Бәрттин эшләгән егетлекне эшли алмыйм.

Ә с ф ә н д и я р. Үз гомереңне үзең кисү егетлек түгел. Ходай биргән гомерне Ходай үзе генә ала.

В ә л и ә х м ә т. Син миңа икенең ике икәнен исбатлама.

Ә с ф ә н д и я р. Үзегез белмәгәч, исбатларга туры килә.

В ә л и ә х м ә т. Беләм мин. Аңлый гына алмыйм. Күңелсез миңа, шуны беләсеңме? Шушы авылның кешеләренә ясин чыгарга кайттым. Ә үземнең яшисем килми башлады. Йә, әйт, нишләргә миңа?

Ә с ф ә н д и я р. Иманга кайтыгыз.

В ә л и ә х м ә т. Иман? Нинди иман?

Ә с ф ә н д и я р. Ә сез аның нинди икәнен беләсез.

В ә л и ә х м ә т *(паузадан соң)*. Йә, килдем ди иманга. Шуннан ни?

Ә с ф ә н д и я р. Шуннан шул...

В ә л и ә х м ә т. Карале, егетем, кит син бу авылдан.

Ә с ф ә н д и я р. Нигә?

В ә л и ә х м ә т. Кит! Кит яхшы чакта.

Ә с ф ә н д и я р. Китмәсәм?

В ә л и ә х м ә т. Куркытырга җыенмыйм. Ялынып сорыйм. Минем үз гомеремдә берәүгә дә ялынганым булмады. Сиңа ялынам. Кит син. Беләсеңме, мин көзге яратмыйм. Көзгегә карасам, андагы кыяфәтемә төкерәсем килә. Син минем көзгем, ахрысы. Ул көзгене ватасым килми. Чөнки аның гаебе юк. Югалтасым гына килә. Кит син бу каһәр төшкән авылдан. Комачаулама миңа ясин чыгарга... *(Туктап кала.)*

Ә с ф ә н д и я р. Нигә туктадыгыз, әйтеп бетерегез?!

В ә л и ә х м ә т. Мин әйтәсен әйттем.

Ә с ф ә н д и я р. Юк, әйтеп бетермәдегез. Сез монда аны әйтергә килмәдегез, сез бушанырга килдегез.

В ә л и ә х м ә т. Нинди бушану?

Ә с ф ә н д и я р. Күңелегездәге авыр йөкне бушатырга килдегез.

В ә л и ә х м ә т *(кычкырып көлә)*. Бала-чага!.. Нинди бушану... Андагы пычракны бушатып бетереп булмый.

Ә с ф ә н д и я р. Ә сез тырышыгыз. Мин мәчетне чистарынган Вәлиәхмәт хәзрәткә калдырып китим. Авыл шаккатсын.

В ә л и ә х м ә т. Мондагы бәндәләргә ыштаның салып артыңны күрсәтсәң дә шаккатмыйлар. Ияләшкәннәр. Үзләрендә бар нәрсәне телевизордан күреп рәхәтләнеп утыралар.

Ә с ф ә н д и я р. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, муллалар вәгазь укырга яраталар. Алып ташлагыз күңелегездән үчне. Үч саклау кешене харап итә. Бабагызны кууда, мәчет манарасын кисүдә бүгенге авыл халкының гаебе юк. Кешеләр язмышы белән хакимнәр уйный.

В ә л и ә х м ә т. Тәкъдирне, ягъни язмышны Ходай яза.

Ә с ф ә н д и я р. Язганны укый да белергә кирәк. Күзе сукырайган кешеләрдән нигә үч алырга?

В ә л и ә х м ә т *(кинәт урыныннан торып чыгып китә)*. Сау бул!

Ә с ф ә н д и я р. Вәлиәхмәт абый, минем сезгә үтенечем бар.

В ә л и ә х м ә т. Үтенеч?

Ә с ф ә н д и я р. Ябыгыз аракы сата торган кибетегезне. Һич югында, төнлә сатмасыннар.

В ә л и ә х м ә т. Эчсеннәр! Бетсеннәр!

Ә с ф ә н д и я р. Үтенеп сорыйм!

В ә л и ә х м ә т. Тапмаслар дисеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Сез сатмагыз. Сез бит мулла оныгы.

В ә л и ә х м ә т *(зәһәрләнеп)*. Это не твоё собачье дело. *(Чыгып китә.)*

Әсфәндияр, тәрәзә янына килеп, Вәлиәхмәт артыннан карап кала.

Ә с ф ә н д и я р. Аллам! Адәм балаларын рәхмәтеңнән ташлама! Күгәргән күңелләрен чистарт! Адашкан җаннарга туры юл күрсәт! Иманын югалтканнарга иманын табарга ярдәм ит! Күңелләренә миһербан, мәрхәмәт иңдер! Кылган гөнаһларын ярлыка, уй-фикерләрен, кыласы ниятләрен изге ит! Йа Аллам, йа Хода, йа Тәңрем!..

Әкрен генә, кыймыйча гына Н а л и м ә керә. Тамак кыра.

Ә с ф ә н д и я р. Килгәнеңне күрмәдем.

Н а л и м ә. Мин икенче яктан килдем. Кайтмыйсың.

Ә с ф ә н д и я р. Җыена идем.

Н а л и м ә. Сагындым!

Ә с ф ә н д и я р. Нәрсә-ә-ә?

Н а л и м ә. Бүтән әйтмим, ишетмәдең.

Ә с ф ә н д и я р. Ишеттем. Ләкин...

Н а л и м ә. Әллә мәчеттә ул сүзне әйтергә ярамыймы?

Ә с ф ә н д и я р. Менә анысын белмим.

Н а л и м ә. Синең дә белмәгәнең бармыни? «Яратам» дип әйтергә ярый микән?

Ә с ф ә н д и я р. Нигә ярамасын икән?

Н а л и м ә. Алайса, нигә әйтмисең? Яратасың бит син дә. Ату, йөрим дә йөрим. Сөйлиләр. Әни дә әйтә: «Ашарга пешерергә генә йөрмисеңдер», — ди. Кешеләр дә сөйли, үзе мулла, үзе гуләйт итә, диләр. Мин бит миңа кызыгып караганыңны сизәм. Кызыгып карыйсың, якын килмисең. Сөйгән кызың калгандыр әле Казанда.

Ә с ф ә н д и я р. Беркемем дә юк минем.

Н а л и м ә. Налимә, диген.

Ә с ф ә н д и я р. Налимә.

Н а л и м ә. Алай гына әйтмә. Беркемем дә юк минем, Налимә, диген... Ярый инде, әйтәсең килмәсә. Хатын-кыз сүзен кабатлаган ир кеше ир кеше түгел инде ул.

Ә с ф ә н д и я р. Әйдә, кайтабыз, Налимә.

Н а л и м ә. Юк. Кайтасым килми әле. Монда рәхәт икән. Мин синең намаз укыганыңны карап торырга яратам. Шундый тыныч. Дөньяда бер кайгы да юк кебек. Син укы, мин карап торыйм.

Ә с ф ә н д и я р. Мин сине гел күрәм, Налимә. Әниеңне бер тапкыр да күргәнем юк.

Н а л и м ә. Өйдән чыкмый ул. Мине тапкач, өзлегеп калган.

Ә с ф ә н д и я р. Әтиең?

Н а л и м ә. Аны сорама. Әтисез тумаган инде, билгеле. Әни авыргач киткән. Мөслимә апа да минем әнием кебек. Ул мине карап үстергән. Монда ковёрлар күп икән. Талап чыкмасыннар тагын.

Ә с ф ә н д и я р. Мәчет әйберенә кемнең кулы күтәрелсен?

Н а л и м ә. Гөлназ кияүгә чыгарга җыена. Никах укытабыз, ди. Әсфәндияр укымас микән, ди. Әйткәннәр тегеләр килеп, калымыңны түлә, дигәннәр. Гөлназ белән үзидарәгә барып әйттек. Әкият сөйләп йөрмәгез, ди Лемур абый. Әкият, ди. Белми. Былтыр Гөлфиягә дә калым түләттергәннәр. Караташ авылыннан иде егете. Миңа мондый кыз кирәкми, дип өйләнмәгән. Гөлфия хурлыгыннан әллә кая китте. Беркемгә дә бернәрсә дә булмады.

Атылып, Гөлназ керә. Аның артыннан Эльбрус һәм тагын бер-ике калым түләттерүчеләр керә. Эльбрус Гөлназга таба атлый.

Әсфәндияр *(аның юлына каршы төшеп)*. Туктале син, егет!

Эльбрус *(ишек төбендә калганнарга)*. Тотыгыз аны!

Әсфәндияр *(янына килеп басканнарга)*. Мәчет бит бу, егетләр! Чыгып сөйләшик.

Эльбрус. Төкердем мин синең мәчетеңә.

Вәлиәхмәт ашыгып килеп керә. Эльбрус янына килеп баса.

Вәлиәхмәт. Нишләп йөрисез монда?

Эльбрус. Менә, Вәлиәхмәт Габделәхәтович, бу мулла кисәге кызларны бикләп тота.

Вәлиәхмәт. Бар әле, ычкын моннан!

Эльбрус. Вәлиәхмәт Габделәхәтович!..

Вәлиәхмәт. Ычкын, диләр. Мине беләсең.

Эльбрус, әкрен генә борылып, ишеккә китә. Аңа иярченнәре тагыла.

Эльбрус *(ишек янында туктап)*. Зря син, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Чыгып китәләр.

Вәлиәхмәт. Нәрсә алар? *(Гөлназга күрсәтеп.)* Моның өченме? Бар, чык киявеңә. *(Налимәгә.)* Син дә бар. Мәчеткә егет эзләп килмиләр… Барыгыз, бар, бар…

Кызлар чыгып китә.

Нәрсә мәчеткә кызлар җыясың. Урын беткәнме?

Әсфәндияр. Үзләре керделәр.

Вәлиәхмәт. Кертсәң, кочагыңа да күчәләр алар. Нәрсә, яныймы теге маңка? Шакшы малай, мәчет манарасын кисүчеләр нәселеннән. Нәрсә син маңка малайлар алдында җебеп төштең?

## Җиденче күренеш

Шул ук күренеш. Мәчет идәненә җәелгән келәмнәр юк.
Мәчеттә – Әсфәндияр, Лемур, Әмир.

Әсфәндияр. Тикшерүчеләрне чакыртыйк.

Лемур. Туктале, зурга җибәрмик. Кемнәр булыр икән, Әмир?

Әмир. Чёрт знает! Откажусь сезнең авылыгыздан. То сарык юк, то бозау, инде бу. Вор на воре сидит.

Лемур. Алай ук димә. Бүтән авылларда да шулай хәзер. Берсен дә тотканыгыз юк.

Әмир. Как это тотканыбыз юк. Тотып торабыз, тагын чыгалар. Без тотып ябып торабыз, там выпускают. Мы что ли виноваты. Уф-фу-фу! *(Лемурга.)* Басма анда, не видишь, следы. Даже обувь не снимали, сволочи! Может эти?

Лемур. Кем белә инде.

Әмир. Кем белә, кем белә?! Банда асрыйсың.

Лемур. Нинди банда? Син нәрсә инде. Авыл малайлары.

Әмир. Малайлар! А этот Эльбрус малай что ли?

Лемур. Ә син нәрсә карыйсың соң?

Мөслимә керә.

Мөслимә. И Ходаем, әллә дөресме?

Әмир. Бар әле, апа, йөрмә монда.

Мөслимә. Йөрмә монда дип... Инде мәчеткә җитештеләр.

Лемур. Синең бер дә күрмәгәнең юк, мәчет тирәсендә кеше күрмәдеңме?

Мөслимә. Күрмәдем.

Лемур. Кирәген күрмисең син дә.

Әмир. Может этот. Как его... Вәлиәхмәт? Подозрительный тип. Ничә ел яши авылда, ничек яши, никто не знает.

Әсфәндияр. Ул түгел.

Әмир. Как ул түгел? Карап тордың что ли?

Әсфәндияр. Ул түгел. Тикшерүче чакыртыгыз. Әнә бит аяк эзләре күренеп тора.

Әмир *(үтеп баручы Эльбрусны тәрәзәдән күреп)*. Әй! Брусок! Кер әле монда!

Л е м у р. Ул төнлә авылда түгел иде.

Ә м и р. Посмотрим! *(Кергән Эльбруска.)* Сәлам, Брусок!

Э л ь б р у с. Минем исемем бар.

Ә м и р. Да, ладно. Күрәсеңме монда нәрсә?

Э л ь б р у с. Сукыр түгел.

Ә м и р. Кемнәр?

Э л ь б р у с. Ә мин каян белим?

Ә м и р. Может ты?

Э л ь б р у с. Син нәрсә?

Ә м и р. Может дружки?

Э л ь б р у с. Может.

Ә м и р. Кстати, син беркайда да эшләмисең, на что живёшь?

Э л ь б р у с. Синең ни эшең бар анда?

Ә м и р. Эшем бар. Сам знаешь.

Э л ь б р у с. Минем бабай белән әби пенсия алалар.

Ә м и р. Значит, ночью син авылда түгел идең?

Л е м у р. Түгел иде, без бергә идек.

Ә м и р. Чем занимались?

Э л ь б р у с. Это не твоё дело. Безне тикшермә, каракларны эзлә.

Ә м и р. Ну ладно. Если син замешан в этом деле, смотри!

Э л ь б р у с. Нәрсә син җикеренәсең?

Ә м и р *(пистолетын чыгарып)*. Күрәсеңме моны?

Э л ь б р у с. Ну, күрәм.

Ә м и р. Он стреляет.

Э л ь б р у с. Беләм.

Ә м и р. И уничтожает.

Э л ь б р у с. Син нәрсә мине куркытасың?

Л е м у р. Егетләр, туктагыз әле, яхшылап кына сөйләшик.

Ә м и р . Надоел он мне.

Э л ь б р у с. Нәрсә надоел? Үзең чакырып алдың, мин килмәдем.

Ә с ф ә н д и я р. Мәчеттән чыгып ызгышыгыз. Мин тикшерүче чакыртам.

Ә м и р. Да подожди ты! Табабыз аны. *(Эльбруска.)* Малайларың да үзең белән идеме?

Э л ь б р у с. Нинди малайлар? Малайларым юк минем, өйләнмәгән.

Ә м и р. Чё лыбаешься?

Э л ь б р у с. Дурак син!

Ә м и р. Кто дурак?

Э л ь б р у с. Мин түгел инде.

Ә м и р. Значит, мин дурак? Я тебя, сука, пристрелю как собаку.

Э л ь б р у с *(Әмирнең изүеннән эләктереп)*. Ты чё сказал, падла? Чё ты сказал?

Л е м у р. Егетләр, егетләр!..

Эльбрус Әмирнең изүеннән тоткан килеш ишеккә таба бара. Чыгып китәләр. «Егетләр, егетләр» дип, Лемур аларга иярә.

М ө с л и м ә. И Ходаем! Ахырзамандыр бу, ахырзамандыр.

Тышта пистолеттан аткан тавышлар ишетелә. Әсфәндияр ишеккә бара. Мөслимә аның юлына аркылы төшә.

Чыкма, улым!

Ә с ф ә н д и я р барыбер чыгып китә.

## Сигезенче күренеш

Әсфәндияр яшәгән өйнең эче. Әсфәндияр чәй эчә. Читтәрәк, урындыкка утырып, Налимә аңа сокланып карап тора.

Ә с ф ә н д и я р. Нигә син үзең дә минем янга утырып чәй эчмисең?

Н а л и м ә. Ярамый.

Ә с ф ә н д и я р. Ни өчен?

Н а л и м ә. Мин бит синең хатының түгел.

Ә с ф ә н д и я р. Булмасаң ни.

Н а л и м ә. Үзең мулла, үзең ярамаган сүз сөйлисең. Ничек инде хатының булмаган килеш яныңа утырып чәй эчим?

Ә с ф ә н д и я р *(Налимәгә таба борылып утырып)*. Әлләниләр әйтеп куясың син.

Н а л и м ә. Әллә ниләр түгел. Мөслимә апа да шулай ди. Хатыны булмаган килеш ир-ат белән икәү генә янәшә утырып чәй эчү аның янәшәсенә яту белән бер, ди.

Ә с ф ә н д и я р. Мөслимә апа шулай ди, ә үзең ничек уйлыйсың?

Н а л и м ә . Үзем дә шулай уйлыйм. Янында утырырмын да торып китә алмам. Мөслимә апа әйтә: «Яратканыңны сиздермә, кыз балага килешми», — ди. Мин яратканымны яшерә белмим шул. Мин бу өйдән чыгасым килми генә чыгып китәм.

Ә с ф ә н д и я р. Миңа нишләргә кушасың?

Н а л и м ә . Кызык син, әйеме! Бүтәннәр «нишләргә» дип сорап тормыйлар. Гөлназны Дамир «яратам» диде дә алып китте. Син дә инде йә ярат, йә яратма. Кумыйсың да, якын да җибәрмисең. Ә минем бик тә яратасым килә. Хатының булып яратасым килә. Бәлки, син мине тиң күрмисеңдер. Син бит укыган кеше. Чынлап та килмәгәнсеңдер әле безгә, китәргә генә килгәнсең. Мине калдырып китәрсең дә, мин нишләрмен. Тагын шул Илбрүсләр кулына калырмын.

Ә с ф ә н д и я р. Юк инде, аның кулына калмаячаксың!

Н а л и м ә. Син булмагач, миңа берсе дә кирәкми. Килмәгән булсаң... Өйләнмәсәң дә, киткәндә алып кит мине моннан. Самат абый белән сөйләш. Берәр җиргә эшкә урнаштырсын.

Ә с ф ә н д и я р. Әйдә!

Н а л и м ә. Кая?

Ә с ф ә н д и я р. Сезгә. Әниеңнән рөхсәт сорыйбыз.

Н а л и м ә. Чынлапмы?

Ә с ф ә н д и я р. Бу эш белән шаярмыйлар.

Н а л и м ә. Алайса, хәзер мин өйгә чыгам. Син килеп керерсең, ярыймы? Мин белмәгән булырмын. Син әнигә әйтерсең, мин Налимәне яратам, аңардан башка яши алмыйм, диярсең. Кер, ярыймы, керми калма тагын. (*Китәргә дип ишеккә бара, анда Эльбрус белән очраша. Туктап кала.*)

Ә с ф ә н д и я р. Бар, Налимә!

Н а л и м ә. Юк, китмим. Ул нигә килгән? *(Эльбруска.)* Нигә килдең?

Ә с ф ә н д и я р. Борчылма, бар!

Н а л и м ә. Ул яхшылыкка йөрми.

Э л ь б р у с. Кит, диләр бит сиңа.

Н а л и м ә. Юк...

Ә с ф ә н д и я р. Налимә!..

Н а л и м ә чыгып китә.

Э л ь б р у с. Хуҗа булып алганмы?

Ә с ф ә н д и я р. Узыгыз әйдә, утырыгыз!

Э л ь б р у с. Урын бирәсең?

Ә с ф ә н д и я р. Сез — кунак.

Э л ь б р у с. Кунак?

Ә с ф ә н д и я р. Ә нигә? Минем бусагамны атлап кергән һәр кеше — кунак.

Э л ь б р у с. Ярый, кунак булып алыйк, алайса. Кунакка бездә бер ярты куялар.

Ә с ф ә н д и я р. Сездә шулайдыр, бездә алай түгел. Налимә әйтә, яхшылыкка йөрми, ди.

Э л ь б р у с. Дөрес әйтә.

Ә с ф ә н д и я р. Башта ук кисәтеп куйыйм, мин сездән курыкмыйм.

Э л ь б р у с. Беләм. Вәлиәхмәт абый әйтте, үзем дә татыдым. Куркытырга килмәдем. Ковёрны тапмыйлармы?

Ә с ф ә н д и я р. Әйткәннәре юк.

Э л ь б р у с. Эзләмиләр дә аны. Теге ментны куганнар бит. Пистолет белән шаярганы өчен. Алар өчен пистолет уенчык кына бит. Нигә килгәнемне беләсеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Киңәш сораргадыр.

Э л ь б р у с. Нинди киңәш?

Ә с ф ә н д и я р. Беткәнмени?

Э л ь б р у с. Миңа синең киңәшең кирәкми.

Ә с ф ә н д и я р. Юкка!.. Минем киңәшемнең файдасы тияр иде сиңа.

Э л ь б р у с. Әйтеп кара.

Ә с ф ә н д и я р. Китегез сез бу авылдан. Бу авыл кысан сезнең өчен. Монда сез сыймыйсыз. Монда сезне барысы да яхшы беләләр. Сездән куркалар, билгеле.

Э л ь б р у с. Миңа шул җиткән.

Ә с ф ә н д и я р. Ләкин бу зона түгел. Монда пахан булып булмый. Шунысы да бар: зонада петух булганнар, чыккач пахан булып кыланалар. Бигрәк тә авыл җирендә. Сезнең турыда әйтмим, кесәгезгә тыгылмагыз. Биографиямнән бер деталь: зонаның ни икәнен беләм. Күреп беләм. Һәм мин бу турыда сезгә генә әйтәм. Китегез сез моннан яхшы чакта.

Э л ь б р у с. Кая?

Ә с ф ә н д и я р. Барыр урыныгыз булмагач, нигә пахан

булып уйныйсыз? Яшәгез матур гына. Яши башларга әле соң түгел. Әби белән бабай пенсиясенә яшәү егетлек түгел бит.

Эльбрус. Ә мин аңа яшәмим.

Әсфәндияр. Беләм. Мәчетне талаучы син түгел, юл күрсәтүче генә. Юк әйбер белән маташасыз. Сарык, бозау урлау, мәчет келәмен урлау көненә калгач, юк инде ул.

Эльбрус. Әллә син!..

Әсфәндияр. Утыр матур гына. Килеп алганнарын көтеп. Мин синең кебекләрне зонада унике яшемдә күргән. Ә Налимәне мин сиңа бирмим. Син бит минем янга «Налимәне бир!» дип әйтергә килдең. Әгәр дә мин Налимәне синнән тартып алган булсам, гафу үтенер идем. Ләкин Налимә үзе. Күрдең бит.

Эльбрус. Мин аны яратам. Яратмасам, әллә кайчан инде…

Әсфәндияр. Яраткан ир кеше беркайчан да яраткан кызының эченә сукмый. Яратмыйсың син аны. Үзеңә буйсынмаган өчен генә үзеңнеке итәсең килә.

Эльбрус. Нәрсә мулла булып йөрисең, син мулла түгел бит.

Әсфәндияр. Мулла, иптәш Брусок, мулла! Синең кебекләр белән синең телдә сөйләшә белүче мулла. Әгәр дисбе тотып яныма килгән булсаң, бүтәнчә сөйләшер идек. Әйт, келәмнәрне китереп куйсыннар! Минем янга килгәнең өчен бер юлга сине кичерәм.

Эльбрус. Мин!..

Әсфәндияр. Әйе, син – син, мин – мин. Хуш иттек, Эльбрус!

Эльбрус чыгып китә. Кулына балта тоткан Налимә керә.

Налимә. Бер генә бәрә идем башына.

Әсфәндияр. Бир әле балтаңны. Мин барында беркайчан да кулыңа балта һәм гер алмыйсың, Налимә. Кул ярыштырып йөрмисең. Алар хатын-кыз эше түгел. Аңлыйсыңмы мине?

Налимә. Аңладым. «Яратам» диме Илбрүс?

Әсфәндияр. Аның шулай дип әйтергә хакы бар.

Налимә. «Яратам» дияргәме?

Әсфәндияр. Ә нигә? Син дә бит миңа «яратам» дидең.

Н а л и м ә. Мин бит...

Ә с ф ә н д и я р. Ул да үзенчә яратадыр. Мин дә бит сине үземчә яратам.

Н а л и м ә. Әйткәнең юк.

Ә с ф ә н д и я р. Әйтү ул әле ярату түгел.

Н а л и м ә. Син бөтен әйберне беләсең, үзең карт та түгел.

Ә с ф ә н д и я р. Син «өебезгә кайтам» дигән идең.

Н а л и м ә. Син чынлап киләсеңме?

Ә с ф ә н д и я р. Яраткан кешеңә ышаналар, Налимә!

И л д а р керә.

И л д а р. Мулла абый, мәчетнең ачкычын бир!

Ә с ф ә н д и я р. Нигә ул?

И л д а р. Малайлар белән намаз укырга керәбез.

Ә с ф ә н д и я р. Әле намаз вакыты түгел.

И л д а р. Ә без өйрәнә торабыз.

Ә с ф ә н д и я р. Әнә эленеп тора, ал.

Н а л и м ә. Аякларыгызны юып керегез. Комган ишек төбендә.

И л д а р. Беләбез инде. Дәү әни куйган комган.

Н а л и м ә. Мөслимә апа өйрәтеп җибәрә инде боларны. Мин киттем. *(Китә.)*

Ә м и р керә. Ишек янында аяк киемен сала.

Ә м и р. Исәнмесез!

Ә с ф ә н д и я р. Исәнмесез, иптәш лейтенант!

Ә м и р. Формадан түгел. Салдырдылар.

Ә с ф ә н д и я р. Ишеттем. Барган идем, тыңламадылар.

Ә м и р. Шулай ул. Үзләре преступностька каршы көрәшергә, диләр. Көрәшә башласаң... Мин бит аңа атмадым, җиргә аттым. Нәрсә, үтергәнне көтеп ятаргамыни?

Ә с ф ә н д и я р. Сүзне дә үлчәп сөйләргә кирәк шул. Андый сүзне төрмә күргән кешегә әйтмиләр.

Ә м и р. Ә нәрсә?! Мин әйтәм, урлатучы шул. Мин барыбер аның эзенә төшәчәкмен. Кусыннар, барыбер үземнекен докажу. Дәшми килгәч тә, муенга менеп атланды. Төрмәдә булган, имеш. Видали мы таких. Әнә Лемур курыксын. Йөрәге алынып тора. Шуның белән аракы эчә.

Ә с ф ә н д и я р. Сез дә инде...

Ә м и р. Мин үзем алып эчәм. Беләсеңме, нишли? Берәр әйбер югаласы булса, юри Лемур тирәсендә бутала. Как будто ул түгел. Белә кемнәр урлыйсын... Менә күрерсең, доканаю. Аның тирәсендә йөрүче бер дуракны, тотып, телен чиштердем. Син анда теге, кемгә, Самат абыйга әйт әле, сөйләшсен безнекеләр белән. Бизнесменнардан шүрлиләр алар.

Ә с ф ә н д и я р. Шулай да сакланыбрак йөрегез инде.

Ә м и р. Ничего! Алар сөйлиләр, милиционер тупой. Вот мин формадан түгел, значит не тупой. Посмотрим кто кого. Әгәр син Брусок икән, мин – кувалда. Да, я как кувалда тупой. Син молодец, сугыша беләсең. Каерып кына алдың кулын. Сине үзидарәгә куярга кирәк. А то утыра анда Лемур. Маймыл есть маймыл.

Ә с ф ә н д и я р. Нишләсен инде ул.

Ә м и р. Да! Нишләсен. Үзидарә, үзидарә. Название одно. Хозяева другие.

### Тугызынчы күренеш

Шул ук урын. Төн. Н а л и м ә урын җәя. Ә с ф ә н д и я р китап укый.

Н а л и м ә *(урынны җәеп бетереп, Әсфәндияр янына килә. Аны кочаклаган килеш, китапка карап тора)*. Аңлыйсың инде боларны, әйеме?

Ә с ф ә н д и я р. Юк, карап кына торам.

Н а л и м ә. Көләсең инде. Теләсәм, моны укырга мин бер айда өйрәнәм.

Ә с ф ә н д и я р. Ә син телә.

Н а л и м ә. Мин яхшы укыдым мәктәптә. Институтка да керә ала идем дә, әнине ташлап китеп булмый иде.

Ә с ф ә н д и я р. Монда бик иркен бит, күчерик әниеңне.

Н а л и м ә. Әлегә кирәкми. Кышка карарбыз әле. Алдыңа утырыйм әле, Әсфәндияр!

Ә с ф ә н д и я р. Син мине туйдыра башладың, аермый булмас.

Н а л и м ә. Алай димә, юри дә әйтмә.

Ә с ф ә н д и я р. Комачаулыйсың бит.

Н а л и м ә. Укы, укы, укы... Миңа да бер китап бир. *(Караваткa барып утыра.)*

Ә с ф ә н д и я р. Әнә Тукай китаплары, ал да укы.

Н а л и м ә. Әй, аны беләм инде мин.

Ә с ф ә н д и я р. Кайсы шигырен беләсең?

Н а л и м ә. «Пар ат», «Туган тел»...

Ә с ф ә н д и я р. Ә син башкаларын укы.

Н а л и м ә *(шүрлектән китап алып укырга утыра да китапны кире илтеп куя)*. Укыйсы килми. Мин лутчы җыр чыгарам. *(Кәгазь белән ручка алып, Әсфәндияр каршына утыра.)* Тәк, тәк... *(Көйли-көйли яза.)*

Җыр чыгарам, җыр чыгарам,
Җырлыйсым килгән өчен...
Минем бәхетемә Ходай
Әсфәндиярны биргән өчен.

Йә, ничек?

Ә с ф ә н д и я р. Нәрсә «ничек»?

Н а л и м ә. Мин җыр чыгарам, ул ишетми дә.

Ә с ф ә н д и я р. Комачаулама инде.

Н а л и м ә. Ярар, ярар.

Җыр чыгарам, җыр чыгарам,
Әсфәндияр янымда булган өчен.

Чыкмый да. Карале, Әсфәндияр, мулла хатынына телевизор карарга ярыймы?

Ә с ф ә н д и я р. Нишләп ярамасын...

Н а л и м ә. Нигә алмыйбыз соң, алайса?

Ә с ф ә н д и я р. Алырбыз.

Н а л и м ә. Куеп тор инде китапларыңны, гел укыйсың да укыйсың.

Ә с ф ә н д и я р. Укымыйча булмый. Мин гарәп телен камил белмим.

Н а л и м ә. Миңа күңелсез бит. Әйдә болай эшлибез. Бер атнаны икегә бүләбез. Биш көне — синең өчен, ике көне — минем өчен.

Ә с ф ә н д и я р. Ярый, шулай эшләрбез.

Н а л и м ә. Бүгеннән башлап... бүген минем җүләрләнәсем килә.

Ә с ф ә н д и я р. Ничек итеп?

Н а л и м ә. Белмим әле.

Ә с ф ә н д и я р. Башта бел, аннан әйтерсең.

Н а л и м ә. Син картлар кебек сөйләшәсең.

Ә с ф ә н д и я р *(китапларын куеп)*. Йә, җүләрлән!

Налимә, Әсфәндиярның алдына утырып, аны коча, үбә.

Н а л и м ә. Бир әле колагыңны!.. *(Әсфәндияр колагына пышылдый.)*

Ә с ф ә н д и я р. Аны кычкырып әйтсәң нәрсә була?

Н а л и м ә. Ярамый, ишетмәсеннәр.

Ә с ф ә н д и я р. Кемнәр?

Н а л и м ә. Шайтаннар! Син дә минем колагыма пышылдап әйт.

Ә с ф ә н д и я р *(Налимә колагына)*. Мин дә яратам.

Н а л и м ә. Тагын, тагын, тагын!.. *(Тагын Әсфәндиярны коча, үбә. Алдыннан төшә.)* Менә хәзер укы.

Ә с ф ә н д и я р. Моннан соң укып буламы?!

Н а л и м ә. Була. Бер хәреф биш булып күренәчәк. Укы, укы! Мин мишәйт итмичә генә сиңа карап торам. *(Әсфәндияр алдына китапларын куеп.)* Укы! *(Үзе, өстәлгә таянып, аңа карап тора.)* Укы инде. Нигә алай карап торасың?

Ә с ф ә н д и я р. Сокланып... Күпме синең кебек асыл кызларыбыз харап була.

Н а л и м ә. Харап була, дип. Итәкләрен җыеп йөрсеннәр... Кара, Илбрүс тәки югалган, әйеме. Синнән куркып инде.

Ә с ф ә н д и я р. Каян беләсең?

Н а л и м ә. Теге вакытта әйттең ич, мин ишек артында тыңлап тордым. Туебызны ямьсезләмәсә ярар иде дип курыккан идем, Аллага шөкер! Рәхмәт инде Самат абыйга, бөтен авылны җыеп туй ясады. Илгиз абый гына әйткән: «Аракылары да булмады, кайтып киттем», — дигән. Аракысыз да биеделәр әле. Син биемәдең. Мулла кешегә биергә килешмидәдер.

Ә с ф ә н д и я р. Бии белмим мин, биегән булыр идем.

Н а л и м ә. Сәлахетдин бабай никахны дөрес укыдымы?

Ә с ф ә н д и я р. Дөрес!

Н а л и м ә. Бер сүз сорасам ачуланмассыңмы, Әсфәндияр?!

Ә с ф ә н д и я р. Сора!

Н а л и м ә. Юк, сорамыйм.

Ә с ф ә н д и я р. Мин синең ни сораячагыңны беләм.

Н а л и м ә. Каян беләсең?

Ә с ф ә н д и я р. Беләм инде.

Н а л и м ә. Әйт, алайса.

Ә с ф ә н д и я р. Әтиең белән әниең дә, туганнарың да туйда булмады, кайда алар дисеңме? Җавап бирәм: берсе дә юк. Әби белән бабай үлделәр. Туганнарым юк. Әти белән әни исәннәрдер. Кайда икәнлекләрен белмим. Артыгын сорама. Киләчәктә сөйләшергә дә сүз калсын. Син минем бердәнберем! *(Налимәне кочагына ала.)* Син моны беркайчан да онытма – бердәнберем! Һәм син бердәнбер булырга лаек. Син миннән әллә нинди иркә сүзләр ишетергә телисең. Син аларны еш ишетмәссең. Син бердәнберем – онытма! Мин сине эзләмәдем, үзең табылдың. Ходай җибәргән! Син – Ходайның иң затлы бүләге! Ят, йокла. Мин һәрвакыт синең яныңда гына ятармын. Булдымы? *(Налимәне, күтәреп алып, урынга яткыра.)* Йокла! *(Үзе өстәл янына килеп утыра.)*

Н а л и м ә *(паузадан соң. Урында яткан килеш)*. Әсфәндияр, бер генә сорау сорыйм инде?

Ә с ф ә н д и я р. Сора!

Н а л и м ә. Мин дә хәзер мөселман булдым бит инде, әйеме?

Ә с ф ә н д и я р. Ни сөйлисең, әллә кайчан мөселман инде син.

Н а л и м ә. Юк инде, барыбер. Догалар да белмәгәч... Телевизордан күрсәтәләр. Казандагы мөселман хатыннары озын-озын күлмәкләр кияләр. Яулыкларын да әллә ничек бәйлиләр. Мин дә шулай йөримме инде?

Ә с ф ә н д и я р. Үз күлмәкләрең сиңа бик тә килешә, Налимә.

Н а л и м ә. Ярый, алайса, тыныч йокы, тәмле төшләр, диген, Әсфәндияр. Син шулай дигәч, рәхәт!

Ә с ф ә н д и я р. Тыныч йокы, тәмле төшләр.

Н а л и м ә *(паузадан соң)*. Әсфәндияр, тагын бер генә сорау сорыйм инде?

Ә с ф ә н д и я р. Сора!

Н а л и м ә. Син Аллага чынлап ышанасыңмы?

Ә с ф ә н д и я р. Ни дидең?

Н а л и м ә. Ачуланма инде.

Ә с ф ә н д и я р *(паузадан соң)*. Юк... Нигә?.. *(Налимә янына килеп, карават читенә утыра.)* Бу сорауны миңа бирәүнең дә биргәне юк иде әле. Мулла бит мин, Налимә!

Н а л и м ә. Анысын беләм инде.

Ә с ф ә н д и я р. Шулай да бик урынлы һәм вакытында бирелгән сорау. Беләсеңме, бердәнберем, мин беркемгә дә, бернәрсәгә дә ышанмый идем. Ләкин минем ышанасым килә иде. Безгә бер бабай килеп йөри башлады. Сөйли бу татар балаларын җыеп. Тыңлыйбыз инде. Тыңларга кушалар чөнки.

Н а л и м ә. Мәктәптәме?

Ә с ф ә н д и я р. Әйе, «мәктәптә»... Тимерчыбыклы мәктәптә. Тагын килә бу. Кешене өмет яшәтә, ди, ышану яшәтә, ди. Нинди өмет, кемгә ышану? Шунда инде бу әйтә, шундый бөек көч бар, ди. Мөселманнар аны «Аллаһы Тәгалә, Ходай» дип атыйлар, ди. Әллә кайчангы бабаларыбыз «Тәңре» дип әйткәннәр, руслар «Бог» дип әйтәләр, ди. Җирдә бүтән ышанычың калмаса, шуңа ышанырга кирәк, ди. Ул сине саклый, ди. Һәм, чыннан да, ул мине саклап калды. Югыйсә мин синең яныңда утырып тора алмаган булыр идем. Минем дә теге бабай кебек кемнәрнедер саклап каласым килә. Ышанмыйча моны эшләп булмый. Аңладыңмы, бердәнберем?

Н а л и м ә. Әйе...

Ә с ф ә н д и я р. Йокла. *(Баланы сөйгән кебек, Налимәне сөя дә өстәл янына барып утыра.)*

Шулвакыт тәрәзә чатырдап чатнаган тавыш ишетелә. Әсфәндияр урындыгыннан авып төшә.

## Унынчы күренеш

Шул ук урын. Ә с ф ә н д и я р урындыкта утырып тора. Н а л и м ә әйберләр җыештырып сумкаларга тутыра.

Ә с ф ә н д и я р. Налимә, әйткәнне тыңла инде.

Н а л и м ә. Әйтмә дә, сөйләмә дә. Китәбез. Сине харап иттереп, ятим бала үстерер хәлем юк.

Ә с ф ә н д и я р. Нәрсә инде син, исән ич мин.

Н а л и м ә. Бүген исән, иртәгә ни булыр?!

Ә с ф ә н д и я р. Самат абый кайтсын инде, ичмасам.

Н а л и м ә. Самат абый да кирәкми, беркем дә кирәкми. Кирәк икән, үзе кайтып мулла булсын. Минем синең

белән бәхетле буласым килә. Ходай җибәргән бәхетем, беркемгә дә бирмим.

Ә с ф ә н д и я р. Авыру әниең бар.

Н а л и м ә. Булсын. Миңа гына карарга димәгән. Мөслимә апа да әйтте, карарбыз, диде.

Ә с ф ә н д и я р. Уйлап бетерми эшлисең, Налимә.

Н а л и м ә. Уйлап бетермәсәм, сиңа кияүгә чыкмаган булыр идем.

Ә с ф ә н д и я р. Кил әле яныма!

Н а л и м ә *(кинәт үзгәреп, Әсфәндияр янына ашыгып килә)*. Нәрсә, бәгырь кисәгем, сызлыймы?

Ә с ф ә н д и я р. Юк ла инде. Кил, утыр яныма! *(Налимә, урындык алып, янына утыргач.)* Ашыкма, кабаланма, сабыр булырга өйрән. Беләм, яратасың, югалтасың килми. Ләкин шашып ярату хәерлегә илтми. Акыл белән яратырга кирәк.

Н а л и м ә. Син ярат акыл белән. Мин бүтәнчә ярата белмим. Син минем бу дөньяда бердәнберем. Сиңа аттылар, синең исең дә китми. Синең иңбашың яраланды, ә минем йөрәгемә тиде.

Ә с ф ә н д и я р. Шундый матур итеп сөйлисең.

Н а л и м ә. Үзең өйрәттең. Китик, Әсфәндияр!

Ә с ф ә н д и я р. Кая?

Н а л и м ә. Сургутта туганнарыбыз бар, булышырлар. Мин эштән курыкмыйм. Сиңа да эш табылыр. Мәчет кенә димәгән. Безгә монда калырга ярамый.

Ә с ф ә н д и я р. Ярый, уйлашырбыз. Тик кабаланма гына.

Н а л и м ә. Юк, уйлашмыйбыз. Миңа күп уйлау килешми. *(Әйберләр җыештыруын дәвам итә.)*

Ә с ф ә н д и я р *(тавышын күтәреп)*. Тукта!..

Н а л и м ә *(каушап калган)*. Нишлисең син? Нигә кычкырасың?

Ә с ф ә н д и я р. Сиңа уйларга килешмәсә, миңа килешә. Ир кеше уйлый икән, аны тыңларга өйрән. Без бит бала-чагалар түгел, ир белән хатын. Нәрсә, мин хатын-кызга ияреп йөрергә тиешмени?

Н а л и м ә. Әсфәндияр!..

Ә с ф ә н д и я р. Әйе, Әсфәндияр.

Н а л и м ә. Син мине ачуланасыңмыни?

Ә с ф ә н д и я р. Ачуланам.

Н а л и м ә. Яратмыйсыңмыни?

Ә с ф ә н д и я р. Яратканга ачуланам.

Н а л и м ә. Китмибезмени?

Ә с ф ә н д и я р. Уйлашыйк, дидем.

Н а л и м ә. Соң, шулай диген. Уйлашыйк, диген.

Ә с ф ә н д и я р. Әйттем бит инде.

Н а л и м ә. Әйе шул. Әйттең шул. *(Әсфәндияр янына утырып.)* Уйлашыйк соң, алайса. Син үзең генә уйла инде, Әсфәндияр. Мин уйлый белмим. Атучы шул Илбрүстер инде. Авылда юк, диләр. Әллә теге Вәлиәхмәт микән? Авылга ясин чыгарга кайттым, дип сөйләнә. Алайса, нигә сиңа аткан? Син бит бу авыл кешесе түгел. Миңа атсын инде, әйеме? Илбрүс булса да миңа атсын иде. Синең бит гаебең юк, сиңа мин үзем яратып чыктым. Күп сөйлим мин, әйеме, Әсфәндияр?

Ә с ф ә н д и я р. Әйе.

Н а л и м ә. Үзең әйттең «уйла» дип. Хатын-кызның уе телендә инде. Китик, Әсфәндияр, ә? Бу авылда минем яшисем дә килми.

Ә с ф ә н д и я р. Туган авылың бит.

Н а л и м ә. Туган дип. Кеше барыбер бер җирдә туа инде. Гел шунда яшәмиләр. Синең дә бит туган җирең бу түгел. Китик синең туган җиреңә.

В ә л и ә х м ә т *(ишекне ачып)*. Ярыйдыр бит?!

Н а л и м ә. Ярамый.

В ә л и ә х м ә т. Нәрсә, бу өйгә хатын-кыз хуҗамыни?

Ә с ф ә н д и я р. Түргә узыгыз, Вәлиәхмәт абзый! Налимә, чәй куясыңмы?

Н а л и м ә, әйтер сүзен әйтмичә түзеп, чәй кайнатырга китә.

В ә л и ә х м ә т. Урынны кайдан бирәсең?

Ә с ф ә н д и я р. Кунакның урыны — түрдә.

В ә л и ә х м ә т. Ярасы куркыныч түгел, диделәр. Иңбашын гына тырнап узган, диләр. Тидерә алмагач, нигә атарга диген. Шакшы кешеләр шундый инде — үзләре аталар, үзләре тидерә алмыйлар.

Ә с ф ә н д и я р. Тидергәннәр шакшы түгелме?

В ә л и ә х м ә т. Түгел! Явыз, ләкин шакшы түгел. Ярый, мәтәлеп китсеннәр, иң яхшысы исән калгансың.

Ә с ф ә н д и я р. Әллә сөенәсез?

В ә л и ә х м ә т. Син нәрсә, әллә мине хайван дип белдеңме? *(Ишектән башын тыгып тыңлап торган Налимәгә.)* Куй чәеңне, тимим иреңә.

Н а л и м ә. Тиеп кенә кара! *(Ишекне ябып куя.)*

В ә л и ә х м ә т. Нәрсә, китәм дисеңмени?

Ә с ф ә н д и я р. Кит, дидегез бит.

В ә л и ә х м ә т. Һәр әйтелгән сүз соңгысы түгел. Соңгы сүзне әйтерлек рәтең калса, җан биргәндә генә әйтәсең. Әле анысы да түгел. Соңгы сүзне синең өчен бүтәннәр әйтә. Ленин белән Сталин да соңгы сүзне әйтмәкчеләр иде. Әнә алар әйтәсене бүген бүтәннәр әйтә.

Ә с ф ә н д и я р. Философ сез.

В ә л и ә х м ә т. Һәрбер эшлексез кеше философ була. Эшләргә иренгәч, акыл сата башлый. Мин килгәнгә ачуланмыйсыңмы?

Ә с ф ә н д и я р. Нигә?

В ә л и ә х м ә т. Сиңа килмәгәч, үзең киләсең инде.

Ә с ф ә н д и я р. Килгәннәрне кертмисез дип ишеттем. Хәтта Бәдретдин абзыйны да бусагадан уздырмагансыз.

В ә л и ә х м ә т. Бәрттиннәрнең урыны түрдә түгел. Син килсәң әгәр, уйлап карар идек... Китәм дисең инде? Бәлки, дөрес эшлисеңдер. Муллалар заманы узгандыр. Безнең бабайлар гына ул кешенең хак юлга басачагына ышанып яшәгән. Үзләрен атканда да бисмилла әйткәннәр. Менә сиңа аттылар. Муллага мылтыктан аттылар. Авыл халкы аһ итте дип уйлыйсыңмы? Авыл халкы сиңа атучыны эзли дип беләсеңме? Тот капчыгыңны! Көтү куганда хатыннар, бер дә юкка атмаганнардыр әле, дип сөйләнәләр. Бер Мөслимә апа гына ах-вах итеп йөри. Миңа иманга кайтырга кушасың. Мин кайтырмын ул, менә бу сарыкларны ничек кайтарырсың... Китеп дөрес эшлисеңдер.

Ә с ф ә н д и я р. Бәлки, минем урынга сез калырсыз.

В ә л и ә х м ә т. Һе... Синең авызга бармак тыгарга ярамый.

Ә с ф ә н д и я р. Нигә? Коръәнне яттан белә, диделәр.

В ә л и ә х м ә т. Ялган! Мин аны урыс телендә укып кына өйрәндем. Тәрҗемәләр алар барысы да. Ясинны гына Коръән телендә беләм. Аннары, мулла булу өчен дога укый белү генә җитми. «Интернационал»ны яттан белгән коммунистлар үз партияләренең башына җиттеләр.

Ә с ф ә н д и я р. Авырдыр сезгә яшәве, әйеме, Вәлиәхмәт абый?

В ә л и ә х м ә т *(озак паузадан соң)*. Китмә син!.. *(Торып, ишеккә юнәлә.)*

Ә с ф ә н д и я р. Сез кая? Чәй өлгергәндер.

В ә л и ә х м ә т. Яратып эчермәгән чәйнең тәме юк аның...

Л е м у р белән Ә м и р керәләр.

Л е м у р. Керергә рөхсәтме, хәзрәт, исәнмесез, әссәламегаләйкем! Хәзрәт, менә Әмирнең әйтәсе сүзе бар.

Ә м и р. Исәнмесез! Менә болай. Әйе, мине эштән кудылар. Кусыннар. Кусалар да, мин үз дигәнемне эшләдем. Сиңа аткан кеше, мулла, милициядә утыра. Вот так. Мин эләктердем аны. Куып тоттым мин аны. Вот так.

Машина килеп туктаган тавыш. С а м а т керә.

С а м а т *(Лемурга)*. Ни булды монда?

Ә с ф ә н д и я р. Гафу итегез, Самат абый! Намаз вакыты җитте, азан әйтергә кирәк.

Шулвакыт азан әйткән тавыш ишетелә.

М ө с л и м ә *(керeп)*. Әсфәндияр энем, ачулана күрмә. Илдарыбыз бу. Тәһарәтен алды.

Азан тавышы яңгырый.

П ә р д ә.

# АЛТЫ КЫЗГА БЕР КИЯҮ

*(Ике пәрдәле моңсу комедия)*

Катнашалар:

Рәхмәтулла Хөрмәтуллович — 59 яшьтә.
Гөлчирә — 42 яшьтә.
Фаягөл — 39 яшьтә.
Рузалия — 19 яшьтә.
Нурзидә Мөбәрәковна — 45 яшьтә.
Хәдичә — 40 яшьтә.
Нина Васильевна — 42 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Вакыйга бухгалтериядә бара. Бер бүлмәдә — алты өстәл. Бөтен өстәлләрдә дә — компьютер. Пәрдә ачылганда, Рәхмәтулла үз өстәле артында эшләп утыра. Әкрен генә көйли.

Заманалар авыр, еллар ябык —
Дус-иш кирәк гомер итәргә…
Заманалар авыр, еллар ябык…
Заманалар авыр, еллар ябык…

Хәдичә керә, Рәхмәтулла өстәленә тастымалга төрелгән ризык куя.

Хәдичә. Суынганчы капкалап алыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Рәхмәтулла. Ач түгел мин, Хәдичә. Нигә инде син?..

Хәдичә сүзсез генә үз өстәле янына барып утыра. Көзгесенә карап төзәтенә. Рәхмәтулла аны күзәтә.

Сиңа чәчне кыектан ачу килешә, Хәдичә! *(Янына килеп.)* Менә бу яктан ач, бу ягын күпертебрәк җибәр. Синең йөзең тулган ай кебек түгәрәк, күпертебрәк җибәрсәң, тагын да чибәрләнәсең. Чын татар кызының чибәрлеге синдә. *(Хәдичәнең аркасыннан чәбәкли дә өстәле янына бара.)*

Фаягөл керә.

Фаягөл. Шушы трамвайларның тәгәрәп җан биргәннәрен генә күрсәм иде. Троллейбусларын үләт себереп китсен иде! Маршруткалары мәтәлеп үлсен иде!

Рәхмәтулла. Соңга калмадың ич, Фаягөл.

Фаягөл. Калмаса ни. Үләрдәй булып чаптым. Үпкәм бугазыма килде.

Рәхмәтулла. Җәяү йөрү сиңа файдалы ул, Фаягөл. Билең әз генә калыная башлады. Кызлар биле 60 сантиметр булырга тиеш.

Фаягөл. Кызлар биле бит ул.

Рәхмәтулла. Синең кай җирең кызлардан ким? Синең атлап йөрүләреңә карап торам да яшь чагым искә төшә.

Фаягөл. Сезнең аркада ашыгам мин. Кайчан килсәң дә, сез тасраеп утырасыз. Сезгә карап мин чабам.

Рәхмәтулла. Яшьрәк булсам, мин синең арттан чабар идем. Алданрак туарга ашыкканмын шул. Яңа туфли алгансың икән.

Фаягөл. Шул аякларымны кырып бетерде инде.

Рәхмәтулла. Аякларың кырып ясалган кебек шул.

Фаягөл. Күз тидермәгез тагын. Без бит исәнләшмәдек тә. Исәнме, Рәхмәтулла абзый! *(Рәхмәтулланың битеннән пәп итеп ала.)*

Рәхмәтулла. Исәнме, Фаягөл! *(Утыра.)*

Рузалия керә.

Рузалия. Исәнмесез!

Рәхмәтулла. А-а-а, Рузалия!.. Безнең яраткан кызыбыз да килде.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Рузалия.
Шул Рузалияне күрсәм,
Йөрәгем сикерия.

Мәхәббәт өлкәсендә уңышлар ничек, Рузалия?

Р у з а л и я. О’кей.

Р ә х м ә т у л л а. Их, миңа унтугыз яшь булса...

Ф а я г ө л. Нишләр идегез, Рәхмәтулла абзый?

Р ә х м ә т у л л а. Рузалияне үземә каратыр идем.

Р у з а л и я. Мин болай да сезгә карыйм, Рәхмәтулла бабай.

Ф а я г ө л. Бабай димә, безне картайтасың.

Н и н а керә.

Н и н а. Исәнмесез! *(Рәхмәтуллага.)* Привет, жених! Килегез әле, аракы исе килмәгән бер егетне кочаклыйм әле, *(Рәхмәтулланы кочаклап алганнан соң.)* привязался бер алкаш трамвайда. Зараза. С утра тыгынган, сволочь. Дөрес әйтәмме, Рахматулла Хурматуллович? «Тыгынган» – «налакался» бит, да?

Р ә х м ә т у л л а. Син әйтсәң дөрес, Ниночка. Ты всегда истину глаголишь. Как спали, Нина Васильевна?

Н и н а *(кәефсез генә)*. Бик яхши.

Р ә х м ә т у л л а. Вы Шекспира читали, Нина Васильевна?

Н и н а. Какого Шекспира?

Р ә х м ә т у л л а. Был такой англичанин. Он писал гениальные трагедии. «Отелло», например. Так вот, Отелло говорит своей возлюбленной: «Молилась ли ты на ночь, Дездемона?»

Н и н а. Ну и что?

Р ә х м ә т у л л а. Задушил Отелло Дездемону.

Н и н а. Причём здесь я?

Р ә х м ә т у л л а. При том, Ниночка, улыбаться надо. Улыбка делает женщину прекрасной.

Н и н а. Ну и улыбнитесь. Кстати, почему сез минем белән урысча сөйләшәсез? Мин татарча өйрәнәм. Мин сине яратам – приходи к воротам.

Г ө л ч и р ә *(кереп)*. Капиталистик хезмәт алдынгыларына ялкынлы сәлам! Рәхмәтигә аерым сәлам! *(Рәхмәтулла янына килеп.)* Нихәл? *(Рәхмәтулланың пеләшен үбеп ала.)* Пеләш башны үбүе җайлы, авызга чәч керми. Кара утырып торуын. Тор һәм кочакла! *(Үзе Рәхмәтулланы кочаклап алгач.)* Утыр һәм эшлә!

Ф а я г ө л. Әгәр дә Зөһрә Таһирны шулай кочаклаган булса, мәхәббәт турында гениаль әсәр язылмый калган булыр иде.

Гөлчирә. Көнләшмә. Шул җиткән аңа. Югыйсә азына башлый. Шунысын да онытмагыз, Таһир пеләш башлы булмаган.

Рәхмәтулла. Пеләш башлы ирләр бүгенге заманда файдалы, Гөлчирәкәй. Парикмахерскаяда бәяләр көн саен арта.

Гөлчирә. Сөйләштермә, эшем күп.

Берара тыныч кына эшлиләр.

Рәхмәтулла. Ишетмим. Бүген кем чираты? Рузалия, синме?

Рузалия. Мин кичә көйләдем. Бүген Нина Васильевна көне.

Рәхмәтулла. Ниночка, начинай. Эшләп булмый.

Нина. Не умею я мурлыкать. Белмим.

Рәхмәтулла. Бүтән көннәрне белә идең.

Нина. Бүген нет у меня настроения.

Рәхмәтулла. Настроение җырлаганда килә.

Нина. Прямо как надзиратель сез, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Не надзиратель, а петух в курятнике.

Гөлчирә. Аһ! Петух! Карт әтәч.

Рәхмәтулла. Сез дә чебиләр түгел. Нина, көтәм. Жду.

Нина авыз эченнән бер көй көйли.
Ул көй салмак кына яңгырый.

Гөлчирә *(кычкырып җибәрә)*. Сабакы! Тагын глюк башланды.

Рузалия. Нәрсә карый президент?!

Нина. Куда смотрит правительство?!

Фаягөл. Нигә Дәүләт Советы дәшми?!

Гөлчирә. Көлмәгез. Миңа иске шайтан машинасы бирделәр дә... Рәхмәти, кил, кара.

Рәхмәтулла. Гел синеке генә кәҗәләнә, Гөлчирә.

Фаягөл. Компьютеры да үзенә охшаган.

Гөлчирә. Молчи, морду набью.

Рәхмәтулла. Матур гына сөйләшегез. *(Компьютерны карый.)*

Нина. Тихо! Рузалия с кавалером будет говорить.

Рузалия кесә телефонын колагына куеп чыгып йөгерә.

Ф а я г ө л. Их! Сотовыең булсын иде дә шылтыратсыннарые.

Р ә х м ә т у л л а. Булды бу, Гөлчирәкәй.

Г ө л ч и р ә. Маладис! Безнең ишан хәзрәтнең белмәгәне юк. *(Көйләп.)*

Ишан хәзрәт, бар, утыр,
Син бит безнең компьютер.

Н у р з и д ә  М ө б ә р ә к о в н а керә.

Н у р з и д ә. Хәерле иртә!

Р ә х м ә т у л л а. Иртә түгел, Нурзидә Мөбәрәковна. Иртә ул эшкә килгәнче генә була. Котлы булсын яңа күлмәгегез!

Н у р з и д ә. Мин күлмәк күрсәтергә кермәдем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Иртәгә отчёт әзер булырга тиеш. Шеф ашыктыра.

Ф а я г ө л. Башта акчасын вакытында түләсен.

Г ө л ч и р ә. Сиңа нәрсәгә акча, ирең «Мерседес»та йөртсен.

Ф а я г ө л. Авыз чайкама минем ирем белән.

Р ә х м ә т у л л а. Әй сез! Кисәм телегезне. Бәхет акчада түгел. Бәхет баш бухгалтерыбыз Нурзидә Мөбәрәковнаның исәнлегендә. Утырып ял итегез, Нурзидә Мөбәрәковна, арыгансыздыр.

Н у р з и д ә *(Рузалия урынына күрсәтеп)*. Бу кыз кайда?

Н и н а. Решает любовные проблемы.

Г ө л ч и р ә. Туалетта бикләнеп, сөйгән егете белән сөйләшә. Кесә телефоныннан.

Р у з а л и я керә. Йөзе балкыган.

Р у з а л и я. Исәнмесез, Нурзидә Мөбәрәковна!

Н у р з и д ә. Бухгалтерия – утырып эшли торган эш. *(Чыгып китә.)*

Г ө л ч и р ә. Ах, нинди афоризм әйтте! Бухгалтерия – утырып эшли торган эш. Ә менә мин юри утырмыйм. *(Рәхмәтулла өстәле каршына килеп баса.)* Сөйлә мәзәгеңне, Рәхмәти.

Р ә х м ә т у л л а. Бер карт үгез су буенда ята икән. Аның янына яшь үгез чабып килгән. «Абый, көтүгә яңа таналар китерделәр, әйдә», – дигән. «Эч пошырып йөр-

мә», — дигән карт үгез. Бераздан яшь үгез тагын чабып килгән. «Әйдә инде, абый, таналары шундый сылу, сокланып туймассың», — дигән. «Нигә миңа анда барып йөрергә, су эчәргә үзләре монда киләчәкләр», — дигән карт үгез.

Гөлчирә. Ах, оятсыз! Ах, азгын! Әле син таналар көтеп утырасыңмыни? Килегез әле монда, таналар. Нишләтергә җыена икән ул безне. *(Янына хатыннар җыелгач.)* Йә, нишләтәсең безне? Менә сиңа сөлек шикелле таналар. Нишләтәбез бу карт үгезне, кызлар?

Нина. Хәзер без аны разденем и стриптиз устроим.

Рәхмәтулла. Пажалысты, пажалысты...

Фаягөл. Болай эшлибез. Без аның башына бармак белән сүзләр язабыз. Белмәсә нишләтәбез?

Гөлчирә. Печәбез. *(Туктаусыз көлеп торган Рузалиягә.)* Башла, Рузалия.

Фаягөл. Ул тана түгел, бозау гына. Куегыз әле башыгызны, иптәш үгез. *(Рәхмәтулла башына бармагы белән яза.)* Ни яздым?

Рәхмәтулла. «Яратам»...

Фаягөл. Дөрес!

Нина. Дай-ка сюда. *(Рәхмәтулла башына яза.)* Нәрсә яздым?

Рәхмәтулла. «Я вас люблю».

Нина. Дөрес!

Гөлчирә. Хәзер минекен белеп карасын ул. *(Яза.)* Әйтеп бир!

Рәхмәтулла. «Яратам».

Гөлчирә. Алдаша. «Яратмыйм» дип яздым.

Рәхмәтулла. Син үзең алдашасың. Нигә яраткан килеш «яратмыйм» дип яздың?

Рузалия. Мин дә языйм инде.

Фаягөл. Сиңа әле иртә. Телефоныңнан сөйләш.

Рәхмәтулла. Әй кулларыгыз да кулларыгыз, кызлар. Шундый йомшаклар. Шундый рәхәт. Карагыз әле, чәчем үсмәдеме?

Нина *(Рәхмәтулланы кочаклап)*. Шевелюра, Рахматулла Хурматуллович!

Гөлчирә. Кочакламагыз, ул минеке генә.

Хатыннар, шау-гөр килеп көлешә-көлешә, Рәхмәтулланы бүлешәләр. Нурзидә Мөбәрәковна кереп карап тора. Хатыннар аны күреп тиз генә урыннарына утыралар.

Н у р з и д ә. Нишлисез соң сез? Ишегегез яныннан үтеп булмый.

Р ә х м ә т у л л а. Гафу итегез, Нурзидә Мөбәрәковна, мин гаепле.

Н у р з и д ә. Мин гаепләне эзләп йөрмим. Болай ярамый бит инде. *(Чыгып китә.)*

Г ө л ч и р ә. Син нәрсә, маңка малай шикелле, мин гаепле, дип торасың ир кеше башыңнан.

Р ә х м ә т у л л а. Нәчәлствога каршы әйтергә ярамый, Гөлчирә. Артыңда ныклы терәк булмаса, нәчәлствога каршы сүз әйтмәскә кирәк.

Г ө л ч и р ә. Ә мин әйтәм. Мине терәп торучы кеше бар. Нигә кем дип сорамыйсыз? Менә Рәхмәтулла абый. Куып чыгарсалар, бер Гөлчирәсен генә ашатыр әле.

Н и н а. Аның үз хатыны бардыр.

Г ө л ч и р ә. Булмагае. Гөлчирә исемле түгелдер әле.

Н и н а. Кстати, хатыныгызны как зовут, Рахматулла Хурматуллович? Вы не разу не говорили о ней.

Г ө л ч и р ә. Төпченмә. Әйтми икән — ярамый. Безгә аның хатыны түгел, үзе кирәк. Булды — шаярдык. Әйдә эшләргә.

Тыныч кына бераз эшләп алалар.

Р ә х м ә т у л л а. Ишетмим. Кем чираты? Фаягөл!..

Фаягөл авыз эченнән генә көй көйли. Шул көй астында ут сүнә. Ут янганда, бүлмә уртасына өстәл куелган. Анда — савыт-саба, ризыклар өстәл тирәсендә Рәхмәтулла кайнаша.

Р ә х м ә т у л л а. Кызлар, чәй әзер, утырып садисыгыз!

Г ө л ч и р ә. Утырып садисыгыз,
Кеше ярларын сөяргә
Җитәрме сависыгыз?
Рәхмәти, яса чәйләреңне!

Х ә д и ч ә. Үзем.

Г ө л ч и р ә. Утыр урыныңа. Матриархат заманы, ирләр изелсен. Рәхмәти, ач вәринҗә капкачын.

Ф а я г ө л. Рәхмәтулла абзый, шикәрең кайда?

Н и н а. Рахматулла Хурматуллович, минем кашыкны бир.

Рәхмәтулла официантларга охшатып йөренә.

Г ө л ч и р ә. Безнең күңелебезне күреп җырлап тор.

Рәхмәтулла. Баш өсте. Кайсы көйне телисез, галиҗәнапбикә Гөлчирә?

Гөлчирә. «Алма турыйм»ны.

Рәхмәтулла.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алманың түгәрәген.
Инде ниләр уйлыйм икән
Мәхәббәт күбәләгем.
Алма турыйм, алма турыйм,
Алмаларның кызылын.
Сине сөйгәч кенә белдем
Бу дөньяның кызыгын.
Алма турыйм, алма турыйм,
Алмаларның яшелен.
Мине сөйми дип уйлама,
Сөюләрем яшерен.

Тагын ниләр телисез, бикәкәйләрем?

Гөлчирә. Миңа осетрина!

Нина. Миңа ананас!

Фаягөл. Миңа... Миңа... Кыздырылган фил борыны.

Рәхмәтулла. Сиңа нәрсә, Хәдичә?

Хәдичә. Миңа берни дә кирәкми.

Фаягөл. Сүз әрәм итеп сөйләшмә аның белән, Рәхмәтулла абзый.

Рузалия. Миңа шоколад.

Рәхмәтулла. Калганнарын табарга тырышырбыз. Ә шоколад — хәзер үк. *(Түш кесәсеннән шоколад алып Рузалиягә суза.)*

Гөлчирә. Ах син, ә! Кара моны нишли!

Рәхмәтулла. Аның шоколад ашый торган чагы.

Рузалия. Рәхмәт, рәхмәт! *(Рәхмәтулланың битеннән үбеп ала.)*

Гөлчирә. Булды, Рәхмәти. Бик әйбәт хезмәт күрсәткәнең өчен синең дәрәҗәңне күтәрәбез — солтан ясыйбыз.

Бер урындыкка папкалар өеп тәхет ясыйлар. Аңа Рәхмәтулланы утыртып куялар.

Гөлчирә. Хәдичә, син солтанга чәй ясап тор. Без шәрык биюен биибез. Без аның җарияләре.

Р ә х м ә т у л л а. Шәрык биюендә кендек күрсәтеп бииләр.

Г ө л ч и р ә. Кендек күрәсең килсә, Бауман урамына чык.

Р у з а л и я. Минем бабай әйтә әбигә: «Пилмән яса, пилмәнең кызлар кендеге кебек матур булсын», — ди.

Ф а я г ө л. Картлар бөтенесе азгын алар. Башладыкмы, Гөлчирә?

Шәрык бию бииләр.
Н у р з и д ә  М ө б ә р ә к о в н а керә.

Р ә х м ә т у л л а. Безнең әбәт вакыты, Нурзидә Мөбәрәковна.

Н у р з и д ә. Обед булса, бу бит ресторан түгел.

Г ө л ч и р ә. Ашханәгә акча җитмәгәч, ресторан ясыйсың инде.

Н у р з и д ә. Үз өстегезгә күпне аласыз, Гөлчирә Нәҗиповна.

Г ө л ч и р ә. Алам икән, димәк, күтәрерлек көчем бар.

Н у р з и д ә. Ә мин сез күтәргән йөкне һәм үзегезне берьюлы күтәрә алмасам?

Г ө л ч и р ә. Андыйларга татарлар, серкәсе су күтәрми, диләр.

Р ә х м ә т у л л а. Гөлчирә, усалланма.

Н у р з и д ә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, минем янга кереп чыгыгыз әле.

Н у р з и д ә чыгып китә. Аңа Р ә х м ә т у л л а иярә.

Р у з а л и я. Эләгә Рәхмәтулла абыйга.

Н и н а. Нәрсә, ул виноват что ли? Безнең обеденный перерыв.

Г ө л ч и р ә. Кеше ашаганда кереп иснәнеп йөри.

Н и н а. Син тоже, Гуля…

Г ө л ч и р ә. Нәрсә, мин тоже?

Н и н а. Нурзидә Мубараковна белән… Пререкаешься.

Г ө л ч и р ә. И, ачуым китереп торма әле марҗа башың белән.

Н и н а. Чё ты? Марзя, марзя… Үзең кем? Әйтәсең, бисмилла, бисмилла, а сама вешаешься на шею мужчин.

Г ө л ч и р ә. Кайчан мин ирләрнең муенына асылынганым бар, ә?

Н и н а. Рахматулла Хурматуллович не мужчина что ли?

Г ө л ч и р ә. Ай-яй-яй... Ревнуешь, да? Может я его люблю.

Ф а я г ө л. Арттырып җибәрәсең инде анысы. Яратканыңны бөтен кешегә күрсәтергә димәгән.

Г ө л ч и р ә. Син тик тор. Минем бит өемдә синеке кебек мужигым юк.

Ф а я г ө л. Ал, кирәк булса бирәм.

Г ө л ч и р ә. Төкердем мин синең өч тиенлек үләтеңә.

Х ә д и ч ә. Җитте инде, кызлар.

Ф а я г ө л. Ә син ояңда тик кенә утыр.

Р у з а л и я. Ә мин сезне Рәхмәтулла абыйга әйтәм.

Ф а я г ө л. Нәрсә дип әйтәсең?

Р у з а л и я. Алар сез булганда гына әйбәт, сез чыгып киткәч, ызгышалар, дим.

Г ө л ч и р ә. Кем ызгыша, әйт әле, кем ызгыша?

Р у з а л и я. Әнә бит ямьсез сүзләр әйтешәсез.

Н и н а. А ты не вмешивайся. Говори по своему телефону.

Г ө л ч и р ә. Әгәр дә Рәхмәтулла абыйга берәр начар сүз әйтсә, бәреп үтерәм мин ул хатынны.

Башын түбән иеп, Р ә х м ә т у л л а керә. Урынына сүзсез генә барып утыра. Шомлы тынлык. Хәтта Хәдичә дә, торып, Рәхмәтуллага карап тора.

Г ө л ч и р ә *(сакланып кына Рәхмәтулла янына килә)*. Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла кулын селтәп кенә җавап бирә. Бүтән хатыннар, Рузалия Рәхмәтулла янына җыелалар. Хәдичә генә тораташтай үз урынында басып тора.

Р ә х м ә т у л л а. Бетте...

Ф а я г ө л. Нәрсә бетте, Рәхмәтулла абый?

Р ә х м ә т у л л а. Мин китәм.

Н и н а. Куда, Рахматулла Хурматуллович?

Р ә х м ә т у л л а. На пенсию отправляют, Ниночка.

Н и н а. Как? Сезгә әле алтмыш юк.

Р ә х м ә т у л л а. Досрочно, Ниночка.

Ф а я г ө л. Чынмы, Рәхмәтулла абзый?

Р ә х м ә т у л л а. Чын, Фаягөл, чын.

Г ө л ч и р ә. Безобразие! Шеф янына керәбез. Шефтан узарга аның ни хакы бар?!

Р ә х м ә т у л л а. Соң инде, Гөлчирәкәй. Шеф янына алып керде Нурзидә Мөбәрәковна. Рәнҗемәгез, кызлар, төрле чакларым булгандыр. Миннән башка тату гына эшләгез, тату гына яшәгез. Әйтәсе сүзләремне бүген әйтеп калыйм. Рузалия, кызым, синнән башлыйм. Бәхетле бул, ярыймы?

Р у з а л и я. Ярый, Рәхмәтулла абый.

Р ә х м ә т у л л а. Фаягөл, бәхетле бул, ярыймы. *(Фаягөлне кочаклый.)*

Ф а я г ө л *(еларга җитешеп)*. Рәхмәт, Рәхмәтулла абый.

Р ә х м ә т у л л а. Будь счастлива, Ниночка. *(Нинаны кочаклый.)*

Н и н а. Спасибо! Рахмат, Рахматулла Хурматуллович.

Р ә х м ә т у л л а. Гөлчирәкәй. *(Гөлчирәне, кочаклап, бит уртасыннан үбә.)* Син үзең дә кочаклап үп инде, Гөлчирәкәй.

Г ө л ч и р ә *(кычкырып)*. Хәшәрәт! Алдаша! Алдаша, кызлар. Күзенә карагыз, күзенә карагыз, елмая. *(Рәхмәтуллага очып куна, тукмый, кочаклый.)* Үтерәм!

Рәхмәтулла көлә, шау-шу.

Р у з а л и я. Арти-и-ист...

Р ә х м ә т у л л а. Утырыгыз урыннарыгызга. Бүгеннән башлап шаярулар бетте. Эшкә вакытында киләсез, эшлисез, шыпырт кына чәегезне эчәсез, шыпырт кына кайтып китәсез. Нурзидә Мөбәрәковна мине бу бүлмәнең старостасы итеп билгеләде. Мин шаярмыйм, кызлар. Утырышыгыз. *(Барысы да үз урыннарына утыргач та.)* Ишетмим? Кем чираты? Минем чират. *(«Әпипә» көенә көйли.)*

Ут сүнә.

Ут янганда, Рәхмәтулла компьютерда эшләп утыра. Әлеге дә баягы үзенең җырын көйли.

Р ә х м ә т у л л а. Заманалар авыр, еллар ябык –
Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Х ә д и ч ә керә.

Х ә д и ч ә. Исәнмесез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Менә җылы өчпочмаклар.

Р ә х м ә т у л л а. Ничек җылы килеш алып килеп җиткерәсең син аларны?

Х ә д и ч ә. Мин аларны кайнар килеш төрәм дә, суынып өлгермиләр.

Р ә х м ә т у л л а. Бик күпкә китте бит инде бу, Хәдичә.

Х ә д и ч ә. Юк, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, миңа рәхәт кенә. Сез шундый тәмле итеп ашыйсыз, рәхмәт.

Р ә х м ә т у л л а. Синең белән бер утырып сөйләшәсе бар әле, Хәдичә.

Х ә д и ч ә. Нәрсә турында, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович?

Р ә х м ә т у л л а. Ташла әле шул «Хөрмәтуллович»ны. Абый, диген.

Х ә д и ч ә. Ияләшкән инде. Нәрсә турында сөйләшергә җыенасыз Рәхмәтулла... абый...

Р ә х м ә т у л л а. Бар сөйләшәсе сүзләр.

Х ә д и ч ә. Әйтерсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Кичә кулъяулыгыгыз төшеп калган булган. Югач чистарды. *(Таслап бөкләнгән кулъяулыкны Рәхмәтулла өстәленә куя.)* Берәр әйберегез каралса әйтерсез.

Р ә х м ә т у л л а. Син нәрсә инде, Хәдичә... Әллә исләмай да сөрткән инде.

Х ә д и ч ә. Ирләрнеке ул. Кибеттә әйттеләр. *(Урынына барып утыра.)* Рәхмәтулла абый, әйткәнгә ачуланмагыз. Нигә сез үзегезне мыскыл иттерәсез? Сез – олы кеше. Алар сезне бала-чагага саный.

Р ә х м ә т у л л а. Алар көлмиләр, шаяралар гына, Хәдичә.

Х ә д и ч ә. Шаяралар дип инде...

Р ә х м ә т у л л а. Менә бүген чәчеңне дөрес ачкансың. Шулай йөрт. Бик килешә.

Р у з а л и я керә дә тәрәзәгә чаба. Карап тора. Урынына килеп утыра.

Р ә х м ә т у л л а. Киттеме?

Р у з а л и я. Уһу...

Р ә х м ә т у л л а. Әйбәт егетме?

Р у з а л и я. Уһу...

Р ә х м ә т у л л а. Әйбәт булгач бик әйбәт. Шулай да син исәнләшергә онытма инде.

Р у з а л и я. Әллә исәнләшмәдемме?

Р ә х м ә т у л л а. Юк шул.

Р у з а л и я. Ай, гафу итегез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Исәнмесез, Хәдичә апа.

Н и н а керә. Кәефсез генә исәнләшеп урынына узып утыра.

Р ә х м ә т у л л а *(аның янына килеп).* Успокойся, Нина Васильевна.

Н и н а. Я спокойна, Рахматулла Хурматуллович.

Р ә х м ә т у л л а. Успокойся, всё будет хорошо.

Н и н а. Спасибо, Рахматулла абы.

Ф а я г ө л керә.

Ф а я г ө л. Исәнмесез! *(Рәхмәтулла янында туктап.)* Рәхмәтулла абый, бүген мине көйләтмәгез, яме. Кәефем юк.

Р ә х м ә т у л л а. Кәеф булмаганда көйләргә кирәк тә инде ул, Фаягөл. Кәефле чакта исерек тә җырлый.

Ф а я г ө л. Чынлап әйтәм, Рәхмәтулла абый. Чынлап та кәефем юк.

Р ә х м ә т у л л а. Ярый, синең өчен үзем көйләрмен.

Ф а я г ө л. Соң, куйыйк берәр музыкальный центр. Торсын көйләп.

Р ә х м ә т у л л а. Әнә шул центрлар күбәйгәнгә кешеләрнең кәефе юк инде, Фаягөл. Ярый, бар, утыр. Тынычлан. Барысы да җайланачак.

Г ө л ч и р ә керә.

Г ө л ч и р ә. Бетте. Көннең рәте-чираты булмаячак. Өйдән чыккач, кара мәче очрады, коридорда Мөбәрәковна каршыга килеп чыкты.

Р ә х м ә т у л л а. Аның каравы монда мин көтеп торам. Нихәл!

Г ө л ч и р ә. Әй, сине дә күрәсе килеп тормый әле. Нихәл?! Бүген магнитлы көн мәллә? Нәрсә берегез дә сөйләшмисез?

Р у з а л и я. Исәнмесез, Гөлчирә апа.

Г ө л ч и р ә. Исәнме, матурым. Әле дә син бар, бәгырькәем.

Р у з а л и я. Сез зря Рәхмәтулла абыйга алай әйттегез.

Г ө л ч и р ә. Нәрсә дип әйттем?

Р у з а л и я. Күрәсем килми, дидегез.

Г ө л ч и р ә. Һай, берәүнең адвокаты табылган. *(Рәхмәтулла янына килеп.)* Кил! *(Бер кулы белән кочаклап ала.)* Булдымы?

Р у з а л и я. Кайчан сез Рәхмәтулла абыйны кочаклыйсыз, миңа бик ошый.

Гөлчирә. Ярый, Аллага тапшырдык. *(Урынына утыра.)*

Тын гына эшлиләр. Фаягөл көй көйли башлый. Аңа Рәхмәтулла кушыла.

Рәхмәтулла. Их, кызлар! Ун яшьтә мин райком секретаре кызына гашыйк булган идем. Аңа тугыз яшь иде. Аларның чия бакчасы бар иде. Шунда чия агачлары арасында үбешә идек. Бервакыт безнең үбешкәнне аның әнисе күргән. Шуның өчен мәхәббәтемнең әтисе мине кычыткан белән сыйлады. Мәңгелек сабак булды. Ун яшьтә чия агачлары арасында райком секретареның тугыз яшьлек кызын үбәргә ярамый икән.

Гөлчирә. Син ул чакта ук азгын булган инде.

Рәхмәтулла. Хатын-кызлар ни өчендер азгын ирләргә кызыгалар.

Нина. Неправда. Кызыкмыйлар, алданалар. Бабники умеют находить ключ к женскому сердцу.

Гөлчирә. Карале, Рәхмәти. Син сөйләмәдең бит әле ни булганын баш бухгалтер кабинетында. Син әйдә шыттырма, сөйлә.

Рәхмәтулла. Без мәхәббәт аңлаштык. Мин аңа багышланган шигыремне укыдым.

Рузалия. Шигырь?! Әллә сез шагыйрь дәме, Рәхмәтулла абый?

Гөлчирә. Аның булдырмаган эше юк. Укы безгә дә шигыреңне, Рәхмәти.

Рәхмәтулла.

Гүзәлләрдән гүзәл баш бухгалтер!
Ничәнче размер икән сезнең бюстгальтер?

Дәррәү көлешәләр.

Гөлчирә. Нәрсә ди Мөбәрәковна?

Рәхмәтулла. Гөлчирәнекеннән зуррак, ди.

Гөлчирә. Үтерәм мин сине, оятсыз.

Нина. Бюстгальтерның татарчасы ничек?

Гөлчирә. Юк аның татарчасы. Элек татар хатыннары аны кимәгән.

Фаягөл. Ә күкрәкчә нәрсә?

Гөлчирә. Ул бюстгальтер түгел.

Рәхмәтулла. Бар аның татарчасы. «Имидж» дип

атала ул. Шуның зурлыгына карап хатын-кызның кемлеге бәяләнә.

Гөлчирә *(Рәхмәтулла янына атылып килеп).* Нишләтим мин моны, әйтегез. Чәчен йолкыр идем, чәче дә юк бит, әй. Карагыз әле, Рәхмәтулла абыйның башы глобуска охшаган икән. Менә Африка, менә Татарстан. *(Рәхмәтулланың борынын кысып.)* Менә Кавказ тавы.

Нина. Ульяновский область кайда?

Гөлчирә. Әйләндер, теге яктадыр.

Рәхмәтулланың башын боргалыйлар.

Рәхмәтулла. Үтерәсез. Әйтәм Нурзидә Мөбәрәковнага.

Гөлчирә. Әле син әләкче дәмени? Фаягөл, бикләишекне, күрмәгәнен күрсәтәбез.

Рәхмәтулла. Рузалия кызым! Үтерәләр болар, коткар.

Рузалия. Тимәгез Рәхмәтулла абыйга.

Рәхмәтулла. Тисеннәр, тик үтермәсеннәр генә.

Гөлчирә. Нина, бир косынкаңны, кулларын бәйлибез.

Косынка белән Рәхмәтулланың кулларын артка каерып бәйлиләр. Рәхмәтулла, әлбәттә, карышмый.

Фаягөл. Булды, нишләтәбез?

Гөлчирә. Печәбез!

Нина. Кастрировать, что ли? Что ты, Гуля! Такого старого бугая. Бирегез аны миңа.

Гөлчирә. Бирәүгә дә булмасын. *(Рәхмәтуллага.)* Бас әле монда. Тәк. Башта ул безнең сорауларга җавап биреп карасын. Сорауларыгызны әзерләгез. Җавап бирә алмаса, җәзасын үзегез билгеләрсез. Тәк, иптәш Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, беренче сорау. Син, җанбиздергеч адәми зат, ни өчен дип кылчыклы арпа башагы кебек кашларың астындагы ике пыяла кисәген күз дип атыйсың?

Рәхмәтулла. Ә син, сөйкемлеләрдән сөйкемле, аккоштан да сылурак бөек зат, ни өчен энҗе сыман тешләреңне каплап торучы ике карбыз телемен иреннәр дип атыйсың?

Фаягөл. Син, дию пәриеннән дә кошбәтсез адәми зат, ни өчен тау куышыдай авызың эчендә боргаланучы җыланны тел дип атыйсың?

Р ә х м ә т у л л а. Ә менә син, алма кисәгем, урман күле сыман серле күзләреңдә урын алган камышларны ни өчен керфекләр дип атыйсың?

Г ө л ч и р ә. Нина, синең чират.

Н и н а. Я потом…

Г ө л ч и р ә. Рузалия, кил, бир соравыңны.

Р у з а л и я. Мин белмим, Гөлчирә апа. Минем өчен син әйт.

Г ө л ч и р ә. Фаягөл, әйт Рузалия өчен.

Ф а я г ө л. Әйт әле, килбәтсезем, син нигә мунча морҗасыдай муеның өстендәге кабакны баш дип йөртәсең?

Р ә х м ә т у л л а. Ә син, фәрештәләр фәрештәсе, нигә таң алсулыгы кунган битләрең уртасындагы фәрештә үпкән сөйдергеч урыннарны чокыр дип йөртәсең? Нигә син, алтын кисәгем, күл өстенә иелгән бөдрә талны иркәләүче йөгерек дулкыннарны чәч дип йөртәсең?

Г ө л ч и р ә. Кара син мутны, кызларга икешәрне әйтә, Хәдичә синең соравың бармы?

Х ә д и ч ә. Юк.

Г ө л ч и р ә. Нина, давай.

Н и н а. Не могу я плохое сказать про Рахматулла Хурматулловича.

Г ө л ч и р ә. Можешь. Смотри, какой он безобразный. Давай…

Н и н а. Ну, если давай… Рахматулла Хурматуллович, почему… Почему вы такой… Но не могу я… Ну почему вы такой?

Р ә х м ә т у л л а. Потому что ты такая милая.

Н и н а. Ну разве можно такого симпатичного… Лучше я поцелую его. *(Рәхмәтулланы ике битеннән дә үбеп ала.)*

Г ө л ч и р ә. Ай-яй-яй. Монысы рөхсәт ителми.

Үзе Нина шикелле үбеп ала. Аңа Фаягөл кушыла.

Ф а я г ө л. Мин дә! *(Рәхмәтулланың битеннән үбә.)*

Шулвакыт ишек шакыйлар.

Бетте баш.

Г ө л ч и р ә *(шыпырт кына)*. Ачмагыз!

Н у р з и д ә т а в ы ш ы: «Ачыгыз!»

Хатыннар тиз генә урыннарына утыралар. Нина Рәхмәтулланың кулларын чишәргә өлгерә. Рәхмәтулла барып ишекне ача.

Н у р з и д ә. Нигә бикләнеп утырасыз?

Н и н а. Чтоб не мешали работать, Нурзида Мубараковна.

Н у р з и д ә. Ой ли. Такой шум стоял.

Г ө л ч и р ә. Рузалия бюстгальтер алган да, шуны үлчәп карадык.

Н у р з и д ә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, сез дәме? *(Рәхмәтулланың иннектән кызарып чуарланган йөзен күреп.)* Ни булды сезгә?

Г ө л ч и р ә. Оялудан шулай кызарган ул. Бюстгальтер күргәне юк икән.

Н у р з и д ә. Гөлчирә Нәҗиповна, һәрнәрсәнең чиге була.

Г ө л ч и р ә. Ә мин чик белмим.

Н у р з и д ә. Кызганыч.

Г ө л ч и р ә. Нурзидә Мөбәрәковна!..

Р ә х м ә т у л л а. Гөлчирә...

Г ө л ч и р ә. Гафу итегез.

Н у р з и д ә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! Иртәгә бүтән бүлмәгә күчәсез. *(Чыгып китә.)*

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Аерым бүлмәдә Р ә х м ә т у л л а эшләп утыра. Шакымый-нитми генә Г ө л ч и р ә килеп керә. Кергәч, бүлмәне карап-тикшереп чыга.

Г ө л ч и р ә. Ай-яй, оялаган берәүләр тыныч урынга. *(Җырлап.)*

Уңга каерылгач та,
Әй, дускаем, рәхәт яшә,
Бездән аерылгач та.

Бездән аерылгач рәхәтме?

Рәхмәтулла. Мин бит үзем аерылмадым, аердылар.

Гөлчирә. Хатын-кызга буйсынып яшәгән иргә ни әйтим? Әйтергә иде! Юк, Нурзидә Мөбәрәковна, хатыннарымнан аерылып башка чыкмыйм, диярgә иде. Җебегән. Беләм инде, миннән качтың. Барыбер үзеңне генә калдырмыйм. Минутына ун керәчәкмен. Аңладыңмы?

Рәхмәтулла. Аңладым.

Гөлчирә. Аңласаң шул. *(Кулын сузып.)* Нихәл? *(Рәхмәтулла күрешергә кулын сузгач.)* Ах, оятсыз! Бер тәүлек буе күрешмәдек, ә ул күрешергә кулын суза. Тор урыныңнан, җирбит. *(Урындыгыннан торып баскан Рәхмәтулланы кочаклап алып.)* Утыр. *(Рәхмәтулла каршысына утырып.)* Нихәл соң?

Рәхмәтулла. Үзең нихәл?

Гөлчирә. Начар.

Рәхмәтулла. Ни булды?

Гөлчирә. Син юк. Килеп кердем эшкә – син юк.

Рәхмәтулла. Менә ич мин.

Гөлчирә. Мине мондагысы канәгатьләндерми.

Рәхмәтулла. Нишләп?

Гөлчирә. Мондагысын кочаклап булмый.

Рәхмәтулла. Кочакладың ич.

Гөлчирә. Монысы аның формально гына кочаклау. Кызлар карап торганда, шаярган булып чынлап кочаклый идем. Монда оялам.

Рәхмәтулла. Кемнән?

Гөлчирә. Үземнән.

Рәхмәтулла. Кызык икән.

Гөлчирә. Кызык түгел. Чөнки мин сине чынлап яратам.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Гөлчирә. Ахмак сорау биреп үзеңнән биздермә. Син дә бит мине яратасың. Мин ни өчен дип сорамыйм.

Рәхмәтулла. Минем яратканымны каян беләсең?

Гөлчирә. Белмим, сизәм. Мин бит тиле-миле. Андыйларны ирләр ярата. Фәритем дә, сине тиле булганың өчен яратам, дия иде. Күзгә карап торма, оялтасың. Әйт, яратырлык хатынмы мин? Ник дәшмисең?

Рәхмәтулла. Яратмаслык түгел инде.

Гөлчирә. Җәбриләр кебек алдын артка куеп сөйләшмә. Өзеп әйт, яратырлыкмы?

Р ә х м ә т у л л а. Яратырлык. Мин яратырлыкны гына яратам.

Г ө л ч и р ә. Әйтмә «яратам» дип. Кызыгы бетә. Ратканыңны мин генә сизим! Минем чибәрлегем әле бетмәгән. Чибәр хатынга «яратам» дип еш әйтәләр. Чибәр хатынны ахмак дип уйлыйлар. «Яратам» диюгә яннарына ятар дип өметләнәләр. Син өметләнмә, яныма яткызмаячакмын. Өзелеп яратсам да, яткызмаячакмын. Чөнки ятканымның берсе ятты инде. Ятты да мәңгелеккә китеп барды. Синең китүеңне теләмим. Сине яшәтәсем килә. Син, бәлки, минем соңгы мәхәббәтемдер. Карап торма алай. Нигә алай караганыңны беләм мин. Их, шуны бер кочаклап үбәргә дип карап торасың. Кочаклаттырам, әмма үптермим. Үптерсәм, дәртем кузгалыр дип куркам. Үземне тыеп кала алмамдыр шикелле. Елмайма. Нигә елмайганыңны беләм. Кая инде миндәй картка дәрт кузгатырлык куәт дип уйлыйсың. Илле тугыз яшьтә бит инде дисең, пенсия яшенә җитәм дип уйлыйсың. Мин беләм, синдәге дәртнең әле чик-чамасы юк. Син дәртеңне минем өчен саклап тоткансың. Яныма яткыза алмаганга кызганам да мин сине. Нишлим, яраткан ирем бар иде шул. Аерылып, ташлап китсә дә авыр булмас иде, бакый дөньяга китеп барды. Яшәүнең кызыгы беткән иде, син очрадың. Кил, чынлап бер кочаклыйм әле үзеңне кеше юк чакта. Утырып кына тор, үзем кочаклыйм. *(Рәхмәтулланы кысып кочаклый да ишеккә таба атлый.)* Кара аны, бүтәннәргә кочаклаттырма, көнләшә торган әшәке гадәтем бар. *(Чыгып китә.)*

Рәхмәтулла эшкә тотынгач кына Ф а я г ө л ишекне ача.

Ф а я г ө л. Керергә ярыйдыр бит, Рәхмәтулла абзый.

Р ә х м ә т у л л а *(урыныннан торып, Фаягөлне каршылый)*. Кер әйдә, кер. Әйдә, уз, утыр.

Ф а я г ө л. Узып тормыйм. Эшкә килдем, нәрсәдер җитми. Нәрсә җитми дисәм, сез юк икән. Шушында күчерделәрмени инде сезне? Бергә утырсак ни була иде инде? Сезнең белән бергә утырганда рәхәт иде. Күрше өстәлдә сез барын тою рәхәт иде. Гөлчирә кереп өлгергәндер инде?

Р ә х м ә т у л л а. Кереп болганып чыгып китте.

Ф а я г ө л. Сезгә гашыйк ул. Шуны яшерер өчен кыланган була. Мин дә яратам сезне, Рәхмәтулла абый. Беләсезме, ни өчен яратам сезне?

Р ә х м ә т у л л а. Белмим инде, Фаягөл. Шундый чибәр хатын яратырлык ниием бардыр? Бигрәкләр дә чибәр бит син. Тулып пешкән алма кебек.

Ф а я г ө л. Шундый сүзләрегез өчен яратам бугай мин сезне, Рәхмәтулла абый. Беләм инде, минем күңелемне күрер өчен генә әйтәсез чибәр дип. Сез — иң олы җанлы, җылы күңелле кеше, Рәхмәтулла абый. Шуңа күрә дә сезнең янда миңа җылы.

Р ә х м ә т у л л а. Юк, син чыннан да чибәр, Фаягөл. Ходай Тәгалә дөньяга ямьсез хатын-кызны яратмый. Хатын-кызны Ходай карап сокланыр өчен ярата. Син, беләсең килсә, арагызда иң чибәре. Кемдер синең чибәрлегеңне күрә белми икән, ул — ахмак, ул — утын агачы.

Ф а я г ө л. Беләм инде, Рәхмәтулла абзый, юатыр өчен генә әйтәсең. Шулай да рәхмәт сезгә. Нишләтәсез, хатын-кызның холкындадыр инде, алдаганны өнәп бетермәсәк тә, алданасы килә. Кайсыдыр шагыйрь шулай әйткән бугай.

Р ә х м ә т у л л а. Алдамыйм, Фаягөл бәгырькәем. Кил әле, бас әле каршыма. Хәзер мин сиңа чибәрлегеңне дәлилләп исбатлыйм. Әйтик, менә синең күзләрең...

Ф а я г ө л. Кирәкми, Рәхмәтулла абый. Миңа хәзер инде барыбер — чибәр булдым ни, булмадым ни. Кияүгә чыгасы унсигез яшьлек кыз түгел. Кырык тула.

Р ә х м ә т у л л а. Алай димә, Фаягөл. Кырык яшь ул — хатын-кызның чәчәк аткан вакыты.

Ф а я г ө л. Җимеше булмагач, чәчәк атудан ни мәгънә, Рәхмәтулла абзый. Бер сүз әйтсәм ачуланмыйсызмы?

Р ә х м ә т у л л а. Нишләп ачуланыйм ди, Фаягөл.

Ф а я г ө л. Мин ир белән егерме ел яшим. Балабыз юк, беләсеңме шуны?

Р ә х м ә т у л л а *(паузадан соң)*. Беләм.

Ф а я г ө л *(аптырап)*. Каян беләсез? Әйткәнем юк. Гөлчирә әйттеме?

Р ә х м ә т у л л а. Юк.

Ф а я г ө л. Шулай да... каян белдегез? Минем ул турыда берәүгә дә әйткәнем юк. Киресенчә, ике балам бар, дип сөйләп йөрим.

Р ә х м ә т у л л а. Хатын-кыз алдашса да алдаша белми. Хатын-кызның дөрес сүзе телендә түгел, йөзендә, Фаягөл.

Фаягөл. Сез сихерчедер, Рәхмәтулла абзый. Ярый, чишелә башлаганмын икән, чишелеп бетим инде. Чишеләсем килә, Рәхмәтулла абзый. Шундый да чишеләсем килә. Күңелемдә җыелган бөтен серләремне кемгәдер сөйлисем килә. Мине тыңлый алырлык кеше юк дөньяда. Сез очрадыгыз. Ничә ел инде сезгә сөйлим-сөйлим дим, һич кенә дә җае чыкмый.

Рәхмәтулла. Мин сине сөйләмәсәң дә аңлыйм, Фаягөл сеңлем.

Фаягөл. Аңлаганыгызны беләм. Ләкин миңа бушанырга кирәк. Рөхсәт итегез. Яратып чыктым мин кияүгә. Ул нигә өйләнгәндер, белмим. «Яратам» дигән сүзен хәтерләмим. Ни өчен яратканмындыр? Эчми, тартмый, сүгенә белми, күп сөйләшми, шул ягы ошагандыр инде. Мин гомерем буе исерекләрдән җирәнеп яшәдем. Бу шундый тәртипле. Ничек яратмыйсың. Тик менә, үзем яратсам да, яраттыра алмадым. Яратып түгел, өйләнергә кирәк булганга гына өйләнгән булып чыкты. Балабыз булмады, дидем. Булмады шул. Булган булса, туң җаны, бәлки, эрегән булыр иде. Бала булмаганга мин өзгәләндем, аның исе дә китмәде шикелле. Унбиш ел гомер шулай үтте дә китте. Бервакытны әйтә бу: «Синең бала тапмавың әйбәт, — ди, — югыйсә үзең кебек ямьсез бала табып бәхетсез итәр идең», — ди. Тыныч кына әйтә, елмаеп әйтә. Ышанасызмы, Рәхмәтулла абзый? Йөрәгемә боз булып төште шул сүзләр. Бөтен яратуларым нәфрәткә әйләнде. Янына яту түгел, янынннан үтеп китәсем дә килми. Шул килеш ничә ел яшибез бит, Рәхмәтулла абый, җанкисәгем. Кайвакытларда башымны элмәккә тыгарлык булам. Яшәү түгел бит инде бу, Рәхмәтулла абый. *(Рәхмәтулланың күкрәгенә башын куеп елый.)*

Рәхмәтулла. Тулган күңелең бушансын. Нишлим соң инде, җыла... Булдымы инде? Инде хәзер күз яшьләреңне сөртик... Менә шулай. Кара син бу күзләргә, алар бит көләр өчен генә яратылган.

Фаягөл. Бирегез берәр киңәш миңа, Рәхмәтулла абзый. Нишлим?

Рәхмәтулла. Нинди киңәш бирим инде сиңа, бәгырькәем? Киңәш бирү җиңел түгел бит.

Фаягөл. Ташламагыз мине, Рәхмәтулла абый. Гафу итегез мине.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Фаягөл. Менә бит... Әллә ниләр сөйләдем. Җылаганымны кешегә әйтмәгез инде, Рәхмәтулла абый. Сез шундый итеп карап торасыз миңа, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Ничек итеп?

Фаягөл. Сокланып.

Рәхмәтулла. Сокланырлык бит.

Фаягөл. Рәхмәт сезгә. Мин кызганып карауларыннан куркам, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Кызганып карарга ярамый кешегә. Ул аны түбәнсетә.

Фаягөл. Мин бит матур җырлый идем яшь чакта. Үз туемда җырлаган җырымны җырлыйммы? Тик ачуланмагыз, ярыймы, Рәхмәтулла абый? *(Җырлый.)* Туйда җырлар өчен нигә шул җырны сайладым икән, Рәхмәтулла абый? Ярый, чыгыйм инде, Рәхмәтулла абый. Гаеп итмәгез, зинһар. Ташламагыз мине. *(Чыгып китә.)*

Гөлчирә керә.

Гөлчирә. Фаягөл нигә кергән?

Рәхмәтулла. Сагындым, ди.

Гөлчирә. Аның сагынырга хакы юк. Чөнки аның ире бар.

Рәхмәтулла. Алай димә инде, Гөлчирә.

Гөлчирә. Нәрсә, аны яклыйсыңмыни?

Рәхмәтулла. Якламыйм да.

Гөлчирә. Якламагач, нигә алай сөйләнәсең?

Рәхмәтулла. Ничә ел бергә утырдык, бергә эшләдек. Бергә эшлибез.

Гөлчирә. Синең бик әйбәт һәм дә бик начар гадәтең бар — син бөтен хатын-кызны да яратасың.

Рәхмәтулла. Нишлим соң инде, барыгыз да яратырлык бит.

Гөлчирә. Ә мин?

Рәхмәтулла. Син син бит инде ул.

Гөлчирә. Сөйләп тора Фаягөл: «Рәхмәтулла абзыйның хатынына рәхәттер Рәхмәтулла абзый белән яшәве», — ди. Беренчедән, нигә ул сиңа «абзый» ди. Нинди абзый син? «Абый» дисә ярамыймы? Икенчедән, ни эше бар аның синең хатыныңда. Миңа булды ни синең хатының, булмады ни. Миңа син булгач җиткән. Мин аның өлешенә керергә җыенмыйм, мин бары тик яратам гына. Мин кочаклаганнан гына Рәхмәтулла ха-

тынының иренә мөгез чыкмас. Рәхмәтулланың хатынына Рәхмәтулла — кочаклап ятар өчен, миңа — яратыр өчен генә. Нигә шулай карап торасың?

Рәхмәтулла. Әллә нинди син. Көнгә әллә ничә төрлегә керәсең.

Гөлчирә. Кермим, үзем шундый мин. Мине Ходай шундый итеп яраткан. Шуңа күрә син мине яратасың. Фәрит тә мине шуның өчен ярата иде. Ләкин мин мәхәббәт мәсьәләсендә генә үзгәрмим. Яратам икән, мәңгелеккә яратам. Фәритне мәңгелеккә яраттым. Аны син алыштырдың, сине дә мәңге яратачакмын. Ләкин Фәрит хисабына түгел. Синең минем җанымда үз урының бар. Мин күп сөйлим, әйеме?

Рәхмәтулла. Әйе.

Гөлчирә *(рәхәтләнеп көлеп)*. Менә шуның өчен яратам да мин сине. Син минем җанымны аңлыйсың. Мин күзәтеп торам бит, син хатын-кызның үзләре дә белмәгән серләрен беләсең. Син кеше кыяфәтендәге Хозыр-Ильяс бит, бәгырькәем. Шуңа күрә бөтен бәхетсез хатыннар сиңа елышалар. Тыңлавы рәхәтме мине?

Рәхмәтулла. Рәхәт. Сиңа карап торуы да җан рәхәте. Яраттыра торган сихерең, сөйкемле сөягең бар синең. Мин синең биегәнеңне карап торырга яратам. Биегәндә син җирдә яшәгәнне дә онытасың шикелле. Дөньяда өлкәнәю килешми торган кешеләр була. Син шуларның берсе, Гөлчирәҗан.

Гөлчирә. «Шуларның берсе» димә, «бердәнбере» диген.

Рәхмәтулла. Бердәнбере.

Гөлчирә. Кил, кочакла шуның өчен. Тик үбәргә үрелмә, ярыймы? *(Рәхмәтулланы кочаклап.)* Әй бу Фаягөлне. Хатыны дигән була, хатынының монда ни катнашы бар? *(Рәхмәтулланы этеп җибәреп.)* Утыр, эшлә. Эшләгәндә мине уйлама, саташуың бар. Сау бул! *(Бөтерелеп бии-бии, чыгып китә.)*

Рәхмәтулла эш өстәле артына утырырга өлгерми, ишектә Хәдичә күренә.

Хәдичә. Мөмкинме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Сөйләшәсем бар, дигән идегез.

Рәхмәтулла. Кер әйдә, Хәдичә, нигә рөхсәт сорап торасың? Уз, утыр.

Х ә д и ч ә *(полиэтилен пакеттан тастымалга уралган тәлинкә ала. Тастымалны сүтеп, тәлинкәне өстәлгә куя.)* Суынып ук өлгермәгәндер әле...

Р ә х м ә т у л л а. Син мине азындырып бетерәсең, Хәдичә. Мин инде өйдә иртәнге ашны ашамый башладым. Хәдичә алып килер әле дим.

Х ә д и ч ә. Сез бит тәмле итеп ашый беләсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Күп итеп пешерергә яратам мин. Минем берүземә күпме кирәк?! Әле дә ярый сез бар. Ашагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! *(Рәхмәтулла ашаганда, күзләрен дә алмый Рәхмәтуллага карап тора. Аннан торып ишеккә юнәлә.)*

Р ә х м ә т у л л а. Туктале, Хәдичә. Нишләп әле алай бик тиз генә.

Х ә д и ч ә. Чыгам...

Р ә х м ә т у л л а. Утыр инде бераз. Синең белән утырып сөйләшкән дә юк.

Х ә д и ч ә. Нәрсә турында сөйләшәсең инде?

Р ә х м ә т у л л а. Тормышларың ничек?

Х ә д и ч ә. Тормышым юк минем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Р ә х м ә т у л л а. «Хөрмәтуллович»ын әйтеп торма, дидем бит инде.

Х ә д и ч ә. Мин бит Гөлчирә түгел, сезнең яшьтәге кешегә Рәхмәти дип әйтә алмыйм. Килешми.

Р ә х м ә т у л л а. Гөлчирәгә килешәме?

Х ә д и ч ә. Аңа да килешми. Сез бит бала-чага түгел. Ул да бала-чага түгел.

Р ә х м ә т у л л а. Син һәрвакыт җитди, Хәдичә. Дөньяга бераз көлеп карарга кирәк.

Х ә д и ч ә. Көлеп карый алмыйм мин, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Яшәве кызык түгел миңа. Яшисем килми генә яшим. Кайвакытларда үкереп-үкереп җылыйсым килә. Юатучы булмаганга җыламый түзәм. Кырык яшь бит инде миңа. Һаман бер ялгызым.

Р ә х м ә т у л л а. Шулайдыр инде. Ялгызлык бәхет түгел. Нишләп соң болай? Чибәр дә үзең. Арагызда иң чибәре син. Эшкә уңган. Пешергән ризыкларың ашап туймаслык.

Х ә д и ч ә. Шулар харап итте дә бугай инде. Сайландым шул. Күңелем ятардае очрамады. Очраганда инде соң иде.

Р ә х м ә т у л л а. Соң түгел, Хәдичә. Яратырга беркайчан да соң түгел.

Х ә д и ч ә. Соң, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Аннан инде минем яшьтә ярату, мәхәббәт дип сөйләнү дә килешми.

Р ә х м ә т у л л а. Очрады, дидең бит.

Х ә д и ч ә. Очрады. Ләкин ул ярату түгелдер, хөрмәт итү генәдер.

Р ә х м ә т у л л а. Хөрмәт итмичә яратып булмыйдыр, Хәдичә.

Х ә д и ч ә. Кем белә инде анысын. Сезнең яшисегез килмәгән чагыгыз булгалыймы, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Карап торсаң, сезнең бәхетегез тулып ташкан кебек. Уен-көлке, мәзәк. Бер кайгыгыз юк кебек.

Р ә х м ә т у л л а. Мин дә адәм баласы бит, Хәдичәкәй. Ләкин яшәргә кирәк. Ходай биргән гомер бит. Бүләк итеп биргән. Мә, яшә, бу дөньяның да рәхәтен күр, дигән.

Х ә д и ч ә. Авыр бит, Рәхмәтулла абый.

Р ә х м ә т у л л а. Авыр, билгеле. Сиңа гына авырмы? Авырайтсаң, ашый торган кашыгың да авырая. Сөйләш син кешеләр белән. Син гел үз-үзеңә йомылып утырасың. Гөлчирәгә җиңелме? Нинага, Фаягөлгә җиңелме? Тиле булганга көләләрме алар? Җилбәзәк булганга шаяралармы? Синең яшен яшьнәгәнен, күк күкрәгәнен күргәнең бармы?

Х ә д и ч ә. Ничек инде булмасын?

Р ә х м ә т у л л а. Ни өчен яшен яшьни? Ни өчен күк күкри? Алар күккә кара болытлар җыелгач яшьниләр, күкриләр. Кара болытлар сыеша алмагач, яшен яшьни, күк күкри дә коеп яңгыр ява башлый. Яңгыр ул — болытларның күз яше. Ә күк күкрәү — табигатьнең кычкырып көлүе. Табигать кычкырып көлә дә, болытлар яңгыр булып яугач, дөнья бушанып кала. Әгәр дә ул бушанмаса, дөнья җыелган кайгысыннан шартлар иде. Дөрес сөйлимме?

Х ә д и ч ә. Сез һәрвакыт дөресен сөйлисез. Ләкин сезнең бөтен сүзләрегез дә әкият. Тормыш әкият түгел.

Р ә х м ә т у л л а. Әкият, Хәдичә җанкисәгем, әкият. Әйт әле менә, нигә дип син миңа иң тәмле ризыклар пешереп киләсең? Нигә син минем төшеп калган кулъяулыгымны табып юып алып килдең? Нигә бүген яныма

керден? Үзем әйтимме? Яшисем килми, диден. Юк, Хәдичә бәгырькәем, яшисең килгәнгә кердең яныма. Чөнки мин – әкият. Мин әкияттәге маймыл. Мин әкияттәге Таз малай. Карале миңа. *(Төрле мимикалар ясап кылана. Бака булып сайрый, әтәч булып кычкыра, үгез булып мөгри.)* Йә, ничек? Нигә елмаясың? Кызык бит, әйеме? Көлке бит. Алтмыш яшьлек карт ничек тилерә.

Хәдичә. Сезгә алтмыш түгел әле. Илле тугыз яшь тә ике ай гына.

Рәхмәтулла. И-и-и, сабый гына икәнмен әле. Алайса, мин сиңа менә дигән кияү егете. Эзләгәнемне таптым дигәнең әллә минме?

Хәдичә. Шаяртмагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Әйе, сез.

Рәхмәтулла. Пәрәмәч... Алайса, гафу ит шаярткаңым өчен.

Хәдичә. Соңгарак калып очрадыгыз шул. Ләкин мин барыбер бәхетле. Сезнең бүлмәгә күчеп утырсам, сез каршы түгелме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Бер бүлмәдә утырсак, миңа артыгы кирәкми...

Гөлчирә кереп карап тора.

Гөлчирә. Бәтәч... Нишләп утырасыз?

Хәдичә чыгып китә.

Кара син боларны, мыштым гына. Нигә ташып ашата дисәм, кулга ияләштерә икән.

Рәхмәтулла *(кискен итеп)*. Узынма, Гөлчирә.

Гөлчирә *(каушап калган)*. Син усал да була беләсеңмени, Рәхмәтулла абый?

Рәхмәтулла. Беләм.

Гөлчирә. Гафу ит инде, алайса. Йомыш белән генә кергән идем. *(Чыгарга борыла.)*

Рәхмәтулла. Йомышыңны әйт.

Гөлчирә. Ярый инде. Фәритем дә, баудан ычкынып китсәм, узынма дия иде. Зинһар, гафу ит, Рәхмәтулла абый. Мин чыннан да йомыш белән кергән идем. Рузалия җылый.

Рәхмәтулла. Ни булган?

Гөлчирә. Ни булсын, йөргән егете шылтыратмый.

Рәхмәтулла. Ә минем ни катнашым бар?

Гөлчирә. Кара бу оятсызны, ни ди. Аңа, җылый, дип

әйтеп торалар. Ул, ни катнашым бар, ди. Син бит аның әтисе урынына калган кеше. Ул бит синең һәр сүзеңне йотып утыра. Аның тома ятим үскәнен белмисеңмени?

Рәхмәтулла. Белмим.

Гөлчирә. Белмәсәң бел. Детдом баласы ул. Әрәм булмаганына рәхмәт әйт. Эшли, тәртипле.

Рәхмәтулла. Егете нигә шылтыратмый?

Гөлчирә. Каян белим? Белеп буламыни сезне. Яраттырасыз да качасыз.

Рәхмәтулла. Кайчаннан бирле шылтыратмый?

Гөлчирә. Ике көн, ди, инде.

Рәхмәтулла. Ике көн күп түгел, шылтыратыр.

Гөлчирә. Кара моны... Ике көн синең белән миңа күп түгел. Аңа бит унтугыз гына яшь. Аңлыйсыңмы — унтугыз.

Рәхмәтулла. Миңа нишләргә кушасың?

Гөлчирә. Менә ул егетнең телефон номеры. Шылтырат.

Рәхмәтулла. Ни дип?

Гөлчирә. Нәрсә, мин өйрәтер көнгә калдыңмыни?

Рәхмәтулла. Нигә үзең шылтыратмыйсың?

Гөлчирә. Ярамый. Мин хатын-кыз. Хатын-кыз чиратны башлый. Черелдәгән хатын-кызны кем тыңласын. Шылтырат, Рәхмәти. Рузалия, шылтыраткач, «номер не отвечает» дигән язу чыга, ди. Юри алмый инде. Кесә телефоныңны бир әле. *(Рәхмәтулла кесәсеннән телефонын алып номерлар җыя.)* Мә, Рәхмәти, мә, җаным. Әйбәт бит син. *(Кесә телефонын Рәхмәтулланың колагына куя.)*

Рәхмәтулла. Исеме ничек егетнең?

Гөлчирә. Әй, Алла, сорарга оныткanмын. Хәзер.

Атылып чыгып китә. Ул арада Рузалиянең йөргән егете телефонны ала.

Рәхмәтулла. Алло! Исәнмесез! Рәхмәтулла абыегыз бу. Хәзер белерсез. Ә сез Рузалия исемле кызны беләсезме?.. Безнең бухгалтериядә эшли. Искиткеч акыллы һәм искиткеч чибәр кыз. Арада иң чибәре. Беләсезме андый кызны?

Гөлчирә *(атылып керә)*. Тимур. Тимур аның исеме.

Рәхмәтулла. Тимур бит әле сезнең исемегез? Бик матур исем. Рузалия әйтмичә, кем әйтсен. Мин аның әти-

се урынына калган кеше. Ул сезнең турыда гына сөйли. Сезне очратуын зур бәхет дип саный. Ул сезнең бәхетегез, Тимур улым. Кулдан ычкындырмагыз. Андыйлар хәзер еш очрамый. Нигә шылтыратаммы? Нигә сез аңа шылтыратмыйсыз, шуңа шылтыратам. Рузалия кушмады, үзем шылтыратам. Телефон номерын ул бирмәде, үзем сорап алдым. Энекәш, сез көлмәгез әле. Көлмә әле син. Кеше җылаганда көлү килешми. Рузалияң җылый. Кызларның күз яшеннән куркырга кирәк, Тимур энекәш. Шылтырат син аңа. Сүзгә килгән булсагыз, очрашып аңлашыгыз. Хатын-кыз кәпризле була ул. Чөнки аларның күңелләре нечкә. Скрипкә кылы кебек. Көйләмәсәң, әче тавыш чыгара. Аңладыңмы? Көлмә син. Минем яшькә җиткәч көлмәссең.

Г ө л ч и р ә *(Рәхмәтулланы кочаклап алып)*. Менә ничек яратмыйсың инде сине. Әле дә син бар әле дөньяда. Килешсәләр ярар иде инде. Бәхетле булсыннар иде. Минем кебек бәхетле булсыннар иде. Сине ратканымны кызым да белә. Элек мин аңа әтисе турында гына сөйли идем. Әтисен хәтерләми бит ул — яшь ярымлык кына иде. Хәзер синең исем дә ычкынгалый икән. Бервакыт әйтә, Рәхмәтуллаң ни хәлләрдә яши, ди. Егылыплар китә яздым. Синең исемгә ияләште инде. Ратканымны сизә, кунакка чакырыйк, ди. Чакыра алмыйм шул. Чыгарып җибәрмәм дип куркам. Кызыбызны нишләтербез икән, Рәхмәтулла?

Р ә х м ә т у л л а. Ничек «кызыбызны»?

Г ө л ч и р ә. Хәзер синең кыз да инде ул. Мәктәпне тәмамлый, кая укырга кертербез икән... Нигә алай карап торасың, Рәхмәтулла, әллә ярамаган сүз әйттемме? Узынма дип әйтергә җыенасыңмы? Ник дәшмисең, Рәхмәтулла? Ни уйлыйсың?

Р ә х м ә т у л л а. Юк-юк, сөйлә, сөйлә...

Г ө л ч и р ә. Юк инде, сөйләмим, ошатмадың. Сау бул. Рузалия өчен рәхмәт.

Р у з а л и я *(атылып кереп, Рәхмәтуллага ташлана, кочаклый)*. Рәхмәтулла абый! Рәхмәтулла абый...

Г ө л ч и р ә. Кысыбрак кочакла. Ике яңагыннан үп. Булды. Инде мине кочакла.

Р у з а л и я. Гөлчирә апа!..

Г ө л ч и р ә. Менә шундый инде без, Рәхмәтулла абый. Ә син безне әллә кем дип уйлыйсың. Күктәге йолдыз!

Тулган ай! Фәлән-төгән, өч тиенлек бер дурак өчен акылдан шашучылар димисең.

Р у з а л и я. Өч тиенлек түгел, Гөлчирә апа. Дурак та түгел. Рәхмәтулла абый кебек әйбәт егет ул.

Г ө л ч и р ә. Нәрсә, Рәхмәтулла абыең шулай бик әйбәтмени?

Р у з а л и я. Искиткеч! Чудо!

Г ө л ч и р ә. Нәрсәсе чудо инде?

Р у з а л и я. Мин каян белим инде? Кызык бит аның белән, күңелле.

Г ө л ч и р ә. Нәрсәсе күңелле инде?

Р у з а л и я. Ну, Гөлчирә апа. Сез беләсез бит инде.

Г ө л ч и р ә. Нәрсәне беләм?

Р у з а л и я. Ну сез, Гөлчирә апа. Үзегез дә яратасыз ич инде Рәхмәтулла абыйны.

Г ө л ч и р ә. Ни өчен яратам соң мин аны?

Р у з а л и я. Ну, Гөлчирә апа.

Г ө л ч и р ә. Бар, чәй куя тор, мин хәзер чыгам. *(Рузалия чыгып киткәч.)* Рәхмәт сезгә, Рәхмәтулла абый.

Р ә х м ә т у л л а. Нишләп әле «сез» дип сөйләшә башладың?

Г ө л ч и р ә. Гаебем бар синең алда. Син миңа шулай әйткәләп тор, ярыймы, Рәхмәтулла абый. Ә миңа шундый рәхәт булды, син узынма, дип әйткәч. Ирләр сүзе җитми шул безгә, Хәдичәгә дә ирләр сүзе җитми. Күпме әйттем «сайланма» дип. Әллә кемне эзли. Син аның ризыкларын тәмле дип аша, Рәхмәтулла абый, күңеле булсын. Ир кирәк шул хатын-кызга, ир кирәк. Хәзер кочаклаттырмассың инде, әйеме?

Р ә х м ә т у л л а. Син миннән уенчык ясап бетердең. Рәхәтләнеп уйныйсың.

Г ө л ч и р ә. Уйныйм, Рәхмәтулла абый. Уйнарлык уенчык барында нигә уйнамаска. Әгәр дә бик беләсегез килсә, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, бер генә бала да яратмаган уенчыгы белән уйнамый, яраткан уенчыгы белән генә уйный. Минем сүзләрем сезләрнең баш шәрифләренә барып җиттеме?

Р ә х м ә т у л л а. Җитте.

Г ө л ч и р ә. Менә шулай. Мин булмасам, нишләпләр бетәр идең син? Әле мин уйныйм гына, чынлап тотынсам — һу-һу-һу!.. Син дә уйна, Рәхмәтулла абый, мин яраткан

уенчыгың булырга риза бит. Менә мин — синеке, теләсәң нишләт. Тездән түбән, кендектән югарысы барысы да синеке.

Р ә х м ә т у л л а. Бар, чыгып кит!

Г ө л ч и р ә. Чыгып китсәм, сагынасың бит.

Телеграм баганасы —
Олы юлга маяк ул;
«Сагынасыңмы» дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул.

*(Боргаланып чыгып китә.)*

Р ә х м ә т у л л а *(Гөлчирәнең җырын дәвам итә)*.

Телеграм баганасын
Саныйсым калган икән;
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

*(Кесәсеннән кесә телефонын алып саннар җыя.)* Исәнме, алтыным. Борчылма, бик яхшы. Укып бетердеңме әле китабыңны? Әйе, бик яхшы язучы ул. Кит инде... Яле, яле укы... Искиткеч, алтыным. Тагын яз. Китап итеп чыгарырбыз. Мин дә шагыйрь ире булып мактанып йөрермен. Сау бул, күгәрченем. Борчылма.

Г ө л ч и р ә *(ишектә күренеп)*. Бу мин түгел, курыкма. Әйдә, Нина. Менә Нинаның синең янга кирәсе килә. Оялам, ди. Үзе марҗа — үзе ирләрдән ояла. Утыр әйдә, Нина. Сөйләш туйганчы.

Н и н а. Балаболка син, Гуля. Исянмесез, Рахматулла Хурматуллович.

Р ә х м ә т у л л а. Пока живой, Ниночка.

Г ө л ч и р ә. Мин чыгам, Нина. Смотри, не трогай Рахматулла абыйны. Марҗаларга ир ышанып калдырсаң... Марҗа күрсә, татар ире акылдан шаша бит ул.

Н и н а . Потому что без матурлар. Әйеме, Рахматулла абы?

Р ә х м ә т у л л а. Әйе.

Г ө л ч и р ә. Кара, кара, монысын. Кил, башта кызыгыңны үзем күрим. *(Рәхмәтулланы кочаклап чыгып китә.)*

Н и н а. Ә мин беләм нигә Гуля кочаклый сезне. Она — вампир. Ул сездән ни... жизненный тонус высасывает. Шуңа ул такая весёлая. Ул сезгә ошыймы?

Р ә х м ә т у л л а. Ошый. Все вы мне нравитесь. Я всех вас люблю.

Н и н а. Сез со мной татарча сөйләшегез, Рахматулла Хурматуллович. Сез ошыйсыз миңа, кайчан татарча сөйләшәсез. Сез сөйлисез, все мне понятно. Язык, наверно, красив тогда, когда на нём красиво говорят. Минем ирем булды татар, аның сөйләшүе татарча меня раздражал. «Раздражал» ничек татарча.

Р ә х м ә т у л л а. Ачуны китерә иде.

Н и н а. Вот, вот, ачуны китерә. Мин уйлый идем – какой грубый язык. Сез сөйлисез, ласкает слух сезнең сүзләр. Какие-то мягкие они. Сез үзегез дә такой йомшак. Вот сез прикоснётесь руками, кулыгыз белән, әйеме, и по всему телу вот такая теплота, җылы. Вроде бы вы уже не молодой. Яшь кеше түгел бит, да? Менә вот сезнең объятие... Кочакка керәсе килә. Гуля ул такая хитрая. Сез гафу итегез мине алай сөйләгәнгә. Мне вот захотелось в любви объясниться. Юк, мин бернәрсә теләмим, сорамыйм. Сезне выгнали безнең бүлмәдән и так скучно мне стало. Откуда у вас такая положительная энергия?

Р ә х м ә т у л л а. Белмим инде, Ниночка. Сез үзегез яхшы булгангадыр ул.

Н и н а. Какой уж яхшы. Үзем беләм. Правильно я говорю – үзем беләм. Кстати, не такая уж я стерва, да, Рахматулла абы?

Р ә х м ә т у л л а. Синме, Ниночка? Син арада иң чибәре, иң яхшысы.

Н и н а. И иң бәхетсез. Самая несчастная, наверно.

Р ә х м ә т у л л а. Алай димә, Ниночка. Бәхетне аны үлчәүгә салып үлчәп булмый.

Н и н а. Как, как?..

Р ә х м ә т у л л а. Ну как сказать. Счастье невозможно положить на весы и взвесить.

Н и н а. Интересно. Может быть. Вот мин, Рахматулла абы, дүрт иргә чыктым, да? Беренче чыктым. Любила. Яраттым. Сигез ел нормально жили. Аннан начал эчәргә. Беспробудно. Вроде бы и причина да юк. Эчә дә сугыша. Кыйный. Үз баласын да кыйный. Аерылдым. Икенче чыктым – такая же картина. Өченче татарга чыктым. Вроде бы трезвее народ. Ну эчте. Хуже других может. Исереп под трамвай попал. Четвёртый раз за

еврея вышла. Ну этот же народ абсолютно трезвый. Умный, рассудительный. Ну откуда мне попался такой экземпляр. Пьяница. Мин хәзер уйлыйм, Рахматулла абы, мы всем миром дышим перегаром. Минем дүрт иремнән өч балам бар. Как аларны уберечь? И у меня хәзер такое ощущение, что мин постоянно йокладым с бочками, наполненными водкой. Гафу итегез, что мин инде болай... Зашла вот объясниться в любви и объяснилась. Сез әйтәсез, что сез старый. Вот если сез әйтәсез миңа, Ниночка, выйди за меня, дип, побежала бы.

Р ә х м ә т у л л а. Читтән караганда гына шулай ул, Ниночка.

Н и н а. Нет, Рахматулла Хурматуллович. Юк, Рахматулла абы. Кайтыгыз безгә, вернитесь. Мы уговорим эту кикимору. *(Нурзидә Мөбәрәковнаның кергәнен күреп.)* Извините. *(Чыгып китә.)*

Н у р з и д ә. Сез мавзолейда яткан кебек, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Чират торып керәләр.

Р ә х м ә т у л л а. Нишләтим инде аларны. Ничә ел бергә утырдык бит, ияләшкәннәр.

Н у р з и д ә. Ияләшү генә түгел бу. Сөйкемле сөягегез бар, күрәсең.

Р ә х м ә т у л л а. Кем белә инде анысын, Нурзидә Мөбәрәковна. Яратам бит мин аларны. Алар яратуга мохтаҗ. Эшли-эшли сезне дә яратырмын, мохтаҗ булсагыз.

Н у р з и д ә. Ләкин бит эш бүлмәсе балаган түгел. Анда ниндидер тәртип булырга тиеш.

Р ә х м ә т у л л а. Эш бүлмәсе төрмә камерасы да түгелдер инде. Монда бит җинаятьчеләр утырмый.

Н у р з и д ә. Комедия театры да түгел инде бухгалтерия.

Р ә х м ә т у л л а. Үз эшләрен эшлиләр бит алар. Мин дә калышмыйм.

Н у р з и д ә. Сез өлкән яшьтә бит инде. Алар сезне уенчык итеп уйныйлар.

Р ә х м ә т у л л а. Уйнасыннар. Сез баскетбол дигән уенны беләсезме? Мин аны яратам. Менә шул уенда уйнаучылар бар, туп бар. Уйнаучылар әллә нинди булсалар да, тупсыз уйный алмыйлар. Мин шул туп. Уйнасыннар, аннан кемгә зыян? Нигә алай карап торасыз? Бу абзый акылында микән дипме?

Н у р з и д ә. Нигә минем турыда начар уйлыйсыз? Бәлки, теге кызларыгыз кебек сокланып карап торамдыр.

Р ә х м ә т у л л а. Охшамаган. Сез кирәгеннән артык җитди, Нурзидә Мөбәрәковна. Телисезме, мин сезгә Нурзидә дип кенә дәшәм. Сез әле миннән күпкә яшь. Чибәр. Беләсезме, бездә ничә хатын-кыз эшли, арада иң чибәре сез. Нигә елмаясыз? Телисезме, мин сезгә бер мәзәк сөйлим. Ишеттем дә бүген көлә-көлә үлә яздым. Көтүдән бер сыер кайтып килә икән. Капка төбендә бер песи баласы утыра, ди. «Кит юлдан, — дигән сыер, — үзең бәләкәй генә, үзең мыек үстергән булгансың», — дия икән. «Үзеңне бел, — дигән песи баласы, — тубал хәтле ими үстереп лифчиксыз йөрисең». *(Нурзидәнең көлгәненә куанып.)* Шәп бит, әйеме?

Н у р з и д ә *(көлүдән туктап)*. Ә бит сезнең тормышыгыз мәзәк сөйләп йөри торган түгел, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Сезнең туганыгыз белән без бер йортта торабыз. Сез унбиш ел буена паралич суккан хатыныгызны тәрбиялисез.

Р ә х м ә т у л л а. Алдаша ул.

Н у р з и д ә. Алдашмый. Сез аны берәүгә дә әйтмисез.

Р ә х м ә т у л л а. Нигә сез аны миңа әйтәсез? Ул бит аны сер итеп сөйләгәндер. *(Югалып калып.)* Кемдә кемнең ни эше бар? Әллә сезнең тормыш тоташ бәхеттән торамы? Бер үтенечем сезгә. Моны миңа сөйләп бер ахмаклык эшләдегез, бүтәннәргә сөйләмәгез. Кемдә кемнең ни эше бар? Кешеләр кайгы түгел, шатлык уртаклашырга тиешләр.

Н у р з и д ә. Гафу итегез. *(Ишектә Гөлчирә башын күреп.)* Керегез, Гөлчирә Нәҗиповна.

Г ө л ч и р ә *(кереп)*. Әллә кермәмме?

Н у р з и д ә. Сау булыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Гафу итегез. *(Чыгып китә.)*

Г ө л ч и р ә. Нигә гафу үтенә ул?

Р ә х м ә т у л л а. Мине синнән аерганга.

Г ө л ч и р ә. Ха!.. Аерып карасын. Ишекне бикләп куйса, тәрәзәдән керәчәкмен. Сиңа ни булды? Сөмсерең коелган сыман.

Р ә х м ә т у л л а. Озак керми тордың бит.

Г ө л ч и р ә. Көлмә инде, чыкканым да юк. Нинага ни әйттең, очынып йөри. «Яратам» дидеңме?

Р ә х м ә т у л л а. «Үлеп яратам» дидем.

Г ө л ч и р ә. Оятсыз! Кочаклап үтерәм бит үзеңне. *(Рәхмәтулланы кочаклый.)* Җылыйсым килсә дә, җы-

ламыйм әле. Җылый белмим бит. Нигә алай икән, Рәхмәтулла абый? Ә син мине бер тапкыр җылаттың. Хәтерлисеңме, Яңа ел каршылаганда. Коллектив белән. Кал безнең янда, дидем — калмадың. Ялындым — калмадың. Хурлыгымнан җыладым. Нишләтәсең, үземнеке түгел шул. Кеше кешесе. Уйныйсың, дисең мине. Уйнамыйм, бик нык яратканымны сиздермәс өчен уйнаган булып кыланам. Һәр кешегә Ходай ярату хисе салган. Миндә әле аның яртысы да сарыф ителмәгән. Син дә мине яратасың бит, әйеме?

Рәхмәтулла. Яратмаска сине мөмкин түгел.

Гөлчирә. Кирәкми, икенче юлы әйтмә. Соң түгел әле, соң түгел. Мин әле сине йөз яшькә хәтле яшәтәм.

Шаулашып, Фаягөл, Нина, Рузалия, Хәдичә керәләр.

Нина. Всё, Рахматулла Хурматуллович, вы — наш. Сез — безнеке.

Фаягөл. Нурзидә Мөбәрәковна рөхсәт бирде.

Рузалия. Күчерегез, диде.

Гөлчирә. Күчерергә ул бит сезгә шкаф түгел.

Нина. Всё, Гуля! Монополия уничтожена — Рахматулла абы общий.

Гөлчирә. Общий булмый торсын.

Нина. Рахматулла абы — всенародное достояние. Дөрес әйтәмме, девочки?

Рузалия. Дөрес!

Фаягөл. Дөрес!

Рәхмәтулла. Нәрсә, миннән сорап та тормыйсызмыни?

Хәдичә. Кайтыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Нина. Башла, Фаягуль. Һай, хилляу, хилляу...

Фаягөл җыр башлый, аңа башкалар кушылалар.

Алма сатучылар килгән,
Үлчәүләре бар микән;
Әҗәлгә дару бар, диләр,
Мәхәббәткә бар микән?
Һай, һилләү, һилләү, һилләү,
Алты кызга бер кияү.
Һай, һилләү, һилләү, һилләү.
Һай, һилләү, һилләү лә.

Пәрдә.

# ГӨРГӨРИ КИЯҮЛӘРЕ

*(Ике пәрдәле этнографик музыкаль комедия)*

Комедия керәшен сөйләменең Кама аръягы диалектында язылды.

Катнашалар:

Гөргөри — Үрбаш авылының үҗәт кылыклы кешесе.
Кәтернә — Гөргөринең сүз тыңлаучан ипле катыны.
Үринә — Гөргөринең чибәр кызы.
Җаграп — Үрбашның «әтәче».
Бәчке — Үрбашның «эш аты».
Микуш — Үрбашның «бозавы».
Анук — Үрбашның кәттә кызы.
Гөрпинә — Микушның чәчрәп торган әнисе.
Палый — җаучы. Җәше туксан җагына авышкан, кәтере җугала башлаган карчык.
Әүдәки — ул да җаучы. Җәшен авылдашлары белми, ләкин үзе белә. Кәтере бик җакшы карчык.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Гөргөри җортының капка төбесе. Өч тәрәзәле ызба. Ызба каршында — рәшәткәле бакча. Пәрдә ачылганда, капка төбендәге эскәмиядә Гөргөри белән Кәтернә җыр сузып утыралар. Җәй башы. Кичке эңгер-меңгер.

Аклылардай җаулыккай шул бик, әй, ямьле, әй, әләй,
Җәйге көнне җәеп бәйләргәй;
Үрбашның буйлары да шул бик ямьле, әй, әләй,
Уйнап-көлеп җәйне җәйләргәй.

Әкрен генә тәрәзә ачыла. Үринәнең аяклары күренә, аннан — гәүдәсе. Оста гына шуып җиргә төшеп җитәм дигәндә, әтисе Гөргөри аны күреп ала.

Г ө р г ө р и. Кая барасың?

Үринә туктап кала.

Кая барасың?! Кер!..

Ү р и н ә *(телләшергә җыенып).* Кая керим?

Г ө р г ө р и. Каян чыктың?

Ү р и н ә. Ызбадан.

Г ө р г ө р и. Ызбага кер. Нәстә дип әйттем?

Ү р и н ә. Ызбага кер, дидең.

Г ө р г ө р и. Ник кермисең?

Ү р и н ә. Керәсем килми.

Г ө р г ө р и *(җирдә җаткан чыбыкны алып).* Кәзер керәсең килер.

К ә т е р н ә *(Гөргөринең кулына җабышып).* Җә инде, җә...

Г ө р г ө р и. Сиңа да кирәкме?

К ә т е р н ә *(рәшәткә кырына барып).* Бар, кызым, бар, тыңла атаңны, колкын беләсең.

Ү р и н ә *(ызбага керә. Тәрәзәдән башын тыгып).* Сез җоклагач, барыбер качам мин.

Г ө р г ө р и. Җап тәрәзәне! *(Тәрәзә җабылгач, бүленгән җырын дәвам итә.)*

Ак та каеннарның да шул бөресен, әй, әләй,
Кулларыңа тотып җөрерсең.
Төшләреңдә мине дә шулай күрерсең, әй, әләй,
Өннәреңдә җылап җөрерсең.

К ә т е р н ә. Бигрәк инде без. Кансирттагы сыман. *(Киемнәрен карап.)* Болай инде хәзер кансиртта гына киенәләр.

Г ө р г ө р и. Син әллә артистлардан кимме? Мин дә...

К ә т е р н ә. Үринә әйтә, үтерсәгез дә кимим ул иске киемнәрне, ди.

Г ө р г ө р и. Әбисенең күлмәген кияргә җирәнәме?

К ә т е р н ә. Җирәнүен җирәнмидер дә, ояладыр.

Г ө р г ө р и. Җалангач җөрергә оялмыйлар, җараусыз бәндәләр. Ничава, өйрәтәм мин аны.

К ә т е р н ә. Гумер буена капка төбендә Үринәне саклап утырырбызмы?

Г ө р г ө р и. Кирәк булса утырырбыз.

К ә т е р н ә. Үринә — җиткән кыз.

Г ө р г ө р и. Сез кыз-катыннар туганда ук җитлегеп туасыз. Үзең дә унсигез дә тулмас борын атылып чыктың кияүгә.

К ә т е р н ә. Үзең җалындың бит.

Г ө р г ө р и. Җегетләр җалынган саен кияүгә чыгалармы? *(Тәрәзә ачылып, Үринәнең аягы күренүгә.)* Җап тәрәзәңне!.. *(Тәрәзә җабылгач.)* Суктырам мин синең ул кызыңны.

К ә т е р н ә. Җә, җә, кызма. Җүри генә үрти ул сине. Ата казны үртәгән сымак.

Г ө р г ө р и. Җүри генә үртәргә мин кем аңа?.. Күрсәтермен ата каз.

К ә т е р н ә. Әй Гөргөри, Гөргөри! Булмый инде, борын заманны кире кайтарып булмый инде ул. Алар үзләренчә җәшиләр инде.

Г ө р г ө р и. Җу-ук, минемчә җәшәп карасын. Ике кызың үзләренчә җәшәп ни булды? Икесе дә әтисез бала үстерәләр.

К ә т е р н ә. Нишләп?.. Әтиләре бар ич аларның.

Г ө р г ө р и. Читтә җәшәгән әти әтимени ул? Җу-ук, монысын кияүгә үзем бирәм. Әүвәлгечә итеп — бөтен җоласына туры китереп бирәм. Мәңге бергә җәшәрлек итеп бирәм.

Ү р и н ә *(тәрәзәдән башын тыгып).* Мин барыбер син тапкан кияүгә чыкмыйм.

Г ө р г ө р и. Чыгарсың. Җап тәрәзәне! *(Тәрәзә җабылгач.)* Җөргән җегете бармы аның?

К ә т е р н ә. Булмый диме, көтүләре белән җөриләр.

Г ө р г ө р и. Көтүләре белән?

К ә т е р н ә. Кызлар матур булгач, шулай инде ул. Үзе кайсын җаратадыр, белмим.

Г ө р г ө р и. Көтүдә кемнәр бар?

К ә т е р н ә. Топыйның Җаграпы.

Г ө р г ө р и. Топый малаемы? Тапкан икән җегет. Нәстә була инде бу? Топый үзе синең арттан җөрде, малае кызыңның артыннанмы?

К ә т е р н ә. Нигә аны миңа әйтәсең, кызыңа әйт.

Г ө р г ө р и. Әйтермен дә, җөрмәсен шалапутлар белән... Тагын кем бар көтүдә?

К ә т е р н ә *(агач күләгәсендә басып торган Микушка күрсәтеп).* Берсе әнә.

Г ө р г ө р и. Кем ул?

К ә т е р н ә. Ибан Микушы.

Г ө р г ө р и. Шул да Үринә артыннан җөриме?

К ә т е р н ә. Җөрми нишләсен, җегет бит.

Г ө р г ө р и *(агач җанына барып)*. Никәл, җегет? Чык монда, нигә анда постың? *(Агач артыннан чыккан Микушка.)* Нишләп җөрисең монда? Сиңа әйтәм, әллә ишетмисеңме?

М и к у ш. Ишетәм, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Ишеткәч әйт, нишләп җөрисең монда? Минем җанга килдеңме?

М и к у ш. Җук, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Кәтернә тутаң җанына килдеңме?

М и к у ш. Җук, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Үринә җанына килдеңме? Ник дәшмисең?

М и к у ш. Әйе, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Үринә җанына килгәч, нигә анда посып торасың? *(Микуш дәшмәгәч.)* Бар, бактың уздырып җөрмә. Үринә чыкмый урамга.

М и к у ш. Ник, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Мин чыгармыйм.

М и к у ш. Ник, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Синең белән җөрттерәсем килми.

М и к у ш. Ник, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Син – җебегән җегет. Җегет кеше бозау кебек ник-мик дип тормый ул. Бар, бар, җөрмә безнең ызба тирәсендә. *(Китә башлаган Микушка.)* Туктале, тукта. Кил әле монда. Җаратасыңмы син Үринәне?.. Әйт инде.

М и к у ш. Җаратам, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Бик җаратасыңмы?

М и к у ш. Бик, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Бик җараткач, нишләргә җыенасың инде?

М и к у ш. Ничек инде нишләргә?

Г ө р г ө р и. Менә мин, Кәтернә тутаңны бик җараткач, өйләндем.

М и к у ш. Мин әле уйлаганым җук, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Синең өчен кем уйлый инде, әниеңме?

М и к у ш. Мин уйлыйм инде анысы.

Г ө р г ө р и. Бар инде, алайса, Микуш, әйбәтләбрәк уйла. Аннары Үринә җанына килерсең, җарыймы?

М и к у ш. Җарый, Гөргөри дәй. *(Чыга башлый да җаңадан әйләнеп керә.)* Мин уйладым, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Нәрсә уйладың, Микуш?

М и к у ш. Мин Үринә артыннан өйләнер өчен җөрим. Өйләнергә бакыт, дип, әни дә әйтә.

Г ө р г ө р и. Җакшы, Микуш, җакшы. Алайса, әниеңә әйт инде син, без Үринәне әүвәлегечә итеп, җоласына туры китереп бирәбез кияүгә.

М и к у ш. Нәстә соң ул әүвәлегечә җола?

Г ө р г ө р и. Синең әниең бик күпне белә. Аңардан сора, җарыймы?

М и к у ш. Җарый, Гөргөри дәй. *(Китә.)*

Г ө р г ө р и. Җарый, Микуш, җарый.

К ә т е р н ә. Җолаңа туры китереп, шуңа бирәсеңме инде Үринәне?

Г ө р г ө р и. Бирәм, ике дә уйламыйм.

Ү р и н ә *(тәрәзәне ачып)*. Мин барыбер сез тапкан кияүгә чыкмыйм.

Г ө р г ө р и. Җап тәрәзәне.

К ә т е р н ә. Бигрәк быламык шул инде бу Микуш. Әнисенә бераз да окшамаган, бигрәк быламык.

Г ө р г ө р и. Бүтән кияүләрең бик җакшы инде. Ташладылар да киттеләр кызларыңны. Җакшымы, җаманмы, әүвәлегечә итеп, җола буенча бирәм Үринәне. Бетте-китте...

К ә т е р н ә. «Җола» да «җола», дисең... Үзең беләсеңме сун ул җоланы?

Г ө р г ө р и. Бөтен кешене дә үзең кебек надан дип уйлама.

К ә т е р н ә. Шул надан белән җәшисең бит әле.

Г ө р г ө р и. Шуңа җәшим дә инде. Күпне белсәң, бер көн дә тотмаган булырыем. *(Җыр тавышы ишетеп.)* Кем ул матур итеп безнеңчә җырлый?

К ә т е р н ә. Мәтүш Бәчкәсе түгелме сун?

Г ө р г ө р и. Ул да көтүдәме? Үринә тирәсендә җөриме?

К ә т е р н ә. Җөри инде, җөри, барысы да җөриләр. Әйдә, керәбез.

Г ө р г ө р и. Тукта!.. *(Җырны тыңлый.)* Монда килә. *(Читкәрәк китеп, Кәтернәне чакыра.)* Кил мондарак. *(Койма чатына посалар.)*

Б ә ч к е *(җырлап керә).*

Күлдә балык җөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер, ай, сизәдер;
Авылыбызда бер чибәр бар,
Үзәгемне өзәдер, ай, өзәдер.

Әкрен кирәк, ипләп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.
Кара шомырт чәчләре лә
Шомарадыр тараса, ай, тараса;
Ушларымны җибәрәдер
Бер җылмаеп караса, ай, караса.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Җырлап-җырлап та Үринәнең нурлы йөзен күрү бәхетенә ирешә алмагач, Бәчке җырлый-җырлый моңаеп китә башлый.

Гөргөри *(җәшеренгән җиреннән чыгып)*. Әй, Бәчке, туктале, тукта...

Бәчке. Исәнмесез, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Сине күргәнче исән идем әле болай, дәлше ничек булыр. Син Үринә җанына килдеңме? Әйтмә, әйтмәсәң дә күренеп тора. *(Тәрәзәгә карап кычкыра.)* Үринә... Үринә, сиңа әйтәм!.. *(Өйдән бернинди тавыш ишетелмәгәч.)* Җоклаган, урамга чыгармаганыем, үпкәләп җоклаган. Нигә чыгармадың дип ник сорамыйсың? Әйтермен. Син миңа шуны әйт: җаратасыңмы Үринәне? Оялма, әйт.

Бәчке. Җаратам.

Гөргөри. Чынлап җаратасыңмы, болай гынамы?

Бәчке. Болай гына җаратмыйлар инде.

Гөргөри. Маладис! Кыз — синеке.

Үринә *(тәрәзәне ачып)*. Мин барыбер аңарга кияүгә чыкмыйм.

Гөргөри. Җокламаган икән. Чык әле монда, чык, чык...

Үринә. Чыкмыйм.

Гөргөри. Кәтернә, кайда минем чыбык?

Бәчке. Кирәкми, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Нәрсә кирәкми, Үринә кирәкмиме?

Бәчке. Аны әйтмим... Мин үзем...

Гөргөри. Нәрсә үзең?.. Үзең җырлап карадың бит. Чыкмады бит. Үринә!.. *(Кәтернәгә.)* Бар, алып чык. *(Кәтернә капкадан кереп киткәч.)* Син, Бәчке, оялма, җегет бул. Җырлавың ошады. Үзебезчә җырладың.

Бәчке. Мин әрбакыт үзебезчә җырлыйм.

Гөргөри. Маладис. *(Капкадан чыккан Үринәнең*

*кулыннан тотып.)* Утыр шушы эскәмиягә. Син дә утыр, Бәчке. Беркая да китмисез, шушында гына сөйләшәсез... Әйдә, Кәтернә. *(Кәтернәне җитәкләп, чыбыгын сөйрәп кереп китә.)*

Б ә ч к е. Нишләгән ул Гөргөри дәй?

Ү р и н ә. Белмәдеңмени, сизмәдеңмени? Мине сиңа кияүгә бирә. Җырлавың бик ошады бит.

Б ә ч к е. Син нигә миннән көләсең, Үринә?

Ү р и н ә. Син нигә минем арттан җөрисең? Жаратмыйм мин сине. Җырласаң да җаратмыйм. Җырлаганыңны әти җарата, аңа өйлән. Мине урамга чыгармый... Син килгәч чыгарды. Мин барыбер сиңа кияүгә чыкмыйм.

Б ә ч к е. Мин бит әле сиңа, миңа кияүгә чык, дип әйткәнем җук.

Ү р и н ә. Алай булгач, ник килдең?

Б ә ч к е. Җаратканга.

Ү р и н ә. Әллә бүтән сүз белмисең дәме?

Б ә ч к е. Беләм.

Ү р и н ә. Белсәң, әйт бүтән сүз.

Б ә ч к е. Әйтәм.

Ү р и н ә. Әйт, нигә әйтмисең?

Б ә ч к е. Мин сине җаратам, Үринә.

Ү р и н ә *(көлә)*. Җырлап та күрсәт инде. Булгач булсын.

Б ә ч к е. Җырлап та күрсәтәм. *(Җырлый.)*

Кара бөдрә чәчкәйләрең
Шомарадыр тарасаң, ай, тарасаң;
Җөрәгемә җал буладыр, ай,
Бер җылмаеп карасаң, ай, карасаң.
Әкрен кирәк, ипләп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Ү р и н ә. Җырлавын әйбәт җырлыйсың да, тик әллә кайчангы җырлар. Искереп беткән җырлар.

Б ә ч к е. Җыр искерми, Үринә.

Ү р и н ә. Син мине өйрәтмә, җарыймы... Син Җаграптан куркасыңмы?

Б ә ч к е. Нигә мин аңардан куркыйм?

Ү р и н ә. Ул синнән көчлерәк.

Б ә ч к е. Булса соң...

Ү р и н ә. Ул да мине җарата.

Б ә ч к е. Җаратса соң...

Ү р и н ә. Ул сиңа әйтсә, Үринә янында йөрмә, дисә?

Б ә ч к е. Дисә сун...

Ү р и н ә. Син нәстә дип әйтәсең?

Б ә ч к е. Ә син нәстә дип әйтәсең?

Ү р и н ә. Мин нәстә дип әйтәмме? Мин болай дип әйтәм... *(Сикереп тора да йөгереп чыгып китә.)*

Г ө р г ө р и *(капкадан атылып чыгып)*. Үринә!.. Борыл кәзер үк!.. *(Үринә борылмагач.)* Кәтернә!.. *(Капкадан чыккан Кәтернәгә.)* Бар, алып кайт кызыңны. Әгәр дә кайтмаса, үзең дә кайтма. Аналы-кызлы икәү бергә гүләйт итеп йөрерсез.

Б ә ч к е. Гөргөри дәй...

Г ө р г ө р и. Син тик тор. *(Кәтернәгә.)* Бар!.. Мә чыбыкны! *(Кәтернә чыбыкны сөйрәп чыгып киткәч.)* Син җегетме? Җегет булгач, кызлар белән шулай сөйләшәләрме?

Б ә ч к е. Җәшләр сүзен тыңлап тору килешми инде, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Тыңларлык сүзегез булдымы сун сезнең?.. Җырлавың әйбәт. Кыз — синеке. Качып бер җиргә китә алмас. Син нигә аңа, кияүгә чык, дип әйтмәдең? Үзең, җаратам, дисең? Үзең кияүгә чык димисең.

Б ә ч к е. Ничек инде...

Г ө р г ө р и. Җаратасың икән өйләнәсең, җаратмыйсың икән йөрмә. Аңладыңмы?

Б ә ч к е. Аңладым, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Ашыкма, әле мин бөтенесен дә әйтеп бетермәдем. Җиңел генә өйләнмәкче буласың, ә? Җу-ук... Шәли-иш... Мин, беләсең килсә, кызым Үринәне әүвәлегечә итеп, йоласына китереп кияүгә бирәм. Беләсеңме йоланы?

Б ә ч к е. Кем белә инде аларны, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Әүвәлеге җырларны беләсең ич.

Б ә ч к е. Аларын җырлап торалар бит аның.

Г ө р г ө р и. Беләсеңме, Бәчке? Мин сине җаратам. Син ат кебек эшлисең. Эшләгән кешене җаратам мин. Тик, ни инде, Үринәне әүвәлегеләр йоласы белән бирәм. Син үзең белмәсәң, берәр карчыктан сора. Үзем әйтер идем дә, җарамый. Әти кеше бит мин.

Б ә ч к е. Әүдәки әби белә микән?

Г ө р г ө р и. Кая инде ул! Белгәнен дә оныткан. Палый

карчык белән сөйләшеп кара син, Бәчке. *(Үринәне җитәкләп кайтып кергән Кәтернәгә.)* Бар, өйгә кертеп биклә.

Кәтернә белән Үринә кереп китәләр.

Бәчке. Гөргөри дәй, әллә әүвәлегеләр кызларны бикләп тотканнармы?

Гөргөри. Син мине тикшермә, Бәчке кияү. Үринәне аласың килсә, мин әйткәнне эшлә. Сау бул, Бәчке кияү.

Бәчке китә.

Кәтернә *(капкадан чыгып)*. Оятка калдырасың син мине. Бозау җитәкләп җөргән кебек кыз җитәкләп җөрергә…

Гөргөри. Кыз җитәкләп җөрисең килмәсә, кыз тапмыйлар аны. Ничә кыз табып, бер җегет юк.

Кәтернә. Мин кызларымны җилдән тапмадым. Үзең кайда идең?

Гөргөри. Күп сөйләмә! Бар, кер, кызыңны җаныңнан җибәрмә.

Кәтернә. Үзең дә кер.

Гөргөри. Әйткәнне тыңла.

Кәтернә. Бигрәк җауызландың, Гөргөри. Алай түгел идең. Аерым җоклый башладың.

Гөргөри. Синең җанга җатсам, уйларга мишәйт итәсең. Үринәне кияүгә бирәбез дә, кочагыңнан да чыкмам.

Кәтернә. Шулай итәрсең, җарыймы, Гөргөри? *(Гөргөригә сыена.)*

Гөргөри *(Кәтернәне иркәләп алганнан соң).* Булды-булды, җитте, бар. Мин дә кәзер керәм. *(Кәтернәне озата да утыргычка утыра. Офыктан тәгәрәп чыккан түгәрәк айга карап әкрен генә җыр суза. Ул башлаган җырны кемдер дәвам итә. Үрбаш авылы кызы Анук икән. Аның җырын Гөргөри сихерләнеп тыңлый. Менә Анук үзе дә күренә. Бөтен урамны бер итеп җырлап килә.)*

Урман авызлары — тарлар авыз,
Агач башы — сары балавыз.
Вак балыклар уйный
Агыйделнең җәмле суында.

Сагынган да саен күрешергә
Җырак булыр безнең арабыз.
Вак балыклар уйный
Агыйделнең җәмле суында.

Анукка каршы Җаграп килә.

Җаграп. Прибет, Анук!..

Анук, аның сәламен дә алмыйча, җырын өзмичә, җулын дәвам итә. Җаграп аның җулына төшә.

Мине ишетмәдең мәллә? *(Анук игътибар итмәгәч.)* Нишлисең син, ә?

Анук. Ишетмисеңмени, җырлыйм ич.

Җаграп. Мин синең җырлаганыңны ишетәм. Син ник мине күрмисең?

Анук. Менә күрдем ич инде.

Җаграп. Нигә исәнләшмисең?

Анук. Исәнләшәсем килми.

Җаграп. Ник килми?

Анук. Үринә белән исәнләш. Син бит аның җанына киләсең чаба-чаба. Аңа өйләнергә җөрисең, ди. Дөресме?

Җаграп. Дөрес булса нәстә?

Анук. Өйлән инде, өйләнеп кара.

Җаграп. Көнләшәсеңмени?

Анук. Бик исем китте. Барыбер минем кулга каласың.

Җаграп. Ничек калам?

Анук. Гөргөри дәй Үринәне сиңа бирми.

Җаграп. Кемгә бирә?

Анук. Синнән әйбәтрәккә.

Җаграп. Кем инде ул миннән әйбәтрәк?

Анук. Койрыклы җен. Җөрмә монда, әйдә су буена.

Җаграп. Бармыйм.

Анук. Ник?

Җаграп. Куркам.

Анук. Кемнән?

Җаграп. Синнән.

Анук. Мин шундый куркынычмыни?

Җаграп. Җук.

Анук. Алайса, ник куркасың?

Җаграп. Миңа өйләнергә кирәк. Болай җөреп туйдым.

Анук. Ник миңа өйләнмисең?

Җаграп. Сиңа өйләнергә җарамый миңа.

Анук. Ник?

Җаграп. Без икебез дә бертөсле. Синең белән җөрергә генә әйбәт. Мин Үринәгә өйләнәм, синең белән җөрермен. Үринә — көндәлеккә, син — кешелеккә.

Анук. Нәстә-ә-ә?

Җаграп. Кил әле монда, нәстә икәнен әйтәм.

Анук. Барыбер үптермим. *(Үзе Җаграп артыннан бара. Агач артында аның чытлыкланып көлгәне ишетелә. Аннан, чыркылдый-чыркылдый чыгып йөгерә.)*

Җаграп рәшәткә янына килеп сызгыра. Аның сызгыруына Гөргөри сызгырып җавап бирә. Җаграп, аптырап, җак-җагына карана да тагын сызгыра. Гөргөри дә сызгыра. Шулай берничә тапкыр сызгырышкач, Җаграп, Гөргөрине күреп алып, аның җанына килә.

Җаграп. Прибет, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Арумы, Җаграп, арумы?

Җаграп. Үринә кайда, Гөргөри дәй?

Гөргөри. Өйдә.

Җаграп. Нигә чыкмый?

Гөргөри. Чыгасы килмидер.

Җаграп. Бар әле, чакырып чык әле.

Гөргөри. Минме?

Җаграп. Сиңа әйткәч, син инде, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Оялмыйсыңмы?

Җаграп. Җук, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Шулай шул — сезнең нәселегез белән оятсыз нәсел. Шалапутлар.

Җаграп. Син безнең нәселгә тимә, Гөргөри дәй.

Гөргөри. Тисәм, ни диярсең?

Җаграп. Кызыңны алсам, киявең булам бит...

Гөргөри. Кызымны бирсәм, киявем булырсың.

Җаграп. Кәзер кызларны атасыннан сорап тормыйлар, Гөргөри дәй. Бар, чакыр инде, ату китәм бит.

Гөргөри. Сау бул.

Җаграп *(рәшәткә җанына килеп кычкыра).* Үринә-ә!

Тәрәзә ачыла, анда Үринәнең башы күренә. Кәтернәнең кулы аны тартып ала да тәрәзәне җабып куя.

Җаграп. Чыгармыйсызмыни кызыгызны минем җанга, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Җук, Җаграп, җук.

Җ а г р а п. Кемгә чыгарасыз?

Г ө р г ө р и. Кем әүвәлегеләр җоласын үтәп өйләнә кызыма — шуңа.

Җ а г р а п. Ничек була инде ул әүвәлегеләр җоласы?

Г ө р г ө р и. Беләсең килсә, сораш.

Җ а г р а п. Кемнән?

Г ө р г ө р и. Кемнәр белә — шулардан.

Җ а г р а п. Син беләсеңме?

Г ө р г ө р и. Чамалыйм.

Җ а г р а п. Өйрәт.

Г ө р г ө р и. Җук инде. Кыз да миннән, өйрәтү дә миннән булмый. Үзең өйрәнеп кил.

Җ а г р а п *(Гөргөрине күтәреп алып, рәшәткә баганасына утырта)*. Бигрәк җиңел икәнсең син, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Куркытма, җарыймы? Атаң да минем белән булышып караганые — оттырды.

Җ а г р а п. Ничек оттырды?

Г ө р г ө р и. Кәтернә тутаң минеке булды.

Җ а г р а п. Алай булгач, синең безгә бурычың бар, Гөргөри дәй. Түлә. Чыгар Үринәне.

Г ө р г ө р и. Чыгармыйм.

Җ а г р а п. Алайса, үзем кереп алам. *(Капкага бара.)*

Г ө р г ө р и *(капкага аркылы төшеп)*. Кермисең, Җаграп.

Җ а г р а п. Керәм, Гөргөри дәй. *(Гөргөрине читкәрәк этеп, капкадан кереп китә.)*

Г ө р г ө р и *(тәрәзәгә барып)*. Кәтернә, бикլә ишекне! *(Үзе тиз генә капкадан кереп китә.)*

Ишегалдында шау-шу. Беравыктан капкадан арты белән чигенә-чигенә Җ а г р а п чыга. Аның артыннан ау мылтыгын Җаграпка төзәгән Г ө р г ө р и чыга.

Г ө р г ө р и. Атам! Күтәр кулларыңны!

Җ а г р а п. Гөргөри дәй, дурака нибәләй.

Г ө р г ө р и. Дәшмә, атла!

Ү р и н ә *(тәрәзәдән башын тыгып, чыркылдап көлә)*. Ат, әти, ат! Атып җык!

К ә т е р н ә *(икенче тәрәзәдән башын тыгып)*. Гөргөри, җүләрләнмә! *(Җаграп белән Гөргөри чыгып киткәч, Үринәгә.)* Син нигә көләсең, җүләр баш?

Ү р и н ә. Җаграп дер-дер калтырый.

К ә т е р н ә. Шундый ул әтиең. Син аның буена карама. Җалгыш атып җибәрмәсә җарарые. Барысы да синең аркада, җүләр баш.

Ү р и н ә. Мин нәстә эшләгән?

К ә т е р н ә. Әллә ничә җегет белән җөрисең.

Ү р и н ә. Мин җөрмим ич, алар җөри.

К ә т е р н ә. Барысы белән дә хихылдап сөйләшәсең. Кара аны, атаңның колыгы үзе белән. Син инде сабый бала түгел, җегетләрнең күңелеңә җакынын сайлап ал да шуның белән генә җөр. Менә мин әтиеңне сайлап алдым да аңа чыктым.

Ү р и н ә. Нигә син бәләкәй буйлы җегет сайладың?

К ә т е р н ә. Аның каравы җөрәге зур аның. Атаң кебек җегет дөнҗада җук ул. Әй, аның җегет чакларын күрсәң!.. Һай, безнең җәш чаклар... *(Җырга күчә.)*

Үрбаш буйкайлары ла, ай, наратлык,
Ай, Үрбаш буйлары,
Наратлыкка бадиян тараттык.
Колык-пигыльләрен лә, ай, белмәдек,
Ай, Үрбаш буйлары,
Чибәр булган өчен лә җараттык.
Үрбаш урамнары ла, ай, пыяла,
Ай, Үрбаш буйлары,
Басканнар ла саен ла уала.
Сезнеңкәйләр белән җәшлегебез
Ай, Үрбаш буйлары ла,
Җырлаплар ла, гөрләп лә уза ла.

*(Кинәт мылтык атылган тавышка сискәнеп куя.)* Бетерде!.. Үтерде!..

Ү р и н ә, тәрәзәдән сикереп төшеп, рәшәткә аша сикереп чыгып чаба. Беравыктан Г ө р г ө р и белән К ә т е р н ә керә. Гөргөри мылтыгын иңбашына аскан.

К ә т е р н ә. Нишләдең син, Гөргөри?

Г ө р г ө р и. Аттым тегене!

К ә т е р н ә. Кемне?

Г ө р г ө р и. Талга кунган ала карганы. Чебешләрне чүпләп бетерде, кәхәр. Вәт син, ә, этеп җибәреп кереп киткән була. Керерсең, бар! Җабыгыз тәрәзәләрне, сүндерегез утны.

Ут сүнә. Ут җанганда инде көн туган, төш вакыты җиткән. Палый карчыкны җитәкләп, Бәчке керә.

Палый. Кая аппарасың син мине?

Бәчке. Үзең әйттең бит, әүвәлегеләр җоласы белән кызны җаучыларга кирәк, дидең.

Палый. Җаучыламыйча булмый, җаучыламыйча булмый. Кызны җаучылап алырга кирәк. *(Җаучы җырын җырларга керешә.)*

Ай, килдек без, килдек без,
Иделләрне кичеп килдек без…

Бәчке. Ашыкма, Палый әби. Анысын Гөргөри дәйләргә баргач җырларсың. Атла инде тизрәк.

Палый. Җибәр, үзем дә җөри алам мин.

Бәчке. Тизрәк, эшкә китәсем бар.

Палый. Нәстә нитәсең бар?..

Бәчке. Эшкә китәсем бар. Әбәткә генә кайттым.

Палый. Нәстә апкайттым дисең?

Бәчке. Әйдә инде, атла инде…

Палый. Кая аппарасың син мине?

Бәчке *(Палыйның колагына кычкырып)*. Әйттем бит инде.

Палый. Оныттым.

Бәчке. Син Үринәне җаучыларга барасың.

Палый. Кем ул Үринә?

Бәчке. Гөргөри дәй кызы.

Палый. Анысы кем?

Бәчке. Әйттем ич инде. Радионыч.

Палый. Памилия белән сөйләшмә. Әтисе ни исемле?

Бәчке. Микипар.

Палый. Микипар Гөргөриенең кызын җаучыларга бараммы?

Бәчке. Әйе инде.

Палый. Кемгә?

Бәчке. Миңа, дидем бит инде.

Палый. Син кем әле?

Бәчке. Әйттем ич инде.

Палый. Оныттым.

Бәчке. Сабук Мәтүшенең Бәчкесе. Аңладыңмы инде? Онытма. Микипар Гөргөриенең кызы Үринәне Сабук Мәтүшенең Бәчкесенә җаучыларга барасың. Онытмассыңмы, Палый әби?

П а л ы й. Җук, җук.
Б ә ч к е. Мин киттем, алайса...
П а л ы й. Кит, кит...
Б ә ч к е. Нишләргә беләсеңме инде?
П а л ы й. Өйрәтмә. Исемең ничек дидең әле?
Б ә ч к е. Бәчке, Бәчке, Бәчке... Сабук Мәтүшенең Бәчкесе.
П а л ы й. Булды-булды... Бар, кит. Кич утынымны җарып китәргә онытма. *(Бәчке чыгып киткәч, кылтыйн-мылтыйн атлап, Гөргөриләр капка төбесендәге утыргыч янына килә, утыра. Нәстәнедер исенә төшерергә тырыша.)* Ничек иде суң әле?.. Җарый, монысыннан башлыйк. *(Куллары белән капка, койма такталарын сыпырып ырым әйтә.)*

Җиңгәй, җиңгәй, җиң җылан,
Киртә астыннан чык, җылан.
Чагар булсаң, чак, җылан.
Башыңны чабарым,
Коерыгың кыярым,
Балауз каян җабышкан,
Чир тимәгән кешегә
Чир каян җабышкан? —
Чире-чоры җилгә-давылга.
Кара җылан, чык, җылан,
Җептән нәзек калырсың;
Бакыр җылан, чык, җылан,
Җептән нәзек калырсың.

Гөргөриләрнең капкасы ачыла.

К ә т е р н ә *(капкадан башын тыгып)*. Кем бар анда? *(Җаучы карчыкны күреп аптырап кала.)* Палый түти, синме сун бу?
П а л ы й. Ә?
К ә т е р н ә. Синме, дим.
П а л ы й. Мин шул. Син — синме?
К ә т е р н ә. Мин. Кәтернә инде мин, Гөргөри катыны.
П а л ы й. Катынымы? Җакшы. Кил әле, утыр.
К ә т е р н ә. Әйдә, үзең өйгә кер.
П а л ы й. Җук, башта моннан башлыйк. *(Җайлап кына утыра да җыр белән нигә килгәнен сөйләп бирә.)*

Кара сыерның ла, ай, мөгезләрен
Каерып та алырга килдек без лә,
Ай, килдек без.
Әнекәйләреннән лә, ай, бер бәбкәсен
Аерып та алырга килдек без лә,
Ай, килдек без.

Син әүвәлеге җолаларны беләсең, диде. Миннән башка белүче калмаган икән авылда әүвәлеге җолаларны. Җаучы булып килдем инде мин. Кемнән икәнне өегезгә кергәч әйтермен. *(Кәтернәгә тотынып, җыр әйтеп кереп китә.)*

Әүдәкине кулларына күтәреп, Җаграп керә. Утыргычка алып килеп утырта.

Әүдәки. И-и-и, рәкәт булды әле бу. Әллә тагын бер урам әйләндереп кайтасыңмы? Күптән күтәреп җөргәннәре җугые.

Җаграп. Син мин әйткәннәрне, үзең белгәннәрне эшлә. Мин сиңа машина алып бирәм, белдеңме, Әүдәки әби.

Әүдәки. Җук, машина кирәкми миңа. Күрше Үләнкәләрнең машинасын урлап киткәннәр, ди. Кәзәмә бер арба печән чабып бирсәң, җарар.

Җаграп. Чабабыз аны, Әүдәки әби. Мин сиңа сыер алып бирәм, белдеңме.

Әүдәки. Әүвәлегеләр җоласы, диме Гөргөри?

Җаграп. Шулай ди шул.

Әүдәки. Әүвәлегеләр җоласын миннән җакшы белүче җук инде. Җаучылаудан башлана инде. Элегрәк заманда җыры да барые.

И утырыр үрдәк лә, айлар утырыр,
Оясына мамык та тутырыр ла,
Нинди хәбәрләр лә, ай, кайтыр, ди дый
Җегет көтеп кенә утырыр ла,
Ай, утырыр.

Җаграп. Син элекке заманны миңа сөйләмә, Әүдәки әби. Боларга сөйләрсең. Син миңа Үринәне алып бир.

Әүдәки. Кай арада үсеп җитәләр диген. Мин әле синең бабаңның бабасын хәтерлим. Башсыз кеше иде. Син дә башсызмы?

Җ а г р а п. Син мине тикшермә, Әүдәки әби.

Ә ү д ә к и. Ничек инде тикшермә... Мин нинди кешегә кыз җаучылаганны белергә тиеш.

Җ а г р а п. Әйбәт җегет мин. Авылда бер дигән.

Ә ү д ә к и. Бабаңның бабасы да шулай әйтәе. Бабаң да башсызые. Кушаматыгыз ничек әле сезнең?

Җ а г р а п. Кушаматыбыз җук безнең.

Ә ү д ә к и. Кушаматсыз керәшен керәшен түгел ул. Җабалакмы әле кушаматыгыз?

Җ а г р а п. Кушамат түгел ул Җабалак.

Ә ү д ә к и. Нәстә сун?

Җ а г р а п. Памилия...

Ә ү д ә к и. «Җабалак» дигән памилия жук керәшендә.

Җ а г р а п. Ябалаков Евграф Трофимович мин. Паспортта шулай.

Ә ү д ә к и. Бозма керәшен исемнәрен. Җабалак Топыйның малае Җаграп син, белдеңме?

Җ а г р а п. «Сайгун Җабалак» дип тә җөртәләр әле.

Ә ү д ә к и. Нәстә ул «сайгун»?

Җ а г р а п. Үзем дә белмим инде.

Ә ү д ә к и. Кушаматыңны белергә кирәк. Исемеңне онытсаң да, кушаматыңны онытма. Менә мин беләм. «Кәзә» безнең кушамат. Бабамның әтисенә кушканнар. Әллә каян мамыклы кәзә алып кайткан булган. Мамыклы кәзә сыердан җакшы, дип сөйләп җөргән. Шуннан...

Җ а г р а п. Әби, өйләренә кертеп биримме?

Ә ү д ә к и. Туктале, капкадан кергәнче нишлиләр иде әле?

Җ а г р а п. Анысы нәстәгә инде, карап тормыйлар ич.

Ә ү д ә к и. Ә-ә-ә, син карап торганга гына үтисеңмени җоланы? Җоланы кеше карап торсын өчен генә эшләмиләр. Башсызлар шул сез, башсызлар. Сезгә кыз җаучылау да гонак. Илтеп куй мине өемә.

Җ а г р а п. Әүдәки әби, алай итмә инде. Кәзәңә печән чабасы да бар.

Ә ү д ә к и. Бер кәзәлек кенә печән табармын.

Җ а г р а п. Әүдәки әби...

Ә ү д ә к и. Җарый. Мине оятка калдырсаң, кара аны. Җабалак дип тормам. Кертеп куй өйләренә. *(Җаграп аны кулларына күтәргәч.)* Тукта... Сезнең нәсел эш эшләргә җаратмый. Катыныңны ничек асырарсың? Аның эшләгәненә җәшәрсеңме?

Җ а г р а п. Мин балыкчылар бригадасы төзим, Әүдәки әби. Милиун сумлык балык тотачакбыз, белдеңме?

Ә ү д ә к и. Төшер. Тоткач җаучыларбыз.

Җ а г р а п. Нәстә инде син, Әүдәки әби? Ышан инде.

Ә ү д ә к и. Җарый инде, әйдә, алып кер.

Кереп китәләр. Ү р и н ә керә, аңа М и к у ш ияргән.

Ү р и н ә. Син нәстә көпә-көндез миңа җабышып җөрисең?

М и к у ш. Үринә...

Ү р и н ә. Үринә инде, җә, Үринә.

М и к у ш. Үринә.

Ү р и н ә. Әти сиңа нәстә әйтте, җөрмә безнең ызба җанында.

М и к у ш. Үринә...

Ү р и н ә. Кит, диләр сиңа!

М и к у ш. Үринә...

Ү р и н ә. Синең белән җөрмим мин, җөрисем килми.

М и к у ш. Ник, Үринә?

Ү р и н ә. Җуаш җегетләрне җаратмыйм. Беләсеңме шуны?

М и к у ш. Белмим, Үринә...

Җ а г р а п *(капкадан чыгып)*. Белмәсен, өйрәтәм мин сине. Тай моннан. *(Микушның җакасыннан эләктереп, читкә алып ыргыта. Микуш торып, Үринә җанына килгәч.)* Нәстә, җитмәдеме әллә?

М и к у ш. Үринә...

Җ а г р а п *(Микушның изүеннән алып)*. Күрсәтәм мин сиңа Үринәне!

Ү р и н ә *(Җаграпның кулына асылынып)*. Җибәр!..

Җ а г р а п. Нәстә, әллә аны җаклыйсыңмы?

Ү р и н ә. Җибәр! *(Җаграп Микушның изүен ычкындыргач.)* Бар, кит, Микуш.

М и к у ш башын иеп чыгып китә.

Җ а г р а п. Микушны җаратасың мәллә?

Ү р и н ә. Нигә көчең белән мактанасың?

Җ а г р а п. Җөрмәсен, көче булмагач, кызлар җанында.

Ү р и н ә. Әгәр дә синнән көчлерәк сине кыйнаса?

Җ а г р а п. Кыйнап карасын.

Ү р и н ә. Мактанчык. Үзең кичә этидән курыктың.

Җ а г р а п. Курыкмадым. Синең өчен генә. Бүтән булса, болгап ыргытаем.

Ү р и н ә. Балыгыңны тотмыйча, урамда нишләп җөрисең?

Җ а г р а п. Ә син бел минем нишләп җөргәнемне.

Ү р и н ә. Нигә җылмаясың?

Җ а г р а п. Ә син бел минем нигә җылмайганны.

Ү р и н ә. Бик беләсем килми әле. Сау бул.

Җ а г р а п. Ашыкма.

Ү р и н ә. Ашыкмаска. Мин – эштәге кеше. Әбәткә генә кайттым. Кара, нигә җылмаясың син әллә ничек итеп?

Җ а г р а п. Нигә җылмайганны ызбагызга кергәч күрерсең.

Ү р и н ә. Әллә җүләр инде син? *(Капкадан кереп китә.)*

Җ а г р а п. Җүләрме, акыллымы – минем кулыма эләгәсең. *(Шатлыгыннан җырлап ук җибәрә.)*

Бара идем урам буйлап, җаный, дөя җигеп,
Бер кыз бала дәшеп калды шунда, җаныем, дип.
Мин аңарга әйткән идем, җаный, алмаем, дип,
Муеныма асылынды, җаный, калмаем, дип.
Җаумый җаңгыр, төшми кояш, җаный, пич башына,
Беркая да китмәенчә, җаный, тор каршымда.

Г ө р г ө р и *(сәнәк күтәреп кайтып керә. Җаграпның җырлап торуын сәнәгенә таянып тыңлый да).* Бәчке синнән матуррак җырлый.

Җ а г р а п. Прибет, Гөргөри дәй. Мин бит син әйткәнне эшләдем, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Нәстә эшләдең?

Җ а г р а п. Әүдәки әби сездә.

Г ө р г ө р и. Нишли ул анда?

Җ а г р а п. Әүвәлегеләр җоласы, диденңме? Әүдәки әбидән дә әүвәлегерәк кеше бармы безнең ауылда? Җук. Ул син белмәгәннәрне дә белә.

Г ө р г ө р и. Шуннан ни?

Җ а г р а п. Шуннан шул – синең алдыңда синең кияүвең басып тора, Гөргөри дәй.

Гөргөри ашыгып капкадан кереп китә.

Җаграп канәгать булып көлеп кала. Атылып, Г ө р п и н ә керә, Җаграпны күреп, каршына «җөзеп» бара.

Г ө р п и н ә. Син мондамыни әле, Сайгун Җабалак? Нәстә син минем улым Микушыма бәйләнәсең, ә? Күзеңне төртеп тишәм бит, Сайгун Җабалак.

Җ а г р а п. Нәстә син?

Г ө р п и н ә. Мин нәстә түгел, мин — Гөрпинә тутаң, белдеңме? Минем улым Микушым җуаш булгач та, аны кыйнарга җарый дип белдеңме?

Җ а г р а п. Бар әле, кит әле моннан.

Г ө р п и н ә. Китәрмен мин сиңа, Җабалак. Топый малае.

Җ а г р а п. Бар, кайт та ireңә бәйлән. Ул синнән куркып тора.

Г ө р п и н ә. Син миннән курыкмыйсыңмы? Шуңа улым Микушны кыйныйсыңмы? *(Җодрыгын Җаграпның борын төбендә уйнатып.)* Менә моны күрәсеңме?

Җ а г р а п. Кит диләр сиңа!

Г ө р п и н ә. Кәзер китәм мин сиңа, Сайгун Җабалак. *(Бик оста итеп Җаграпка тибеп ала. Җаграп кычкырып сыгылып төшә.)* Тагын кирәкме, Җабалак? *(Тагын тибеп алырга чамалаганда, Җаграп аның аягыннан эләктереп ала. Гөрпинә дөнҗа селкетеп кычкырырга тотына.)* Каравыл, үтерәләр! *(Икенче аягыннан галушын салып, Җаграпны шуның белән җаңаклый. Үзе һаман кычкыра.)* Каравыл!.. Үтерәлә-әр!..

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә Гөрпинәнең «Каравыл... Үтерәләр!» дигән тавышы белән ачылып китә. Капкадан Г ө р г ө р и чыга. Тәрәзәләр ачыла. Анда К ә т е р н ә, Ү р и н ә, П а л ы й башлары күренә. Гөргөри килеп Ж а г р а п к а җабыша. Г ө р п и н ә н е аның кулыннан тартып ала.

Г ө р г ө р и. И-и-их син... Кыз-катын белән сугышып җатасыңмы?

Җ а г р а п. Мин түгел, Гөргөри дәй, ул үзе...

Г ө р п и н ә. Җаңгаллама, Җабалак. Матур гына итеп сезгә килә идем, Гөргөри, менә шушы урында Җабалак Топыйның малае тора. Исәнме, мин әйтәм, Җаграп

улым, нишләп торасың, монда, дим. Матур гына итеп әйттем. Ул, үтерәм мин синең улың Микушны, ди. Алай җарамый, мин әйтәм, Җаграп. Ә ул нәстә әйтә? Уди атсуда, дип урысчалап әйтә. Нәстә, мин урысмыни аңа? Мин әйтәм, алай җарамый, Җаграп, дим. Ул сүгенде.

Җ а г р а п. Җаңгаллама. *(Торып кагына.)*

К ә т е р н ә. Әй, Җаграп, Җаграп, үзең җаучы җибәргәнсең. Үзең безнең җорт каршында сүгенеп торасың.

Җ а г р а п *(Кәтернә каршына аксый-аксый барып).* Сүгенмәдем, Кәтернә ти, сүгенмәдем.

Г ө р г ө р и. Бар, кит моннан, Җаграп. Җакшы чакта.

Җ а г р а п. Сүгенмәдем мин, Гөргөри дәй. Мин вапшы сүгенә белмим. Ул үзе мине тибеп җыкты.

Гөрпинә көлә башлый. Аңа бүтәннәр кушыла.

Г ө р п и н ә. Гөрпинә типкәнгә җыгылдыңмы?

Җ а г р а п. Ул бит тибә белеп типте.

Г ө р п и н ә. Җылап җибәр инде, җылап җибәр, Җабалак.

Җ а г р а п. Җиттеме сиңа, җукмы. *(Гөрпинәгә таба килә.)*

Г ө р п и н ә. Әнә күрдегезме, әнә күрәсезме?

Г ө р г ө р и. Алып чыгам мылтыкны, Җаграп. Бар, кит!

Җ а г р а п. Китәм, китәм. Тик белегез, әйтеп китәм. Ишет, Үринә, син дә. Син барыбер минеке булачаксың. *(Аксап чыгып китә.)*

Г ө р п и н ә. Җабалак. Җилкенгән була. Җә инде, исәнләшик. Исәнме-саумы, Гөргөри? Исәнме-саумы, Кәтернә? Син исәнме, Үринә? Ә Палый карчык монда нишләп җөри?.. Исәнме, Палый ти?

П а л ы й. Нәстә дисең?

Г ө р п и н ә. Саумы, дим.

П а л ы й. Син кем суң?

Г ө р п и н ә. Әй, саңкай карга. *(Утыргычка барып утырып.)* Кил әле, утыр әле шушында Гөргөри. Чык әле монда, Кәтернә.

Гөргөри утыргач, җыр башлый. Кәтернә белән Палый чыгып тыңлап торалар.

Чәчләремне бишттән дә лә үрерләр идем,
Чәчен бишттән үргән дә лә, айлар, димәсләр.
Ай, сезләрнең өчен дә лә үләрләр идем,
Сезнең өчен үлгән дә лә, айлар, димәсләр.

П а л ы й. Алай җырланмый ул җыр. Безнең заманда алай җырланмые, болай җырланае. *(Җырлый.)*

Кара сыерның ла, ай, мөгезләрен
Каерып та алырга килдек без лә,
Ай, килдек без.
Әнекәйләреннән лә, ай, бер бәбкәсен
Аерып та алырга килдек без лә,
Ай, килдек без.

Г ө р п и н ә. Син, Палый ти, онытып бетергәнсең инде. Безнең калыкта алай җырламыйлар.

П а л ы й. Син мине өйрәтмә, җәме. Әүвәлегедән шулай җырлана.

Г ө р п и н ә. Җук, безнең калык алай җырламый.

Ә ү д ә к и *(капкадан күренеп)*. Сез икегез дә дөрес җырламыйсыз.

Г ө р п и н ә *(Әүдәкине күреп)*. Кодаем… Син нишләп җөрисең, Әүдәки ти? Җөри алмый идең ич инде.

Ә ү д ә к и. Торгыздылар менә. Урын бирегез. Кагыл, Гөргөри. *(Утыра.)* Сез икегез дә дөрес җырламыйсыз. Болай җырлана ул. *(Җырлап күрсәтә.)*

Җаварлар килгән җаңгырларны
Җаумаенча китәр димәгез;
Җаучыларга килгән кызыгызны
Алмаенча китәр димәгез.

П а л ы й. Алай түгел.

Ә ү д ә к и. Син тик тор, Палый. Мин кияүгә чыкканда, син әле тумаган идең. Сезнең ишеләр тудылар да җырларны бозып бетерделәр.

П а л ы й. Кем кызып китте? Үзең кызып киттең…

Ә ү д ә к и. Кызып киттең, димим, бозып бетердегез, дим. Колагың ишетмәгәч, җаучы булып килмиләр аны.

П а л ы й. Син әле аягың җөрмәгән килеш тә килгәнсең.

Г ө р п и н ә. Икегезне дә әйтер идем инде… Туктагыз әле, тукта, тукта, тукта… Нәстә дидегез әле сез? Нинди җаучы дидегез?

К ә т е р н ә. Менә Палый ти белән Әүдәки ти Үринәне җаучыларга килгәннәр.

Г ө р п и н ә. Ә?! Кемгә?!

Г ө р г ө р и. Җабалак Топый Җаграпы белән Мәтүш Бәчкесенә.

Г ө р п и н ә. Ә?! Нәстә?! Сез әле, саңкай карга белән чатан карга...

Г ө р г ө р и. Кызма-кызма, Гөрпинә, син үз җомышыңны әйт.

Г ө р п и н ә. Җомыш? Нинди җомыш? Син минем нишләп җөргәнемне аңламадыңмыни?

Г ө р г ө р и. Аңлавын аңладык та...

Г ө р п и н ә. Аңласагыз, шул... Минем Микушымнан да җакшы җегетне дөнҗадан эзләп-эзләп тә...

П а л ы й. Җарый, алай, кем... Кем әле синең исемең?

Г ө р г ө р и. Гөргөри, Палый ти, Гөргөри.

П а л ы й *(Кәтернәгә)*. Син Үринәме әле?

Ә ү д ә к и. Җәп-җәш башыңнан башың эшләми. Кәтернә ул, Кәтернә бит ул. Үртәми кызы Кәтернә.

П а л ы й. Шулай бугай шул. Шулай итәбез инде, болай булгач. Кызның әти-әнисе каршы килмәде, дибез. Бүген кич, эш беткәч, үзе килсен... Кем әле аның исеме?

Г ө р г ө р и. Бәчке инде, Бәчке.

П а л ы й. Шул бугай шул. Мин киттем инде, алайса, кем... *(Китә.)*

Г ө р п и н ә. Кит, бар, кит, саңкай карга.

Ә ү д ә к и. Кешегә алай әйтергә җарамый, Гөрпинә.

Г ө р п и н ә. Җарамагач, нигә җөрисең ике җөз җәшеңә җиткән килеш. Кешесе кеше булса. Җабалак малаена.

Ә ү д ә к и. Тик тор... Каян чыккан ул олыларга каршы сүз әйтү. Җабалакка ни булган? Карап торсаң — гәүдәсе бар. Ир булгач, аның гәүдәсе дә кирәк. Башсызын башсыз инде дә. Кәзер бөтенесе дә башсыз инде. Кич белән килсен дисеңме, Гөргөри?

Г ө р г ө р и. Сөйләштек инде, Әүдәки ти.

Ә ү д ә к и. Мине кайсыгыз илтеп куя суң өемә?

Г ө р п и н ә. Ничек килдең, шулай китәсең инде.

Ә ү д ә к и. Тик кенә тор, диләр, Айгыр Ычтапый Гөрпинәсе. Илтеп куй, Гөргөри.

Г ө р г ө р и. Кәтернә, алып чык әле бәләкәй арбаны.

Ә ү д ә к и. Җук-җук, аңарга утырып җөрсәм, эчәкләрем селкенә, күтәреп кенә илт.

Г ө р г ө р и. Бигрәк кадерле җаучы булып чыктың әле, Әүдәки ти. Кил, әйдә. *(Әүдәкине күтәреп ала.)*

Г ө р п и н ә. Миңа ни дидең, Гөргөри?

Г ө р г ө р и. Кич килсен Микушың, кич... үзе килсен. Киттек, Әүдәки әби.

Ут сүнә. Ут кабынганда, кич җиткән. Урамнан Анук җырлап үтеп бара.

Анук. Ышкаплар, ышкаплар, ай, өстендәй,
Карточкасы ышкаплар өстендәй.
Гөрли күгәрчен, гөрли күгәрчен, —
Бодайлар сибәрсең;
Кеше читләтер дә, син читләтмә,
Ыригым синең өстәлдәй.
Гөрли күгәрчен, гөрли күгәрчен,
Бәлки лә, сөярсең.

Җаграп *(Анукка каршы килеп)*. Прибет, Анук. *(Анук, аның сәламен дә алмыйча, җырын өзмичә, җулын дәвам итә. Җаграп аның җулына төшә.)* Нәстәле син гел кыланасың?

Анук. Кыланмыйм ич, җырлыйм ич.

Җаграп. Ишетәм җырлаганыңны. Ник мине күрмисең?

Анук. Менә күрдем ич инде.

Җаграп. Нигә исәнләшмисең?

Анук. Исәнләшәсем килми.

Җаграп. Ник килми?

Анук. Нәстә, Үринә эләкмәгәч, тагын мин кирәк булдыммы?

Җаграп. Кем әйтә, эләкмәде, дип?

Анук. Эләкмәячәк. Гөргөри дәй барыбер сиңа бирмәячәк Үринәсен.

Җаграп. Ә мин аңардан сорап та тормыйм.

Анук. Әй, әй, әй, сөйләгән була. Әүдәки әбине күтәреп җөргәнеңне белмиләрме әллә?

Җаграп. Мин җүри генә.

Анук. Ничек инде җүри генә?

Җаграп. Гөргөри дәй кызымны бирәм дип әйткәч, кызыңны алмыйм дип китәм дә барам.

Анук. Әй, әй, әй, сөйләгән була. Үринәне эзләп җөрисең бит инде.

Җаграп. Җук, Анук, Ябалаков Евграф Трофимович кызлар эзләп җөри торган җегет түгел ул. Кызлар үзләре аны эзлиләр.

Анук. Алайса, нигә монда болганасың суң?

Җаграп. Болганасым килгәнгә. Кая барасың?

Анук. Су буена.

Җаграп. Нишлисең анда?

А н у к. Җегетләр эзлим.

Җ а г р а п. Нәстә-ә-ә? Эзләтермен мин сиңа!

А н у к. Миндә синең ни эшең бар?

Җ а г р а п. Мужыт, мин сине җаратамдыр.

А н у к. Нәпесең зур икән.

Җ а г р а п *(агач артына ишарәләп)*. Кил әле монда.

А н у к. Бармыйм.

Җ а г р а п. Кил, диләр.

А н у к. Бармыйм, диләр.

Җ а г р а п. Нәстә, син дә җалындырасыңмы? Ачуымны китерсәгез, Пәнәчегә барырмын да Бираны алып кайтырмын, җөрерсез җылап…

А н у к. Кайтмагаең.

Җ а г р а п. Килмисеңмени?

А н у к *(Җаграпка ияреп)*. Бер тапкыр гына барам, башка бармыйм.

Агач артына посалар. Анукның чыркылдаганы ишетелә. Менә ул агач артыннан атылып чыга да җөгерә.

Җ а г р а п. Әй, кая качтың? Кил монда. *(Агачка сөялеп кала.)* Әллә шул Анукка гына өйләнергә инде? Үринәсе чибәррәк шул, кәхәр. *(Җырлап җибәргәнен сизми дә кала.)*

Әкрен кирәк, ипләп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын…

Сәхнәнең икенче читендә Б ә ч к е күренә. Өченче яктан М и к у ш керә.

Җ а г р а п *(аларны күреп)*. Әй, килегез әле монда!

М и к у ш. Әгәр дә кулың белән кагылсаң, таш алам да бәрәм.

Б ә ч к е. Мин синнән курыкмыйм, Җаграп.

Җ а г р а п. Курыкмасаң кил. Килегез, кил, тимим. *(Җегетләр сагаеп кына килгәч.)* Никәл, җегетләр?

М и к у ш б е л ә н Б ә ч к е. Җакшы.

Җ а г р а п. Үринә җанына килдегезме?

Б ә ч к е. Син кем җанына килдең суң?

Җ а г р а п. Җәле, әйбәтләп кенә сөйләш әле. Мин әйбәтләп сөйләшәм бит. Мин дә Үринә җанына килдем. Гөргөри дәй әллә ниләр уйлап чыгара бит. Сезне дә әллә Гөргөри дәй чакырганмы? Әйтегез инде, нәстә җәшергән буласыз?

Б ә ч к е. Чакырган.

Җ а г р а п. Син Палый әбине җаллаган идеңмени?

Б ә ч к е. Җалласа ни булган?

Җ а г р а п. Җә инде, эрәтләп сөйләш инде. Настроениемне бозма инде. Нишләтергә җыена икән Гөргөри дәй? Өчебезне җыеп әйтә инде, мин Үринәне Җаграпка бирәм, дип әйтәчәк инде. Сез нишлисез инде? Сез миңа ачу сакламагыз, җарыймы? Туйга акча җыясы була инде. Җегетләр, әйдәгез, бригат оештырабыз. Эчтирләт тотып, киласын унар меңнән сатсак, «бер КамАЗ» эчтирләттән, белдеңме, күпме җыябыз?

М и к у ш. Эчтирләт түгел, килкә дә тоттырмый әле сиңа.

Җ а г р а п. Нәстә-ә? Менә күрерсең. Бригат оештырып, моторлы лутты белән җәтмә сатып алабыз да... Керегез минем бригатка, җегетләр. Көймәне син сатып ал, Микуш, җәтмәне Бәчке алыр.

Б ә ч к е. Син нәстә аласың?

Җ а г р а п. Мин бригадир булам ич инде.

Б ә ч к е. Акылың котмы?..

Җ а г р а п. Хулиган син, Бәчке. Менә Микуш, ичмасам, жегет. Бар, Микуш, өеңә кайт, җөрмә бу хулиган белән. Писталит сатып алдым әле мин, җегетләр. Җегерме сигез патрон сыя көпшәсенә. Бер атканда бүрене үтереп була, белдегезме?

Үринәнең җырлаган тавышы ишетелә. Өчесе дә тораташ булып катып калалар. Гөргөри ызбасының тәрәзәсе ачыла. Анда Ү р и н ә. Җегетләр тын да алмый аның җырын тыңлыйлар.

Ү р и н ә. Кара урманнарның, ай, уртасында
Карт имәннәр кистем күмергә.
Пар үрдәкләр йөзәдер әрәмәдә-күлләрдә,
шул,
Җыен дуслар җыелышкач,
Чәчәк ата гөлләр дә, шул.
Узган гомерләрнең лә буйларында
Тату булсак иде лә без бергә.
Җыйдым җиләк, җыйдым җиләк,
Җиләктән кайтып киләм, шул,
Җир җиләге ничек тәмле —
Сезне дә шулай күрәм, шул.
Су буйларында ла йөри торгач,
Алтын тәңкә таптым — әлләли.

Җыйдым җиләк, койдым как
Бөрлегәннәре белән шул,
Без йөрибез дус-ишләрнең
Бер дигәннәре белән шул.
Алтын тәңкә безгә зур мал түгел,
Бер күрешүләре әллә ни.
Француз яулыклар киштәдә —
Бөклә дүрткә-бишкә дә шул,
Сезнең белән күрешүләр
Кермәс инде төшкә дә шул.

Үринә җырлап бетергәч, өчесе дә тәрәзә каршына барып, рәшәткәгә җабышалар. Өчесе дә бер аваз чыгаралар: «Үринә!..»

Ү р и н ә. Исәнмесез, җегетләр!
Җ а г р а п. Исәнме, Үринә!
Б ә ч к е. Никәл, Үринә?
М и к у ш. Арумы, Үринә?
Ү р и н ә. Нишләп җөрисез, ә?
Җ а г р а п. Без су буена барабыз.
Б ә ч к е. Мин синең җаныңа килдем, Үринә.
М и к у ш. Мин дә синең җаныңа килдем, Үринә.
Җ а г р а п. Алар түгел, мин синең җаныңа килдем, Үринә. Чык монда.
Ү р и н ә. Әти чыгармый шул.
Җ а г р а п. Әтиең үзе бит безне чакырткан.
Ү р и н ә. Әти чакырткач, әтине көтегез.
Б ә ч к е. Ул кайда?
Ү р и н ә. Алгы өйдә чәй эчә.

Капка артында Гөргөринең «Җап тәрәзәне!» дигән тавышы ишетелә. Үринә тәрәзәне жаба. Капкадан Г ө р г ө р и чыга.

Г ө р г ө р и . Ә-ә-ә... Кияүләр. Никәлләрегез бар, кияүләр? Ник дәшмисез? Әрмиядә начар өйрәткәннәр икән сезне. Без солдат чакта генералны «Здравие желаю, тавариш генерал!» дип кычкырып каршы алаек.
Җ а г р а п. Син генерал түгел бит, Гөргөри дәй.
Г ө р г ө р и. Генерал булмагач, ник килдегез?
Б ә ч к е. Ник чакырттың, Гөргөри дәй?
Г ө р г ө р и. Палый карчыкны син җибәрдеңме?
Б ә ч к е. Мин.
Г ө р г ө р и. Палый карчык нәстә әйтте?

Б ә ч к е. Кич белән Гөргөриләргә бар, диде.

Г ө р г ө р и. Килдеңме?

Б ә ч к е. Килдем.

Г ө р г ө р и. Нишләп мин чакыртыйм инде, шулай булгач? Үзең килгәнсең ич. Миңа сезнең берегез дә кирәкми. Өчегезгә дә мин кирәк.

М и к у ш. Үринә кирәк.

Г ө р г ө р и. И-и-и, Микуш та монда икән. Сиңа Үринә кирәкмени? Кәзер чакырабыз Үринәне, чакырабыз. *(Кычкырып.)* Кәтернә!.. Кәтернә!..

К ә т е р н ә *(тәрәзәне ачып)*. Иске киемнәрне кимим, ди.

Г ө р г ө р и. Кидер!.. Ә сез, җегетләр, рипититсия ясый торыгыз.

Җ а г р а п. Рипититсия? Нәстә ул?

Г ө р г ө р и. Барыгызның да җаучылары килдеме? Килде. Мин берсенә дә атказ бирмәдем. Барысы да әүвәлегеләр җоласы белән әйбәт итеп сөйләштеләр. Инде кәзер үзегез җарышасыз.

Б ә ч к е. Ничек җарышабыз?

Г ө р г ө р и. Ничек икәнен әйтермен, Бәчке кияү. Җарыш була. Шул җарышта кем җиңә, кыз да шуңа була.

Г ө р п и н ә *(әллә кайдан атылып чыгып)*. Андый җола җук.

Г ө р г ө р и. Син монда нишләп җөрисең? Мин сиңа килергә әйттемме?

Г ө р п и н ә. Үзем килдем. Андый җола җук. Җегетләрне җарыштыра торган җола җук бездә.

Г ө р г ө р и. Сездә булмаса, бездә бар.

Г ө р п и н ә. Сез керәшен түгелмени? Андый җола җук. Интектермә Микушны.

Г ө р г ө р и. Алып кит, алайса, Микушыңны.

Г ө р п и н ә. Китмим, алып китмим. Андый җола җук.

Җ а г р а п. Җук андый җола, Гөргөри дәй. Җарыштыра торган җола җук.

Г ө р г ө р и. Син нәстә белер-белмәс кычкырасың? Көрәшәсең килмимени Микуш белән, куркасыңмыни?

Җ а г р а п. Ә-ә... Көрәшергәмени? Алайса, бар андый җола!

Г ө р п и н ә. Кычкырма, Җабалак! Җук! Ышанмасагыз, Палый белән Әүдәкине алып килегез. Алар да әйтер, җук андый җола.

Г ө р г ө р и. Палый дисеңме? Әүдәки дисеңме? Барыгыз әле, кияүләр, тиз генә алып килегез әле.

Б ә ч к е. Мин алып килмим.

Г ө р г ө р и. Үзеңә кара, Бәчке кияү, мин җалынмыйм. Җаграп, син алып киләсеңме?

Җ а г р а п. Киләм, Гөргөри дәй, киләм. Бар андый җола. *(Китә.)*

Г ө р г ө р и. Ничек соң, Бәчке кияү? Оттырасың бит, бар тизрәк.

Б ә ч к е теләр-теләмәс кенә чыгып китә.

Г ө р п и н ә. Киттек, Микуш, бу тиле Гөргөри белән кода булганчы...

М и к у ш. Мин китмим.

Г ө р п и н ә. Микуш!.. Кемгә әйтәм. Сине Җабалактан кыйнатыр кәлем җук. Бик исем китте Үринәләренә. Аның кебекләрне мин Пәнәчедән олавы белән төяп кайтам.

Г ө р г ө р и. Төя, Гөрпинә, төя.

М и к у ш н ы җитәкләп, Г ө р п и н ә чыгып китә. Ү р и н ә н е җитәкләп, капкадан К ә т е р н ә чыга.

К ә т е р н ә. Түзеп-түзеп торам да, Гөргөри...

Г ө р г ө р и. Шуннан нишлисең инде, Кәтернә ти?

К ә т е р н ә. Артыгын кыланасың.

Г ө р г ө р и. Артыгын кылансам нишлисең инде, Кәтернә ти?

К ә т е р н ә. Кешеләрне көлдереп...

Г ө р г ө р и. Кешеләр көлсә нишлисең инде, Кәтернә ти?

К ә т е р н ә. Котыртма мине.

Г ө р г ө р и. Котыртсам нишлисең инде?..

К ә т е р н ә *(кинәт җомшап)*. Нишлисең дип... Үринә бит... Кызың...

Г ө р г ө р и. Аңа ни булган?

Ү р и н ә. Катышмыйм мин синең уеныңа.

Г ө р г ө р и. Мин уйнамыйм.

Ү р и н ә. Нигә киерттегез боларны?

Г ө р г ө р и. Алар безнең киемебез булган. Исеңә төшерер өчен. Шушы киемне киеп кияүгә бер чыккач, шул киемеңне сандыгыңа салып, ирең белән аерылмый яшәр өчен. Апаңнар кимәде, хәзер әтисез бала үстерәләр. Ише-

теп кал, әтисез бала үстерәләр. Тагын бер тапкыр әйтәм: әтисез бала үстерәләр.

Үринә. Син тапкан кияүгә барыбер чыкмыйм.

Гөргөри. Башта киявен табыйк әле, аннары карарбыз.

Әүдәкине күтәреп, Җаграп килеп керә.

Әүдәки. Нишләтәсең инде тагын, нишләтәсең, башсыз?

Җаграп. Әүдәки әби әйтә, андый җола бар, ди. Әйдә, Гөргөри дәй, кайсысы белән көрәшим? *(Җиңнәрен сызгана.)*

Гөргөри. Ашыкма, Җаграп, ашыкма.

Җаграп *(Үринә каршына килеп, сокланып карап тора)*. Үринә-ә-ә!

Үринә. Нәстә күзеңне акайттың?

Җаграп. Минеке буласың. Бәчке белән Микушны мин аны икесен бер җулы…

Бәчке Палыйны җитәкләп керә.

Бәчке. Әйдә инде, атла инде тизрәк, Палый әби.

Палый. Тукта, кума. Кем син?

Бәчке. Бәчке ич инде, бүген җаучыладың ич инде…

Палый. Кемне җаучыладым?

Бәчке. Үринәне җаучыладың ич инде.

Палый. Җаучылагач, тагын кая алып барасың?

Бәчке. Менә бит, Гөргөри дәй…

Гөрпинә Микушны җитәкләп керә.

Гөрпинә. Ә, бездән башка гынамы? Җук андый җола.

Әүдәки. Нинди җола сөйлисез?

Гөрпинә. Менә Гөргөри уйлап чыгарган. Әүвәлегеләр җоласы, ди. Менә бу малайларны көрәштерергә җыена. Кайсы җыга, Үринәне шуңа бирәм, ди. Бармы андый көрәштерә торган җола кыз өчен? Әйт, булганмы?

Палый. Нәстә турысында сөйләшәсез анда?

Гөрпинә *(Палый җанына очып килеп)*. Гөргөри малайларны көрәштереп җарыш җасый. Билгеле инде, ул Җабалак Топый малае минем Микушымны җыга.

Микуш. Нәстә инде син, җыкмаган бит әле.

Гөрпинә. Тик тор, ичмасам, ул Җабалакны җыгып буламы?

Г ө р г ө р и. Син җыктың бит әле…

П а л ы й. Нәстә сөйләшәсез анда?

Г ө р п и н ә. Андый җола җук. Кыз өчен көрәштерә торган җола җук.

Ә ү д ә к и. Күпне белмә, Гөрпинә, миннән узып… Мин әйтсәм бар дип, була. Мин кияүгә чыкканда, син әле тумаган даең. Әйт, Гөргөри, нәстә монда?..

Г ө р г ө р и. Менә, Әүдәки әби, сез бит инде өчәүләп минем кызны җаучыладыгыз. Өчегезнең дә сүзен кире какмадым. Инде нишлим? Кызым берәү генә…

П а л ы й. Нәстә сөйлисез, миңа әйтеп сөйләгез.

Г ө р г ө р и *(Палый җанына килеп)*. Кил әле, Палый ти, менә монда утыр әле. *(Палыйны утыргычка Әүдәки янына утырта.)* Җакшылап тыңла, Палый ти… Сез җаучылаган кыз берәү генә, дим, җегетләр өчәү, дим. Мин хәзер аларны җарыштырам. Кем җиңә, кыз шуңа.

Г ө р п и н ә. Андый җола җук.

Ә ү д ә к и. Булгандыр ул, кәтерлим, колакка кереп калган. Әүвәлеге заманда кызлар өчен сугышканнар да бугай әле.

П а л ы й. Нишләгәннәр?..

Ә ү д ә к и. Әй… Картайдың, Палый. Мин кияүгә чыкканда син әле курчак кына уйнап җатаең. Булган андый җола. Әйдә, Гөргөри, җарыштыр. Җарыштырсынмы, Палый?..

П а л ы й. Булган андый җола, булган.

Г ө р п и н ә. Җарый инде, җарый, җыелышып Җабалакка кыз бирәсез… Кара аны, кәрәмләшмә, Җабалак. *(Палый белән Әүдәки уртасына кереп утыра.)* Җөрисез инде шунда.

Ә ү д ә к и. Син дә җөрисең бит әле…

П а л ы й. Син кем әле?

Г ө р г ө р и. Башлыйбыз. Нык итеп карап торыгыз сез дә, түтиләр. Җәгез, кемнәрдән башлыйбыз?

Җ а г р а п. Миннән инде, Гөргөри дәй. Җә, җегетләр, кайсыгыз чыга?

Б ә ч к е *(чыгып)*. Аяк чалма.

Җ а г р а п. Сиңа аяк чалып тораммы, Бәчке?

Тотынышалар. Бераз торгач, Җаграп Бәчкене җыга. Бик горур кыяфәт белән Үринә каршыннан үтә.

Г ө р г ө р и *(Җаграпка)*. Җал итеп аласыңмы, кәзер үк көрәшәсеңме Микуш белән?

Җ а г р а п. Кәзер үк.

Г ө р г ө р и. Син, Микуш, көрәшеп торасыңмы Җаграп белән?

М и к у ш. Әни, көрәшимме?

Г ө р п и н ә. Күтәреп бәр шул Җабалакны, улым!

М и к у ш. Җарар, әни. *(Үринә каршына барып.)* Үринә, көрәшимме?

Г ө р г ө р и. Үринәне катнаштырма.

М и к у ш. Җарар, алайса. *(Җаграп белән тотышалар. Һәм шунда ук Җаграп үзе дә сизмәстән сырты белән килеп төшә. Ах итәләр, билгеле. Гөрпинә бөтен дөнҗаны җаңгырата.)*

Җ а г р а п. Дөрес түгел, дөрес түгел. Мин тотып өлгермәдем.

Г ө р г ө р и. Булды, булды. Бүтән чакта тотып өлгерерсең, Җаграп. Кәзер инде Микуш белән Бәчке... Әйдәгез.

Микуш белән Бәчке алышалар. Алышу Бәчкенең җиңүе белән тәмамлана.

Г ө р г ө р и. Ничек килеп чыкты инде бу? Бөтенесе дә берәр җыкты, берәр җыгылды.

Җ а г р а п. Җаңадан, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Җук инде, бүтән төрле җарышлар да бар. Кәзер берәм-берәм җырлыйсыз инде, җегетләр.

Җ а г р а п. Андый җола җук.

Г ө р п и н ә. Бар, бар!.. Әүвәлегеләр кыз өчен җарышканнар. Җарышканнармы, Әүдәки әби?

Ә ү д ә к и. Палый нәстә ди?

Г ө р п и н ә. Җарышканнар бит, Палый ти?

П а л ы й. Булган, булган...

Г ө р п и н ә. Башла, Гөргөри... Чык әле, Микуш улым. Җырлат, Гөргөри.

Г ө р г ө р и. Иң әүвәлеге җырны җырлап бир әле, җегет.

М и к у ш *(җырлый)*.

Читлеккәен ачып, һай, тутый кош
Очырдым ла сезнең тарафка;
Асыл җаннарым да тәрәзәсен
Ачып куяр әле жаратса, әле җаратса.
Әй, Иганә буе, әй, Эләке,
Җан тәрәзен ачыр җаратса, әле җаратса.
Искә төшсә, өзә, һай, үзәкне.

Зиһенемнең бетә эрәте, әле эрәте.
Үзе булмаса да, һай, җанымда,
Күз алдымнан китми сурәте, әле сурәте.
Әй, Иганә буе, әй, Эләке,
Күз алдымнан китми сурәте, әле сурәте.

Г ө р г ө р и. Җарый. Кайсыгыз тагын?..
Җ а г р а п. Бәчке чыксын.
Б ә ч к е *(җырлый.)*

Ай, әле бик җырактан килдек без,
Җитмеш чакрым җулны үттек без;
Ак калфакның каралган чагы,
Ак калфакның каралган чагы—
Туганнарның таралган чагы.
Җитмеш чакрым җирне, һай, үттек без,
Бер күрешер өчен килдек без;
Ак калфакның табылган чагы,
Ак калфакның табылган чагы —
Туганнарның сагынган чагы.

Г ө р п и н ә. Бу әүвәлеге җыр түгел.
Г ө р г ө р и. Кайчангы җыр?
Г ө р п и н ә. Кайчангы икәнен белмим, әүвәлеге җыр түгел.
Б ә ч к е. Ул җырны, Гөрпинә ти, беләсең килсә, Илһам Шакиров сиксән ел инде җырлый.
Г ө р п и н ә. Җарый инде, алайса, ул җырлагач, әүвәлегедер. Җә инде, җә, Җабалак, син җырла.
Г ө р г ө р и. Син, Гөрпинә, тик кенә утыр, җарыймы? Җә, Җаграп...
Җ а г р а п. Әллә җырламас дип беләсезме? *(Җырлый.)*

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләр микән көзгә?
Урманда куак кына,
Без монда кунак кына, —
Кунак булып җөрибез.
Сандугачлар китәр көзгә,
Җамансу булыр безгә.
Урманда таллык кына,
Бу безгә шатлык кына,—
Шатлык белән җәшибез.

Г ө р г ө р и. Кара, өчегез дә җарыйсы гына җырлыйсыз икән. Кәзер биисез инде, җегетләр. Китер әле гарбунны, Кәтернә. Башладык, җегетләр, «Чабата» көенә.

Җегетләр аерым-аерым да, бергә дә бииләр, арыганчы бииләр дә чирәмгә җал итәргә утыралар.

Г ө р г ө р и. Җә, түтиләр, ничек минем кияүләр?

Г ө р п и н ә. Җабалак бии белми.

Җ а г р а п. Җиттеме-җукмы сиңа, Гөрпинә ти?

Ә ү д ә к и. Берсенә дә сүзем җук. Җарый. Тик менә безнең замандагыча түгел. Алай биемиләр иде безнең заманда. Безнең заманда болай бииләр иде. Гөрпинә, Кәтернә, тотыгыз әле мине. Бастырыгыз әле җиргә.

Гөрпинә белән Кәтернә Әүдәкине култыклап алып җиргә бастыралар. Җыгылмасын өчен тотып торалар. Әүдәки аякларын боргалап биегәндәй итә.

Менә шулай бииләр иде безнең заманда, менә шулай итәләр иде. Менә шулай, менә шулай. Утыртыгыз урыныма.

Гөрпинә белән Кәтернә утырталар.

П а л ы й. Җук, Әүдәки ти. Алай итмиләр иде, болай итәләр иде. *(Таягын биетеп күрсәтә.)*

Г ө р п и н ә. Селкенмәгез әле ачу китереп... Гөргөри, әйт сүзеңне...

Г ө р г ө р и. Бу җулы да тигезләр. Бәчке әйбәтрәк әйбәтрәген...

Г ө р п и н ә. Җаклама Бәчкене. Гел шуны җаклыйсың.

Ә ү д ә к и. Җегетләрне биеттең дә, Гөргөри, кызыңның биюен күрмәдек бит әле. Җәле, күрсәтсен әле, кемне җаучылап җөрибез икән? Шулаймы, Палый?

П а л ы й. Нәстә дисең?

Ә ү д ә к и. Әнә Палый да шулай ди.

Г ө р г ө р и. Күрсәтербез аны, Әүдәки ти. Җәле, Үринә.

Ү р и н ә. Биемим.

Г ө р г ө р и. Кемгә әйтәм?!

Ү р и н ә. Мин бии белмим.

Г ө р г ө р и. Беләсең.

Ү р и н ә. Белмим.

А н у к. Уйна, Гөргөри дәй, үзем биеп күрсәтәм. *(Ул әлегә хәтле капка төбендәге җарышны агач артыннан күзәтеп торган иде.)* Уйна. *(Гөргөринең уйнаганын да көтмичә, үзе җырлап, үзе биеп китә.)*

Ү р и н ә. Агыйдел суы тирбәлә
Уртасында сал булса;
Суга салсаң калкып чыгар,
Безгә насыйп җар булса.
Их, тала, тала, тала,
Тала минем беләгем;
Нигә тала, нигә җана
Икән минем җөрәгем?
Талмас иде беләккәем,
Талдыручы булмаса;
Җанмас иде җөрәккәем,
Җандыручы булмаса...

Бии-бии дә чыгып җөгерә. Аңа Җаграп иярмәкче була да «кияү» икәнлеге исенә төшеп туктап кала. Анукның кыланышы Үринәнең дә кытыгын китерә, ул да сикереп чыгып такмак әйтә-әйтә бии.

Кара урманда бөрлегән,
Чәчәкләре бер дигән;
Нишләп җөрим берәү белән,
Сынап карыйм төрледән.
Их, тала, тала, тала,
Тала минем беләгем;
Нигә тала, нигә җана
Икән минем җөрәгем?
Талмас иде беләккәем,
Талдыручы булмаса;
Җанмас иде җөрәккәем,
Җандыручы булмаса.

Үринә биеп туктап, үз урынына утыра.

Ә ү д ә к и. Туй булды бит бу, Гөргөри. Туй булды бу, Кәтернә.

Г ө р г ө р и. Туй болай гына булмаячак, Әүдәки ти.

Ә ү д ә к и. Без җәш чакта...

Г ө р п и н ә. Җәш чагыңны аннары сөйләрсең, Әүдәки ти. Гөргөри, сүзеңне әйт.

Г ө р г ө р и. Әйтәм, Гөрпинә, әйтәм. Микушны курламыйм. Быламык дип йөри ием дә, түгел икән. Җаграп та җарыйсы, Бәчке дә әйбәт.

Г ө р п и н ә. Тагын Бәчкене данныйсыңмы?..

Г ө р г ө р и. Мин үземә ошаганын данныйм, Гөрпинә. Җарый, тагын да җарыштырып карамакчы ыем да, калып торсын. Инде болай була. Калынны кайсысы күбрәк түли, кыз шуңа була инде.

Г ө р п и н ә. Нинди калын тагын?

Г ө р г ө р и. Әүвәлегеләр җоласы.

Г ө р п и н ә. Әллә ниләр уйлап чыгарма, Гөргөри. Кәтернә, син нигә бер сүз дә дәшмисең? Нишли бу синең лилипутың?

К ә т е р н ә. Мыскыл итмә, Гөрпинә, үзеңнеке да әллә кем түгел. Безнең Гөргөри бөтенесен дә белә. Ул ни әйтсә, шул булыр.

Г ө р п и н ә. Әйт, Гөргөри, нәстә ул калын дигәнең?

Г ө р г ө р и. Әнә Әүдәки ти белән Палый ти әйтсен.

Г ө р п и н ә. Әйт, Әүдәки ти. Нәстә сөйли ул Гөргөри?

Ә ү д ә к и. Бик белеп сөйли. Әүвәлегеләр кызны калын түләп алганнар.

П а л ы й. Булган андый җола, булган.

Г ө р п и н ә. Акча түләпме?

Ә ү д ә к и. Акча гына түгел.

Г ө р п и н ә. Нәстә, кызыңны сатып бирәсезмени, Гөргөри?

Г ө р г ө р и. Сатып бирмибез, җола кушканча бирәбез. Әүвәлегеләр шулай эшләгән.

Г ө р п и н ә. Алар күпме түләргә кушкан инде?

Г ө р г ө р и. Күпме икәнен әйтеп калдырмаганнар. Анысын үзебез әйтәбез.

Г ө р п и н ә. Күпме инде?

Г ө р г ө р и. Күп, Гөрпинә.

Г ө р п и н ә. Күпнең дә чиге була, Гөргөри.

Г ө р г ө р и. Акчасын кәзер түләсәгез, жарты милиун.

Г ө р п и н ә. Җарты милиун?!

П а л ы й. Нәстә сөйләшәсез?

Г ө р п и н ә. Җарты милиун, ди...

П а л ы й. Нәстәгә җарты лимун?

Ә ү д ә к и. Тыңлап кына утыр, Палый. Болары безнең башка сыймый.

Г ө р г ө р и. Кәзергә генә шулай. Кәзер түләмәсәгез,

әрбир каклары үскән саен, калын акчасы да арта барыр. Мужыт, бер милиун булыр, мужыт, ун милиун.

Җаграп. Ун милиун?!

Гөргөри. Ун милиун, Җаграп. Әзрәкме әллә? Шуның өстенә миңа эче җонлы тун, Кәтернәгә тышы җонлы тун.

Гөрпинә. И-и-и, и-и-и...

Гөргөри. Ашыкма, Гөрпинә. Ике баш сыер, бер баш тана, сигез баш сарык.

Бәчке *(көлеп)*. Өстә, әйдә, Гөргөри дәй, өстә.

Гөргөри. Син көлмә, Бәчке, мин бит чынлап әйтәм. Шулар өстенә өч көпчәкле мотоцикл.

Гөрпинә. Кодаем! Нишләвең, Гөргөри?..

Гөргөри. Синнән күбрәк тә тиеш әле, Гөрпинә.

Гөрпинә. Анысы нигә инде?

Гөргөри. Телең бик әче. Синең килененң булып җәшәүләре, ай-яй!

Гөрпинә. Җәшәп караганың җук бит, нигә мыскыл итәсең?

Бәчке. Алай җарамый бит, Гөргөри дәй. Калын алырга җарамый.

Гөргөри. Кем әйтте җарамый дип? Өйрәндегез бушка кыз алып. Бушка алалар да биш көннән аерып җибәрәләр. Бушка килгән нәрсәне ыргыту җәл түгел шул. Җук инде, түләп алып карагыз. Җаратасың икән, түләп ал.

Җаграп. Закон бар, Гөргөри дәй. Мин беләм, бер үзбәк сөйләде, закон бар, диде.

Гөргөри. Син законга өйләнерсең, җарыймы, Җаграп? Син, Микуш, нигә бер сүз дәшмисең?

Гөрпинә. Ник дәшсен? Дәшерлек иттеңмени? Дәшмибез, Гөргөри. Син әйткән акчага каладан бер олау марҗа төяп кайтабыз. Әйдә, Микуш.

Микуш. Гөргөри дәй, син чыннан да чынлапмы?

Гөргөри. Чынлап, Микуш, чынлап.

Гөрпинә. Әйдә, Микуш...

Әүдәки. Әй, күңелле генә утыраек, әллә нишләттең, Гөргөри. Бигрәк кыйбат.

Гөргөри. Минем кызым арзан түгел. Бер тиен дә төшмим. Уйлагыз, җегетләр, уйлаганнарыгыз иртәгә килеп әйтер.

Микуш. Мин уйладым, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Нәрсә уйладың, Микуш?

М и к у ш. Мин риза.

Г ө р п и н ә. Микуш!..

Г ө р г ө р и. Ашыкма, Микуш. Ныклабрак уйла. Иртәгә шушы вакытта әйтерсең. Бергәләп килегез.

Ут сүнә. Ут җанганда Җ а г р а п керә, рәшәткә җанына килә, Анукның җырлаганын ишетеп, агач янына барып сыена. Җырлап А н у к керә.

Җ а г р а п *(Анук җулына аркылы төшеп).* Прибет, Анук. Нәстә, тагын исәнләшмисеңме, тагын мине күрмисеңме?

А н у к. Син мине күрәсеңме суң?

Җ а г р а п. Күрәм.

А н у к. Син күргәч, шул җиткән.

Җ а г р а п. Кыланма инде.

А н у к. Нәстә, Үринә бик кыйбат булгач, арзан Анук җанына килдеңме?

Җ а г р а п. Мин килмәдем, син очрадың.

А н у к. Үринәгә акча алып килдеңме? Сыерың белән танаң кайда сун? Эләктеме инде Үринә? Син ул сораган әрбирләрне мәңге табасың җук.

Җ а г р а п. Көлмә. Ачуны китерсәң, балыкчылар бригадасы төзим. Бер КамАЗ эчтирләт тотып сатам да. Киласы унар меңнән... Кая барасың?

А н у к. Су буена.

Җ а г р а п. Көн дә көн дә нишлисең анда?

А н у к. Көн дә, көн дә түгел, төн дә, төн дә...

Җ а г р а п. Төн дә, төн дә нишлисең?

А н у к. Сине көтәм.

Җ а г р а п. Мин килмимме?

А н у к. Килмисең шул.

Җ а г р а п. Сине Үринәдән артыграк җарата башлагач килермен, җәме?

А н у к. Җә. Сау бул.

Җ а г р а п. Тукта инде...

А н у к. Нишлибез?

Җ а г р а п. Син Үринәдән әйбәтрәк биисең, Анук.

А н у к. Мин аны син әйтмәсәң дә беләм.

Җ а г р а п. Су буенда нишләп утырасың, Анук?

А н у к. Аккан суга карап утырам.

Җ а г р а п. Ник?

А н у к. Кызык.

Җ а г р а п. Мин сине җарата башладым әле, Анук.

А н у к. Рәкмәт инде.

Җ а г р а п. Кил монда, Анук. *(Агач артына чакыра.)*

А н у к. Нишлибез анда?

Җ а г р а п. Беләсең ич инде.

А н у к. Оныттым.

Җ а г р а п. Җә инде, беләсең...

А н у к. Бер үпкәнең өчен — бер милиун. Ике үпсәң, өстәвенә ике сыер.

Җ а г р а п *(рәкәтләнеп көлә).* Үтерәсең син, Анук.

А н у к. Үләсе көнең алда әле, Җаграп. Әнә тәрәзәдән минем белән сөйләшкәнеңне катының карап тора.

Җ а г р а п. Ачуны китерсәләр өйләнмәм дә әле. Тотармын да сиңа өйләнермен.

А н у к. Әгәр мин чыкмасам?

Җ а г р а п. Син чыгасың. Кил инде мондарак.

А н у к. Җук, Җаграп. Анда бармыйм. Үпсәң, менә шушында үп.

Җ а г р а п. Ничек инде. Үринә карап торса?..

А н у к. Торса тора инде.

Җ а г р а п. Әллә куркыр дип уйлыйсыңмы?

А н у к. Уйламыйм.

Җаграп аны кочаклап үбеп ала. А н у к көлә-көлә чыгып җөгерә, Җаграп рәшәткә каршына килеп сызгыра.

Б ә ч к е *(кереп).* Мин монда, Җаграп.

Җ а г р а п. Ә-ә-ә, Бәчке. Прибет. Җә, алып килдеңме калын?

Б ә ч к е. Син алып килдеңме сун?

Җ а г р а п. Җә инде, җәшергән булма. *(Микушны күреп.)* Әнә бит килә. Моңарда инде байлык. Әниең кайда, Микуш?

М и к у ш. Син бәйләнмә миңа. Таш белән алам да бәрәм.

Җ а г р а п. Бәреп кара. Җыктым дигәч тә. Җалгыш кына җыгылдым мин. Әйдә, көрәшәбез. *(Микушны эләктереп ала.)*

Г ө р г ө р и *(капкадан чыгып).* Никәл, җегетләр?

Җ а г р а п. Прибет, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Исәнме, исәнме... Җә, ни уйладыгыз? Син ни уйладың, Җаграп?

Җ а г р а п. Уйладым мин болай: көтәргә биреп тор Үринәне.

Г ө р г ө р и. Ничек инде көтәргә?

Җ а г р а п. Әҗәткә... Бурычка... Өйләнгәч түләрмен. Мин балыкчылар бригадасы төзим. Бер КамАЗ эчтирләт тотып сатам да... Килосы унар меңнән...

Г ө р г ө р и. Эчтирләтеңне саткач килерсең, Җаграп, җарыймы?

Җ а г р а п. Алайса, үзеңә кара, Гөргөри дәй. Үринәне бәхетсез итәсең килсә... Ул бит миннән башка берәүне дә җаратмый. Мине үлеп җарата.

Ү р и н ә *(тәрәзәне бәреп ачып)*. Җаратмыйм! Җаратмыйм! *(Тәрәзәне җабып куя. Тагын ачып кычкыра.)* Җаратмыйм! *(Тагын җаба.)*

Җ а г р а п. Җаратма, әйдә, җаратма... Җарты милиун акчам булса, өйләнеп тормас идем әле. Әнә Бәчке өйләнсен акча түләп...

Г ө р г ө р и. Җарый, булды. Җә, Бәчке?

Б ә ч к е. Син чынлап әйттеңме, Гөргөри дәй?

Г ө р г ө р и. Чынлап, Бәчке.

Б ә ч к е. Синең белән Үринә дә килештеме?

Г ө р г ө р и. Килеште.

Б ә ч к е. Калын түләсәм чыгамы?

Г ө р г ө р и. Чыга.

Б ә ч к е. Үзе теләпме?

Г ө р г ө р и. Үзе теләп.

Б ә ч к е. Үринә үз теле белән әйтсен.

Г ө р г ө р и. Нәстә дип әйтсен?

Б ә ч к е. Әгәр дә Бәчке эти сораган калынны түләсә, үзем теләп Бәчкегә чыгам, дисен.

Г ө р г ө р и. Әй, Үринә! Үринә, дим!

К ә т е р н ә *(тәрәзәдән)*. Нәстә инде тагын?

Г ө р г ө р и. Үринәне чакыр. *(Үринә тәрәзәдә күренгәч.)* Үринә, әйт, әгәр дә Бәчке эти сораган калынны түләсә, үзем теләп Бәчкегә чыгам, диген.

Ү р и н ә. Чыкмыйм.

Г ө р г ө р и. Үринә!..

Ү р и н ә. Чыкмыйм.

Г ө р г ө р и . Син нитмә, Бәчке, курыкма. Чыгарам мин аны.

Б ә ч к е. Җук инде, Гөргөри дәй. Шулчаклы калын түләп җаратмаган катын алып булмас.

Җ а г р а п. Дөрес, Бәчке. Пәнәчегә барабыз да үзебез сайлап алабыз.

Г ө р г ө р и. Бәчке! Мужыт, уйларсың, ә?

Б ә ч к е. Җук, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Уйла әле, Бәчке, уйла әле.

Б ә ч к е. Җук.

Г ө р г ө р и. Җегет түгел икәнсең, Бәчке. *(Микушка.)* Җә, син нәстә?

М и к у ш. Мин — риза.

Г ө р г ө р и. Нәстәгә риза?

М и к у ш. Калын түләргә!

Г ө р г ө р и. Әниең әйтәме?

М и к у ш. Үзем.

Г ө р г ө р и. Акчаң шулай күпмени?

М и к у ш. Җук. Эшләрмен, көне-төне эшләрмен. Җыярмын. Көтсен генә Үринә. Ике-өч җыл көтсен генә.

Г ө р г ө р и. Әй, Үринә, ишетәсеңме?

К ә т е р н ә. Ишетә, ишетә.

Г ө р г ө р и. Нәстә ди?

К ә т е р н ә. Көтмим, ди.

М и к у ш. Көтмәсен. Мин барыбер калын алып киләм. Алып киләм дә сиңа бирәм, Гөргөри дәй, мә, дим.

Г ө р г ө р и. Шулай ук җаратасыңмыни Үринәне?

М и к у ш. Җаратам.

Г ө р г ө р и. Кәтернә!

К ә т е р н ә. Ишетә инде, ишетә.

Г ө р г ө р и. Алып чык монда.

К ә т е р н ә. Чыкмыйм, ди.

Г ө р г ө р и. Алып чык! Үзем кереп сөйрәп алып чыгам. *(Бәчке белән Җаграпка.)* Нәстә карап торасыз, җегетләр?

Җ а г р а п. Нишләрсең икән дип, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Син әле нишлисемне белмисеңме, Җабалак? *(Капкадан чыккан Үринәне кулыннан тотып, Микушка бирә.)* Ал, җегет. Кыз — синеке. *(Үринәгә.)* Карама Топый малаена. Җегет түгел ул. Җегет түгел алар. Китегез, китегез минем ызбам җаныннан.

Җ а г р а п. Син чамалап кына, Гөргөри дәй.

Г ө р г ө р и. Китегез. Мылтыгымны алып чыгам да икегезне дә атып үтерәм.

Җ а г р а п. Бик исебез китте. Әйдә, Бәчке, су буена.

Китәләр.

Г ө р г ө р и *(Микушка)*. Син нәрсә җебеп торасың? Тот нык кына итеп, җараткач. Нык тот, җибәрмә.

Ү р и н ә. Калыны җук бит.

Г ө р г ө р и. Булыр. Кәтернәгә бер чәчәкле җаулык алып бирсә, шул җиткән. Киттек, Кәтернә.

Кереп китәләр.

М и к у ш. Үринә... Мин җаратам бит сине.

Ү р и н ә. Беләм ич инде... Җаграпны син чынлап җыктыңмы?

М и к у ш. Синең өчен мин, Үринә, дию пәриен дә җыгам.

Ү р и н ә. Мактанма инде.

М и к у ш. Менә күрерсең, Үринә, мин... Мин... Җаратырсың син мине...

Ү р и н ә. Мин сиңа җаратмыйм дигәнем дә җук.

М и к у ш. Җук шул, Үринә, җук шул.

Ү р и н ә. Җырла әле теге җырыңны.

М и к у ш. Кайсын, Үринә?

Ү р и н ә. Минем өчен җарышканда җырлаганны.

Микуш җыр башлый.

П ә р д ә.

# ЙӨРӘК МАЕМ

*(Ике пәрдәле этнографик комедия)*

К а т н а ш а л а р:

А л ә ү е т д и н — Әцәт авылы кешесе, 50 яшьләрдә.
А й ш ә б и к ә — Аләүетдиннең хатыны, иреннән ике-өч яшькә яшьрәк.
А й м ә т — аларның улы, 20 яшь тирәсе.
А с и м ә — Аләүетдиннең авылдашы, 85 яшендә.
А л и я, С а н и я, Х а н и я — Асимә карчыкның оныклары.
М и ң н у р ы й — Айшәбикәнең сеңлесе.
М и ң с ы л у — Айшәбикәнең апасы.
Ү м ә р — Аләүетдиннең баҗасы.

Комедия татар теленең мишәр диалекты Сергач сөйләшендә язылды.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Аләүетдин йорты каршындагы күл буе. Бөдрә таллар. Матурлык. А л ә ү е т д и н шул матурлык уртасына утырган да гармун уйный. М и ң н у р ы й күренә, Аләүетдиннең уйнавын бирелеп тыңлый. Аләүетдин, аны күреп алып, уйнавыннан туктый.

А л ә ү е т д и н. Исәнме, Миңнури!
М и ң н у р ы й. Балдыз, диген Аләүетдин езни. Саумы, Аләүетдин езни! Бозау бәләп катеп килә идем, унавыңны иштем дә... Уня инде, уня.
А л ә ү е т д и н. Әз генә багып торим үзеңә.
М и ң н у р ы й. Картайдым инде, Аләүетдин езни. Багарлыгым юк.

А л ә ү е т д и н. Картайсаң да ямьне син, балдыз.

М и ң н у р ы й. Айшәбикә тутай да ямьне бит.

А л ә ү е т д и н. Айшәбикә дә ямьне. Икегезне дә сүә идем бит, балдыз.

М и ң н у р ы й. Тутайны салядың шыл. Миңа насип булмадың.

А л ә ү е т д и н. Алимың да бик яхшы, Миңнури балдыз.

М и ң н у р ы й. Ходайга шөкер. Уня, Аләүетдин езни, уня.

А л ә ү е т д и н. Алим үдәме?

М и ң н у р ы й. Мәскәүгә китте. Абзиларга.

А л ә ү е т д и н. Мин дә китәм, Миңнури. Дальний Вастукка, Япониягә. Хат язырсыңмы, Миңнури? Тихакянда моряк булганда язган идең.

М и ң н у р ы й. Онытмисың.

А л ә ү е т д и н. Онытырга ярами, Миңнури.

М и ң н у р ы й. Балдыз, диген, Аләүетдин езни.

А л ә ү е т д и н. Онытырга ярами, балдыз. Яшь цакларын оныткан кеше — бәхетсез. Мыний яшь цаклар искә төште. Киц белән шында цык, Миңнури. Ерларбыз, биербез. Яшь цакларны искә төшерербез. Төнә кызыңны күрдем, үзең кебек ямьне. Туган булмасагыз малайга алыр идек кызыңны, кода-кодаги булып торыр идек.

М и ң н у р ы й. Езни белән балдыз булып торик, Аләүетдин езни. Син уня. Вакытым юк, берсәк тыңлим да китәм. *(Аләүетдин уйный, Миңнурый бөдрә талга сөялеп тыңлый. Түзмичә, «Таң җилләре исәр...» көенә җырлап та ала.)*

Таң җилләре исәр, исмәс димә,
Бәлки, алар сезгә кагылмас.
Таң җилләре беләν эзләсәң дә,
Узган яшь үмерләрең табылмас.

Сау бул, Аләүетдин езни! *(Китә.)*

Аләүетдин аның киткәнен сизми дә уйный. А й ш ә б и к ә кереп, Аләүетдиннең кыланмышына аптырап карап тора. Аләүетдин игътибар итмәгәч, каршына ук килеп басып иренә күзен теки.
Аләүетдин алай да күрмәгәч, Аләүетдиненә иелеп карый.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин... *(Аләүетдин игътибар итмәгәч.)* Аләүетдин, син мине кюрәсеңме? *(Тавышын күтәреп.)* Аләүетдин!.. Йерәк маем!

А л ә ү е т д и н *(сискәнеп куя. Уйнаудан туктый).* Ә?..

А й ш ә б и к ә. Нишлисең син?

А л ә ү е т д и н. Ә?..

А й ш ә б и к ә. Нишлисең? Иртә таңнан үдән цыгып китеп кюл буенда гармун тартып утырасың. Багам — юк. Яри гармуныңның тавышы бар.

А л ә ү е т д и н. Яшь цаклар искә төште, Айшук.

А й ш ә б и к ә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин, йерәк маем. Яшь цагыңны син көндез уйлама, төннә уйлап ят. Мине коцакла да уйла. Көндез эш бар.

А л ә ү е т д и н. Пред миңа ян тартырга бирде. Цәцү бетте, уракка цаклы берсәк ян тарт, Аләүетдин абзи, диде.

А й ш ә б и к ә. Синең өцен мин — пред, Аләүетдин, ерәк маем. Белмисеңме, оныттыңмыни, җанкисәгем... Адә кать үгә, куй гармуныңны урынына. Әцәтне суярга кирәк.

А л ә ү е т д и н. Нәк?

А й ш ә б и к ә. Күрше тавыклары янына ери. Үзебезнең тавыкларны бар дип тә белми.

А л ә ү е т д и н. Аның өцен нигә әцәтне суярга? Әцәтне яннарында тоталмаган тавыкларны суярга кирәк.

А й ш ә б и к ә. Нәрсә сүлисең син, Аләүетдин... Адә, мин күрше тавыклары яныннан әцәтне тотып катям. *(Җилләнеп чыгып китә.)*

Аләүетдин утырып кала. Янәдән гармун уйный. Уйнаганына кушылып җырлый да.

А л ә ү е т д и н. Таң җилләре исәр, исмәс димим,
Бәлки алар сезгә кагылмас.
Таң җилләре белән эзләсәң дә,
Узган яшь үмерләрең табылмас.

Бакча ягында тавыкларның пыр тузып кытаклашканнары ишетелә. Кып-кызыл кикрикле әтәчне култык астына кыстырып, А й ш ә б и к ә керә. Тагын аптырап Аләүетдингә карап тора.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин...

А л ә ү е т д и н. Ә?..

А й ш ә б и к ә. Мин сиңа ни атьтем?

А л ә ү е т д и н. Кать, дидең.

А й ш ә б и к ә. Катьтыңмы?

Аләүетдин. Онытканмын, Айшук. Яшь цаклар искә төште бит.

Айшәбикә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин... Яшь цакларыңны искә алып картайтасың син мине, йерәк маем. Мин түзеп-түзеп торырмын да шартлармын, Аләүетдин. Атом бомбасыннан бер дә ким булмас. Бир әле гармуныңны.

Аләүетдин. Бирмим.

Айшәбикә. Аләүетдин, йерәк маем, нишлисең? Әцәтне суярга кирәк. Тизрәк. «Трапиканка» башлана.

Аләүетдин. Вата Абдрахманнан суйдыр.

Айшәбикә. Мине бит Абдрахман тегел, син коцаклыйсың. Абдрахман суйган әцәт итен иялмица ашар идеңме?

Аләүетдин. Һаман әцәт, әцәт... Сыер, бозау, пецән, картош. Мин гармун уняма келим. Миңа утпыскы бирде пред, аңнисыңмы — утпыскы.

Айшәбикә. Илледә гармун унямилар, Аләүетдин.

Аләүетдин. Кырыкта да унятмадың, утызда да унятмадың. Һаман тавык, тавык, әцәт...

Айшәбикә. Син тилергәнсең, Аләүетдин, йерәк маем. Бальниска бар.

Аләүетдин. Барырмын да. Котылырсың миннән.

Айшәбикә. Нәрсә сүлисең син, Аләүетдин, бәгырькәем. Сиңа мин котылырга цыктыммы? Өц ылан үстереп. Илле яшеңдә. Тиресләнмә, Аләүетдин. Бир гармуныңны. Мә, тот, әцәтне. Бир, йерәк маем, бир. Киц белән туйганцы унярсың. Бир, Аләүетдин, бир. Йә инде, «Трапиканка» башлана, Аләүетдин. *(Әтәчне Аләүетдин кулына биреп, гармунны алмакчы була.)*

Аләүетдин. Тимә гармунга. Алып цык пыцагыңны.

Айшәбикә. Шындамы?

Аләүетдин. Әцәт суярга үгәме керип торим?

Айшәбикә. Тилермә, Аләүетдин...

Аләүетдин. Алайса, суймим да әцәтне.

Айшәбикә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин, картайтасың мине. *(Китә.)*

Аләүетдин *(әтәч белән сөйләшә)*. Нәрсә, суялармыни, брат? Шылай инде, шылай, егет булсаң, суялар. Күрше тавыгы ямьнерәк инде ул, ямьнерәк. Син мине аеплама инде, брат. Мин тегел бит, вата Айшәбикә апаң. Бик дерес яшәмә кели Айшәбикә апаң. Мулла

кушканца гына яшәмә кели. Сиңа да, миңа да бик кыен инде алай яшәве. Яри әле мине суймыйлар. Аеплама инде, брат.

Айшәбикә *(пычак алып килә)*. Мыний пыцак, мыный аякларын бәләргә еп. Бисмилланңы атергә онытма, Аләүетдин... Куй инде гармуныңны.

Аләүетдин. Тавыкларың ямьсез булганга әцәтнең ни аебы бар?

Айшәбикә. Аләүетдин, ацуымны цыгарма. Егерме биш тавык етмимени анарга. Күпме атьтем үзенә. Сад бакцасында үзебезнең тавыклар сине көтеп зар елаша, син гулятьта ерисең, дидем. Суй, Аләүетдин, суй. Бөген ыланыбыз Аймәт тә катя, әцәт ите белән силарбыз.

Аләүетдин *(әтәчне култык астына кыстырып сөйләнә)*. Да, брат, шылай инде безнең хальләр, әцәтне әцәттән суйдыралар. *(Әтәчне суярга әзерләнә.)*

Айшәбикә. Нишлисең, Аләүетдин?..

Аләүетдин. Әцәт суям.

Айшәбикә. Юлда әцәт суялармы. Циткәрәк кит. Бәлә аякларын. Ать бисмилланңы.

Аләүетдин читкәрәк китә. Айшәбикә кемнеңдер үтеп барганын күрә дә кулын изәп, Аләүетдинне чакыра.

Аләүетдин!.. Аләүетдин!.. Аләүетдин, цукынцык...

Артта әтәчнең Аләүетдин кулыннан ычкынып кычкыра-кычкыра качканы ишетелә. Аләүетдин керә.

Аләүетдин. Ни бар?

Айшәбикә. Кил, кил бире.

Аләүетдин. Әцәтне куркыттың, вата кацты.

Айшәбикә. Куй шыл әцәтне. Вата бак, кем анда суга бара. Бактыңмы?

Аләүетдин. Ницек багим, арбаңны ал юлдан. *(Айшәбикәне читкәрәк этеп карый.)* Абдрахманның төпцек кызы тегелме ул?

Айшәбикә. Шыл үзе бит инде, Аләүетдин, йерәк маем.

Аләүетдин. Как үзе?

Айшәбикә. Безнең булацак киленебез. Аймәтебезнең катыны.

Аләүетдин. Как катыны? Үләнгәнцәме?

Айшәбикә. Үләнмәсә, үләнер. Үләндерәбез. Бу катьканында аягын кулын бәләп үләндерәбез.

А л ә ү е т д и н. Юкны сүләмә. Анарга әлдә егерме яшь тә тулмаган.

А й ш ә б и к ә. Тиле цагында үләнеп калсын. Акыл кергәц үләнмиләр алар.

А л ә ү е т д и н. Уки.

А й ш ә б и к ә. Укысын. Укып бетергәнен катыны безнең үдә көтеп торыр. Казан кызлары тотып алганцы үләндерәбез. Күзеңне ацыбрак бак, Абдрахманның кызына. Ницек?

А л ә ү е т д и н. Калынрак тегелме?

А й ш ә б и к ә. Калын булса, ни булган?

А л ә ү е т д и н. Үгә ницек сыярсыз?

А й ш ә б и к ә. Калын малда бәрәкәт, Аләүетдин. Үзең дә коцагымда эреп ятасың. Скилит булсам, кем елытыр үзеңне.

А л ә ү е т д и н *(икенче бер кызны күреп алып)*. Вата!.. Вата мынийсы кыз дисәң кыз.

А й ш ә б и к ә. Кемне атәсең, Аләүетдин?

А л ә ү е т д и н. Вата кыз! Вата килен! Шыны алабыз, Айшә.

А й ш ә б и к ә. Кем ул, Аләүетдин, күрмим.

А л ә ү е т д и н. Вата үвеннән цыкты. Фәйзинең уртанцы кызы. Ай-ай... Бак син аны, бак...

А й ш ә б и к ә. Сүләмә, Аләүетдин. Анасы миннән дә явыз.

А л ә ү е т д и н. Синнән явыз катын буламы, Айшук. Син явызларның президенты, Айшук. Бак, Айшук, бак!.. Как атлап килә! А-а-а!.. Кыр кәзәсе кебек... А-а-а... Кыз цакта син шындый идең. Айшук. Вата кыз! Вата килен!.. *(Соклануына түзә алмый.)* Бак син аны, Айшук, бак...

А й ш ә б и к ә. Адә, катябыз.

А л ә ү е т д и н. Ни булды, Айшә абыстай?

А й ш ә б и к ә. Сиңа кыз багарга ярами. Безнең әцәттән дә яман.

А л ә ү е т д и н. Юк инде, Айшук. Нигә инде син... Абдрахманның кызы калынрак.

А й ш ә б и к ә. Аймәтебез дә юка тегел. Торма каршымда, кит. Ай, Аләүетдин, Аләүетдин. Ни явызлык кылдым сиңа, йерәк маем? Нигә мине рисвай иттең?

А л ә ү е т д и н. Как иттем? Как иттем мин сине?

А й ш ә б и к ә. Явызларның президенты дидең *(елый ук башлый).*

Аләүетдин. Вата... вата... Мин бит сүвеп кенә атьтем, Айшәбикә.

Айшәбикә. Сүмисең син мине, Аләүетдин.

Аләүетдин. Как сүмим?..

Айшәбикә. Миңнурины сүәсең.

Аләүетдин. Сүсә ни. Ул бит синең сеңелең?

Айшәбикә. Син аны балдыз диеп сүмисең.

Аләүетдин. Юк, Айшәбикә, Миңнурины балдыз диеп сүвәм, сине катын диеп сүвәм. Миңнуриның Алиме бар.

Айшәбикә. Әцәтне дә син үзең белеп ебәрдең. Үзеңә ибдәш булсын диеп ебәрдең. Кызларга багасың. Картаеп беттең, кызларга һаман багасың.

Аләүетдин. Үзең цакырдың, Айшук. Әцәтне кацырып цакырдың.

Айшәбикә. Мин сине кызлар багарга цакырмадым.

Аләүетдин *(Алия, Сания, Ханиянең чиләк-көянтә күтәреп үткәнен күреп)*. Айшук, бак. Вата кызлар! Өцәү. Һай-ай-ай! Асимә карцыкның нукларымы алар? Шыларны алыйк, Айшук, Аймәткә.

Айшәбикә. Һай, Аләүетдин... Вата азгын, вата азгын.

Аләүетдин. Абдрахманның кызы калынрак, Айшук.

Айшәбикә. Кать үгә. Цыкма да үдән. Мин сине үгә ябып куям.

Аләүетдин. Мыний ансы булмый, Айшук. *(Гармунын алып китә башлый.)*

Айшәбикә. Кая барасың?

Аләүетдин. Китәм.

Айшәбикә. Кая, Аләүетдин?

Аләүетдин. Дальний Вастукка, Япониягә. Син мине куып тоталмаган ергә.

Айшәбикә. Тагын шыл Япунияңне башладыңмы?

Аләүетдин. Башладым. Узган ел сине кызганып китми калдым. Бу ел китәм.

Айшәбикә. Куркытма инде, Аләүетдин. Син куркытсаң, мин куркам бит.

Шулчак атылып сиксән биш яшьлек Асимә карчык керә. Керә дә, Аләүетдин белән Айшәбикә каршына басып, таянып йөри торган таягын Аләүетдингә төзи.

А с и м ә. Хак атәләрме? Дересме?

А л ә ү е т д и н. Ни булды, Асимәттай?

А с и м ә *(таягын Айшәбикәгә төзәп)*. Дересме? Хак атәләрме?

А й ш ә б и к ә. Туктале, Асимәттай...

А с и м ә. Туктамим. Хак атәләрме? Ыланыгызны үләндерәсезме? *(Аләүетдингә.)* Үләндерәсезме?

А л ә ү е т д и н. Мин тегел, вата Айшәбикә үләндерә. *(Бер читкә китеп утыра.)*

А с и м ә *(Айшәбикәгә)*. Үләндерәсезме?

А й ш ә б и к ә. Кем атьте аны сиңа, Асимәттай?

А с и м ә. Кем атькәнен тикшермә. Дересме?

А й ш ә б и к ә. Дерес булса ни булган?

А с и м ә. Кемнең кызына?

А й ш ә б и к ә. Белмибез әлдә.

А с и м ә. Как белмисез? Ыланнарын үләндерергә ериләр, кемгә икәнен белмиләр. Миннән яшерәсезме?

А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең, Асимәттай?..

А с и м ә. Үзең сүләгәнсең Абдрахман катынына. Ыланыбызны үләндерәбез, диепсең. Үзебезнең авыл кызына, диепсең. Циттән берәүне дә кертмибез, диепсең.

А й ш ә б и к ә. Дисә ни булган?

А с и м ә. Как ни булган? Авылда безнең үнең барлыгын оныттыңмы? Безнең нәселнең барлыгын белмисеңме? Самакайлар нәселеннән кызларның кемнәр икәнен истән цыгардың? Без — бөтен тирә-якта дан тоткан нәсел. Безне, Мәскәүгә, Петербурга баргач, тройка беләнкаршы алганнар. Аршауга хатле, Финляндиягә цаклы барып еткән безнең нәсел. Сез безне санга куймисызмы? Безнең кызларны кызга санамисызмы?

А й ш ә б и к ә. Язмаганны сүләмә, Асимәттай. Кем сезне санами.

А с и м ә. Алайса, нигә башкода ебәрмисез?

А й ш ә б и к ә. Ебәрергә, без әлдә сүләшәбез генә.

А с и м ә. Сүзегезне миңа да сүләргә ярамимы? Абдрахман катынына сүлисең.

А л ә ү е т д и н. Абдрахманның кызын сүвә ул.

А с и м ә. Кем?

А л ә ү е т д и н. Айшук.

А с и м ә. Абдрахман кызын нацар димим. Безнекеләр яхшырак.

А й ш ә б и к ә. Аймәт үзе ни атер бит. Ул әлдә Казанда

уки. Атер, миңа авыл кызы кирәкми диеп. Анарга атьтек, үләнсәң, мишәр кызына үлән, дидек.

Аләүетдин *(утырган җиреннән генә)*. Мин атьмәдем, син атьтең, Айшук.

Айшәбикә. Мин атьтем. Мин атькәнцә булыр. Мишәр кызына үлән, дидем. Ул атә, яри, дир, Цистай кызына үләнәм, дир. Мишәрләрнең пирвый сурты Цистайда, дир.

Аләүетдин. Цистайда второй сурты. Пирвый сурты Израилда.

Айшәбикә. Ацуымны китермә, Аләүетдин... Вата шылай дир Аймәт.

Асимә. Шылай дирме? Вата ристан. Аләүетдин сыман икән.

Аләүетдин. Мин Цистай кызына үләнмәдем. Вата Айшәбикәне бирделәр.

Айшәбикә. Һай-ай-ай... Кем бирде? Үзең ердең бит, Аләүетдин.

Көянтә-чиләк күтәргән Алия, Сания, Хания үтеп баралар.

Асимә. Туктагыз, карлыгацларым. Исәнләшегез Аләүетдин абзиегыз белән. Исәнләшегез, Айшәбикә апагыз белән.

Кызлар. Исәнмесез, Айшәбикә апа! Исәнмесез, Аләүетдин абзи!

Аләүетдин. Сөбханалла, сөбханалла!..

Айшәбикә. Аләүетдин!..

Асимә *(кызларга)*. Барыгыз.

Кызлар китә.

Аләүетдин. Кызларыгыз ямьне, Асимәттай.

Асимә. Ямьнедән ямьне туа, Аләүетдин. Нәселебез ямьне. Мин дә яшь цагымда дөньяда бер идем... Миңа туры баккан егетләрнең күзе сукырая иде. Мыний шыл ямьнеләрнең кайсын кая урнаштырырга кирәк, Алюк. Хәзерге заманда ямьне булу куркыныц. Алдилар да кацалар. Өцәү бит. Кецкенәсе дә үсеп етте. Уналты тула.

Аләүетдин. Касын алабыз инде үзебезгә, Асимәттай?

Асимә. Касын, касын... Олысын. Апаларын калдырып сеңелләре китмәс. Өлгергән цагы. Унтугыз тулып егермегә китте. Башкода ебәрегез.

А й ш ә б и к ә. Әлдә башкода ебәреп тормыйлар.

А с и м ә. Торсыннар. Башкода ебәрмәгәц ике ыланыгыз нишләде? Бер ыланыгыз Казан кызының колы булды. Икенце ыланың әллә кадян табак битле кызга ябышып калды.

А л ә ү е т д и н. Әллә кадян тегел, Уфадан. Татар кызы.

А с и м ә. Татар кызы бодау-бодау дип сүләми. Бозау, дир.

А л ә ү е т д и н. Типтәр татары ул, сез ни беләсез.

А с и м ә. Син ни беләсең? Ыланнарың мишәрнең канын сыегайтып ери. Үзебезнең авыл кызлары кияү көтеп картая. Өцәү бит. Берсеннән-берсе ямьне. Атьтем үземнең ыланга, үләнмә Хәйрулла нәселенә, дидем. Алар — юаш нәсел, дидем. Үләнде. Мыний кан сыегайды. Хәйрулла кызы өц кыз тапты. Утыралар кияү көтеп. Безнең нәсел кызлары кияүгә барми утырыр идеме? Минем кулымны егерме егет сорап килде. Егерме беренцесенә цыктым. Болар өцәү утыра. Атәм аналарына, урнаштыр кызларыңны, диеп. Картаялар, димен. Тыңнами. Үзләренә насиб табылыр, ди. Өцәү бит, Айшәбикә, өцәү бит, Аләүетдин. Телевизыр багып картаялар.

А л ә ү е т д и н. Өцәү кюп инде ул, Асимәттай, кюп. Кияүгә цыкмаган катын-кыз явыз да була.

А й ш ә б и к ә. Син кызлар тикшермә, Аләүетдин.

А л ә ү е т д и н. Кызларны егетләр тикшермәгәц кем тикшерсен.

А с и м ә. Айшәбикә, ни сүли ул синең ристаның. Анаңнан өлкән карцык янында ни сүлисең син, иятсыз? Аягыңны сугып сындырырмын. Вата белерсең шында мишәр карцыгының кем икәнен.

А л ә ү е т д и н. Беләбез, Асимәттай, беләбез.

А с и м ә. Ни беләсең, ә, ни беләсең?

А л ә ү е т д и н. Мишәрләрнең кызы яхшы, катыны белән карцыгы усал.

А с и м ә. Усал шыл. Сезгә усал булмасаң. Усал… Кыз цагымда да кара-каршы такмак атешеп синең кебекләрне тонцыктыра идем.

А л ә ү е т д и н. Юк, такмак атешеп, син мине еңә алмисың, Асимәттәй.

А с и м ә. Синеме?

А л ә ү е т д и н. Юк, еңә алмисың.

А с и м ә. Айшәбикә, ни сүләгән була ул синең ристаның?

А й ш ә б и к ә. Син аны тыңнама. Ул мыскыллап котырта.

А л ә ү е т д и н. Еңә алмисың, Асимәттай.

А с и м ә. Ярый, Алюк, котырт, котырт. Асимәттаңны коцыкны котырткан кебек котырт. Мин котырам. Тотцы, Айшук, таякны. Юк, бир, Айшәбикә, таякны. Хәзер мин котырам сиңа, Аләүетдин. *(Такмак әйтә башлый.)*

Ак пирцаткалар бәләдем
Алты-биш энә белән;
Без вак тегел, вакланмибыз
Сезнең ишеләр белән.

А л ә ү е т д и н *(җавап бирә)*.

Безнең урам түбән таба —
Шывып бара бер цана.
Мин, мин димә, я хту димә,
Барыбыз да бер цама.

А с и м ә.

Аклы ситса күлмәгемне
Салып куям өстемнән:
Сүзләреңне җиргә бәреп
Таптап ерим өстеннән.

А л ә ү е т д и н.

Ишектән керәсеңме,
Келәсен эләсеңме;
Кешедән бик кюп көләсең,
Үзеңне беләсеңме.

А с и м ә.

Су буена төшәрсең,
Ишкәкләрдә ишәрсең;
Төртмә-төртмә кабыргага,
Кабырганы тишәрсең.

А л ә ү е т д и н.

Актыр пәке саплары,
Күктер пәке саплары;
Сиксән биштә, туксан биштә
Кызның ямьне цаклары.

А с и м ә.

Алтын балдак бармакта —
Аләнәдер салмакка.
Миңа атер сүзең булса,
Адә барик аулакка.

Аләүетдин ык-мык итә дә туктый. Асимә тәмләп көлә.

Булдымы? Котырдыңмы, Аләүетдин? Тагын бер кирәкме? *(Такмак әйтә.)*

Урамнардан без киләбез —
Билләрдә сары каеш;
Синең кебекләрне кюргән,
Мактанма, панимаешь.

*(Таягын Аләүетдингә төзәп.)* Кулың күтәр, Аләүетдин, Арифулла ристаны. *(Аләүетдин кулын күтәргәч, тәмләп көлә.)* Куып цыгар син моны, Айшук. Сиксән биш яшьлек карцыкка торырлыгы юк. Шындый безнең нәсел, Айшәбикә, безнең кызыбызга башкода ебәр.

Аләүетдин. Юк, Асимәттай. Сездән кыз алмибыз. Син берсәк картайдың, туйда бии алмисың. Бии алмаган карцыкның кодасы булмим.

Асимә. Бак, Айшук. Котырта. Мине биетмә кели. Ристан син, Алюк… Башкода ебәрегез. Башкода ебәрмим дисәң, Айшук, кызны алып килеп, түрегезгә утыртам. Биетмә кели, ә. Вата ристан. Сау булыгыз. *(Ничек кергән булса, шулай чыгып китә.)*

Аләүетдин. Вата карцык!.. Нуклары ямьне шыл.

Айшәбикә. Аләүетдин… Мин ни атьтем? Абдрахман кызын алабыз.

Аләүетдин. Юк, Айшук. Йә Фәйзи кызын, йә бу кызны.

Айшәбикә. Ацуымны цыгарма, Аләүетдин, йерәк маем. Бар, әцәтне тот. Суй. Мин «Трапиканка» багам.

Аләүетдин. Әцәт куып ерергә кем дип белдең мине?

Айшәбикә. Аләүетдин, ацуымны китермә.

Аләүетдин. Син дә минем ацуымны китермә.

Айшәбикә. Ни сүлисең син, Аләүетдин, йерәк маем?

Аләүетдин. Шыны сүлим, миңа приказ бирмә. Мин утпыскыда.

Айшәбикә. Аймәт катя. Ыланың катя.

Аләүетдин. Каться, китәр.

Айшәбикә. Ни сүлисең син, Аләүетдин. Тотасыңмы, юкмы әцәтне?

Аләүетдин. Тотмыйм.

Айшәбикә. Тотмисыңмы?

Аләүетдин. Тотмим.

Айшәбикә. Ашарга пешермим бит.

А л ә ү е т д и н. Пешермә.

А й ш ә б и к ә. Ни ашисың?

А л ә ү е т д и н. Балдызларга керәм. Миңнури пешереп ашатыр. Алим үдә дә юк.

А й ш ә б и к ә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин... Бар, кереп бак, бар. *(Аләүетдин китә башлагач.)* Аләүетдин, кая барасың? *(Аләүетдиннең каршына бара.)* Кая барасың, ерәк маем?

А л ә ү е т д и н. Дальний Вастукка, Япониягә.

А й ш ә б и к ә. Китмә, Аләүетдин, катярсың бит.

А л ә ү е т д и н. Катьмим, бу юлы катьмим.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин, ацуымны китермә. Ацуымны китермә, Аләүетдин. *(Аләүетдинне кочаклап ала.)* Аләүетдин, йерәк маем.

Ү м ә р белән М и ң с ы л у керәләр.

Ү м ә р. А-а-а, Халил белән Алиябану икән монда.

А й ш ә б и к ә. Үмәр езни, апа, атегез шынарга.

Ү м ә р. Ни атим?

А й ш ә б и к ә. Китәм дир.

Ү м ә р. Китсен. Елга бер китеп ала бит ул. Кюл буена етә дә аләнеп катя. Тагын Япониягә китәсеңме, базя?

А л ә ү е т д и н. Син көлмә миннән.

Ү м ә р. Ә син көлдермә.

М и ң с ы л у. Башлана «Трапиканка».

Ү м ә р. Һай, истән цыгардыгыз. «Трапиканка» башлана. Безнең телевизор ватылды. Сезгә кердек — сез юк. Тавышыгыз — мында. Адә керик.

А й ш ә б и к ә. Адя, Аләүетдин.

А л ә ү е т д и н. Мин «Трапиканка» бакмим.

А й ш ә б и к ә. Бакмасаң, утырып кына торырсың. Адә, кер. Әцәтне дә үзем тотармын. Адә, кер. Кер, Аләүетдин.

Ү м ә р. Без керә торабыз...

А й ш ә б и к ә. Туктагыз инде, езни. Апа, китә бит Аләүетдин.

Ү м ә р. Кая китә? Өц ел инде китәм диеп ери. Адә, керәбез.

Ү м ә р китә. Аңа М и ң с ы л у иярә.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин, багим инде «Трапиканка»-ны. Баккац бергә китәрбез. Аләүетдин, «Трапиканка» кюрсәт миңа, бәхетсез итмә инде, йерәк маем. *(Тагын Аләүетдинне кочаклый.)*

Аймәт кайтып керә.

Аймәт. Исәнмесез-саумысыз! Нишлисез сез мында кюл буенда?

Айшәбикә. Улым! Аймәт! Тот атаңны. Ебәрмә. «Трапиканка» башлана. *(Ашыгып кереп китә.)*

Ут сүнә.

## Икенче күренеш

Шул ук күл буе. Шул ук бөдрә таллар. Таллар арасыннан түп-түгәрәк тулган ай күренә. Җиргә авып үскән тал өстендә шул ук Аләүетдин «Ак чәчәккәй» көен гармунда уйнап җырлап утыра.

Аләүетдин.

Кара урманнарның уртасында
Карцыгалар куа пебетне;
Ике кулыңа ла шәмнәр тотып
Табалмассың бездәй егетне.
Әллү-әллү кыцкыра асыл кош,
Безне сагына микән асыл кыз.

*(Айшәбикәнең «Аләүетдин!.. Аләүетдин!» дигән тавышын ишетеп, агач артына поса.)*

Айшәбикә белән Аймәт керәләр.

Айшәбикә. Аләүетдин!.. Аләүетдин!.. Ай акылсыз, ай акылсыз, ай акылсыз Аләүетдин. Цыга да китә, цыга да китә.

Аймәт. Катя бит инде ул. Кая китсен.

Айшәбикә. Аны кем аңлаган. Картайган саен дураклана.

Аймәт. Китмәгәндер, суга баткандыр ул, әни.

Айшәбикә. Ни сүлисең син. Акылсыз. Гармунының тавышы шыннан иштелде.

Аймәт. Ана кюл өсте дулкынланып тора. Шында сикергән. Гармунын коцаклап.

Айшәбикә. Котыртма мине. Атаң да үзе котырта да аннан цыгып китә. Миңа атә, Фәйзи кызын алабыз, дир.

А й м ә т. Фәйзи абзиның кызы белән нишлисез?

А й ш ә б и к ә. Сиңа. Сүләштек тә атаң белән. Үзебезнең авыл кызына үләндерәбез диеп. Фәйзи кызын алик, дир.

А й м ә т. Ә сиңа ул ошамимы?

А й ш ә б и к ә. Абдрахман кызы яхшырак.

А й м ә т. Икесен дә алыгыз, миңа кирәкми. Сезнең авылда миңа яраклы кыз юк. Яхшылары Москвага кацып бетте.

А й ш ә б и к ә. Ай акылсыз. Ай акылсыз... Атасы да шынди, ыланы да шынди. Кая китте инде, ә... «Санта-Барбара» башлана бит. Аләүетдин!.. Аләүетдин!.. Йерәк маем! Бар, син бу якка бар, мин бу яктан эзлим. Ать үзенә, эти, диген, дуракланма, диген. Япониягә китеп нишли ул, япон телен дә белми бит... Аләүетдин!.. *(дип китеп бара. Аймәт китәм дигәндә, Аләүетдиннең сызгырганын ишетеп туктап кала. Аләүетдин үзе дә күренә.)*

А л ә ү е т д и н. Аймәт...

А й м ә т. А-а-а, кацкын... Нихаль. Синең Японияң шындамыни?

А л ә ү е т д и н. Көлмә атаңнан.

А й м ә т. Балалар аталарыннан көләр өцен туалар, эти.

А л ә ү е т д и н. Сиңа ницә яшь?

А й м ә т. Миңа егерме. Сиңа илле.

А л ә ү е т д и н. Илле яшькә еткәц сүләшербез.

А й м ә т. Син, китсәң, гармуныңны алып цыгып китмә. Минем дә унягым кели.

А л ә ү е т д и н. Үзеңә сатып ал.

А й м ә т. Акца бирмисең.

А л ә ү е т д и н. Анаң дерес сүләми. Мин Фәйзи кызы өцен цыгып китмәдем. Ул миңа атә, әцәтне суй, дир. Мин утпыскада. Минем ян тарткым кели. Мин – моряк. Тихакиян морягы. Ул миңа каз суйдыра, әцәт суйдыра. Егерме биш ел каз суям да әцәт суям, тавык суям. Абдрахман суйсын тавыкны. Ул моряк тегел.

А й м ә т. Син дерес атәсең, эти. Кит син Япониягә. Әни бик нацар катын. Мине дә алып кит Япониягә. Мин япон кызына үләнермен. Сиңа да бер япон кызы табарбыз.

А л ә ү е т д и н. Атаң белән шылай сүләшергә кем үрәтте?

Аймәт. Син. Әни атә, атаңа охшаган, акылсыз, дир. Адә, катябыз.

Аләүетдин. Катьмим.

Аймәт. Алайса, мин дә катьмим, әни дә катьми. Өцәү шында ерибез.

Аләүетдин *(гармунын сузып).* Мә, уня.

Аймәт. Касе ерны?

Аләүетдин. Ерны уняма, биюне уня.

Аймәт. Биисеңме?

Аләүетдин. Син уня.

Аймәт «Яблочко»ны уйный. Аләүетдин тыңлап кына утыра.

Аймәт. Бие инде.

Аләүетдин. Уня. Минем йерәк бии. Мин бит моряк, әцәт суюцы тегел. Бу нинди бию, беләсеңме?

Аймәт. «Яблочко».

Аләүетдин. «Яблочко» тегел, бу – безнең бабайлар биюе. Мишәрләр моряк булганнар. Алар Тихакиянда корабльдә ергәннәр. Иван Грузный бездән әцәт, тавык суюцы ясаган. Иван Грузный ул синең анаң. Кыцкыртып уня. *(Аз гына биеп алгач.)* Бак, мишәрнең биюе итек киеп бии торган бию – шак. Шак. Шак... Казанның биюе цитек киеп бии торган бию. Тавышы юк. Алар моряк тегел. Кыцкыртып уня.

Көянтә-чиләк асып, Миңнурый үтеп бара. Аләүетдин биюеннән туктый.

Миңнури!

Миңнурый. Балдыз, диген, Аләүетдин езни. Исәнме, Аймәт. Качан катьтең?

Аймәт. Бюген. Менә әтине биетәм. Әти белән биисеңме, апа? Сез икәү бик яхшы биисез.

Аләүетдин. Юк, Миңнури, үзең генә бие. Бие, балдыз.

Миңнурый. Берсәк картайдым инде, Аләүетдин езни.

Аләүетдин. Син картаймадың. Апаң картайды. Айшәбикә картайды. Ерламый да, биеми дә. Бие, Миңнури.

Миңнурый. Балдыз, диген, Аләүетдин езни. Биесәм, апа ацулана. Езнәңне аздырасың, дир.

Аләүетдин. Аңнамый ул Айшәбикә.

Аймәт. Әни аңнамый ул, Миңнури апа.

М и ң н у р ы й. Әниеңә каршы сүләмә, уня.

Аймәт уйный. Миңнурый бии дә көянтә-чиләген алып китеп бара.

А л ә ү е т д и н. Вата Миңнури!.. Вата балдыз!.. *(Аймәткә.)* Син әниеңне яманлап сүләмә, яримы.

А й м ә т. Яри, яри...

А л ә ү е т д и н. Тукта. Тыңна, ишетәсеңме?

А й м ә т. Нәрсәне?

А л ә ү е т д и н. Тавышны.

А й м ә т. Юк.

А л ә ү е т д и н. Юк шул. Авыл үлгән. Су буе буп-буш. Нигә, беләсеңме?

А й м ә т. «Трапиканка» багалардыр.

А л ә ү е т д и н. Багалар шыл. «Трапиканка» багалар. «Санта-Барбара» багалар. Үдән цыкмилар. Су буе буп-буш. Әлдә бу ерләр шаулап торыр иде. Уеннар уни идек. Үзебезцә ерлый идек. Хазер «Трапиканка». Телевизыр да телевизыр. Улсы да безнекецә кюрсәтми. Казан да мында кюрсәтми.

А й м ә т. Казан ул үзендә дә кюрсәтми.

А л ә ү е т д и н. Су буе буп-буш. Тып-тын. Әцәт суй, ди. Китәм, Япониягә китәм. Анда «Трапиканка» юк, анда әцәтләрне әцәттән суйдырмилар.

А й м ә т. Әцәтне дә суярга кирәк бит.

А л ә ү е т д и н. Тиле син. Мин сиңа бер нәрсә сүлим. Син... Бир гармунны. *(Аймәт кулыннан гармунны ала да чыгып китә.)*

А й м ә т. Әти! Әти!.. *(Аләүетдингә иярә.)*

Иңнәренә көянтә-чиләкләр аскан А л и я, С а н и я, Х а н и я н е ияртеп, А с и м ә керә.

А с и м ә *(кинәт туктап)*. Алия, башыңны югары тот. Алга карап бар. Күзләрең уң якны да, сул якны да кюрсен. Адәгез. *(Тезелешеп китәләр. Асимә тагын туктый, таягын уртада баручы Саниянең аякларына төзи).* Сания, кюпме атәм мин сиңа. Аякны кызлар алай атламилар. Боз өстеннән сыйр баргандай атлисың. Мыний, бак. Тот таякны *(Саниягә таякны тоттыра да үзе аның көянтә-чиләген ала.)* Мыний, кюр. *(Йөреп күрсәтә.)*

С а н и я. Мин дә шылай ерим бит.

А с и м ә. Шылай тегел. Син мыний былай ерисең.

Кызлар ямьне ерергә тиеш. Ун циләк су кютәрсә дә ямьне ерергә тиеш. Тиливизыр багып утырып ерергә дә онытасыз. Киттек. *(Таягын алып, көянтә-чиләген бирә дә, атлыйлар. Асимә тагын туктата.)* Хания, сузма кютеңне, үзбәк куе тегелсең. Кызлар алай ерми, карцыклар гына шылай ери. Тиливизыр багып ятып май баскан.

А л и я. Әби, адә инде тизрәк, «Санта-Барбара» башлана.

А с и м ә. Кюрсәтермен мин сиңа барбара. Ни атагыз сюз атьми, ни анагыз белми, каласыз тиливизырдагы нигрны коцаклап. Картайдың инде тиливизыр багып.

Х а н и я. Нишләп картайсын, анарга әлдә унтугыз гына яшь.

А с и м ә. Мин унтугызда беренце ыланымны таптым. Адәгез... *(Бераз баргач.)* Туктагыз. Куегыз циләкләрегезне. Утырыгыз шыл агацка. *(Кызлар утырышкач.)* Хания, шылай утыралармы? Кая аякларыңны аердың? Бөтен амирикаң кюренә. Кызлар аяклар еып утыра, итәкләрен рәтләп куя. Мишәр кызының тездән югары ерен ире генә кюрергә тиеш. Улсы да төнне генә. Аңнадыгызмы? *(Кызлар пырхылдап көлгәч.)* Кешнәмәгез. Кюрсәтермен мин сезгә таяк белән анагыз кюрсәтмәгәнне. Азындыгыз. Белегез, азгын кызларга егетләр үләнми. Азгын кызларны коцаклап ериләр дә яхшы кызларга үләнәләр. Көлмәгез!.. Йоклап та ермәгез. Йоклап ергән кызларны егетләр кюрми кала.

А л и я. «Санта-Барбара» башланды инде.

А с и м ә. Алия, сугам таяк белән.

Х а н и я. Әбкай, миңа кияүгә цыгарга иртә. Апалар калсын, мин катим.

А с и м ә. Юк, дидем! Үрән. Мин үлеп китсәм, кем үрәтер. Бабагызны мин мыний шында оцраттым. Судан катеп киләм. Ул ат эцерергә бара. Үзем аны кюрәм, үзем кюрмәгәндәй кебек булам. Судан катеп киләсеңме, Асимә, дир. Күәндәмне шылай итеп тотты. Ебәр, дим. Тагын суга кил, дир. Тагын бардым суга. Ун кат бардым. Суымны ана шында алып барам да түгәм. Тагын барам. Усман көтеп тора. Шыннан инде...

Х а н и я. Әби, мине ебәр.

А с и м ә. Тыңна!..

Х а н и я. Мин аны ез кат тыңнадым инде.

А с и м ә. Тагын тыңна. Син дә үзеңнең нугыңа сүләр-

сең. Барыгыз Сания белән су алып менегез. Син, Алия, минем янда кал. *(Сания белән Хания киткәч.)* Син, кызым, ацуланма картайдың дигәнемә. Мин барыгызны да сүәм.

Алия. Ацуланмыйм.

Асимә. Син мишәр кызына охшамаган, Алия кызым. Анаң да шылай. Мишәр кызы үткен була, теле телгә йокми. Нигә шылай, беләсеңме? Син елмайма. Беләм нигә елмайганыңны. Әбиең кюпне күргән. Бабагыз мине кайларда гына ертеп катьмады. Ай, булган егет иде бабагыз. Мишәр үткен булырга тиеш, кызым. Ул төрле халыклар арасында яшәгән халык. Үткен булмаса, аны бетерәләр. Юашларны асалар бу дөньяда... Сиңа бу Айшәбикәнең ыланы ошыймы, кызым?

Алия. Аймәтме?

Асимә. Шыл инде. Үләндерәбез, дир анасы.

Алия. Уки бит ул.

Асимә. Укысын. Син дә укыган. Мидпункытта эшлисең. Син уйла, кызым. Тиливизыр багып эш цыкмый.

Миңнурый кайтып килә.

Миңнурый. Исәнме, Асимәттай!

Алия. Исәнмесез, Миңнури апа!

Асимә. Бар, Алия.

Алия көянтә-чиләкләрен алып китә.

Миңнурый. Кызларыгыз кияүгә бирерлек булган, Асимәттай.

Асимә. Булгац алыгыз. Ать апаңа, ать Аләүетдин езнәңә.

Миңнурый. Касен, Асимәттай?

Асимә. Алиябез өлгергән.

Миңнурый. Юк, Асимәттай, Аймәткә ул ярами. Кирәгеннән артык акыллы ул Алиягез.

Асимә. Аләүетдиннең акылсыз ыланына бик таман.

Миңнурый. Кирәгеннән артык акыллы кызны ирләр сүми. Аларга елбәзәгрәк катыннар кирәк.

Асимә. Синең сыманмы?

Миңнурый. Минем сыман, Асимәттай. Синең сыман. Минем Алимем минем күземә генә багып тора. Сау бул, Асимәттай. *(Китеп бара.)*

А с и м ә *(судан кайтып килүче кызларны күреп).* Сания, нәрсә атьтем мин сиңа? Аякларыңны бак... Хания!..

Х а н и я. Сузмим инде, сузмим.

А с и м ә. Куегыз циләкләрегезне. Сания, сукмакка куйма. Аннан кеше ери. Циләгеңнең эце генә тегел, тышы да ару булсын. Инде син бар, Алия. *(Алия көянтәчиләкләрен иңенә салгач.)* Башың югары тот, кызым, югары тот. Кайгысы бар, димәсеннәр. Сез утырыгыз.

Х а н и я. «Санта-Барбара» бетә инде.

А с и м ә. «Санта-Барбара»ң кияүгә цыкми. Ул инде цыккан. Утыр.

С а н и я. Син, әби, бик усал.

А с и м ә. Атегез әтиегезгә, безнең әби усал, куып цыгар, диегез.

Х а н и я. Хайләкәр син, әби.

Ашыгып-кабаланып, абына-сөртенә, А й ш ә б и к ә үтеп бара.

А с и м ә. Кая цабасың, Айшук?

А й ш ә б и к ә. Туктале, Асимәттай, синең кайгың юк әлдә. Бетә... «Санта-Барбара» бетә.

А с и м ә. Ай тилерде халык. Цаба. Бетә, ди. Әкиятнең беткән цагы буламы. Тилерде халык. Башы әләнгән. Берсен берсе кюрми. Уң ягын да кюрми, сул ягын да кюрми. Картайгац нәрсәне сагынып сүләрләр. Мыний багып калыгыз, уңга да бак, суңга да бак. Вата кюл. Вата таллар. Кюңелегезгә сеңеп калсын. Адәм баласының сагынып сүләрлек истәлеге булырга тиеш. Ай хәтерсез халык китте.

Х а н и я. Әби, катик.

А с и м ә. Катьмисыз. *(Су күтәреп менгән Алиягә.)* Утыр, кызым. Кая мин үрәткән еруыгыз. Сания, син башла. Картайгац, әби белән кюл буенда, кизләүдән су алып катьканда ерлашып утырган иек диеп сүләрсез. Син, Хания, кыцкырып ерлама, бу кыцкырып ерлый торган тегел.

Сания «Бадъян бакчалары» көенә җыр башлый, аңа кушылалар.

Бадъян бакцалары тютәл-тютәл,
Арасыннан былбыл кош үтәр, шыл,
Арасыннан былбыл кош үтәр.
Безнең яшь үмерләр үтәр китәр,

Яшьтә сүвешеп калуга ни етәр, шыл,
Яшьтә сүвешеп калуга ни етәр.
Ацуланма сүгәнемә атькәгә,
Үкенерсең үмерең үткәнгә.
Бадъян бакцасында ерер идем,
Ике кул гынама гөл уцлап, шыл,
Ике кул гынама гөл уцлап.
Яным сүгән ярым булса иде,
Бәлки, йоклар идем тыныцлап, шыл,
Бәлки, йоклар идем тыныцлап.
Кызыл мәрьян кызларның кул бавы,
Авыр яр сүгәннәрнең булмавы.

Асимә *(җыр беткәч).* Онытмагыз безнең борынгы әбиләребез ерлаган бу ерны. Барыгыз, китегез, Алия, син тагы кил суга. *(Аймәтне күреп алып.)* Алия, син кал. Без китәбез.

Хания. Ә ул нигә кала?

Асимә. Кюпне белмә. Сиңа да етәр цират. Адәгез. *(Сания белән Ханияне ияртеп китә.)*

Аймәт керә.

Аймәт. Нихаль?

Алия. Исәнме, Аймәт!

Аймәт. Су ташисыңмы?

Алия. Ташим.

Аймәт. Тиздән безнең мунцага ташырсың суны. Башкода ебәр, дигән Асимәттай. Мине үләндерәләр, сине миңа кияүгә бирәләр. Өц кыз миңа саляп куйганнар. Касегыз элек килә, шынарга үләнәм инде. *(Алия китәргә җыенгач.)* Кая барасың?

Алия. Үгә катям.

Аймәт. Ашыкма. Сүләшик. Ник яшмисең?

Алия. Ни яшим?

Аймәт. Сүвәм, диген. Мине генә саляп ал, диген. Ать инде.

Алия. Мин андый сүзләр белмим.

Аймәт. Үрән.

Алия. Син нигә минән көләсең, Аймәт?

Аймәт. Көлмим. Мин сине сүвәм. Шындый сүвәм мин сине! Сине кюргәц бәбәкләрем ялтыри, кулларым калтыри. Вата тотып бак кулларымны, калтыри.

Алия. Казанда син бозылыпсың, Аймәт.

Аймәт. Ницек бозылыпмын?

Алия. Шылай бозылыпсың. Ебәр мине.

Аймәт. Юк, ебәрмим. Коцакламадым да. Сагынып катьтем. Катькац Алия мине коцаклап ала инде, димен. Син аска гына багып торасың. Югары бак. Миңа бак. Вата минем күзләрем сиңа гына багып тора.

Хания белән Сания кереп, таллар арасыннан Аймәт белән Алия сөйләшкәнне күзәтеп-тыңлап торалар.

Аймәт. Бакмасаң, Фәйзи абзиның кызы Исламиягә үләнәм бит. Ник яшмисең?

Алия. Нигә мине котыртасың? Мин бит тиле тегел.

Аймәт. Мин тиле кызларны сүвәм. Абдрахман абзи кызы Зарема тиле, дир. Анарга үләнәм. Үләнимме анарга, әллә сиңа үләнимме? Коцаклап кюрим инде. Коцаклап кюрмицә үләнә алмим бит инде. Коцакли белмәгән катын белән ницек торим. Бак, фигураң ямьне синең. Сиңа үләнәм. *(Алиянең елаганын күреп.)* Нәк елыйсың? Тимәдем бит.

Хания *(атылып чыгып, Аймәт каршына килә).* Син нәк апамны елатасың?

Сания *(Аймәтнең икенче ягына басып).* Нәк апага тиясең?

Аймәт. Сез кемнәр?

Хания. Син кем?

Сания. Син кем?

Хания. Апага тисәң, бәбәгеңне төртеп тишәрмен.

Аймәт. Шылаймыни? *(Саниягә.)* Син дә төртеп тишәрсеңме?

Хания. Телеңне озайтма, кисәрбез.

Аймәт. Бак, бак, нә ди…

Хания. Нәди-мәди, мәмәди… Хулиган.

Аймәт. Кем син? Алия, кем бу кызи?

Сания. Кызи тегел ул сиңа, йерәк маем. Ул минем сеңелем. *(Алиягә.)* Адә, апа, катябыз.

Хания. Тагын да апаны елатсаң, аягыңны сугып сындырырбыз.

Аймәт *(Хания янынарак килеп).* Яле, яле, сындыр.

Хания. Килмә!.. *(Ике бармагын сәнәк итеп.)* Килмә, төртеп тишәм бәбәгеңне.

Сания. Килмә!.. *(Ике бармагын сәнәк итеп, Аймәткә суза.)*

А й м ә т. Яле, тишегез, тишегез…

Хания белән Санияне икесен дә билләреннән эләктереп, кочаклап күтәреп ала. Кызлар чырылдап кычкыралар, куллары белән чәбәләнәләр, тиберченәләр. Хания Аймәтнең иңбашын тешләп ала. Аймәт кычкырып, кызларны ычкындыра. Үзе «үләм, үләм» дип җиргә егылып тәгәри. Аннан кинәт чалкан яткан килеш тынып кала. Кызлар аптырап карап торалар.

Х а н и я. Адә, киттек.
С а н и я. Син аны нишләттең?
Х а н и я. Мыний бу ерен тешләдем.
А л и я. Мында бит елкә тамыры.
Х а н и я. Кылына гына ул, адә, киттек.
А л и я *(Аймәт янына килеп тезләнеп).* Аймәт, Аймәт…
С а н и я *(Аймәт янына килеп тезләнеп).* Аймәт, Аймәт…
Х а н и я. Кылына.
А л и я *(тешләгән урынны карап).* Тамырны тешләп өзгәнсең.
Х а н и я. Мин каты тешләмәдем. *(Аймәткә якынрак килеп карый.)* Кылына. *(Аягы белән Аймәткә төрткәли.)* Тор, кылынма.
С а н и я. Типмә, үтерәсең. *(Алиягә.)* Апа, тыңна ерәген, сулимы?
А л и я *(Аймәтнең күкрәгенә колагын куеп тыңлый).* Сулами.

Сания елап җибәрә.

Х а н и я *(еларга җитешеп).* Мин каты тешләмәдем. Үзе аеплы.

Аймәт кинәт кенә сикереп тора, Ханияне күтәреп ала да җиргә төшерә. Үзе кача. Качышлый Саниянең яңагыннан үбеп ала. Хания белән Сания аны куып йөриләр.

Х а н и я. Хулиган!..
С а н и я. Хулиган!..
Х а н и я *(Алия янына килеп).* Аттем, кылына, диеп. Адә, киттек. *(Агачка сөялеп карап торган Аймәткә.)* Дурак. Башыңда синең тавык мие.
А й м ә т. Юк, әцәт мие.
С а н и я. Тиле.
А й м ә т *(көйләп).*

Калды ич, калды ич, Казан сөлгеләре,
Апасыннан матур сеңелләре.

Х а н и я. Тагын безгә оцрап кына бак.
С а н и я. Оцрап кына бак.

Өчәүләшеп чыгып китәләр. Айшәбикәнең «Аләүетдин, Аләүетдин» дигән тавышы ишетелә. Үзе дә күренә.

А й ш ә б и к ә *(Аймәтне күреп)*. Тапмадыңмы?
А й м ә т. Юк.
А й ш ә б и к ә. Калярда эзләдең?
А й м ә т. Мыний шыннан.
А й ш ә б и к ә *(киткән кызларга күрсәтеп)*. Ул кызлар белән сүләштеңме?
А й м ә т. Сүләштем.
А й ш ә б и к ә. Сүләшмә. Абдрахман кызы белән генә сүләш.
А й м ә т. Болар да бит мишәр кызлары.
А й ш ә б и к ә. Аләүетдин!.. Аләүетдин!..
А й м ә т. Син әтине бозау цакыргандай цакырасың.
А й ш ә б и к ә. Итәрсең аны бозау. Калярдан эзләдең?
А й м ә т. Дальний Востокка да барып катьтем.
А й ш ә б и к ә. Көлмә анаңнан. Атаңны белмисең син, китәр дә барыр... Абдрахман кызы белән генә сүләш.
А й м ә т. Юк, мин бу кызлар белән сүләшәм.
А й ш ә б и к ә. Һай бу Аләүетдинне. Ай кылына, ай кылына. Хәерлегә тегел бу. «Трапиканка»да да кыланды, кыланды да хур булды. Акылдан ук таймаса яри инде. Ать, кюрдеңме?
А й м ә т. Кюрдем.
А й ш ә б и к ә. Кать диеп атьтеңме?
А й м ә т. Атьтем. Катьмим, дир. Әниеңне сүмим, дир.
А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син... Абдрахман кызы белән генә сүләш... Гармунны алырга иде. Гармунын алсаң, катя ул.
А й м ә т. Бирми.
А й ш ә б и к ә. Нишлибез, ать?
А й м ә т. Син, әни, аерыл аңардан. Синең белән торгым келәми, диген. Минем өцен алимент сорап судка бир.
А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син. Берүземә ике тиле... Кызларның касысы оши?
А й м ә т. Син, әни. Миңа син ошисың.
А й ш ә б и к ә. Асимә карцык нукларының касе оши, дим.

А й м ә т. Кецкенәсе.

А й ш ә б и к ә. Анысы бала гына.

А й м ә т. Мин үләнгәнце үсә ул.

А й ш ә б и к ә. Юк. Бу катьканыңда үләндерәбез. Сезгә ышаныц юк. Олы абзиең Казанда калды үләнеп, кеце абзиең Уфада калды үләнеп. Абдрахман кызы ошамаса, Асимә карцыкның Алиясен саляп ал.

А й м ә т. Мин Абдрахман абзи кызына үләнәм. Абдрахман абзиның машинасы бар.

А й ш ә б и к ә. Икегезнең берегез бер көн буена бер акыллы сүз атьте... Аләүетдин!.. Аләүетдин!.. Касе якка барып эзлим икән.

А й м ә т. Бу якка бар, әни. Аннан бу якка барырсың.

А й ш ә б и к ә. Адә, барып багик.

А й м ә т. Мин бармим. Син килмә, диде. Әниең үзе эзләп тапсын, диде.

А й ш ә б и к ә. Шылай дидеме? Һай, Аләүетдин, Аләүетдин... *(Чыгып китә.)*

Аймәт авыш үскән агач өстенә чалкан сузылып ята. Җырлый.

Калды ич, калды ич, Казан сөлгеләре,
Апасыннан матур сеңелләре.

Х а н и я *(агачлар арасыннан күренә)*. Тиле.

А й м ә т *(сикереп торып утыра).* Нәк килдең, каннибал?

Х а н и я. Кем ул каннибал?

А й м ә т. Кеше ашауцы.

Х а н и я. Тиле.

А й м ә т. Син акыллымы? Кешене үтерә яздың. Менә хазер дә авырта. Уй-уй-уй, үләм. *(Җиргә егылып төшә.)*

Х а н и я *(кычкырып көлә)*. Тиле.

А й м ә т *(башын калкытып).* Кил инде, үләм бит.

Х а н и я. А-яй-яй...

А й м ә т. Синең атың ницек?

Х а н и я. Кылынма. Беләсең.

А й м ә т. Каян белим. Мин киткәндә тумаган да идең.

Х а н и я. Тиле.

А й м ә т. Әллә син үңгә сүз белмисеңме?

Х а н и я. Тумаган, дисең бит.

А й м ә т. Кил инде якынрак. Куркма.

Х а н и я. Мин куркмыйм. Син мине куып та тоталмисың.

А й м ә т. Мин сине кумим да.

Х а н и я. Куасың. Ә син ул ерны Казанда үрәндеңме?

А й м ә т. Касе ерны?

Х а н и я. Казан сөлгесен.

А й м ә т. Үзем цыгардым.

Х а н и я. Алдакцы. Син апага бәләнмә. Ул юаш.

А й м ә т. Син усалмы?

Х а н и я *(Асимә күрсәткәнчә, гәүдәсен төз тотып йөренә)*. Усал шыл. Апага бәләнсәң, аягың сугып сындырырмын, ерла. Казан сөлгесен.

А й м ә т. Ерлыйм.

Калды ич, калды ич, Казан сөлгеләре,
Апасыннан матур сеңелләре.

Х а н и я. Син дерес ерламыйсың.

А й м ә т. Дерес.

Х а н и я. Дерес тегел.

А й м ә т.

Калды иц, калды иц, Казан сөлгесе,
Апаларыннан ямьне сеңлесе.

Хәзер дересме?

Х а н и я. Дерес. Мин дә ерлый беләм.

А й м ә т. Ерла.

Х а н и я *(Асимә өйрәткән җырны җырлый)*.

Бадъян бакцалары тютәл-тютәл,
Арасыннан былбыл кош үтәр, шыл,
Арасыннан былбыл кош үтәр.
Безнең яшь үмерләр үтәр китәр,
Яшьтә сүвешеп калуга ни етәр, шыл,
Яшьтә сүвешеп калуга ни етәр.
Кызыл мәрьян кызларың кул бавы,
Авыр яр сүгәннәрнең булмавы.

Безнең борынгы әбиләр ерлаган бу ерны. Ә син озаккамы катьтең?

А й м ә т. Син китмә дисәң, озак торам, кит дисәң, мыний хазер китәм.

Х а н и я. Тиле. Син Казанца сүләшә беләсеңме?

А й м ә т. Юк.

Х а н и я. Казанда укыпмы?

А й м ә т. Казанның теле япон теленнән дә авыр.

Х а н и я *(көлә)*. Китаплар Казанца язылган. Радио да Казанца сүли. Миндә кассеталар кюп. Сүләп кюрсәт Казанца.

А й м ә т. Якынрак кил, сүлим.

Х а н и я. Коцаклама. Коцакласаң, тешлим. *(Аймәт яына килеп баса.)* Сүлә.

А й м ә т. Бу чибәр кыз бигрәк тә чибәр икән. Бу чибәр кызның исеме ничек икән.

Х а н и я. Тагын. Тагын...

А й м ә т. Бөтен чибәр кызлар да бу чибәр кыз янында өч тиен дә тормыйлар икән. Чибәр Галиябанудан да чибәр икән бу кыз.

Х а н и я. Хания минем атым.

А й м ә т. Шылаймыни?

Х а н и я. Шылай. Ә синең цынлап та авырттымы мин тешләгәц?

А й м ә т. Юк. Тагын тешлә.

Х а н и я. Ай-яй-яй. Хайләкәр төлке.

А й м ә т. Бак, ницек мин сине кюргәнем юк икән? *(Җырлап.)*

Син кайда идең, кайларда йөрдең,
Ничек мин сине күрмәдем икән.

А с и м ә *(күренеп)*. Хания! Кил әле мында. *(Хания килгәч.)* Кая кацтың?

Х а н и я. Кацмадым.

А с и м ә. Кать үгә.

Ханияне озата да үзе Аймәт каршына килеп, Аймәткә текәлеп карап тора.

А й м ә т. Нигә алай багасың, Асимәттай?

А с и м ә. Баккым кели. Алиягә ни атьтең?

А й м ә т. Берни атьмәдем.

А с и м ә. Нәк ул елый?

А й м ә т. Мин каян белим.

А с и м ә. Бак аны, ристан. Бу таякны кюрәсеңме?

А й м ә т. Кюрәм.

А с и м ә. Яхшылабрак бак. Аягың сугып сындырырмын. *(Китә.)*

А й м ә т. Аяк яри, бәбәгемне генә төртеп тишмә. *(Агачлар арасында Санияне күреп алып.)* Һайт!.. Нишлисең анда?

С а н и я. Колак алкам төшеп калган. Шыны эзлим.

А й м ә т *(иелеп җирдән нидер алган була)*. Мыний ул мында. Мә, ал.

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

С а н и я. Кюрсәт.

А й м ә т. Якынрак кил.

С а н и я *(якынрак килеп)*. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим *(җырга күчә)*.

Ак перцаткаң бар мәллә,
Бармакцасы тар мәллә?
Аләнәсең дә карыйсың,
Атер сүзең бар мәллә?

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

Атер сүзең бар мәллә?
Ак перцаткалар кигәнсең,
Ницек кулың тирләми?
Мынди ямьне, гүзәл булып,
Кая үстең цирләми.

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

Кая үстең цирләми.
Аклы күлмәк киепсең,
Билләреңне буыпсың.
Ай туганда син туыпсың,
Шыңа ямьне булыпсың.

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

Шыңа ямьне булыпсың.
Ай яктылары бик якты –
Кизләүдән су ташырга:
Кюңелләрем сиңа төште,
Мөмкинме танышырга?

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

Мөмкинме танышырга.

С а н и я. Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

С а н и я. Бир, алайса, алкамны.

А й м ә т. Сүвәм дисәң, бирәм.

С а н и я. Беренце оцрашуда ук сүвәм димиләр.

А й м ә т. Хания миңа атьте.

С а н и я. Алдисың. Ул әлдә сүүнең ни икәнен дә белми.

А й м ә т. Син беләсеңме?

С а н и я. Мин инде быел мәктәпне бетерәм. Укырга Казанга барам, Казанда укырга алалармы?

А й м ә т. Мин атьсәм, алалар.

С а н и я. Син безнең апаны сүвәсеңме?

А й м ә т. Ул мине сүвәме соң?

С а н и я. Ул безнең бик акыллы.

А й м ә т. Син тилеме?

С а н и я. Нәк мин тиле булим. Ә синең Казанда ергән кызың бармы?

А й м ә т. Бар иде дә ташлим инде.

С а н и я. Нәк?

А й м ә т. Сине оцраттым.

С а н и я. Алдисың... Син Ханиянең башын аләндермә. Ул әлдә мәхәббәтнең ни икәнен белми.

А й м ә т. Син беләсеңме?

С а н и я. Беләм.

А й м ә т. Белгәц, миңа да ать инде.

С а н и я. Мәхәббәт ул бик каты сүвү.

А й м ә т. Шылаймыни?

С а н и я. Шылай. Син Алия апаны бик каты сүмисең.

А й м ә т. Каян беләсең?

С а н и я. Сүләшкәнегезне тыңнап тордык. Син алдакцы. Алканы таптым, дидең, ә уцыңда юк.

А й м ә т. Син аны югалтьмадың да.

А с и м ә *(күренеп)*. Сания!.. Кил мында. *(Сания килгәч.)* Нишләп ерисең?

С а н и я. Алкам югалган.

А с и м ә. Кать үгә. *(Санияне озата да Аймәт каршысына килә.)* Анарга ни атьтең?

А й м ә т. Берни атьмәдем.

А с и м ә. Нәк ул кызарган?

А й м ә т. Мин каян белим.

А с и м ә. Бак аны, ристан. *(Ике бармагын сәнәк ясап.)* Мыни кюрәсеңме?

А й м ә т. Кюрәм.

А с и м ә. Яхшылабрак бак. Бәбәкләреңне төртеп тишәрмен. *(Китә.)*

А й м ә т. Бәбәкләр яри, аякларны гына сугып сындырма. *(Айшәбикәне күреп.)* Тоттыңмы?

А й ш ә б и к ә. Катьмим, дир... Катьмим, дир... Әллә унап, әллә цынлап... Һай, Аләүетдин, Аләүетдин...

А й м ә т. Катер.

А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син. Мин атькәц катьмаганны, үзе катямы? Вата юктан бит... Син кать, мунца суынгандыр. Сөлгеләр, сабыннар шында.

А й м ә т. Ә син?

А й ш ә б и к ә. Мин берсәк көтәм... Ә син нәк елмаясың? Сәгать ницә?

А й м ә т. Унике.

А й ш ә б и к ә. Как унике?

А й м ә т. Төнге унике.

А й ш ә б и к ә. Һай, мынысы да көлә. Кит.

А й м ә т китә. Айшәбикә ялгызы гына уфылдап утыра да «һай, Аләүетдин, Аләүетдин» дип «Ак чук» көенә җыр башлый.

Аягымдагы кәвешем
Үкцәләре езләгән.
Ак цук, малым юк,
Сүвәр идем, ярым юк.
Синең кюңлең бизгән булса,
Минем кюңлем бизмәгән.

А л ә ү е т д и н күренә. Айшәбикәгә кушылып, гармун уйный. Айшәбикә, җырлаудан туктап, Аләүетдин янына килә.

Аләүетдин, йерәк маем. Адә, адә, катябыз. Аймәт тә катеп китте. Адә, Аләүетдин.

А л ә ү е т д и н. Ерла.

А й ш ә б и к ә. Катькац ерларын. Биермен дә катькац.

А л ә ү е т д и н. Син мында ерла, мында бие.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин... Яхшы тегел. Вата урамда ерлап-биеп тору.

А л ә ү е т д и н. Урам тегел. Кюл буе. Ерли идек, бии идек.

А й ш ә б и к ә. Ул бит яшь цакта. Әлдә мин картайдым, син дә картайдың.

А л ә ү е т д и н. Мин картаймадым. Мине син картайтасың.

А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син, Аләүетдин, йерәк маем? Ходайдан курк.

А л ә ү е т д и н. Барыгыз да картайдыгыз. Үдән цыкмисыз. Китәм.

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин, катик. Яри, әцәтне суймибыз. Тагын бер әцәт алырбыз. Өцәү булырсыз. Катик, Аләүетдин…

А л ә ү е т д и н. Биесәң, катям.

А й ш ә б и к ә. Урам бит, Аләүетдин. Берсе багып торса… Син утпыскада да, мин утпыскада тегел. Дальний Вастукта да булмаган.

А л ә ү е т д и н. Биемәсәң, катьмим.

А й ш ә б и к ә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин. Аракы эцсәң, исерек дияр идем. Нигә азаплисың? Кая, уня инде, уня.

Аләүетдин уйный, Айшәбикә бии. Башта Аләүетдиннең күңеле булсын дип кенә бии башлый да аннан кызып китә. Хәле бетеп, Аләүетдин янына килеп утыра да Аләүетдингә сөялә.

Син мине үтерәсең, Аләүетдин.

А л ә ү е т д и н. Биегән кеше озын үмерле була, Айшук.

А й ш ә б и к ә. Сүләмә, Аләүетдин, сүләмә. Адә, катик.

А л ә ү е т д и н. Катик та китик. Үдә ятып ницек туймисыз. Бак син… Мыний тирә-якка бак. Кюлгә бак, тал яфрагына бак. Исеңдәме, Аләүетдин, мин кыз цакта, син егет цакта шыл урында үбешкән идек, диген.

А й ш ә б и к ә. Үбешмәдек. Син үптең. Билемнән кысып алып кютәрдең дә үптең.

А л ә ү е т д и н. Адә, тагын үбешәбез.

А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син, Аләүетдин. Катик, йерәк маем. Адә, адә.

А л ә ү е т д и н. Балдызны цакыр.

А й ш ә б и к ә. Ә?

А л ә ү е т д и н. Миңнури, минем балдыз, кать, Аләүетдин езни, дисә, катям.

А й ш ә б и к ә. Аләүетди-ин… Аләүетди-и-ин!..

А л ә ү е т д и н. Катьмим.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Күл буе. Таллар арасыннан А й ш ә б и к ә белән М и ң н у р ы й чыгалар. Аләүетдинне эзлиләр.

А й ш ә б и к ә. Аләүетди-и-ин!..

М и ң н у р ы й. Аләүетдин езни-и-и!

А й ш ә б и к ә. Юк. Мин цакыргац та юк, син цакыргац та юк. *(Авыш үскән тал өстенә утырып елый башлый.)*

М и ң н у р ы й. Тукта. Катер. Төнә катьте.

А й ш ә б и к ә. Төнә дә син атькәц кенә катьте. Тагын кацты вата.

М и ң н у р ы й. Яныннан китмәскә иде.

А й ш ә б и к ә. Китмәдем. Коцаклап яттым. Сүз атьмәде. Иртән дә яхшы гына ерде. «Трапиканка» бакканыма да сүз атьмәде. Үдән цыкмады. Көндез дә цыкмады. Мин, Аләүетдин, йерәк маем дип, янында тордым. Ямьне сүләштем. Ул да... Айшук, дир, адә икәүләп китәбез, дир. Кая, димен. Дальний Вастукка, дир. Тихакиянны карап катябыз, дир. Акца юк бит, Аләүетдин, йерәк маем, димен. Үне сатабыз дир.

М и ң н у р ы й. Үне сатабыз дир?

А й ш ә б и к ә. Шылай дир. Мин әцәтне тотып, Үмәр езниләргә суйдырырга киттем. Катьтем — Аләүетдин юк.

М и ң н у р ы й. Гармуны да юкмы?

А й ш ә б и к ә. Гармуны да юк. Аймәтне ебәрдем. Барып кать диеп. Ул да юк.

М и ң н у р ы й. Син елама, апа. Асимәттай атә, илле белән алтмыш арасында ирләр дуракланып алалар, дир.

А й ш ә б и к ә. Тагын ун ел тиле белән ториммы?

М и ң н у р ы й. Катьса, торырсың.

А й ш ә б и к ә. Ни сүлисең син?..

М и ң н у р ы й. Аләүетдин езни тиле тегел ул. Аның йерәге күкрәгенә сыйми.

А й ш ә б и к ә. Яклама. Аны син供 аздырасың.

М и ң н у р ы й. Как аздырам?

А й ш ә б и к ә. Гармун уня дип килеп етәсең.

М и ң н у р ы й. Гармун тавышын сүвәм бит, нишлим.

А й ш ә б и к ә. Алимеңне үрәтергә иде.

М и ң н у р ы й. Гармун унярга үрәтеп кенә булми шыл.

Чиләк-көянтә күтәреп, А л и я судан кайтып бара.

Алия. Исәнмесез!

Миңнурый. Исәнме, Алия!

Айшәбикә. Аләүетдин абзиеңны кюрмәдеңме?

Алия. Юк.

Айшәбикә. Аймәтне дә кюрмәдеңме?

Алия. Юк. *(Китеп бара.)*

Айшәбикә. Асимәттай атә, тизрәк башкода ебәр, дир. Башкода кайгысымы калды. Әллә станцагамы барып багик? Поездга утырып китеп бармасын.

Үмәр белән Миңсылу керәләр.

Үмәр. Кая ерисез сез, Айшәбикә балдыз? Башлана бит.

Миңнурый. Нәрсә башлана, Үмәр езни?

Үмәр. Шыны да белмисеңме? «Трапиканка» башлана. Үзебезнең телевизыр емерелде. Айшәбикә балдызларга керәбез, үдә юклар. Тавышын ишетәм — мында.

Айшәбикә. Аләүетдин югалды бит, езни.

Үмәр. Как югалды? Ул нәрсә, бозаумы югалырга.

Айшәбикә. Югалды. Төнә дә үдән цыгып китте. Киц белән генә тотып катьтек Миңнури белән.

Үмәр. Япониядәме тотып катьтең?

Айшәбикә. Шыннан, кюл буеннан.

Үмәр. Аның Япониясе шында инде.

Айшәбикә *(Миңсылуга)*. Апа, нишлик икән, каян эзлик икән Аләүетдинне?

Миңсылу. Аләүетдинneңме кайгысы. Төнә дә «Санта-Барбара»ны бага алмадык.

Үмәр. Адә, Айшәбикә, катик. Башлана. Күрик, Иден бала тапмады микән?

Айшәбикә. Аләүетдинне табик инде, езни.

Үмәр. Каян табик?

Айшәбикә. Белмим бит.

Үмәр. Син башта бел. Атьтем мин сиңа, цыкма анарга дидем, ул тулы ук акыллы тегел, дидем. Цыктың.

Миңнурый. Сүгәц цыгасың, езни.

Үмәр. Син тик тор, цикерткә. Сүгәц... Алимеңнең түмәсен дә кади белмисең.

Миңнурый. Синме кадисың? Кади белмәсәм дә, мин аның каршында биеп кенә торам.

Үмәр. Цикерткә. Атәм — цикерткә. Иллегә етеп киләсең, акылың юк.

М и ң н у р ы й. Үзең кем?

А й ш ә б и к ә. Туктагыз. Аләүетдин турында гына сүләшегез. Аләүетдинне табарга кирәк.

Ү м ә р. Ыланыгыз кая?

А й ш ә б и к ә. Атасын эзләп китте!

Ү м ә р. Вата табып катер. Катьмаса, бергә китәрләр Япониягә. Икесе дә пар килгән. Үләндерәсең дип ишеттем, дересме?

А й ш ә б и к ә. Дерес иде дә…

Ү м ә р. Укыган кеше үләнми ул. Катыннымы баксын, укысынмы. Телевизырдан атьтеләр — укыганнарга акца бирмиләр икән. Сездән файда юк, сез акца туздыруцылар дип атәләр дир. Дерес тә. Кем дөньяны бути? Аларның башында уки-уки мазгалары кани башлый. Мазгалары колакларыннан цәцрәп цыкмасын өцен башкаларның мазгаларын кайнаталар. Аләүетдин дә вата укыган…

А й ш ә б и к ә. Аләүетдиннең укуы…

Ү м ә р. Укымаганны марякка алмилар. Вата аны Дальний Востокта укытканнар. Япнияне күрсәткәннәр. Вата аны шында тарта. «Трапиканка» да кемнәр бути? Укыганнар. «Санта-Барбара»да кемнәр бути? Укыганнар. Син, Айшәбикә, белмисең. Аймәт үләнми. Аймәт Казанда кала, Айшәбикә. Аләүетдин дә сиңа үләнеп дерес эшләмәде. Анарга Япония марҗасына үләнергә кирәк иде.

А й ш ә б и к ә. Эцемне пошырма, Үмәр езни.

М и ң с ы л у. «Санта-Барбара»ны тагын биш ел күрсәтәләр, дир.

С а н и я белән Х а н и я н е ияртеп, А с и м ә керә.

А с и м ә *(кызларга)*. Исәнләшегез кешеләр белән.

К ы з л а р. Исәнмесез!

А с и м ә. Бара торыгыз. Циткә тайпылмагыз. Сез мында нишләп утырасыз?

Ү м ә р. Аләүетдин югалган.

А с и м ә. Аләүетдин югалмас… Айшәбикә, башкода килмәде.

А й ш ә б и к ә. Ишетмәдеңмени Асимәттай. Аләүетдин югалды. Цынлап югалды. Цынлап югалды.

А с и м ә. Югалыр да шыл. Ирне тота белергә кирәк. Минеке югалмады. Азраил гына алып китте. Үзем үдә юк цакта. Үдә булсам, бирми идем.

Ү м ә р. Адә, Айшәбикә. Соңга калабыз.

А с и м ә. Кая каласыз?

Ү м ә р. «Трапиканка» башлана.

А с и м ә. Йа Хода. Синең Аләүетдинең югалмаган, Айшәбикә. Үмәр югалган.

А й м ә т *(җырлап керә)*.

Калды ич, калды ич, Казан сөлгеләре,
Апасыннан матур сеңелләре.

А й ш ә б и к ә *(Аймәткә каршы барып)*. Ницек, Аймәт?

А й м ә т. Нәне атәсең, әни?

А й ш ә б и к ә. Табылдымы әтиең?

А й м ә т. Ә ул югалмаган да... Исәнмесез тутайлар, езниләр, әбиләр!

А й ш ә б и к ә. Кая әтиең?

А й м ә т. Константиновкада.

А й ш ә б и к ә. Нишли анда?

А й м ә т. Марҗалар биетә.

А й ш ә б и к ә. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин!.. Нәк алып катьмадың?

А й м ә т. Катьми. Әниең килсен, дир, тутайларың килсен, дир, езниләрең килсен, дир. Мин кайтацак маряк тегел. Алар килеп алмаса, дир.

А й ш ә б и к ә. Езни, барик, алып катик.

Ү м ә р. Вата бизбашка, эцмицә марҗа биетеп ери. *(Миңсылуга.)* Барабызмы, Миңсылу?

М и ң с ы л у. Сисинең катыннары өцәү булганмы ул?

А й ш ә б и к ә. Адәгез инде, Константиновкадан цыгып китмәсен.

Ү м ә р. Вата бизбашка. Шылай инде без — Японияга дип цыгып китәбез дә, марҗа итәгенә ябышып, Константиновкада калабыз. Адәгез. *(Читкәрәк китеп баскан Миңнурыйга.)* Миңнури... Миңнури, син анда нишләп торасың? Адә.

М и ң н у р ы й. Кая?

Ү м ә р. Ишетмәдеңме, Аләүетдин Константиновкада, дир.

М и ң н у р ы й. Багыгыз кюл өсте шындый ямьне. Багып торгым кели.

Ү м ә р. Бер нормальный кеше юк дөньяда. Адәгез.

А с и м ә. Мине калдырасызмы?

Ү м ә р. Сиңа ярами. Урыс егетләренең алып калуы бар. Адә, Аймәт, алдан атла.

А й м ә т. Ул атьте, син килмә, диде.

Ү м ә р, М и ң с ы л у, М и ң н у р ы й, А й ш ә б и к ә, А с и м ә чыгып китәләр. Ләкин А с и м ә әйләнеп керә.

А с и м ә. Бак әле күземә.

А й м ә т. Йә, бактым...

А с и м ә. Бак аны, бунеңны борып сындырырмын. Бар, атаңны алып кайтырга.

А й м ә т. Бармим.

А с и м ә. Нәк?

А й м ә т. Вакытым юк.

А с и м ә. Нишлисең?

А й м ә т. Үләнәсем бар.

А с и м ә. Кемгә?

А й м ә т. Абдрахман абзи кызына.

А с и м ә. Бак күземә.

А й м ә т. Бакмим.

А с и м ә. Билеңне сугып сындырырмын. Бар, кит мыннан.

А й м ә т. Китмим. Мында минем оцрашасым бар.

А с и м ә. Кем белән?

А й м ә т. Абдрахман абзи кызы белән.

А с и м ә. Башыңны сугып ярырмын.

Икәү сүзсез генә утыралар.

А й м ә т. Асимәттай...

А с и м ә. Яшьмә.

А й м ә т. Кюл буенда карцык белән утыра алмим бит инде. Мында хазер Алия килә.

А с и м ә. Кем килә?

А й м ә т. Алия килә. Ул синнән ояла.

А с и м ә. Бак күземә.

А й м ә т. Йә, бактым. Син дә бак. *(Алия килгән якка күрсәтеп.)* Вата шында бак.

А с и м ә *(Алия килгәнне күреп, Аймәтне аркасыннан сөя.)* Пәрәмәцнең иң кайнары сиңа булыр.

Ашыгып китеп бара. Көянтә-чиләк асып, А л и я керә.

А й м ә т. Кая ташисың ул суны, Алия? Кизләүнең суын бетерәсең инде. Тукта, берсәк утырып тор, ян тарт. Сүләшик.

А л и я. Вакытым юк, «Трапиканка» башлана.

А й м ә т. «Трапиканка»ны мин үзем кюрсәтермен сиңа.

А л и я. Ницек?

А й м ә т. Коцаклашырбыз да «Трапиканка» шыл булыр.

А л и я. Син цын кеше тегел, Аймәт.

А й м ә т. Цын кеше нинди була?

А л и я. Цын кешеләр үңгәләрне мыскыллап сүләшми.

А й м ә т. Цын кеше әбисе кушканга төн буе су ташып ереми.

А л и я. Мин әби кушканга еремим.

А й м ә т. Нәк ерисең?

А л и я. Син цын тегел. *(Җылый башлый.)*

А й м ә т. Вата, вата... Нәк елыйсың?

А л и я. Син цын тегел.

А й м ә т. Ну, тегел, тегел. Мин — тиле, мин — дурак... Ну, нишләтим. Дөньясы шынди. Тилеләр көлә, акыллылар ели. Мыний син ать, нәк елисың? Кинадыммы сине?

А л и я. Син көләсең миннән.

А й м ә т. Син дә көл миннән. Вата синең сеңелең Хания көлә. Мин еламим.

А л и я. Аның акылы юк.

А й м ә т. Акылым бар дип елапмы утырырга. Әгәр дә миңа цыксаң кияүгә...

А л и я. Мин сиңа цыкмим.

А й м ә т. Цыкмагац нәк суга ерисең? Нәк юлыма цорисың? *(Алия кычкырыбрак елагач.)* Вата тагын ели. Ну, ать миңа, ать...

А л и я. Ни диеп атим?

А й м ә т. Ать. Сине цораткым келәми, диген. Син юлымда, диген, церегән агац кебек ятасың, диген. Сине кюргем келәми, диген. Син цебен кебек күземә керәсең, диген. Ать, ну, ать. Мин еламам. Сүсәң, ать. Сүүәм, диген, сүмәсәң ать, сүмим, диң.

А л и я. Сүвәм.

А й м ә т. Вата, вата шылай. Ату... *(Алия булып елап күрсәтә.)* Син бит мишәр кызы. Ебеп торма. Сеңелләреңнән үрән. Вата, атьтең сүвәм дип, мин дә сүвәм дип атьсәм нишлибез?

А л и я. Белмим.

А й м ә т. Вата бел. Үзең медучилищеда укып катепсың, үзең белмисең.

А л и я. Анда аны укытмадылар.

А й м ә т. Ул укып үрәнә торган нәстә тегел. Вата бел, син атьтең сүвәм диеп, мин дә атьсәм сүвәм диеп, коцаклашалар, үбешәләр. Аннан инде бик сүвешсәләр, үләнешәләр. Ә син атәсең миңа, цыкмим, дисең. Шылай булгац нишлибез инде, коцаклашабыз, үбешәбез дә, син үз юлыңнан китәсең, мин үз юлымнан китәм. Син мине ирегеп көтәсең, мин сине ирегеп яшим. Шылай ирегешеп картаябыз. Аңнисыңмы?

А л и я. Аңнамим.

А й м ә т. Ницек инде аңнамисың? Ницек итеп ирегүләрен. Аңнамисыңмы? Мыний былай итеп утыралар, тулган айга багалар да ерлилар. *(Җырлап та күрсәтә.)*

Их, целбәем, тал нәзек,
Талдан билләрең нәзек.
Талдан нәзек билләреңә
Булма келим беләзек.

Инде аңнадыңмы?

А л и я. Юк.

А й м ә т. Вата кил мында. Куй циләкләреңне. Вата утыр. Айны кюрәсеңме?

А л и я. Кюрәм.

А й м ә т. Вата бак шыңа. *(Алияне биленнән кочаклап.)* Ай тагын да яхшыракмы кюренә?

А л и я. Кюренә.

А й м ә т *(тагын да кысыбрак кочаклап).* Тагын дамы яхшырак кюренә?

А л и я. Әйе.

Х а н и я *(агачлар арасыннан атылып чыгып).* Ебәр апаны. *(Аймәт кочагыннан ычкынып өлгергән Алиягә.)* Апа, нишләтте? *(Аймәткә.)* Апаны нишләттең?

А й м ә т. Апаң су алып катьканда абынып егылган, билен авырттырган. Шыны турайттык.

Х а н и я *(Алиягә).* Апа, цынмы?

А л и я. Цын.

Х а н и я *(Аймәткә).* Алдисың.

А й м ә т. Алдамим.

Х а н и я. Апа, авыртуы беттеме?

А л и я *(чиләк-көянтәләрен алып).* Бетте. *(Чишмәгә төшеп китә.)*

Х а н и я *(Аймәткә).* Коцакладыңмы?

А й м ә т. Юк.

Х а н и я. Коцакладың. Багып тордым. Бак кюземә.

А й м ә т. Йә, бактым.

Х а н и я. Башыңы сугып ярырмын. Син мине дә коцаклисың, Сания апаны да коцаклисың, Алия апаны да коцаклисың.

А й м ә т. Качан сине коцаклаганым бар?

Х а н и я. Төнә коцакладыңмы? Коцакладың. *(Асимәнең килгәнен күреп).* Кац... Адә.

Кача-поса үрмәләп, агачлар арасына кереп китәләр.
А с и м ә, С а н и я керәләр.

А с и м ә. Хания!.. Хания!.. Кая ул?

С а н и я. Белмим.

А с и м ә. Һай яфаланам сезнең белән. Сезнең аркада Константиновкага марҗалар биюен багарга бармица калдым.

С а н и я. Без нишләгән...

А с и м ә. Белмимме мин? Күрмимме мин? Алия кая?

С а н и я. Үзең беләсең. Су таши да су таши.

Судан А л и я кайтып килә.

А с и м ә. Ханияне кюрдеңме?

А л и я. Юк.

А с и м ә *(Саниягә).* Бар, бак су буеннан. *(Алиягә.)* Ристан кая?

А л и я. Кем?

А с и м ә. Аләүетдиннең ристаны. Сүләштегезме?

А л и я . Сүләштек.

А с и м ә. Нәрсә диеп сүли?.. Нәк яшмисең?.. Ярый, бар, кать. *(Алия киткәч.)* Хания! Хания!.. Сания!.. Сания!.. *(Агачка утырып.)* Ай бу кызларны. Ай бу кызларны. Әти-әниләре уйлап та бакми. Мин яфаланып ерим. Әле дә яри үзем бар. Мин булмасам нишләрләр. *(«Жаныкаем» көенә җыр суза.)*

Былбыл кош моңая, әй, тугайда.
Мин моңаям нигә бу айда?
Моңайсам да юктыр, әй, бер файда,
Севеп ергән ярым, син кайда,
Севеп ергән ярым, син кайда ла?
Егълаулардан юктыр, шыл, бер файда.

Вата дөнья. Саниясе дә югалды. Сания! Хания! *(Чыгып китә.)*

Хания чыгып артыннан карап кала да кул изәп, Аймәтне чакыра.

Хания. Цык. Куркма.

Аймәт. Кулында таягы бар.

Хания. Ул атә генә, сукми. Кацып торганда син ни уйладың?

Аймәт. Эзләп тапмаса ярар иде дип уйладым.

Хания. Мин дә шыны уйладым. *(Агачка утырып.)* Син дә утыр. Якынрак утыр. Айны кюрәсеңме?

Аймәт. Кюрәм.

Хания. Якынрак утыр. Бик якын килмә. *(Аймәт күчеп утыргач.)* Ай тагын дамы яхшырак кюренә?

Аймәт. Кюренә.

Хания. Тагы да якынрак утыр. *(Аймәт күчебрәк утыргач.)* Тагы да яхшыракмы кюренә?

Аймәт. Әйе.

Хания. Адә, Казанца сүләшәбез.

Аймәт. Адә.

Хания. Син мине яратасыңмы?

Аймәт. Ә?

Хания. Яратасыңмы, димен.

Аймәт *(каушабрак калган)*. Яратам.

Хания. Кыцкырыбрак ать.

Аймәт. Яра-та-ам...

Хания. Якын килмә. Тешлим. Анауында китеп утыр. *(Аймәт читкәрәк күчеп утыргач.)* Ерла.

Аймәт. Казан сөлгесенме?

Хания. Шыны.

Аймәт. Таптым. Таптым Казан сөлгесен,
Апасыннан матур сеңлесе.

Хания. Касы апасыннан? Санияападанмы? Алияападанмы?

Аймәт. Икесеннән дә.

Хания. Ярату ул ницек була?

Аймәт. Мыний шылай була.

Хания. Апасының да биленнән коцаклау, сеңелесенең дә биленнән коцаклау буламы?

Аймәт. Сине коцакламадым бит.

Хания. Мин коцаклаттырмадым. Кулларыңны сузган идең. Белеп тор: мин синнән дә хайләкәр. Синең Япониядә булганың бармы?

А й м ә т. Юк.

Х а н и я. Алып бар мине Япониягә.

А й м ә т. Нәрсә?

Х а н и я. Японияне кюргем кели.

А й м ә т. Нәрсә сез барыгыз да Япония белән саташасыз? Минем әти дә Япониягә китәм диеп ери.

Х а н и я. Аләүетдин абзимы? Ать анарга, мине дә алып барсын.

А й м ә т. Сине башта Казанга алып барырга кирәк.

Х а н и я. Нәк?

А й м ә т. Психиатрга күрсәтергә.

Х а н и я. Тиле икәнсең син. *(Торып китә башлый.)*

А й м ә т *(аның артыннан барып).* Ацуланма инде, мин шаярдым гына, мыскыллап кына атьтем.

Х а н и я. Тезләнеп гафу үтен.

А й м ә т *(тезләнеп).* Зинһар өцен, афу ит.

Х а н и я. Сау бул.

А й м ә т. Китмә инде.

Х а н и я. Минем йокым кели. Балалар бу вакытта йокларга тиеш. Озатма да. Мин сиңа үпкәләдем. Үпкәләвем беткәц сүләшербез. *(Китеп бара.)*

Аймәт әлеге дә баягы яраткан агачы өстенә ятып җыр суза. С а н и я керә. Аймәтнең җырын бирелеп тыңлый.

А й м ә т *(Санияне инде күптән күреп алган).* Ошимы сиңа минем ерым?

С а н и я. Синең ерың тегел ул — халык еры.

А й м ә т. Ерлавым ошимы димен мин сиңа?

С а н и я. Кызлар белән ятып сүләшмиләр.

А й м ә т *(сикереп торып).* Афу ит, зинһар, афу ит. Бак, авылда үңгә кызлар юк мәллә ул? Кюл буенда сез генә йөрисез.

С а н и я. Сиңа урын етмиме аллә? Үңгә кызларны күргең келәсә, ары як кизләүгә бар. Абдрахман абзи кызы шында ери суга.

А й м ә т. Шылаймы?

С а н и я. Шылай шыл.

А й м ә т. Кил мында, утыр шында.

С а н и я. Сүзең булса, үзең кил.

А й м ә т. Нәк алай сүләшәсең?

С а н и я. Ницек сүләшәм?

А й м ә т. Төнә алай сүләшмәгән идең.

С а н и я. Төнә мин бер көнгә яшьрәк идем.

А й м ә т. Бүген бер көнгәме картайдың? *(Сания янына килеп.)* Адә, ямьне итеп сүләшик.

С а н и я. Сүлә.

А й м ә т. Сандугац, беләсеңме, нәк сайрый? Ул минем сайравымны Аймәт белән Сания тыңнасын диеп сайрами. Ул ата сандугацны цакырып сайри. *(Сандугач булып сайрый.)* Ана сандугац сайравын тыңнап башы әләнә дә ата сандугацның йерәге елкенә. Шыннан ана сандугац янына оцып килә. Шыннан ана сандугац сори, кая ердең, дир. Мин сине ирегеп көттем, дир. Ата сандугацның башы тагы да катырак әләнеп китә. Ана сандугацны коцаклап ала. Син аңнисыңмы минем ни сүләгәнемне?

С а н и я. Сүлә.

А й м ә т. Күгерценнәр дә шылай. Ана күгерцен, ата күгерценгә ошарга тырышып, ызба кыегында түшен киереп егереп ери. Ата күгерцен ана күгерценнең түш киереп ергәнен циттән багып тора. Ана күгерцен ергә оцып төшә дә ердән шылай ери башли. *(Йөреп күрсәтә.)* Ата күгерцен һаман да циттән багып тора. Уйли эценнән генә — ошимы ул миңа, юкмы? Ана күгерцен дә ата күгерценнең багып торганын сизә. Тагын да ямьнерәк ери башлый. Ата күгерцен уйли — бу миңа оши. Ана күгерценнең янына килә. Шыннан ана күгерцен атә ата күгерценгә, син дә минем кебек ереп күрсәт, дир. Шыннан алар икәүләп түшләрен киереп ериләр. Аннан соң үбешәләр. Син аңнисыңмы минем ни сүләгәнне?

С а н и я. Сүлә.

А й м ә т. Вата балыклар да үбешә, бакалар да үбешә. Еланнар да коцаклаша. Куллары юк — коцаклашалар. Вата син уйлисың, агацларның яны юк. Бар. Агацлар да коцаклаша. Вата син микроскоптан бак. Бер тамцы суны ал да пиялага куй. Шынарга бак микроскоптан. У-у, андагы микроблар! Миллион! Бары да болгана. Нәк болгана? Әрбер микроб үзенең парын эзли. Шыннан эзләп таба. Коцаклашалар. Вата филләр коцаклашми. Алар үбешә. Ата фил борынын шылай итеп суза, ана фил дә шылай итеп суза. Шыннан чулт — үбешәләр. Ни сүләгәнемне аңнадыңмы инде?

С а н и я. Сүлә, сүлә...

А й м ә т. Мин инде сүләдем. Син аңнадыңмы?

С а н и я. Аңнадым.

А й м ә т. Нәрсә аңнадың?

С а н и я. Мин сандугач булып сайрасам, күгәрчен булып éрсәм, бака булып үбешсәм, син миңа үләнәсеңме?

А й м ә т. Ницек дидең?

С а н и я. Үләнәсеңме?

А й м ә т. Ә син цыгасыңмы?

С а н и я. Ата сандугач булып оцып килсәң, күгәрчен булып янымда ересәң, бака булып сайрасаң, цыгам.

А й м ә т. Ах, город Магадан!
Күренәдер һавадан.
Шыл сүзеңне ямьне итеп
Атьце әле яңадан.

С а н и я. Микроб булып озак болганып ересәң, цыкмыйм.

А й м ә т. Ах, город Кустанай!
С крутыми горами,
Атьмә әле шыл сүзеңне
Ерәгемә ярами.

С а н и я. Син елан булып шуышып килсәң, мин синнән курксам, син, куркма, мин елан тегел, дип, кабыгыңны салсаң, безнең күрше егете Аймәт абый булып калсаң, цыгам.

А й м ә т. Ах, город Саратов!
Багып торам яратып;
Тагын атьце шыл сүзеңне,
Шикләремне таратып.

С а н и я. Син мине күтәрсеңме соң? Ахылдамыйца гына күтәрсеңме?

А й м ә т. Ницә ел?

С а н и я. Үмерең буена.

А й м ә т. Күтәрмен.

С а н и я. Мин сиңа «йерәк маем» дип кенә атермен. *(Ханиянең елаганын ишетеп тынып калалар. Сания як-ягына карана.)* Кем ул елый?.. Хания елый. *(Эзлиләр. Агач артыннан табып алалар. Сания Ханияне кочаклап.)* Хания, нәк елыйсың?

Х а н и я. Ул миңа сүвәм диде.

С а н и я. Кем?

Х а н и я *(Аймәтне күрсәтеп)*. Ул. Сине генә сүвәм диде.

С а н и я *(Аймәткә)*. Атьтеңме?

А й м ә т. Сүвәм димәдем, яратам дидем. Сине генә дә димәдем. *(Ханиягә.)* Син сорадың, син мине яратасыңмы дидең. Мин яратам дидем. Сүвәм димәдем. Шынди кызга ницек инде яратмим дип атим?

С а н и я. Ерладың. Казан сөлгесен.

А й м ә т. Ерладым.

Х а н и я. Сүмәгәц нәк ерладың?

А й м ә т. Мин сүвәм димәдем. Мин сине яратам гына.

Х а н и я. Сания апага да яратам дидең.

А й м ә т. Яратам димәдем. Сүвәм дидем.

Х а н и я. Алия апаны да коцакладың.

А й м ә т. Мин анарга сүвәм дип атьмәдем.

Х а н и я. Сүмәгәц нәк коцакладың?

А й м ә т. Мин аның биленнән генә коцакладым. Сүвәм дип атьмәдем. Сиңа да мин яратам дип кызларга атькән кебек атьмәдем. Балаларга атькән кебек атьтем. Укытуцы атә бит балаларга, балалар, мин сезне яратам, дир.

Х а н и я. Әллә укытуцы булдың? Син әле үзеңдә укуцы гына.

А й м ә т. Укуцы тегел. Студент.

Х а н и я. Сания апа, нәк син яшьмисең? Ать алдалакка, сине сүмим, диген. Ать инде, Сания апа. Ать инде…

А й м ә т. Хания! Бар үгә кать. Сиңа йокларга вакыт. Балалар төнне йөрми. Адә, Сания.

С а н и я. Кая?

А й м ә т. Күлдә айның юынганын багабыз.

Х а н и я. Мин дә барам.

А й м ә т. Еламасаң гына бар. Кыз-катыннар белән сабиларның елаганы йерәгемә ярами.

Х а н и я. Мин бармим.

А й м ә т. Хуп мәйле, балдыз.

Х а н и я. Барам.

А й м ә т. Хуп мәйле. Әйдәгез.

Х а н и я. Бармим.

А й м ә т. Хуп мәйле, балдыз. Киттек, Сания.

Х а н и я. Тиле!

Чыгып киткән А й м ә т белән С а н и я артыннан «Тиле! Тиле!» дип кычкырып кала да җиргә утырып җылый. «Хания! Сания!» дип, оныкларын чакырып, А с и м ә керә.

А с и м ә *(Ханияне күреп)*. Ни булды?

Х а н и я. Бәбәгемә цебен керде.

А с и м ә. Йә, карик.

Х а н и я. Цыкты инде.

А с и м ә. Үгә кать.

Х а н и я. Катьмим.

А с и м ә. Хания!.. Кемгә атям... *(Ханияне кочагына алып сөя.)* Бар, кызым. Бар. Үдән цыкма да. Етәр вакыт — цыгарсың. Мин дә хазер катям. Константиновкага барам да катям.

Хания чыгып китә. Айшәбикәнең «Тотыгыз! Тотыгыз!» дигән тавышы ишетелә. Гармунын култык астына кыстырган А л ә ү е т д и н йөгереп үтә. Аның артыннан А й ш ә б и к ә чаба. Көлә-көлә, «Тотыгыз!» дип кычкырып, М и ң н у р ы й җилдерә. Асимә дә алардан калмый, «Тотыгыз!» дия-дия чыгып чаба. Ү м ә р белән М и ң с ы л у көчкә сулыш алып кереп егылалар.)

Ү м ә р. Уф!.. Миңсылу, тыңна минем йерәкне, нишли?

М и ң с ы л у. «Санта-Барбара» бетте микән?

Ү м ә р. Син минем йерәкне тыңна. *(Миңсылу, үрмәләп килеп, колагын Үмәр күкрәгенә куйгач.)* Нишли?

М и ң с ы л у. Ишетмим.

Ү м ә р. Син аллә каягы Сисинең йерәген иштәсең, Үмәрнекен иштмисең. Тыңна!

М и ң с ы л у. Иштелми.

Ү м ә р. Төшепме калган? Адә...

М и ң с ы л у. Кая?

Ү м ә р. Мин куып тотам теге марякны. Колак төбенә берне ямим. Аннан катябыз. Адә.

Ашыгып чыгып китәләр. Кулга-кул тотынышып,
А й м ә т белән С а н и я керәләр.

А й м ә т *(туктап)*. Хания!..

С а н и я. Мин Хания тегел.

А й м ә т. Афу ит, Хания..

С а н и я. Мин Хания тегел...

А й м ә т. Нишләдем мин, ә? Юк, мин Хания турында уйламим, синең турыда гына уйлим, Сания. Син миңа бик тә, бик тә ошадың. Сүгән кызым шындый булсын иде дип мин төннәр йоклами уйланам.

С а н и я. Син алдамица гына сүлә. Мин сиңа дересен сүләсәң дә ышанам.

А й м ә т. Цынмы, Сания? Ошадыммы мин сиңа?

С а н и я. Ошисың.

А й м ә т. Цынмы, Сания? Сүвәсең дәме?

С а н и я. Бәлки, сүвәрмен дә.

А й м ә т. Цынмы, Сания? Миңа кияүгә дә цыгарсыңмы?

С а н и я. Цыгармын да. *(Аймәт кочакларга үрелгәч.)* Коцаклама. Катының булгац коцакларсың. Мин сиңа Казан кызы тегел, кияүгә цыкканцы коцаклатырга.

А й м ә т. Мин бит билеңнән генә коцаклим. Билең бигрәк нәзек бит.

С а н и я. Күп коцакласалар, калыная ул. Кулымнан гына тотып ере.

А й м ә т. Детсат ыланының гына кулыннан тотып ериләр.

С а н и я. Мин үмерем буена синең өцен детсат ыланы булырмын. Тотып кая алып барсаң, шында барырмын. Суң кулың белән мине тотсаң, уң кулың белән ун ыланыңны тотарсың.

А й м ә т. Унау?..

С а н и я. Унау, йерәк маем, унау. Алты малай. Дүрт кыз... Шының өцен укуыңны укып кал, үләнгәц укыргым бар диеп еремә. Синең ыланнарыңны кем ашатсын да кем киендерсен, ерәк маем. Япуниягә китәм диеп уйлама, ун ыланыңны артыңа ябыштырып ебәрәм.

А й м ә т. Вата катты койрык бозга. Әллә исән цакта кациммы синнән.

С а н и я. Юк инде, кулымнан тоттың, каца алмисың. Ебәрмим мин сине.

А й м ә т. Цынмы атәсең, Сания?

С а н и я. Мин масхар итә белмим бит, йерәк маем, абзикаем.

А й м ә т. Каян үрәндең син шылай ямьне итеп сүләшергә?

С а н и я. Синең әниеңнән. Ул Аләүетдин абзига, йерәк маем, диеп кенә тора.

А й м ә т. Болай булса, мин сиңа үләнәм, Сания.

С а н и я. Цыксам, үләнерсең.

А й м ә т. Цыгам, дидең.

С а н и я. Цыгам димәдем, цыгармын да, дидем, ебәрмим, дидем.

А й м ә т. Ир белән катын булгац, тотынышып ереп булмас, кыз белән егет цакта тотынышып шыл кюл тирәсендә ереп катик, Сания.

С а н и я. Катик, йерәк маем, катик.

А й м ә т. Калды ич, калды ич, Казан сөлгесе,
Сеңлесеннән дә, апасыннан да яхшы Саниясе.

Җитәкләшеп чыгып китәләр. А л и я н е ң кулыннан сөйрәп, Х а н и я керә.

А л и я. Кая алып барасың мине?

Х а н и я *(каранып)*. Әнә, әнә алар. Кюрәсеңме кемнәр?

А л и я. Кюрәм.

Х а н и я. Каласың. Карт кыз булып каласың. Ул ристан Сания апага үләнәцәк. Сания апа да аны сүә. Үзем кюрдем. Каласың.

А л и я. Ул мине сүми.

Х а н и я. Ә син сүдерә белмисең. Кызлар сүвә белергә дә, сүдерә белергә дә тиеш. Аңнисыңмы? Каласың.

А л и я. Нишлим соң?

Х а н и я. Уйла. Баш сиңа ни өцен бирелгән. Нәк елисың? Елама. Елак кызларны егетләр сүми. Күпме үрәтәм мин сине. Адә, киттек. Сания апага атәбез, апаң барында алга цыкма дибез.

А л и я. Алай ярами.

Х а н и я. Мин атькац яри. Адә…

А л и я. Бармим.

Х а н и я. Адә, диләр сиңа. Каласың.

А л и я. Үземә тиңе табылыр.

Х а н и я. Бу ристан бик ямьне бит. Аны езни дип әтү үзе ни тора.

А л и я. Саниягә үләнсә дә, сиңа езни була инде.

Х а н и я. Сания апага минем ацуым килде. Ристанны тартып алды. Адә, үзеннән дә тартып алабыз. Адә.

Айшәбикәнең «Тотыгыз!» дигән тавышы ишетелә. А л ә ү е т д и н йөгереп керә. Алия белән Хания аңа асылыналар. Бу бәхеттән Аләүетдин каушап кала, туктап, кызларга карап тора. А й ш ә б и к ә керә.

А й ш ә б и к ә. Ебәрегез Аләүетдинемне! *(Аләүетдинне кызлар кулыннан тартып ала.)*

А с и м ә атылып кереп, «Тотыгыз!» дия-дия Аләүетдингә асылынырга тели. Айшәбикә аны Аләүетдингә якын җибәрми.

Китегез! Аләүетдин минеке. Һай, Аләүетдин, Аләүетдин!.. Һай, йерәк маем! Ниләр генә булды соң сиңа? Кил шында,

утырып ян тарт, йерәк маем. Асимәттай, ебәрмә. Кил. Кил, Аләүетдин... *(Аләүетдинне агачка утыртып.)* Арыдыңмы, йерәк маем?

Аләүетдин. Сакаяма, футаям, каталама...

Асимә. Нәрсә дир ул?

Айшәбикә. Япунца сүләшә, Асимәттай, япунца...

Асимә. Безнеңцә ницек була?

Айшәбикә. Белмим, Асимәттай, белмим. Ни дип атәсең, Аләүетдин?

Аләүетдин. Футаяма, каталама...

Айшәбикә. Аңнамим бит, Аләүетдин, йерәк маем, аңнамим.

Асимә. Футаямасын белмим, каталамасы колакка якын сүз. Япуния мишәрләренең сүзе тегелме икән.

Айшәбикә. Сүләмә инде син дә юкны, Асимәттай. Япуниядә мишәр бармы?

Асимә. Булмагац нәк анда барам дир. Булмады инде. Айшәбикә, кызымны сезгә бирмим инде. Башкода ебәрцәң дә бирмим. Ацуланма да...

Айшәбикә. Нәк алай дисең, Асимәттай?

Асимә. Сез футаямаларга кыз биреп сакаяма булып ерисем килми.

Айшәбикә. Анди тегел ул. Кылына гына ул, Асимәттай, кылына гына. Ать, Аләүетдин, кылынам гына, диген.

Көлә-көлә Миңнурый керә.

Миңнурый. Ай рәхәт! Вата рәхәт!.. Вата кызык!

Айшәбикә. Нәрсә көләсең, йә, нәк көләсең?

Миңнурый. Күпердән цыкканда Үмәр езни суга егылып төште. *(Көлә. Аңа Аләүетдин кушыла.)*

Асимә. Һи-и, һи-и... Сез барыгыз да тилергән. Бирмим кызымны, бирмим сез тилергәннәргә.

Айшәбикә. Миңнури, тукта! Ницек син көлә аласың? Күрмисеңме апаңның хален.

Миңнурый. Сиңа ни булган?

Айшәбикә. Бак моңа, Асимәттай, ни булган, дир. Аләүетдин езнәң Константиновкада маржа биетеп ери, без аны куып ерибез. Ул, ни булган, дир. Аләүетдин езнәсе япунца сүләшә, ул, ни булган, дир.

Миңнурый. Япунца? Цынмы, Аләүетдин езни?

Аләүетдин. Балдаяма, Миңнури, сузуки.

Миңнурый. Аңлаяма, Аләүетдини езники.

А л ә ү е т д и н. Үдәяна ятаяна...

А й ш ә б и к ә. Асимәттай, нишлиләр алар?

А с и м ә. Барыгыз да тиле. Саубуллама дураклама. *(Китә башлый.)*

А й ш ә б и к ә. Асимәттай. Калдырма мине болар белән. Аләүетдин, йерәк маем, йылим бит. Миңнури сеңелем...

М и ң н у р ы й. Нәрсә инде син... Кил, утыр Аләүетдин езни янына. Әйт Аләүетдин езнигә япунца ямьне сүз.

А й ш ә б и к ә *(Аләүетдин янына утырып)*. Аләүетдин, йерәк маем. Футаяма.

А л ә ү е т д и н. Сакаяма, Айшук, сакаяма. Кюрәсеңме син бу ямьнелекне?

А й ш ә б и к ә. Кюрәм, Аләүетдин.

А л ә ү е т д и н. Син дә кюрәсеңме, Асимәттай?

А с и м ә. Мин аны сиңа хәтле үк кюргән.

А л ә ү е т д и н. Ә син вата бу кюйне беләсеңме? *(Уйнап күрсәтә.)*

А й ш ә б и к ә. Аләүетдин, катик үгә.

А л ә ү е т д и н. Бар. Кать. Бак, «Трапиканка»ңны, бак «Санта-Барбара»ны. Без Япуниягә китәбез. Китәсеңме езнәң белән, Миңнури балдыз?

М и ң н у р ы й. Китәм, Аләүетдин езни.

А л ә ү е т д и н. Китәсеңме безнең белән, Асимәттай?

А с и м ә. Нишлим, Айшук?

А й ш ә б и к ә. Аллә без дә китәбезме, Асимәттай?

А с и м ә. Әй-й-әй, кеше киткән ердән калырга... Китәбез.

Х а н и я *(Асимә янына килеп).* Әби, алып бар мине дә Япониягә.

А с и м ә. Ә сез монда нишләп йөрисез?..

Ах-ух килеп, Ү м ә р белән М и ң с ы л у килеп керәләр. Үмәр, җиңнәрен сызганып, Аләүетдин өстенә бара.

А й ш ә б и к ә *(Үмәр юлына аркылы төшеп)*. Аләүетдингә якын килмә, Үмәр езни.

М и ң н у р ы й *(Айшәбикә янына басып).* Үмәр езни, тимә Аләүетдин езнигә.

А с и м ә *(Айшәбикә белән Миңнурый янәшәсенә басып).* Кулың сузма Аләүетдингә.

Ү м ә р. Нишлисез сез?

М и ң н у р ы й. Без барыбыз да Япониягә китәбез.

Ү м ә р. Миңсылу, нишлиләр алар?

М и ң с ы л у. «Санта-Барбара»ны бакми калдык.

М и ң н у р ы й. Апа, барып катик Япониягә, аннан карарбыз. *(Үмәргә.)* Үмәр езни, алып бар апаны Япониягә.

Ү м ә р. Аллә бармас дисезме. Уня гармуныңны, Аләүетдин базя. Ать, Миңсылу такмагыңны.

М и ң с ы л у. Целбәем бар, целбәем бар,
Целбәем бар — минеке.
Минем целбәем минеке,
Синеке — тиленеке.

Аңа бүтәннәр кушылалар. Такмак әйтә-әйтә бииләр.

Их, целбәем, целбәем,
Целбәем — йерәк маем.
Син целбәйне кюргем кели,
Кәзәне кюргән саен.
Целбәемә бик килешә
Цабатасы, чулкасы.
Алмасам да кайгырмимын,
Кесәмдә карточкасы.
Бер целбәем армиядә,
Икенцесе төрмәдә.
Өценцесе сознательный —
Ятып тора өргәдә.
Их, целбәй — күәндә,
Су буена кил әлдә.
Цәцең тарап битеңне ю
Су буена килгәндә.

А с и м ә. Туктагыз! Мында минем кызларым бар. Алар да биесен. Биегез. Барын да уздырып биегез. Уня, Аләүетдин!

Аләүетдин уйный, Хания бии. Калганнар аны куәтләп кул чабып торалар.

А й ш ә б и к ә. Булды, Аләүетдин арыды, үләрегезгә категыз. Барыгыз, бар, бар, бар. *(Бүтәннәр чыгып беткәч.)* Арыдыңмы, Аләүетдин, йерәк маем?

А л ә ү е т д и н. Юк, Айшәбикә. Аләүетдин ари белми ул.

А й ш ә б и к ә. Китмисеңме инде, Аләүетдин?

А л ә ү е т д и н. Әцәт суй дип бәләнмәсәң, китмим.

А й ш ә б и к ә. Ярый, ярый, Аләүетдин... Син мине сүвәсеңме соң, Аләүетдин?

Аләүетдин. Ә син сүвәсеңме?

Айшәбикә. Күреп торасың. Ике көндә ябыгып калдым. Мыни бак, билләрем нәзегәеп калды. Япун катыннарының да билләре нәзекме, Аләүетдин?

Аләүетдин. Нәзек.

Айшәбикә. Тихакиянда маряк булганда аларны коцакли идеңме?

Аләүетдин. Алар мине коцакли иде.

Айшәбикә *(Аләүетдинне кочаклап)*. Шылай итепме, Аләүетдин?

Аләүетдин. Шылай.

Айшәбикә *(агачлар арасыннан җитәкләшеп үтеп баручы Аймәт белән Санияне күреп.)* Аләүетдин, бак... кюрәсеңме?

Аләүетдин. Миңа сине күргәц бик еткән, Айшук.

Айшәбикә. Һай, шылай диеп атюләрең, Аләүетдин. Йерәк маем! Һай, Аләүетдин! Һай, йерәк маем.

Пәрдә.

## КҮРШЕ КЫЗЫ

*(Драма өч пәрдәдә, алты күренештә)*

Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта.

*Һ. Такташ*

Катнашалар:

Фәния — урта мәктәпне тәмамлап, тормышка яңа гына аяк баскан 18 яшьлек кыз.

Хәлим — инженер-механик. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, туган авылына кайткан, 26 яшьтә.

Әминә — зоотехник дипломының хуҗасы, 25 яшьтә.

Вахит — Фәниянең классташы.

Нурлидә — Фәниянең әнисе, 45 яшьтә.

Хәйретдин — авыл карты, 75 яшьтә.

Хәйдәр — комбайнчы егет. Хәлимнең тиңдәше.

Малай.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Өй арты. Канәфер куаклары. Куаклар эченәрәк кертеп эшләнгән утыргыч. Утыргыч өстендә, аякларын картларча бөкләп, Фәния утыра. Кич. Кайдадыр «Фазыл чишмәсе» көенә гармун моңлана. Фәния ул көйне йотылып-йотылып тыңлый. Аннан, көйгә кушылып, әкрен генә җырлый башлый.

Фәния. Чылтырап аккан чишмәгә
Суга дип килгән идем,
Тиз генә әйләнеп өйгә
Кайтырмын дигән идем.

Жыр артта дәвам итә.

Өздереп нигә карадың,
Ник тоттың чиләгемнән,
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән.

Жыр әкренәя.

Нинди матур җыр!

Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән.
Суларым түгел, ялкыным
Түгелде йөрәгемнән…

*(Шул сүзләрне кабатлый-кабатлый, утыргычтан сикереп төшә, сабыйларча тилелек белән сикеренгәли, аннан бармакларын бөгеп саный башлый.)* Егерме бише, егерме алтысы, егерме җидесе! Ә-әни!.. Әнием! *(Сикереп тора, коймага тотына.)* Әни!..

Тәрәзә ачыла. Н у р л и д ә күренә.

Н у р л и д ә. Нигә шулкадәр кычкырасың?

Ф ә н и я *(бармакларын бөгеп санап)*. Әнием, карап тор, егерме бише, егерме алтысы, егерме җидесе! Аннан ул кайтып та җитә.

Н у р л и д ә. Кем?

Ф ә н и я. Әйтмим, әнием. Ялынып сорасаң да әйтмим.

Н у р л и д ә. Кыланмыйча гына сөйләш.

Ф ә н и я. Бүген йә иртәгә кайтып җитә.

Н у р л и д ә. Әй тиле! Кер өйгә. Кайдан чыккан ул көн саен төн саклау? Кер!

Ф ә н и я. Кермим, әнием, мондый кичтә өйдә утырырга ярамый. *(Кире урынына утыра.)* Әни, ишетәсеңме, уйныйлар? Күрәсеңме, ай чыгып килә. Әнием, чык монда! Чык!

Н у р л и д ә. Унсигез яшькә җиттең, һаман акыл кереп бетми үзеңә.

Ф ә н и я. Мин җүләр, әйеме, әнием? *(Такмаклап.)* Мин җүләр, мин җүләр! Әнием, чык әйдә, кил, икәүләп җүләрләнәбез!

Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, кил инде!

Кил, кил, кил,
Кил, иркәм, кил инде!
Кил, иркәм, кил инде,
Елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине!

Тәрәзә ябыла.

Һәй, үпкәләде дә.
Кил, иркәм, кил инде,
Елмаеп көл инде,
Сагындым, бәгърем, сине!

Яңадан утыргыч өстенә менеп чүгәли. Гармун уйнап, Вахит үтеп бара. Фәния куаклар артына яшеренә. Вахит, Фәнияләр өе каршына килеп, тәрәзәгә карап тора. Аннан, авыр сулап, утыргычка утыра. Фәния, куаклар арасыннан чыгып, Вахитны утыргычтан этеп төшерә.

Фәния. Вахит килеп утырсын дип ясап куйган урындык юк монда.

Вахит. Фәния?!

Фәния. Ә мин синең нишләп йөргәнеңне беләм, әйтимме?

Вахит. Фәния...

Фәния. Өегездән гармуныңны күтәреп чыктың да урамның теге башында сыздырып җибәрдең. Янәсе, Фәния ишетсен дә йөгереп килсен. Мин бармагач, үзең килдең. Ә ник килгәнеңне әйтимме? Миңа мәхәббәтеңне аңлатырга. Йә, әйт, дөрес түгелме?

Вахит *(уңайсызланып)*. Дөрес.

Фәния. Менә күрдеңме? Сөйкемле сөягем бар минем. Йә, аңлат инде мәхәббәтеңне!

Вахит. Син һәрвакыт шаяртасың. Гел уенга гына борып алып китәсең.

Фәния. Сөйләшсәң, Вахит, үпкәләмичә генә сөйләш. Һай, тәрәзә янында нинди сүзләр сөйләшеп торабыз. Әни ишетсә, икебезнең дә кирәкне бирер. Әйдә тегендәрәк. Алып бар утыргычны.

Вахит утыргычны ала. Читкәрәк илтеп куя. Фәния утыра.

Вахит, теге көйне уйна әле. Тик әкрен генә. Йә инде...

Вахит уйный. Фәния җырлый.

Инешкә төшкән сукмакның
Читләре үлән генә.
Вәгъдәм бар сиңа, белмәсен
Тик күрше-күлән генә.

Матур көй, әйеме, Вахит? Яратам мин бу көйне. Син дә яратасың, әйеме? Кил, Вахит, син дә утыр. Күңел иркен булса, урын табыла, әйеме, Вахит? Гармунчы кешедән дә бәхетле кеше юктыр бу дөньяда. Вахит, мине дә өйрәт әле. Мең-мең рәхмәтләр укыр идем. Бер рәхмәт мең бәладән коткара, диләр бит.

Вахит. Хәзер соң инде. Аны кечкенәдән өйрәнергә кирәк.

Фәния. Өйрәнмәс дисеңме? Бир әле гармуныңны! *(Вахиттан гармунын ала да уйнап карый; көй чыгара алмагач туктый.)* Булмый икән. *(Вахитның сокланып каравын сизеп.)* Вахит, нигә алай карыйсың?

Вахит. Син, Фәния, дөрес әйттең. Мин сине эзләп йөрим. Көндезләрен дә, кичләрен дә — һәрвакыт сине эзлим. Син үзең якында гына, үзең еракта.

Фәния. Кызык итеп сөйлисең син, әйеме, Вахит?

Вахит. Нигә?

Фәния. Үзе якында, үзе еракта... Дөнья күргән кешеләр кебек.

Вахит. Нигә, күрмәгәнмени? Безгә унсигез яшь. Унсигез яшендә минем әти кулакларга каршы сугышкан.

Фәния. Әтиең бит ул, син түгел...

Вахит. Безгә дә җитдирәк булырга вакыт инде.

Фәния. Ә-ә-ә, онытып җибәргәнмен. Син һәрвакыт җитди булырга яратасың бит. Әле дә хәтеремдә, бишенче класста микән, алтынчыда бугай, син, Павел Корчагин кебек буласым килә, дигән идең. Тәки була алмадың бит, ә? Унбер классны бетердең дә комбайнчы ярдәмчесе булдың да куйдың. Һе, шул да булдымы егет эше?! Менә апаңнан өйрән син. Чебиләр үстерәм.

Вахит *(елмаеп)*. Әкәмәт син, Фәния!

Фәния. Нигә, мактанырга хакым юкмы әллә? Инкубатор чебиен үстереп кара әле син. Алар синең белән минем кебек кенә түгел. Син аннан хәзер елап качасың.

Вахит *(елмаеп)*. Мин аны әйтмим.

Фәния. Ә нәрсәне әйтәсең?

Вахит. Болай гына.

Ф ә н и я. Хәйретдин бабай әйтә, сүзләрен өзеп сөйләгән кешеләрне яратам, ди.

В а х и т. Ни әйтергә теләгәнемне беләсең ич инде...

Ф ә н и я *(кинәт җитдиләнеп)*.Вахит, син, безгә унсигез яшь, дидең. Бу чыннан да күп бит, ә? Без синең белән картаябыз икән бит инде. Егерме, егерме биш булыр, аннан нишләрбез? Беләсеңме, Вахит, мин үземнең илле яшьлек вакытымны күрәсем килә. Ул вакытта безнең авыл нинди булыр икән? Мин һаман да чебиләр үстерермен микән? Юк, мин югары белемле инженер булырмын. Сиңа көлкеме, Вахит?

В а х и т. Нигә көлке булсын?

Ф ә н и я. Әллә нәрсәләр сөйлим ич. Син башка сүз көтеп утырасың. Көтмә, Вахит. Әйтмим мин аны сиңа. Чынлап.

В а х и т. Мин барыбер ышанмыйм.

Ф ә н и я. Анысы синең эш. Вахит, син акыллы, җитди кеше. Ләкин мин башка кешене яратам.

Пауза.

В а х и т. Кемне?

Ф ә н и я. Хәлим абыйны.

В а х и т. Бу шаяртуың, Фәния, бөтенләй урынсыз.

Ф ә н и я. Әгәр шаяртмасам?

В а х и т. Соң... соң, Хәлим абый бит... Ә Әминә апа?

Ф ә н и я. Нәрсә «Әминә апа»?

В а х и т. Әминә апа белән алар хат алышып торалар бит. Мин беләм.

Ф ә н и я. Ялганлама.

В а х и т. Алар Казанда танышканнар.

Ф ә н и я. Ничек танышканнар?

В а х и т. Ничек икәнен белмим. Беркөн Әминә апаның авылдаш егете әйтте. Хәлим абый аңа хатлар язып тора икән.

Ф ә н и я. Көнләштерергә уйлама. Барыбер булдыра алмыйсың. Хәлим абый үзе дә мин яратканны белә. Мин булганда нишләп Әминә апа белән танышсын ди ул.

Пауза.

В а х и т. Нишләп соң, алайса, монда утырасың? Хәлим абый кайтты ич.

Ф ә н и я. Кайтты? Кайчан?

В а х и т. Мин килгәндә өйләренә кереп бара иде. *(Гармунын каты итеп тартып уйнап чыгып китә.)*

Ф ә н и я. Вахит, Вахит, тукта әле... Хәлим абый кайткан! *(Кинәт исенә килеп.)* Ай, нишләвем бу? *(Уйланып тора.)*

Н у р л и д ә чыга. Кулында — Фәниянең пальтосы.

Н у р л и д ә. Фәния!

Фәния куркып китә.

Туңып үләсең бит, төн сакчысы. Мә, өстеңә ки.

Ф ә н и я *(йөгереп килеп, әнисен кочып әйләндерә)*. Әнием, әнием!

Н у р л и д ә. Тукта, нишләвең бу?

Ф ә н и я. Әнием, Хәлим абый кайткан!

Н у р л и д ә. Кайтса ни?

Ф ә н и я. Эх, әнием, мин сиңа әйттем ич. Кайткан бит! Яңа гына кайтып төшкән. Әнием, мин хәзер кайтам.

Н у р л и д ә. Кая барасың?

Ф ә н и я. Хәлим абыйларга.

Н у р л и д ә. Нишлисең анда?

Ф ә н и я. Күрешергә, хәлен белергә.

Н у р л и д ә. Кеше юлдан арып кайткандыр. Күрешер өчен иртәгә дә көн бетмәгән.

Ф ә н и я. Тәрәзәдән генә карап киләм. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Х ә й р е т д и н керә.

Х ә й р е т д и н *(Нурлидәгә)*. Кая чаба тагын?

Н у р л и д ә. Хәтимә малае кайткан. Шуларга китте. Үлеп тора шул Хәлим абый дип. Бертуган абыйсы диярсең.

Х ә й р е т д и н. Һе... Ай-һай, әтчәйни кыз үстерәбез, Нурлидә килен. Хәерлегә генә булсын. Тәүфыйгы булсын инде.

Н у р л и д ә. Тәүфыйклы булмый нишләсен ул, минем сүземнән чыкмый...

Х ә й р е т д и н. Кем белә бит. Бишектә чагында шулай булгандыр да, хәзер синең сүзең белән генә яши алмый шул инде ул. Үзендә тәүфыйк булсын. Без аның белән кайчак серләшеп утырабыз. Күрсәң көнләшеп туймассың.

Су алып кайта да чәй куеп җибәрә. Мең төрле сораулар биреп аптырата. Нигә, Хәйретдин бабай, болай? Нигә тегеләй? Җавап биреп кенә өлгер. Үсә торган чагы шул. Канат кагынып очарга әзерләнгән чагы.

Нурлидә. Очар, Хәйретдин абзый, очар, күрми дә калырбыз әле.

Хәйретдин. Ничек очар бит, Нурлидә килен, кай якка очар.

Нурлидә. Башка кайгың булмаса, борчылма, Хәйретдин абзый.

Хәйретдин. Борчылма, дисеңме? Әле менә Минһаҗ янына кергән идем дә, бераз телгә килеп алдык. Хәзерге яшьләрне яманлый. Ә мин мактыйм. Эшли дә беләләр, яратыша да беләләр, дим. Минһаҗ әйтә, ашыкма әле, кордаш, ди. Эшли белүләренә сүзем юк, җир җимертәләр, ә тормыш итүләренең рәте-чираты юк, ди. Бәхәсләштек-бәхәсләштек, тәки очына чыга алмадык.

Нурлидә. Картлык көнегездә башка сөйләшер сүз тапмагансыз икән.

Хәйретдин. Тукта әле син, Нурлидә килен. Көләргә ашыкма. Үзең беләсең, Минһаҗ кордашның сүзе дә, бер уйласаң, ниерәк шул. Ике малай үстерде. Хәкимҗанына сүз әйтеп булмый. Җәмәгате белән матур яшиләр. Салихҗаны эчне пошыра. Кичә хат килгән, икенче хатынын да аерган. Менә бит. Үзе болай азган-тузган да түгел кебек иде. Минһаҗга аны ишетү җиңелме? Менә нигә алай ул? Ярый инде, безнең заманда көчләп өйләндерәләр, көчләп кияүгә бирәләр иде. Хәзер бит алай түгел. Хәзер бит әйтәләр, сөйгәнеңне ал, сөйгәнеңә бар, диләр. Рәхәтләнеп яшәгез, диләр. Минһаҗ әйтә, заманасы бик әйбәткә китте, яшьләрне шул боза, ди.

Нурлидә. Әйбәтлектән кеше бозыламыни?

Хәйретдин. Мин дә шулай дидем диюен. Тик барыбер эч пошып китте. Минһаҗ яныннан чыккач, чишмә буйларын урап уйланып йөрдем. Шунда бер егет белән кызның сөйләшкәннәре колагыма чалынды. Сүзләренең мәгънәсе юк, Нурлидә килен. Мәгънәсез сүзләр сөйләшәләр.

Нурлидә *(көлеп)*. Китсәнә, Хәйретдин абзый, килешмәгәнне… сүз тыңлап…

Хәйретдин. Килешә торган нәрсә түгел, билгеле. Туры килүен генә әйтәм. Шунда менә синең кызың исемә төште. Куркыбрак киттем.

Н у р л и д ә *(көлеп)*. Һи, Хәйретдин абзый, кирәкмәгәнне уйлап йөргәнче, өеңә кайт та тынычлап йокла.

Х ә й р е т д и н. Һе-һе-һе. Тынычлап йокла, имеш. Минем йоклыйсы көннәрем алда. Миңа чирек сәгать күз йомып алсам, шул җиткән. Әнә Нәфисә җиңгәң дүртенче елын йоклый. Бераз ашыкты шул, мәрхүмә. Җир өстен күреп калырга кирәк, Нурлидә килен. Мин йөрим әле. Дөньяны карап йөрим. Дус-ишләр янына кереп хәлләрен белешеп чыгыйм. Минһаҗның аягы сызлабрак тора әле. Хәерлегә генә булсын. Ярый, хуш иттек, Нурлидә килен.

Н у р л и д ә. Хуш, хуш. *(Кулындагы пальтосына карап, Фәния киткән якка бара башлый. Ләкин тукталып нәрсәдер уйлана да кереп китә.)*

Пауза. Урамнан Ә м и н ә белән Х ә й д ә р килә.

Х ә й д ә р. Тукта инде, слушай, әллә кем булма. Зоотехник дигәч тә, без дә төшеп калганнардан түгел.

Ә м и н ә. Нәрсә кирәк сезгә?

Х ә й д ә р. Йә инде, әллә кем булып, «сез» дигән булма. Син дә авыл кызы бит. Кем икәнеңне беләбез. Шәһәрдә укып кайттым дигәч тә…

Ә м и н ә. Барыгыз, кайтып йоклагыз.

Х ә й д ә р. Бик йоклар идем, синең аяк тавышың йокларга мишәйт итә. Үкчәле туфлиең белән йөрәккә басып йөрисең.

Ә м и н ә. Ничек, ничек? Кара нинди матур итеп сөйли беләсез икән сез!

Х ә й д ә р. Как же. Комбайнер дигәч тә, без дә культурный.

Ә м и н ә. Ярый, җибәрегез инде, соңга калам.

Х ә й д ә р. Курыкма, авылыгызга үзем илтеп куярмын. Әниеңә, минем белән булды, диярмен.

Ә м и н ә. Әйтегез әле, нәрсә кирәк соң сезгә?

Х ә й д ә р. Әйтегез дип, әйтәм, нигә… Яратам, слушай. Ышанмыйсыңмы? Валлаһи менә!

Ә м и н ә. Нишләп болай кинәт кенә ярата башладыгыз соң әле?

Х ә й д ә р. Кинәт кенә түгел, слушай, син кайтканнан бирле. Матур бит син, каһәр! Коеп куйган кебек. Любой егетне аяктан егарлык. Шушы яшькә җитеп, яратканым юк ие, сине күрүем булды — беттем.

Ә м и н ә. Йә, ярый, хушыгыз.

Х ә й д ә р. Тукта инде, слушай. Сөйләшик инде. Мин бит өйләнергә исәпләп йөрим, чык син миңа кияүгә. Чык, слушай, үкенмәссең. Әллә тиң түгел дисеңме? Миңа үзем кебек укыган кеше кирәк дисеңме? Курыкма. Укымасам да, кешедән ким яшәмим мин. Минем өй авылда бер.

Ә м и н ә. Ярый, мин уйлармын. Тик бүген җибәр.

Х ә й д ә р. Ну, слушай, син уйлаганны көтсәң, болай да утызга җитеп киләм инде. Әйдә, сразы безгә китәбез. Курыкма, синең чүпрәк-чапракларыңны иртәгә дә алып кайтып була.

Ә м и н ә. Сез, ахры, яхшылап әйткәнне аңламыйсыз?

Х ә й д ә р. Нишләп аңламаска? Аңлыйм... Ну, ярый, чурт с ним, уйла.

Ә м и н ә. Кая барасың?

Х ә й д ә р. Озатам. Укымасак та, аның тәртибен беләбез без.

Ә м и н ә. Мин үзем генә кайтам.

Х ә й д ә р. Кара әле, слушай, әйдә минем мотоцикл белән. Бу караңгыда сезнең авылга хәтле ике чакрым, үзеңә генә куркыныч. Әйдә.

Ә м и н ә. Икенче вакытта.

Х ә й д ә р. Кайчан?

Ә м и н ә. Бер җае чыгар әле.

Х ә й д ә р. Ну, слушай, җай чыкканны көтсәң...

Ә м и н ә. Уф! Нинди кеше соң син?

Х ә й д ә р. Минме? *(Кочаклап ала.)*

Ә м и н ә. Алыгыз кулыгызны!

Х ә й д ә р. Алмасам нишләтәсең?

Ә м и н ә *(тартылып ычкына)*. Китегез хәзер үк, кычкырам.

Х ә й д ә р. Булды, булды. Шаярганны аңла инде. Ну, пока, иртәгә көт, яме? *(Китә.)*

Ә м и н ә. Тәрбиясез!

Х ә л и м күренә. Шәһәрчә спай киенгән. Ул каядыр ашыга. Аның артыннан, аяк очларына гына басып, Ф ә н и я килә. Хәлим Әминә белән очраша.

Х ә л и м. Әминә?!

Ә м и н ә. Хәлим! Тукта әле, тукта, күземә ялгыш күренәсеңме соң? Ой! Тукта! Ничек болай?

Х ә л и м. Менә шулай. Кайттым.

Ә м и н ә. Көтмәгәндә. Менә бәхет! Мин тагын

авылыбызга кайтырга җыенып йөрим. *(Хәлимгә текәлеп карап тора.)* Нигә бер сүз дә әйтмисең?

Хәлим. Каушап калдым ич. Сине очратырмын дип уйламаган идем. Кайтып кердем дә авылны күрергә дип чыккан идем. Ә син мине көтеп торасың икән.

Әминә. Көтеп тормасам нишләр идең, эзләп барыр идеңме?

Хәлим. Тукта әле, нигә без урам уртасында басып торабыз? Утырыйк.

Әминә. Мин соңга калам.

Хәлим. Кайтып-килеп эшлисеңмени? Алай читен ич. Көн саен ике чакрым ара үтәсе.

Әминә. Башыңа төшкәч нишлисең.

Хәлим. Йә, утырыйк әле. Бүгенге төн безнеке.

Утыралар. Пауза. Фәния аларга таба ташлана. Ләкин, кинәт туктап, капкага таба чигенә. Өй артындагы рәшәткәгә тотынып күзәтә.

Әминә *(Хәлимнең күзләренә карап)*. Сагындырдың.

Хәлим. Бикме?

Әминә. Бик. Син сагындыңмы?

Хәлим. Сагындым.

Әминә. Алдашасың ич.

Хәлим. Ничек алдашам?

Әминә. Алдашасың. Югыйсә... *(Иркәләнеп Хәлимнең кочагына сыена.)*

Фәния йөзен кулы белән каплап кереп китә. Капка ябылган тавышка Хәлим белән Әминә караналар.

Кемдер бар.

Хәлим. Фәния кайткандыр.

Әминә. Кайдан?

Хәлим. Дөньяда болай утыручылар синең белән без генә түгел ич. Мин кайтканны белмидер әле. Югыйсә без болай утыра алмас идек.

Әминә. Нигә?

Хәлим. Мине күрсәме? Хәлим абый, ничек кайттың? Ничек укыдың? Ничә бишлең бар, дип сорашып, җанга тия башлый ул. Әкәмәт кызый. Яратам үзен. Шуның кебек сеңлем булмаган бит...

Әминә. Хәлим, мин үзгәргәнме?

Хәлим. Сизелми кебек.

Ә м и н ә. Үзгәрдем. Бик нык үзгәрдем. Картайдым, ямьсезләндем, тупасландым. Хәзер көзгегә карарга да куркам.

Х ә л и м *(Әминәнең йөзенә карап)*. Элекке кебек үк.

Әминә. Ә син аз гына да үзгәрмәгәнсең. Һаман да шул коры. Язган хатларың искә төшә дә, көләсем килеп китә.

Х ә л и м. Нигә?

Ә м и н ә. «Сәлам Казаннан. Исән-сау. Зачётларны уңышлы бирдем». Ә сөю, мәхәббәт турында ләм-мим. Әйтерсең лә мин сиңа чит кеше.

Х ә л и м. Син беләсең ич инде.

Ә м и н ә. Беләм шул, Хәлимем. Шуңа үпкәләмим дә. Әле дә хәтеремдә, син мине туган көнем белән котлап шигырь язып биргән идең.

Географлар, нигә алдашасыз,
Кара диңгез берәү генә, дисез.
Кара диңгез өчәү. Ышанмасагыз,
Килегез дә Әминәнең
Күзләренә карап китегез.

*(Көлә.)* Ничек яза алдың икән син аны? Хәлим…

Х ә л и м. Нәрсә, Әминә?

Ә м и н ә. Яратасыңмы?

Х ә л и м. Беләсең ич инде.

Ә м и н ә. Ә син кабатла.

Х ә л и м. Яратам.

Ә м и н ә. Тагын?

Х ә л и м. Яратам.

Ә м и н ә. Тагын?

Х ә л и м. Күпкә китә бит инде.

Ә м и н ә *(канәгатьләнеп көлә)*. Ә син санап барма. Мин синнән ул сүзне гел ишетеп торасым килә… Хәлим, әйдә безнең авылга.

Х ә л и м. Ә нигә сезнең авылга?

Ә м и н ә. Шулай. Мактана аласың. Мин генә түгел, минем әни дә сине көтә. Ул бөтенесен дә белә. Мин аңа сөйләдем. Хәлим кайту белән өйләнешәбез, дидем. Әни инде туйга да әзерләнә башлады.

Х ә л и м. Туйга?!

Ә м и н ә. Әллә вәгъдәңне оныттыңмы?

Х ә л и м. Бүген соң инде, Әминәкәй. Кияү булгач, әдәплерәк булырга кирәк. Иртәгә иркенләп барырмын. *(Көлеп.)* Киенеп, ясанып. Йә, сөйлә, үзеңнең эшләр ничек?

Ә м и н ә. Нинди эшләр?

Х ә л и м. Зоотехникның нинди эшләре барын син яхшырак беләсең инде.

Ә м и н ә. Аны әйтәсең икән. Начар.

Х ә л и м. Ничек начар?

Ә м и н ә. Шулай. Көнозын тирес, пычрак арасында сыер савучылар, көтүчеләр, чебеш үстерүчеләр белән талашып йөри-йөри ардым.

Х ә л и м. Баштарак, өйрәнгәнче, шулай була торгандыр инде ул. Зарар юк, өйрәнерсең. Без монда икәүләп җир җимертербез. Мин сезнең фермаларны механикалаштырып бирермен. Син фән буенча...

Ә м и н ә. Хәлим, кирәкми.

Х ә л и м. Нәрсә кирәкми?

Ә м и н ә. Очрашуның беренче сәгатендә үк андый сүзләр нәрсәгә? Минем сиңа карап торасым килә. Син кайттың, миңа шул җиткән. *(Хәлимгә сыена.)* Бүген өйгә кайтырга соңга калгач курыккан идем. Соңлавым шатлыкка булган, югыйсә сине тагын бер көн күрә алмыйча интеккән булыр идем. *(Иркәләнеп.)* Сине яратканыма үкенә башладым инде. Көтәргә дә көтәргә. Көтә-көтә картаеп беттем... Хәлим, әйдә чишмә буена. Син кайткач, шунда утырып сөйләшербез дип, мин анда бер урын сайлап куйдым. *(Хәлимне тартып торгыза, кочагына ташлана.)* Хәлим! Хәлимем! Син минем ничек шатланганымны белсәң иде. Эх, Хәлим! *(Хәлимнең кулыннан тотып.)* Әйдә, Хәлим, төн буе йөрибез! Бүген мин сине беркая да җибәрмим. Әйдә! *(Хәлимне җитәкләп алып чыгып китә.)*

Пауза.

Капкадан Ф ә н и я атылып чыга. Әминә белән Хәлимнең киткәннәрен күреп туктап кала. Аннан алар артыннан йөгермәкче була, тагын туктый.

Ф ә н и я. «Син сагындыңмы?» — «Бик!..» Юк!.. Кирәкми!..

Х ә й р е т д и н *(үтеп бара)*. Ни булды, кызым?

Ф ә н и я. Бабай!..

Х ә й р е т д и н. Чү-чү... Нигә кычкырасың?

Ф ә н и я. Синең кычкырган чагың булмадымыни, бабай?!

Х ә й р е т д и н. Кычкырганым бар, кызым. Тик кычкыруның төрлесе була бит.

Ф ә н и я. Эх, бабай!

## Икенче күренеш

Беренче күренештәге декорация. Кич. Ф ә н и я эш киеменнән эштән кайтып килә. Х ә л и м керә. Ул, әкрен генә килеп, Фәниянең күзләрен каплый. Фәния аптырап туктап кала.

Ф ә н и я *(дорфа)*. Кем ул? *(Тартыла.)*
Х ә л и м *(тавышын үзгәртеп)*. Мин бу…

Фәния Хәлимнең тавышын танып, кинәт тартылып ычкына. Куркынып, каушап, Хәлимгә карап тора. Хәлим рәхәтләнеп көлә.

Нигә курыктың, күрше кызы Фәния? Мин бу. Барыбер очраттым бит үзеңне. Миннән качып котыла алмассың. Бүген өегезгә кергән идем. Син юк. Нурлидә апа әйтә, эшкә китте, ди. Ай-яй, бик эшчән булып киткәнсең. Йә, күрешик. Исәнме, дус!

Ф ә н и я *(каушавы бетмәгән)*. Исәнмесез…

Х ә л и м. Ә нигә алай салкын гына исәнләшәсең? Мин тагын, юләр, әллә ниләр хыялланып йөрим. Фәния күрә дә кочагыма ташлана инде дип көтәм. Тукта әле, дәү кыз булгансың бит син. Кыш көне бәләкәй генә идең ич. Миннән рөхсәт сорамыйча, болай үсеп китүеңә ризалыгым юк.

Ф ә н и я *(ни әйтергә белмәгәннән)*. Бөтенләйгә… укып бетереп кайттыгызмы, Хәлим абый?

Х ә л и м. Билгеле. Әле ярый кайтып җиткәнмен, югыйсә мин кайтканчы кияүгә чыгып куйган булсаң, болай сокланып карый да алмас идем. Тфү-тфү, күз тимәсен.

Ф ә н и я. Колхозда эшләргә кайттыгызмы?

Х ә л и м. Кая барыйм ди, авыл хуҗалыгы институтын бетереп, аптекада дару сатып ятмам бит инде. Әйе, күрше кызы, Хәлим абыең хәзер инженер-механик. Ә нигә син болай күңелсез? Әллә минем кайтканымны ошатып бетермисеңме?

Ф ә н и я. Күңелсез түгел ич.

Х ә л и м. Күреп торам. Күзләрең моңсу. Әллә сөйгән ярың ташлап киттеме? Әйт, кем ул? Фәнияне ташлап китәргә рөхсәтем юк. Минем күршем Фәния бөтен авылга бер генә ул.

Фәния, Фәния, димәгез,
Фәниягә тимәгез!
Фәниягә тигән кеше
Рәхәт күрер димәгез.

Ф ә н и я. Сез бик шаянланып кайткансыз, Хәлим абый.

Х ә л и м. Ә нигә? Мин һәрвакыт шундый. Ах, курнос борын, үзең кем соң? Үзең бит әле кайчан гына, койма башына менеп, узган-барган чагымда: «Хәлим абый, Хәлим абый», — дип мине үртәп кала идең. Хәзер ул җитдиләнгән, үсеп киткән, имеш. Әллә кем булган. Ничә яшь инде сиңа? Тәк... Унөч, ундүрт. Кара, унсигез була икән ич. Менә сиңа мә! Чынлап та, синең белән шаярырга ярамый икән шул. Өлгергәнлек аттестатың да бардыр инде. Бармы?

Ф ә н и я. Бар.

Х ә л и м. Документларыңны җибәрдеңме әле?

Ф ә н и я. Кая?

Х ә л и м. Институтка.

Ф ә н и я. Институтка укырга керү өчен ике ел эшләргә кирәк.

Х ә л и м. Нурлидә ападан сораштым. Чебиләр үстерәсең икән. Үзеңне мактыйлар икән. Молодец, минем күрше булсын да, сынатсын, имеш! Чебиләрең хәзер тавык булгандыр инде.

Ф ә н и я. Бүген соңгыларын тапшырдым.

Х ә л и м. Инде нишләргә уйлыйсың?

Ф ә н и я. Белмим.

Х ә л и м. Безгә киләсеңме? Бригадага. Идарәдә сөйләшеп утырдылар, кыр станына аш пешерүче кирәк, диделәр. Кил безгә, мин сине өрмәгән җиргә дә утыртмам. Котлый аласың. Мин бит начальник. Әйе-әйе. Колхозда нинди тимер-томыр бар, бөтенесе миңа буйсынган. Шушы көннәрдә уракка чыгабыз. Нинди бәхет, ә, күрше кызы? Йә, килештекме?

Ф ә н и я. Юк.

Х ә л и м. Ни өчен?

Ф ә н и я. Мин аш пешерүче түгел.

Х ә л и м. Булырсың.

Ф ә н и я. Мин мәктәптә комбайн өйрәндем.

Х ә л и м. Шулаймыни?! Кечкенәдән үк малайлар кебек машиналар тирәсендә чуалырга ярата идең шул. Комбайнга ал дисеңмени? Алырбыз. Тик баштарак аш

пешерергә туры килер. Аннан комбайнга. Аннан укырга. Шулай ярыймы?

Ф ә н и я. Белмим.

Х ә л и м. Ә син бел. Белми яшәү килешми. Йә, киләсеңме?

Ф ә н и я. Белмим.

Х ә л и м. Булды, килештек. Бернинди дә белмим юк. Мин председательгә әйтермен, аш пешерүченең менә дигәнен таптым, диярмен. Билгеле, Фәния булсын да минем сүзне тыңламасын. *(Сәгатенә карап.)* Фәниякәй, соңга калам бит мин.

Ф ә н и я. Кая ашыгасыз, Хәлим абый?

Х ә л и м. Өйгә. Иртән чыгып киткәннән кайтканым юк. Ашап алырга кирәк тә, аннан...

Ф ә н и я. Аннан кая?

Х ә л и м. Әйтмим.

Ф ә н и я. Шәпкә авылынамы?

Х ә л и м. Кайдан белдең?

Ф ә н и я. Хәлим абый, сез аны бик яратасызмы?

Х ә л и м. Кемне?

Ф ә н и я. Әминә апаны.

Х ә л и м. Оһо, әнә син нәрсә беләсең икән!

Ф ә н и я. Яратасызмы?

Х ә л и м. Син сорау аласың түгелме соң?

Ф ә н и я. Әйтегез, Хәлим абый!

Х ә л и м. Синеңчә ничек соң?

Тәрәзә ачыла.

Н у р л и д ә. Фәния, кайттыңмы?

Ф ә н и я. Әйе, әни.

Н у р л и д ә. Әйдә, кер инде, хәзер аш әзерлим.

Х ә л и м. Хәерле кич, Нурлидә апа!

Н у р л и д ә. Ә, Хәлим, син дә андамыни? Әйтәм аны, дөньясын оныткан.

Х ә л и м. Күптән очрашкан юк бит. Сөйләшеп туеп булмый.

Н у р л и д ә. Сөйлисе дә юк инде. Шунда үзең белән Казанга алып китмәдең. Тик Хәлим абый дип артыннан ияреп йөрсен иде. Эшең әйбәт булдымы, кызым?

Х ә л и м. Соңгыларын тапшырдым, ди.

Н у р л и д ә. Бик әйбәт, озаклама, кызым. Вакытында ашап-эчәргә кирәк.

Тәрәзә ябыла.

Ф ә н и я. Хәзер, әнием.

Х ә л и м. Ашарга дигәч, ашарга, Фәния, шагом марш!

Ф ә н и я. Хәлим абый, сез әни белән алай шаярып сөйләшмәгез. Минем белән дә...

Х ә л и м. Нигә?

Ф ә н и я. Шулай.

Х ә л и м. Алай икән. Син әллә ниндигә әйләнгәнсең, Фәния. Йә, ярый...

Ф ә н и я. Хәлим абый, сез җавап бирмәдегез.

Х ә л и м. Әйтмим, үзең шаярып сөйләшкәнне дә яратмыйсың.

Ф ә н и я. Ә сез шаяртмыйча әйтегез.

Х ә л и м. Шаяртмыйчамы? Нигә кирәк ул сиңа?

Ф ә н и я. Кирәк. Беләсем килә.

Х ә л и м. Яратсам, ни әйтерсең?

Ф ә н и я. Сез аның белән кайчан таныштыгыз?

Х ә л и м. Кайчан икән соң? Ике еллап бардыр.

Ф ә н и я. Ә миңа әйтмәдегез.

Х ә л и м. Әйткәнем булмадымыни? Менә син, ә! Ничек әйтмәдем икән? Хәер, җае туры килмәгәндер. Үзең дә сорашмадың. Син ничек соң? Кайсы егетнең башын әйләндерәсең?

В а х и т керә. Хәлим, кинаяле итеп, Фәниягә карый.

В а х и т. Хәерле кич, Хәлим абый.

Х ә л и м *(кабаланып)*. Бетте баш. Эләктем. Менә телеңә салынып утырсаң. Качам, Вахит, гафу ит. *(Чыгып китә.)*

Ф ә н и я. Нигә килдең?

В а х и т. Килергә уйламаган идем, Хәлим абый белән утырганыңны күргәч... Фәния, алай эшләмә...

Ф ә н и я. Син нәрсә, сөенергә, сүзләреңнең дөреслеген тикшерергә килдеңме? Ишет, алайса, әйе, син хаклы. Алар хат язышып торганнар. Кичә очрашканнарын үз күзләрем белән күрдем. Ләкин минем мәхәббәтем көчлерәк.

В а х и т. Шуннан? *(Пауза.)* Хәлим абыйны Әминә ападан тартып алам дисеңме?

Ф ә н и я. Мин алай димәдем.

В а х и т. Нишләргә телисең соң?

П а у з а.

Ф ә н и я. Әминә апаның хакы юк. Ул Хәлим абыйны яратырга тиеш түгел иде.

В а х и т. Үч аласың инде, алайса?

Ф ә н и я. Алмыйм. Миңа бернәрсә дә кирәкми. Син дә кирәкмисең. Мин бернәрсә уйларга теләмим.

В а х и т. Уйламый ярамый бит, Фәния!..

Ф ә н и я. Юк, бер киңәшең дә кирәкми. Бар, кит, кирәкми.

В а х и т. Тукта әле син...

Ф ә н и я. Кит, Вахит. *(Вахит киткәч, үз-үзенә.)* Мин бернәрсә дә эшләргә теләмим! Теләмим! Теләмим! *(Әминәнең үтеп барганын күреп каушап кала. Аннан үзе дә сизмәстән.)* Әминә апа! Исәнмесез!

Ә м и н ә *(туктый)*. Исәнме, Фәния!

Ф ә н и я. Ашыгасызмы, Әминә апа?

Ә м и н ә *(сәгатенә карап)*. Ә нигә?

Ф ә н и я *(утыргычны алып килеп)*. Утырыгыз әле, Әминә апа.

Ә м и н ә *(аптыраган хәлдә килеп утыра)*. Йә, ни бар?

Ф ә н и я. Болай гына, Әминә апа. Бүген мин сезне көттем. Сез килмәдегез. Чебешләрне сездән башка гына тапшырдык.

Ә м и н ә. Ничек булды соң?

Ф ә н и я. Яхшы. Ә ни өчен килмәдегез?

Ә м и н ә. Сезгә җайлырак булсын өчен. Сез бит анда мине яратмыйсыз. Безгә мондый зоотехник кирәкми дип, бер җыелышта син үзең үк кычкырдың бит.

Ф ә н и я. Мин кычкырмадым, әйттем генә.

Ә м и н ә. Менә шул, хәзер күңелең булыр, мин зоотехник түгел.

Ф ә н и я. Кем соң?

Ә м и н ә. Анысын инде миңа уйларга рөхсәт ит. Әйтәсе сүзең шул идеме? *(Торып китә башлый.)*

Ф ә н и я. Әминә апа, минем сезгә тагын бер соравым бар.

Ә м и н ә *(көлемсерәп, канәгать)*. Йә, анысы нәрсә?

Ф ә н и я. Сез Хәлим абыйны бик яратасызмы?

Ә м и н ә. Ничек?

Ф ә н и я. Хәлим абыйны яратасызмы?

Ә м и н ә. Нигә кирәк ул сиңа?

Ф ә н и я. Кирәк булмаса сорамас идем. Йә, ярый,

әйтмәгез. Сез эшегез буенча да, белемегез буенча да миннән өлкәнрәк. Минем белән ул хакта сөйләшү сезгә уңайсыз. Тик менә мин сөйләгәндә, мине бала-чаганы тыңлаган кебек тыңламагыз. Миңа да унсигез яшь. Димәк, сездәге хисләр миндә дә бар. Дөресен генә әйтегез, Хәлим абыйны яратасызмы?

Әминә *(ни дип әйтергә дә белми, әңгәмәнең мондый борылыш алып китүенә аптырап)*. Йә, яратам ди, шуннан?

Фания. Өзеп әйтегез, минем беләсем килә. Ул миңа кирәк. Бу сезнең үзегезгә дә кирәк.

Әминә *(аптыраганнан-аптырый барып)*. Тукта әле, ни сөйлисең соң син?

Фания. Алайса, әйтегез, нәрсә ул ярату? Җавап бирмәгез, үзем әйтәм. Ярату ул сиңа ошаган кешегә ышану, аңа табыну, аны үзеңнең идеалың итеп күрә белү, хөрмәт итү, серләреңне аңардан яшермәү, авыр чакларда чын күңелдән ярдәм итү, кайгысын-шатлыгын уртаклашу, ул кешене күргән саен күрәсе килеп тору… Менә мин Хәлим абыйны шундый ярату белән яратам.

Әминә. Син?..

Фания. Әйе, яратам. Һәм бик күптәннән. Унике яшьлек чагымда ук безнең капка төбеннән Хәлим абыйның үтеп киткәнен сәгатьләр буе көтеп тора идем. Ул эштән кайтканда, аның каршысына йөгереп чыгып, ардыңмы, Хәлим абый, бик ардыңмы дип сорашып, аптыратып бетерә идем. Үзем сорашам, үземнең күзләрем Хәлим абый күзләрендә. Аның тузанга баткан йөзен үз кулларым белән юасым килә. Әгәр ул эштән төнлә кайтса, мин, йокламыйча, тәрәзәдән аны күз карашым белән өйләренә кадәр озатып куя идем. Мин аны аяк атлавыннан ук таный идем. Аннан Хәлим абый Казанга укырга китте. Күпме хатлар көттем мин аңардан! Тик күрше кызына хат язарга ул онытa иде. Әнисенә язган хатларында гына миңа сәлам тапшырырга куша иде. Үзем аңа хат язарга талпындым. Яздым. Язган берсен ерта бардым. Бәлки, элегрәк бу хисләр балалык җүләрлеге, яшь кызның өлкән кешегә сукырларча табынуы гына булгандыр. Китапларда андый мәхәббәтне шулай аңлаталар бит. Ләкин мин хәзер башка, миңа унсигез яшь. Менә ул кайтты. Һәм мин сезнең таныш икәнегезне ишеттем, очрашканыгызны күреп тордым. Бәлки, бу

турыда сезгә әйтергә кирәкмәгәндер, сез, җилбәзәк кыз акылыннан шашкан, дип көләрсез генә. Көлегез, мин барысын да күтәрәм. Әмма Хәлим абыйны яратуыгыз минеке кебек көчле булмаса, яраткан сыман гына тоелса, калдырыгыз аны.

Ә м и н ә. Ничек?

Ф ә н и я. Сезнең хакыгыз юк. Әйе-әйе... Сез Хәлим абыйга тиң түгел.

Ә м и н ә. Нәрсә?

Ф ә н и я. Хәлим абый ялгышкан, сез дә ялгышкансыз.

Ә м и н ә. Менә ни өчен син һәрвакыт минем белән дорфа сөйләшкәнсең икән!

Ф ә н и я. Юк, аның өчен түгел. Белми идем әле. Кичә генә ишеттем. Хакыгыз юк сезнең! *(Йөгереп капкадан кереп китә.)*

Ә м и н ә *(ялгыз, аптырап)*. Нәрсә сөйләде ул? Хакың юк, ди...

Х ә л и м керә.

Х ә л и м. Хәерле кич, Әминә. Сезнең авылга барырга дип чыккан идем.

Ә м и н ә. Безнең авылга? *(Сынаулы карап.)* Ә ни өчен моннан? Безнең авылга юл тегеннән бит.

Х ә л и м. Моннан өйрәнелгән юл. Башка җирдән үтсәм, юлым уңмас кебек. Аннан соң монда — Фәния...

Ә м и н ә. Фәния?

Х ә л и м. Әйе. Кечкенә чагында, мин кая гына барсам да, койма өстенә менеп, миңа хәерле юл теләп озатып кала иде. Һәрвакыт. Моңа шулчаклы күнегелгән, хәтта биш ел үткәч тә онытылмый. Бүген сөйләшеп утырдык, үскән, җиткән кыз булган...

Ә м и н ә. Сине сагынганмы?

Х ә л и м. Сагынган. Мин үзем дә сагындым. Минем кочагымда үсте ич ул.

Ә м и н ә. «Шуның кебек сеңлем булмаган бит...» Кичә син шулай дигән идең бугай? Син, Хәлим, алдаша да беләсең икән.

Х ә л и м. Ничек?

Ә м и н ә. Кичә әйттең, иртәгә очрашабыз, дидең.

Х ә л и м. Менә ич, очраштык.

Ә м и н ә. Мин үзем эзләп килгәчме?

Х ә л и м. Мин фермага барган идем, син эшкә килмәгәнсең.

Ә м и н ә. Ә мин сине авылда көттем. Әни дә көтте.

Х ә л и м. Ә ни өчен эшкә килмәдең?

Ә м и н ә. Мин эшләмим.

Х ә л и м. Ничек эшләмисең?

Ә м и н ә. Мин бүгеннән соң зоотехник түгел. Җитәр. Син кайтканчы түздем.

Х ә л и м. Берни дә аңламыйм...

Ә м и н ә. Аңлаешлы итеп әйттем ич.

Х ә л и м. Шаяртма әле, Әминә.

Ә м и н ә. Шаяртырга җыенмыйм да.

Артта Фәниянең җыры ишетелә. Әминә яшен суккандай тетрәп китә. Текәлеп, Хәлимгә карый.

Хәлим, син яратасыңмы мине?

Х ә л и м. Тукта әле, Әминә, син теге сүзне чынлап әйттеңме?

Ә м и н ә. Яратасыңмы мине, Хәлим? Әйт!

Х ә л и м. Ничәнче тапкыр соравың, Әминә!

Ә м и н ә. Хәлим, син минеке генә бит, шулаймы? *(Ялварган тавыш белән.)* Минеке генәме? Әйе, минеке! Минеке генә!

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Өченче күренеш

Биек текә ярлы елга буена урнашкан кыр станы. Бер якта вагон чите күренә. Пәрдә ачылганда, Ф ә н и я өстәл янында юылган табак-савытларны тастымал белән сөртеп тора. Ашыгып, Х ә й р е т д и н керә.

Х ә й р е т д и н. Исәнлекме, саулыкмы, кызым? Башламадылармы әле?

Ф ә н и я. Юк.

Х ә й р е т д и н. Кайчан башлыйбыз диләр?

Ф ә н и я. Озакламаслар.

Х ә й р е т д и н. Алаймы? Яхшы. *(Өстәл янындагы утыргычка утыра.)* Син, кызым, ни өчен безгә килми башладың?

Ф ә н и я. Вакыт юк, бабай.

Х ә й р е т д и н. Шулаймы? Элек вакыт таба идең бит. Әллә миңа бер көянтә су алып кайтып бирү кыенга китә башладымы?

Ф ә н и я. Бабай...

Х ә й р е т д и н. Суны мин үзем дә алып кайта алам, кызым. Аллага шөкер, әлегә тазалыгым бар. Чишмә ерак түгел. Нәрсә, хәтереңне калдырдыммы?

Ф ә н и я. Юк, бабай.

Х ә й р е т д и н. Беркөн дә әллә ничек, төне буе эчем пошып чыкты. Ни булды дип төпченмим. Син хәзер җиткән кыз. Шулай да минем өемә юлны онытырга ашыкма әле син.

Ф ә н и я. Гафу итегез, бабай.

Х ә й р е т д и н. Гафу ит дип, анысы инде аның ул чаклы ук җинаять түгел. Кил син, кызым, кил. *(Комбайннар ягына карап.)* Тегесе кем ул?

Ф ә н и я. Кайсы?

Х ә й р е т д и н. Әнә бу якка килә.

Ф ә н и я. Вахит.

Х ә й р е т д и н. Кадыйр малаемы? Кара, күзләрем аермый башлаган. Кеше танымый башлаганмын. *(Тирә-якка каранып.)* Син шушында эшлим дисеңмени?

Ф ә н и я. Әйе, бабай.

Х ә й р е т д и н. Ярый-ярый, эшләп арган кешеләрнең тамакларын туйдыру изге эш ул. *(Торып китә башлый.)*

Ф ә н и я. Кая ашыгасың, бабай? Хәзер аш әзер була.

Х ә й р е т д и н. Рәхмәт, кызым. Ашыңнан бигрәк сүзеңә рәхмәт. Тамагым тук. Анда башларга җыеналар бугай. Яңа ашлыкны алып калып өлгерергә кирәк. Шундый гадәтем бар. Ел саен уракка төшкән көнне бер уч яңа сугылган ашлыкны алып калам да төенчеккә төйнәп куям. Һәр елныкы аерым төенчек. Байтак җыйналды инде.

Ф ә н и я. Нишлисең алар белән, бабай?

Х ә й р е т д и н. Нишлимме? Беренче ашлыкның, заманы узган саен, кадере арта төшә, кызым. Беренче мәхәббәт кебек. *(Фәниянең аркасыннан кагып, сөеп чыгып китә.)*

Фәния аны сокланулы уйчан караш белән озатып кала.

Пауза. В а х и т керә.

В а х и т. Исәнме, Фәния!
Ф ә н и я. Исәнме!
В а х и т. Хәлим абый килмәдеме әле?
Ф ә н и я. Юк.
В а х и т *(паузадан соң)*. Монда эшләргә булдыңмыни инде?

Фәния эндәшми. Пауза.

Билгеле, монысы да эш. Ләкин монда килергә кирәкми иде сиңа.

Фәния дәшми.

Фәния!
Ф ә н и я. Нәрсә?
В а х и т. Ярамый, Фәния. Мин үз турымда сөйләмим. Мәхәббәтне теләнеп алып булмый икән, анысын аңладым.
Ф ә н и я. Мин теләнмим.
В а х и т. Сине әйтүем түгел, үземне әйтәм әле. Ә син ник килдең монда? Башка җирдә эш беткәнмени? Хәлим абыйга якынаер өченме? Нигә алай эшлисең? Мин бит беләм, бу уен эш түгел, Фәния. Куркам мин, синең өчен оялам. Болай начар кешеләр генә эшли...
Ф ә н и я. Вахит, нигә инде алай дисең?
В а х и т. Дөресе шулай бит.
Ф ә н и я. Мин алдашмый, күңелемдәген яшермичә әйткәнмен икән, нигә син очраган саен мине гаепләргә тотынасың?
В а х и т. Мин синең бәхетле булуыңны телим.
Ф ә н и я. Бәхет... Еллар буе саклап килгән хыялымнан Вахитка ошамый дип ваз кичсәм, шул бәхет буламы?
В а х и т. Ялгышасың, Фәния, ялгышасың. Хисләрне йөгәнли белергә кирәк, диләр бит. Үзеңнән көлдермә, Фәния. Ташла. Яратышалар икән яратышсыннар. Башта гына авыр була ул. Аннан рәтләнә. Менә бүген бункерга беренче ашлык төшәчәк. Шатлык бит. Мин, үз кулларым белән комбайн йөртеп, кешеләргә икмәк бирәм. Бәхет бит ул икмәк. Шул турыда уйларга кирәк, Фәния. Шулай уйласаң, үз кайгыларың онытылып тора. *(Соңгы сүзләрне сөйләгәндә, Фәния чыгып киткән була.)* Сизәсеңме, икмәк исе килә. Әнә никадәр ашлык! Тизрәк амбарларга керәсе килә аларның...

Х ә й д ә р керә.

Х ә й д ә р. Син нәрсә болай үз-үзеңә сөйләнеп утырасың?

Вахит Фәния басып торган урынга карый. Фәния юклыгын күргәч, бераз уңайсызлана.

Вахит. Суктыра башлыйбыз бит, шатлык.

Хәйдәр. Шатланып кал. Эшли башлагач, шатланырга вакытың булмас. Мин, агай-эне, эшләгәндә шаярырга яратмыйм. Помощник дип, сине дә кызганып тормам. Акча аласың килсә эшлә. Йә-йә, курыкма. Минем белән, беләсең, акчаны күрәп аласың. Мин, агай-эне, умачлык эшләдем, шул җиткән дип йөрүчеләрдән түгел. Акчаны учлап алырга күнеккән. Понял?

Вахит. Понял.

Хәйдәр. Вәт шулай, тизрәк башларга кирәк иде, нәрсә көтәбез соң?

Вахит. Хәлим абый әйтте бит, мин килмичә башламагыз, диде. Ул икенче бригадада.

Хәйдәр. Нәрсә белә соң ул? Ачу китереп йөриләр шунда. Механик, имеш. Мотор сүтеп җыя белмиләр...

Вахит. Син җыйган мотор эшләмәгәч, Хәлим абый төзәтеп бирде ич.

Хәйдәр. Син, помощник булсаң, телеңне кыска тот, ярыймы? *(Папирос алып кабыза. Вахитка да папирос суза.)* Мә, көйрәтеп җибәр. Зарплат алгач түләрсең.

Вахит. Тартмыйм дип әйттем ич инде.

Хәйдәр. Дурак. Ничава, башың яшь, өйрәнерсең әле. Йә, синең эшләр ничек соң?

Вахит. Нинди эшләр?

Хәйдәр. Сөйләгән идең ич комбайн ремонтлаганда. Бу Нурлидә кызы белән? Һаман кәҗәләнәме?

Вахит. Хәйдәр абый, мин, сине акыллы кешегә исәпләп, серләремне сөйләгәнемә үкенеп бетә алмыйм.

Хәйдәр. Сөйләсәң ни булган? Миннән, дус, сүзне киләшчә белән дә тартып ала алмассың. Ә син җебемә. Кызлар алар җебегән егетне яратмыйлар. Башта кысып ал да кочакла. Май кебек эреп төшә. Эх син, менә абыеңны күрерсең. Пока дәшми йөрим әле. Бер җае туры килгәндә, теге зоотехник кызны Хәлимнән тартып алмасаммы... Пока миңа кирәкми. Тик йөри бирсеннәр. Кирәк булгач, тотармын да өйләнермен. Фигурасы матур ул зоотехникның. Чибәр, каһәр. Әгәр теләсәм, мин Фәниянең башын әйләндерергә дә күп сорамыйм. Бары сине кызганып кына тимим инде.

Вахит. Әйдә, комбайн янына. Тагын бер кат тикшереп чыгыйк.

Хәйдәр. Чурт булганмы аңа, майлаган, җайлаган, син минем белән булганда аптырама. Абзаң махы бирә торганнардан түгел ул.

Фәния керә.

Фәния, боткаң тиз пешәме инде? Ашыйсы килә башлады.

Фәния. Башта эшлә.

Хәйдәр. Вахит, әйт әле шуңа, блат буенча, бәлки, ашатып җибәрер, син, ни әйтсәң дә...

Вахит. Хәйдәр абый!

Хәйдәр. Оялма инде. *(Өстәл янында кайнашкан Фәниянең биленнән кочаклап ала.)* Менә, егет булсаң, шулай бул.

Фәния башта аптырап кала. Аннан, борылып, кулындагы миски белән Хәйдәргә суга. Хәйдәр Фәнияне ычкындыра.

Әй, әй, санга санап кочаклаганга рәхмәт юк!

Вахит *(Хәйдәр каршысына килеп басып)*. Хәйдәр абый, хәзер үк Фәниядән гафу үтен.

Хәйдәр. Нәрсә-ә?

Вахит. Мин синең белән бергә эшләмим.

Хәйдәр *(көлеп)*. Ну, сөйләп тә куясың, ә? Бар, эшләмәсәң, килгән юлың тап-такыр. Чакырып китермәдем.

Вахит *(Хәйдәргә ябышып)*. Гафу үтен!

Хәйдәр. Кит әле бер якка!

Хәлим керә. Фәния вагонга кереп китә.

Хәлим. Нишлисез?

Хәйдәр. Минем помощник кызып киткән. Көрәшик дип бәйләнә.

Вахит. Хәлим абый, мин аның белән бергә эшләмим. Теләсәгез нишләтегез. Әшәке куллары белән икмәккә якын килмәсен.

Хәйдәр. Нәрсә сөйләгәнеңне белеп сөйлә, энем.

Вахит. Фәниядән гафу үтен.

Хәлим. Тукта әле, Вахит. Хәйдәр, биредә нәрсә булды?

Хәйдәр. Нәрсә булсын, шаярып, Фәниясен кочаклаган идем, шуңа әтәчләнә.

Х ә л и м. Гафу үтен, бар!

Х ә й д ә р. Бәйләнмәле, пажалысты. Каян килгән культурный халык.

Х ә л и м. Ә син барыбер гафу үтен.

Х ә й д ә р. Нәрсә барыгыз да командовать итәсез, ә? Кирәк булса, үзең үтен. Мин сезгә малакасус түгел. Нәрсә аны кактырып, суктырып әйтәсең? Турыдан-туры әйт. Мин Казанда чакта, син, Хәйдәр, минем Әминәгә күз салып йөргән икәнсең, диген. Жалоба бирде, диген. Хәзер мин синең өстән начальник, теләсә нәрсә эшли алам, диген.

Х ә л и м. Хәйдәр, минем Сабан туенда көрәшкәнем бар.

Х ә й д ә р. Сук, йә, сук! Без дә төшеп калганнардан түгел. Нишләргә кирәген белербез.

Х ә л и м. Егет димәсәң, хәтерең калыр.

Х ә й д ә р. Сүзеңне үлчәп сөйлә, ярыймы? Укымасак та, без дә андый гына сүзләрне әйтә беләбез.

Х ә л и м *(Вахитка)*. Бөтенесе дә килеп беттеме?

В а х и т. Күптән инде. Сине көтәбез, Хәлим абый. Арыш кипкән. Җыйдыра башларга вакыт. Юкса лафетчылар урдыра да урдыра. Әнә урылган җир никадәр. Аны сугып бетерәсе дә бар бит әле.

Х ә л и м. Агроном булдымы?

В а х и т. Председатель белән килеп киттеләр.

Х ә л и м. Бераз юешрәк шул. Валга чорналып интектермәгәе.

В а х и т. Юк, шатырдап кипкән.

Х ә л и м. Әйдәгез, барып карыйк.

Хәйдәр урыныннан кузгалмый.

Х ә й д ә р. Мин бармыйм.

Х ә л и м. Син нәрсә?

Х ә й д ә р. Мин кирәкмим ич сиңа. Помощник белән сөйләшәсең. Алай бик мачтырлар икән, барыгыз, эшләгез.

Х ә л и м. Хәйдәр, без монда уен уйнамыйбыз.

Х ә й д ә р. Мин дә уйнамыйм. Мин комбайнер булып, Аллага шөкер, алты ел эшлим. Эшләп карагыз, кирәк булсам чакырырсыз.

Х ә л и м. Эх, син!

В а х и т. Кирәкми, Хәлим абый, бармасын.

Х ә й д ә р. Ха-ха-ха…

Вахит. Нәрсә көләсең, әллә ялынырбызмы?

Хәйдәр. Герой!

Хәлим. Хәйдәр, каприз күрсәтә торган чак түгел, бар комбайның янына.

Хәйдәр. Комбайнны менә монда минем янга китереп куегыз. Күтәреп утыртыгыз, заводить итеп бирегез.

Хәлим *(Вахитка)*. Әйдә.

Китәләр. Хәйдәр утыргычка утыра. Аркасы белән өстәлгә сөялеп карап кала.

Хәйдәр. Ялыныр көнегез алда әле. Хәйдәрне күп куып карадылар инде.

Күлдә балык йөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер, һай, сизәдер...

Әминә керә.

Нишләп йөрисең монда?

Әминә. Сезгә барыбер түгелмени?

Хәйдәр. Әллә агитатормы? Ну, табалар да соң инде. Агитатор дисәң дә агитатор. Ату, үткән ел илле яшьлек Нәҗип абыйны куеп үзәккә үткәннәр иде. Йә, агитациялә инде, газитләрдә ниләр язалар? Кычкырып торып укып җибәр, ә мин синең тезләреңә башым куеп тыңлармын.

Әминә. Тәрбиясез.

Хәйдәр. Сөйгән егетең дә миңа шулай дигән иде, кычкырыштык.

Авылыбызда бер чибәр бар,
Үзәгемне өзәдер, әй, өзәдер,
Әкрен кирәк, ипләп кирәк...

Әминә аңа әһәмият бирми, Хәлимнәр киткән якка карап тора.

Слушай, синең акчаң күпме? Әйт инде, курыкма, таламыйм. Булмаса, үзем биреп тора алам.

Әминә эндәшми. Хәйдәр торып, аның янына килә.

Нигә дәшмисең?

Әминә. Китегез бiредән!

Хәйдәр. Кая китим? Мин аш пешкәнне көтәм. Менә син ник килдең? Хәлимне эзләпме? Кара әле, слушай, син зоотехник түгелмени хәзер? Беркөн правлениедә колагыма чалынды. Ташлады, диләр, дөресме ул?

Ә м и н ә. Анда синең эшең булмасын.

Х ә й д ә р. Болай гына әйтүем. Молодец. Син укыган кеше, ничывы тирес арасында йөрергә. Синең бит, авылда туып үссәң дә, тирес арасында буталырга натураң килешми. Син картинка кебек, үкчәле туфли киеп, егетләрнең борынына чиртеп йөрергә генә яратылган.

Ә м и н ә. Нигә сез һаман миңа бәйләнәсез?

Х ә й д ә р. Менә әкәмәт, нигә бәйләним? Мактыйм. Эшләү ул — ирләр эше, безнең эш. Чык миңа, слушай, Хәлимгә чыгып уңмыйсың син, эшләтеп җаныңа тиячәк. Ә мин сине, пожалысты, яңа өйнең түрендә генә утыртырмын. Әни карчыкка иптәш булырсың.

Әминә китмәкче була.

Тукта инде, слушай. Әйдә, загарать итәргә барасыңмы? Су әйбәт монда: әле яңа гына коенып чыктым.

Ә м и н ә. Җибәрегез, дим.

Вагоннан Ф ә н и я чыга. Хәйдәр аны күреп ала.

Х ә й д ә р *(Фәниягә)*. Нәрсә авызыңны ачып тыңлап торасың? Кулларыңны уйнатма син, слушай. Менә синнән олырак апаңнар да сукмый миңа. *(Өстәл читендә яткан бер газетаны алып.)* Слушай, бу гәзитне миңа бир әле. Мотоциклның свичәсенә тузан кунган.

Ф ә н и я. Куй урынына.

Х ә й д ә р. Ике тиенлек гәзитеңне жәлләмә инде. Ярый, сезнең белән чүбек чәйнәп май чыкмас. *(Фәниягә.)* Хәлим килсә, әйт, мин елга янында булам. Загарать итә, диген. *(Җырлый-җырлый китә.)*

Күлдә балык йөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер, һай, сизәдер...

Әминә Фәнияне күреп аптырап кала. Фәния, килеп, газетаны рәтләп куя, табак-савытларны җыя.

Ә м и н ә. Син нишләп биредә?

Ф ә н и я. Эшлим.

Ә м и н ә. Синең эш урының монда түгел.

Ф ә н и я. Сезнеке дә монда түгел бит.

Ә м и н ә. Ах, шулаймы? Без синең белән Хәлимне бүлешәбезмени?

Ф ә н и я. Хәлим абый алма түгел ул, нигә бүлешәсең?

Ә м и н ә. Синең өчен алма ул. Син, койма башына менеп, аңа кызыгып торгансың ич. Бар, хәзер үк кайтып кит.

Ф ә н и я. Минем эшләрем бар, мин аш пешерәм.

Ә м и н ә. Нинди аш пешергәнеңне беләм мин.

Ф ә н и я *(кызып китә)*. Әминә апа, сез әле генә Хәйдәр абыйны тәрбиясез дип атадыгыз. Сезнең авылда ничектер, безнең авылда әдәплерәк итеп сөйләшәләр.

Ә м и н ә *(кычкырып)*. Әдәплерәк! Әдәпле сөйләшкәнне аңлыйсыңмы соң син?!

Ф ә н и я. Сез миңа андый гаеп ыргытмагыз. Һәм миңа кычкырырга да хакыгыз юк сезнең.

Ә м и н ә. Әллә рәхмәт әйтимме?

Ф ә н и я. Мин аңа мохтаҗ түгел. Мин сезне элек тә яратмый идем. Хәлим абый белән таныш икәнегезне белгәнче үк. Ни өченме? Хәйдәр абый әйткәндәй, тирес-тузан арасында йөрергә натурагыз килешмәгән өчен. Авылда үсеп, авылдан җирәнүегез өчен. Сез бит, бер ел зоотехник булып эшләп, терлек абзарларына кереп тә карамадыгыз. Чебиләр янына килгәндә дә борыныгызны яулык белән каплый идегез. Дөрес түгелме? Хәзер бөтенләй ташлагансыз. Киенеп-ясанып, авылдан авылга чабып йөрисез. Мин эш урынымда, мин эшлим. Сез нишләп йөрисездер — билгесез. Ә инде беркөн сөйләшкән сүзләрне искә төшерәсез икән, мин аны сезгә тагын кабатлый алам. Әйе, яратам мин аны. Ә сез аны яратмыйсыз. Хәлим абыйны хөрмәт итсәгез, бу кыяфәтегез белән аның эш урынына килмәс идегез сез. *(Табак-савытларны күтәреп чыгып китә.)*

Х ә л и м керә.

Х ә л и м. Әминә? Нишләп йөрисең син монда?

Ә м и н ә *(йөзенә бәреп)*. Синең янга килдем. Көтмәгән идеңме?

Әминәнең бәйрәмчә киенүен күреп, Хәлимнең кәефе кырыла, дөресрәге, уңайсызлана.

Нәрсә, Хәлим, әллә минем килүем сиңа ошамадымы?

Х ә л и м. Эшкә бардыңмы?

Ә м и н ә. Юк.

Х ә л и м. Сөйләшкән идек ич. Ничек инде, Әминә, югары уку йортын бетереп, зоотехник дипломы алып, шул эшне ташларга мөмкин? Мин аңламыйм.

Ә м и н ә. Аңларсың әле, Хәлим. Мин бер ел эшләдем. Туйдым, ардым. Ә синең эшли башлавыңа ай да тулмаган.

Х ә л и м. Минем эшли башлавыма сигез ел инде. Мин укып чыккач ничек буласын укырга киткәнче үк белдем.

Ә м и н ә. Ә мин укып кайткач кына белдем. Баштук белсәм, авыл хуҗалыгы институтына аягымны да атламаган булыр идем. Фермада йөрер өчен югары белем кирәкми икән.

Х ә л и м. Соң хәзер нишләргә уйлыйсың?

Ә м и н ә. Белмим, син әйт.

Х ә л и м. Юк, Әминә, алай булмый. Бүген сезгә барам, әниең белән сөйләшергә кирәк.

Ә м и н ә. Мин бала-чага түгел, үзем өчен үзем җавап бирә алам.

Х ә л и м. Андый җавап ишетәсем килми минем синнән, Әминә. Чөнки яратам мин сине.

Ә м и н ә. Кемне яратасың соң син? Минеме? Әллә зоотехникнымы? Ә мин синең үзеңне яратам. Шуңа килдем дә. Син мине ничек куарга белми аптырыйсың, яратумы бу? Безнең бирешкән вәгъдәләребез шуның өчен идемени? Кайткач ук өйләнешәбез дигән вәгъдә зоотехникка гына бирелгән идемени? Син кайтканга никадәр вакыт узды.

Х ә л и м. Үзең күреп торасың бит, Әминә.

Ә м и н ә. Мин күп нәрсәләрне күреп торам. Менә шуңа күрә сине алырга килдем дә.

Х ә л и м. Кая?

Ә м и н ә. Загска.

Х ә л и м. Загска?! Бүген үкме?

Ә м и н ә. Әйе. Бүген үк! Хәзер үк! Мин көтә-көтә арыдым. Минем кеше кебек яшәп каласым килә. Миңа хәзер егерме биш яшь. Мин ышанып яшәдем. Сиңа! Ә син... *(Еларга тели.)*

Х ә л и м. Кирәкми, Әминә.

Ә м и н ә. Юатма мине. Миңа теләсә кем кычкыра. Имеш, мин сиңа тиң түгел.

Х ә л и м. Әминә, нигә инде андый сүзләр? Тукта, Әминә, мин Хәйдәрне генә табып киләм, югыйсә...

Ә м и н ә. К чёрту, к чёрту миңа Хәйдәрләрегез. Беләм мин ни өчен миннән качуыңны. Сиңа Фәния кирәк.

Х ә л и м *(кинәт туктап)*. Нинди Фәния?

Ә м и н ә. Белмәгән булып кыланма!

Х ә л и м. Тукта әле, син, Фәния кирәк, дидеңме? Ни өчен?

Ә м и н ә. Ни өчен икәнен үзеннән сора. Ул бит сине ярата.

Х ә л и м. Кем әйтте?

Ә м и н ә. Үзе.

Х ә л и м. Кайчан?

Ә м и н ә. Сиңа барыбер түгелмени?

Х ә л и м. Шаяртадыр ул.

Ә м и н ә. Шаярту белән шаяртмауны аера беләм мин.

Х ә л и м. Димәк, син шуңа... Юк, ничек алай булсын? *(Кинәт.)* Ә минем моңа ни катнашым бар?

Ә м и н ә. Ул бит синең кочагыңда үскән.

Х ә л и м. Үссә?

Ә м и н ә *(үзгәреп)*. Хәлим, мин беләм. Син алдашмыйсың. Мин сине гаепләп әйтүем түгел. Ә аның яратуы дөрес. Хатын-кыз күңелен хатын-кыз аңлый. Ул сине миннән тартып алачак. Аның явызлыгы җитәрлек. Ул хатын-кыз кыяфәтендәге Демон.

Х ә л и м. Ничек инде, Фәния ярата дип, бөтен эшне ташлап, шундый көндә загска чабыйкмы?

Ә м и н ә. Мин куркам...

Х ә л и м *(зиһене таралган)*. Юк-юк. Күрәм, минем артта әллә нәрсәләр эшләнә, мин бернәрсә дә белмим. Син миңа ышанмый ук башлагач, димәк, бу җитди. Кайда ул?

Ә м и н ә. Кирәкми, Хәлим.

Х ә л и м. Юк, болай ярамый, Фәния!..

Әминә китә башлый.

Әминә, китмә!.. Фәния!

Ә м и н ә китә.

Әминә...

Ф ә н и я керә. Хәлим үзен кулга ала.

Фәния, утыр әле. Безгә сөйләшергә кирәк.

Ф ә н и я. Әминә апа куштымы?

Әминә вагон читенә килеп тыңлап тора.

Х ә л и м. Бәлки, шулайдыр да. Әминә апаңа әйткән сүзләрең дөресме?

Ф ә н и я. Әйе.

Х ә л и м. Нигә кирәк булды инде ул?

Ф ә н и я. Хәлим абый, сез миннән сорау алмагыз, ачуланасыз икән ачуланыгыз...

Х ә л и м. Юк, мин ачуланырга җыенмыйм. Ләкин бу шаяра торган нәрсә түгел.

Ф ә н и я. Мин шаярмыйм, Хәлим абый.

Х ә л и м. Ничек инде?

Ф ә н и я. Әгәр Әминә апа сезгә сөйләгән икән, белегез, аңа әйткәннәрем чын.

Х ә л и м. Бу турыда сөйләшүе дә уңайсыз. Син мине бит авыр хәлгә куйдың. Миңа синең алда оят.

Ф ә н и я. Сез оялмагыз, Хәлим абый. Монда мин оялырга тиеш.

Х ә л и м. Димәк, сүзне шуның белән бетердек? Икенче тапкыр кабатланмас бит?

Ф ә н и я. Белмим.

Х ә л и м. Ничек инде «белмим»? Аңлаштык ич.

Ф ә н и я. Юк.

Х ә л и м. Менә сиңа кирәк булса! Йә, син үзең аңлат, алайса.

Ф ә н и я. Минем хыялларымның ни өчен юкка чыкканын белергә телим мин.

Х ә л и м. Нинди хыяллар?

Ф ә н и я. Сез мине кечкенәдән үк дөньяны, җирне яратырга өйрәттегез. Сез мине яшәргә өйрәттегез. Сез миңа олы мәхәббәт турында сөйли идегез. Мин мәхәббәтне аңлый башладым. Мин аны таптым дип уйлаган идем.

Х ә л и м. Син яшь әле, Фәния. Күп нәрсәләрне аңлап бетермисең.

Ф ә н и я. Аңлатыгыз.

Х ә л и м. Ничек дип? Билгеле, синең белән сөйләшкән сүзләр күп булды. Мәхәббәт турында да. Әмма алар икенче төрлерәк иделәр. Ничек әйтим, гомумән мәхәббәт турында. Аларны үзеңчә кабул итәрсең дип башыма да китермәгәнмен. Күрәсең, синең олыгая баруыңны сизмәгәнмен. Болай буласын белсәм...

Ф ә н и я. Ничек соң сез, Хәлим абый, бөтен эштә уйлап эшли торган абый, ничек сез аны күрә алмадыгыз? Нигә мине һаман өмет белән яшәттегез? Хәзер мин нишләргә тиеш? Юк, сез уйламагыз, мин сездән мәхәббәт теләнмим. Тик киңәш бирегез миңа. Ничек миңа бөте-

несен дә онытырга, ничек сезне очраткан саен, берни булмагандай гади итеп, чит кешеләр белән сөйләшкән кебек сөйләшергә? Киңәш бирегез.

Хәлим ни әйтергә белми. Ә м и н ә атылып чыга.

Ә м и н ә. Киңәш бир, Хәлим! Нигә бирмисең? Алайса, мин бирәм. Менә сиңа иң яхшы киңәш! *(Фәниянең яңагына суга.)*

Х ә л и м. Әминә!

Ә м и н ә. Нәрсә «Әминә»! Синнән киңәш сорый бит. Син дәшмисең. Ни өчен дәшмәгәнеңне беләм мин. Алдакчы! Алдакчы! *(Йөгереп чыгып китә.)*

Х ә л и м. Гафу ит, Фәния.

Кинәт артта, елга янында, чырылдап кычкырган тавыш. Әминә тавышы. Х ә л и м йөгереп чыга. Артта кешеләр йөгерешкән, сөйләшкән тавышлар. Бераздан, Әминәне күтәреп, Х ә й д ә р керә. Хәйдәр бил тиңентен ялангач. Башкалар да керә.

Х ә л и м. Әминә! Әминә!

Әминә дәшми.

Х ә й р е т д и н *(Хәйдәргә)*. Аңлатып сөйлә, нәрсә булды?

Х ә й д ә р. Ну, нәрсә, йөгереп бара иде, егылды. Аяк астындагы җир ишелде дә, суга килеп төште. Анда биек ташлар. Башы шунда бәрелгәндер.

В а х и т. Врач чакырырга кирәк.

Х ә й д ә р. Синең врачыңны көтеп ята ди ул. Мин аны авылга алып кайтам. *(Әминәгә карап торучы Хәлимне читкә этеп.)* Кит әле, мишәйт итмә. *(Әминәне күтәреп чыгып китә.)*

Аның артыннан башкалар да чыга. Фәния, төсе киткән килеш, сәхнә уртасында басып кала. Мотоцикл кузгалып киткән тавыш. Фәния елап җибәрә.

## Дүртенче күренеш

Район больницасының ишегалды. Бакча. Эскәмияләр. Эскәмияләрнең берсендә Әминә утыра. Мотоцикл килеп туктаган тавыш. Эш киеменнән, тузанга батып, Хәйдәр керә. Туп-туры Әминә янына уза.

Хәйдәр. Сәлам! Бу нишләп йөри дип ачуланма, бик ашыгам. Хәлеңне белергә чаптым. *(Сәгатенә карап.)* Унбиш минут вакытым бар. Комбайнны теге малайга гына калдырып тордым. Йә, ничек?

Әминә *(коры)*. Күреп торасыз.

Хәйдәр. Болай әйбәт күренә. Слушай, мин монда синең турыда бер әкәмәт әйбер ишетеп килдем бит әле.

Әминә *(нидер сизенгән сыман)*. Нәрсә бар?

Хәйдәр. Түлке, мин уйлап чыгарган, димә. Бөтен кеше сөйләгәнгә генә әйтәм. Мин бит теге вакытта сине ярдан егылып төште дип уйлаган идем, син үзең сикергәнсең икән ич.

Әминә. Кем әйтте?

Хәйдәр. Бөтен кеше шулай сөйли. Хәлимгә ачу итеп сикергәнсең диләр. Дөресме?

Әминә. Китегез моннан.

Хәйдәр. Кума инде. Менә кеше. Рәхмәт әйтәсе урында куа. Мин коткармасам, үлә идең бит. Мин әле синең өчен медаль сорарга җыенып йөрим. Суга баткан кешене коткарганга медаль бирәләр, ди. *(Кәефе килеп көлә.)* Ну, хәйләкәр дә үзең, слушай. Даромга гына укымагансың икән. Әйтәм аны, әкәмәт кенә егылып төштең. Ярның тәбәнәк урынын гына эзләп. Нәрсә, анда суның тирән икәнен белмәгән идеңмени? Әйтәләр аны, мин шунда ич, Хәйдәр, мин суга сикерәм, кайсы җире сайрак, дип сорыйлар аны. Уеннан уймак чыгарып, үлеп куюың бар. Нәрсә, Хәлим ташладымы әллә? Фәнияне ярата башлаганмыни? Син миңа әйбәт әйбер өйрәттең бит әле, слушай, кайтам да, мин дә сикерәм. Әминә өчен сикердем дип, язу язып калдырам.

Әминә урыныннан торып китә башлый. Хәйдәр кинәт җитдиләнә, Әминәнең юлына аркылы төшә.

Әминә. Җибәрегез!

Хәйдәр. Ашыкма. Син миңа характерың күрсәтмә,

ярыймы! Каян беләсең, әллә мин сине серьёзно ярата торганмындыр. Шуның өчен килгәнмендер. Дурак, суга сикереп ачу алалармыни? Барып Хәлимнәрнең капка баганасына асылынасың калган. Кызганырлар иде. Хәлимнән башка кеше беткәнмени? Мин сиңа кайчаннан бирле әйтеп киләм. Хәлим, имеш. Ул синең яныңа да килеп карамады. Мотоцикл белән мин алып килдем. Мин! Беләсеңме? Шуңа күрә миңа булырга тиеш тә син!

Ә м и н ә *(кычкырып)*. Сестра!

Х ә й д ә р *(каушап)*. Аңламагач та аңламыйсың икән, ярый, кычкырма, китәм. Вакыт та җитте. Иртәгә тагын килермен, ярыймы? *(Кесәсеннән кыйммәтле шоколад плиткалары чыгарып.)* Мә, боларны ал. Курыкма, мин аны болай гына. Кичә зарплат алдым. Әйбәт шоколад ул. Больницаның манный боткасы түгел. Ятып чыктым инде мин монда, беләм. Курыкма, шоколадның зыяны юк аның. Син диет түгел бит.

Әминә китә, Хәйдәр бер больница ишегенә, бер шоколадларына карап тора да ачу белән шоколадларны җиргә бәрә.

Дурак!

Капкага таба бара. Хәлим белән очраша.

Х ә л и м. Нишләп йөрисең монда?

Х ә й д ә р. Син нишләп йөрисең соң?

Х ә л и м. Җитте сиңа, Хәйдәр, уйнама!

Х ә й д ә р. Кем уйный?! Син ул авылдагы бөтен кызларны берүзеңә алып бетердең дә... Бүтәннәр теләсә нишләсен! Белмиләр дип беләсеңме әллә? Бөтен кеше белә.

Х ә л и м. Нәрсә? Нәрсә беләсең? Нәрсә беләләр?

Х ә й д ә р. Шуны беләм — син кешене чак кына үтермәдең. Синең аркада кеше суга сикергән.

Х ә л и м. Син нәрсә?

Х ә й д ә р. Җикеренмә, пажалысты. Ачуымның кабарган чагы. Унбиш суткы дип тормам, колак төбеңә берне генә ямармын. Сөякләреңне җыеп ала алмассың. *(Чыга.)*

Хәлим, нишләргә белми, аңа карап кала. Артта, әллә нинди яман тавышлар чыгарып, мотоцикл кузгалып китә. Хәлим больницага кереп китә. Шулвакыт унике-унөч яшьләрендәге б е р м а л а й килеп чыга. Үзе больница ягына карана, үзе җирдә аунап яткан шоколадны җыеп кесәсенә тутыра. Ишектән Х ә л и м чыга. Малай агачлар арасына кереп югала. Хәлим, утыргычка утырып, тәмәке кабыза. Малай килеп, Хәлим янына чүгәли.

М а л а й. Исәнме, Хәлим абый!

Х ә л и м *(гаҗәпләнеп карап)*. Син мине каян беләсең?

М а л а й. Белмәс. Абыеңның белмәгәне юк аның. Әминә апаның сөйгән егете бит син. Мин монда бөтенесен белеп бетердем инде. Мин Әминә апа белән бер авылдан. Шәпкәнеке мин. Габдуллаҗаннарны беләсеңме? Шуларныкы.

Х ә л и м. Кайсы җирең авырта соң синең?

М а л а й. Бер җирем дә авыртмый.

Х ә л и м. Нигә больницада ятасың?

М а л а й. Җибәрмиләр. Киемнәрне бикләп куйдылар да менә боларны кидерделәр. Шуларны киеп качып кайткан идем, тотып китерделәр. Хәзер ияләштем инде. Кайт дисәләр дә кайтмыйм.

Х ә л и м. Юкка тотмыйлардыр, авыруың бардыр.

М а л а й. Аның ише авыру! Трахум. Күзем минем бинокль кебек күрә. Авылдагы сестра бәйләнде. Авылда берүзең генә, ди. Башкаларга йоктырырсың дип, монда китерделәр. Үзе бозып бетерде дә. Трахум да түгел, чүп кергән иде. *(Кесәсеннән алмалар чыгара.)* Хәлим абый, алма ашыйсыңмы?

Х ә л и м. Каян алдың ул кадәр алманы?

М а л а й. Минем күп ул. Аша. Менә монда, күрше бакчада гына. Мин аны ямь-яшел вакытыннан ашыйм инде. Хәзер өзеп бетерделәр, соң өлгерә торганнары гына калды.

Х ә л и м. Урлыйсыңмы?

М а л а й. Әһе. Бер тапкыр да тотканнары юк. Син әйтмә тагын, Хәлим абый.

Х ә л и м. Урларга ярамый бит.

М а л а й. Ярамаса җибәрсеннәр. Мин аларның бөтен әйберләрен урлап бетерәм әле.

Х ә л и м. Ярамый. Әти-әниең ишетсә?

М а л а й. Әти-әни юк минем.

Х ә л и м. Кайда соң?

М а л а й. Белмим. Аерылыштылар да киттеләр. Берсе Ташкентта, берсе Казанда. Мин әби белән торам.

Х ә л и м. Әбиең белсә?

М а л а й. Белә инде ул, күзе начар күрә аның. Кыйнарга дип мине куа башласа, абына да егыла. Детдомга бирәм, хәерсез, ди, әйтерсең мин куркам. Бирсен. Александр Матросов та детдомда үскән әле.

Х ә л и м. Әтиең белән әниең хат язалармы соң?

М а л а й. Юк. Аларга яхшы. Аерылыштылар да киттеләр. Синең өчен мин нужа чигәм, ди әби. Чикмәсен... Ренат та монда ята әле.

Х ә л и м. Кем ул Ренат?

М а л а й. Сезнең авылныкы. Сукыр эчәген кисеп ыргытканнар. *(Көлеп.)* Башта болай бөкрәеп кенә йөрде. Аны, бакчадан чыгып килгәндә, сестралар тотып алдылар әле. Мин ычкындым. Хәзер Ренатка эләгә инде. Без дус. Ренатка өеннән гел әйберләр җибәреп торалар. Башта бөтенесен миңа биреп барды. Хәзер икәү ашыйбыз. Берсекөнгә ул да китә инде...

Х ә л и м. Нәрсә, монда ашарга бирмиләрмени?

М а л а й. Бирәләр. Өйдән килгән тәмлерәк була. *(Кесәсеннән шоколад чыгарып.)* Күрдеңме, нәрсәләр! Юк, боларын урламадым, теге, сиңа сугып җибәрермен дигән кешенеке. Ай, син шунда карап тордың. Миңа эләксә! Урак бетәме әле, Хәлим абый?

Х ә л и м. Бетә.

М а л а й. Монда ятып уракны да күрми калдым. Бригадир Нурмый абый әйткән иде, комбайнда салам төшереп йөрерсең, дигән иде. Хәзер Вәкил йөри торгандыр инде, мактанып, комбайнга утырып. Укырга вакыт җитә, укыйсы да килми. Ренат ул, гел бишлегә укыйм, ди. Әллә аңардан үрнәк аласы инде? Аның яхшы, этисе-әнисе бар! *(Кисәк алмаларны, шоколадларны җиргә бәрә.)*

Х ә л и м. Нигә ташлыйсың?

М а л а й. Кирәкми лә! Кеше әйбере белән нишлим? Хәлим абый, тетя Мутя белән сөйләш әле, җибәрсен. Ул — күз врачы.

Х ә л и м. Ярый, сөйләшермен. Тик бу әйберләрне җыеп, кертеп куй. Икенче тапкыр урлашма.

М а л а й. Беләм лә инде! Кайчакта котырынып кителә. Тыелып калып булмый. Әминә апаны чакырыйммы?

Х ә л и м. Кирәкми. Үзе дә чыга ул.

М а л а й. Хәлим абый, ул суга юри генә сикердемени? Сине куркытыр өчен генәме?

Х ә л и м *(шикләнеп)*. Ничек, ничек?

М а л а й. Сөйлиләр инде монда. Мин бөтенесен тыңлап торам. Минем әни дә шулай иде. Әти белән кычкырышсалар, барыбер яшәмим, үземне юк итәм,

җавап бирерсең, дип куркыта иде. Ул суга сикермәде, аерылыштылар гына. Яратышмагач нигә өйләнешәләр диген. Менә хәзер ятим булып йөр инде. Әбигә дә җиңел түгел бит. Минем кебек хулиганны үстерү уен эшмени?! Детдомга китми булмас, ахры. Ренат та шулай ди. Әби берүзе генә кала шул. Хәлим абый, бу малай юләр икән дип уйлама. Мин сиңа бер киңәш итәм.

Хәлим. Нинди киңәш?

Малай. Әминә апага өйләнмә син.

Хәлим. Нигә?

Малай. Син аның кемлеген миннән сора. Беләм инде мин аны. Әнисе белән икәүләп сине әләктереп алсалармы, мәңге котыла алмассың. Син аларның кушаматларын беләсеңме? Төлке. Койрыгын болгап җибәрсә, бүре дә ермакка мәтәлеп төшә. Аның әнисе, авырыйм дигән булып, колхозда эшләми. Үзе трактор кебек таза. Әби әйтә, аптырыйм, ди, бу Төлке Фатыйма акча кайдан ала, ди. Беләм мин аның кайдан алганын. Базардан базарга чабып йөри ул. Әминә апа укыган башы белән әнисенә дәшми. Зоотехник, имеш! Бик инде. Бер ел эшләмәде, унбиш баш сыерны үтерде.

Хәлим. Җитәр.

Малай. Әллә үпкәләдеңме, Хәлим абый? Сине кызганып кына әйтүем. Хәзердән үк суга сикерәм дип йөргәч булмый инде ул. Аерылышасыз. Күренеп тора инде.

Ишек ачыла. Әминә чыга.

Ярый, Хәлим абый, күрешербез әле. *(Кул биреп күрешә, Әминәгә ымлый.)* Син аңа әйтмә, Хәлим абый, мин әйткәнне.

Әминә *(малайга)*. Нәрсә йөрисең монда, бар, сине эзлиләр. Тәрбиясез!

Малай. Хуш иттек, Хәлим абый!

Хәлим. Хуш!

Әминә. Исәнме, Хәлим! *(Иронияле.)* Кызу эш вакытыгыз бит, мәшәкатьләнеп килеп йөрмәскә иде…

Хәлим. Кирәкми алай, Әминә. Йә, ничек?

Әминә. Кичә күреп киттең ич, үзгәреш юк. Авыртмый. Озакламый чыгаралар.

Хәлим. Хәйдәр нигә килгән?

Әминә. Син аны күрдеңмени? *(Сүзне икенчегә борып алып китү өчен.)* Кичә синнән соң, теге, кем әле,

Хәйретдин исемле карт килде. Юл уңаенда кереп чыктым, ди. Синең әниең белән килгәннәр. Син әйт аларга, йөрмәсеннәр.

Х ә л и м. Без кичә әни белән сөйләштек. Ул мине ачулана. Авылда төрле кирәкмәгән сүзләр йөри. Хәзер мин үземнән үзем шикләнә башладым инде. Бәлки, мин гаепледер дигән шик килә. Уйлап карасаң, нindидер бер... Әминә, бәлки, сине җибәрерләр? Әйдә, кайтыйк... Безгә... Болай итеп булмый. Моның бер ахыры булырга тиеш. Миңа җинаятьче дип карауларын теләмим.

П а у з а.

Ә м и н ә. Нинди ахмаклык! Больницада ятам. Нинди ахмаклык!

Х ә л и м. Кирәкми, Әминә, искә алма.

Ә м и н ә. Авылыгызда нәрсә сөйлиләр?

Х ә л и м. Әминә, сөйләшмик ул турыда.

Ә м и н ә. Сөйлиләрдер шул, сөйләсеннәр. Югыйсә авылыгызда сиңа Аллага табынган кебек табыналар. Янәсе, менә безнең авылдан да нинди кешеләр чыга. Юк, мин андый ук фикердә түгел хәзер. Син — гап-гади бер авыл егете. Кичә уйлап яттым. Безнең беренче танышкан көннәрне. Кызык. Институтта кичә бара. Танцының кызган чагы. Вальс әйләнәләр. Янымда бер төркем кызлар басып тора. Алар кем турындадыр сөйләшәләр. Мактыйлар. Галим булачак, диләр. Кем икән ул, дип кызыксынам. Ниһаять, сүзнең кем турында барганы ачыклана. Ул егет күрше авыл егете икән. Менә ул мине биергә чакыра. Биибез. Сөйләшәбез. Икенче кич тә очрашабыз. Тагын очрашабыз. Тагын, тагын... Яратам, ди. Мине авылга кайтарып җибәрәләр, аның тагын бер ел укыйсы бар. Вәгъдәләр бирешәбез. Ул кайта... һәм аның мине яратмавы ачыклана.

Х ә л и м. Минем бит, Әминә, алай дип әйткәнем юк.

Ә м и н ә. Аңа мин кирәкмим, аңа зоотехник кирәк икән. Ахмаклык! Теге кызны искә алмаганга гаҗәпләнәсеңме? Сәбәбе ачык. Исемен телгә аласым килми. Хәлим, бар кайт, сине эш көтә, бар.

Х ә л и м. Юк, мин бүген синсез кайтмыйм.

Ә м и н ә. Син акыллы кеше, уйлап сөйлә.

Х ә л и м. Миңа хәзер барыбер.

Ә м и н ә. Мине җибәрмиләр. Җибәрсәләр дә, мин ашыкмыйм әле. Бераз ял итеп алырга исәп.

Х ә л и м. Тик син, зинһар, әллә ниләр уйлама.

Ә м и н ә. Ярый, сау бул, миңа керергә кирәк.

Х ә л и м. Мин иртәгә килермен.

Ә м и н ә. Рәхим ит.

Х ә л и м. Иртәгә кадәр.

Хәлим китә башлый. Әминә башта аны тыныч кына озата. Аннары кинәт Хәлим артыннан ташлана.

Ә м и н ә. Хәлим, китмә, тукта!

Хәлим туктый. Әминә аның кулларына ябыша.

Әйт, Хәлим!

Х ә л и м. Нәрсә әйтим?

Ә м и н ә. Кил, иртәгә кил!

Ф ә н и я күренә. Ул, Хәлим белән Әминәне күреп, читкә китә.

Кил, килми калма. Хәлим, нигә син шундый? Син бүген ниндидер ят кешегә охшагансың.

Х ә л и м. Юк. Нигә алай булсын?

Ә м и н ә. Булма, ят булма... Ярат син мине, Хәлим! Син мине яратырга тиеш... Ә хәзер бар, кайт...

Х ә л и м китә. Әминә уйланып басып тора. Аннан әкрен генә ишеккә юнәлә. Ашыгып, Ф ә н и я керә.

Ф ә н и я. Әминә апа!

Әминә яшен суккандай борыла.

Ә м и н ә. Син? Тагын син?!

Ф ә н и я. Әминә апа, мин гафу үтенергә килдем. Хәлим абыйны ратуым өчен сездән гафу үтенәм. Мин башка бервакытта да, беркайчан да... Мин сезнең бәхетле булуыгызны гына телим.

Ә м и н ә. Килдеңме, ниһаять? Иртәме-соңмы, минем алдыма киләчәгеңне белдем мин, көттем мин сине.

Ф ә н и я. Тик Хәлим абыйны барыбер яратам мин, яратам. Гафу итегез.

П ә р д ә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Бишенче күренеш

Чишмә буе. Агачлык. Төрле юллар, сукмаклар киселешеп үткән.
Кич. Пәрдә ачылганда, Хәйретдин карт чишмә акканын күзәтеп тора.

Хәйретдин. Челтер-челтер, челтер-челтер агасың да агасың, җанкисәгем. Җырлый-җырлый агасың. Мин белгәннән бирле агасың. Ә суың кимеми. Син һаман да яшь. Мин картаям, чишмә. Бер ялгызым картаям. Моңайма, тирә-ягыңда кешеләр күп, дисеңме? Шулаен ул шулай, кешеләр күп, яхшы кешеләр күп. Тик менә Нәфисә юк бит. Без Нәфисә белән беренче тапкыр синең янында күрешкән идек. Һәй, күңелле булганые. Аны җирләгәннән бирле күңелсез миңа. Кешеләр арасында уйныйм, көләм, үзем генә калгач моңаям шул, чишмә. Ни хәл итим? Синең яныңа килеп утырып юаныч табам. Ак әйдә, җанкисәгем, ак. Син бик күп кешеләрне күрерсең әле. Синең яныңда күпләр вәгъдә бирешәләр. Бәхетле булсыннар. Нәфисә белән минем кебек яшәсеннәр...

Нурлидә керә.

Нурлидә. Абау! Хәйретдин абый, син икәнсең әле.
Хәйретдин. Ә-ә, Нурлидә! Нишләп йөрисең?
Нурлидә. Аптырап килдем, Хәйретдин абый. Фәниям югалды.
Хәйретдин. Ничек югалды?
Нурлидә. Эшеннән кайтты да сөйләшми-нитми каядыр чыгып йөгерде.
Хәйретдин. Кая китте икән?
Нурлидә. Синең янда түгел микән дип, сезгә бардым.
Хәйретдин. Килмәде шул. Сирәк килә.
Нурлидә. Бик борчулы чагы. Әллә нигә күңелем тыныч түгел. Ул-бу булмагае дип куркам.
Хәйретдин. Кызым минем сүземнән чыкмас, дигән идең, Нурлидә килен.
Нурлидә. Әллә нишләде шул. Көннән-көн үзгәрә. Хәерлегә түгел. Сорашып та карыйм, дәшми. Теге кызның шулай булуына син гаепләме дим, әйтми.

Хәйретдин. Ничек ул гаепле?

Нурлидә. Соң бит ишеткәнсең. Үзең дә шунда булгансың. Бөтен кеше сөйли ич. Минем Фәниям, имеш, араларына кергән. Теге кыз шуның хурлыгыннан…

Хәйретдин. Син, Нурлидә килен, гайбәтче хатыннар сүзен тыңлама.

Нурлидә. Һәй, Хәйретдин абый, гайбәт түгел шул. Фәниянең араларына керүе хак. Үз теле белән әйтте.

Хәйретдин. Шулай укмыни?

Нурлидә. Ичмасам, син бер киңәш бир, Хәйретдин абый.

Хәйретдин. Мин нәрсә әйтим инде? Монда синең белән минем киңәшнең файдасы тияр микән? Менә теге чакта ни өчен елаган икән ул! Шуның өчен икән. Әй бу дөнья дигәнең!

Нурлидә. Кем уйлаган бит, кем уйлаган.

Хәйретдин. Монда кайгырып торып булмый. Эзләргә кирәк. Син күл буена барып кил. Мин басуга барам. Бәлки, эшендәдер, комбайннар тирәсендәдер?

Нурлидә. И Ходаем! *(Китә.)*

Хәйретдин дә китәргә җыена. Үтеп баручы Хәлим белән очраша.

Хәлим *(туктап)*. Исәнмесез, Хәйретдин бабай!

Хәйретдин. Шөкер әле, олан. Каян киләсең?

Хәлим. Районнан.

Хәйретдин. Бульнистанмы?

Хәлим. Әйе.

Хәйретдин. Савыгамы?

Хәлим. Әйе.

Хәйретдин. Син, ни… күңелеңә авыр алма, синең болай итеп йөрүең миңа бер дә ошамый, олан. Нәрсә инде бу? Әйбәт түгел бит. Икегез дә укыган кешеләр. Вәгъдәләшкәнсез дип ишетәм. Ник алай тәмсезләнеп йөрисез?

Хәлим. Минем ни гаебем бар?

Хәйретдин. Синең бабаң авылның күрке иде, атаңны мактап туя алмыйбыз. Син нәрсә? Ярамый бит.

Хәлим. Син берни дә аңламыйсың шул, Хәйретдин бабай.

Хәйретдин. Авыл белән күреп торабыз. Аңламаслык хикмәте юк. Дөресен әйтим, безнең авыл халкы ошатмый

ул кызны. Эшлексез, диләр. Үзем дә күргәлим, бар эше киенеп-ясанып урам буйлап йөрүдә. Хәер, анысын үзегез беләсездер. Сез бездән акыллырак, укыган. Ә болай килешми. Тәмле итеп яши белергә кирәк. Уйла, олан. Аннан соң… әле генә Нурлидә килен монда сугылган иде. Фәниясен эзли.

Х ә л и м. Фәния нишләгән?

Х ә й р е т д и н *(сынаулы карап)*. Нәрсә сезнең аның белән?

Х ә л и м. Берни дә юк.

Х ә й р е т д и н. Берни дә юк дисеңме?

Х ә л и м. Нәрсә дип әйтим инде?

Х ә й р е т д и н. Мин сиңа, киңәш биреп, тегеләй эшлә, болай эшлә дип әйтмим. Шулай да син, олан, ызанда үсә торган хуҗасыз агач булма. Аны да бит шулай үткән-сүткән кеше сындырып китә. Син Нурлидә кызы белән сөйләш әле.

Х ә л и м. Сөйләштем. Фәниянең гаебе юк.

Х ә й р е т д и н. Мин дә аны гаепләмим. Аның шундый канат кагынып очарга җыенган чагы. Син уйлап эшлә. Канаты каерылмасын. Син егет кеше бит.

Х ә л и м. Миңа шул турыда гына уйларгамы? Болай да инде эшемне җүнләп эшләгәнем юк. Ә миннән эш көтәләр.

Х ә й р е т д и н. Мәхәббәтең җимерек булса, барыбер җүнле эш башкара алмассың.

Х ә л и м. Мин аңа әйттем бит инде.

Х ә й р е т д и н. Кемгә?

Х ә л и м. Әминәгә.

Х ә й р е т д и н. Соң?

Х ә л и м. Әллә ничек шунда. Куркам мин, Хәйретдин бабай. Мин хәзер бөтенесенә риза. Теләсә нишләсен.

Х ә й р е т д и н. Алай булмый. Хәзердән үк әнә нинди бит. Сиңа шул ошыймы?

Х ә л и м. Шайтан алсын!

Х ә й р е т д и н *(урыныннан торып)*. Шайтан дигәнең бик явыз, хәвефле нәрсә, диләр. Сине дә эләктереп алмагае. *(Китә.)*

Хәлим уйга чумып утырып кала. Җырлый-җырлый, В а х и т кайтып килә. Хәлим янына җиткәч туктый.

В а х и т. Хәлим абый, сәлам бирдек!

Хәлим. Хәерле кич, Вахит!

Вахит. План үтәлде, Хәлим абый, йөз илле процент.

Хәлим. Ул-бу юкмы?

Вахит. Нәрсә булсын? Соңгы участокка күчтек. Эх, рәхәт тә булды соң бүген! Ике сәгать берүзем генә эшләдем. Хәйдәр абыйдан башка. Әле кайтырга исәп юк иде. Ул куып кайтарды. Эзең булмасын, ди. Ай-яй, кеше. Нигә алайдыр инде? Миндә ни ачуы бардыр? Мотоцикл белән жуылдап килеп җитте дә штурвалдан мине куып төшерде. Смена бетте, кайтып йокла, ди, мин бүген гулять итәм, ди.

Хәлим. Кайда ул хәзер?

Вахит. Кырда. Мотоциклы бозылган, шуны төзәтә калды. Әминә апа янына бардыгызмы, Хәлим абый?

Хәлим. Бардым.

Вахит. Кайчан кайта?

Хәлим. Озакламас.

Вахит *(паузадан соң)*. Хәлим абый, мин сездән бер әйбер сорасам көлмәссезме?

Хәлим. Нәрсә?

Вахит. Чын мәхәббәт буламы, Хәлим абый?

Хәлим *(Вахитка карап торып)*. Үзең ничек уйлыйсың соң?

Вахит. Белмим шул, китапларда була, анысын беләм. Менә китапта язган кебек яшәсәң иде ул, Хәлим абый. Миңа бер папирос бирегез әле, Хәлим абый?

Хәлим. Нигә ул?

Вахит. Йөрәк яна.

Хәлим. Тәмәке тарткач басыламы?

Вахит. Кем белә инде! Болай бит ул, Хәлим абый. Әгәр мин яратам икән, шул ярату ымны аңа әйтәм икән, мин ялганламыйм бит инде. Чынлап әйткәнне белергә тиеш ич инде ул. Ятратканыңны башка төрле белдереп булмый бит. Ә ул... Бир инде бер папирос, Хәлим абый. *(Хәлим аңа папирос бирә. Вахит кабыза, ләкин тарта белми, бер суыруга ташлый.)* Әче... Хәлим абый, сез мине әллә нинди дип уйламагыз. Сезне беләм мин. Сез алай эшли торган кеше түгел. Сез яхшы кеше. Әйтегез әле аңа. Күреп тора бит ул. Аңламый бит.

Хәлим. Сиңа Әминә апаң ошыймы, Вахит?

Вахит. Ник, Хәлим абый?

Хәлим. Яратасыңмы син аны?

В а х и т *(шикләнеп)*. Кызык кына әйтеп куйдыгыз. Нишләп мин Әминә апаны яратыйм ди... Ә нигә алай дип сорадыгыз, Хәлим абый? Әллә берәр сүз ишеттерделәрме?

Х ә л и м. Бая син мине яхшы кеше диден. Ярый, синеңчә булсын, мин бик яхшы кеше ди. Ә Әминә апаң ничек?

В а х и т. Үзегез беләсездер инде.

Х ә л и м. Юк, син боргаланмыйча әйт. Менә миңа бөтенесе дә әйтәләр, Әминә фәлән, Әминә төгән, диләр. Сиңа тиң түгел, син аның белән бәхетле булмаячаксың, диләр. Син әйт, ничек?

В а х и т. Мин, Хәлим абый, андый сорауга җавап бирә алмыйм. Ничек инде кешегә бәхетле булмаячаксың дип әйтәсең? Минемчә, дөньяда ничаклы кеше бар, бөтенесе үзенчә бәхетле. Сез миннән үзем турында сорасагыз, мин әйтә алам. Мин һәрвакыт бәхетле булачакмын. Әминә апа турында сорыйсыз икән, шуны гына әйтәм, Хәлим абый, ул мин яраткан әйберне яратмый.

Х ә л и м. Җирнеме?

В а х и т. Әйе. Бу минем үз карашым. Сезгә ничектер, белмим.

Х ә л и м. Син мине ни өчен яхшы кеше дип атыйсың соң?

В а х и т. Мин яратканны яраткан өчен.

Х ә л и м *(Вахитның иңбашына кулын салып)*. Ярый, бар, кайт, Вахит, йокла, ял ит.

В а х и т. Мин арымадым. Өч төн йокламасам да, берни булмый. Йоклап ни файда? Менә урак бетә. Клуб ачыла башлар. Танцылар. Хәзер безгә клубка барып танцевать итәргә ярый инде, укучы түгел... Хәлим абый, гармунны монда алып килимме? Чишмә буенда гармунның тавышы бик әйбәт чыга.

Х ә л и м. Кирәкми. Мин хәзер комбайннар янына китәм.

В а х и т. Бергә барабыз. Юлда уйнармын.

Х ә л и м. Сиңа ял итәргә кирәк бит. Иртәгә тагын эшкә.

В а х и т. Алып килим инде, Хәлим абый? Сагындым гармунымны. Урамда уйнарга уңайсыз. Ичмасам, кырда уйнармын. Алып килим?

Еракта яшен яшьни.

Х ә л и м. Бар, алайса, тизрәк. Әнә яшен уйнап тора.

В а х и т. Уйнасын. Мин аңардан курыкмыйм. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Хәлим еракта яшьнәгән яшенне күзәтә. Шулвакыт ашыгып Ф ә н и я керә. Хәлимгә очрагач, кинәт туктап кала, ирексездән артка чигенеп куя.

Х ә л и м. Фәния?

Ф ә н и я. Юк! Юк!!

Х ә л и м. Сиңа ни булды?

Ф ә н и я. Ә?.. Юк... Берни дә юк.

Х ә л и м *(нидер сизенеп, Фәния янына килә).* Яле, кара әле? Бөтенләй төсең киткән ич.

Ф ә н и я. Җибәрегез мине, өйгә кайтасым бар. Мине әнием көтә.

Х ә л и м. Тукта! Нишләдең син?

Ф ә н и я. Нигә? Нигә сез мине саклап тордыгыз? Мин бит... Китегез!

Хәлим, ни әйтергә белми, читкә тайпылып, Фәниягә юл бирә. Фәния, бер-ике адым атлагач, тагын туктап кала, үзен кулга алырга тырыша.

Хәлим абый, мин... аның янына бардым.

Х ә л и м. Син больницада булдыңмы?

Ф ә н и я. Мин аңардан гафу үтендем.

Х ә л и м. Гафу үтендең?

Ф ә н и я. Кызганам мин сезне, Хәлим абый.

Х ә л и м. Нәрсә? Ни өчен?

Ф ә н и я. Юк, берни дә юк. Ул мине гафу итте. Сез дә мине гафу итәрсез дип уйлыйм.

Х ә л и м. Ни өчен?

Ф ә н и я. Бөтенесе өчен дә. Мин уйламаганмын. Мин ялгыш уйлаганмын. Мин сезнең өчен күрше кызы Фәния генә икәнлегемне белмәгәнмен. Үземнең мәхәббәтем аркасында башкаларның мәхәббәтен күрмәгәнмен. Хәзер инде аңладым. Сез мине, Хәлим абый, һаман да шул күрше кызы Фәния дип кенә атагыз, ярыймы? Хәер, кирәкми, мин сезнең өчен беркем дә түгел. *(Китә башлый.)*

Х ә л и м. Тукта әле, Фәния!

Ф ә н и я. Мине әнием көтә. Вакытында өйгә кайтмасам борчыла ул.

Х ә л и м. Юк, Фәния, мин җибәрмим сине. Синең болай китүең начар. Мин синнән ул сүзләрне ишетергә

теләмим. Синең гафу үтенүең дә кирәкми миңа. Минем тынычлыгым югалды.

Ф ә н и я. Җибәрегез, Хәлим абый.

Х ә л и м. Фәния, китмә! Ярый, синеңчә булсын. Гафу үтенгәнсең. Тик китмә. Миңа күңелсез. Элек мин синең белән көлеп, шаярып сөйләшә ала идем. Синең янда һәрвакыт күңелле була иде. Нигә хәзер дә шулай булмаска?

Ф ә н и я. Шул шаярып сөйләшүләр минем башымны әйләндергән инде, күрәсең.

Х ә л и м. Калсын шулай, Фәния.

Ф ә н и я. Кала алмаганын үзегез дә беләсез, Хәлим абый.

Х ә л и м. Белмим, мин белергә дә теләмим. Мин уйладым. Басуда сөйләгән сүзләреңне, аннан соң булган вакыйганы күз алдыма китердем. Бөтен үткәннәрне искә төшердем. Минем өчен иң күңелле минутлар синең капка башына менеп, мине үртәп калуың булган. Минем өчен иң кадерле сәгатьләр синең булачак хыялларыңны тыңлап таң аттыру булган. Минем өчен иң ләззәтле секунд мин Казанга киткәндә сине сеңлем кебек күреп, кысып кочаклаган вакыт булган. Нигә үстең, нигә һаман сабый булып калмадың син, Фәния? Кирәкми, гафу үтенмә. Мин монда гафу үтенергә тиеш. Фәния, кара әле миңа!

Мотоцикл үтеп киткән тавыш. Фара яктысы Фәния белән Хәлимне яктырта. Хәлим Фәниянең күзләренә карап җырлап җибәрә.

Фәния, Фәния, димәгез,
Фәниягә тимәгез!
Фәниягә тигән кеше
Рәхәт күрер димәгез.

Фәния кинәт елап җибәрә.

Фәния, кирәкми, кирәкми. *(Яулык алып аның күз яшьләрен сөртә. Фәния карышмый.)*

Ф ә н и я. Миңа бүген сезне күрергә ярамый иде, Хәлим абый.

Х ә л и м. Эх, син, күрше кызы Фәния. Еларга ярамый. Ул сиңа килешми. Син бит инде зур үскән, дәү кыз. *(Фәниянең күзләренә карап тора.)* Йә, көл әле. Көл инде!

Фәния ирексездән елмая.

Менә шулай. Эх син!..

Яшен яшьни. Фәния, куркып китеп, Хәлим кочагына сыена. Вахит керә. Хәлим белән Фәнияне күргәч, кулыннан гармуны төшеп китә.

Фәния *(кинәт исенә килеп, Хәлимнең кочагыннан чыга)*. Хәлим абый! Мин тагын ялгыштым, әйеме? Юк, мин болай булуын теләмәгән идем. Өйгә кайтып бара идем. Абындым, тагын абындым. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Хәлим нишләргә белми басып кала. Вахит җирдән гармунын алып, Хәлим янына килә. Сүзсез сәхнә. Вахит гармунын тартып уйнап җибәрә.

## Алтынчы күренеш

Бишенче күренештәге декорация. Вакыт иртә. Сукмакта Хәлим күренә. Ул басуга бара. Больницадан Әминә кайтып килә. Китеп барган Хәлимне күрә.

Әминә. Хәлим! Хәлим!

Хәлим керә. Әминәне күреп аптырап кала.

Хәлим. Син ничек?

Әминә. Кайтып киләм. Җибәрделәр. Киемнәрне кичә үк алып куйдым да бүген иртә таңнан юлга чыктым. Машина очрады. Бәрлегуҗа күперенә кадәр утырып кайттым. Нигә йөзең чытык? Әллә мине очраткангамы?

Хәлим. Юк. Нигә?

Әминә. Күзләреңнән күреп торам. Ә мин тагын ашыгып кайткан булам. Хәлим мине көтәдер дип хыялланам.

Хәлим. Әминә, бар, син кайт.

Әминә. Кайттым бит инде.

Хәлим. Өегезгә кайт. Мин бүген барырмын. Сөйләшербез.

Әминә. Син һаман да шул, кайт, сөйләшербез... Ни эшләргә уйлыйсыңдыр... Бөтенесе сөйләшенгән, хәл ителгән ич инде.

Хәлим. Сөйләшенмәгәнен син яхшы беләсең, Әминә.

Әминә. Минем бернинди сүз дә ишетәсем килми.

Ике ел сөйләштем, җитәр. Мин хәзер турыдан-туры сезгә кайтам. Беркая да китмим.

Хәлим. Ничек безгә?

Әминә. Шулай. Хатының булып.

Хәлим *(паузадан соң)*. Алай булмаячак, Әминә.

Әминә *(куркып)*. Димәк?..

Хәлим. Әйе.

Әминә. Хәлим, минем хисләрем белән шаярма. Вәгъдәң бар.

Хәлим. Син аны юк дип исәплә.

Әминә. Менә ничек?! Шул сүзне әйтер өчен ике ел алдап йөрдеңме?

Хәлим. Кем кемне алдагандыр, анысы билгесез. Инде моннан соң да алдашмыйк, Әминә.

Әминә. Бәлки, синең күңелең үсеп киткәндер? Синең өчен кешеләр суга ташланалар бит. Алайса, бел, сикермәдем мин! Сикерергә дә уйламадым. Яр ишелде. Ялгыш егылдым.

Хәлим. Әминә, нигә инде андый сүзләр?

Әминә. Шуңа үзеңне әллә кемгә санарга ашыкма.

Хәлим. Син мине торган саен гаҗәпләндерәсең, Әминә.

Әминә. Дөресен ишеткәч, гаҗәптер шул. Миңа да гаҗәп. Сине аңлый алмый интегәм ич. Әллә, ябь-яшь кызның артыннан чабуын күргәч, күңелең үзгәрдеме? Башың-күзең әйләндеме?

Хәлим. Фәниягә кагылма.

Әминә. Тик өметеңне сузма. Кичә ул минем янга килде. Гафу үтенде.

Хәлим. Беләм.

Әминә. Каян беләсең? Димәк, сез очраштыгыз? Аңлашылды. Бөтенесе дә аңлашылды. Ой, нинди ахмак мин! Шуның сүзенә ышанып. Ахмак! *(Елый.)*

Хәлим. Әминә...

Әминә. Юк! Мин алдандым, алдандым! *(Елавыннан кинәт туктап.)* Йә, әйт инде, хәзер нишләргә миңа?

Хәлим. Әминә, әйдә, тынычлап аңлашыйк. Яраттым мин сине, Әминә. Ничек танышканыбызны үзең беләсең. Күңелле иде ул чакта. Ләкин, кайткач, мин сине таныймый башладым. Синең турыда кайтканнан бирле бер генә яхшы сүз дә ишеткәнем юк. Билгеле, мәхәббәттә кеше сүзе артык. Ләкин, Әминә, без кешеләр арасында

яшибез. Мине кешеләр кеше итте. Хыялыма ирешергә, җирнең хуҗасы булырга, олы теләкләр белән яшәргә мине кешеләр өйрәтте. Ә ул хыялларым синең өчен чүп кенә икән. Хәтта мин сабый дип исәпләгән Фәния аларны күрә белә, ә син, вәгъдә дип, мине әллә кая өстерисең. Синең өчен җир дә, кешеләр дә кирәкми. Сиңа ир кирәк. Сиңа ир булган кеше, сине бер җирдә дә эшләтмичә, байлык-муллыкта яшәтеп, сиңа калкан булырга тиеш. Мин аны булдыра алмыйм. Фәния әйткәндәй, мәхәббәт — мәхәббәт белән, тик ул намуска тап төшерерлек булмасын. Мещан буласым килми минем, Әминә.

Ә м и н ә. Менә ничек сөйләшә беләсең икән! Юкка гына сине җебегән егеткә санап йөргәнмен. Йә, нишләргә кушасың соң миңа?

Х ә л и м. Анысын үзең уйла инде. Сабый түгел. Ярый, Әминә, мин ашыгам. Хуш!

Ә м и н ә. Юк, беркая да бармыйсың. Мин синнән калмыйм. Теләсәң нишлә. Безнең авылда туй көтәләр. Ничек мин кеше күзенә кайтып күреним? *(Хәлимнең кулына тотынып.)* Китмә, Хәлим! Яратам мин сине. Син ни әйтсәң, шуны эшләрмен. Мин бөтенесенә күнәм. Хур итмә мине! Миңа кешеләрдән оят.

Х ә л и м. Эх, Әминә...

Х ә й д ә р эшкә бара. Әминә белән Хәлимне күреп, яннарына килә.

Х ә й д ә р. Пар күгәрченнәргә сәлам! *(Әминәгә.)* Әле кай арада кайтып өлгердең? Иртә таңнан свидание?

Х ә л и м. Хәйдәр, син бара тор, мин хәзер барып җитәрмен.

Х ә й д ә р. Синсез эш чыкмый анда, слушай. Тизрәк, комбайн свичәсенең задний мусты эрегән. *(Көлә.)*

Ә м и н ә. Юлыңда бул.

Х ә й д ә р. Әле сез үбешеп туймадыгызмыни? Ул кадәр нәфесле булмыйлар инде. Кичә дә төне буе үбештегез. Күреп киткән идем. Бигрәк сагынышкансыз икән. Һаман аерылыша алмыйсыз.

Ә м и н ә *(шикләнеп)*. Хәлим, нәрсә сөйли ул?

Х ә й д ә р *(Әминәгә)*. Нигә, син түгел идеңмени ул? Мин аны син дип уйлаган идем. Берсе Хәлим иде инде, точно күрдем. Икенчесе кем булды икән? Әллә Фәния булды микән?

Хәлим. Син! *(Хәйдәргә кизәнә.)*

Хәйдәр *(аның кулын әләктереп)*. Кулыңны уйнатма, унбиш сутка укыган кешеләргә дә бар. Нәрсә монда юл чатында очрашып чутыйн-чутыйн киләсең. Әйт, Фәния идеме? Нигә дәшмисең? *(Каушап калган Хәлимне этеп җибәрә.)* Җитмәсә, җикеренгән була.

Әминә. Хәлим, дөресме?

Хәйдәр. Мин ялганламыйм, слушай.

Әминә. Мин синең белән сөйләшмим.

Хәйдәр. Ай Алла, сөйләш соң, аның белән сөйләш. *(Юл кырыендагы ташка барып утыра.)*

Әминә. Хәлим, дөресме? Кичә Фәния белән шушында...

Хәйдәр. Юк, тегендәрәк. Әнә алар утырган җир.

Әминә. Оятсыз! Юк, җавап бирәчәксең син болар өчен. Мин барыбер үчемне алачакмын. *(Елый.)* Ике ел гомерем әрәмгә китте. Нинди егетләрне шуңа алыштырдым бит. Нигә? Нигә? Кем миннән көлә? *(Елавыннан туктап.)* Юк-юк! Алай булмаячак! Мин – Әминә! *(Хәйдәр янына килә.)*

Хәйдәр таш өстендә селкенми генә утырган җиреннән кинәт торып чигенеп куя.

Нигә куркасың?

Хәйдәр *(каушап)*. Нишләп... Курыкмыйм.

Әминә. Яратасыңмы мине?

Хәйдәр. Ничек? Ни дисең?

Әминә. Туры әйт, яратасыңмы? Син бит минем арттан сөйрәлеп йөргән идең. Менә хәзер мин синеке. Әйдә, алып кайт инде өеңә. Мин синең хатының булырга риза.

Хәйдәр. Өйгәме? Хатын итепме? Ничек?

Әминә. Туй үткәрербез.

Хәйдәр. Туймы? Бүгенме?

Әминә. Әйе, бүген.

Хәйдәр. Хәзер үкме?

Әминә. Әйе, хәзер үк.

Хәйдәр. Хәзер үк... Хәзер үк... Тукта әле...

Әминә. Мин шаяртмыйм, мин – синең хатының. Әйдә, алып кайт.

Хәйдәр *(тәмам аптырашта, ни дип әйтергә дә белми, тораташ кебек басып тора)*. Ничек, болай кинәт кенә...

Ә м и н ә. Әйе, кинәт кенә. Моментыннан файдаланып кал, югыйсә…

Х ә й д ә р *(уйларыннан айнып)*. Нәрсә «югыйсә»… Куркытма син мине, слушай. Хәлимне каптыра алмагач, хәзер Хәйдәр дә ярый дисеңме? Акула булмаса, кильке?

Ә м и н ә. Килька түгел, пешка син, белдеңме?

Х ә й д ә р *(ярсып)*. Телеңне озайтма… Хатын-кыз дип тормам…

Ә м и н ә. Кабахәтләр, кансызлар! Ненавижу, барыгызны да ненавижу! Берегез дә кирәкми! *(Үксеп елап чыгып китә.)*

П а у з а.

Х ә й д ә р *(үз-үзен кулга алырга тырышып)*. Һе, ир кирәк булган… Әзер ир… Чак кына елан авызына барып кермәдем бит, ә! Уф, гомеремдә беренче тапкыр тезләрем калтырый. Котырган эт тешләгәнмени? Тизрәк комбайн янына барырга кирәк. *(Тиз генә чыгып китә.)*

Хәлим – уйлар диңгезендә. Таш янына килә. Утыра. Адашкан карашы белән авыл ягын күзәтә. Кемнәрнеңдер килгәнен күреп, урыныннан тора. Ф ә н и я керә. Кулында – кечкенә генә чемодан. Ашыгып, юл буйлап атлый. Н у р л и д ә аны куып җитә. Хәлим аларга күренми.

Н у р л и д ә. Кызым, Фәния, тукта, акылыңа кил.

Ф ә н и я. Борчылма, әнием, мин акылымда. Олы юлга чыгам да… Машиналар йөреп тора.

Н у р л и д ә. Әй кызым, кызым, сөйләшү юк, киңәшү юк. Ярый әле, капкадан чыгып киткәнеңне күреп калдым.

Ф ә н и я. Сиңа хат язып калдырдым мин, әнием.

Н у р л и д ә. Шул хатыңны гына укып хәсрәтләнер өчен үстердеммени мин сине? Шуның өчен төн йокыларымны калдырып, бишегең янында утырдыммыни? Әйдә, кайт, кызым. Китәсең килсә, тотмам. Иртәгә китәрсең. Юлга үзем җыйнап, пристаньга кадәр озатып куярмын.

Ф ә н и я. Йә инде, әнием, бернәрсә дә булмаган ич. Тынычлан, бар, кайт.

Н у р л и д ә. Әйт, ичмаса, кая төбәп барасың?

Ф ә н и я. Казанга, Садыйк абыйларга.

Н у р л и д ә. Бу чаклы холыксызланырсың дип кем уйлаган. Ярый, бар, кит. Ни хәл итим, үз башыма хәсрәт үстергәнмен. Кит, әлегә кадәр яшәдем, үлмәдем.

Ф ә н и я. Әнием, сөйләмә инде андый сүзләр. Аңлыйсың бит...

Н у р л и д ә. Аңламыйм да, кирәкми дә. Бар, хәерле юл. Үсеп җиткәч, әниең арткандыр, хуш. *(Кайтыр юлга борыла.)*

Ф ә н и я. Әнием! *(Нурлидә янына килеп туктала.)* Әнием, аңла, читен миңа! Миңа монда калырга ярамый. Аңлыйсыңмы, мин сиңа бөтенесен дә аңлатып яздым. Барысы да син теләгәнчә. Син миңа ачуланып калма. Кайтырмын мин, әнием, тик хәзергә миңа китәргә кирәк. Минем авылдан ераграк китеп уйлыйсым килә. Син мине һәрвакыт аңлый идең бит.

Н у р л и д ә. Юк шул, аңламаганмын, кызым. Үсеп җиткәнеңне сизми калганмын. Юлыңа акчаң бармы?

Ф ә н и я. Бар.

Н у р л и д ә. Садыйк абыеңа ни дип әйтерсең инде?

Ф ә н и я. Белмим әле.

Н у р л и д ә. Әче каргышым төшсен бу Хәлимгә.

Ф ә н и я. Әнием, кирәкми, каргама. Гаебе юк аның. Мин... мин үзем гаепле. Йә, әнием, сау бул. *(Нурлидәне кочаклап үбә дә әкрен генә китә.)*

Нурлидә аны кайгылы караш белән озатып кала. «Каз канаты» көе уйнала. Хәлим, бәйләп куелган кешедәй, сүзсез генә басып торуында дәвам итә. Кинәт бер уйга килеп кузгалмакчы була, ләкин юлдан килгән В а х и т н ы күреп, туктап кала. Вахит Нурлидә белән очраша.

Н у р л и д ә *(күреп)*. Вахит улым, сез бит бергә уйнап үстегез, бергә укыдыгыз, ничек соң? Китте бит, китте!

В а х и т *(аңламыйча)*. Кем китте?

Н у р л и д ә. Фәния китте. Әнә, әнә бара, Вахит! Улым!

В а х и т китеп барган Фәнияне күреп чыгып йөгерә. Хәлим Нурлидәгә күренми генә басуга таба атлый. Нурлидә, кулын маңгаена куеп, Фәния белән Вахит киткән якка карап күзәтә. Пауза. Ф ә н и я н е кулыннан җитәкләп В а х и т керә.

Ф ә н и я. Җибәр!

В а х и т. Юк, ычкына алмассың. *(Фәния кулындагы чемоданны алып Нурлидәгә бирә.)* Мә, Нурлидә апа, алып кайта тор.

Н у р л и д ә. Вахит улым, зинһар, җибәрмә! *(Чемоданны кочаклап, кайтыр якка борыла. Китә.)*

В а х и т *(Фəниягə)*. Син нəрсə, Фəния? Нишлəвең бу?

Ф ə н и я. Синең анда эшең юк!

В а х и т. Юк, Фəния, бар минем эшем. Бөтен нəрсəдə эшем бар минем. Сине яратуым өчен генə түгел. Синең белəн бергə үскəнем, синең белəн бергə укыганым өчен эшем бар минем. Синең кебеклəр өчен кызарырга телəмим мин. Əнилəребезнең күз яшен күрергə телəмим мин. Кая барасың син, кая китəсең? Качарга җыенасыңмы? Үзүзеңнəн качып котылып буламыни?

Ф ə н и я. Сөйлəп бетердеңме?

В а х и т. Бу əле башлавым гына. Син, Фəния, тормышыңның, хыялларыңның, бəхетеңнең тамырына балта белəн кизəнмə. Кайда синең горурлыгың? Шаянлыгың? Шушымы синең килəчəгең? Шуның өчен яшəдеңме син? Нəрсə, мəхəббəт гаепле дип исəплисеңме? Мəхəббəт ул – изге нəрсə. Җүлəр хислəр түгел ул. Мəхəббəт ул олы, аны юл тузанына гына күмеп булмый. Менə ничек аңлыйм мин мəхəббəтне. Эх, Фəния, Фəния!

Фəния башын иеп сүзсез генə тыңлый.

Хəтереңдəме, бервакыт бөтен класс белəн урманга экскурсиягə бардык. Син йөгерə-йөгерə чəчəклəр җыйдың, мин сиңа такыя үреп бирдем. Син көлдең, шаярдың, малайлар кебек агач башларына үрмəлəдең. Шуннан торып очасым килə, дип кычкырдың. Хəтерлисеңме? Безгə ул чакта ундүрт яшь кенə иде. Хəтерлисеңме, мəктəпне тəмамлаганда, класс белəн бергə җыелып, Идел ярына бардык. Бөтенебез дə хыялларыбызны сөйлəдек. Идел шаһит. Ике ел колхозда эшлəгəч, укырга китəбез, дип антлар бирдек. Йə, хəзер нишлисең? Шушымы синең очуың?

Фəния кинəт елап җибəрə.

Елама, күз яшьлəре сиңа килешми. Əйдə.

Ф ə н и я *(күз яшьлəренə тыгылып)*. Кая?

В а х и т. Эшкə. Бүген соңгы участокны урдырабыз бит. Бəйрəм. Бөтен кеше синең сыеңны көтə. Мондый тəмле итеп пешерүче күргəнебез юк иде, дилəр.

Ф ə н и я. Куркам...

В а х и т. Ə син күзеңне йомып бар. Менə нинди курккак йөрəклегə əйлəнə барасың! Син бит андый түгел

идең. Фәния, әйдә башта сезгә кайтабыз. Өс-башыңны алыштыр. Әйдә тизрәк, соңга калырга ярамый. Бүген бәйрәм көн, урак бетә. Әйдә!

Фәния. Юк, юк...

Вахит. Фәния! *(Кулыннан ала.)*

Фәния. Җибәр!

Вахит. Юк, җибәрмим. Адашуыңны теләмим мин синең.

Фәниянең кулыннан тотып, авыл ягына китәләр. Фәния теләр-теләмәс кенә атлый. Пауза. Яңадан Хәлим керә. Ул бөтенләй югалып калган. Басуга бара алмаган, билгеле. Нәрсәнедер ачыкларга, нәрсәнедер хәл итәргә кирәк. Шуның өчен, күрәсең, яңадан авылга кайтып бара. Хәлимгә ике кулын артка куеп атлаучы Хәйретдин очрый.

Хәлим. Хәйретдин бабай!

Хәйретдин. Исәнме, олан!

Ул борчылган, үз-үзенә сөйләнеп, башын селки-селки, басу ягына юнәлә. Юлдан, йөгерә-чаба, Малай кайтып килә.

Малай *(Хәлимне күреп)*. Хәлим абый, нихәл?

Хәлим. Исәнме!

Малай. Мин кайтып киләм бит. Тәки ычкындым. Тотарсың мине! Машинаңны да узып китәм мин. Менә сезнең авылга кереп чыгам әле. Ренат кушты. Әти килеп алсын, ди. Хәлим абый, әллә авырыйсыңмы?

Хәлим. Юк.

Малай. Ә нигә болай?..

Хәлим. Менә шулай, энекәш. Син бернәрсә аңламыйсың шул.

Малай. Аңламас. Әминә апаны очраткансыңдыр әле.

Хәлим. Әйе.

Малай. Шуның өчен кайгырасыңмы? Әллә начар сүз әйттеме?

Хәлим. Сиңа ничә яшь?

Малай. Җиде елдан егерме тула.

Хәлим. Зур икәнсең инде. Синең белән серләшергә була. *(Үз-үзенә сөйләнгәндәй.)* Мин, энекәш, ниндидер бер бушлыкны мәхәббәт дип санаганмын.

Малай. Молодец, Хәлим абый! Мин сиңа әйттем бит инде. Күптән шулай уйларга кирәк булган.

Хәлим. Күптән шулай кирәк булган шул, энекәш.

М а л а й. Кешене белеп бетермисең бит ул. Безнең авылның Вәкил дә, дус, дип йөргән иде. Бер тапкыр да бальниска минем янга килмәде. Ну, кайткач күрсәтәм әле мин аңа. Эх, Хәлим абый, әби авырып тора, ди, әле анда. Детдомга китеп булмас, ахры. Укулар башланыр вакыт та җитте. Болай яшәп булмый бит. Бераз уйларга кирәк. Син кайгырма, Хәлим абый. Менә дигәне булыр әле.

Х ә л и м. Шулай дисеңме?

М а л а й. Билгеле. *(Вахит белән Фәния киткән якка күрсәтеп.)* Кемнәр ул, Хәлим абый?

Х ә л и м. Вахит белән Фәния, Фәния белән Вахит.

М а л а й. Бигрәк инде, әллә кемнәр кебек кулга-кул тотынышып баралар.

Х ә л и м. Мәхәббәт, энекәш.

М а л а й. Мәхәббәт четерекле нәрсә инде ул. Әби дә шулай ди. Ну, ярый, Хәлим абый. Тизрәк кайтып җитәргә кирәк. Гел-гел болай йөреп булмый. Хуш! Мин очтым. Күрешербез әле, Хәлим абый.

Х ә л и м. Хуш!

Малай йөгереп чыгып китә. Хәлим аны елмаеп озата.

П ә р д ә.

# ҖАНКИСӘККӘЕМ

*(Ике пәрдәле пьеса)*

К а т н а ш а л а р:

Җ ә м и л ә — бу дөньяда үзенә генә тиешле бәхетне эзләүче хыялга бай авыл кызы.

Ш ү р ә л е — урманга сыеша алмаган хыялый җан иясе, мәгълүм әкият герое.

Н ә с и м ә, Р ә с и м ә — авыл кызлары.

Р и м — авыл егете.

И с ф а н — Казаннан кайткан егет.

Ш ү р ә л и я, Ш ү р ә л и н ә, Ш ү р и к, Ш ү р к ә — Шүрәленең нәселдәшләре.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Әкиятләрдәге урман аланы. Чәчәгенә карасаң, күзне чагылдыра, чытырманлыгына күз салсаң, куркудан чигенеп куярлык. Әмма шул чытырманлыкка кереп, анда ниләр барын күрәсе килә. Менә шушы аланлыкка йөгереп чыга да инде Җ ә м и л ә. Ул монда җанына урын таба алмаганга, күңеле бәргәләнгәнгә килгән. Анда да кая барырга белми йөри: анда сугыла, монда сугыла да бер каенга сыена. Аланга Н ә с и м ә керә, Җәмиләне эзли. Күреп алып, янына килә.

Н ә с и м ә. Ник табынны ташлап киттең, Җәмилә?

Җ ә м и л ә. Күңелсез анда.

Н ә с и м ә. Вәт кызык! Монда кина күрсәтмиләр инде. Урман ич бу. Үпкәләдең мәллә? *(Җәмилә дәшмәгәч.)* Көчләп алып килмәдек ич. Үзең килдең. Җегетләр синең белән сөйләшмәгәнгә ачуың килдеме?

Җ ә м и л ә. Килде ди! Бик исем китте.

Н ә с и м ә. Алайса, нигә киттең? Кызык кына, торды да китте. Сиңа егетләр карамаганга без гаепле түгел инде.

Җ ә м и л ә. Мин гаепләмим ич. Сез рәхәтләнеп утырыгыз. Мин монда гына йөрим дә...

Н ә с и м ә. Йөр инде, алайса. Безгә генә үпкәләмә, үзең ияреп килдең. *(Китеп бара.)*

Җәмилә ялгызы дөньяга карап кала. Күңелендә җыр туа.

Җ ә м и л ә. Исәнме, күк йөзе!
Исәнме, кояшым!
Җанымның уйнавын
Сизәмсең, тоямсың?
Исәнме, җир генәм!
Исәнме, урманым!
Җырлале, урманым,
Моң тулы җырларың.
Исәнме, исәр җил!
Исәнме, ак болыт!
Яу минем җаныма
Ак булып, пакь булып.
Исәнме, каеным!
Исәнме, миләшем!
Бул әле сердәшем,
Бир әле киңәшең...

И с ф а н *(кереп, Җәмиләнең җырын тыңлап тора).* Яхшы син җырлыйсың икән. *(Җәмиләне кочакламакчы була. Җәмилә читкә тайпылгач.)* Ты чего?

Җ ә м и л ә. Ничава.

И с ф а н. Оһо, русча беләсең икән.

Җ ә м и л ә. Беләм шул.

И с ф а н. Ә син нигә андый усал?

Җ ә м и л ә. Усал булганга усал.

И с ф а н. Ярамый усал булырга. Егетләр яратмас.

Җ ә м и л ә. Яратмасыннар.

И с ф а н. Ә син миңа понравилась. *(Кочакларга үреләкүрелә, Җәмилә тагын тайпыла.)* Ты чего?

Җ ә м и л ә. Ничава.

И с ф а н. Кочаклашырга, што ли, теләмисең?

Җ ә м и л ә. Теләмим.

И с ф а н. Ну, смотри. Миңа кызлар бетмәгән. Ә син миңа ошыйсың. Мин дә сиңа ошыйм. Мин карап тордым, күрдем.

Җ ә м и л ә. Дөрес түгел.

И с ф а н. Дөрес. Син күрми дип уйладың да. Мин бөтенесен күрдем. Әйт, ошыйммы мин сиңа? Әйт дөресен. *(Җәмилә дәшмәгәч.)* Ну, вот. Ә син ломаешься. Ну, ладно. Мин киттем, алайса. *(Китә башлый. Җәмиләнең талпынып алганын сизеп.)* Чего? *(Җәмилә янына килеп.)* Ну, курыкма, курыкма... Чего, егетләр белән кочаклашканың, што ли, юк?

Җ ә м и л ә. Юк.

И с ф а н. Ну, вот, өйрәнерсең.

Җ ә м и л ә. Миннән көләсезме?

И с ф а н. Ничек көләм? Нигә мин синнән көлим?

Җ ә м и л ә. Мин ямьсез. Шуңа күрә...

И с ф а н. Конешно, не красавица. Но мин көлмим. Короче, син миңа ошыйсың, бабушка.

Җ ә м и л ә. Ошасам, сез миңа яратам диегез.

И с ф а н. Яратам?.. Что ж... Була әйтергә. Ну... яратам...

Җ ә м и л ә. Яратсагыз, каршыма тезләнегез.

И с ф а н. Ну, тезләнәм. *(Тезләнә.)* Инде нишлим?

Җ ә м и л ә. Яратсагыз, сез мине кулларыгызга күтәрегез дә еракка-еракка алып китегез.

И с ф а н. Кая, еракка?

Җ ә м и л ә. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән якка.

И с ф а н. Анда нишлибез?

Җ ә м и л ә. Белмим.

И с ф а н. Белмәгәч, нигә еракка барырга? Монда да беркем күрми.

Җ ә м и л ә. Нәрсәне күрми?

И с ф а н. Без нишләгәнне күрми.

Җ ә м и л ә. Без нишлибез соң?

И с ф а н. Ты чего? Дура что ли?

Җ ә м и л ә. Син үзең дура.

И с ф а н. Ну, смотри, бабушка. Мин әйттем. Мин бит яратмаска да могу. Син көзгегә кара, красавица. Ну, ладно, сау бул. И бүтән син миңа карап торма телячьими глазами. У меня тоже душа есть. *(Китеп бара.)*

Җәмилә тагын ялгызы калып бәргәләнә. Агачларга, чәчәкләргә сарылып, күңелендә мең төрле сорауларга җавап эзли.

Җ ә м и л ә. Әйтегез, каеннар, нигә миннән көләләр? Әйтегез, миләшләр, нигә мине мыскыл итәләр? Әйтегез, юкәләр... Әйтегез, күбәләкләр... Мин, бәлки, аңламыймдыр бу дөньяның серләрен? Аңлатыгыз. Минем яратасым, яраттырасым килә. Мәхәббәт, сөюнең серенә төшенәсем килә.

Кем белә мәхәббәт серләрен?
Сөйләгез, тын алмый тыңлармын.
Тыңлармын — күңелемә салырмын —
Тылсымлы җыр итеп җырлармын.
Кем белә ярату серләрен?
Тын алмый тыңлармын, сөйләгез.
Җитмәсә сүзегез сөйләргә,
Җыр итеп, көй итеп көйләгез.
Кем белә сөюнең серләрен?
Сөйләгез, тыңлармын, тын да алмам.
Әйтегез, әллә соң мәхәббәт
Туамы сихерле моңнардан?

Аланга Ш ү р ә л е килеп чыга. Ул бармагы кыстырылган бүрәнәне җилкәсенә салган. Җәмилә, каршында пәйда булган Шүрәлене күреп, тораташ булып катып кала. Шүрәле дә аптыраушта. Ләкин ул беренче булып телгә килә.

Ш ү р ә л е. Исәнмесез...
Җ ә м и л ә. Исәнмесез...
Ш ү р ә ле. Мин — Шүрәле.
Җ ә м и л ә. Шүрәле? Нинди Шүрәле?
Ш ү р ә л е. Шундый Шүрәле.
Җ ә м и л ә. Без мәктәптә укыган Шүрәлеме?
Ш ү р ә л е. Сез укыган да Шүрәле, сез укымаган да Шүрәле. Син кем?
Җ ә м и л ә. Кеше.
Ш ү р ә л е. Матур кыз икәнеңне күреп торам. Исемең ничек?
Җ ә м и л ә. Җәмилә.
Ш ү р ә л е. Исемең үзең кебек матур икән. Нигә шулай карап торасың? Әллә миннән куркасыңмы?
Җ ә м и л ә. Куркам.
Ш ү р ә л е. Ник куркасың?
Җ ә м и л ә. Сез, шүрәлеләр, кешеләрне кытыклап үтерәсез.
Ш ү р ә л е. Кем әйтте?

Җ ә м и л ә. Мәктәптә укыттылар. Шуның өчен дә бүрәнә ярыгына кысканнар бармакларыңны.

Ш ү р ә л е. Алай икән. Алайса, нигә куркасың? Бармаклары кысылган Шүрәле куркыныч түгелдер ич?

Җ ә м и л ә. Барыбер куркам.

Ш ү р ә л е. Курыккач, нигә кычкырмыйсың? Кычкыр! Сез, кешеләр, кычкырырга яратасыз бит. Тавышыгыздан дөнья яңгырап тора. Үзегезнең генә тавышыгыз җитмәгәч, әллә нинди машиналар ясап кычкыртасыз. Ә без менә кычкырмыйбыз. Без көләбез генә. Сез, кешеләр, көлүнең ни икәнен оныттыгыз. Мин, кети-кети уйнап көлешик, дидем. Былтырыгыз минем бармакларымны кысты. Ләкин мин барыбер көләм. Бер кулымның бармаклары бүрәнә ярыгында булса, икенчесе – иректә. Алабыз да кулыбызга бүрәнәне, аны мандолина итеп уйныйбыз. *(Бүрәнәне мандолина итеп уйнап җырлый.)*

Мандолина, мандолина,
Мандолина кыллары;
Күңелләрне күтәрәдер
Кылларының чыңлавы.
Мандолина, мандолина,
Мандолина кыллары;
Мандолина кылларында
Бу дөньяның моңнары.
Мандолина, мандолина,
Мандолина кыллары;
Миңа рәхәт уйнаулары,
Сиңа кызык тыңлавы.

Син нигә елмайдың, Җәмилә?

Җ ә м и л ә. Кызык ич.

Ш ү р ә л е. Әйттем бит мин сиңа. Ә үзеңә елмаю шундый килешә. Син һәрвакыт елмаеп йөр. Җылыйсың килгәндә дә елмай, көл. Син мандолина уйный беләсеңме, Җәмилә?

Җ ә м и л ә. Юк.

Ш ү р ә л е. Өйрәнәсең киләме?

Җ ә м и л ә. Бармакларың авыртамы?

Ш ү р ә л е. Син бармакларыңны бүрәнә ярыгына кыстырып кара. Һай, гафу ит, Җәмиләкәй. Мин ямьсез итеп сөйләштем бугай. Чибәр кызлар белән алай сөйләшергә ярамый.

Җ ә м и л ә. Мин чибәр түгел.

Ш ү р ә л е. Ялгышасың, Җәмиләкәй. Гаҗәеп чибәр син.

Җ ә м и л ә. Шүрәлегә чибәр булып күренсәм генә инде.

Ш ү р ә л е. Син нигә мине мыскыл итәсең? Сез, кешеләр, бөтенесен дә беләбез дип уйлыйсыз. Бәлки, без күбрәк беләбездер.

Җ ә м и л ә. Гафу ит… Ә син нигә карт түгел?

Ш ү р ә л е. Ә нигә мин карт булырга тиеш?

Җ ә м и л ә. Синең бармакларыңны әллә кайчан кысканнар бит инде. Тукай бабай заманында.

Ш ү р ә л е. Шүрәлеләр картаймый, чибәркәй. Алар һаман да унсигез яшьтә. Сезгә ничә яшь, сылукай?

Җ ә м и л ә. Унсигез.

Ш ү р ә л е. Без яшьтәшләр икән ләбаса. Исәнме, Җәмиләкәй!

Җ ә м и л ә. Мин сине кызганам. Куркам да…

Ш ү р ә л е. Мин шулхәтле куркынычмыни, гүзәлкәй?

Җ ә м и л ә. Ул хәтле үк түгел дә…

Ш ү р ә л е. Ә менә мин синнән бераз гына да курыкмыйм.

Җәмилә кычкырып көлеп җибәрә, аңа кушылып, Шүрәле көлә.

Нигә көлдең, Җәмиләкәй?

Җ ә м и л ә. Көлдерәсең ич. Курыкмыйм, дисең… Әгәр дә мин синең бармакларыңны ычкындырсам, миңа тимисеңме?

Ш ү р ә л е. Минем беркемгә дә тигәнем юк.

Җ ә м и л ә. Куркам.

Ш ү р ә л е. Куркып дөрес эшлисең, чибәркәй.

Җ ә м и л ә. Нигә?

Ш ү р ә л е. Чөнки мин сиңа гашыйк булачакмын.

Җ ә м и л ә. Синме?

Ш ү р ә л е. Мин.

Җ ә м и л ә. Шүрәлеме?

Ш ү р ә л е. Шүрәле.

Җ ә м и л ә. Мин бит Шүрәле кызы түгел.

Ш ү р ә л е. Беләм. Ләкин син кеше малаен куып җибәрдең.

Җ ә м и л ә. Күреп тордыңмы?

Ш ү р ә л е. Гафу итә күр, Җәмиләкәй. Сез кычкырып сөйләштегез. Ә шүрәлеләрнең колаклары сак, күзләре үткен.

Җ ә м и л ә. Әйдә минем белән.

Ш ү р ә л е. Кая?

Җ ә м и л ә. Без, кызлар-егетләр, урманга килдек. Мин сине алар янына алып барам. Таныштырам. Аларны да көлдерерсең.

Ш ү р ә л е. Юк, чибәркәй, бармыйм мин анда. Куркам мин алардан. Рөхсәт итсәң, сиңа сокланып карап торам да китәм, мандолинамны җилкәмә салып... *(Җырга күчеп.)*

Урман эчләрендә урман,
Керсәм чыгалмам инде;
Таң алдыннан кошлар сайрый,
Сагынам, түзалмам инде.

Шулай дип җырлыйлармы сезнең авылда?

Җ ә м и л ә. Кил, мин синең бармакларыңны ычкындырам.

Ш ү р ә л е. Курыкмыйсыңмы?

Җ ә м и л ә. Юк.

Ш ү р ә л е. Көчең җитмәс шул, гүзәлкәй.

Җ ә м и л ә. Әйдә икәүләп. Ярыкның бу ягыннан син тот, бу ягыннан — мин. Берьюлы тартабыз да син тиз генә тартып алырсың бармакларыңны.

Ш ү р ә л е. Ә безнең бу бармакларыбыз кысылып калса?

Икәүләп көләләр.

Җ ә м и л ә. Ә без болай эшлибез. Берәр шакмак эзләп табабыз да ярыкка кыстырып барабыз. Хәзер... *(Шакмак эзли.)*

Шул чакта аланга «Җәмилә! Җәмилә!» дип кычкырып, Н ә с и м ә белән Р ә с и м ә керәләр. Ш ү р ә л е юкка чыга.

Н ә с и м ә. Нигә дәшмәгән буласың инде?.. Кычкырабыз, кычкырабыз. Кайтырга кирәк.

Җ ә м и л ә. Кайтырга? Кая?

Н ә с и м ә. Кая булсын, өйгә.

Җ ә м и л ә. Өйгә? *(Як-ягына каранып.)* Ә ул кайда?

Р ә с и м ә. Кем?

Җ ә м и л ә. Шүрәле.

Н ә с и м ә. Нинди Шүрәле?

Җ ә м и л ә. Шушында гына иде ич. *(Алан буйлап чабып эзли.)* Кая китте соң ул? Шушында гына иде. *(Кычкырып.)* Шүрәле!.. Шүрәле!..

Р ә с и м ә. Нишләгән? *(Җәмиләгә.)* Ни сөйлисең син? Нинди Шүрәле?

Җ ә м и л ә. Әле генә монда иде. Бармакларын ычкындырыйм дигән идем.

Н ә с и м ә. Күзеңә генә күренгәндер.

Җ ә м и л ә. Күземә генә? Юк, юк...

Р ә с и м ә. Менә сиңа кирәк булса!

Җ ә м и л ә. Ул сездән курыкты. Ул сездән куркып качты.

Н ә с и м ә. Әйдә, кайтабыз. Тилермә.

Җ ә м и л ә. Юк, мин аны күрергә тиеш.

Н ә с и м ә. Нишләдең соң син? Рәсимә, чакыр әле егетләрне. *(Ава-түнә үтеп барган Римны туктатып.)* Кайда егетләр?

Р и м. Егетләр — мин ул. Нәрсә кирәк, җанкисәгем?

Н ә с и м ә. Менә Җәмилә...

Р и м. Юк, миңа Җәмилә кирәкми. Миңа син кирәк. *(Ава да йоклап китә.)*

«Рим! Рим!» дип кычкырып, И с ф а н керә.

Н ә с и м ә. Исфан...

И с ф а н. Короче, бабушка... Что у тебя болит?

Н ә с и м ә. Җәмилә...

И с ф а н. Җәмилә, Җәмилә... Мине, што ли, эзли?

Н ә с и м ә. Эзләми.

И с ф а н. Ну и хорошо. Киттек гөмбә җыярга. *(Нәсимәне култыклап ала.)*

Н ә с и м ә. Туктале. Җәмилә җүләрләнгән.

И с ф а н. Ну и хорошо. Может быть, җүләр Җәмилә акыллы Җәмиләдән яхшырактыр. Ну, киттек гөмбә җыярга.

Ут сүнә. Ут янганда аланда берәү дә юк. Җ ә м и л ә йөгереп керә, Шүрәлене эзли, чакыра.

Җ ә м и л ә. Шүрәле, Шүрәле, Шүрәле!
Йөгереп кер әле, кер әле —
Урманны, аланны, дөньяны яңгыратып
Көл әле, көл әле, көл әле.

Шүрәленең көлгәне ишетелә. Җәмилә тавыш килгән якка бара. Ләкин тавыш һаман күчеп йөри. Җәмилә чакыруын дәвам итә.

Шүрәле, Шүрәле, Шүрәле!
Мин килдем күр әле, күр әле.
Мин сине коткарам, коткарам богаудан,
Кил әле, кил әле, кил әле.

*(Шүрәлене каршында күреп каушап кала.)* Исәнме, Шүрәле!

Шүрәле. Исәнме, Җәмилә!

Җәмилә. Мин сиңа ярдәм итәргә килдем.

Шүрәле. Ә мин сине көттем.

Җәмилә. Син нигә качтың?

Шүрәле. Син үзең генә түгел идең.

Җәмилә. Кил тизрәк, ычкындырабыз бармакларыңны. Тот бу ягыннан.

Шүрәле. «Шул урыннан нык кына итеп тот, и урман сарыгы...»

Җәмилә. Ник син үзеңне мыскыл итәсең?

Шүрәле. Минме? Итәмме?

Җәмилә. Сарык дисең ич.

Шүрәле. Аны мин уйлап чыгармадым. Сезнең Былтырыгыз уйлап тапкан.

Җәмилә. Димәк, уйлап ук бетермәгән. Сарык түгел син.

Шүрәле. Кем соң?

Җәмилә. Син — Шүрәле.

Шүрәле. Син — Җәмилә.

Җәмилә. Яле, Шүрәле. Тот әле шушы урыннан нык кына итеп. Бер, ике, өч!

Шүрәленең бармаклары бүрәнә ярыгыннан ычкына. Шүрәле, ике кулын күккә чөеп, дөнья яңгыратып көлә-көлә алан буйлап чабып йөри. Җәмилә сокланып һәм, билгеле, куркып та аның кыланышын күзәтә.

Шүрәле *(Җәмилә каршына килеп тезләнеп).* Гүзәлләрдән гүзәл, сылулардан сылу, чибәрләрдән чибәр Җәмиләкәй. Мин синең мәңгелек колың булырмын, ни боерсаң, шуны үтәрмен...

Җәмилә. Миңа кол кирәкми.

Шүрәле. Кем кирәк сиңа, әйт, Җәмиләкәй?

Җәмилә. Минем күңелемне аңлаучы җан иясе кирәк. Ә син сөен, Шүрәле, шатлан, көл.

Шүрәле. Син дә көл, Җәмилә-Җәмиләкәй. Хәзер мин сиңа кызыклар күрсәтәм — көл, Җәмиләкәй.

*(Җәмиләне көлдерергә теләп әллә ниләр кылана — баштүбән кулларында да йөри, тәгәрәп тә китә, агач ботагында да атына.)*

Җәмилә, әлбәттә, көлә һәм Шүрәлегә кушылып, алан уртасында бөтерелә. Аларның кыланулары биюгә күчә.

Алан аллы-гөлле төсләргә чума. Аланга шүрәлеләр кереп тула. Гаҗәпкә калып, Җәмилә белән Шүрәле биюен күзәтәләр. Җәмилә кинәт аларны күреп алып туктап кала.

Шүрәле *(Җәмиләнең курыкканын күреп, янына атылып килә)*. Син курыкма, Җәмилә. Болар — шүрәлеләр. Алар минем дусларым. *(Шүрәлеләргә карап.)* Исәнмесез, дусларым! Менә, күрәсезме, бармакларым минем ирекtә. Җәмилә минем бармакларымны азат итте. Җәмилә бу чибәр кызның исеме. Таныш булыгыз, дусларым.

Шүрәлеләр, кызыксынып, тезелешеп, Җәмилә каршыннан үтәләр. Кайберләре исемнәрен үк әйтеп танышалар.

Шүрик. Исәнмесез! Мин — Шүрик.

Шүркә. Ә мин Шүркә.

Шүрәлия *(бик горур кыяфәт белән Җәмиләгә бармакларын суза)*. Шүрәлия...

Шүрәле. Урманыбызның иң чибәр кызы. Гүзәлләр конкурсында иң актыккы урынны алган кыз.

Җәмилә. Мин дә. Ләкин син матур, ә мин ямьсез.

Шүрәле. Дөрес түгел. Дөрес түгел бит, әйеме, дусларым? Җәмилә чибәр бит, әйеме, дусларым?

Шүркә *(тагын бер тапкыр Җәмиләгә карап)*. Чибәр.

Шүрик *(Шүркә сыман кыланып)*. Бик чибәр.

Шүрәле. Дусларым! Бармакларымның кысылганын күреп сез кайгырган идегез. Инде аларның иректә икәнлеген күреп сөеник. Рәхмәт әйтик Җәмиләгә.

Шүрәлеләр, бергәләп җырлап, Җәмиләгә рәхмәт әйтәләр.

Без, шүрәлеләр, шат күңеллеләр,
Без — дөньяның иркә җаннары;
Көлеп яндырабыз йолдызларны,
Көлеп аттырабыз таңнарны.
Сәлам сезгә шүрәлеләр затыннан,
Рәхмәт сезгә бар шүрәле халкыннан!
Көлеп чыга кояш, без булганда,

Ай да көлеп туа офыктан.
Көлә белгәннәргә дөнья кызык,
Көлгәннәргә диңгез тубыктан.
Сәлам сезгә шүрәлеләр затыннан,
Рәхмәт сезгә бар шүрәле халкыннан!

Җәмиләне уртага алып биергә тотыналар. Бии-бии аланнан ук чыгып китәләр. Шүрәлия туктап кала.

Ш ү р ә л и я. Кайдан таптың бу кызны?

Ш ү р ә л е. Мин аны тапмадым, үзе килеп чыкты.

Ш ү р ә л и я. Ә нигә ул ямьсез?

Ш ү р ә л е. Ямьсез түгел ул, чибәр.

Ш ү р ә л и я. Әллә күзең сукырайдымы? Шүрәле кызлары арасында чибәррәкләр юк идемени?

Ш ү р ә л е. Син миңа карамадың бит. Бармакларым кысылганны күреп тә көлеп кенә киттең. Кызганмадың да.

Ш ү р ә л и я. Җүләр Шүрәледән көләләр инде ул.

Ш ү р ә л е. Акыллылар көлми.

Ш ү р ә л и я. Илтеп куй бу кызны авылына.

Ш ү р ә л е. Мин аны авылдан алып килмәдем, үзе килде.

Ш ү р ә л и я. Алайса, куып җибәр.

Ш ү р ә л е. Нишләп әле боерык бирәсең?

Ш ү р ә л и я. Бирмим, әйтәм генә. Яратмыйм мин кешеләрне.

Ш ү р ә л е. Син яратмый дип, мин дә...

Ш ү р ә л и я. Явызлар алар. Беләсеңме, явызлар!

Ш ү р ә л е. Җәмилә андый түгел.

Ш ү р ә л и я. Барысы да бер, куып җибәр.

Ш ү р ә л е. Нигә боерасың? Кем булдың ул кадәрле?

Ш ү р ә л и я. Минем исемем Шүрәлия.

Ш ү р ә л е. Минеке – Шүрәле.

Ш ү р ә л и я. Ах, шаяртасың, егет. Шул шаяруың аркасында бармакларыңны кыстылар кешеләр. Муеның кысылганын телисеңме? Куып җибәр бу кызны һәм оныт. Начар булачак, җанкисәгем.

Җ ә м и л ә. Шүрәле, син кайда? *(Шүрәлене эзләп керә.)*

Ш ү р ә л и я. Менә ул, менә монда Шүрәле. *(Такмаклап.)*

Арттагы алга карый,
Алдагы артка карый;
Авыл егете карамагач,
Шүрәлеләр дә ярый.
Алларын алга манам,
Гөлләрен гөлгә манам;
Авыл егете алмагач,
Шүрәлегә дә барам.

Сау бул, Җәмилә. *(Боргаланып чыгып китә.)*

Җәмилә. Нигә ул алай?

Шүрәле. Шаяра ул. Шаяра гына ул...

Җәмилә. Шүрәлеләр дә шулай шаярамыни? Хуш, Шүрәле!

Шүрәле. Нигә хуш дисең, Җәмилә?

Җәмилә. Мин китәм инде.

Шүрәле. Кая?

Җәмилә. Авылыма.

Шүрәле. Китмә, Җәмилә. Ашыкма. Мин бит әле сиңа рәхмәтемне дә әйтмәдем.

Җәмилә. Әйттең, Шүрәле. Хуш!

Шүрәле. Җәмилә, мин бит сиңа Якты күлне дә күрсәтмәдем. Син аны күрергә тиеш. Аның якты суына карап үзеңнең йөзеңне күрергә тиеш.

Җәмилә. Ни өчен?

Шүрәле. Сере бар, Җәмилә. Тик аны хәзер әйтергә ярамый. Якты күлнең якты суына караганчы син ул серне белмәскә тиеш. Син курыкма, Җәмилә. Мин сиңа орынмам да. Мин синең янәшәңдә генә булырмын. Китмә син, Җәмилә. Телисеңме, мин сиңа бер кызык күрсәтәм? Тыңлап тор. *(Кулларын авызына куеп нидер пышылдый. Аның пышылдаганы кайтаваз булып яңгырый: «Мин яраттым сине, Җәмилә!»)*

Җәмилә. Кем ул?

Шүрәле. Кайтаваз. Ул минем сүзләремне кабатлый. *(Тагын пышылдый, кайтаваз тагын «Мин яраттым сине, Җәмилә!» дип кабатлый.)*

Җәмилә. Мин куркам, Шүрәле.

Шүрәле. Миннәнме?

Җәмилә. Синең серләреңнән. Мин кайтам. Озатып куй урманны чыкканчы.

Шүрәле. Мин синең җырларыңны отып алдым, Җәмилә.

Исәнме, җир генәм,
Исәнме, урманым.
Җырлале, урманым,
Сер тулы җырларың.

Нәсимә белән Рәсимә кереп, качып күзәтеп торалар.
Шүрәле җырын дәвам итә.

Исәнме, каеным,
Исәнме, миләшем.
Бул минем сердәшем,
Бир миңа киңәшең.

*(Җәмиләнең әкрен-әкрен чигенгәнен күреп.)* Китмә, Җәмилә. *(Җәмилә чыгып йөгергәч.)* Җәмилә, китмә! *(Артыннан йөгерә.)*

Нәсимә. Вәт монда эшлә-әр!.. Күрдеңме, Рәсимә?

Рәсимә. Күрдем дә, ишеттем дә.

Нәсимә. Менә сиңа Җәмилә. Ә без, җүләрләнгән, дибез. Ярый әле, артыннан килдек. Кызык күрми каласыбыз икән.

Рәсимә. Чын Шүрәле микән ул?

Нәсимә. Ничек инде чын булмасын?! Җәмилә үзе әйтеп тора ич Шүрәле дип.

Рәсимә. Үзенә тиң Шүрәлесен тапкан бит, ә?

Нәсимә. Шүрәледән башка кем карасын инде мескенгә?

Рәсимә. Алай димә, Нәсимә. Ишеттеңме ул Шүрәленең сүзләрен? Ишеттеңме, җырын?

Нәсимә. Безнең егетләр дә йөргән булалар. Шүрәле хәтле дә җырлый белмиләр. Шүрәленең сөйләвен тыңлаулары рәхәт. Минем арттан Рим йөргән була инде. Ник бер рәтле сүз белсен.

Рәсимә. Казаннан кайткан егетнең дә бар белгәне — короче, бабушка. Сөйгән егетең булсын иде дә, Шүрәле кебек матур итеп сөйләшсен иде.

Нәсимә. Әйтик мәллә Җәмиләгә, безгә дә шүрәлеләр табып бирсен.

Рәсимә. Кытыкласа нишләрсең?

Нәсимә. Исең киткән икән. Кытыкласа көләрбез.

Рәсимә. Кит инде, кит... Шүрәле белән...

Нәсимә. Бер ияләшкәнче генә ул. Әнә безнең күрше Нәҗибә апа дию пәрие белән тора әле. Дию пәриеннән дә болайрак, ди Нәҗибә апа. Кара син Җәмиләнең

Шүрәлесенә. Мин сиңа орынмам да, ди, янәшәңдә генә булырмын, ди.

Р ә с и м ә. Әй, орынмагач та нигә кирәкләре бар егетләрнең?

Н ә с и м ә. Алайса, нигә Казан егетеннән качасың соң? Ул орына бит.

Р ә с и м ә. Анысы инде бигрәк. Эләктереп алырга гына тора. Алай ук ярамый инде. *(Кинәт.)* Нәсимә! Карале, Нәсимә! Кемнәр ул?

Н ә с и м ә. Шүрәлеләр түгелме соң?

Р ә с и м ә. Шулар шул. Әйдә, качабыз.

Н ә с и м ә. Туктале. Нишләрләр икән?

Р ә с и м ә. Монда таба киләләр ич. Әйдә инде тизрәк! Киләләр ич, киләләр.

Н ә с и м ә. Килсәләр, исем китми әле. Әллә без Җәмиләдән кимме? Ияртәм дә кайтам авылга бер көтү шүрәле егетен, күрсен Рим кем артыннан йөргәнен. *(Алан уртасына чыгып.)* Әй, Шүрәле! Килегез әле монда.

Р ә с и м ә. Нишлисең син, җүләр?

Н ә с и м ә. Курыкма. Әнә тегесе сиңа, монысы — миңа.

Ш ү р и к белән Ш ү р к ә керәләр.
Кыяр-кыймас кына кызлар янына киләләр.

Ш ү р и к. Сез чакырдыгызмы?

Н ә с и м ә. Нәрсә-ә? Кем чакырган сезне.

Ш ү р и к. Безгә чакырган кебек тоелды.

Н ә с и м ә. Безгә чакырмаган кебек тоелды.

Ш ү р к ә. Шулаймыни?

Н ә с и м ә. Шулай шул.

Ш ү р и к. Нихәлләрдә сез?

Н ә с и м ә. Әйбәт әле без. Үзегез нихәлләрдә?

Ш ү р к ә. Үзебез әйбәт хәлләрдә. Сез әллә Җәмиләнең дусларымы?

Н ә с и м ә. Сез аны беләсезмени?

Ш ү р и к. Ул безнең дустыбызның дусты.

Ш ү р к ә. Ул безнең дустыбызның бармакларын бүрәнә ярыгыннан чыгарды.

Ш ү р и к. Сезнең исемнәрегез ничек?

Н ә с и м ә. Сезнеке ничек соң?

Ш ү р к ә. Без инде урман сарыклары.

Н ә с и м ә. Без — авыл кәҗәләре.

Шүрәлеләр көләләр.

Нигә көләсез?

Ш ү р к ә. Кәҗәләр болай булмый.
Н ә с и м ә. Сарыклар да болай булмый.
Ш ү р к ә. Син бик үткен кыз икән.
Н ә с и м ә. Сездән куркып тормыйм әле.
Ш ү р и к. Без куркытырга җыенмыйбыз да. Сез генә ул бер-берегезгә мылтыктан атып уйныйсыз.
Н ә с и м ә. Бик күпне беләсең, Шүрәле.
Ш ү р к ә. Мин – Шүрик, ул – Шүркә.
Н ә с и м ә. Сез әллә урыс шүрәлеләреме? Шурка, Шурик дисез.
Ш ү р к ә. Шурка да, Шурик та түгел, Шүркә дә Шүрик.
Н ә с и м ә. Без Нәсимә белән Рәсимә. Мин менә Нәсимә.
Ш ү р к ә. Дус кызыгыз нигә сөйләшми?
Н ә с и м ә. Ояла.
Ш ү р и к. Кеше кызлары да ояла беләмени? Безнең бабай әйтә: кеше кызлары күптән инде оятларын югалттылар, ди.
Н ә с и м ә. Бабагыз Шүрәле кызларын тикшерсен, ярыймы?!
Ш у р и к. Ярый, әйтермен.
Ш ү р к ә. Ә сез урманда нишләп йөрисез?
Н ә с и м ә. Сез нишләп йөрисез соң?
Ш у р и к. Урман – безнең йортыбыз. Әйтегез инде, нишләп йөрисез?
Р ә с и м ә. Сине эзләп йөрибез.
Ш ү р к ә *(шатланып)*. Ура-а-а! Ура-а-а!.. Рәсимәнең теле ачылды. Тавышыгыз бигрәк матур икән, Рәсимә.
Ш ү р и к. Нәсимәнең дә тавышы матур. Исемнәрегез дә матур: Нәсимә – Рәсимә. *(Көйли.)* Рәсимә – Нәсимә, Нәсимә дә Рәсимә, Рәсимә дә Нәсимә. Бик матур Рәсимә, бик чибәр кыз Нәсимә.
Н ә с и м ә. Ә Шүрәлеләрнең кызлары матурмы?
Ш ү р к ә. Матур. Шүрәле кызлары да матур.
Р ә с и м ә. Ярый, алайса, хушыгыз.
Ш ү р к ә *(Рәсимәнең юлына төшеп)*. Юк-юк, сез матуррак.
Р ә с и м ә. Ә син нигә болай ямьсез?
Ш ү р к ә. Әй, Рәсимә, Рәсимә... Күңелләремә тимә. Ямьсез Шүрәле шулай буламы? Карале син миңа әйбәтрәк итеп!

Р ә с и м ә. Әйбәтрәк итеп карасаң, әллә ни ямьсез дә түгел икән.

Ш ү р к ә. Һай, рәхмәт, Рәсимә. *(Аланнан бер чәчәк өзеп, Рәсимәгә суза.)* Танышуыбызның истәлеге булсын, Рәсимә.

Ш ү р и к *(шулай ук бер чәчәк өзеп, Нәсимәгә суза)*. Күрешүебез билгесе булсын, Нәсимә.

Н ә с и м ә. Кызык икән болар, әйеме, Рәсимә?

Ш ү р к ә б е л ә н Ш ү р и к.

Бер күрүдә гашыйк булдык сезләргә,
Рәсимә, Нәсимә.
Сезне күрми ничек итеп түзәргә,
Нәсимә, Рәсимә?
Ах, җаным, Рәсимә, вах, җаным, Нәсимә.
Балдан татлы әйткән һәрбер сүзегез,
Рәсимә, Нәсимә.
Сүзегездән гүзәлерәк үзегез,
Нәсимә, Рәсимә.
Ах, җаным, Рәсимә, вах, җаным, Нәсимә.

Нәсимә белән Рәсимә каршына тезләнәләр. Нәсимә белән Рәсимә көлешәләр.

Ш ү р и к. Сез дә әйтегез инде берәр сүз, Нәсимә, Рәсимә.

Н ә с и м ә. Без сүз әйтә белмибез.

Ш ү р к ә. Җыр җырлагыз.

Р ә с и м ә. Без җыр җырлый белмибез.

Ш ү р к ә. Нәрсә эшли беләсез?

Н ә с и м ә. Безме? Рәсимә, кил әле. *(Рәсимәне сәхнә алдына алып килә.)* Нишлибез? Бәйләнә бит болар. Эләксәң, котыла алмассың. Әйдә, яхшы чакта качыйк.

Р ә с и м ә. Туктале. Берәр нәрсә алып булмас микән болардан?

Н ә с и м ә. Шүрәленең нәрсәсе булсын?

Р ә с и м ә. Алай димә. Урманда байлык ничаклы…

Н ә с и м ә. Китик.

Р ә с и м ә. Син дә инде, башта, калыйк, дидең, инде, китик, дисең.

Н ә с и м ә. Китик. Беләсеңме нишлибез? Иртәгә Рим белән Исфанны алып киләбез. Болар белән очраштырабыз. Менә була әкәмәт.

Р ә с и м ә. Сугышсалар?

Н ә с и м ә. Сугышсалар соң... Казан егете сугыша беләдер әле. Бик әтәчләнеп йөри бит авылда.

Ш ү р и к белән Ш ү р к ә *(тезләре белән атлап кызлар янына киләләр)*. Безгә дә әйтегез инде сүзләрегезне.

Н ә с и м ә. Безнең сүзне ишетәсегез килсә, күзләрегезне йомып торыгыз. Унга хәтле санагыз.

Шүрәлеләр унга хәтле санаганда,
Р ә с и м ә белән Н ә с и м ә чыгып йөгерәләр.

Ш ү р и к. Унга хәтле санадык, күзләрне ачыйкмы? *(Җавап ишетелмәгәч.)* Ачыйкмы?

Ш ү р к ә *(күзләрен ачып)*. Киткәннәр.

Ш ү р и к *(күзләрен ачып)*. Ычкынганнар.

Ш ү р к ә. Менә ышан авыл кызларына.

Ш ү р и к. И-их, кызлары чибәр иде.

Ш ү р к ә. И-их, матурлар иде шул.

Ш ү р и к *(җыр сузып)*.

Их, кызлары, кызлары!
Таң нурыдай йөзләре!
Йөрәкләрне өтеп алды
Көлеп әйткән сүзләре.

Ш ү р к ә.
Их, кызлары, кызлары!
Керфекләре, күзләре!
Йөрәгемнең талпынганын
Нигә инде сизмәде?

И к ә ү б е р г ә.
Ах, кызлары, кызлары!
Атлап киткән эзләре!
Йөрәккәем, сабырлар ит,
Үзәгем, өзелмәле.

Ш ү р и к. И-и-их!

Ш ү р ә л и я белән Ш ү р ә л и н ә керәләр.

Ш ү р ә л и я. Нигә ихылдашасыз, ә?

Ш ү р и к. Ә? Нихәл, Шүрәлия?

Ш ү р к ә. Нихәлләрдә, Шүрәлинә?

Ш ү р ә л и я. Тегеләр кемнәр иде ул?

Ш ү р и к. Кемнәрне әйтәсең, Шүрәлия?

Ш ү р ә л и я. Сезнең яннан киттеләр...

Ш ү р к ә. Ә-ә-ә. Аларны әйтәсеңмени... Авыл кызлары.

Ш ү р ә л и я. Әллә сез тилердегезме барыгыз да?

Барысы да авыл кызы белән саташкан. Безне күрмиләр дә.

Шүркә. Күрәбез, Шүрәлинә. Без бит болай гына.

Шүрәлия. Ачуыбызны китермәгез. Без дә авыл егетләрен карата алабыз. Шулай бит, Шүрәлинә?

Шүрәлинә. Шулай, Шүрәлия.

Шүрәлия. Син карата алмыйсың инде, анысы, мин менә карата алам.

Шүркә. Бик мактанма инде.

Шүрәлия. Ышанмыйсыңмы?

Шүрәле керә. Ул беркемне дә, бернәрсәне дә күрми, алан буйлап мәхәббәт канатларында очып бара. Җырлаган җыры да сокландыргыч һәм үзәкләрне өзәрлек. Безнең «Авыл көе»н кемнән отып алгандыр?

Шүрәле. Урман эчләрендә урман,
Каен белән карама;
Янам синең утларыңда,
Ниләр табыйм дәвага?
Урман эчләрендә урман,
Кереп югалыйм микән?
Эчем яна, тышым яна –
Ничек юаныйм икән?

Шүрәлия. Мескен. Бөтенләй беткән бу. Әй, Шүрәле!

Шүрәле. Ә? Нәрсә?

Шүрәлия. Кил әле монда. Беләсеңме син нишләгәнеңне?

Шүрәле. Белмим. Мин бернәрсә дә белмим. Белергә дә теләмим.

Шүрәлия. Нинди җыр җырлаганыңны беләсеңме?

Шүрәле. Белмим. Белергә дә теләмим.

Шүрәлия. Син бит кешеләр җырын авыл көенә җырлап йөрисең.

Шүрәле. Минем кеше буласым килә!

Шүрәленең бу сүзенә барлык шүрәле ах итә.

Шүрәлия. Син нәрсә, бер ямьсез авыл кызы аркасында, шүрәле милләтенә хыянәт итәргә җыенасыңмы?

Шүрәлинә. Алай ярамый инде, Шүрәле.

Шүрик. Алай ук кирәкми инде, брат.

Шүркә. Алай килешми ич инде, ахир.

Ш ү р ә л и я. Китегез, сез барыгыз да сатлык.

Ш ү р ә л е. Гафу ит, Шүрәлия.

Ш ү р ә л и я. Гафу итмим. Китегез.

Ш ү р ә л е. Китәм, китәм. *(Китә башлый.)*

Ш ү р ә л и я. Ул якка түгел. Ул як — авыл ягы.

Ш ү р ә л е. Шулаймыни? Кайсы якка барырга соң миңа?

Ш ү р ә л и я. Менә бу якка. *(Шүрәле киткәч, Шүрик белән Шүркәгә.)* Сез дә аңардан калмагыз. *(Шүрик белән Шүркә киткәч.)* Бетәбез болай булса, бетәбез.

Ш ү р ә л и н ә. Карале, Шүрәлия, гашыйк булу шулай иттерәмени ул?

Ш ү р ә л и я. Ничек иттерә?

Ш ү р ә л и н ә. Шүрәле тилергән бит.

Ш ү р ә л и я. Элек тә акыллы түгел иде инде ул.

Ш ү р ә л и н ә. Карале, Шүрәлия, син гашыйк була беләсеңме?

Ш ү р ә л и я. Мин бөтенесен дә беләм.

Ш ү р ә л и н ә. Мине дә өйрәт әле, ә, Шүрәлия?!

Ш ү р ә л и я. Гашыйк булырлык Шүрәлесе дә юк аның урманында.

Ш ү р ә л и н ә. Авыл егетләрен каратабыз, дидең бит.

Ш ү р ә л и я. Аларны гашыйк булмыйча гына каратам мин. Көләр өчен генә.

Ш ү р ә л и н ә. Әйдә, каратыйк әле, ә?!

Ш ү р ә л и я. Нигә сикеренәсең?

Ш ү р ә л и н ә. Кызык бит. Их, Шүрәле кебек тилерсәң иде ул.

Урман эчләрендә урман,
Кереп югалыйм микән?

Ш ү р ә л и я. Нишлисең?

Ш ү р ә л и н ә. Тилереп карыйсым килде.

Ш ү р ә л и я. Чамалап кына кылан.

Ш ү р ә л и н ә. Авыл егетләрен ничек табабыз, Шүрәлия?

Ш ү р ә л и я. Кара, кара моны, шашты.

Ш ү р ә л и н ә. Үзең әйттең ич.

Ава-түнә килеп кергән Р и м н ы күреп алалар.

Ш ү р ә л и я. Әнә Шүрәлинә. Кил монда, тизрәк.

Аланда болганып йөргән Римне күзәтәләр.

Р и м. Әй! Кем бар монда? Нәсимә-ә!.. Исфа-ан! Рәсимә-ә? Нинди җир соң бу? Ишегалды дисәм, өй белән абзар юк. Әни-и!..

Ш ү р ә л и н ә. Әллә ул да гашыйк булганмы? Тилергән бит.

Ш ү р ә л и я. Тик кенә тор.

Р и м *(җырлап маташкан була).*

Сөембикә манарасы
Бишбалтага ауса иде;
Кабан күле спирт булып,
Күктән пилмән яуса иде.

Их, алмагачлары, их, алмагачлары, их, алмагачлары…

Әй! Кем бар монда! Нәси-мә-ә! *(Болгана-болгана Шүрәлияләр качкан агачка килеп таяна. Шүрәлияне күреп.)* Ә?.. Кем син?

Ш ү р ә л и я. Син кем?

Р и м. Туктале, тукта, тукта… Тукта… тукта…

Ш ү р ә л и я. Туктадым.

Р и м. Кем әле син?

Ш ү р ә л и я *(Шүрәлинәгә).* Бар әле, егетләрне чакыр әле.

Ш ү р ә л и н ә. Үзең генә курыкмыйсыңмы?

Ш ү р ә л и я. Шүрәлиянең кайчан курыкканы бар?

Ш ү р ә л и н ә китә.

Р и м. Ә? Кем минем белән сөйләшә?

Ш ү р ә л и я. Мин.

Р и м. Син кем?

Ш ү р ә л и я. Нәсимә.

Р и м. Ә? Синме Нәсимә?

Ш ү р ә л и я. Әллә танымыйсыңмы?

Р и м. Юу-ук, Нәсимә мондый түгел ул.

Ш ү р ә л и я. Нинди соң?

Р и м. Туктале. Кем соң син? Безнең бакчада нишләп йөрисең?

Ш ү р ә л и я. Бакчамыни бу?

Р и м. Агачлар булгач, нәрсә була соң? Туктале, тукта… Нигә син монда?..

Ш ү р ә л и я. Сине сагынып килдем.

Р и м. Мине? Тотылды ялганың. Нәсимә мине сагынмый. Ул мине яратмый. Аракы эчәсең, ди.

Шүрәлия. Нәрсә соң ул аракы?
Рим. Кем соң син, аракының да ни икәнен белмәгәч?
Шүрәлия. Мин — Шүрәлия.
Рим. Шүрәлия?.. Туктале, тукта... Нурания, Шәмсия, Шү-шү-шү...
Шүрәлия. Шүрәлия.
Рим. Кит әле, андый исем була димени?
Шүрәлия. Синең исемең ничек соң?
Рим. Әллә белмисеңме? Рим ич мин. Мине районда белмәгән кеше юк. Плотник. Знак качества белән, белдеңме? «Большевик» колхозыннан милиун сум аласым бар, белдеңме? Шабашник! Кем дидең әле исемеңне? Ша-ша-ша...
Шүрәлия. Шүрәлия...
Рим. Шүрә... Шүрәле... Әллә син Шүрәлеме?
Шүрәлия. Шүрәле.
Рим. Кит әле, кызлар кебек ич син.
Шүрәлия. Шүрәле кызы.
Рим. Кит әле, Шүрәленең кызы була димени?
Шүрәлия. Була шул менә.
Рим. Имиләрең дә юк ич синең.
Шүрәлия. Сиңа алар кирәкмени?
Рим. Кирәкме дип... Нишлим мин алар белән? Кызлар дисең ич.
Шүрәлия. Син егетме?
Рим. Егет булмый!.. Карале, Исфанны күрмәдеңме син?
Шүрәлия. Кем соң ул?
Рим. Казанныкы... Шәп егет. Карале, синдә берәр нәрсә юкмы, ә?
Шүрәлия. Нәрсә?
Рим. Баш авырта. Кая соң болар? Исфан да юк, Нәсимә дә юк, Рәсимә дә юк, Җәмилә дә юк.
Шүрәлия. Мин бар.
Рим. Кем соң син? Шүрәлеме әле син? Карале, баш чатный бит. Табыйк әле берәр нәрсә.
Шүрәлия. Әйдә минем белән.
Рим. Кая?
Шүрәлия. Башыңны дәвалыйбыз.
Рим. Үләм, давай тизрәк. *(Шүрәлиягә ияреп чыгып китә.)*

Йөгереп, Шүрәлинә керә.

Ш ү р ә л и н ә. Шүрәлия! Мин аларны таба алмадым. *(Шүрәлияне күрмәгәч.)* Шүрәлия, син кайда?.. Менә кызык... Шушында гына иделәр бит. Әллә Шүрәлияне урлап киткән инде авыл егете? *(Җылап.)* Хәзер мин нишлим инде берүзем? Миңа караучы да юк, мине яратучы да юк. Шүрәлиягә авыл егете бар, миңа Шүрәле дә юк. *(Күзләрен угалап үкереп җылап чыгып барганда, аланга килеп кергән Исфанның кочагына эләгә.)*

И с ф а н. Короче, бабушка!.. Что у тебя болит?

Ш ү р ә л и н ә *(айнып китеп)*. Ә? *(Исфанның кочагыннан ычкынмакчы була.)*

И с ф а н. Осторожно, бабушка.

Ш ү р ә л и н ә. Җибәр.

И с ф а н. Мин эләккәнне җибәрмим, бабушка.

Шүрәлинә аны бик җиңел генә күтәреп алып, җиргә сылый. Исфан аптырап кала.

Ты чё? Шаярганны аңламыйсың, что ли?

Ш ү р ә л и н ә. Син шаярдың гынамыни?

И с ф а н. Конешно, шаярдым.

Ш ү р ә л и н ә. Гафу ит.

И с ф а н *(Шүрәлинәгә төбәлебрәк карап)*. Ты чё?

Ш ү р ә л и н ә. Нәрсә?

И с ф а н. Син кеше түгел мәллә?

Ш ү р ә л и н ә. Түгел шул.

И с ф а н. Пәри, что ли?

Ш ү р ә л и н ә. Түгел.

И с ф а н. Җен?

Ш ү р ә л и н ә. Түгел. Мин – Шүрәле кызы Шүрәлинә.

И с ф а н. Шүрәле кызы? Интересно. Ә кем соң ул Шүрәле?

Ш ү р ә л и н ә. Шүрәле Шүрәле инде.

И с ф а н. Беренче тапкыр ишетәм.

Ш ү р ә л и н ә. Шүрәлене авылда бөтенесе белә.

И с ф а н. Мин авыл түгел. Мин Казанский. *(Шүрәлинәгә якын килми генә тирәсендә әйләнеп йөри.)* Интересно. Каратэ белән заниматься иттең, что ли? Как ловко мине атып бәрдең.

Ш ү р ә л и н ә. Без, шүрәлеләр, үзебезне яклый беләбез.

И с ф а н. Интересно. Берәр приём өйрәт миңа, ә?!

Ш ү р ә л и н ә. Нәрсә соң ул приём?

И с ф а н. Ну, көрәшергә өйрәт...

Ш ү р ә л и н ә. Ансат ич ул. *(Исфанның кулларыннан алып.)* Менә болай тотасың... *(Исфанның күзләренә карап катып кала.)*
И с ф а н. Ну, дальше, давай, ничек... Чё молчишь?
Ш ү р ә л и н ә. Мин аңламыйм. Син ни сөйлисең?
И с ф а н. Урысча белмисең, да?
Ш ү р ә л е. Нәрсә ул урысча?
И с ф а н. Вот деревня.
Ш ү р ә л и н ә. Нәрсә-ә-ә?
И с ф а н. Нәрсә торасың карап?
Ш ү р ә л и н ә. Күзләрең синең шундый...
И с ф а н. Ты чё?
Ш ү р ә л и н ә. Нәрсә-ә-ә?
И с ф а н. Вот даёт. Гашыйк булдың, что ли?
Ш ү р ә л и н ә. Күзләрең матур синең.
И с ф а н. Күз... күз... Ну, давай, раздевайся, что ли... Ну, чишен, чишен...
Ш ү р ә л и н ә. Ә нигә?
И с ф а н. Ну, интересно. Күз матур, дисең... Яратасың...
Ш ү р ә л и н ә. Яраткач чишенәләрмени?
И с ф а н. А как еще?.. Яраткач сразу чишенеп ташлыйлар.
Ш ү р ә л и н ә. Минем берәүне дә яратып караганым юк.
И с ф а н. Вот и өйрәнерсең. Минем дә Шүрәле кызы белән булганым юк. Интересно. Синең бу нәрсә, күлмәк, что ли, шундый?
Ш ү р ә л и н ә. Әйе...
И с ф а н. Замоклары да юк. Ә ул ничек салына?
Ш ү р ә л и н ә. Ул үзеннән-үзе салына.
И с ф а н. Салып күрсәт.
Ш ү р ә л и н ә. Безнең тәнне кояш күрергә тиеш түгел.
И с ф а н. Мин бит кояш түгел.
Ш ү р ә л и н ә. Кояш күктә. Ул бөтенесен дә күрә.
И с ф а н. Ну, әйдә агач арасына керәбез.
Ш ү р ә л и н ә. Кояш анда да күрә.
И с ф а н. Кояштан оялган кызны первый раз вижу. Казанда, наоборот, кояш чыккач кына чишенәләр.
Ш ү р ә л и н ә. Сез бит кешеләр.
И с ф а н. Какая разница? Син миңа даже күбрәк ошыйсың.

Ш ү р ә л и н ә. Чыннанмы?

И с ф а н. Чё миңа ялганларга? Фасад, конешно, не красавица. А фигура! Чишенеп тә күрсәтсәң!..

Ш ү р ә л и н ә. Ә син төнлә кил.

И с ф а н. Урманга, что ли? Здорово! Киләм! Валлаһи, киләм! Знаешь, Шүрәле кызы? Мин вообше оригинальныйларны яратам. Вот син мине атып бәрдең, да? И мин шунда ук уйладым — она моя. Аңлыйсыңмы минем ни әйткәнне? Төшенәсең, да? Фирштейн?

Ш ү р ә л и н ә. Фәрештәен.

И с ф а н. Здорово! Ах, үләм! *(Күккә карап.)* Ничек кенә тизрәк баетырга кояшны? А может, кояшта да ярыйдыр, ә? Ох, я бы тебя... Но куркам. Ну, дай хоть поцелую, а? Үбим, да?

Ш ү р ә л и н ә. Нәрсә ул «үбим»?

И с ф а н. Белмисең, да? Күрсәтергә, что-ли? Только син без приёмов, ладно? Ярыймы?

Ш ү р ә л и н ә. Ярый.

Үбешәләр. Шүрәлинәгә бу эш ошый.

И с ф а н. Здорово! Всё! Мин сиңа өйләнәм. А то әни — өйлән, өйлән. Вот и өйләнәм. Әти аңа ведьма, ди, вот мин дә аңа Шүрәле кызы алып кайтам. Только мин белмим — Шүрәле ул вроде леший, что-ли?

Ш ү р ә л и н ә. Әйдә, тагын үбешәбез.

И с ф а н. Ошады, да?

Үбешәләр. Башы-күзе тонган Ш ү р ә л е керә. Үбешүчеләргә килеп бәрелә. Ш ү р ә л и н ә чыгып чаба. Исфан Шүрәлегә карап чигенә.

Ты чё?

Ш ү р ә л е. Син?..

И с ф а н. Ну, мин?

Ш ү р ә л е. Син Җәмиләне беләсеңме?

И с ф а н. Ну, беләм!

Ш ү р ә л е. Мин — Шүрәле.

И с ф а н. Ну, мин — Исфан. Чё, драться, что ли, будешь?

Ш ү р ә л е. Нәрсә?

И с ф а н. Сугышырга, что ли, телисең?

Ш ү р ә л е. Мин Җәмиләне күрергә телим.

И с ф а н. Ну и шулай дип әйт.

Ш ү р ә л е. Табасың миңа аны, әйеме?

И с ф а н. Чё, гашыйк булдың, что ли?

Ш ү р ә л е. Әйе.

И с ф а н. Ну... Тоже мне тапкан. Телисеңме, мин сине Рәсимә белән таныштырам? Во девка!

Ш ү р ә л е. Миңа Җәмиләдән башка беркем кирәкми.

Урман эчләрендә урман,
Керсәм чыгалмам инде;
Сагынуларым чиктән ашты —
Күрми чыдамам инде.

Син беләсеңме, мин аны шушында очраттым. Ул минем бармакларымны иреккә чыгарды.

И с ф а н. Ну, влип, да? Гашыйк булдың, да? Ну, син кайгырма. Я всё тебе устрою. Мин Җәмиләләр авылында пока торам, беләсеңме? Бүген кил. Договоримся. Килештек. Мин булганда курыкма. Килештек?

Ш ү р ә л е. Килештек.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Авыл читендәге әрәмәлек. Җәйнең айлы төне. Җ ә м и л ә ялгызы. Утыргычка утырган да моңлана.

Ай янында якты йолдыз
Айга сөйли серләрен;
Ул айга сөйли серләрен,
Мин кемнәргә сөйләрмен?
Ай янында якты йолдыз —
Минем йолдызым гына;
Таң алдыннан ул да сүнә,
Калам ялгызым гына.

Н ә с и м ә белән Р ә с и м ә керәләр. Сүзсез генә икесе Җәмиләнең ике ягына утыралар. Җырга кушылалар.

Ай янында якты йолдыз
Янар да сүнәр инде;
Сүнгән йолдызлардан сүнәр
Көннәр дә килер инде.

Н ә с и м ә. Күңелсез.
Р ә с и м ә. Эч поша.
Н ә с и м ә. Көн саен, көн саен... Һаман шушы әрә-мәлек. Һаман без өчәү...
Р ә с и м ә. Һаман шул Рим. Бердәнбер Рим.
Н ә с и м ә. Анысы да айнымый.
Р ә с и м ә. Анысы да әле күренми. Казан егете дә юк.
Н ә с и м ә. Әллә урманда калдылар инде?
Р ә с и м ә. Калмагайлары. Икесеннән бер җүнле сүз ишетеп булмый. Күңел ачылмасмы дип ияреп урманга барган булдык, көн әрәм булды.
Н ә с и м ә. Җәмилә, син ник дәшмисең?
Җ ә м и л ә. Мин уйлыйм.
Р ә с и м ә. Нәрсә уйлыйсың?
Җ ә м и л ә. Әйтергә куркам.
Н ә с и м ә. Шүрәле турындадыр әле?
Р ә с и м ә. Карале, Нәсимә, чын булдылармы соң алар? Күзебезгә генә күренделәрме?
Н ә с и м ә. Чын булса ни дә, ялган булса ни? Шүрәле, ни әйтсәң дә, Шүрәле инде ул. Шүрәле көненә калырга язмасын инде.
Р ә с и м ә. Алай димә. Безнең авылда шундый егетләр булсын иде әле.
Н ә с и м ә. Андый егетләр безнең авылда түгел, бөтен Советлар Союзында юк инде ул.
Р ә с и м ә. СыСыСыР үзе дә юк инде.
Н ә с и м ә *(ләззәт белән көлеп)*. Ничек сөйләшәләр бит, тәмле итеп. Бик үк ямьсезләр дә түгел инде.
Р ә с и м ә. Төсе-бите нәрсәгә, татлы итеп сөйләшә белсен дә сиңа сокланып карасын ул. Әйдәгез иртәгә дә барып кайтыйк урманга.
Н ә с и м ә. Нишлисең инде анда?
Р ә с и м ә. Сөйләшеп кайтыйк бер матур итеп.
Н ә с и м ә. Сөйләш инде, Җәмилә.
Р ә с и м ә. Күңеле белән һаман да Шүрәлесен эзли.
Җ ә м и л ә. Һәр кешенең дә үз Шүрәлесе булырга тиеш.
Н ә с и м ә. Тиештер дә бит, юк менә.
Җ ә м и л ә. Эзли белеп эзләргә генә кирәктер.
Р ә с и м ә. Син эзли белеп эзләдең дә, таптыңмы соң?
Җ ә м и л ә. Таптым.
Н ә с и м ә. Кайда соң ул?

Җ ә м и л ә. Менә монда — күңелемдә.

Р ә с и м ә. Безгә шул хыялланып тилерү генә җитми инде. Тилереп акылдан шашарбыз да әле. Әллә инде бу Казан егетенә ияреп, Казанына китеп югалырга? Монда бит югалып та булмый.

Н ә с и м ә. Ичмасам, өчебезнең берсе егет булмаган. Икәүләп яратыр идек.

Р ә с и м ә. Беребездән беребез көнләшер идек.

Н ә с и м ә. Яңа Сала егетләре дә килми, ичмасам. Безнең авылда без барын белмиләр микәнни? *(Торып кычкыра.)* Әй, Яңа Сала егетләре! Килегез безнең авылга! Без әрәмәлектә сезне көтеп утырабыз.

Җ ә м и л ә. Ярый, сау булыгыз, кызлар.

Р ә с и м ә. Китмә инде, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Китәм инде. *(Китә.)*

Н ә с и м ә *(җырлап).*

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кайталмам инде, шул,
Китсәм кайталмам инде;
Сынды сабыр канатларым —
Сабыр италмам инде.

Р ә с и м ә. Нәсимә, нәрсә ул анда таллар арасында күренә?

Н ә с и м ә. Кайда?

Р ә с и м ә. Әнә ич, әнә! Поскан.

Н ә с и м ә. Шүрәле ич ул, Рәсимә.

Р ә с и м ә. Әйдә, йөгерәбез.

Н ә с и м ә. Йөгерәм ди менә! Килсен дә алып китсен. Кил монда, Шүрәле, кил.

Ш ү р и к *(күренеп).* Мин — Шүрик. Исәнмесез!

Н ә с и м ә. Шүрик... Бәгырькәем, Шүрик! Нигә анда торасың? Кил безнең янга.

Ш ү р и к. Шүркә дә монда.

Н ә с и м ә. Нигә ул күренми?

Ш ү р и к. Ояла.

Н ә с и м ә. Урманда оялмадыгыз ич.

Ш ү р и к. Урман бит ул безнеке, әрәмәлек — сезнеке.

Н ә с и м ә. Оялмагыз инде, килегез монда. Ояла торган заманмы.

Ш ү р и к. Шүркә, әйдә.

Ш ү р к ә дә таллар арасыннан чыга. Икәүләп кызлар янына киләләр. Икесе дә берәр кочак чәчәк күтәргән.

Ш ү р к ә. Исәнмесез! Исәнмесез, Рәсимә! *(Чәчәкләрне Рәсимә алдына куя.)*

Р ә с и м ә. Исәнме!

Ш ү р и к. Сез нигә качтыгыз бездән, Нәсимә?

Н ә с и м ә. Тапкансыз бит әле качсак та.

Ш ү р и к. Мин синең тавышыңны ишеттем. Син җырладың.

Н ә с и м ә. Матур җырлыйммы соң мин?

Ш ү р и к. Бик матур.

Р ә с и м ә. Чәчәк белән хәзер дөнья тулган. Җиләк алып килергә иде безгә.

Ш ү р к ә. Җиләк бит ул ашый торган нәрсә.

Р ә с и м ә. Чәчәк ашарга да ярамый.

Ш ү р к ә. Ничек инде?.. Ярый, иртәгә җиләк җыеп килербез.

Р ә с и м ә. Күп итеп, бик күп итеп.

Н ә с и м ә. Нигә шулай карап торасың, Шүрик?

Ш ү р и к. Син чөнки бик матур.

Н ә с и м ә. Бик, бик матурмы?

Ш ү р и к. Бик, бик матур.

Н ә с и м ә. Нишлибез инде хәзер, Шүрик белән Шүркә?

Ш ү р и к. Ә без сезгә шигырь чыгардык.

Н ә с и м ә. Шигырь? Нәрсәгә ул?

Ш ү р и к. Ничек нәрсәгә? Без чыгардык. Шүркә белән ярыша-ярыша чыгардык. Мин сиңа чыгардым, Шүркә Рәсимәгә чыгарды. Укып күрсәтимме?

Н ә с и м ә. Чыгаргач укыгыз инде.

Ш ү р и к. Шүркә, башта син укы.

Ш ү р к ә. Син укы.

Ш ү р и к. Каеннарның алгансың син аклыгын,
Чык тамчысының алгансың пакьлеген.
Зәңгәр чәчәкнең төсләре күзеңдә,
Алсу чәчәк алсулыгы йөзеңдә.
Юкәләрнең зифалыгы буеңда,
Кашларыңның каралыгы муелдан.
Иреннәрең пешкән каен җиләге —
Син бу җирнең иң гүзәле, чибәре.

Н ә с и м ә. Беттеме?.. «Муел» нәрсә соң ул?

Ш ү р и к. Башкортча ул. «Шомырт» дигән сүз. Башкорт шүрәлеләреннән өйрәндем.

Нәсимә. Инде Шүркәнекен тыңлап карыйк.
Шүркә *(Рәсимәгә карап укый).*

Күзләреңдә кара төннең карасы —
Уф, йөрәгем! Кайдан дәва табасы?
Ай кызының көянтәсе — кашларың —
Уф, йөрәгем! Әйләнәдер башларым.
Йолдызларның җемелдәве — тешләрең —
Уф, йөрәгем! Күрми торсам нишләрмен?
Йөзләреңдә балкып уйный ай нуры —
Син бу җирнең иң гүзәле, матуры.

Шүрик. Ник сөенмисең?
Рәсимә. Нигә сөеник ди?
Шүркә. Без бит шигырь укыдык.
Нәсимә. Укысагыз ни булган?
Шүрик. Без аны ярыша-ярыша яздык.
Рәсимә. Язсагыз... Эшегез юктыр.
Шүркә. Шигырьне бит аны эш булмаганнан язмыйлар.
Нәсимә. Ни өчен язалар соң?
Шүрик. Бүтәннәр укып соклансын өчен. Сезнең шигырь чыгарып караганыгыз бармы?
Рәсимә. Менә шул шигырь чыгарып ятарга гына калды. Бик кирәге бар.
Шүркә. Кызык түгел икән тормышыгыз, алайса.
Нәсимә. Кызык түгел, кызык түгел. Синнән башка белмиләр ди. Торма әле каршымда сураеп, Шүрәле башың белән акыл өйрәтеп. Чакырып китердек мәллә?
Шүркә. Гафу итегез, кәефсез чагыгызга туры килдек, ахры.
Нәсимә. Сез урысча беләсезме?
Шүрик. Урысча? Нәрсә соң ул «урысча»?
Нәсимә. Ярый, белмәсәгез, бик яхшы. *(Рәсимәгә.)* Шту будем делать болар белән?
Рәсимә. Ни знаю.
Нәсимә. Вчера ничава күренгәннәр иде, сигудня ни красивыйлар.
Рәсимә. Бижать будем.
Шүрик. Һай, сез шундый кызык сөйләшәсез.
Нәсимә. Интересныймы? Безгә ни интересный шул. Кызык түгел, белдеңме?
Шүрик. Кызык булсын өчен без нәрсә эшлик, Нәсимә?

Р ә с и м ә. Я знаю что дилать болар белән. Яңа Сала пайдюм. Клуб зайдюм. Боларны покажем.

Икәүләп көләләр.

Ш ү р к ә. Кызыкмы?

Н ә с и м ә. Бик кызык.

Ш ү р и к. Безгә дә әйтегез, без дә көлик.

Н ә с и м ә. Безнең белән барасызмы?

Ш ү р к ә. Кая?

Р ә с и м ә. Әнә тегендә Яңа Сала дигән авыл бар. Шунда...

Ш ү р и к. Нигә анда барабыз?

Р ә с и м ә. Клубка. Биергә.

Ш ү р к ә. Ә нәрсә ул клуб?

Н ә с и м ә. Надан. Өй кебек нәрсә инде.

Ш ү р и к. Биер өчен нигә өйгә керергә? Монда яхшырак. Монда иркен.

Р ә с и м ә. Нәрсә, бармыйсыңмыни? Алайса, китегез урманыгызга.

Ш ү р и к. Рәсимә, син бик матур кыз. Син нигә алай усал сөйләшәсең?

Р ә с и м ә. Әллә каршыңда биеп торыйммы?

Ш ү р к ә. Юк, кызык түгел сезнең белән.

Н ә с и м ә. Вәт бәйләнде! Нинди кызык кирәк сиңа? Мә менә, кызык күрәсең килсә... *(Такмак әйтеп тыпырдый.)*

Бас, кызым, Әпипә...
Бас, кызым, Әпипә...
Бас, кызым, Әпипә...
Бас, кызым, Әпипә...

Кызыкмы?

Ш ү р к ә. Бу да кызык түгел. Ачу белән биегән бию кызык түгел.

Н ә с и м ә. Вәт бәйләнде Шүрәле тәре. Бик кызык кирәк булса, үзең кызык яса.

Ш ү р и к. Әйдәгез безнең белән урманга.

Р ә с и м ә. Урманда безгә кызык ясарга җыенасызмы?

Ш ү р к ә. Әйе. Беләсеңме, айлы төндә урман ничек матур! Ай нуры, агач яфраклары арасыннан үтеп, аландагы чәчәкләргә куна. Юкә чәчәкләреннән бал исе килә. Төн кошлары, ай нурларына коенып, үзләренең көйләрен көйлиләр. Аларның моңлы көйләре җанны иркәли.

Күңелдә матурлык туа. Синең дә кошларга кушылып җырлап җибәрәсең килә.

Н ә с и м ә. Алайса, сез Җәмиләне алып китегез инде урманыгызга. Ул да сезнең сыманрак.

Р ә с и м ә. Җәмилә дигәннән, нигә аның Шүрәлесе күренми?

Ш ү р и к. Ул Якты күлдән төнбоеклар җыя калды. Әйдәгез, без сезне Якты күл янына алып барабыз.

Н ә с и м ә. Пайдюм, шту ли, Рәсимә?

Р ә с и м ә. Ни нады. Боларга ышанып... Юк инде, шүрәлеләр, үзегез генә кайтыгыз урманыгызга. Безнең иртүк торып сыер савасы да бар. Иртәгә килегез, җиләк җыеп килегез.

Ш ү р к ә. Шүрәлеләр бер китсәләр, икенче килмиләр, Рәсимә.

Н ә с и м ә. Килмәсәгез тагын.

Ш ү р и к. Ярый инде, алай булгач. Хушыгыз.

Н ә с и м ә. Хушыгыз. *(Шүрәлеләр башларын иеп чыгып киткәч.)* Йөриләр йөрәккә тоз салып. Кызык түгел, ди. Сиңа яхшы урманда, син – Шүрик. Менә шушы ун өйле авылда яшәп кара. Әйдә, кайтабыз.

Р ә с и м ә. Бу чәчәкләрне нишләтәбез?

Н ә с и м ә *(чәчәк бәйләмен тибеп очырып)*. Чукынып китсен чәчәкләре. Күреп туйган. Кайда йөри соң бу Рим? Исерек тәре. Тегесе кайда? Иртәгә яныма килмәс микән ялманып?

Р ә с и м ә. Шүрәлесенә кадәр... Мыскыл иткән булалар бит.

Н ә с и м ә. Аларның гаебе дә юк инде, бер уйласаң.

Р ә с и м ә. Юк инде, анысы...

Н ә с и м ә. Ну, урысча сөйләшеп кызык иттек үзләрен.

Р ә с и м ә. Авызларын ачып торалар.

Көлешәләр.

Н ә с и м ә. Болай ямьсез дә түгел кебек алар үзләре.

Р ә с и м ә. Шигырь язган булганнар бит.

Н ә с и м ә. Язганнары болай әйбәт, әйеме?

Р ә с и м ә. Арттырганнар инде.

Н ә с и м ә. Арттырмагач, шигырь булмый инде ул. Ияреп китәсе калган.

Р ә с и м ә. Әллә нишләтмәгәннәр булыр иде әле.

Н ә с и м ә. Нишләтсәләр нәрсә була? Барыбер бер исерек нишләтә инде.

Р ә с и м ә. Чәчәк җыйган булганнар. *(Чәчәк бәйләмен кулына алып.)* Карале, безнең болында юк бит мондыйлар. Карале, карале, нindиләр... Яле, синекен дә карыйк әле.

Н ә с и м ә *(тибеп очырган чәчәген алып килеп).* Минеке матуррак.

Р ә с и м ә. Минеке дә матур.

Н ә с и м ә. Исләре нинди!.. Менә иснәп карале. *(Чәчәк бәйләмнәрен иснәп туйгач.)* Җүләрләр, китәсе калган. Әллә чакырабызмы?

Р ә с и м ә. Әй, ялынып йөргән кебек була.

Н ә с и м ә. Әнә алар. Әнә Кәҗә тавында басып торалар. Әйдә күренмичә генә яннарына барыйк әле, ни сөйләшәләр икән?

Р ә с и м ә. Әй...

Н ә с и м ә. Әйдә инде... *(Рәсимәне җитәкләп алып чыгып китә.)*

Бер кулына төнбоеклар көлтәсе тотып, иңбашына Римны салып, Ш ү р ә л е керә. Римны утыргычка утырта, үзе дә утыра. Көчкә сулыш ала.

Р и м *(уфылдап).* Рәт бетте минем, малай. Башка эчтем юк. Ярый әле син очрадың. Беткән идем бит. Күп эчелгән.

Ш ү р ә л е. Нәрсә эчеп шулай булдың?

Р и м. Һәй, әйтмә инде. Уф... Шул аракы инде. Ярый әле син булдың. Теге шүрәле хатыны мине бөтен урман буенча йөртте. Бөтен звирләргә күрсәтеп чыкты... Менә, күрегез, ди... Эчсәгез, сез дә шулай буласыз, ди. Аннары урман кырыена алып чыгып ыргытты да үзе югалды. Ярый әле син...

Ш ү р ә л е. Менә шунда ятып ял ит.

Р и м. Юк, өйгә илтеп куй инде син, малай. Рәт юк. Әнинең яшереп куйган бер яртысы бар бугай...

Ш ү р ә л е. Тагын эчәсеңме?

Р и м. Эчмичә булмый, малай. Ату үләм. Ярый син булдың. Шүрәле дигәнгә ышанмый идем, бар икән бит, әй. Коткардың.

Ш ү р ә л е. Җәмиләләрнең өе кайда?

Р и м. Җәмилә? Нинди Җәмилә? Ә-ә-ә... Син аны беләсеңмени? Әллә... Ярый, ярый, бер сүз әйтмим. Ә-әнә аларның өе, ә-нә... Башта син мине илтеп куй, ярыймы?

Тик өйгә кермә, әнинең куркып үлүе бар. Куеп тор инде ул чәчәкләреңне, кем тия аңа? Килерсең дә алырсың.

Ш ү р ә л е, төнбоекларны утыргычта калдырып, Р и м н ы күтәрә дә чыгып китә. Җәмилә йөгереп керә, ул киткән якка карый. Чәчәкләргә иелә. Аларны күкрәгенә кыса, утыргычка таратып җибәрә. Карап соклана. Үзе дә сизмәстән, Шүрәленең җырын кабатлый.

Җ ә м и л ә. Урман эчләрендә урман,
Каен белән карама;
Янам синең утларыңда,
Ниләр табыйм дәвага?

*(Шүрәленең килгәнен күреп кача.)*

Ш ү р ә л е керә. Төнбоекларны ала. Китәргә җыена да туктап утыра.

Ш ү р ә л е. Чакырсам, чыгар микән? Ничек чакырыйм икән? Тавышымнан таныр микән? Сүз әйтеп чакырыйм микән, җыр җырлап чакырыйм микән?

Дөнья гизеп килдем сине эзләп,
Кайда син, Җәмилә?
Сумакларда калган синең эзләр —
Үзең юк, Җәмилә.
Йолдызлардан сорап карыйм микән,
Кайда син, Җәмилә?
Йөзләреңнең нуры айга күчкән —
Үзең юк, Җәмилә.
Соң килдемме әллә, соңладыммы,
Кайда син, Җәмилә?
Сандугачлар җырлый җырларыңны —
Үзең юк, Җәмилә.
Ишетер микән җырымны? *(Төнбоекларны кочаклап.)* Таныр микән җырымны? Аңлар микән ниләр уйлап килгәнемне? *(Чыгып китә.)*

Җ ә м и л ә *(яшеренгән җиреннән чыгып)*. Шүрәле!.. Мин монда, Шүрәле.

Ш ү р ә л е йөгереп керә. Җәмиләне күтәреп алырга дип кулларын суза да туктап кала. Бары тик «Җәмилә!» дип кенә әйтә ала.

Җ ә м и л ә. Шүрәле!..

Ш ү р ә л е. Җәмилә!..

Җ ә м и л ә. Шүрәле…

Ш ү р ә л е. Мин сине эзләп таптым, Җәмилә!

Җ ә м и л ә. Мин дә сине көттем, Шүрәле!

Ш ү р ә л е. Чынлап әйтәсеңме, Җәмилә?

Җ ә м и л ә. Мин алдаша белмим, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Сиңа сөйләргә дип бик күп, бик күп матур сүзләр уйлап килдем, Җәмилә. Сине күрдем дә оныттым.

Җ ә м и л ә. Берсен генә булса да исеңә төшер, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Мин яратам сине, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Бу бит инде бик күп әйтелеп, таушалып беткән сүз, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Аны кешеләр таушалтып бетергән, Җәмилә. Безнең өчен ул иң изге, иң кадерле сүз.

Җ ә м и л ә. Шүрәле…

Ш ү р ә л е *(җиргә сибелгән төнбоекларны җыеп)*. Болар сиңа, Җәмилә. Якты күл чәчәкләре.

Җ ә м и л ә. Рәхмәт, Шүрәле. Алар шундый матур.

Ш ү р ә л е. Син гүзәлрәк, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Нигә алар бик күп?

Ш ү р ә л е. Аларның һәрберсендә сиңа әйтәсе меӊ сүзем бар, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Син ул сүзләрне әйт.

Ш ү р ә л е. Төнбоекларны тыңла, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Син кешеләр эшли алмаганны эшли аласыңмы?

Ш ү р ә л е. Нинди эш ул, Җәмилә?

Җ ә м и л ә. Алып барып кайт мине йолдызлар иленә. Киек Каз Юлы буйлап үтәсем килә. Йолдызларга ятып ял итәсем килә.

Ш ү р ә л е. Йолдызларга якын барырга ярамый.

Җ ә м и л ә. Нигә, Шүрәле?

Ш ү р ә л е. Чөнки серләре ачыла.

Җ ә м и л ә. Минем ул серләрне ачасым килә.

Ш ү р ә л е. Кирәкми, Җәмилә. Ачылган сер кызык түгел. Әгәр дә бөтен серләр дә ачылса, җирдә яшәве бик күңелсез булыр иде.

Җ ә м и л ә. Сөйлә, Шүрәле, сөйлә, туктама.

Ш ү р ә л е. Сез, кешеләр, дөньяның серләрен ача-ача, җирне үзегез яши алмаслык иттегез. Инде йолдызларга үреләсез. Син җир өстенә күзләреңне тутырып кара, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Шүрәле, ә син бармы?

Ш ү р ә л е. Ничек инде «бармы»?

Җ ә м и л ә. Бәлки, син юктырсың? Мин үзем белән үзем сөйләшәмдер. Шүрәлеләр күренеп йөрмиләр бит.

Ш ү р ә л е. Күрә белгәннәргә күренәләр.

Җ ә м и л ә. Мин менә күрәм. Мин бәхетле, әйеме, Шүрәле?

Ш ү р ә л е. Мин бәхетлерәк, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Ни өчен, Шүрәле?

Ш ү р ә л е. Кешеләрдән өметемне өзгән идем, син очрадың, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Миңа син очрадың.

Ш ү р ә л е. Әйдә киттек, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Кая?

Ш ү р ә л е. Син серләр яратасың. Якты күлне күрсәтәм.

Җ ә м и л ә. Ул серлеме? Мин ул серләрдән куркам да, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Янында мин бар, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Ә син мине яклый аласыңмы?

Ш ү р ә л е. Шүрәлеләр кешеләр түгел, көчсезләрне яклый беләләр.

Җ ә м и л ә. Нигә, алайса, бармагыңны кысканда, үзеңне яклый алмадың?

Ш ү р ә л е. Мине алдадылар. Ә шүрәлеләр алдаша белми. Без — табигать балалары. Табигатьнең серләре күп булса да, хәйләсе юк.

Җ ә м и л ә. Без дә табигать балалары.

Ш ү р ә л е. Ләкин сез аны оныткансыз. Әнисенең кем икәнен оныткан бала явыз була.

Җ ә м и л ә. Син әллә ниләр беләсең, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Янымда син булганга шулай ул, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Син янымда булгач, миңа да рәхәт.

Ш ү р ә л е. Киттек, Җәмилә.

Җ ә м и л ә. Киттек, Шүрәле. Теләсәң кая алып бар. Мин ышанам сиңа, Шүрәле.

Чыгып китәләр. И с ф а н, кереп, алар артыннан карап кала.

И с ф а н. Во даёт Җәмилә!.. Давай, давай, Шурале, шуруй... Кайда соң болар, берсе дә күренми? Хитрый бу авыл кызлары. Сами лезут и ускользают. Бер ай җөрим, и никакого результата. Казанда булса... Бу алкаш та

күренми. Урманга, что ли, китәргә? Опасно одному. Всё-таки Шүрәле. Но хочется. Экзотика. Так... Маржа белән гулял, татарка белән йөрдем, марийка белән тоже, молдаванка белән дә... Шүрәле кызы — интересно.

Шурали, Шурали, Шуралеечка,
Шуралеечка жалобно поёт.
Раз поёт, два поёт, три поёт.
Шуралеечка жалобно поёт.

*(Римның җырын ишетеп, туктап тыңлый.)* Появился солист. *(Ике бармагын авызына тыгып сызгыра.)*

Р и м *(кереп).* А-а-а, ахир! Кайда югалдың син, ә?

И с ф а н. Мин югалмадым, син югалдың.

Р и м. Мин күргәннәрне сөйләсәң, малай! Сөйлимме?

И с ф а н. Только не ври, ладно?

Р и м. Кайчан яңгаллаганым бар? Ну, малай! Сөйләсәң...

И с ф а н. Ну, рассказывай инде...

Р и м. Әле болай белеп бетермим, төш булдымы ул, өн булдымы. Күземне ачып җибәрсәм, малай, — Шүрәле кызы! Күрсәң, малай, Нәсимәдән ямьсезрәк, Җәмиләдән чибәррәк. Син аны күрсәң ябыша идең, валлаһи. Ә минем пахмил, Шүрәлене түгел, үземне күрәсем килми. Мин әйтәм Шүрәле кызына, баш авырта, дим. Төзәтәм башыңны, ди. Шуннан алып китте каядыр, әйеме? Барып кердек бер чытырманлыкка. Анда — шүрәле көтүе. Шунда Шүрәле кызы нишли дисең инде? Мине уртага алып кереп бастырды бу. Бөтен шүрәлеләргә карап әйтә. Менә, карагыз, бу — кеше дип атала торган нәрсә, ди. Беләбез, диләр шүрәлеләр. Юк, белмисез, ди Шүрәле кызы, сез кешеләрне әйбәт дип уйлыйсыз, ди. Кешедән дә әшәке җан иясе юк, ди. Карагыз моның кыяфәтенә, ди. Моңарга карап төкерергә дә җирәнгеч бит, ди. Валлаһи, шулай ди, малай. Шуннан әйтә бу, ә безнең кайбер егетләребез кеше кызларына ияреп йөри башлаганнар, ди. Әгәр дә болай булса, бетәбез бит, ди. Кешеләр безне бетерәчәкләр, ди. Айнып китә яздым, малай. Куркуга төштем. Изәләр, мин әйтәм, болар мине. Ярый әле тимәделәр. Шуннан Шүрәле кызы мине бөтен звирләргә күрсәтеп чыкты.

И с ф а н. Белая горячка ул синең.

Р и м. Юк. Белая горячка булса, җен күрәсең ул.

Ә бу – шүрәлеләр. Шуннан Шүрәле кызы мине урман кырыена чыгарып ташлады.

Исфан. Күтәреп, что ли?

Рим. Күтәреп түгел инде, сөйрәп йөртте. Күтәреп мине авылга Шүрәле алып кайтты. Җәмиләне эзләп килгән. Мине өйгә үк кайтарып куйды. Ярый әле әнинең яшереп куйган бер яртысы булган, үлә идем, малай. Хәзер ничава инде, төзәткәч. Карале, малай, ул шүрәлеләр төш булды микән, өн булды микән?

Исфан. Чё я те психиатр, что ли? Фигурасы как?..

Рим. Ничек «как»?

Исфан. Фигурасы ничек Шүрәле кызының?

Рим. Фигура күрерлекмени минем рәт...

Исфан. Вот мин сиңа әйтәм. Күп эчмә. Күп эчсәң, импотент буласың.

Рим. Нәрсә соң ул импотент, малай?

Исфан. Ну, как те сказать... Ну, кызларның фигурасын күрми башлыйсың. Өйләнсәң, хатының аерылып китә.

Рим. Ә мин өйләнмим. Юк, син миңа әйт, Шүрәле кызы чынмы?

Исфан. Чын, конешно.

Рим. Чын?

Исфан. Но синең белая горячка да булырга может.

Рим. Син нәрсә, мин алкаш түгел ич.

Исфан. Кем соң?

Рим. Шүрәле кызы чын дисең инде? Син аны күрсәң, Исфан дус...

Исфан. Чё миңа аны күрергә? Мин шунда барам.

Рим. Кая?

Исфан. Урманга.

Рим. Ничек урманга?

Исфан. Свиданиегә. Шүрәле кызы белән. Понял?

Рим. Кит әле, көлмәле миннән.

Исфан. Нигә мин көлим? Син күргәнсең бит Шүрәле кызын. И я видел.

Рим. Кит әле...

Исфан. Вот те на... Әйтеп торалар. Твоя как? Биекме иде?

Рим. Ничек биекме?

Исфан. Ну, высокая, что ли, была?.. Шүрәле кызы?

Рим. Кем күргән инде аны. Әйтәм ич... Ну, ярыйсы инде болай...

И с ф а н. А моя... Конфетка... Личико, конешно, так себе... А фигура...

Р и м. Ул сине чакырдымы?

И с ф а н. Ну, свидание. Көтәм, диде. Беләсеңме, алар төнлә генә күлмәкләрен салалар. Кояш противопоказан, ди. Интересно, да, төнлә.

Р и м. Курыкмыйсыңмы?

И с ф а н. Кемнән?

Р и м. Урманнан.

И с ф а н. Чё урманнан куркырга? Мин Казанда йөрергә дә курыкмыйм әле.

Р и м. Мин курыктым, малай. Кара, синең бернәрсә дә юктыр инде, ә?

И с ф а н. Нәрсә?

Р и м. Куркуны басарга.

И с ф а н. Чё сиңа басарга?.. Урманга бармыйсың ич.

Р и м. Пахмил чыгып бетмәгән.

И с ф а н. Не пей, дурачок. Импотент будешь. Вот миннән өйрән. Максимум ике рюмка. Для смелости. Аңладыңмы?

Р и м. Аңлавын аңлыйм мин аның да. Мине дә алып бар, ә, Исфан дус?!

И с ф а н. Урманга, што ли? Чё, карап торасың килә, что ли?

Р и м. Өйгә кайтасы килми. Әни тагын сүгә. Әтиең эчеп үлде, ди. Инде син, ди.

И с ф а н. Вот и эчмә. Ну, әйдә. Только якын килмә. Аңладыңмы?.. Син сандугач кебек сайрый беләсеңме?

Р и м. Нигә?

И с ф а н. Шүрәле кызы әйтте, сандугач кебек сайрарсың, и мин килермен, диде.

Р и м. Әнә бит сандугач сайрый, өйрән.

И с ф а н *(сандугач сайравын тыңлап)*. Ну разве болай була...

Р и м. Була. *(Сандугач булып сайрап күрсәтә.)*

И с ф а н. Ну-у!.. Ты же гений!

Р и м. Нәрсәсе бар аның?..

И с ф ан. Киттек. *(Китәләр. Кинәт туктап.)* Стоп!

Р и м. Нәрсә?..

И с ф а н. Молчи... Кил монда. *(Куаклар артына яшеренәләр.)* Вот смотри.

Р и м. Бернәрсә дә күрмим.

И с ф а н. Точно бернәрсә дә күрмисеңме? Ну, они же!
Р и м. Кемнәр?
И с ф а н. Кач! *(Яшеренәләр.)*

Кача-поса, Ш ү р ә л и я белән Ш ү р ә л и н ә үтеп китәләр.

Р и м. Теге... Теге ич бу. Нишләп йөриләр алар монда?
И с ф а н. Сине эзлиләр. Вот поймают тебя и будут кастрировать.
Р и м. Йә инде...
И с ф а н. Әйдә за ними!
Р и м. Ю-у-ук.
И с ф а н. Их син, куркак! Берсе, беләсеңме, которая пониже — моя. Давай, син үзеңнекен лови, мин свою. Әйдә.
Р и м. Юк. Үтерсәң дә бармыйм.
И с ф а н. Пойми. Нельзя упускать, импотент несчастный. Пойми, их надо разлучать. Аерырга кирәк, беләсеңме?
Р и м. Икесе дә сиңа булсын.
И с ф а н. Ты чё, одурел... Так... Ну, ладно. Рим, ну, давай! Курыкма. Без икәү.
Р и м. Ул көчле.
И с ф а н. Минеке дә. Приёмы знает... Ну, знаешь, көчлене җиңү интересно. Чё со слабыми көрәшергә?
Р и м. Киттеләр инде алар.
И с ф а н. Чё ты! Урман — анда... Вот они, вот. Монда киләләр.

Р и м чыгып шыла. Ш ү р ә л и я белән Ш ү р ә л и н ә керәләр.

И с ф а н *(төче елмаеп исәнләшә).* Исәнмесез, кызлар!

Шүрәлинәнең шатлыгы йөзендә балкый, Шүрәлиянең ачуы чыккан.

Ш ү р ә л и я. Безнең егетләр кайда?
И с ф а н. Вот мин егет.
Ш ү р ә л и я. Безнең егетләр, шүрәле егетләре кайда?
И с ф а н. Ә мин белмим. Утырыгыз, кызлар.
Ш ү р ә л и я. Кызларыгыз кайда?
И с ф а н. Нинди кызлар? Бездә кызлар юк.
Ш ү р ә л и я. Рәсимә, Нәсимә, Җәмилә кайда?
И с ф а н. Ә-ә-ә, алар. Ә мин алар белән... Шүрәлинә...

Ш ү р ә л и я *(Исфанга тартылган Шүрәлинәне туктатып)*. Нишлисең син?

Ш ү р ә л и н ә. Мин аны яратам.

Ш ү р ә л и я. Ничек яратасың? Син аны беләсеңмени?

Ш ү р ә л и н ә. Без урманда үбештек.

Ш ү р ә л и я. Нишләдегез?

Ш ү р ә л и н ә. Үбештек.

Ш ү р ә л и я. Ә нәрсә ул үбешү?

И с ф а н. Показать, что ли? Күрсәтергәме? Кил, Шүрәлинә.

Шүрәлинә Исфан кочагына сыена. Үбешәләр.

Ш ү р ә л и я. Шулмы? Шуннан нәрсә була? Яле минем белән...

И с ф а н. С удовольствием. Рәхәтләнеп... *(Шүрәлияне үбә. Шүрәлиягә рәхәт.)*

Ш ү р ә л и я. Яле тагын берне!

Үбешәләр. Шүрәлиянең башлары әйләнеп китә.
Кинәт акылына килеп.

Сихер бу. Сихер! Киттек тизрәк! *(Шүрәлинәне өстери, Шүрәлинә тартыла.)*

Ут сүнә. Ут янганда, Җ ә м и л ә белән Ш ү р ә л е йөгерешеп керәләр. Утыргыч тирәли әйләнәләр-бөтереләләр. Бөтен дөнья әйләнә. Сандугачлар җырлый, бака сайрый, күктә йолдызлар бии, ай кул чабып тора.

Ш ү р ә л е. Җәмилә-ә-ә!..

Җ ә м и л ә. Шүрәле-е-е!.. Син кайда-у-у?

Ш ү р ә л е. Мин монда-у-у...

Кара-каршы киләләр. Бер-берсенә карашып торалар.
Җәмилә чибәрләнгән, карап туймаслык булган.

Җ ә м и л ә. Шүрәле...

Ш ү р ә л е. Җәмилә. Син шундый чибәр.

Җ ә м и л ә. Мин күрдем. Якты күлнең суына карасам... Үземне танымадым да. Бигрәк серле күл икән ул Якты күл.

Ш ү р ә л е. Якты күл ул күңеле гүзәлләрне генә чибәр итә.

Җ ә м и л ә. Шүрәле...

Ш ү р ә л е. Җәмилә...

Аларның сөйләшүләре җыр белән дәвам итә.

Җ ә м и л ә. Очрадың да хыялымда,
Алып киттең үзең белән.
Очрашуның татлылыгын
Үзем белəм, үзем беләм.

Ш ү р ә л е. Хыялыңның сукмагыннан
Атлый бел син, атлый бел син.
Күңелеңдә туган җырны
Саклый бел син, саклый бел син.

Җәмилә. Ниләр көтә киләчәктә –
Хыялымның чикләрендә?
Ташлап тормыш упкынына,
Китмә генә, китмә генә.

Ш ү р ә л е. Яшьлегеңнең ал гөлләрен
Күрми таптап үтмә генә.
Хыялыңның толымнарын
Сүтмә генә, сүтмә генә.

Җ ә м и л ә. Йөр син минем хыялымда –
Төшләремдә, өннәремдә.
Сине уйлап кына узсын
Төннәрем дә, көннәрем дә.

Ш ү р ә л е. Көтә белсәң, мин килермен,
Очып кына килермен мин;
Тезләнермен алларыңа,
Шатланырмын, көлермен мин.

И к ә ү б е р г ә. Хыялыңның канатлары
Арымасын, талчыкмасын.
Өметләреңне өзәргә
Ашыкма син, ашыкма син.

Ш ү р ә л е. Син елмай, син көл, Җәмилә. Көлсәң, син тагын да чибәрләнәсең.

Җ ә м и л ә. Көләсе килмәгән чаклар еш була бит, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Андый чакта син күз алдыңа Шүрәленең бүрәнә ярыгына кысылган бармакларын китер дә көл.

Җ ә м и л ә. Аңардан көләләрмени инде, Шүрәле?

Ш ү р ә л е. Ә син көл, көл, Җәмилә! *(Бармакларын уйнатып.)* Күр әле ниндиләр алар!

Җ ә м и л ә. Шүрәле, син ул бармакларың белән миңа бер тапкыр да кагылмадың, әйеме?

Ш ү р ә л е. Ярамый, Җәмилә. Мин яратып кына кагылсам да, кытыклый дип уйлыйлар кешеләр. Мин бүген китәм инде, Җәмилә. Озакламый таң ата.

Җ ә м и л ә. Мин сине көтәрмен, Шүрәле.

Ш ү р ә л е. Мин килермен, Җәмилә. *(Югала, тавышы гына ишетелә.)* Мин килермен, Җәмилә... Ә син көл, елмай, Җәмилә.

Р и м *(кереп, Җәмиләгә карап).* Җәмилә, синме соң бу?

Җ ә м и л ә. Мин...

Р и м. Сине танымассың да. Шундый чибәрләнгәнсең. *(Җәмилә янына утырып.)* Йоклап булмый. Төшкә әллә ниләр керә. Чыктым әле. Кара, син шундый матур. Эчүне ташлыйм әле мин, Җәмилә. Нишләп утырасың соң әле үзең генә?

Җ ә м и л ә. Мин үзем генә түгел.

Р и м. Кем белән соң?

Җ ә м и л ә. Синең белән ич. *(Көлә. Аңа Рим да кушылып көлә.)*

Н ә с и м ә белән Р ә с и м ә керәләр.

Н ә с и м ә. Карале боларны, тик торганнан көлешеп утыралар. Нидән көләсез, ә?

Җ ә м и л ә. Менә ич, Рим белән утырабыз.

Р ә с и м ә. Аның ни көлкесе бар?

Җ ә м и л ә. Ул мине көлдерә.

Н ә с и м ә *(Римга).* Син кая югалдың? Әллә урманда йоклап калдыңмы, Шүрәле?

Р и м. Син үзең Шүрәле. Шүрәлия син.

Н ә с и м ә. Син – Шүркә.

Көлешәләр.

Р ә с и м ә. Чынлап та, кая киттең син, Рим?

Р и м. Сезнең белән кызык түгел.

Н ә с и м ә. Кем белән кызык соң? Кызык түгел дигән була, адәм тәганәсе... Эчә-эчә дә...

Р и м. Ә мин ташлыйм эчүне.

Р ә с и м ә. Әнә тагын бер шүрәлесе килә.

Көлешәләр. И с ф а н керә.

И с ф а н. Чё смеётесь?

Н ә с и м ә. Синнән смиюмсә.

И с ф а н. А чё я? Клоун, что ли? *(Җәмиләгә күзе төшеп.)* О-о-о! Җәмилә!.. Ты чё? Такая красивая. Матур.

Чибәр. Какие еще слова есть? Гүзәл. Чё? Мине көтәсең, что ли? Менә мин. Ария из оперы «Шурале».

Менә ми-и-н. Менә ми-и-ин!..
Я красив и лю-би-им!

Җәмилә, давай-давай, җырла минем белән. Опера. Әйдә инде.

Җәмилә. Тик кулың белән кагылма, ярыймы?

Исфан. Кайчан мин сиңа кагылганым бар? Мин нәрсә? Син нәрсә мине обижаешь, Вася?!

Җәмилә. Йә инде, йә, үпкәләмә. Әйдә, башла операңны. Тик татарча җырла. Мин урысча белмим.

Исфан. Яхшы, яхшы.

Менә ми-и-ин, менә ми-и-ин.
Каршы ал, киләм мин.

Кушыл, Җәмилә.

Җәмилә. Елмаям, көләм мин,
Сөясең, беләм мин.

*(Кинәт туктап.)* Ә кайда ул?

Исфан. Кем?

Җәмилә. Шүрәле... Шүрәле кайда?..

Исфан. Менә ич мин — Шүрәле.

Рәсимә. Син Шүрәле түгел, Шүрик син.

Исфан. Ә син...

Җәмилә. Исфан, операңны оныттың. Менә ми-и-ин!

Исфан. Менә ми-и-ин!

Җәмилә. Кайда си-и-ин?

Исфан. Монда ми-и-ин.

Шушы сүзләрне кабатлап, аларга бүтәннәр кушыла. Еракта Шүрәленең көлгәне ишетелә.

Пәрдә.

# ИЛГИЗӘР + ВЕРА

*(Ике пәрдәле драматик хикәя)*

Катнашалар:

Нурхәмәт — 75 яшьләр тирәсендәге татар карты.
Хәлиулла — 45 яшьләрендә, Нурхәмәтнең улы.
Дания — 40—45 яшьләрендә, Хәлиулланың хатыны.
Мария — Нурхәмәтнең кордашы, рус карчыгы.
Алексей — Хәлиулланың яшьтәше, Мариянең улы.
Наталья — 40—45 яшьләрендә, Алексейның хатыны.
Илгизәр — 17 яшьтә, Хәлиулланың улы.
Вера — 17 яшьтә, Алексейның кызы.
Туй агасы.
Нина.
Ислам.
Беренче ир.
Икенче ир.
Беренче хатын.
Икенче хатын.
Авыл кешеләре: кияүләр, кәләшләр, туйлардагы кунаклар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Иделдән ерак түгел генә җәелеп утырган Җикән авылы. Авылның яртысында татарлар яши, яртысында — руслар. Бүген бу авылда — туй. Татар туе. Туйның кызган чагы. Кунаклар, өйгә сыешмыйча, ишегалдына чыгалар. Гармунчыга дигән урындыкны баш очына утыртып бии-бии, Туй агасы чыга. Урындыкны ишегалды уртасына куя. Гармунчы үз дәрәҗәсен үзе белеп шул урындыкка урнаша, бию көен уйнавын дәвам итә. Өйдән чыккан кунакларның бер ише биюгә кушыла, кайсылары биючеләргә куәт биреп кул чабып тора.

Туй агасы үзенең көр тавышы белән шундый әмер бирә.

Туй агасы. Шым кал!.. Үррә кат!.. Селкенмә!.. Берәү дә сүз дәшми, беркем дә бернинди хәрәкәт ясамый. Үррә кат! Кияү белән кәләш, түгәрәк уртасына рәхим итегез. *(Кияү белән кәләш уртага чыгып баскач, гармунчыга әмер бирә.)* Башла!

Гармунчы яңа бию көен уйный, кияү белән кәләш татарчалап бииләр. Калганнар, әлбәттә, җырлап, биючеләргә дәрт өстәп торалар.

Әй, биегез, биегез,
Уйнагыз да көлегез;
Бүген сезнең тыпыр-тыпыр
Бии торган көнегез.

Әй, кияве, кияве –
Егетнең бер дигәне;
Йөрешләре дә килешле –
Асыл заттыр сөяге.

Әй, биегез, биегез,
Матур икән көегез;
Матур көйгә матур итеп
Биеп туймас көнегез.

Әй, кәләше, кәләше –
Кызларның бер генәсе;
Эшкә уңган, төскә булган
Гүзәл затлар иясе.

Әй, биегез, биегез,
Күккә йолдыз чөегез;
Киләчәктә шатлык белән
Балкып торсын өегез.

Наталья *(уртага атылып чыгып)*. Иптәшләр! Дуслар!..

Туй агасы. Наташа апа! Минем рөхсәттән башка беркем дә бер сүз әйтми.

Наталья. Туктале, энекәем!

Туй агасы. Мин сиңа энекәем түгел – туй агасы. Туйга мин хуҗа. Әйтәсе сүзеңне өстәл янында әйтергә иде. Монда бию һәм җыр гына.

Наталья. Әйтим инде бер сүз, энекәем! Күңелемнең ташыган чагы.

Т у й а г а с ы. Күңелеңнең ташыган чагы булса, әйт инде, алайса. *(Кунакларга мөрәҗәгать итеп.)* Әйтсенме, иптәшләр? Рөхсәт итәбезме?

Т а в ы ш л а р. Әйтсен, әйтсен!..

Н а т а л ь я. Авылдашларым! Бәгырькәйләрем! Нәрсә генә әйтим икән? Әйтәсе сүзләрем шулчаклы күп. Күз генә тимәсен иде. *(Кәләшне кочаклап.)* Карагыз инде моңа: сокланып туймаслык бит. Бәхеткәйләр телим үзеңә, сеңелкәем. Әтиең, әниең дөнья бәясе кешеләр — бәхетле булырсыз. *(Кияүне кочагына алып.)* Монысын карагыз инде — сөеп туймаслык лабаса. Әйтсәм әйтим инде, әтиеңә гашыйк идем мин синең. Әтиең миннән дә матурракны алды шул. Миңа менә шушы Алексей эләкте инде. *(Ире Алексейны уртага тартып чыгарып.)* Яле, Алёша, бәгырь кисәгем, әйтик әле кияү белән кәләшкә иң матур сүз. Бүген бит аларның иң бәхетле һәм иң җаваплы көннәре. Алар бүген озын-озак юлга чыгалар. Бәхет яусын алар барасы юлга. Синең белән минем кебек матур яшәсеннәр. Әйдәле, алар хөрмәтенә сузыйк әле үзебезнең иң яраткан җырыбызны. *(Гармунчыга.)* Габдрахман энекәем, безнең җырны беләсеңме син?

Гармунчы, шунда ук рус халкының «Зачем тебя, милый, узнала» җырын уйный башлый. Наталья җырлый, аңа Алексей кушыла.

Зачем тебя я, милый мой, узнала,
Зачем ты мне ответил на любовь?
Ах, лучше бы я горюшка не знала,
Не билось бы сердечко моё вновь.

Терзаешь ты сердечко молодое,
Тебя твоя зазнобушка зовёт…
Проходит только время золотое,
Зачем же ты, желанный, не идёшь?

Я жду, и вот приходит долгожданный,
Целует, нежно за руку берёт.
Ах, милый друг, мой нежный друг желанный!
И сердце песню радости поёт.

*(Җыр туктагач, Наталья русча итеп кунакларга башын ия.)* Рәхмәт сезгә, авылдашлар, җырымны күтәреп алдыгыз.

Шулчак Ислам тавышы ишетелә. Авылдагы бер мәҗлестән дә, бер туйдан да калмый торган кеше. Тавышы матур, килешле, авылча. Ул үзенең һәрвакытта да җырлый торган җырын җырлый — татар халкының «Кыр казы» дигән җыры.

Ислам. Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы —
Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә.
Беләсеңме, дустым, сизәсеңме
Аерылулар килеп җиткәнен?
Кыр казы
Суларда уйный шул,
Ялгыз башым гел сине уйлый.

Туй агасы. Булдымы? Җырлап бетердеңме?

Ислам. Икенче куплетым бар, белдеңме?

Туй агасы. Анысы икенче туйда, ярыймы?

Ислам. Син нигә гел мин җырлаганда килеп кысыласың, ә?

Туй агасы. Туй бит бу. Туйда бер син генә түгел.

Ислам. Бер син генәме?

Туй агасы. Ярый-ярый, булды. Җәмәгать, күңел ачуны дәвам итәбез. Яле, Дания апа, әйттер әле берне.

Дания. Нигә? Әйттерәм. Бер яшьлектә, бер картлыкта. Әйдә, Наташа.

Такмак әйтә башлый. Аңа Наташа кушыла.

Әйдә, бас, бас, әйдә,
Биеп калыйк бу җәйдә,
Ике матурның туенда
Тагын берне бас, әйдә.

Бас, әйдә, бас, әйдә,
Биеп күңел ач, әйдә.
Биемибез дигәннәргә
Ялынмыйбыз, бигайбә.

Икәүләп кодаларны биергә чакыралар.

Кодалар, кодалар —
Уңганнар һәм булганнар.
Кодагыйларга карагыз —
Дөнья бизи торганнар.

Балдызлар да кайнешләр,
Барыгыз да беришләр.
Атна саен туй ясарбыз,
Гел болай барса эшләр.

Ишегалдында аягына басып тора алган һәр адәм баласы бии башлый. Бии-бии кайберәүләре арып туктый. Тора-бара уртада Илгизәр белән Вера гына калалар. Алар дөньяда үзләреннән башка беркемне дә күрми бииләр. Бераздан гына аңнарына килеп туктыйлар да арттырып җибәргәннәреннән оялып чыгып йөгерәләр. Туй дәвам итә. Андагы көлеш, шау-шу карт өянке астындагы эскәмиядә утырган Нурхәмәт белән Мариягә дә килеп җитә.

Нурхәмәт. Мифтахетдиннәрдә инде бу галәмәт, Маруся күрше.

Мария. Алар нәселе бәйрәм ясый белә инде ул. Карале, Нурхәмәт күрше, кайсы елны ул без синең белән кара-каршы төшеп биегән идек?

Нурхәмәт. Безнең биегәннәрне санасаң...

Мария. Юк, анысы үзенә бертөсле бию булды ул. Әле дә хәтеремдә...

Нурхәмәт. Сезнеңчә биегән идекме, безнеңчәме?

Мария. Сезнеңчә дә, безнеңчә дә. Кайсыбыз алдан арып туктар дип биергә тотынган идек, мин арый башлаганны син сизеп алдың да арыган булып егылдың.

Нурхәмәт. Юктыр, мин үзем арыганмындыр. Сине биетеп арытып булмый иде. Марҗа биеп арый димени ул, Маруся күрше? Сез бит биергә бик маһир халык.

Мария. Сез дә кимен куймыйсыз инде.

Нурхәмәт. Анысы шулай, кәнишне... Тыңлале, бу синең килен тавышы бит. Уңдың киленнән, молодец синең Әләкчәй.

Мария. Күз тимәсен, синең килене дә бик уңган.

Нурхәмәт. Уңуын уңдым да, малай бик юаш булып чыкты минем, Маруся күрше... Кара, ничек сиптерәләр, ә?.. Шулай инде, безне хәзер туйга да чакырмыйлар.

Мария. Нишлисең инде... Оныкларыбызның туенда утырсак кына.

Нурхәмәт. Күзле бүкән булып дисеңме?

Мария. Нишләп, биербез дә әле, биетсәләр. Сездә туй булса, әйтерсең, Марияне чакырыгыз, диярсең, бездә булса, мин сине үзем кереп чакырырмын. Шунда яшь чакларны искә төшереп бер биербез дә әле. Синең хәтер

начарлана бара шул, Нурхәмәт күрше, икәү кара-каршы төшеп биегәнне дә оныткансың.

Нурхәмәт. Онытмадым ла инде... Булды инде, Ходай хәерле кылсын.

Мария. Хәзер Ходай дип утырасың. Ул чакта...

Нурхәмәт. Йә инде, искә төшермә инде.

Мария. Ояласыңмыни, карт төлке?

Нурхәмәт. Үзең бит...

Мария. Нәрсә үзең? Мин нишләгән?

Нурхәмәт. Чибәр идең бит.

Мария. Чибәр дигәч тә, юлда тотып үбәләр димени?

Нурхәмәт. Үзең дә качмадың бит.

Мария. Кая качыйм? Инеш юлы – тар сукмак. Ике ягы шомыртлык.

Нурхәмәт. Шомыртлык шул, шомыртлык, мать честная... Шулай инде. Шулай шул.

Ап-ак, ап-ак каз итләрен
Ах, ты, Маруся,
Мин турадым, син аша.
Ах, ты, не бойся!
Пущай безне рассуждают,
Ах, ты, милая,
Кил, утырыйк янәшә,
Кому какое дело?

Ә, Маруся?.. Шулай бит?..

Мария. Шулай иде, Нурхәмәт, шулай иде.

Нурхәмәт. Ярый, Маруся күрше, керим инде мин. Әллә нәрсә билләр сызлап тора.

Мария. Сау бул, Нурхәмәт күрше! Исән-сау очрашырга язсын.

Нурхәмәт. Шулай булсын, күрше, шулай булсын.

Икесе ике якка китәләр. Туй шау-шуы дәвам итә. Йөгереп, Илгизәр белән Вера керәләр. Карт өянке янында туктыйлар. Кочаклашып үбешәләр.

Ут сүнә. Ут янганда инде икенче туй бара. Рус туе. Әлегә аның тавышы гына ишетелә. Аны Нурхәмәт белән Мария тыңлый.

Нурхәмәт. Менә китте дөнья, ә? Бер атна гына элек Мифтахетдиннәрдә туй булды, бүген Микулайлар гуләйт итә.

Мария. Кай арада үсеп җитәләр диген син малайлары.

Н у р х ә м ә т. Кызлар өлгергәч, малайлар үсә инде ул. Кем кызына өйләнгән соң Микулайның малае?

М а р и я. Иваннар белән кода булдылар инде.

Н у р х ә м ә т. Кайсы Иван? Чтапан Иванымы?

М а р и я. Юк ла инде. Степан Иванының кызы юк ич. Теге Аграфена малае Иванның кызы. Беләсеңдер лә. Правлениедә утыра ич инде. Ак чәчле.

Н у р х ә м ә т. Сез барыгыз да ак чәчле, кем белеп бетергән.

М а р и я. Син үзең бик кара инде.

Н у р х ә м ә т. Бар иде чәчләрнең чем-кара чаклары, Маруся. Бар иде. Хәтерлисеңме, без синең белән кара-каршы төшеп биегән идек?

М а р и я. Безнең биегәннәрне санасаң...

Н у р х ә м ә т. Юк, анысы үзенә бертөсле бию булды ул.

М а р и я. Син арып егылдың. Шуны әйтәсеңме?

Н у р х ә м ә т. Арып түгел лә инде, арыган булып кына, синең алда.

М а р и я. Докажи!

Н у р х ә м ә т. Соңрак шул инде доказать итәргә, Маруся. Картайдык, күрше, картайдык.

М а р и я. Әй, шыгырдап утырма әле, карт өянке кебек. Тоже мне старик.

Н у р х ә м ә т. Ты не старуха, что ли?

М а р и я. Старуха не старуха, синең кебек зарланып утырмыйм. *(Урыныннан тора.)*

Н у р х ә м ә т. Кая киттең әле?

М а р и я. Туйларын карап кайтыйм әле Николайларның.

Н у р х ә м ә т. Мине калдырып китәсеңме?

М а р и я. Нәрсә, парлап барыйк дисеңмени кеше туена? Чакырылмаган килеш. Әйдә, ишегалдында бииләр бугай. Читтән генә карап кайтыйк.

Н у р х ә м ә т. Килешер микән соң?

М а р и я. Килешмәсә кал... Без бит анда ашарга-эчәргә сорап бармыйбыз.

Н у р х ә м ә т. Әйдәле, бер кызык булсын әле. Килен күрсә яхшы түгел инде түгелен.

М а р и я. Ир башыңнан киленнән куркып торасыңмы? Татар булган килеш?

Н у р х ә м ә т. Әй, Маруся, татар киленнәре хәзер... Беләсең инде үзең... Киттекме?

М а р и я. Подручком барабызмы?

Н у р х ә м ә т. Әллә куркыр дисеңме? *(Марияне култыклый.)*

М а р и я *(кулын тартып алып)*. Кит, юньсез! Син тилегә әйткән мин җүләр.

Чыгып китәләр. Ә Николайларның ишегалдында туй гөр килә. Монда да Н а т а л ь я уртада. Н и н а исемле бер хатын белән бергәләп частушкалар әйтә-әйтә бииләр.

Н а т а л ь я. Ой, «подгорная», «подгорная»,
Весёлая игра.
Всё бы пела, всё бы пела
Всё бы пела до утра.

Н и н а. Я «подгорную» плясала,
Меня мама уняла:
«Рано, дочка, гулять стала,
Рано волюшку взяла».

Н а т а л ь я. Не хотела я плясать,
Не хотела выходить.
Гармонист такой хороший –
Ему надо угодить.

Н и н а. Поиграй повеселее,
Раньше ты мне играл.
Неужели не сознаешься,
Что ты со мной гулял?

Г а р м у н ч ы. Сам играю, сам пою,
Подпевать-то некому.
Дайте мне подпевочку –
Лет семнадцать девочку.

Н а т а л ь я. Гармонист, гармонист,
Не гляди глазами вниз.
Гляди прямо на меня,
Завлекать буду тебя.

Н и н а. Сыграй, сыграй, припою,
Чтобы раздавалося.
Про измену про твою
Давно я догадался.

Г а р м у н ч ы. Ты не лай, не лай, собачка –
У крылечка дамочка.
Ты послушай-ка, милашка,
Как ревёт тальяночка.

Н а т а л ь я, Н и н а *(икәүләп)*.

Ой, спасибо, гармонист,
За игру отличную.
Мы еще тебе желаем
Милку симпатичную.

Н а т а л ь я. Ой, спасибо, мои дорогие! Спасибо, милые! *(Баш ия.)*

Т у й а г а с ы. Прошу внимания! Жених и невеста. Прошу, жених. Прошу, невеста. *(Кияү белән кәләшне кулларыннан тотып уртага чыгара.)*

И с л а м *(уртага чыга)*. Мин инде, җәмәгать, сүз әйтә белмим...

Т у й а г а с ы. Әйтә белмәсәң әйтмә.

И с л а м. Син тик тор, агай-эне, белдеңме?!

Т у й а г а с ы. Минем тик торырга хакым юк. Мин — туй агасы, бу туйның хуҗасы.

И с л а м. Бу туйның хуҗасы — Микулай белән Татияна. Менә мин алар хөрмәтенә бер җыр җырлыйм. Син читкә китеп тор, яме.

Т у й а г а с ы. Һаман шул җырыңмы?

И с л а м. Анда синең эшең юк, белдеңме?! *(«Кыр казы»н җырлый.)*

Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы —
Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә.

Д а н и я. Бетмәде шул җырың. Туйда җырлый торган җырмы инде...

И с л а м. Синең ни эшең бар минем җырда?

Д а н и я. Туйда күңелле җыр җырларга кирәк.

И с л а м. Бик күпне беләсең. Хәлләңне өйрәт, белдеңме?

Д а н и я. Хәлиулланы өйрәтәсе юк, ул син түгел.

И с л а м. Миңа ни булган, ни булган?

Д а н и я. Бернәрсә дә булмаган. Кит, болганма.

И с л а м. Китәрмен мин сиңа!

Д а н и я *(Исламга игътибар итмичә, гармунчы каршына бара)*. «Барыйна»ны уйна! *(Гармунчының уйный башлаганын да көтмичә, такмак әйтә-әйтә бии.)*

Әй, барыйна, барыйна,
Күзләреңә карыйм ла,
Күзләреңә карый-карый,
Керфекләрең саныйм ла.

Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.
Әй, барыйна, барыйна,
Бер озата барыйм ла.

Кеше-кара күрмәгәндә
Бер кочаклап алыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

Әйдәгез! Әйдәгез! *(Бүтәннәрне дә биергә чакыра.)*

Әй, барыйна, барыйна,
Булыйм сөйгән ярың ла.
Җаның сөйгән ярың булып
Яннарыңда калыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

Кунаклар барысы да ду килеп бии. Алгы планда Илгизәр белән Вера сиптерә. Аларның биегәнен Нурхәмәт белән Мария дә карап торалар. Менә Илгизәр белән Вера йөгереп чыгып китәләр. Туйдагылар биеп кала. Илгизәр белән Вера карт өянке янына чабышып киләләр. Сулулары капкан, икесе дә көлешәләр. Үбешеп алырга да онытмыйлар.

В е р а. Шундый рәхәт миңа, Илгизәр!

И л г и з ә р. Миңа да.

В е р а. Нигә рәхәт икән ул, Илгизәр?

И л г и з ә р. Ә мин каян белим?

В е р а. Ничек инде белмисең?

И л г и з ә р. Беләсем дә килми. Рәхәт булгач рәхәт инде.

В е р а. Мине яратасыңмы син, Илгизәр?

И л г и з ә р. Яратам, билгеле.

В е р а. Өзелеп яратасыңмы?

И л г и з ә р. Өзелеп яратам, билгеле.

В е р а. Ничек итеп яратасың?

Илгизәр *(Вераны үбеп ала)*. Минә шулай итеп.
Вера. Ни өчен яратасың, Илгизәр?
Илгизәр. Каян белим?
Вера. Ничек инде белмәгән килеш яратасың?
Илгизәр. Син мине ни өчен яратасың соң?
Вера. Мин сиңа яратам дип әйтмәдем ич.
Илгизәр. Яратмагач, нигә үбешәсең соң?
Вера. Рәхәт булганга. *(Көлешәләр һәм, әлбәттә, үбешеп алалар.)*
Илгизәр. Әйдә без дә туй ясыйбыз.
Вера. Нинди туй, Илгизәр?
Илгизәр. Өйләнешәбез дә туй ясыйбыз.
Вера. Туйны бит аны өйләнешкәннәр ясамый, әтиәниләре ясый.
Илгизәр. Безнекеләр дә ясарлар. Әллә ясамаслармы?
Вера. Ә ни өчен өйләнешәбез, Илгизәр?
Илгизәр. Минә кызык. Бергә яшәргә.
Вера. Ә ни өчен бергә яшәргә?
Илгизәр. Кара... Син нәрсә миннән көлеп утырасың?
Вера. Мин көлмим, Илгизәр.
Илгизәр. Алайса, нигә гел сорау биреп утырасың?
Вера. Ә син җавабын тап.
Илгизәр. Бик кирәге бар.
Вера. Алайса, син сорау бир, мин җавабын эзлим.
Илгизәр. Минем соравым юк.
Вера. Бер генә, бер генә дә соравың юкмы?
Илгизәр. Юк.
Вера. Илгизәр! Тагын бер генә сорау бирим инде? Син нигә миңа исемем белән эндәшмисең? Мин сиңа «Илгизәр» дип кенә торам. Ә син бер генә тапкыр да миңа «Вера» дип эндәшкәнең юк.
Илгизәр. Бер дәме?
Вера. Бер тапкыр да юк.
Илгизәр. Белмим. Миңа барыбер.
Вера. Миңа барыбер түгел.
Илгизәр. Ишет инде, алайса: Веры, Веры, Веры, Веры, Веры, Веры!
Вера. Веры түгел, Илгизәр, Вера.
Илгизәр. Барыбер инде ул.
Вера. Барыбер түгел, Илгизәр.
Илгизәр. Кара, нигә бәйләнәсең әле миңа?

В е р а. Хатын-кызлар бәйләнә инде ул, Илгизәр. Түзәсең инде. Түзәсеңме?

И л г и з ә р. Бик исем китте. Рәхәтләнеп бәйлән. Безнең әни әтигә гел бәйләнә, әтинең исе дә китми. Башын иеп тик йөри.

В е р а. Син дә өйләнгәч башың иеп тик йөрерсеңме?

И л г и з ә р. Әни әйтә, син миңа охшагансың, ди.

В е р а. Маменькин сынок инде, алайса?

И л г и з ә р. Үртәмә, диләр сиңа...

В е р а. Үртәсәм нишләтәсең?

И л г и з ә р. Нишләтәмме? *(Вераны үбәргә үрелә, Вера тайпылып өлгергәч.)* Нишлисең, ә?

В е р а. Үптерәсем килми.

И л г и з ә р. Менә кызык. Кызык икәнсең син. Әле яңа гына үбештең ич.

В е р а. Яңа гына үбештек, хәзер үбешәсем килми.

И л г и з ә р. Ни өчен?

В е р а *(кычкырып көлеп)*. Соравым юк, дигән идең, ике сорау бирдең. *(Илгизәрне үбеп ала.)* Әйдә, Илгизәр, җырлыйбыз.

И л г и з ә р. Мин җырлый белмим.

В е р а. Ә мин җырлыйммы?

И л г и з ә р. Җырла.

В е р а. Синең өчен җырлыйм, ярыймы? Кайсы җырны җырлыйм?

И л г и з ә р. Миңа барыбер.

В е р а. Сиңа бөтенесе дә барыбер икән.

И л г и з ә р. Миңа син булгач җиткән.

В е р а. Ярый, тыңла, алайса. *(Әкрен генә җырлый.)*

Вот и встретились!.. Вот и прощаемся...
Как натянуто мы улыбаемся.
Что ж друг к другу с тобою мы тянемся,
Если будучи вместе маемся?

Вот и встретились!.. Вот и прощаемся...
Может быть, навсегда разлучаемся.
Вот и встретились! Вот и прощаемся.
И с тоскою запоздалою каемся.

Что ж мы каемся, что ж мы маемся,
Вряд ли когда-нибудь догадаемся.
Вот и встретились!.. Вот и прощаемся...
Может быть навсегда разлучаемся.

Ут сүнә. Сәхнә яктырганда, Хәлиуллаларның өй эчен күрәбез. Сәхнәдә берәү дә юк. Ишек шакыйлар. Чаршауны ачып, чаршау артындагы караваттан торып, Хәлиулла чыга. Утны яндыра. Чоланга чыгып, ишекне ача. Аннан Алексей белән керә.

Алексей. Ачуланма инде, Хәллә.

Хәлиулла. Нишләп ачуланыйм, уз, әйдә.

Дания *(чаршау артыннан)*. Алексей, синме соң ул?

Алексей. Мин әле, Дания. Төнлә йөргәнгә ачуланмагыз инде.

Дания. Берәр нәрсә булмагандыр ич?

Алексей. Булуын булмады да. Кердем әле. Наташа, йөрмә төнлә кеше борчып, дигән иде дә, кердем әле. Хәллә белән сөйләшәсе сүз бар иде. Хәллә, капка төбенә чыгып утырыйк.

Дания. Килешмәгәнне. Өйгә кергәч. *(Чаршау артыннан халатын киеп чыга.)* Уз, әйдә, утыр. Хәлиулла, нәрсә катып калдың? Ки чалбарыңны. Сәгать ничә соң әле?

Алексей. Соң инде, Дания. Ачуланма инде.

Дания. Юк сүз сөйләп торма әле. *(Өстәл янына урындык куеп.)* Утыр. Мин хәзер.

Алексей. Миңа берни дә кирәкми.

Дания. Тик кенә утыр. Хәлиулла, кая югалдың инде? Уяна алмыйсың мәллә?

Хәлиулла *(чалбарын киеп чыгып)*. Хәзер, хәзер. Бармы соң безнең?

Дания *(өстәл әзерли-әзерли)*. Нишләп булмасын инде?!

Алексей. Зинһар, борчылмагыз. *(Хәлиулла өстәлгә шешә куйгач.)* Кирәкми.

Дания. Йә-йә. Күрше булсагыз да, көн саен кереп тормыйсыз. Наташаны да алып керергә иде. Бәрәңгеләр алынып бетте, кешеләр туй ясый. Безгә дә бер утырып алырга ярыйдыр инде. Бар, Хәлиулла, алып чык Наташаны. Кермим дисә, сөйрәп алып кер.

Алексей. Юк-юк, Дания, кирәкми, зинһар. Мин Хәллә белән генә...

Дания. Син Хәлләң белән сөйләшерсең, сезнең сүзегез миңа кирәкми. Без Наташа белән сөйләшергә сүз табарбыз.

Алексей. Юк, дидем, Дания. Ачуланма. Наташаның кәефе дә юк.

Дания. Ни булды?

Алексей. Булды инде. Зинһар, бернәрсә кирәкми. Алайса, чыгып китәм. *(Хәлиуллага.)* Утыр әле, Хәллә. Дания, ачуланма, без Хәллә белән икәү генә.

Дания *(аптырап калган җиреннән)*. Ярый инде, алайса, чыгып торам, сөйләшегез. *(Бүлмәләренең берсенә кереп китә.)*

Алексей. Капка төбендә генә утырасы иде.

Хәлиулла *(стаканнарга аракы салып)*. Йә, тотыйк әле.

Алексей. Монсыз гына сөйләшик.

Хәлиулла. Тот, әйдә, тот. Әйбәт булды әле керүең, баш та авыртып торае.

Чәкешеп эчеп куялар.

Алексей. Фу, чиргә әйләнде бу. Кешегә керер хәл юк.

Хәлиулла. Нишлисең инде. Шулай инде. Капкала. Даниянең булган әле ярый. Кичә малайлар белән җыелышып эштән соң бераз ниткән идек. Нәрсә, сез дә ниткән идегез мәллә?

Алексей. Юк ла... Нихәлләрдә соң, Хәлиулла?

Хәлиулла. Нихәлләрдә дип, үзең беләсең инде. Алга барган җир юк.

Алексей. Юк шул. Очы-кырые күренми.

Хәлиулла. Хәерле булсын инде. Шунысына шөкер, яшьтәш, ашарга-эчәргә бар.

Алексей. Син сизәсеңме, Хәллә, дөньяның рәте-чираты булмагач, булган ризыкны рәхәтләнеп, тәмләп ашап булмый икән.

Хәлиулла. Валлаһи, шулай бит әй, Алексей! Телевизор карыйсың да, әппитит бетә.

Алексей. Да-а-а... Төн уртасында нишләп йөри инде бу дип уйлыйсың инде син, әйеме? Нигә сүзен әйтми дип уйлыйсың инде?

Хәлиулла. Уйламыйм да...

Алексей. Болай әллә ни юк-югын. Наташа белән сөйләшеп яттык әле. Син минем бабайны хәтерлисең микән, яшьтәш?

Хәлиулла. Ничек инде хәтерләмәскә?

Алексей. Аның сөйләгәннәрен искә алып яттык әле Наташа белән. Безнең менә монда сезнең авылга килеп

төпләнүебез турында. Безнең халыкны монда Пётр Беренче заманында көчләп күчереп утырткannар. Бабайның әйтеп калдырганынча, Воронеж якларыннан булырга тиеш без. Кайсыбер татар авылларыннан татарларны бөтенләй куып җибәреп, безнең кебекләрне урнаштырганнар. Авыл исемнәре татарча калган. Беләсең инде аларны. Тәмте, әнә Каратун, Бортас... Күп инде алар.

Хәлиулла. Татарлар булганмыни анда?

Алексей. Татарлар, конечно. Сезнең авылга ни өчендер тимәгәннәр. Сезнең яннан безгә җир бүлеп биргәннәр. Татарлар турында куркыныч әкиятләрне күп ишеткән бабайлар. Башта сакланыбрак яшәгәннәр. Сезнекеләр үзләренчә, безнекеләр үзләренчә. Бара-тора инде, үзең беләсең. Үзең беләсең инде бүген ничек. Күз тимәсен, бер авыл, бер ил булып яшибез. Өч йөз елга якын бергә яшәп, бер генә тапкыр да сугышып урамга чыкмаганбыз. Сез безнең телне беләсез, без сезнең телне өйрәндек. Безнең бабайлар сезнең бәйрәмнәргә, сезнең бабайлар безнең бәйрәмнәргә йөргән. Безнең туйларда сез табын уртасында, сезнең туйларда без кадерле кунак.

Хәлиулла. Ничек инде шулай булмасын, бер авылда яшәп.

Алексей. Хәтерлисеңме, Хәллә, өченче ел сабан туенда Бакырчы авылының бер егете минем энекәшкә бәйләнгән иде. Ике арада сугыш чыккач, бүтәннәр дә кушылып, ике авыл бәргәләшергә тотынды. Без, татары-урысы, бергәләп бакырчыларга каршы сугыштык. Син үзең дә катнаштың бугай.

Хәлиулла. Андый чакта карап тормыйсың инде. Бер җүләр аркасында ямьсезләштек, шунысы гына.

Алексей. Урыс егетен яклап сугыштың бит, Хәллә, Бакырчы татарлары белән.

Хәлиулла. Урысның, татарның ни катнашы бар монда? Син әллә нинди әле бүген, Алексей. Тот әле, әйдә, исәнлеккә-саулыкка... *(Күтәреп куялар. Пауза.)*

Алексей. Бер сорау биримме сиңа, Хәлиулла яшьтәш? Беләсеңме, ни өчен без ничәмә-ничә йөз ел бергә яшәп сугышу түгел, телгә дә килгәнебез юк?

Хәлиулла. Ә нигә сугышасың ди?

Алексей. Кешеләр нигә сугыша соң?

Хәлиулла. Нигә дип, бүлешә алмыйлар.

А л е к с е й. Безнең бабайларның да бүлешәсе нәрсәләре булмаган дисеңме? Сугышмаганнар. Акыллы итеп бүлешкәннәр. Безнең бабайлар безнең патшалардан акыллырак булганнар. Сез үз җирегездә рәнҗетелгән, без үз җиребездән куылган — нигә сугышырга? Язмышлар бер.

Х ә л и у л л а. Кызык син бүген, Алексей. Укытучылар кебек сөйләшәсең.

А л е к с е й. Юк, син көлмә, Хәллә. Безнең бабайлар бер-берсен хөрмәт итә белгәннәр. Сугыш чыгарырлык эш эшләмәгәннәр. Безнең тел — бөек тел, сезнең тел бәләкәй дип, ахмак сүз сөйләмәгәннәр.

Х ә л и у л л а. Син татарча миннән остарак сиптерәсең әле.

А л е к с е й. Яле, сал әле, Хәллә, чүт кенә итеп. *(Тотып куйгач.)* Да-а-а... Шулай шул, Хәллә, шулай. Аннан соң, Хәллә, син беләсеңме, безнең бабайлар ничаклы бергә яшәп, бер тапкыр да уртак туй ясамаганнар. Әтиләр дә андый эшне эшләмәгәннәр. Ни өчен?

Х ә л и у л л а. Әллә чыннан да?

А л е к с е й. Шулай, Хәллә. Руслар белән татарлар безнең авылда берәү дә бер-берсенә өйләнмәгән дә, кияүгә дә чыкмаган.

Х ә л и у л л а. Кара, чыннан да, әйеме? Минем дә ишеткәнем юк.

А л е к с е й. Арада яратышучылары да булгандыр инде юкса. Сезнең кызлар нинди чибәрләр, егетләрегез нинди. Без дә ямьсез халык түгел, күреп торасыз. Бер-берсенә күзләре төшкәндер инде. Ни өчен өйләнешмәгәннәр икән?

Х ә л и у л л а. Әкәмәт. Казанда өйләнешәләр инде анысы.

А л е к с е й. Син Казанны алма. Казан шәһәр шул. Шәһәрдә анда эт — баш, сыер — аяк. Берсен берсе белми дә, күрми дә. Кемгә өйләнгәнен дә, нәрсә сөйләгәнен дә чамаламый. Йөриләр өерелеп урам этләре шикелле. Бүген өйләнә, иртәгә аерыла. Авыл ул бүтән, монда берберeңнән башка яшәве читен. Монда мин сине көн саен күрәм. Монда өерелеп йөреп булмый.

Х ә л и у л л а. Шулай шул. Чыннан да, өйләнешүчеләр нигә булмады икән?

А л е к с е й. Нурхәмәт абый өйдәме соң?

Х ә л и у л л а. Өйдә. Йоклый.

А л е к с е й. Чакырыйк әле.

Х ә л и у л л а. Минем эчкәнне яратмый ул. Өйдә шешә күрсә, тавыш куптара.

А л е к с е й. Алып куй әле. *(Шешә, стаканнар яшерелгәч.)* Чакыр әле, Алексей дәшә, диген. *(Хәлиулла Нурхәмәт йоклый торган бүлмәгә кереп чыккач.)* Чыгамы?

Х ә л и у л л а. Хәзер. Сөйләшеп утырырга дисәң, ул...

Н у р х ә м ә т *(чыгып җитеп)*. Нихәл, Әләкчәй күрше?

А л е к с е й. Йокыңнан уяттым инде, Нурхәмәт абый.

Н у р х ә м ә т. Йоклыйсы көннәр алда әле безнең, Әләкчәй күрше. Нихәлләрдә?

А л е к с е й. Менә сөйләшеп утырабыз әле Хәлиулла белән.

Н у р х ә м ә т. Ярый-ярый, яхшы. Күрше белән күрше сөйләшеп утырса әйбәт ул, дөнья тыныч дигән сүз.

А л е к с е й. Менә бер сорауга җавап таба алмыйбыз әле, Нурхәмәт абый.

Н у р х ә м ә т. Бик четереклемени? Нәрсә, аракының да файдасы тимәдемени?

Х ә л и у л л а. Без әз генә.

А л е к с е й. Нурхәмәт абый... Менә безнең авылда руслар белән татарлар күпме яшәп бер тапкыр да берберсе белән өйләнешмәгәннәр. Болай гынамы ул, берәр хикмәте бармы?

Н у р х ә м ә т. Хикмәте бар, Әләкчәй күрше, хикмәте бар. Болай гына бернәрсә дә булмый бу дөньяда. Болай гына тавык тирәсендә әтәч тә йөрми.

А л е к с е й. Нәрсәдә инде аның хикмәте?

Н у р х ә м ә т. Нәрсәдәме? Синең мәрхүм әтиең белән сөйләшкән бар иде ул турыда. Аның хикмәте шунда. Әләкчәй күрше, тату яшәргә кирәк бит, талашып бергә яшәп булмый бит. Талашмас өчен шулай эшләгән безгә кадәргеләр. Без дә шулай эшләдек. Шулай тиеш.

А л е к с е й. Тиеш үкмени?

Н у р х ә м ә т. Тиеш. Ир белән хатын кем ул? Сез әйтәсез дә: муж и жена — адна сатана дип, адна сатанага әйләнгәнче алар башта аерым-аерым сатана бит әле. Башта һәрбересе үз ягын каера. Кайвакыт каера-каера каерып ук чыгаралар. Башта юктан гына тавыш чыга да ызгышка да әйләнә. Кызып китеп бер-берсенең начар якларын

санап бетергәч, нәсел-нәсәпләргә барып җитәләр. Кайчак ахмак ир белән юньсез хатынның җүләрлеге аркасында чыккан ызгыш туган-тумачаларына күчә. Китә талаш, китә сугыш.

А л е к с е й. Гел алай булмый инде.

Н у р х ә м ә т. Гел булмый, билгеле. Сезнең белән безгә берсе дә җитә, Әләкчәй күрше. Безгә кадәргеләр ара бозылудан курыкканнар. Ике җүләр арасында чыккан гауга зурга китсә, ни белән бетәсен чамалаганнар.

А л е к с е й. Язылмаган закон булган инде, алайса?

Н у р х ә м ә т. Булган, Әләкчәй күрше, булган. Беләсегез килсә, кешеләрне язылган законнар түгел, язылмаган законнар кеше итеп тота. Язылмаган законнарны бозсалар, кешеләр звиргә әйләнәләр. Хикмәте бар, Әләкчәй күрше, хикмәте бар.

А л е к с е й *(паузадан соң)*. Менә шуның өчен дә кердем бит әле, Нурхәмәт абый. Сез берни дә белмисезме?

Н у р х ә м ә т. Нәрсәне?

А л е к с е й. Илгизәр бернәрсә дә әйтмәдеме?

Н у р х ә м ә т. Миңа ул нәрсә әйтсен? Мине түгел, этисен дә санга сукмый ул.

Х ә л и у л л а. Нәрсә булган Илгизәргә?

А л е к с е й. Алар бит Вера белән өйләнешергә җыеналар.

Х ә л и у л л а. Ничек өйләнешергә?

А л е к с е й. Вера бүген кич белән әйтте, озакламый туебыз була, ди.

Н у р х ә м ә т. Ничек инде ул «туебыз була»?

Х ә л и у л л а *(Данияне чакырып)*. Дания, беләсеңме, Илгизәр белән...

Д а н и я. Ишетеп торам. Өйләнешсәләр ни булган?

Х ә л и у л л а. Сиңа әйттеме Илгизәр?

Д а н и я. Әйтсә әйткәндер инде...

Н у р х ә м ә т. Әтисе белми.

Д а н и я. Әткәй, син безнең семья эшенә кысылма. Урының җылыда. Син дә, Алексей, төн уртасында ах-ух килеп... Нәрсә булган ул хәтле? Яшьләр өйләнешә инде ул. Нәрсә, безнең белән кода буласыгыз килми мәллә?

А л е к с е й. Кодаларын кодалар да...

Д а н и я. Син безнең әткәйне тыңлама. Ул инде яшисен яшәгән. Хәзер инде бүтән замана. Яшьләр нишләргә кирәген үзләре беләләр.

Н у р х ә м ә т. Нәрсә беләләр, нәрсә беләләр? Аракы эчә беләләр.

Д а н и я. Син дә әүлия булмаган, әткәй, дәшми генә утыр. Тапканнар тавыш чыгарырлык нәрсә.

А л е к с е й. Без тавыш чыгармыйбыз, Дания күрше, уйлашабыз.

Д а н и я. Күп уйласагыз, тиз картаерсыз. Язылмаган закон дигән булып, юк-барны уйлап чыгарып утырасыз. Әнә безнең Рашат язылган закон буенча өйләнде. Татар кызына. Аның кебек иблисне дөньядан эзләп таба алмассың. Төкерәм мин аның татарлыгына.

А л е к с е й. Татарның татарлыгына син төкерсәң бер хәл, Дания. Менә мин төкерсәм, бик яман. Русның руслыгына син төкерсәң дә начар.

Д а н и я. Нәрсә, син каршымыни, Алексей? Татарга кызыңны бирәсең килмимени? Кимсенәсеңмени? Шулай дип өзеп әйт, нәрсә аны... Наташа да шулай диме? Шуны әйтергә сине кертеп җибәрдеме?

А л е к с е й. Туктале син, Дания күрше. Кинәт кенә бит.

Д а н и я. Малайларың, кызларың үсеп җитүе кинәт була инде ул. Кинәт беләсең инде ул. Безнекеләр, ярый әле, әйтеп торалар өйләнешәселәрен, кайсыларыныкы балалары тугач кына беләләр. Шунысына рәхмәт әйт. Миңа әйтте Илгизәр. Рөхсәт сорады. Уйлашырбыз, дидем. Нигә аңа күтәрелеп бәрелергә?

Х ә л и у л л а. Миңа да әйтергә була иде инде.

Д а н и я. Эштә идең. Эчеп кайткан идең. Укаң коелмас, әйткән булыр идем.

Х ә л и у л л а. Үзе кайда соң Илгизәр?

Д а н и я. Кайда булсын? Егет кешенең кайда булганы билгеле инде.

Н у р х ә м ә т. Егет. Авызыннан балавыз сарысы китмәгән. Бала-чагалар. Өйләнешкәч кем ашатыр дип уйлыйлар икән соң?

Д а н и я. Анысы синең кайгың түгел, әткәй.

А л е к с е й *(Нурхәмәтнең үз бүлмәсенә кереп баруын күреп)*. Нурхәмәт абый, тукта әле.

Д а н и я. Йокласын. Аның эше беткән инде, үзенекен өйләндергән. Менә нинди әйбәт килене бар. Дөньяда бер дигән. *(Көлә.)*

Н у р х ә м ә т. Бер дигән инде...

Д а н и я. Нәрсә, әллә ошамыймы? Татар кызы бит. Таптылар сөйләр сүз. Радиосын ачсаң — татар, телевизорын карасаң — татар. Сөйләргә сүзләре беткән диярсең. Аптырама, Алексей. Яшьләр әйткән белән генә бүген-иртәгә туй үткәрмәбез. Әйбәт итеп эшләрбез. Кешеләрнекеннән ким булмас. Үзләре табышканнар икән, бер-берсенә ярашканнар икән өйләнешсеннәр. Яраткан елан ите ашаган, ди. Менә мин дә яраттым — чыктым. Карап торырлык кыяфәте дә юк иде, нишлисең син, җүләр, диделәр. Мин чыктым. Аллага шөкер, менә дигән итеп егерме биш ел торабыз. Менә шул. Берсе үзсүзләнеп Чаллыга китте, ята хатынының колы булып. Монысын үз順ыбыздан җибәрде юк. Үзебезнең авыл кызын сайлаган — бик әйбәт. Бергә-бергә менә дигән итеп яшәрбез.

А л е к с е й. Безгә хәтле бит...

Д а н и я. Безгә хәтлесе безгә кирәкми, Алексей кода. Безгә үзебезнеке дә бик җиткән.

Н у р х ә м ә т *(ишекне ачып)*. Сез генә түгел дөньяда, бүтәннәр дә бар. Өч йөз елга чаклы сакланып килгән тәртипне нигә синең малаең гына бозарга тиеш? Башыңда миең бармы синең бераз?

А л е к с е й. Сезнең җирегездә сезнең белән талашып яшисем килми минем, күршеләр.

Д а н и я. Ә кем куша сиңа талашырга?

Ут сүнә. Сәхнә яктыртганда, Илгизәр белән В е р а өянке астындагы утыргычта утыралар. Сөйләшер сүзләр беткән, күрәсең, үбешеп алалар да тагын үз алларына карап утыра бирәләр.

В е р а *(тынлыкны бозып)*. Гел үбешәбез дә үбешәбез...

И л г и з ә р. Нишлисең инде тагын?

В е р а. Минем әти белән әни аптырап калдылар.

И л г и з ә р *(көлеп)*. Минем дә әни күзләрен акайтып миңа карап тора. Ул карап калды, мин чыгып киттем.

Көлешәләр дә үбешеп алалар.

В е р а. Әйткәч кызыгы да бетте. Әйтмәгән чакта кызыклырак иде. Әллә кияүгә чыкмаска инде? Чыгасы да килми башлады. Синең һаман да өйләнәсең киләме әле, Илгизәр?

Илгизәр. Килә.

Вера *(көйләп)*. Әй, илә-лә, илә-лә,
Өйләнәсем килә лә.
Өйләнәсе килгән егет
Кәҗә сатып өйләнә.

Әйдә, болай эшлибез, Илгизәр. Әнә син тегендә бас, әйеме? Мин – монда. Шуннан, күзләрне йомышып, кулларны сузып, кара-каршы киләбез. Әгәр дә кулларыбыз очрашса өйләнешәбез, очрашмаса өйләнешмибез.

Илгизәр. Өйләнешмичә нишлибез соң?

Вера. Анысын аннан соң уйлашырбыз. Әйдә.

Икесе сәхнәнең ике ягына басалар да, кулларын сузып, кара-каршы киләләр. Куллары очрашкач, кочаклашып үбешәләр.

Илгизәр. Әйттем бит.

Вера. Нәрсә әйттең?

Илгизәр. Өйләнешәбез, дидем.

Вера. Ә син күзләреңне йомган идеңме?

Илгизәр. Әллә ышанмыйсыңмы?

Вера. Әйдә тагын бер тапкыр.

Янә баягы уеннарын кабатлыйлар, янә куллары очраша, янә үбешәләр!

Илгизәр. Әйттем бит... Кара, Алексей абзый бездән чыгып бара. *(Өянке артына посалар.)* Ну, эш булды аларга. Туй, диләр инде, чабыша башлыйлар инде. Әтинең кирәген бирәчәк кенә инде әни, чаптырачак кына. Бабай гына утырачак, кем өйләнгән шул чапсын, дип. Гел акыл өйрәтә ул, туйдырып бетерә.

Вера. Минем авылда да каласым килми инде.

Илгизәр. Ә кем кала авылда? Китәбез Чаллыга, абый янына китәбез.

Вера. Әниең әйтә дисең ич, авылда калдырам, дип әйтә, дисең.

Илгизәр. Аның сүзенә карасаң... Китәбез дә барабыз. Бер тузыныр да бетәр.

Вера. Синең армиягә дә барасың бар.

Илгизәр. Әй, бер ел бар әле аңа.

Вера. Әгәр дә армиядән кайткач өйләнешсәк?

Илгизәр. Әй, аңынчы... Бәлки әле, алмаслар да.

Вера. Ничек инде алмаслар?

Илгизәр. Радиодан әйттеләр. Армия бетә, диделәр.

Вера. Радио әйткәнгә ышансаң... Син мине яратасыңмы, Илгизәр?

Илгизәр. Ну, бәйләнәсең син, әйеме? *(Вераны кочаклап үбә.)*

Ут сүнә. Ут янганда, Хәлиуллалар өендә туй. Өстәлләрдә – ризык, шешәләр. Өстәл янында кунаклар. Алгы планда Нурхәмәт белән Мария янәшә утыралар. Түрдә кияү белән кәләш, ягъни мәсәлән, Илгизәр белән Вера урыны буш. Анда әлеге дә баягы Туй агасы басып тора.

Туй агасы. Внимание! Тынлык! Карагыз аны, барыгыз да мине тыңлагыз. Бу туй, иптәшләр-товаришлар, башка туйлар төсле булмаячак. По-новому будем проводить свадьбу.

Дания. Ашыкма, сабыр ит, кунаклар килеп бетмәде әле.

Туй агасы. Күпме көтәргә була? Ике сәгать көттек – җитте. Нишлибез, җәмәгать, көтәбезме-юкмы? Будем ждать или нет?

Дания *(Туй агасын җитәкләп алга килә)*. Син нәрсә кыландырасың? Монда барысы да татарча белә.

Туй агасы. Барысы да русча да беләләр. Интернациональ туй булгач, интернациональ булсын. Ике якка да тигез булсын. Үзең бит миннән Туй агасы булырга сорадың, Дания апа. Теләмәсәгез, көчләп килмәдем.

Дания. Ярар, үпкәләргә торма.

Туй агасы. Башлыйк инде. Киләсе кеше килгәндер инде. Килсәләр, урын күп, матур итеп утыртырмын.

Дания. Ярар, әйдә. Килмәсәләр, чукынып китсеннәр. *(Натальяны чакырып алып.)* Башлыйбызмы, Наташа? Килмәгәннәрне көтеп утырып булмас.

Наталья. Башлыйк.

Дания *(Туй агасына)*. Әйдә.

Үзләре утырышалар.

Туй агасы *(түр башына барып)*. Внимание! Тынлык! Без монда хуҗалар белән киңәшмә-совещание үткәрдек тә туйны башлап җибәрергә булдык. Внимание! Начали!

Гармунчы туш уйный. Шаһитлар, кияү белән кәләшнең кулларыннан тотып, тантаналы рәвештә алып керәләр, өстәл башына утырталар. Кул чабучылар да бар.

Кияү белән кәләш! Жених и невеста. Поздравляю вас с вашим самым великим днём! Сезнең икегезгә дә ак бәхетләр телим һәм беренче сүзне кияүнең әтисенә бирәм.

Х ә л и у л л а *(торып)*. Мин нәрсә әйтим инде? Мин сүз әйтә белмим бит.

Д а н и я. Әйт инде, нәрсә... Әйбәт яшәгез, диген. Котлыйм, диген.

Х ә л и у л л а. Әйбәт яшәгез, балалар. Котлыйм! Әйдәгез, кунаклар, җитешегез әле. Өстәлдә бары белән.

Т у й  а г а с ы. Стоп! Ашауга иртәрәк. Сүз – кәләшнең әтисенә!.. Прошу.

А л е к с е й *(тора да өстәл янында утыручыларны карашы белән барлап чыга)*. Авылдашлар! Рәхмәт килгәнегезгә. Безне санга сугып килгәнегезгә рәхмәт. Менә безнең балаларның туе инде бу. Туйга килгәнегезгә тагын бер рәхмәт. *(Илгизәр белән Верага озак итеп карап торганнан соң.)* Менә безнең балалар инде болар. Илгизәр кияү белән Вера кызым. Нәрсә әйтим инде сезгә? Котлыйм инде, билгеле... Нинди теләк телим? Теләгем шул гына инде, әйбәт яшәгез, безнең йөзгә оят китерә күрмәгез, менә шул инде безнең теләкләр. *(Кулындагы чәркәсен тоткан килеш уйланып басып тора.)*

Т у й  а г а с ы. Тост. Тост әйт, Алексей Степаныч.

А л е к с е й. Тост! Менә шул теләкләр кабул булсын өчен күтәрик инде.

Т у й  а г а с ы. Урра! Кем дә кем шул теләкләр кабул булсын ди, шул иптәшләр кулларын, гафу итегез, рюмкаларын күтәрәләр. Молодцы. Туй бара, туй дәвам итә. Өченче тост өчен сүзне ике свидетельнең берсенә бирәбез. Рәхим итегез, свидетельләр, прошу, кайсыгыз әйтә?

Шаһитлар икесе дә торып басалар.

Ш а һ и т  к ы з. Без икебез дә әйтәбез.

Т у й  а г а с ы. Пожалысты. Баш өсте. Бүтән булса, каршы килер иде, мин –юк.

Ш а һ и т л а р *(алдан әзерләп куйган кәгазьне алып, икәүләп шуны укыйлар)*. Дорогие Вера и Илгизәр! Кадерле Вера һәм Илгизәр!

Мы вас крепко поздравляем,
Семейной дружбы желаем.
Живите вместе долго-долго,
Растите детей много-много,

Друг друга уважайте,
Радостных дней умножайте,
Если печаль придет,
Пусть она обратно уйдет.
Вы теперь муж и жена,
Пусть мужа любит она,
Пусть и он любит жену,
Пусть любит только одну.
*(Җырга күчеп.)* Сокланып карап туймаслык
Зифа буегызга да;
Онытмагыз чакырырга
Бәби туегызга да.
Алсу йөзле, зәңгәр күзле
Балалар үстерегез;
Туган илгә матур кызлар,
Батыр уллар бирегез.

Җырлап туктыйлар да утыралар.

Туй агасы. Кем дә кем шаһитларның сүзләренә кушыла, шул иптәшләр кулларына рюмка тотып төшереп куя. *(Үзе дә чәркәсен эчеп куйгач.)* Ә хәзер ашап алырга рөхсәт. *(Утыра.)*

Берара тавыш-тынсыз гына ашыйлар. Кашык-чәнечкенең тәлинкәгә бәрелгәне, тәмле итеп чәйнәгән, йөткергән, борын тартып алган тавышлар гына ишетелә. Ләкин рәхәтләнеп ашаганда гына Туй агасы тагын сикереп тора.

Иптәшләр! Внимание! Туйга килсәң, туеп кил дигән мәкальне ишеткәнегез бармы? Ишетсәгез шул, рюмкаларны, ягъни мәсәлән, чәркәләрне тутырыгыз. Сүзне кемгә бирәбез? Сүзне кияүнең әнисенә, Дания апага бирәбез.

Дания *(кияү белән кәләш янына ук килеп).* Минем кадерле улым Илгизәр, минем кадерле кызым Вера!.. Мин сезгә бүген шуны телим: бәхетле булыгыз. Кызым Вера, мин сиңа «кызым» дип кенә дәшәрмен. Без һәрвакытта да күршеләр булдык, бик тату яшәдек. Киләчәктә дә шулай яшәрбез. Без хәзер туганлаштык. Кадерле кода Алексей, кадерле кодагый Наташа, мин сезгә телим озын гомер, шатлык, куаныч. Әйдәгез, кадерле кунаклар, безнең улыбыз белән кызыбызның бәхете өчен күтәреп куйыйк әле.

Чәркәләр күтәрелгәндә, Нинаның әче тавышы яңгырый.

Н и н а. Горько!.. Горько!..

Аңа тагын кемнәрдер кушыла. Илгизәр белән Вера, урыннарыннан торып, гадәттәгечә үбешәләр. Н у р х ә м ә т урыныннан торып чыгып китә. Сәхнәдәге яктылык аның белән бергә карт өянке астындагы утыргычка күчә. Нурхәмәт бераз утыргач, аның янына М а р и я чыгып урнаша.

М а р и я *(паузадан соң)*. Шулай инде, Нурхәмәт күрше...

Н у р х ә м ә т. Кода, диген.

М а р и я. Кода. Хәерле булсын инде, Нурхәмәт кода.

Н у р х ә м ә т. Хәерле булмый нишләсен? Бабалары алдында лачкылдатып үбешкәч хәерле була инде. Аннары этләр кебек синең белән минем каршыда өегешә үк башларлар. Шуннан хәерле була инде.

М а р и я. Син нигә әле мине гаепләгән кебек сөйлисең?

Н у р х ә м ә т. Нишләп сине гаеплим? Мин үземне гаеплим. Бездән туганнан туганнар бит алар. Безнең дә синең белән үбешкән булды. Безнең үбешкәнне кеше түгел, ай да күрмәде. Инеш юлындагы шомыртлар гына күрделәр.

М а р и я. Без бит синең белән ир белән хатын түгел идек.

Н у р х ә м ә т. Нәрсә, ир белән хатын булгач, кеше алдында чишенеп, өстәл өстенә менеп ятаргамы?

М а р и я. Туйда үбешү электән калган йола инде.

Н у р х ә м ә т. Сездә калган ул, бездә түгел. Сезнең туегызда үбешкәнне мин үзем дә рәхәтләнеп карап утырам. Сездә аны килешле итеп эшлиләр. «Горько» дигән сүзе дә бар. Бездә бит аның сүзе дә юк.

М а р и я. Монда сезнең туй гына түгел бит инде.

Пауза.

Н у р х ә м ә т. Түгел шул, Маруся, түгел шул.

М а р и я. Нишлисең инде хәзер? Яши генә күрсеннәр инде. Бигрәк яшьләр шул әле.

Н у р х ә м ә т. Эш яшьлектә түгел монда, Маруся, башсызлыкта.

М а р и я. Дөньясы буталды шул.

Н у р х ә м ә т. Буталмады. Бутадылар.

М а р и я. Да-а-а. Боже мой, боже мой…

Н у р х ә м ә т. Гуспади пумилуй, диярсең әле, Маруся кодагый.

М а р и я. Ярый, әйдә, кереп утырыйк, йә әллә ни уйларлар.

Н у р х ә м ә т. Кем уйлый? Синең белән мине оныттылар инде алар. Шайтан туена синең белән мин кирәкме? Менә әлегә үзебезне үзебез йөртәбез, Маруся. Алар кулына калырга язмасын. Картлар йортына илтеп ыргытачаклар. Вәт шунда булыр бужы муй, бужы муй.

М а р и я. Йә инде, нәрсә инде син? Нишлик, үликмени? Яшәргә кирәк ләбаса.

Н у р х ә м ә т. Ачуланма инде, Маруся күрше.

М а р и я. Ачуланмыйм да. Туй көнендә болай әллә ничек. Бер алар гына түгел.

Н у р х ә м ә т *(туйдан китеп барган бер ир белән хатынны күреп)*. Нишләп бик тизләдегез, Салихҗан? Туй яңа башланды гына.

Б е р е н ч е  и р. Красноярскидан кунаклар кайтканые да, үзләре генә. Тиз кайтабыз дип киткән идек.

Н у р х ә м ә т. Бераз көтәрләр иде әле.

Б е р е н ч е  и р. Кунак көттерү әллә ничек шул, Нурхәмәт абый. Табын ташлап килгән идек.

Н у р х ә м ә т. Шулаен шулай да…

Б е р е н ч е  х а т ы н. Ике сәгать буш урындык саклап утырганга без гаепле түгел инде. *(Иренә.)* Әйдә.

Б е р е н ч е  и р. Сау булыгыз, Нурхәмәт абый. Сау булыгыз, Маруся апа.

Н у р х ә м ә т. Сау булыгыз, сау булыгыз… Хатын-кыз азды, Маруся. Кара, ире адәм рәтле сөйләшә, хатыны пуләмит кебек тырылдый. Шулай, Маруся.

Мәскәүски Маручкалар
Кияләр саручкалар;
Көн дә шулай гүләйт итсәк,
Җитмәс шул палучкалар

диген, ә, Маруся кодагый?

Әйдә, Маруся, күрше, мать якасын. Керик, гүләйт итик.

Өйдә туй дәвам итә. Яшь-җилкенчәк магнитофоннан яңгыраган заман ритмына «танцавайт» итә. Өлкәнрәкләр бер-берсенә тотынышып селкенәләр. Шунда Ислам магнитофонны кинәт сүндерә.

Т у й  а г а с ы *(Ислам янына килеп)*. Нигә туктаттың манитофонны? Син хуҗамы монда, минме?

И с л а м. Син тик тор, агай-эне, яме? Нәрсә һаман урыс җыры җырлатасың? Бу бит сиңа урыс туе түгел, белдеңме?

Т у й  а г а с ы. Син, белмәсәң, тик кенә тор, ярыймы? Урыс җыры түгел бу, беләсең килсә.

И с л а м. Кем җыры соң? Әллә татар җырымы?

Т у й  а г а с ы. Бу – Америка ансамбле, беләсең килсә.

И с л а м. Миңа барыбер, белдеңме? Нигә син татарча җырлатмыйсың, ә, нигә җырлатмыйсың? Урыс булдыңмыни?

Д а н и я *(Исламга килеп ябышып)*. Син эчсәң, буеңа сеңдер, Ислам.

И с л а м. Эчермәгәч тә ник чакырдың соң?

Д а н и я. Чакыргач, дуңгыз булганчы эчеп тавыш чыгарыргамыни?

И с л а м. Кем дуңгыз булган, кем? Җырлыйсым килә минем, белдеңме?

Д а н и я. Бик ишетәселәре килә ди синең үкергәнеңне.

И с л а м. Нигә син минем җырымнан көләсең, ә?

Н а т а л ь я *(килеп)*. Нәрсә, Ислам, әллә җырлатмыйлармы? *(Исламны кочаклап алып.)* Әйдә, җырлыйбыз.

И с л а м. Мин кеше белән җырлый белмим, мин үзем генә җырлыйм.

Н а т а л ь я. Әйдә, җырла.

И с л а м. Хәзер инде әпититне бетерделәр.

Н а т а л ь я. Үзем җырлыйммы синең җырыңны?

И с л а м. Әллә беләсең?

Н а т а л ь я. Беләм, билгеле. Ничек инде ул синең җырыңны белмәскә?!

И с л а м. Яле-яле. Тыңлап карыйм әле.

Н а т а л ь я *(җырлый)*.

Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә.

И с л а м *(Наталья алдына тезләнеп)*. Их, Наташа!.. Җанкисәгем!..

Н а т а л ь я. Бүлдермә, Ислам.

Беләсеңме, дустым, сизәсеңме
Аерылулар килеп җиткәнен?

Кыр казы
Суларда уйный шул,
Ялгыз башым гел сине уйлыйм.

Булдымы, Ислам?

Ислам. Мәңге онытмам, Наташа!.. Наташа!.. Бәгырькәем! Менә бу ичмасам җыр дисәң дә җыр. *(Туй агасына.)* Ә син, завклуб дигәч тә, командовать итмә, белдеңме?

Туй агасы. Белдем-белдем. Ярый, бар, утыр. Внимание! Барыгызга да утырырга. По коням! Тутырдыгызмы чәркәләрне? Сүзне Наталья Васильевнага бирәбез. Рәхим итегез, Наталья Васильевна. Пажалысты.

Наталья. Әйтеләсе сүзләр әйтелде бугай инде. Авылдашларыма гына әйтәсе сүзем бар барын. Әйтим микән? Әйтимме, Алёша? Әй, әйтим әле. Гаепләмәгез инде сез безне, авылдашлар. Не обессудьте нас, дорогие мои.

Тавышлар. Нигә гаепләргә?.. Син нәрсә?.. Рәхмәт чакырганыгызга...

Наталья. Так уж получилось, дорогие мои. *(Эченнән генә җылап алганнан соң.)* Давайте, выпьем за всё хорошее, что было в нашей жизни.

Нина. Горько!.. Горько!..

Ислам *(сикереп торып)*. Горько булса, тышка чык та үбешеп кер, белдеңме? Нәрсә кеше үбешкәнгә кызыгып утырасың?

Нина. Әйдә, минем белән чыгасыңмы соң?

Ислам. Чыкты диярләр.

Нина. Их ты, трус! Куркак. Үзең кычкырып утырган буласың. Чего ты хорохоришься-то? Урыс туе түгел, урыс туе түгел. Какая тебе разница? Вот я выйду да попляшу, что ты скажешь? Запретишь, что ли? *(Частушкалар әйтә-әйтә, биергә тотына.)*

Я девчонка боевая,
В себе уверена;
Глазки вниз не опускаю, —
Совесть не потеряна.
Говорят, что я горда —
По-гордому ответила:
Любить тебя, гулять с тобой
Я плана не наметила.

У стола четыре ножки,
У лоханки только три;
Всем ты миленький, хороший,
Только носик свой утри.
Ой, с характером милёнок,
Не могу его понять:
То заржет, как жеребёнок,
То захнычет – не унять.

*(Биеп, Ислам янына бара. Аны сөйрәп чыгара, муенын каерып үбә дә аяк чалып ега. Көлеш беткәч.)* Менә, җанкисәгем, марҗалар шулай эшли ул, белдеңме? Йә, тагын ни әйтәсең?

Ислам *(аптырап калган)*. Мин сиңа күрсәтермен әле, белдеңме?

Нина. Күрсәт-күрсәт. Күрик әле, хатының ни өчен аерылып китте икән? Менә мин синең кебек дуракны куып чыгардым.

Туй агасы. Тихо! Туй дәвам итә. Тагын сүз әйтергә теләгән иптәшләр бармы? Әгәр дә сүз әйтергә теләүчеләр булса, миңа заявка бирсеннәр. Ә хәзер танца.

Магнитофонны кабыза. Селкенеш башлана. Ут өянкене яктырта. Анда Алексей белән Хәлиулла тәмәке тартып утыралар.

Алексей. Син берне дә тотып куймадың, ахры?

Хәлиулла. Малай туенда килешми. Әти дә шунда...

Алексей. Да-а-а... Шәп кешеләр сез, Хәллә.

Хәлиулла. Кеше кеше инде, Алексей. Сезнең дә начар чагыгызны күргәнем юк.

Алексей. Менә бу өянкегә ничә яшь, беләсеңме? Йөз яшьтән дә ким түгел. Аны синең прадед белән минем прадед утырткannнар. Ике арага. Бергә карап үстергәннәр. Элек бит сезнең йорт урыны белән безнең йорт урыны бушлык булган. Безнең авылны икегә аерып торган ул бушлык. Аннан безнең бабайларның әтиләре сөйләшеп йорт җиткергәннәр, ике арага шушы өянкене утыртканнар. Аның мәгънәсе бар, бәйләп тора. Ике йортка бер өянке, өянке астында ике йортка бер утыргыч. Хәзер инде менә кодалар булдык.

Хәлиулла. Ислам гына әллә нишли әле.

Алексей. Ислам гел шулай инде ул.

Хәлиулла. Чакырмыйк, дигән иде Дания. Чакырмасаң, үзе килеп керә.

А л е к с е й. Ислам гел шундый, Хәллә. Элек аның әйткәннәрен ишетми дә идек, бүген ишетелә. Хәзер шаярып әйткәне дә усал булып ишетелә. Безгә ияләшергә кирәк инде яңадан. Яңабаштан ияләшергә кирәк. *(Ир белән хатынның китеп барганнарын күреп.)* Чего вы, Стёпа?

И к е н ч е  и р. Чего? Пора, Алёша. Пусть молодые-то танцуют. Нам-то чего? Спасибо за приглашение. Рәхмәт, Хәллә.

Х ә л и у л л а. Иртә бит әле, Степан.

И к е н ч е  х а т ы н. Иртәгә иртүк торасы бар. Пошли, Степан, пошли. *(Китәләр.)*

А л е к с е й. Таралып бетәләр.

Болганып, И с л а м чыкканы күренә. Алексей белән Хәлиулла каршына басып карап тора.

И с л а м. Утырабыз дисез инде, әйеме? Утырыгыз, утыр. Ә мин китәм.

А л е к с е й. Утырырга иде әле бераз.

И с л а м. Юк. Туй түгел бу. Как хош, Алексей, туй түгел. Туй түгел бу, Хәллә.

Х ә л и у л л а. Нәрсә, аракы җитмәде мәллә, Ислам?

И с л а м. Төкерәм мин синең аракыңа, белдеңме?! Туйга аракы эчәр өчен йөриммени мин? Мин кешеләрнең ничек итеп бер-берсен яратышканнарын күрер өчен йөрим. Үзем алардан көнләшәм, үземә рәхәт.

Х ә л и у л л а. Ярый, сау бул инде, алайса. Килүеңә рәхмәт.

И с л а м. Алдашма, Хәллә. Минем килгәнемә сөенмәдең, киткәнемә сөенәсең син. Вот так, Хәллә. Вот так, Алексей. Җырлыйммы?

Х ә л и у л л а. Ишеткәнем бар инде җырлаганыңны.

И с л а м. Юк, аны җырламыйм мин. Ул җырны мин кадерләп кенә саклыйм, белдеңме? Мин сезгә бүтән җыр җырлыйм, белдеңме?

Ай, җаный, вай, җаный,
Татар үпкән марҗаный.
Нигә үпмәсен марҗаный,
Марҗаның да бар җаный.

Ак мунчага як мунча,
Тимә, сызылып тик янсын.
Ак мунчада үп марҗаны,
Спачибы дип калсын.

Вот так, Хәллә.

Хәлиулла тора да Исламның йөзенә суга.

Алексей. Нишләдең син, Хәллә?! Нишләдең, күрше?!

Ә өйдә туй дәвам итә. Магнитофон үкерә дә үкерә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хәлиуллалар өе. Туй узган. Табын җыештырылган. Өстәлләр генә үз урыннарында түгел. Өстәл башында каракаршы Нурхәмәт белән Хәлиулла утыралар.

Нурхәмәт. Дәшмә!.. Синең урыныңда мин булсам… Син беләсеңме шуны, безнең нәселдә кешегә кул күтәреп суккан кеше булмаган. Син башладың.

Хәлиулла. Йә, нәрсә инде… Түзмәдем. Каршыда ырҗаеп тора. Сизми дә калдым.

Нурхәмәт. Бүтән вакытта каршыңда гел көлеп кенә тордыlargeмыни?

Хәлиулла. Монда бит… Алексей да шунда.

Нурхәмәт. Алексей сукмаган бит.

Хәлиулла. Ничек инде Алексей суксын, аңа килешми дә.

Нурхәмәт. Сиңа килешә.

Хәлиулла. Ярый, булды инде, булды. Каныма тоз салма. Болай да… Ничаклы акча түгеп туй ясап. Чакырган кунакның яртысы килмәде. Килгәннәре дә туй беткәнче таралды. Туй булмады инде бу, әллә нәрсә булды.

Нурхәмәт. Хатын сүзе белән йөрсәң шулай була инде ул.

Дания *(бер бүлмәдән атылып чыгып)*. Нәрсә хатын сүзе белән? Нәрсә булган ул хәтле? Аптырагансыз икән. Суккан-суккан, нәрсә ахылдап утырасыз. Телен тыя белсен. Килмәгәннәр икән чакырып, килмәсеннәр, мәтәлеп китсеннәр. Татар тәресенең шул булыр инде аның, үзенүзе әллә кемгә куеп…

Н у р х ә м ә т. Татар тәреләре генә түгел, урыс тәреләренең дә бик күбесе килмәде.

Д а н и я. Килмәгәйләре. Чукынып китсеннәр. *(Хәлиуллага.)* Кодаларның өстәлләрен кертергә кирәк. Нәрсә тәресен югалткан урыс кебек утырасың?

Х ә л и у л л а. Сүзеңне үлчәп сөйлә инде, ичмасам.

Д а н и я. Минем барысы да үлчәнгән. *(Хәлиуллага.)* Тот, әйдә.

Бер өстәлне икесе ике башыннан тотып алып чыгып китәләр. Үз бүлмәләреннән эчке күлмәктән генә В е р а чыгып тышкы ишеккә үтеп китә. Аның артыннан трусиктан гына И л г и з ә р чыга.

И л г и з ә р. Әниләр кайда соң?

Н у р х ә м ә т. Синең, нәрсә, кияргә ыштаның юк мәллә?

И л г и з ә р. Бәйләнмәле. *(Кереп чалбарын киеп чыга. Чалбарын кия-кия.)* Әниләр кайда китте ул?

Н у р х ә м ә т. Хатының урамга ялангач чыгып китте. Бар, күлмәк чыгарып бир. Әйт үзенә, минем алда ялангач йөрмәсен.

И л г и з ә р. Ялангач түгел ич ул. Әллә күзең күрмиме?

Н у р х ә м ә т. Бик әйбәт күрә минем күзем. Минем күзем күрмәсә, син бүген бу дөньяда булмас идең. Хәзер син олы кеше булдың инде. Симия башы. Малай булып йөрү килешмәс.

И л г и з ә р. Әниләр кайда ул?

Н у р х ә м ә т. Синең туеңнан соң өй җыештыралар. Син йоклап ятасың.

И л г и з ә р. Бәйләнмә инде. Әни әйтеп тора бит сиңа, урыныңда гына утыр, дип.

А л е к с е й *(кереп)*. Мөмкинме? Нихәл, Нурхәмәт абый. *(Илгизәргә.)* Син нихәл?

И л г и з ә р. Яхшы.

Н у р х ә м ә т. Шөкер, Әләкчәй. Әйдә, уз.

А л е к с е й. Узып тормыйм. Менә булышырга кирәк. Бүген бездә җыелабыздыр инде.

Н у р х ә м ә т. Көн дә бәйрәм, көн дә туй диген...

А л е к с е й. Шулай инде, нишлисең. *(Тыштан кереп килгән Вераны күреп.)* Син нишләп болай йөрисең?

В е р а. А чё?

А л е к с е й. Чё, чё... Голая... Голову, что ли, потеряла?

В е р а. Ну уж... *(Бүлмәләренә кереп китә, аңа Илгизәр иярә.)*

А л е к с е й. Син ачуланма инде, Нурхәмәт абый.

Н у р х ә м ә т. Ачуланып нишлисең инде, Әләкчәй. Бер синең кызың гына түгел. Оят югалды бит ул хәзер. Телевизорларда анадан тума йөрергә өйрәткәч, болар нишләсен инде?

А л е к с е й *(Нурхәмәт янына утырып)*. Нурхәмәт абый, үзеңә генә әйтеп куйыйм, ул-бу булса, тәмсезләшмик, ярыймы?

Н у р х ә м ә т. Нәрсә булсын...

А л е к с е й. Дөресен әйтәм, бергә яшәүләренә ышанмыйм мин.

Н у р х ә м ә т. Кызың турында андый сүз сөйләмә. Син — ата кеше.

А л е к с е й. Шулай инде... Ата инде. Башсыз бер курчак үстер дә, нинди ата? Иткә тапшырасы үгезне печкән шикелле, безне печәргә кирәк булган, Нурхәмәт абый.

Н у р х ә м ә т. Әниең ни хәлдә?

А л е к с е й. Аның да кәефе юк, Наташаның да... Вообшем, юк инде, Нурхәмәт абый. *(Өстәл күтәреп чыгып китә.)*

Д а н и я белән Х ә л и у л л а кайталар.

Д а н и я *(Хәлиуллага)*. Бирәнең булгандыр. Шунда кергәч тә эчмәсәң.

Х ә л и у л л а. Эчмәдем ич мин, тотып кына куйдым.

Д а н и я. Куйдың! Беләм мин синең куйганыңны. Миңа гына дигәнмени җыештырырга, чабарга?..

Х ә л и у л л а. Туй, туй, дип, үзең кычкырдың, җыештырырсың инде.

Д а н и я. Эчмәдем дигән була, теле ачылды.

И л г и з ә р *(чыгып)*. Әни, ашыйсы килә. Кая йөрисең инде?

Д а н и я. Тордыгызмы?

И л г и з ә р. Әллә кайчан инде. Ашыйсы килә.

Д а н и я. Килен кайда? Нигә күренми?

И л г и з ә р. Нинди килен?

Д а н и я. Аңгыра. Вераны әйтәм.

И л г и з ә р. Ул киенә.

Д а н и я. Әйт хатыныңа, чәй куйсын. Әнә теге

бүлмәдә өстәл тулы ризык. *(Хәлиуллага.)* Әйдә, ал урындыкларны, нәрсә терәлеп каттың?

Ислам *(кереп)*. Ярыймы керергә?

Дания *(аның каршына килеп куып)*. Бар, бар, эзең булмасын. Күземә күренмә.

Ислам *(Данияне читкә этеп)*. Туктале. Синең янга килмәдем, белдеңме?!

Дания. Чыгып кит, диләр сиңа!

Ислам. Хәллә, әйт әле аждаһаңа берәр сүз.

Дания *(Исламга ябышып)*. Бирермен мин сиңа аждаһа, зимагур!

Ислам. Хәллә, кичә миңа суккан кебек тамыз әле шуңа берне.

Хәлиулла. Дания!.. Дания, кемгә әйтәләр?!

Дания *(Исламны этеп җибәреп)*. Күрсәтермен әле мин сиңа. *(Урындыкларны алып, пырлап чыгып китә.)*

Ислам. Ай-яй! Ничек яшисең син моның белән? Шул гомер? Мин аны әллә кайчан кыйнап үтергән булыр идем. Нурхәмәт абый, нихәл?

Нурхәмәт. Саумы!

Ислам. Савын сау да. Кичә Хәллә бик каты сылады бит әле, белдеңме? Борынның карарлыгы юк бүген. *(Хәлләгә.)* Йодрык саллы икән үзеңнең.

Нурхәмәт. Син ямьсезләнеп йөрмә инде, Ислам туган. Үзең гаепле.

Ислам. Ә мин гаепле булганга килдем дә, Нурхәмәт абый. Мин гаебемне Хәллә суккач та аңладым. Гаепсез булсам, Хәлиулланың сөяген генә җыеп алган булыр идегез. *(Хәлиуллага.)* Кинә кума, ярыймы, Хәллә? Мин әйттем — син суктың. Квит. Бир кулыңны.

Хәлиулла кулын суза — килешәләр. Ислам Нурхәмәт янына барып утыра.

Әмма дә ләкин шунысы бар, Нурхәмәт абый, җырны бит мин чыгармаган. Мин чыгарган җыр түгел бит ул, белдеңме?

Нурхәмәт. Бөтен җырны да җырлап йөрергә димәгән.

Ислам. Җырланмый торган җырны кеше чыгармый.

Хәлиулла. Бар әле, Ислам, безнең эш күп.

Ислам. Ә мин мишәйт итмим. Мин Нурхәмәт абый белән... Син эшлә. Син, Хәллә, эшләр өчен генә яра-

тылган җан иясе. Синең кебек дураклар булмаса, болай бөлми идек без, белдеңме? Эшлә син, эшлә, Хәллә, Нурхәмәт абый инде эшлисен эшләгән, минем дә стаж нормальный.

Н у р х ә м ә т. Пенсия ала, диләр, дөресме?

И с л а м. Дөрес бит, Нурхәмәт абый. Синең киленең зимагур дигәч тә. Шундый эшләр бар, Нурхәмәт абый, илледән пенсиягә чыгасың да үлем көтеп йөрисең. Менә мин дә үләргә авылга кайттым. *(Хәлиулла урындыклар алып чыгып киткәч.)* Чәй куеп эчер димим инде, Нурхәмәт абый. Берәр буш стакан бир әле.

Н у р х ә м ә т. Өегездә стакан булмадымыни?

И с л а м. Күп сөйләмә инде. *(Кесәсеннән шешә чыгара да Нурхәмәт алып килгән стаканга салып эчә.)* Берәр ипи катысы да бир инде. *(Нурхәмәт теләр-теләмәс кенә ипи телеме алып килеп бирә. Ислам көлеп куя.)* Теләнчегә биргән кебек, ә?

Н у р х ә м ә т. Чакырылган кунагым түгел, гаеп итмә, Ислам туган.

И с л а м. Да-а... Син менә шуны әйт әле, Нурхәмәт абый. Утыз өч ел буе мич башында яткан Илья Муромецны кем ашаткан?

Н у р х ә м ә т. Кем соң ул Илия Муромис?

И с л а м. Авылга лектор-фәлән килсә сора: кем ул Илья Муромец, диген. Утыз өч ел эшләмичә мич башында яткан Илья Муромецны кем эшләп ашаткан диген... Үзең акыллы да кеше син, Нурхәмәт абый. Нәселегез тәртипле. Безнең ише зимагур нәсел түгел. Ләкин бөтенесен уйлап бетермисең. Әгәр дә дөньясын бер урап кайтсаң, Әбүгалисина булыр идең.

Н у р х ә м ә т. Без урыйсын урадык. Герман җирләреннән урап кайттык.

И с л а м. Анысы шулай, шулай. Гафу ит, Нурхәмәт абый. *(Үз бүлмәләреннән киенеп-ясанып чыккан Илгизәр белән Верага.)* Сез ни хәлләрдә, тутый кошлар? Йокы туйдымы? *(Илгизәр белән Вера исәнләшмичә дә чыгып киткәч.)* Шулай. Дөнья бервакыт шундый өйрәтә, Нурхәмәт абый, дуңгызга иелеп сәлам бирә башлыйсың... Ярый, ачуланма, киттем мин. Хәлләдән гафу үтенергә дип кенә килгән идем. Ну, барыбер дөрес эшләмәдегез сез, Нурхәмәт абый. Безнең авылда иң беренче булып сезнең нәсел чикне бозды. Урыс белән туганлаштыгыз.

Минем урыска бер дошманлыгым юк, белдеңме? Мин күп йөрдем, күпне күрдем, татарны яратмый урыс, белдеңме? Наданнар сез. Без урыс белән кушыла алмыйбыз. Урыс белән янәшә генә яши алабыз. Син марҗага өйләнгән бер татарның баласына татар исемен кушканын ишеткәнең бармы? Урыска кияүгә чыккан татар хатынының баласы әнисенә «әни» дип әйтәме? Урыс татар белән татарны йотар өчен генә туганлаша, белдеңме? Наданнар сез. Нигә бүгенге көнгә хәтле безнең авылда бер татар да бер марҗага өйләнмәгән, нигә бер урыс та бер татар кызын алмаган? Нәрсә, алар сездән дураграк булганнар мәллә? Юк, бер-берсен бик яхшы белгәннәр алар. Кушылырга ярамаганны белгәннәр.

Н у р х ә м ә т. Бар әле, энем, бар, өеңә кайт.

И с л а м. Кайтам. Ләкин шуны белегез, марҗасын алып авылдан китсен бу аңгыра бәрәнегез. Көн күрсәтмәячәкмен мин аңа. *(Ишеккә бара. Анда ишектән килеп керүче Хәлиулла һәм Алексей белән очраша.)* Нихәл, Алексей?

А л е к с е й. Яхшы.

И с л а м. Син миңа ачуланма, яме.

А л е к с е й. Нигә ачуланыйм?

И с л а м. Минем сиңа дошманлыгым юк.

А л е к с е й. Минем дә.

Ут сүнә. Яктырганда, өянке төбендәге утыргычта М а р и я утыра, Уйларына чумган. Н и н а үтеп барышлый аның янына туктый.

Н и н а. Здравствуй, бабка Мария.

М а р и я. Да вот сижу, Нинуленька, сижу и думаю.

Н и н а. О чём это думаешь-то, если не секрет?

М а р и я. Чё уж тут секретничать-то. В мои-то года…

Н и н а. Твои года — твое богатство инде. Сездә туй дип ишеткән идем дә, бер дә тавыш-фәлән ишетелми. Туйны сездә уздырмаска булдыгызмыни?

М а р и я. Мин ул эшләргә катышмыйм.

Н и н а. Наталья өйдәме соң?

М а р и я. Өйдәләр. Туган-тумачалар, кодалар гына җыйналып…

Н и н а. Алайса, туй инде. Шыпырт кына диген. Наталья мине чакырмады да.

М а р и я. Анысын мин белмим инде. Бар соң, кер.

Н и н а. Чакырылмаган килеш... «Незваный гость хуже татарина» дигәнне ишеткәнең юкмы әллә?

М а р и я. Юк, ишеткәнем юк.

Н и н а. Киявегез татар булгач, колагыгыз ишетми башлагандыр шул. Качып-посып кына туй үткәрәсез. Кичәге туегызны да әйтер идем инде. Татарлар теләсә нәрсә кылана. Без ят кешеләр кебек утырдык.

М а р и я. Боларны син нигә миңа әйтәсең?

Н и н а. Авылдагы үзебезнең егетләрне санга сукмыйча...

М а р и я. Син санга суктың да бит, үзебезнекеләр сине санга сукмады. Аерып җибәрделәр. Ничәвенә чыгып карадың, хәзер менә ялгыз яшисең.

Н и н а. Ну и пусть. Мин, гомеремдә ир күрмәсәм дә, татарга кияүгә чыкмыйм. Пачкать себя не стану.

М а р и я. Балаболка ты, Нина.

Н и н а. Ну и балаболка. Вот ты на старости лет своих правнуков-татарчат будешь нянчить. *(Кулында бала тирбәткәндәй итеп.)* Әхмәт, Җәмилә, Абдулла... Әхмәт, Җәмилә, Абдулла. Бәү-бәү, бисмилла, бәү-бәү, бисмилла.

М а р и я. Нигә шулчаклы яратмыйсың татарларны, алар сиңа ни начарлык эшләде?

Н и н а. Яратмыйм, и всё. Чё они зашумели? Суверенитет, суверенитет... Туган тел, туган тел... Недорезанные. Чуть что, они начнут тут хозяйничать. Им только дай волю. Триста лет нас мучали, опять хотят.

М а р и я. Кто тебя мучил-то? Беспутная ты, бесстыжая. От злости это у тебя всё. Люди как люди. По людски-то надо жить.

Н и н а. Продались вы все. Душу дьяволу продали. Вот пошло все кувырком. Свадьбу справляют – от людей прячутся. Тьфу!.. Креста на вас нету. Прости, господи, за наши грехи-то... *(Урыныннан торып.)* Прощевайте, бабка Мария, пейте, ешьте, гуляйте. *(Алексейлар өендә ишетсеннәр дип, кычкырып частушкалар әйтә-әйтә чыгып китә.)*

Я хотела выйти замуж,
Хотела за барина.
Хотела за барина,
Вышла за татарина.

Мой милёнок – татарчонок,
Сама не татарочка.
Я сикушка, он чаплашка –
Мировая парочка.
Милого обрезали –
Обезобразили;
Не обезобразили –
Разнообразили.

Наталья *(атылып кереп)*. Это кто? Нинка, что ли?

Мария. Она.

Наталья. Чё это она? *(Нина артыннан куып чыгып китә. Анда талашкан, сугышкан тавышлар.)*

Мария. Господи!.. Господи!.. *(дип кенә утыра)*.

Наталья *(әйләнеп керә. Чәчләре тузган)*. Я покажу тебе, вертихвостка! Я тебе покажу, потаскуха чертова. А ты что здесь сидишь? Места, что ли, дома нет? *(Мариянең йөзенә игътибар беләнрәк карап.)* Ты чё, плачешь что ли? Чё ты? Мама... Мам... *(Мария эндәшмәгәч, аның каршына тезләнә.)* Ну, перестань. Мама... *(Шуннан Мариянең алдына башын салып, үзе кычкырып елап җибәрә.)* Да что же это такое!.. Господи!.. Что я тебе плохого сделала? Единственная дочь... На свадьбе-то как на похоронах. Что же это такое? За что, за что так?! Мамаша!. Милая!.. За что же такое наказание?!

Мария. Наталья!.. Не надо, Наталья... Успокойся, чё ж теперь убиваться-то?!

Наталья *(тынычлана төшеп)*. Живут же люди... Зачем же так?.. Живут же... Ничего ж такого не случилось. Ну, вышла замуж... Ну, не послушалась. Разве мы слушали родителей? Так уж ведётся, живут же... Зачем же людей срамить-то? Ну, вышла, что я могу делать-то?.. Дура она, Нинка, дура...

Дания *(күренә. Ул шат күңелле)*. Наташа, кая югалдың син? Анда күрсәң... Синеке белән минеке кочаклашканнар да җырлыйлар. Нәрсә җырлаганнарын да белеп булмый. Әйдә, әйдә, утырма, кер. Әйдә, бер кара-каршы басып биик әле, чукынып китсен дөньясы, әйеме? *(Такмак әйтә-әйтә бии.)*

Пич башыннан егылып төшкән
Сәхипҗамал тәтәгез;

Безгә гармуннар кирәкми —
Гармунсыз да әйтәбез.
Әй, барыйна, барыйна,
Мин дә суга барыйм ла;
Мине суга аппармасаң,
Күтең тибеп ярыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

Туктаусыз кабатлап бии. Ут сүнә. Ут янганда, Хәлиуллаларның өе. Нурхәмәт идәнгә яулык җәйгән дә шуның өстендә намаз укый. Д а н и я кайтып керә, чишенә. Гомерендә намаз укымаган каенатасының «кыланышына» аптырап карап тора да көлеп җибәрә. Нурхәмәт аңа игътибар итми.

Д а н и я *(көлүеннән туктап)*. Нишлисең син? *(Нурхәмәт эндәшмәгәч.)* Сиңа әйтәләр, әткәй.

Н у р х ә м ә т *(амин тотып, яулыкны җыеп алгач)*. Күрмисеңмени?

Д а н и я. Күргәнгә сорыйм да шул менә. Гомердә кыланмаганны.

Н у р х ә м ә т. Мин кыланмыйм. Колагыңа киртләп куй.

Д а н и я. Киртләвен киртләрмен дә… Беренче тапкыр күрәм. *(Көлеп.)* Шундый килештерәсең. Әллә мулла булырга җыенасыңмы? Эт чаба дип, бет чаба. Тотындылар. Дин дә дин. Татар да мөселман. Мәчет салалар да искечә китаплар саталар. Син дә шуларга иярдеңмени?

Н у р х ә м ә т. Гөнаһ җыеп күп йөрдек. Җитәр. Бер Ходайдан гафу сорарга вакыт.

Д а н и я. Укый беләсеңме хет, ичмасам? Бисмилла да әйтмәгән кеше…

Н у р х ә м ә т. Белмәсәк өйрәнербез.

Д а н и я. Өйрән инде, алайса, өйрән. Кәләпүш алып җибәрербез үзеңә. *(Яулыкны кулына алып.)* Әнкәй мәрхүмәнең яулыгы түгелме соң бу?

Н у р х ә м ә т. Булса ни?!

Д а н и я. Нигә әле минем белән сырт куеп сөйләшәсең? Сиңа сүз әйткән кеше юк лабаса. Рәхәтләнеп укы. Миңа димәгәе. Хәлиуллага әйт. Казан мәчетеннән әйбәт намазлык алып кайтсын. Анда саталардыр… Илгизәрләр кайтмадымыни?

Н у р х ә м ә т. Кайттылар.

Д а н и я. Нәрсә, кайтып керүгә тагын шунда кереп киттеләрме?

Н у р х ә м ә т. Әйтмәделәр.

Д а н и я. Кызык тапты. Ияртә дә алып кереп китә, ияртә дә алып кереп китә.

Н у р х ә м ә т. Керсә... Атасының йорты. Сагынгандыр.

Д а н и я. Монда йорт түгелмени? Дәшми торгач та... Миңа әйткәндә өздереп әйтәсең. Шуңа берәр сүз әйтергә ярыйдыр сиңа да.

Н у р х ә м ә т. Ни әйтим мин аларга?

Д а н и я. Бу – төп йорт, диген. Килен булып төшкәнсең икән, онытма, диген. Менә мин алай эшләмәдем бит.

Н у р х ә м ә т. Эшләмәдең инде, эшләмәдең...

Д а н и я. Нәрсә, нәрсә, нәрсә?.. Нәрсә эшләгән ул кадәрле? Малаең юаш булганга әллә мин гаеплеме? *(Киенә башлый.)*

Н у р х ә м ә т. Йөрмә. Кеше белән сөйләшә белмисең. Тавыш чыгарыргамы? Кайтырлар.

Д а н и я. Өйрәтмә.

Н у р х ә м ә т *(тәрәзәдән күреп)*. Әнә кайтып киләләр. Сүзеңне үлчәп сөйлә.

Д а н и я. Өйрәтмә, диләр.

И л г и з ә р белән В е р а көлешә-көлешә кайтып керәләр.

В е р а. Исәнмесез!

Д а н и я. Исәнен исән дә бит менә... Кайтып кергәнсез дә чыгып чапкансыз. Өйләнешкәнегезгә өч ай, өйдә торганыгыз юк. Кунактан кунакка, кунактан кунакка. Ярый, барыгыз, чишенегез. *(Илгизәр белән Вера үз бүлмәләренә кереп киткәч.)* «Әни» дип тә әйтә белмиләр.

Н у р х ә м ә т. Өйрәтмәгәч, ничек әйтсеннәр...

Д а н и я. Җитте инде сиңа. Болай да ачуым чыгарга тора.

Н у р х ә м ә т үз бүлмәсенә кереп китә. И л г и з ә р белән В е р а чыгалар.

В е р а *(Даниягә бер төргәк сузып)*. Менә әнинең апалары сезгә җибәрделәр. Бүләк.

Д а н и я *(төргәкне сүтеп, аннан кофта ала)*. Ай, рәхмәт. Озак тордыгыз.

И л г и з ә р. Җибәрмиләр.

В е р а. Мәскәүдә безнең туганнар бик күп бит. Әле берсенә, әле берсенә.

Д а н и я. Яхшы булган. Мәскәү ошадымы соң?

В е р а. Юк. Кибетләрдә бернәрсә дә юк. Мин теге барганда бөтен нәрсә бар иде.

Д а н и я *(Илгизәргә)*. Син нигә бер сүз дә дәшмисең?

И л г и з ә р. Нәрсә дәшим? Әйбәт... Яхшы...

Д а н и я. Яхшы икән, яхшы. Инде болай. Сиңа – ир, *(Верага)* сиңа хатын булырга вакыт. Гел кунакта гына йөрмиләр. Бу өйдә сез кунак түгел.

В е р а. Ә нишләргә? Чәй куярга, что ли?

Д а н и я. Чәй дә куярсың, башкасын да эшләрсең. Мин биреп җибәргән акчагызны нишләттегез?

И л г и з ә р. Анда киемнәр юк. Спекулянткаларда гына. Кыйбат. Ә без, беләсеңме, нәрсә алдык? Японский магнитофон. Беләсеңме, арзанга туры килде. Болай биш меңгә саталар. Бу – өч меңгә.

Д а н и я. Күпмегә?

И л г и з ә р. Өч мең. *(Бүлмәсенә кереп, магнитофон күтәреп чыга.)* Менә. Дүрт кассетасы бар.

Д а н и я. Акылың бармы соң синең?

И л г и з ә р. Ә нәрсә? Моны әле көчкә таптык. Оляның танышлары табып бирде.

Д а н и я. Кем инде ул Оля?

В е р а. Моя двоюродная сестра.

Д а н и я. Ике мең генә алып киткән идең бит акча.

В е р а. Тётя дала. Взаймы.

Д а н и я. Син нигә әле урысча сөйләшеп утырасың? Монда бит урыслар юк. Кем түли инде ул бурычыгызны?

И л г и з ә р. Туйдан калды бит әле акча.

Д а н и я. Әй Алла... *(Өстәлдән самавырны җилтерәтеп алып китә.)*

В е р а. Я тебе сказала.

И л г и з ә р. Әй... Аның ни эше бар туй акчасында? Бүген клубка алып чыгабыз. Көнләшеп үләчәкләр. *(Магнитофонны кабыза. Аннан пәри туена охшаган ритм бәреп чыга.)*

Н у р х ә м ә т *(ишектән башын тыгып)*. Ни булды?

И л г и з ә р *(рәхәтләнеп көлеп, магнитофонны туктата)*. Ишеттеңме, бабай? Менә шундый була ул магнитофон. Японский. «Сони». *(Нурхәмәт ишекне ябып*

*куйгач.)* Мин сиңа әйттем бит, Вера. Миңа бер сүз дә әйтә алмыйлар алар. *(Магнитофонны кабыза.)*

Д а н и я *(кереп, бар тавышына кычкыра)*. Тукта-а-ат!..

И л г и з ә р *(магнитофонны туктатып)*. Нишлисең син, ә?

Д а н и я. Кертеп куй тизрәк, күземә күрсәтмә.

И л г и з ә р. Нишлисең син, ә?

Д а н и я. Кертеп куй, аяк астына салып таптаганчы... *(Илгизәр магнитофонны алып кереп киткәч, Верага.)* Син әйтер идең шул аңгырага. Син бит хатын-кыз. Семья тотасы кеше. Син дә санамагач акчаны, кем санасын? Ирләргә аларга нәрсә: гөмбә — шалкан, бук — талкан. Гомер итәсегез бар.

В е р а. Ә миңа нәрсә...

Д а н и я. «Миңа нәрсә, миңа нәрсә»... Кияүгә чыкканда белмәдеңмени нәрсә икәнен? Кияүгә чыгуны әллә кунакка йөрү дип белдеңме?

В е р а. А чего вы на меня кричите?

Д а н и я. Мин ни кричу, мин ничек яшәргә әйтәм.

В е р а. Ну и яшәгез. Какое ваше дело в нашей жизни?

Д а н и я. Ничек инде эшем булмасын? Мин сезгә әниме, юкмы? Синең миңа «әни» дип тә әйткәнең юк.

В е р а. У меня есть своя мама. Только на меня не кричите. Моя мама на меня не кричит.

И л г и з ә р *(бүлмәдән чыгып)*. Вера, әйдә. *(Вераның кулыннан тотып, бүлмәсенә тарта.)*

В е р а. Перестань. Скажи своей маме, чтоб она на меня не кричала. Накричалась.

И л г и з ә р белән бүлмәгә кереп китәләр. Бик әйбәт кенә сабак алган Дания ни эшләргә дә белми басып кала. Хәтта ул бераз курыккан да бугай әле. Х ә л и у л л а кайтып керә. Сүзсез генә чишенә.

Х ә л и у л л а. Салкынайтты кичкә таба.

Д а н и я. Нәрсә?..

Х ә л и у л л а. Салкынайтты, дим. Чәй куйдыңмы?

Д а н и я. Ни дидең?

Х ә л и у л л а. Чәй куйдыңмы, дим? Балалар кайда соң әле? Кайттылар дигәннәр ие.

Д а н и я *(әкрен генә исенә килеп)*. Бүлмәләрендә.

Х ә л и у л л а *(Даниянең, йөзенә карап)*. Берәр нәрсә булды мәллә? Кыяфәтең киткән?

Дания. Нәрсә булсын миңа? *(Үзе борынын мышкылдатып елый башлый.)*

Хәлиулла. Ни булды?

Дания. Сорама. Сорама, Хәлиулла.

Хәлиулла. Әти белән әйткәләштегезме?

Дания. Кайчан минем әткәй белән әйткәләшкәнем бар? Әй, дурак булдым, дурак булдым. Үз кулларым белән тотып бирдем бит улымны. Күршедә генә яшәп, кем икәнен белмәгәнмен. Дурак булдым, дурак булдым.

Хәлиулла. Инде бу киленең белән дә чәкешеп өлгердеңмени? Нәрсә җитми сиңа, ә? Нигә яшьләр арасына керәсең? Тимә, яшәсеннәр үзләренчә. Аларның үз тормышы, безнең — үзебезнеке.

Дания. Саруым кайнатып утырмале син дә... Сиңа бөтенесе дә әйбәт. Мин изаланам алар белән. Ходаем, бер сыер алырлык акчага моның хәтле тартма күтәреп кайтканнар бит! «Ни кричи» дигән була бит әле, марҗа тәресе.

Хәлиулла. Әкрен инде... Нәрсә алып кайтканнар дисең?

Дания. Нәрсә булсын — магнитофон, ди. Өч мең тәңкә, ди.

Хәлиулла. Чит илнекедер. Бик кыйммәт дип сөйләп торалар иде мастерскойда малайлар. Йә, ярый, алган — булган. Югалтмаганнар бит. Яшьләргә анысы да кирәктер. Үзләре эшли башлагач, акчаның ни икәнен аңларлар әле. Мин механик белән сөйләштем, Илгизәрне үз яныма урнаштырырбыз. Эшкә үзем өйрәтеп, үз урыныма калдырырмын. Вера фермага барыр. Син инде, Дания, давай канатларыңны бик җилпемә. Бераз гына алар җаена да тор. Дөнья бит син дигәнчә генә булмый. Ярый ла мин түзәм...

Дания. Түзәрлек нишләттем соң әле мин сине? Ашарыңа әзер, өс-башың чиста.

Хәлиулла. Анысы шулай инде. Яшьләр беләмени аны...

Илгизәр белән Вера чыгалар.

Вера. Исәнмесез... Хәлиулла... абый...

Хәлиулла *(Вераның уңайсызланганын күреп)*. Ярый, ярый, ничава... Өйрәнерсең. *(Илгизәргә.)* Син нихәл?

Илгизәр. Әйбәт.

Хәлиулла. Әйбәт булгач бик әйбәт.

Вера *(Даниягә)*. Сез мине гафу итегез... Я не хотела...

Дания. Ярар. Булган – беткән. Утырыгыз. Чәй чыгарам. *(Өстәл әзерли.)*

Вера бик матур итеп кенә утырып тора, ярдәм итәргә уйламый да. Дания аңа карап-карап ала, Вера аның карашын, кызганычка каршы, аңламый.

Хәлиулла *(Нурхәмәт бүлмәсенең ишеген ачып)*. Әти, чык чәй эчәргә. *(Нурхәмәт чыгып утыргач.)* Эшләр ничек, әти?

Нурхәмәт. Тәгәри.

Дания *(эш арасында)*. Син аңа кәләпүш алып кайт, намаз укый башлаган.

Нурхәмәт. Булды инде сиңа, җитте.

Хәлиулла *(Илгизәргә)*. Мин механик Хәерҗан абыең белән сөйләштем. Мастерскойга урнашырсың эшкә. Җылыда. Эшкә өйрәнерсең.

Илгизәр. Без бит китәбез.

Дания *(самавыр күтәреп чыгып килгән җиреннән ишетеп калып)*. Ничек китәсез? Кая китәсез?

Илгизәр. Абыйлар янына, Чаллыга.

Дания *(самавырны өстәлгә куеп)*. Нәрсә калган анда сезгә?

Илгизәр. КамАЗга эшкә керәбез.

Дания. Нинди КамАЗ?

Илгизәр. Машина заводы. Автомашиналар чыгарачак ул. Шунда китәбез.

Дания *(Хәлиуллага)*. Син аның нәрсә сөйләгәнен ишетәсеңме? *(Илгизәргә.)* Кем котыртты?

Илгизәр. Беркем котыртмады. Авылда калмыйбыз.

Дания. Безнең ни әйткәннәрне оныттыңмыни? Әтиең белән гел әйтеп килдек, авылда, үзебезнең янда, төп йортта каласың, дидек. Беркая да китмисез. Менә ындыр табагы хәтле өй. Кем өчен дип тырышып-тырмашып салдык без аны? Анда упшыйжитиедә йөрергә... Абыеңнар ничә ел упшыйжитиедә интектеләр?

Вера. Мин авылда калмыйм.

Дания. Нигә?

Вера. Фермада эшләргә теләмим.

Дания. Анда эшләмәсәң, бүтән җирдә эш табылыр.

Вера. Мин барыбер авылда калмыйм.

Дания. Ничек инде «калмыйм», ирең бар бит синең.

Вера. Ул теләсә нишләсен.

Дания. Ничек инде...

Хәлиулла. Туктагыз әле, туктагыз. Алексей, Наташа, бергәләп сөйләшербез. Болай гына булмый ул. Уйлашырбыз. Син, кызым, алай кистереп сөйләшмә. Әнә әнкәң Дания, сүзен өзеп сөйли дә, соңыннан үкенеп бетә алмый. Һәрнәрсәнең дә тәртибе бар бит. Әйдәгез әле, табын янында әйбәтләп кенә чәй эчик. Карагыз ничек, нинди түгәрәк табын — әти, без, сез... *(Нурхәмәткә.)* Шулаймы, әти?

Нурхәмәт. Матур итеп сөйләргә өйрәнеп кайткансың әле, тыңлыйм да аптырап утырам.

Дания *(Вераның муенына асылган тәрене күреп алып)*. Нәрсә ул?

Хәлиулла. Тагын ни булды инде?

Дания. Тәре бит. Чын тәре. Муенына аскан. *(Верага.)* Яле, күрсәт әле...

Вера. А чё? Крестик есть крестик. Оля бүләк итте, үзенә алган булган, миңа бүләк итте. В Москве их полно.

Дания. Син тактыңмы?

Вера. А чё?

Дания. Тәре бит ул.

Вера. Я знаю, что тәре.

Дания *(Нурхәмәткә)*. Әткәй... Тәре таккан бит.

Нурхәмәт. Утыр әле урыныңа. Әллә тәре күргәнең юкмы?

Дания *(Илгизәрнең изүен ычкындырып карап)*. Син нигә такмадың? Нәрсә инде бу, йә, нәрсә инде бу? *(Илгизәргә.)* Син күрдеңме аның такканын?

Илгизәр. Күрсә ни булган?

Дания. Тәре бит ул, беләсеңме син шуны, тәре!..

Вера. Нәрсә инде сез тагын кычкырасыз?! Он же подарок сестры моей. Я же не верующая. Вы же знаете, я не верующая.

Дания. Хәлиулла, син нигә бер сүз дә дәшмисең?

Хәлиулла *(кычкырып)*. Җитте, диләр сиңа! Дәшмидәшми торгач та. Башта үзең йөрдең. Белмәдеңмени малаеңның кемгә өйләнгәнен?

Дания. Белмәдем, белмәдем. Мин тәре тага торган

маржага өйләндерергә үстермәдем улымны. Миңа тәреле марҗа кирәкми.

Хәлиулла. Әйтеп торалар бит сиңа. Бүләк, диләр. Киеп йөрер дә салып куяр.

Дания *(Верага)*. Сал, хәзер үк сал. Күземә күрсәтмә.

Вера. А вот и не сниму. Назло буду носить.

Хәлиулла. Вера, кызым, туктале, утыр әле.

Вера. Ә нигә ул миңа кычкыра? Не кричите на меня! *(Кычкырып елап, өстенә дә кимичә чыгып йөгерә.)*

Хәлиулла *(аның артыннан ашыгып)*. Вера, туктале, Вера...

Дания башын учлап уфылдап утырып кала.

Нурхәмәт *(башын аска иеп утырган Илгизәргә)*. Син нишләп утырасың, бүкән? Хатының чыгып китте. Хатының чыгып китте, диләр сиңа!

Илгизәр, урыныннан торып әнисенә карый-карый, ишеккә таба бара.

Дания. Тукта!.. Аягыңны атлыйсы булма!..

Нурхәмәт. Син нишләгәнеңне беләсеңме, тиле баш?! *(Туктап калган Илгизәргә.)* Бар!

Дания. Тәре ич, әткәй! Мин аны шушы яшемә җитеп авылда карт маржалар белән карт урысларда гына күрә идем. Ялтырап тора торган тәре тагып кайткан бит.

Илгизәр. Әни!..

Дания. Тәресен өйләрендә салып калдырмаса, бусагамны атлап кермәгез.

Ут сүнә. Ут карт өянкене яктырта. Утыргыч буш. Сәхнәнең ике ягыннан Мария белән Нурхәмәт керәләр. Берсен берсе күреп туктап калалар. Ике күрше йорт арасыннан узып киткән шомның шаукымы боларга да кагылган — икесе дә гөнаһ эшләгән кешеләр сыман уңайсызланалар.

Мария *(ниһаять, телгә килеп)*. Нихәл, Нурхәмәт? Берәр җиргә баруыңмы?

Нурхәмәт. Кибеткә дип чыккан идем дә, ачыктырмы?

Мария. Ачыгын ачык та, бернәрсә дә юк анда. Сания берүзе туңып утыра.

Нурхәмәт. Көн суыткан, ахрысы.

Мария. Ни дисең?

Н у р х ә м ә т. Көнне суыткан, ахры, дим.

М а р и я. Минем колак шаулый башлады әле, Нурхәмәт күрше. Кычкырыбрак сөйлә. Унбиш градус дигәннәрие иртән радиодан.

Н у р х ә м ә т. Булыр. Раштуа җитеп килә бит. Нихәлләрдә соң, күргәнем дә юк? Өйдән дә бик чыгасы килми хәзер. Мичкә сыртны терәп утырам шунда. Эш кушучы да юк. Сыерлар астын карарга дип чыкканыем да кичә, килен куып кертте. Йөрмә, ди, авырып егылсаң, миңа интегергә кала, ди.

М а р и я. Шулай инде, нинди эш инде ул бездән…

Н у р х ә м ә т. Гомер буе эшләгәч, йөрәк чыдамый шул. Кирәксез кеше булудан да начар нәрсә юк икән, Маруся күрше. *(Икесе дә әкрен-әкрен селкенеп үзләре сизмәстән утыргыч янына килеп җиткәннәр, Нурхәмәт урындыкны бияләе белән сыпырып.)* Утыр әле, Маруся күрше.

М а р и я. Кирәкми, Нурхәмәт, кузгатма, искә төшерәсем килми.

Н у р х ә м ә т. Юк, мин аны әйтмим. Теләсәләр нишләсеннәр. Безнең ни катышыбыз бар, әйе бит?

Шулчак һәрвакыттагыча салып алган И с л а м пәйда була.

И с л а м. Һәйт! *(Куркып киткән Мария белән Нурхәмәттән көлеп.)* Кода белән кодагый нишли монда бу салкында? Өегездә утырыгыз. Эшләр ничек соң, ә? Как дела, тётя Маруся? Картаеп буламы?

М а р и я. Син үзең дә инде яшь түгел.

И с л а м. Синең арттан куам.

Н у р х ә м ә т. Бик әллә ни куалмассың ла…

И с л а м. Нигә, Нурхәмәт абый?

Н у р х ә м ә т. Аек көнең юк.

И с л а м. Син минем өчен кайгырма, Нурхәмәт абый. Ходай биргәнен яшәрбез. Салкын бит. Үтеп барышлый Ниналарга кердем дә, яле, мин әйтәм, Раштуа бәйрәменә куган самогоныңнан авыз иттер әле, дим. Юк, дигән була. Белмиләр ди самогоны барлыгын. Тәки бер стакан салып бирде, мә, проклятый татарин, ди. Үзе проклятый, ди, үзе бирә. Шулай ул дөнья, Тетя Маруся. Җырлыйммы, Нурхәмәт абый?

Н у р х ә м ә т. Бугазыңа суык тияр.

И с л а м. Ничава. Безнең бугазлар каешланып беткән инде ул.

Кыр казы
Иделләр читендә.
Ялгыз башым миңа читен лә…

Ут Хәлиуллаларның өе эченә күчә. Анда Х ә л и у л л а, Д а н и я һәм И л г и з ә р.

Х ә л и у л л а *(Даниягә)*. Чәеңне куй.

Д а н и я. Аңарга әнисе куйган чәй ошамады бит. Кипәтүк эчәргә китте, пумала башка ияреп.

Х ә л и у л л а. Бергә яшәгәч иярәсең инде ул. Мин дә бит утыз ел сиңа ияреп йөрим.

Д а н и я. Ияртерсең сине. Дәшми-дәшми торасың да тешләп аласың. *(Илгизәргә.)* Рәхәттер инде упшыйжитийдә яшәүләре. Сүз әйтергә әни юк. Хат язып салу юк. Балаларының туганын да кешеләрдән генә ишетәбез.

И л г и з ә р. Үзең ич. Кайтып күренәсе булмагыз, дидең.

Д а н и я. Кайткансың бит әле. Хатыныңның әнисе килдеме соң?

Х ә л и у л л а. Барсак бергә генә барабыз, диде ич Наташа.

Д а н и я. Ышан ул астыртын еланга.

Х ә л и у л л а. Булды. Чәеңне куй. *(Илгизәргә.)* Бар, бабаң белән исәнләшеп чык, чирләбрәк тора. *(Илгизәр кереп киткәч.)* Бик каты бәрелмә, болай да башы әйләнгән чагыдыр.

Д а н и я. Әйләнчек бәрән булып туган инде туганда ук. Сора әле, балаларына нинди исем куштыралар икән? Әйт, Айдар кушсыннар.

Х ә л и у л л а. Үзләре табарлар әле. Баласын тапканнар бит.

Д а н и я. Табарлар, бик әйбәт итеп табарлар. Иван куштырып куяр марҗасы.

Х ә л и у л л а. Иван булса Иван инде, бернишләп тә булмый.

Д а н и я. Утырмасана үртәп… Болай да җыларга гына торам. Бөтен нервыларымны бетерде. Хәлиулла, сөйләш, яме, матур итеп. Мин әйткәнне колагына алмый ул. Зинһар өчен дип сорыйм, урыс исеме куштыра күрмәсен баласына.

Хәлиулла. Әйтте ич инде Наташа, Илгизәр үзе нинди исем таба, шуны кушарлар, диде. Алексей да шулай ди.

Дания. Кайчан сөйләшеп өлгердең соң әле?

Хәлиулла. Кичә сүз чыкты да...

Дания. Үзең тагын, мыштым гына йөрсәң дә... *(Илгизәр чыкканны күреп.)* Ярый, сөйләшеп утыра торыгыз, мин хәзер чәй куеп җибәрәм. *(Самавырны күтәреп алып чыгып китә.)*

Хәлиулла. Бабаң нык чирли. Таныдымы сине?

Илгизәр. Таныды.

Хәлиулла. Берәр сүз әйтмәдеме?

Илгизәр. Юк. Карап кына торды.

Хәлиулла. Озак тормастыр инде. Җирләргә кайт. Телеграм сугарбыз. Абыйларыңны күрәсеңме?

Илгизәр. Баргалыйбыз.

Хәлиулла. Нәрсә, Вера кайтмаска иттемени?

Илгизәр. Кайтты ул.

Шул сүз әйтелүгә, Дания ялт итеп килеп чыга, тыңлап тора.

Хәлиулла. Кайда соң, алайса?

Илгизәр. Өйләренә кереп китте.

Хәлиулла. Бергә кайттыгызмы соң?

Илгизәр. Бергә.

Хәлиулла. Сүзгә килмәгәнсездер ич?

Илгизәр. Юк.

Хәлиулла. Ничек инде ул алай?

Илгизәр. Мин сезгә кермим, диде. Әниең күзенә күренмәскә кушты, диде.

Дания *(түзмичә)*. Нигә соң, алайса, үзең кердең? Ияреп киткәнне ияреп керергә иде.

Хәлиулла *(чыгырыннан чыгып)*. Җитте сиңа канса да кансов! Сугып торып җибәрермен. Нәрсә сез мине!.. Кем башына ашкынасыз? Әллә сез мине уенчык дип белдегезме? *(Даниягә.)* Бар урыныңа, күренәсе булма.

Дания *(куркуга төшеп)*. Нишлисең син, ә? *(дип чигенә-чигенә чыгып югала)*.

Хәлиулла *(Илгизәрнең изүеннән тотып күтәрә)*. Ә син!.. *(Ни әйтергә белми улына карап тора да.)* Их сез!.. *(Илгизәрнең изүен җибәреп.)* Ишәк!.. Хәер, атасы ишәк булгач, малае кем булсын?!

Бала күтәргән В е р а н ы җитәкләп, Н а т а л ь я керә.

Н а т а л ь я. Исәнме, Хәллә? Менә киленегезне алып кердем. *(Верага.)* Утыр шунда. Менә бу синең төп йортың. Ничә әйттем мин сиңа. *(Илгизәргә.)* Ә син нигә бер хатыныңа баш була белмисең? *(Верага.)* Бәхетең, әтиең өйдә булмады. Менә, Хәлиулла, нәрсә әйтәсең инде боларга? Дания безне битәрли, безнең ни катнашыбыз бар? Кайда соң әле үзе? *(Данияне күреп, аның янына кереп китә.)*

Х ә л и у л л а. Нихәл соң, Вера?

В е р а. Исәнмесез. *(Баласын кочаклап утыра бирә.)*

Х ә л и у л л а. Безнең онык ничек соң? Яле, күрик әле.

Вера янына килгәндә, тышта карт өянкенең шатырдап ауганы ишетелә. Хәлиулла тәрәзәгә барып каплана. «Ни булды?» дип, Д а н и я белән Н а т а л ь я чыгалар.

Х ә л и у л л а. Өянке ауды.

Д а н и я. Күпме әйттем, кисеп ташла, дип. Черегән иде инде.

Х ә л и у л л а *(тәрәзә яныннан китеп)*. Йә, ярар. Хәерлегә булсын! Ярый әле үтеп баручы булмаган. *(Илгизәргә.)* Әйдә, урамга аркылы ауган, юлны ачыйк.

Чыгып китәләр.

Н а т а л ь я. Син миңа ачу саклама, Дания. Икесе дә тиле бит әле, нишләтәсең. Утыра бит әнә авызын турсайтып. *(Верага.)* Исәнләшергә дә оныттыңмы әллә? Кара, мине яклар дип уйлама!

В е р а. Ну и не надо. Я и не хотела приезжать… Сама писала-плакалась.

Н а т а л ь я. Замолчи! *(Даниягә.)* Нурхәмәт абый ничек?

Д а н и я. Ята.

Н а т а л ь я. Сөенечен алырмын дигән идем. Онызыбыз койган да куйган ул. Сакал-мыек та ябыштырсаң. *(Верага.)* Күрсәт әле, кызым. *(Баланы, үз кулына алып, Даниягә күрсәтә.)* Күр әле, койган да куйган, әйеме?

Д а н и я. Исемен Айдар дип кушабыз.

Н а т а л ь я. Айдар? Айдар Илгизәрович. Нигә? Матур. *(Верага.)* Шулай бит, кызым?

В е р а. У него уже есть имя.

Н а т а л ь я. Куштырдыгызмыни? Нигә соң аны әйтмәдең?

В е р а. Не спрашивала – не сказала.

Н а т а л ь я. Ничек соң?

В е р а. Иван.

Д а н и я. Иван?!

В е р а. Да!.. Иван!.. Есть свидетельство о рождении... Иван!..

Д а н и я. Ходаем!.. Хәлиуллa-a!.. *(Үкереп чыгып йөгерә.)*

Аңа Наталья иярә. Ул Данияне ауган өянке янына озата чыга. Дания кычкырып өянке янында балта тотып торган Хәлиулла янына чаба.

Хәлиулла-а!.. Иван... Хәлиулла-а...

Н а т а л ь я *(йөгереп килеп, Данияне тота)*. Дания!.. Туктале, Дания!

Д а н и я. Кит! Китегез! Барыгыз да бер... *(Натальяны этеп җибәреп.)* Иван... Иван... *(сөйләнә-сөйләнә, өянкенең теге ягына күчеп чыгып китәргә җыена.)*

Х ә л и у л л а. Кая барасың? Тукта!

Д а н и я. Китегез! Берегез дә кирәкми. *(Чыгып китә.)*

Аңа Х ә л и у л л а белән Н а т а л ь я иярә. Илгизәр берүзе басып кала. Бала күтәреп, В е р а чыга. Илгизәргә күз дә салмый, үзләре ягына юнәлә.)

И л г и з ә р. Вера...

В е р а *(өянке өстенә баскан килеш)*. Отстань! *(Китеп бара.)*

Илгизәр ялгызы өянке янында утырып кала. М а р и я керә.

М а р и я. Ни булган бу өянкегә? Әллә кискәннәр инде? Ауган түгелме соң бу? Ауган ич бу! Кара, бер дә авар кебек түгел иде ич. Ауган шул. Нурхәмәт белә микән? Кара син, ә, бер дә авар төсле түгел иде...

П ә р д ә.

# СИН МИНЕ КҮРӘСЕҢМЕ?

*(Ике пәрдәле музыкаль комедия)*

Катнашалар:

Гәрәй — 25—30 яшьләрдәге егет.
Галәү — 25—30 яшьләрдәге егет.
Галия — 25 яшьлек кыз.
Илүзә — 18 яшьлек кыз.
Нурания — 60 яшьтә.
Нургали — 65—70 яшьләрдә.
Галя — 20—25 яшьләрдә.
Гөлинә, Сәкинә — 20 яшьтән узган кызлар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Үзе моңлы, үзе дәртле кереш музыка җанны җилкендерә, күңелне алгысыта. Бу музыка безне табигатьнең гүзәл бер почмагы — Мишә елгасы ярына алып килә. Әрәмәлек. Ял итәргә килгән бер төркем (ун-унбиш кыз, ике егет) мәш килә, кайнаша.

Гәрәй. Шым кал! Чаукылдашмагыз! Мин булган җирдә тәртип булырга тиеш. Мин монда хөрмәтле вә гыйззәтле Айдар Исламовичның безне бер көнлек вә һәм бер төнлек коллектив ялга җибәрүе хөрмәтенә мин язган һәм сезгә өйрәткән җырны хор белән башкарабыз. Мин солист һәм оркестр ролен башкарам. Башладык. *(Гитара кылларында бармакларын йөгертеп аккорд бирә.)*

Җыр башлана.

Хор. Дөнья көтүләре авыр, диләр,
Җиңел дөнья барын кем белә?
Кемдер зарын сөйләр кеше тапмый,
Кемдер авыз ерып гел көлә.
Кемгәдер нидер ярамый,
Безгә бар да яраган.
Бу дөньяны авыр диләр,
Кем күтәреп караган?
Кемнәргәдер кояш нурын сибә.
Кемдер айга таба үрелә.
Кемдер гашыйк булып җыр чыгара,
Кемдер ярын тапмый сүгенә.
Кемдер сакалын кырган да,
Кемдер чәчен тараган;
Бу дөньяның тәрәзәсен
Кемнәр ачып караган?
Кайсы дөнья әйбәтлеген
Кемнәр үлчәп караган?
Безгә аның тегесе дә,
Монысы да яраган.

Гәрәй *(җыр туктагач)*. Татарның һәр җыры бию белән тәмамлана. Хөрмәтле вә гыйззәтле Айдар Исламович хөрмәтенә күмәк бию!

Бию башлана. Бераздан Гәрәй аны туктата.

Туктагыз! Син нигә биемисең, Галәү?

Галәү. Мин бии белмим бит.

Гәрәй. Бии белмәгән кеше юк. Селкен. Хәзерге заманда селкенү «бию» дип атала. Нурания апа, син ник килдең?

Нурания. Үзең алып килдең ич.

Гәрәй. Беренчедән, мин алып килмәдем, Айдар Исламович җибәрде. Икенчедән, монда тамашачылар юк, барыбыз да артистлар. Музыка!

Бию дәвам итә. Гәрәй биюне туктата.

Ә хәзер барыгыз да Мишәгә!

Нурания. Биюе ошап китте бит әле, Гәрәйҗан!

Гәрәй. Дәвамы кич белән булачак. Барыгыз! *(Бию туктагач.)* Барыгыз да Мишәгә! Су өсте сезнең шатлыклы көлүегездән дулкынланып торсын. Рәсәйнең бер почмагында көлүен онытмаган халык калган икән дип

уйласыннар. Алып килгән байлыкларыгыз өчен курыкмагыз, сакта үзем калам. Пистолетым — кесәмдә, автоматым — иңсәмдә.

Хатын-кызлар, чыр-чу килеп, йөгереп чыгып китәләр. Нуранияләнең муенына аскан телефоны шылтырый. Ул туктап калып сөйләшә.

Нурания. Нихәл, Нургали! Без монда, Мишә суы буенда. Балык тотарга килгән идек бит теге вакытта. Шул җирдә. Нишлибез дип, биедек тә коенырга барабыз. Бүген кайтып булмастыр. Гәрәй шулайрак әйтте. Сау бул! Мин чаптым. *(Кызлар артыннан чыгып китә.)*

Гәрәй янында Галәү белән Илүзә генә кала.

Гәрәй. Ә сез нишләп калдыгыз?

Галәү. Беләсең ич, мин йөзә белмим.

Гәрәй. Яр өстендә утырырсың. Бар!.. Ата казсыз каз көтүе булмый, Галәветдин. Галиягә дә күз-колак булырсың. Мишә буе егетләре үткеннәр, урлап китмәсеннәр. *(Галәү чыгып киткәч, Илүзәгә.)* Син нигә коллективтан аерылдың?

Илүзә. Минем сезнең янда каласым килде.

Гәрәй. Ничек инде ул «каласым килде»?

Илүзә. Сезнең белән бергә әйберләр саклашам.

Гәрәй. Миңа ярдәмчеләр кирәкми. Бар! Коен, йөз, кыска җәйнең рәхәтен күр. Бар, нәрсә Таһирга гашыйк булган Зөһрә шикелле карап торасың?

Илүзә. Ә мин сезгә гашыйк, Гәрәй абый!

Гәрәй. Нәрсә-ә-ә?

Илүзә *(җыр белән)*.

Ә мин сезгә гашыйк, Гәрәй абый,
Гәрәй абый, мин бит сезгә гашыйк!
Сезне күрсәм, җаным канатлана,
Күңлем очып йөри күккә ашып.
Мин бит сезгә гашыйк, Гәрәй абый,
Сезне уйлап, иртән уянам мин.
Дөнья миңа сезсез кызык түгел,
Сезне уйлап кына юанам мин.

Гәрәй. Шул гына җитмәгән иде миңа. Син генә калган идең миңа гашыйк булмаган... Син мине күрәсеңме?

Илүзә. Күрәм.

Гәрәй. Минем башны күрәсеңме?

И л ү з ә. Күрәм.

Г ә р ә й. Андагы ак чәчләрне күрәсеңме?

И л ү з ә. Күрмим.

Г ә р ә й. Ничек инде күрмисең? Менә кара, кара! Минем ничә яшьтә икәнлегемне беләсеңме?

И л ү з ә. Белмим.

Г ә р ә й. Белмәсәң бел, миңа тиздән утыз яшь тула, балакаем! Сиңа ничә?

И л ү з ә. Унсигез!

Г ә р ә й. Менә күрәсеңме? Син, сабый бала башыңнан, миндәй азып-тузып беткән кешегә «гашыйк булдым» дип торасың. Егетләр белән йөргәнең бармы?

И л ү з ә. Бар.

Г ә р ә й. Яратышыпмы?

И л ү з ә. Юк. Болай гына. Сез — минем беренче мәхәббәтем!

Г ә р ә й. Нәрсә-ә? Ни сөйлисең син, тиле? Әйт әле, кайчан һәм ни өчен гашыйк булдың миңа?

И л ү з ә. Беренче күргән көннән. Сез миңа карап тордыгыз да «нихәл, сары чебеш» дидегез. Башымнан сыйпадыгыз.

Г ә р ә й. Шуның өчен гашыйк булалармы?

И л ү з ә. Сез яратып карадыгыз, яратып сыйпадыгыз.
Мин бит сезгә гашыйк, Гәрәй абый!
Сезне уйлап ятам төннәр буе,
Сезне уйлап каршылыйм һәр таңны,
Сезне уйлап йөрим көннәр буе.

Г ә р ә й. Әй-әй-әй... Әй, сабый! Бәлки, мин сиңа караганмын да их, бу сары чебешнең башын әйләндереп, кочаклап һәм алдап ташласаң иде дип уйлаганмындыр.

И л ү з ә. Сез алай уйламадыгыз. Сез сокланып карадыгыз.

Г ә р ә й. Ха-ха-хи, хи-ха-ха!.. Сокланырлык ниең бар соң синең? Ни буең юк, ни ниең тавык йомыркасы хәтле... Өстәвенә башың сары.

И л ү з ә. Сары түгел ул, аксыл. Аның каравы күзләрем матур минем. Менә карагыз.

Г ә р ә й. Карамыйм. Сезгә ышансаң, йә сихерләрсез. Мин, балакаем, гашыйк булмаска сүз биргән кеше.

Гашыйк ирләр мескен җаннар алар,
Богауланган коллар шикелле.

Мәхәббәт дип күккә ашу җиңел,
Төшүләре әмма икеле.
Юк, тимәгез миңа, тимәгез,
«Мин яратам сине» димәгез.
Гашыйк булу — эзләп алган чир ул,
Чирләрнең дә иң-иң яманы.
Мәхәббәт дип төпсез күлгә чумсаң,
Аннан чыгулары чамалы.
Юк, тимәгез миңа, тимәгез,
Зинһар өчен, якын килмәгез!

Илүзә. Ә сез мине башта гашыйк булмыйча гына яратыгыз. Бара-тора гашыйк булырсыз.

Гәрәй. Сине кочаклаганнары бармы? Кочаклап үпкәннәре булдымы?

Илүзә. Юк.

Гәрәй. Кайда үстең соң син? Казандамы?

Илүзә. Казанда.

Гәрәй. Казанда үсеп, кочакланылмаган, үбелмәгән килеш калдыңмы? Бу бит тәмугка эләгеп тә янмый чыгу белән бер. Соң, бәгырькәем, мин бит сине алдый алам.

Илүзә. Алдагыз!

Гәрәй. Нәрсә-ә-ә? Бар, ычкын моннан! Синең аркада гөнаһ җыясым килми. Болай да гөнаһларым муеннан. Бар, диләр. Башыңны салкын суга тык та уйла бераз. Бар!

Илүзә. Минем купальнигым юк.

Гәрәй. Ничек «юк»? Кая, ни өчен барганыңны белдеңме? Әйттеләрме?

Илүзә. Мин сез барганга гына килдем.

Гәрәй. Син, кызый, мине җүләргә санама, ярыймы?! Минем белән уйнарга да җыенма. Синдәйләрне мин миллиунны күргән. Яле, күтәр әле итәгеңне!

Илүзә. Нигә?

Гәрәй. Карыйк әле, бармы купальнигың.

Илүзә. Оялам.

Гәрәй. Менә анысы әйбәт, оялуың әйбәт. Бар, анда хатын-кызлар гына. Галәү абыеңа исең китмәсен, ул да ояла. Шәрә хатын-кыз күрсә, артына борылып утыра. Бар! *(Илүзәнең башыннан сыйпап, озатып куя.)* Вәт вәсвәсә! Тәки ышанып куюың бар. *(Гитарасын алып, җиргә ята. Җыр суза.)*

Мин ятам болында –
Иң матур урында.
Атым юк урамда,
Кайгым юк буранда.
Хатын юк өемдә –
Яшим үз көемә.
Кызлар күп янымда –
Яратам барын да.
Мин ятам болында –
Гитарам кулымда.
Өс бөтен, тамак тук.
Хәсрәтем, кайгым юк.
Киләм, «кил» дисәләр.
Китәм, «кит» дисәләр.
Агам, «ак» дисәләр.
Багам, «бак» дисәләр.

*(Кереп, үзенә карап торган Галияне күрә.)* Нигә кайттың, Галия?

Галия. Илүзә белән нишләдегез?

Гәрәй. Ничек инде нишләдек? Кызлар белән нишлиләр соң?

Галия. Хатын-кызлар яратмыйм дисәң дә, кызларга күзең төшә.

Гәрәй. Галия, җанкисәгем, хатын-кызларны яратмыйм, дигәнем юк. Киресенчә, бөтенесен дә бертигез яратам. Менә бу сары чәчле кызыгызны да сине яраткан кебек яратам.

Галия. Яратмыйсың шул мине.
Яратмыйсың мине, яратмыйсың,
Яратырга мине теләмисең.
Хисләремнән сиңа учак ягам –
Син янмыйсың анда, үрләмисең.

Гәрәй. Яраталмыйм сине, кичер мине,
Тик үземне генә яратам мин.
Үзем өчен яшим дөньяларда,
Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм.

Галия. Яннарымнан үтеп киткән чакта,
Өмет итәм назлы карашыңны.

Гәрәй. «Яратам» дип, коллык чылбырына
Бәйләп куя алмыйм бу башымны.

Галия. Яратмыйсың мине, яратмыйсың.

Гәрәй. Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм.

Г а л и я. Яратырга мине теләмисең.

Г ә р ә й. Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм. Мәхәббәт мәсьәләсендә мин — демократик республика, Галия! Минем өчен бөтенегез бертигез. Аннары шунысы да бар, Галиякәй, син дә бит мине яратмыйсың. Интектермә йөрәгеңне. Сиңа ир кирәк. Син картаеп барасың. Мин өйләнмәгән булгач, мине ир итмәкче буласың. Ялгышма, Галия, миннән рәтле-җүнле ир чыкмый. Җилбәзәк акыллы кеше мин. Син — тәртипле, төпле кыз. Сиңа тотрыклы ир кирәк.

Г а л и я. Миңа мин яраткан кеше кирәк.

Г ә р ә й. «Мин яраткан» дип, үзеңне алдама, Галия! Син Ләйлә дә, Зөһрә дә, Галиябану да түгел! Мәхәббәт дип саташып йөрергә сиңа ярамый. Тагын биш елдан утызны узасың. Кызлар ул яшьтә пенсиягә чыга.

Г а л и я. Бик беләсең инде, илле биштән чыгаралар безне.

Г ә р ә й. Мин, кызлар, дидем, хатын-кызлар, димәдем. Ташла минем арттан йөрүеңне. Мин өйләнергә җыенмыйм. «Өйләнәм» дип, сине алдарга да теләмим.

Г а л и я. Мин алданырга җыенмыйм да әле.

Г ә р ә й. Беләм, җыенмыйсың. Чөнки син — кирәгеннән артык акыллы кыз. Сиңа мин түгел, әнә Галәү кирәк.

Г а л и я. Нигә һаман саен аны миңа кодалыйсың?

Г ә р ә й. Чөнки ул сиңа менә дигән ир булачак. Өрмәгән җиргә дә утыртмас.

Карап торыр күзләреңә,
Күзләреңә, йөзләреңә,
Басып йөрер эзләреңә,
Каршы дәшмәс сүзләреңә.
Түзеп торыр безләвеңә,
Герләр булыр бизмәнеңә,
Чишмә булыр кизләвеңә,
Ефәк дияр бүзләреңә,
Алтын дияр җизләреңә,
Маяк булыр эзләреңдә,
Язлар булыр көзләреңдә.
Ярата ул сине, Галия!

Г а л и я. Яратса, әйтер иде ятканын.

Г ә р ә й. Бөтен кеше дә мин түгел. Син инде бала-чагалыктан узган, күрә бел кемнең кем икәнен.

Г а л и я. Беләм, пешмәгән!

Гәрәй. Сиңа минем ише пешкәннәр кирәкме? Мин инде, Галия бәгырькәем, матурым, җанкисәгем, алма кисәгем, йөрәк маем, пешә-пешә көеп беткән. Галәү пешеп җитмәгән икән, пешереп бетерерсең. Сөйләшеп кара син аның белән.

Галия. Үзе сөйләшмәгән кеше белән ничек сөйләшим? Без коенган җиргә килеп, яр өстендә карга кебек утыра.

Гәрәй. Карга кебек түгелдер, бәлки, бөркет кебектер.

Галия. Шулай да ни сөйләштегез теге кыз белән?

Гәрәй. Яратам, ди.

Галия. Шулмы?

Гәрәй. Ә нигә? Аның да яратырга хакы бар. Аңа инде унсигез яшь, Галия!

Галия. Алар унбиштә үк егетләр муенына асылыналар.

Гәрәй. Яраткач асылынасың инде. Менә син «яратам» дисең, бер дә асылынмыйсың. Димәк, мине яратмыйсың. Бик әйбәт яратмавың. Ә Галәүне тилмертмә син. Бүтәнгә өйләнеп куймасын.

Галия. Нишләтим инде мин аны? Яныма да килеп карамый. Үткәндә-сүткәндә күзләре белән генә ашап кала.

Гәрәй. Китерәсең киләме яныңа? Сөйләштерәсең киләме? Мине яратсаң, тыңла киңәшемне. Галәү — тиз ышанучан егет. Телевизордан сөйләгән төрле әкиятләргә ышана. Әйдә, бер эксперимент эшләп карыйбыз. Бүген ул синең яныңа килсә, син аны күрмәгән булып кылан. Тавышыңны гына ишетәм, диген.

Галия. Нәрсә кыландырырга җыенасың?

Гәрәй. Кыландырмыйм. Сине дә, Галәүне дә бәхетле итәсем килә.

Галия. Синнән башка бәхет юк миңа.

Гәрәй. Нинди кешеләр соң сез, ә? Нәрсәмә кызыгасыз минем?

Галия. Синең белән сөйләшү, синең юк-бар шаяруларыңны тыңлау, синең яныңда тору рәхәт.

Гәрәй. Мираж алар барысы да, Галия! Сиңа төпле ир кирәк, дип әйтәм икән, ышан миңа. Галәү кирәк сиңа, Галәү кирәк. Тыңла минем киңәшемне, сүзен тыңла Галәүнең, үзен күрмә. Әнә кара, кара син ул Галәүгә. Кайдан табасың шундый ирне. Онытма, сиңа тиздән утыз яшь. Кара, сине эзли. Бар, кит тизрәк моннан, югыйсә мине үтерәчәк.

Галия. Кыланчык! Кай җиреңне яратамдыр.
Гәрәй. Мин дә шуңа аптырыйм бит.
Галия. Тиле! *(Китеп бара.)*
Гәрәй. Онытма мин әйткәнне. Әй бу тормыш дигәнең!..

Әй тормыш, син тормыш –
Акылга утыртмыш,
Акылдан яздырмыш.
Бәхет дип котыртмыш,
Күз яше койдырмыш,
Гыйшык дип алдамыш,
Җаннарны ялгамыш,
Яшьләрне картайтмыш,
Картларны... нишләтмеш?
Мыш та мыш, мыш та мыш,
Мыш та мыш, мыш та мыш...

Галя керә.

Галя. Получается?
Гәрәй. Что получается, Галина?
Галя. Вроде бы поёшь.
Гәрәй. Җырлыйм. Син дә миңа мәхәббәт аңлатырга килдеңме?
Галя. С чего это ты взял?
Гәрәй. Монда кызлар киләләр дә «яратам» диләр.
Галя. Нет, Гарай, дорогой, за полотенцем пришла. Впрочем, ты мне нравишься. Встретила бы раньше, привязала бы к себе.
Гәрәй. Булмый, Галинушка, мин убежденный холостяк! Галя, можно я тебя буду звать Галябану. Син бик матур, Галябану.
Галя. Ещё бы! Может поцелуемся!
Гәрәй. Нет! У тебя муж. Я с разведёнными целуюсь.
Галя. Баламут вы, Гарай Хамитович! И за это вас все любят.
Гәрәй. Бер җыр җырлыйммы, Галинушка? Син татарча аңлыйсың бит.

Ай җаный, вай җаный,
Татар үпкән марҗаны.
Нигә үпмәсен марҗаны,
Марҗаның да бар җаны.

Аңладыңмы, Галина?

Г а л я. Аңладым. Кстати, я не русская. Я – марийка. Мари кызы, мари хатыны.

Г ә р ә й. Әйтәм аны чибәр! Мари кызларының күзләре серле була.

Иртән торып, күл буена
Кудым үрдәкләремне,
Күз тутырып кара әле,
Мари кызы Галябану,
Өзмә үзәкләремне.
Их, мари, мари, мари,
Мари кызы да мари.
Әйтче миңа, мари кызы,
Күңелең кемнәргә карый?
Гөлләр булып түтәлемдә
Чәчәк атарсың микән?
Түшәгеңдә мине генә,
Мари кызы Галябану,
Уйлап ятарсың микән?
Их мари, мари, мари,
Мари сылуы мари.
Бер елмаеп кара гына,
Яратмасаң да ярый.

Г а л я. Хватит! Не дай бог, влюблюсь. Хочешь я тебе марийскую песню спою.

Моланат, моланат муралшаш да
Моланат, моланат шушкалмаш?
Лыпат лийшаш шумем-мокшем,
Моланат, моланат тарваталшаш?

Моланат, моланат ойгыршаш да,
Моланат, моланат шортылдалшаш?
Лыпат лийшаш шумем-мокшем
Моланат, моланат тарваталшаш?*

---

* Нигә, нигә җыр башладың,
Нигә инде сызгырдың?
Тыныч күңлем, йөрәгемнең
Тынычлыгын ник алдың?

Нигә кайгыларга салдың,
Ник күз яше түктердең?
Тыныч күңлем, йөрәгемнең
Тынычлыгын ник алдың?

*(Сөлгесен ала да үтеп барышлый Гәрәйнең яңагыннан үбеп чыгып йөгерә.)*

Г ә р ә й. Да-а-а!.. Түзеп кара болар арасында. Бирешмә, Гәрәй!

Мин ятам болында —
Иң матур урында.

*(Килгән Галәүне күреп.)* Нигә башларың идең, дускаем Галәветдин? Ни кайгылар төште башкайларыңа? *(«Авыл көе»нә көйләп.)*

Кулымдагы йөзегемнең
Исмен Галәү кушканнар,
Имә башларыңны түбән —
Сөенмәсен дошманнар.

Г а л ә ү. Галия синең янга нигә килгән?

Г ә р ә й. Син аның янына бармаганга, ул минем янга килгән.

Г а л ә ү. Әйттеңме минем турыда берәр сүз?

Г ә р ә й. Нишләп әле син әйтәсе сүзне мин әйтергә тиеш.

Г а л ә ү . Мин аның суда йөзгәнен карап тордым. Су кызы кебек йөзә.

Г ә р ә й. Су кызының йөзгәнен күргәнең бармыни?

Г а л ә ү. Бар, Гәрәй, бар! Мин бит авыл малае. Безнең өй күл буенда. Бервакыт, төнлә суга карап утырганда, күрдем су кызын.

Г ә р ә й. Бәлки, ул крокодил булгандыр.

Г а л ә ү. Каян килсен инде авылга крокодил?

Г ә р ә й. Синең кебек мокыт каян килгән соң?

Г а л ә ү. Мыскыл итмә инде, Гәрәй!

Г ә р ә й. Итәм! Мин сине су коенучы каз көтүе янына ата каз итеп җибәрдем. Ә син, ярым шәрә кызларның суда чупырдашканнарын күреп рәхәтләнәсе урынга, аларга сыртыңны куеп яттың. Әле тагын «Галия йөзә» дигән була. Күрмәдең бит син аның йөзгәнен.

Г а л ә ү. Күрмәсәм дә сиздем. Беләсеңме, Гәрәй, бервакыт мин күрше апаны шәрә килеш күрдем. Шуннан бирле шәрә хатын-кызны күрсәм оялам. Сиңа рәхәт, син ояла белмисең. Синең кебек булырга тырышам да, килеп чыкмый.

Г ә р ә й. Әйе-е-е!.. Кызганам да мин сине, Галәү, кызыгам да. Йөз илле ел буе яратып йөреп тә, яратуын әйтергә оялган егеткә ни диләр? Кем диләр?

Г а л ә ү. Беләм инде, пешмәгән, диләр. Нишләтим, шундый инде мин.

Нишлим инде, серле минем мәхәббәтем,
Күңелемнең төпкеленә яшеренгән.
Үзем янам, үзем көям, үзем сөям,
Бер үләм мин аны уйлап, бер тереләм.
Нишлим инде, шундый минем мәхәббәтем,
«Сөям» дисәм, сүнәр төсле януларым.

Г ә р ә й. Шулай йөрсәң, ихтимал бит, агай-эне,
Гомер буе буйдак булып калуларың.

Г а л ә ү. Көтәм әле, көтәм әле, көтәм әле,
Көтәм әле сөю кошы кагынганын.

Г ә р ә й. Юк, көтмә син, өмет итмә, көталмассың
Син ул кошның кочагыңа сарылганын.

Г а л ә ү. Сиңа җиңел, Гәрәй, теләсә кайсы кызны кочаклыйсың, теләсә кайсы хатынның биленнән тотасың. Берсе дә сиңа сүз әйтми, көлеп кенә торалар.

Г ә р ә й. Заманасы шундый, Галәветдин, заманасы. Кочаклата һәм кочаклаттыра торган заман.

Г а л ә ү. Мин дә шул заманда яшим бит инде.

Г ә р ә й. Синең тактик һәм стратегик ялгышың бар, Галәү дус! Син берәүне генә яратасың. Хәлил белән Галиябанулар заманасы үтте, Галәветдин! Берләр – унны, уннар берне ярата торган заман килде. Оныт син Галияне. Мин сиңа Галяларны табып бирәм.

Ах ты, моя Галочка,
Биле нечкә талочка.
Тавык кебек курочка,
Тавык сыман дурочка.
Галәветдин – Галочка,
Мировая парочка.
Вот какая дамочка
Мин табасы Галочка.

Г а л ә ү. Көлмә инде, Гәрәй! Миңа Галиядән башка беркем дә кирәкми.

Г ә р ә й. Хәлеңне аңлыйм, ярдәм итә алмыйм. Мин күп кызларны берьюлы ярату догасын гына беләм. Син беләсеңме, Галәветдин, мин бит кызлар янына күренмичә барам.

Г а л ә ү. Ничек «күренмичә»?

Г ә р ә й. Миңа әбиемнең ахирәт дусты — йөз дә бер яшьлек Бәдигылҗамал карчык бер дога өйрәтте. Шул доганы укыйм да кызлар күзенә күренми башлыйм. Кызлар янына барам, алар мине күрмиләр, юк дип уйлыйлар.

Г а л ә ү. Көлмә инде, Гәрәй!

Г ә р ә й. Ышанмасаң ышанма. Кызлар караватта йоклап ята, иеме, чишенгән. Мин инде аңа ияреп кайткан булам. Карап торып чишендерәм. Мине син бозык-фәлән дип уйлама, бөтенләй үк чишендермим. Бөтенләй үк чишенеп күлмәген, тегесен-монысын алыштырса, читкә карап торам. Ярамый кызлар белән шаярырга, Галәветдин! Ходай аларны кыз итеп яраткан, Ходайга каршы барырга ярамый. Мин нишлим? Алар чишенеп караватларына яткач, яннарына киләм дә яңакларыннан гына пәп итеп алам. Колакларына «яратам мин сине» дип пышылдыйм. Алар, беләсеңме, нишлиләр? Күзләрен ачып, тирә-якны күзәтәләр. Ах-ух итәләр. Ә мин шунда уң колак яфрагын пәп итеп куям. Пышылдап кына колакларына шушы җырны җырлыйм.

Гөлләрем син минем, алым син,
Шикәрем син минем, балым син.
Алтыным, көмешем, якутым,
Гомергә онытмас ярым син.
Ах, синең чәчләрең, толымың,
Мин синең бер мескен колыңмын.
Онытма, гүзәлем, онытма,
Әнкәмнең бер иркә колынын.

Шуннан кызый, тәмам гасабиланып, урыныннан торып утыра. Җыр иясен эзли. Ә мин — юк. Мин күренмим. Шуннан нишлисең дип сора.

Г а л ә ү. Шуннан нишлисең?

Г ә р ә й. Кызның күзләрендә сөю ялкыны дөрли башлагач, сул колак яфрагын пәп итеп алам да сиздермичә генә ишекне ачып чыгып китәм. Кызга тимим. Кызларга тияргә ярамый. Тияр өчен ирләрен өеннән куып чыгарган, аерылып кайткан хатыннар бар.

Г а л ә ү. Әллә ниләр уйлап чыгарасың.

Г ә р ә й. Минме уйлап чыгарам? Менә син ул уйлап чыгарасың җыен юк-барны. «Үлгән әбиемнең теге дөньяда ятканын күрдем» дип син сөйләдеңме?

Г а л ә ү. Аны мин генә сөйләмим, газеталарда язалар, телевизордан күрсәтәләр.

Г ә р ә й. Галәветдин, бәгырь кисәгем, моннан илле ел элек үлгән кеше күренгәч, исән кеше дә күренмичә йөри ала. Укыганың бардыр бит китапларда.

Г а л ә ү. Бар, ярты төндә чәчәк аткан абаганың чәчәген ашасаң гына күренмисең, ди.

Г ә р ә й. Соң, атаңның башы, анаңның аягы, бар бит миндә абага чәчәге. Мин аны төнге сәгать унике тулганда Кариле урманында эзләп таптым да өзеп, киптереп куйдым. Менә ул монда йөрәк янында күкрәк кесәсендә йөри. Шуны чеметеп кабам да, әбинең догасын укып, ул өйрәткән йоланы үтәп, күренмичә генә китәм кызлар артыннан.

Г а л ә ү. Анысын сөйләдең инде.

Г ә р ә й. Юк, бөтенесен дә ишетмәдең әле син, Галәветдин.

Ах, ул кызлар, ах, ул кызлар-кыркыннар,
Ул кызларны күренмичә күрүе!
Кызлар яткан караватның янында
Татлы, тәмле уйлар уйлап йөрүе!
Сул колакның яфрагыннан тәм алып,
Уң колакның яфрагына үрелү!
Мондый рәхәт — җанны кертү мунчага,
Мондый бәхет — үлгәннән соң терелү!

Әйт, телисеңме Галиягә күренми генә аның колак яфракларын үбәргә.

Г а л ә ү. Телим дә бит...

Г ә р ә й. Соң, теләсәң, өйрән абзаңнан.

Г а л ә ү. Син көләсең генә бит. Беренче апрель көнне дә ничә кешене алдадың.

Г ә р ә й. Сине алдадыммы?

Г а л ә ү. Юк та бит.

Г ә р ә й. Син ничек шофёр булып йөрисең, ә? Шофёрлар үткен була бит. Соңгы тапкыр сорыйм, телисеңме Галиягә күренмичә йөрергә?

Г а л ә ү. Башта үзең күрсәт миңа.

Г ә р ә й. Нәрсәне?

Г а л ә ү. Миңа күренмичә йөреп кара.

Г ә р ә й. Син нәрсә, әллә сихерне уен-муен дип белдеңме? Нигә мин синең алда күренмичә йөрим. Әллә ко-

лак яфрагыңны үбәсем бармы? Аннан соң, абага чәчәге миндә бит бер пот түгел. Ике генә чеметем. Мин капсам, сиңа калмый. Ярый, син теләмәсәң, мин Галияң янына керермен дә күренмичә үбеп чыгармын. Ризамы?

Г а л ә ү. Үбеп кенә кара!

Г ә р ә й. Нишләтәсең?

Г а л ә ү. Соң, алай була алмый бит инде, Гәрәй! Күренмичә йөреп булмый.

Г ә р ә й. Була, диләр сиңа. Син сынап кара. Сынап караудан ни була? Әнә бит пьеса язучылар сынап карыйлар. Комедия язып конкурска җибәрәләр. Үзләрен дә сынап карыйлар, жюри членнарын да сынап карыйлар. Барып чыкмаса, язудан туктыйлар.

Г а л ә ү. Әллә ниләр беләсең!

Г ә р ә й. Син дә бел, Галәветдин!

Г а л ә ү. Йә, әйтеп кара доганны.

Г ә р ә й. Дога гына түгел ул, Галәветдин! Игътибар белән тыңла. Кыйбла якка карап басасың. Ике кулыңның ун бармагын кушырып түшеңә куясың. Колак салып тыңлыйсың. Сиңа син ишетмәгән бер музыка, көй иңәр. Аңладыңмы? Мин китеп торам. Син мин әйткәннәрне эшлә. Берәр көй ишетсәң, мине дәшәрсең. Шунда син ышанырсың минем сүзләремә. *(Чыгып китә.)*

Галәү ул кушканнарны эшли. Һәм, чыннан да, көй ишетә.
Ул көйне без — тамашачылар да ишетәбез.

Г а л ә ү *(Гәрәйне чакыра)*. Гәрәй? Мин ишеттем ул көйне.

Г ә р ә й. Әйтмә. Миңа әйтмә. Үзең генә бел. Мин читкә авышкач, шул көйгә җыр чыгар.

Г а л ә ү. Нинди җыр?

Г ә р ә й. Нишләтәсең килә Галияне? Шул хакта җырла. Җырлап туктагач, тагын тыңла, Галиянең тавышы ишетелгәндәй булыр.

Г а л ә ү. Мин аңа атап гел җырлыйм, тавышы ишетелми.

Г ә р ә й. Димәк, тыңлый белмисең. Колагың белән түгел, күңелең белән тыңла. Мин читкә авышып торам. Җырла!

Г а л ә ү. Кычкырыпмы?

Г ә р ә й. Мәхәббәт җырын кычкырып җырламыйлар. Әкрен генә, моңлы итеп. *(Чыгып китә.)*

Г а л ә ү *(җыр суза).*

Уйлыйм сине таңнар аткан чакта,
Уйлыйм сине кояш чыккан чакта.
Уйлыйм сине салкын кышлар үтеп,
Алмагачта бөре шыткан чакта.
Син уемда кояш батканда да,
Күктәге ай нурын сипкәндә дә,
Сандугачның сайрауларын хатка салып,
Җилләр аша сиңа бүләк иткәндә дә.
Ятсам, төшләремә керәсең дә
Үзәккәйләремне өзәсең лә,
Беләсең лә, синең утларыңда
Минем янганымны сизәсең лә.

*(Шул чакта, Галиянең «Галәветдин» дигән назлы тавышын ишетеп, сискәнеп китә.)*

Гәрәй, Гәрәй, мин ишеттем аның тавышын!

Г ә р ә й. Ышандыңмы инде, Алла бәндәсе. Мә, кап шушы бер чеметем абага чәчәген. Бу сиңа төнге сәгать уникегә хәтле җитә. Ул вакытка хәтле әйтәсе сүзеңне әйт Галиягә!

Г а л ә ү. Үлмәм микән, Гәрәй!

Г ә р ә й. Әллә син үзеңне тере дип беләсеңме? Кап тизрәк, озак тотсаң, сихере бетә.

Г а л ә ү *(кабып).* Әче. Борыч ич бу.

Г ә р ә й. Әллә сиңа бал каптырырлар дип көткән идеңме? Мәхәббәт ул төче генә булмый.

Г а л ә ү. Әйдә көл инде, көл миннән. Тик көлгәнеңне кешеләргә сөйләмә, ярыймы? Ишетсәм, бәреп үтерәм. Галиядән курыксам да, синнән курыкмыйм мин. Йә, ничек, мин сиңа күренәмме?

Г ә р ә й. Син Галия турында уйладыңмы, аңа атап җырладыңмы? Син бөтен кешегә күренәсең, Галиягә генә күренмисең. Аңладыңмы?

Җырлап, х а т ы н - к ы з л а р кайталар.

Н у р а н и я. Рәхмәт яусын сиңа, Гәрәй! Кырык ел суга кермәгән идем, рәхәтләндем.

Г ә р ә й. Миңа рәхмәт әйтмә, Нурания апа! Айдар Исламовичка рәхмәт әйт. Ул бүләк итте бу көнне.

Н у р а н и я. Син оештырдың, рәхмәт! Җыештыручы дип тормадың, мине дә алдың.

Г ә р ә й. Безнең илдә, Нурания апа, идән себерүче дә, министр да, депутат та бертигез.

Н у р а н и я. Тфү, нәгаләт, телең!..

Г ә р ә й. Мин — экспедитор, Галия — бухгалтер, син — җыештыручы. Кайчан тамак аерганыбыз бар? Тамакларыбыз бер безнең, хезмәт хакларыбыз гына төрле.

Н у р а н и я. И-и, шушы юк-бар сөйләвең өчен яратам да инде үзеңне! Хәзер безне нишләтәсең?

Г ә р ә й. Әнә агач күләгәсе, алып килгән җәймәңне җәй дә рәхәтләнеп ят, Нурания апа!

Н у р а н и я. Шулай итми булмастыр. *(Җырлый-җырлый китә.)*

Г а л и я. Нишләп үзең генә, Галәветдинең кайда?

Г ә р ә й. Күрмәдеңмени? Нәрсәгә кирәк булды соң әле? Сорашканың юк иде моңа кадәр.

Г а л и я. Үзең әйттең бит, үзең кодалап йөрисең.

Г ә р ә й. Үпкәләп кайтып китмәгәндер ич.

Г а л и я. Автобусы монда ич.

Г ә р ә й. Чыннан да, кая китте икән? Ярый, кайтса әйтермен, Галия эзләде, диярмен.

Г а л и я. Эзләмәдем, болай гына сорадым. *(Китеп бара.)*

Г а л ә ү. Әллә чынлап күрмәдеме мине?

Г ә р ә й. Нәрсә әйттем мин сиңа, ышандыңмы инде?

Г а л ә ү. Ышанмадым да...

Г ә р ә й. Бар, калма артыннан. Ул хәзер агач артында киемен алыштыра, карап тор. Куса, күренгән буласың, кумаса, үзеңә кара.

Г а л ә ү. Юк. Карамыйм. Ярамый.

Г а л и я *(җәймә күтәреп килә)*. Шушында гына ятыйм әле. Күләгәсе дә иркен икән.

Г ә р ә й. Син ят. Мин су коеныгра киттем.

Г а л и я. Минем янга ятмыйсыңмы?

Г ә р ә й. Син Галәү килгәнне көт инде.

Г а л и я. Аның килгәнен көтсәң... Егет булгач, эләктереп алсын иде дә ул, кысып кочакласын иде. Кочагында эретсен иде.

Г ә р ә й. Ашыкма, бер кабынып китсә, эреп парга әйләнерсең. *(Галәүгә күз кысып чыгып китә.)*

Г а л и я *(җәймә өстенә сузылып ята)*. Их, рәхәте!

Җәйнең гүзәл кызу көннәрендә
Болыннарның яшел мендәрендә,
Күләгәле куак төпләрендә,

Йоклап киткәч татлы төшләреңдә,
Бер сөйгән яр табылсын иде.
Уянып ла киткән чакларымда,
Ятсаң иде дә кочакларында,
Янсаң иде дә учакларында,
Күңелнең серле почмакларында
Гыйшык уты кабынсын иде.

Галиянең җырын Галәү әсәрләнеп тыңлый. Ләкин Галиягә якын ук килергә базмый. Галиянең аны күрмәвенә ышанып ук бетми. Андый булмаган хәлгә кем ышансын. Шулай да ышанасы килә, шайтан алгырысы.

Галия җырын дәвам итә.

Бергә-бергә тормыш корсаң иде,
Бергә ятып, бергә торсаң иде.
Шатлык чәчеп, бәхет урсаң иде,
Тормыш рулен бергә борсаң иде.

Галәү. Булыр, Галия! *(Шунда ук, ник әйткәненә оялып, авызын учлары белән томалый.)*

Галия *(сикереп тора, як-ягына карана)*. Абау! Кем бар монда?.. Әллә ниләр ишетелә. Әллә башка кызу сукты инде. *(Тагын сузылып ята.)*

Галәү аңа сокланып карап тора. Галиягә якын килмичә генә, янәшәсенә ятып карый. Үлән кыягы өзеп ала да шуның белән Галиянең аяк табаннарын кытыклый.

*(Янә торып.)* Әллә кырмыскалы урынга туры килдем инде?

Галәү, тыела алмыйча, кете-кете көлә.

*(Галия тагын як-ягына карана.)* Нәрсә соң бу? Галәү көлүенә дә охшаган. Ул шулай кызык итеп көлә. Әллә төш күрәм инде? *(Ята.)*

Галәү, әкрен генә үрмәләп килеп, Галиянең сул колак яфрагын үбә. Галия тагын торып утыра.

Абау, ни булды соң бу?

Галәү. Мин бу, Галия!

Галия. Кем соң?

Галәү. Мин ич инде – Галәү! Көлүемнән таныдың.

Галия. Кайда соң син?

Г а л ә ү. Янында!

Г а л и я. Янымда булгач, нигә күренмисең?

Г а л ә ү. Мин синең төшеңә кердем.

Г а л и я. Ничек кердең? Мин әле йокламадым да.

Г а л ә ү. Йокламыйча күргән төшләр дә була.

Г а л и я. Җыен юк-барга син ышанып йөрисең.

Г а л ә ү. Юк-бар түгел, Галия! Әйт, син мине күрәсеңме?

Г а л и я. Ничек күрим булмагач? Син әллә Галәү булып сөйләшүче пәриме?

Г а л ә ү. Чын Галәү мин, Галия! Мин сиңа күренмим генә. Ничек күренмәгәнемне аннары сөйләрмен. Син курыкма.

Г а л и я. Ничек курыкмыйсың ди. Тавышың бар, үзең юк. Нигә миңа күренмисең?

Г а л ә ү. Оялам! Мин синнән оялам бит, Галия! Бухгалтериягә путёвканы керткәндә, сине күрсәм, телем бәйләнә. Ничә ел инде. Ә син мине күрмисең дә. Күренсәм дә күрмисең. Ишетәм инде, пешмәгән, дисең. Пешмәгән түгел мин, Галия! Оялчан да түгел. Сине күргәч кенә шулай.

Г а л и я. Колагымнан син үптеңме?

Г а л ә ү. Мин. Ачуланма инде, Галия!

Г а л и я. Кызларны колагыннан үпмиләр, иреннәреннән үбәләр.

Г а л ә ү. Миңа Гәрәй өйрәтте. Сиңа күренми йөрергә дә ул өйрәтте.

Г а л и я. Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Ул колактан үбәргә ярата.

Г а л ә ү. Әллә үпкәне бармы?

Г а л и я. Үпкәне юк, үрелгәне бар.

Г а л ә ү. Күренепме, күренмичәме?

Г а л и я. Ул син түгел. Бөтен этлеген күренеп эшли.

Г а л ә ү. Юк, этлек эшләми ул. Ул сине дә, мине дә бәхетле итәргә тели. Минем сине яратканны белә ич ул.

Г а л и я. Син чынлап та мине яратасыңмы?

Г а л ә ү. Сизәсеңдер ич инде.
Сандугачлар таңны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!
Бөдрә таллар суны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!

Ак каеннар язны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!
Аккош күлен сөеп яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!

Галия. Әй Галәветдин, Галәветдин! Күзгә күренеп йөргән егетне яраталар шул кызлар. Син гел күләгәдә. Исемең дә Галәветдин. Фердинанд йә Марсель булсаң иде, ичмасам.

Галәү. Миңа ул исемне әти кушкан. Галәветдин дигән кешенең тылсымлы лампасы булган. Мин генә әле тылсымлы лампаны таба алмыйм.

Галия. Кызык кына, үзең күренмисең, ә үпкәнең сизелә. Кулларымнан тотып кара әле, сизәрләр микән?!

Галәү *(Галиянең кулларын учына алып)*. Сизеләме?

Галия. Кул икәне сизелми, кайнары сизелә. Кочаклап кара әле?!

Галәү *(Галияне кочаклап)*. Сизеләме?

Галия. Бигрәк кайнар икәнсең син, Галәветдин!

Галәү. Син кайнар булганга, мин кайнар ул, Галия!

Галия. Син күрен, Галәү, сине күрәсем килә!

Галәү. Булмый шул, Галия! Мине төнге уникегә хәтле күренмәс итте Гәрәй. Әйдә су буена, Галия!

Галия. Нишлим анда, әле яңа кайттык.

Галәү. Син йөзәрсең, мин карап торырмын. Йөзгәндә син аккош кебек, Галия!

Галия. Арттырма инде, йә ышанырмын.

Галәү. Валлаһи, билләһи, шулай.

Галия. Әйдә соң, алайса. Ал җәймәне.

Галәү җәймәне ала.

Һай, бир тизрәк!

Галәү. Ни булды, Галия?

Галия. Җәймә күренә, син күренмисең. Кешеләр әллә ни уйлар. *(Җәймәне ала.)*

Чыгып киткәндә, Гәрәй очрый.

Гәрәй. Кая юл тоттың, Галиякәй?!

Галия. Галиякәй түгел мин сиңа, Галия! Кая телибез, шунда барабыз.

Гәрәй. Син патшалар кебек, «без» дип сөйләшәсең икән.

Галия. Шундый инде без. *(Чыгып китә.)*

Г ә р ә й *(Галәүне туктатып)*. Йә, ничек?

Г а л ә ү. Гаҗәп. Ул ышана, мин ышанмыйм.

Г ә р ә й. Син ышан, Галәветдин! Кешеләр чынга түгел, ялганга ышана. Коммунизмда яшибез, дигәнгә миллионнар ышанды. Бар, калма. Һәм йөзәргә өйрән. Йөзә белгәннәр заманасы бүген.

Г а л ә ү чыгып йөгерә.

Г ә р ә й. Бәхетле кешеләр чүтеки бар дөньяда.

И л ү з ә пәйда була.

И л ү з ә. Гәрәй абый, мәтрүшкә нинди була ул?

Г ә р ә й. Агачтан кырып ясыйлар. Буяп күз, борын, авыз ясыйлар, яулык бәйләтәләр.

И л ү з ә. Мин аны әйтмим. Анысы аның — матрёшка. Мәтрүшкә ул чәчәк икән.

Г ә р ә й. Анысы, әйе, үлән. Мәтрүшкә чәчәге шәмәхә төсле була. Синең кебек сары чәчәклесе дә була. Анысын, сары мәтрүшкә, диләр. Нәрсәгә кирәк булды әле мәтрүшкә?

И л ү з ә. Нурания апа ире белән мәтрүшкә җыйганда танышкан икән.

Г ә р ә й. Мине әллә мәтрүшкә җыярга чакырасыңмы?

И л ү з ә. Әйе.

Г ә р ә й. Мәтрүшкә әле чәчәк атмаган.

И л ү з ә. Бәлки, аткандыр, карап кайтыйк, Гәрәй абый!

Г ә р ә й. Монда мәтрүшкә юк.

И л ү з ә. Нурания апа, бар, ди.

Г ә р ә й. Дисә, аның белән барыгыз.

И л ү з ә. Минем сезнең белән барасым килә.

Г ә р ә й. Әй, сары мәтрүшкә, бәйләнмәле миңа. Үзләре килеп сыланалар да көчләде дип судка бирәләр. Кит, бозма тәһарәтемне. Вәт ахырзаман сандугачлары! Нигә елыйсың?

И л ү з ә. Үзе мыскыл итте дә...

Г ә р ә й. Кем сине мыскыл итте? Кем килеп бәйләнә беренче? Синме, минме?

И л ү з ә. Мәхәббәт өчен көрәшергә кирәк, ди Нурания апа.

Г ә р ә й. Нәрсә белә ул Нурания апаң. Менә мин аны өзелеп сөям, ул аны сизми дә.

Илүзә. Сезме? Нурания апанымы?
Гәрәй. Мин шул. Нурания апаңны.
Илүзә. Карт ич инде ул.
Гәрәй. Мин дә карт, йөрисең бит артымнан.
Илүзә. Бабае бар бит Нурания апаның.
Гәрәй. Нәрсә ул безгә бабай?
Илүзә *(көлеп)*. Мин сезне шуның өчен яратам, Гәрәй абый!
Гәрәй. Бабай өченме?
Илүзә. Җүләр булганыгыз өчен. Сез дә мине яратасыз.
Гәрәй. Мин сине ни өчен яратырга тиеш инде?
Илүзә. Җүләр булганым өчен. Җүләр бит мин. Сезнең кебек. Менә күрегез. Мин – балерина. *(Биеп күрсәтә.)*
Гәрәй. Тукта. Кеше әллә ни уйлар.
Илүзә. Әйдәгез кеше күрмәгән җиргә. Мәтрүшкә җыярга.
Гәрәй. Нинди афәт соң син? Кит моннан, Барби курчагы!
Илүзә. Курчак белән уйныйлар бит, Гәрәй абый!
Гәрәй. Мин курчак уйнар яшьтән узган. Аңлыйсыңмы?
Илүзә. Юк, аңламыйм.
Гәрәй. Аңлатырлар әле, болай йөрсәң. Бәлки инде, аңлатканнардыр да. Нәрсә тасраеп карап торасың?
Илүзә. Менә хәзер аңладым. *(Кинәт борылып китә башлый.)*
Гәрәй. Тукtale, кызый! *(Илүзәнең кулыннан тота.)*
Илүзә. Җибәрегез!
Гәрәй. Әйт, нәрсә аңладың?
Илүзә. Сез бүтәннәр кебек үк пошляк икән. *(Чыгып йөгерә.)*
Гәрәй *(Илүзәгә ияреп)*. Илүзә! Илүзә!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук урын, шул ук әрәмәлек. Сихри төн. Дискотека бара. Шау-шу. Көчле музыка. Ял итәргә килүчеләр теләсә нинди бию хәрәкәтләре ясап сикерәләр, селкенәләр, калтыраналар. Барыннан да бигрәк Нурания рәхәт чигә.

Нурания *(ниһаять, биючеләрдән читкәрәк китеп ава)*. Уф, үләм! Бәлки инде, үлгәнмен дә, оҗмахтыр бу. Рәхмәтләр яусын сиңа, Гәрәй!

Гәрәй. Миңа түгел, Айдар Исламовичка рәхмәт.

Нурания. Белмим, белмим. Бөтенегезгә рәхмәт. Путиныгызга да рәхмәт, Шәймиевебезгә дә рәхмәт! Ятсын әле Нургали өйдә берүзе бикләнеп, сагынсын әле Нуранiясен. Торырга булыш әле, Гәрәй! Тагын бер үлгәнче биим әле. *(Магнитофон белән идарә итүче Галәүгә.)* Кызларныкын биедем. Инде үзебезнекен дә биик. Килегез әле, кызлар, тотынышыгыз әле кулларыгыз белән. Син, Илүзә, уртага чыгып бас әле.

Кызлар түгәрәк ясап тезелә.

Башладык. *(Җыр башлый.)*

Уртага чыктың да бастың,
Кемдә синең уйларың?
Уйлаган уйларың белән
Үтсен иде туйларың...
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

«Талы, талы» дигәндә, биеп торырга кирәк. «Талы, талы» дип, барыгыз да җырлагыз.

Барысы да «талы, талы»ны кабатлыйлар. Илүзә биеп тора.

Нурания. Берәрсенә бас. Ул уртага чыксын. Үзең безгә кушыл. *(Җырлый башлый.)*

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем;
«Сөймә мине, сөй башканы»
Дигәнче сөячәгем.
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

Яшьләргә бу уен ошый. Нураниягә кушылып җырлыйлар, бииләр. Уртага Гәрәйне дә чыгаралар.

Әй, дускаем, буең зифа –
Тал кебек бөгеләсең.
Таллар кебек бөгеләсең –
Кем өчен өзеләсең?
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Сагындым, күрәсем килеп
Үзәк өзелеп тора.

Көй «Дубыр-дубая»га күчә.

Су буена төшкән идем –
Су буйлары каз гына.
Күп уйласаң саргаерсың,
Уйламый тор аз гына.
Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая,
Зәңгәр яулыгыңны бәйләп
Кая бардың син бая?
Су буена төшкән идем –
Су буйлары әрәмә;
Бик ялынгач, бер үптердем,
Әнкәй, зинһар, әрләмә.
Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая,
Кыска итәгеңне киеп
Кая бардың син бая?

Бию, сәхнәгә генә сыймыйча, залга да күчәргә тиеш. Бию, кабат сәхнәгә кайткач, кинәт туктый. Барысы хәлдән таеп егылалар.

Н у р а н и я. Үләм! Үләм! Гәрәй! Гәрәйҗан! Тагын нишләтәсең безне?!

Г ә р ә й. Сулыш алыгыз бераз.

Н у р а н и я. Кирәкми! Үләргә икән, биеп үләргә. Җылап үлде димәсеннәр, биеп үлде дисеннәр.

Г а л я. Давайте женим Гарай Хамитовича! Туй сыграем.

Г ә р ә й. Ты чего, Галябану? Какой туй?

Г а л я. Сколько можно ходить в холостяках. Все надеемся на тебя. Поженим, девочки?

Бу идея барысына да ошый. «Өйләндерәбез! Өйләндерәбез!» дип кычкыралар.

Н у р а н и я. Валлаһи, дөрес бит бу. Кызлар ымсындырып йөрмәсен, койрыгын бозга катырырга кирәк.

Г а л я. Девочки, стройтесь! Гарай Хамитович невесту будет выбирать.

Н у р а н и я. Әйдәгез, тезелегез! Сайла, Гәрәй!

Г ә р ә й *(уенны кабул итеп)*. Сайларгамы? Тәк... тәк... Син бармыйсың, Нурания апа. Беренчедән, кияүгә чыгарга яшең тулмаган, икенчедән, Нургали абзыйны беләм мин, сиңа өйләнсәм, икебезнең дә ботыбызны сугып сындырачак. Галя, Галина, Галябану, выйдешь за меня замуж?

Г а л я. Выйду!

Г ә р ә й. Не выйдет, Галочка! Ты замечательная, прелестная, очаровательная, таинственная девочка...

Н у р а н и я. Нинди девочка булсын, ике баласын Николаена калдырып килде.

Г ә р ә й. Дәшмә, Нураниякәй! Монда хатыннар юк, монда кызлар гына.

Г а л я. Правильно, дөрес! Приедем домой, станем бабами. Здесь все девочки. Выбирайте, Гарай Хамитович!

Г ә р ә й. Значит так, милая Галочка, я при всей моей любви к тебе, не могу жениться на тебе. Во-первых, я – мусульманин, во-вторых, я – магометанин, в-третьих, ваххабист.

Г а л я. Вы же безбожник, Гарай Хамитович!

Г ә р ә й. Тем более. Не хочу портить замечательную биографию прелестной Галочки. *(Гөлинә янына туктап.)* Гөлинә!.. Гөлинә!.. Чыгасыңмы миңа, Гөлинә?

Г ө л и н ә. Чыгам, Гәрәй абый!

Г ә р ә й. Ярый, мин бу турыда уйлап карармын. Тәк... Галия чутка керми. Егете бик усал... Нигә бер сүз дә дәшмисең, Галия?

Г а л и я. Мин сине күрмим бит, Гәрәй!

Г ә р ә й. Бөтенләйме?

Г а л и я. Кечерәйгәннән-кечерәя барасың. Ә син мине күрәсеңме?

Г ә р ә й. Ике булып күренәсең.

Н у р а н и я. Егете юк аның.

Г ә р ә й. Син беләсеңме, Нурания апа, мин беләмме? А-а-а, Сәкинә!.. Ул да чутка керми, Минтимере бар.

Хәтта мин аны сайласам да, ул миңа чыкмас иде. Дөресме, Сәкинәкәй?

Сәкинә. Дөрес!

Илүзә *(чәчрәп чыгып)*. Мин чыгам Гәрәй Хәмитовичка! Берегезгә дә бирмим. Аласызмы мине, Гәрәй Хәмитович?

Гәрәй *(каушап калган)*. Синең чират җитмәде бит әле.

Илүзә. Мин чиратсыз керергә өйрәнгән. Әйтегез, нишләргә безгә? Кем регистрация ясый, кем никах укый? *(Югалып калган Гәрәйне, җитәкләп, агач янына алып килә.)* Туй өстәленең башы шушында булыр. Кияү белән кәләш шунда утыра.

Нурания. Туктагыз, монда әле башкода бар. Сорашмыйча, белешмичә кыз биреп булмас. Гәрәй Хәмит улы Ганибаев, син Илүзә... Илүзә, әтиеңнең исеме ничек?

Илүзә. Мөхәммәт.

Нурания. Гәрәй Хәмит улы, син Илүзә Мөхәммәт кызын үзең теләп кәләшлеккә алдыңмы?

Илүзә. Алды, алды!

Нурания. Синнән сорамыйлар. Чиратыңны көт.

Егетләрнең егете,
Күп кызларның өмете –
Хәмит углы Гәрәйҗан,
Башың белән йөрәгең
Үзләренә кирәген
Белеп сайладылармы?
Мөхәммәт кызы Илүзәне
Үз итеп алдылармы?

Хор. Хәмит углы Гәрәйҗан,
Мөхәммәт кызы Илүзәне
Кәләшлеккә алдыңмы?

Гәрәй. Мөхәммәт кызы Илүзә
Шундый итеп карады.
Хәмит углы Гәрәйҗан
Каршы килә алмады.

Хор. Үзең теләп алдыңмы?

Гәрәй. Алмый кая барасың,
Табалмагач чарасын.

Хор. Үзең теләп алдыңмы?

Г ә р ә й. Алдым!

Н у р а н и я. Асылларның асылы,
Йөрәккәе ярсулы
Мөхәммәт кызы Илүзә,
Башың белән йөрәгең
Үзләренә кирәген
Белеп сайладылармы?
Хәмит углы Гәрәйҗанны
Үз итеп бардылармы?

Х о р. Мөхәммәт кызы Илүзә,
Хәмит углы Гәрәйҗанга
Үзең теләп чыктыңмы?

И л ү з ә. Хәмит углы Гәрәйҗан
Миңа сөеп карады,
Мөхәммәт кызы Илүзә
Аны гына сайлады.

Х о р. Үзең теләп чыктыңмы?

И л ү з ә. Чыкмый нишли аласың,
Табалмагач чарасын.

Х о р. Үзең теләп чыктыңмы?

И л ү з ә. Чыктым!

Н у р а н и я. Туй! Туй! Галәветдин, нәрсәң бар, уйнат!

Г а л ә ү. Миндә дискотека гына.

Н у р а н и я. Хәчтерүш! Ыргыт магнитофоныңны, үзебез җырлыйбыз.

Х о р. Туй! Туй! Туй итәбез,
Парсызны парлы итәбез.
Котлы булсын туйларыгыз,
Бергә булсын уйларыгыз.
Котлы булсын, Гәрәй, туең,
Сиңа — чын, безгә — уен.
Туй! Туй! Туй туйлыйбыз —
Туй ясап уен уйныйбыз.
Котлы булсын бәйрәмегез,
Тәмле булсын чәйләрегез.
Бу, Илүзә, синең туең,
Сиңа — чын, безгә — уен.

И л ү з ә. Туктагыз! Мин киявем белән вальс әйләнергә телим. *(Гәрәйне, җитәкләп, уртага алып чыга. Аны, әйләндереп, сәхнә алдына алып килә.)* Нигә җебедегез, Гәрәй Хәмитович! Елмаймыйсыз да. Җитди булу сезгә килешми.

Г ә р ә й. Син нәрсә кыландырасың?

И л ү з ә. Кияүгә чыктым ич. Ирем белән биергә хакым бар. *(Әйләндереп, уртага алып килә.)* Әйдәгез, күз йомыш уйныйбыз, кияүнең күзен бәйлибез, ул мине тотарга тиеш.

Гәрәйне уратып алып, яулык белән күзен бәйлиләр.

И л ү з ә. Син мине күрәсеңме?

Г ә р ә й. Юк!

И л ү з ә. Күрмәсәң эзлә! Чур!.. *(Баскан җирендә катып калган Гәрәй тирәсендә әйләнеп йөри дә кочагына керә.)*

Г а л я. Горько! Горько!

Гәрәй, Галя янына барып, аны үбеп ала.

А причём я?

Г ә р ә й. Тебе же горько, Галочка!

Г а л я. Невесту целуй.

Г ә р ә й. Невеста еще несовершеннолетняя.

Г а л я. Ха!

И л ү з ә. Чё «ха»? Мин әле сабый гына. Беләсегез килсә, мин Гәрәй Хәмитовичның кызы. Ул моннан ун ел элек минем унсигез яшьлек әниемне алдап киткән. Тугыз айдан мин туганмын. Исәнме, әтием! *(Гәрәйнең муенына асылына.)*

Г ә р ә й. Нишлисең син, тиле?

И л ү з ә. Мин тиле түгел, әтием! Нәрсәнең ни икәнен аңлап өлгермәгән кызый. Туй өзелә, хөрмәтле кунаклар! Әтиләр үз кызларына өйләнә алмый.

Н у р а н и я. Әйдәгез су керергә. Төнлә дә коенып карыйм әле. Сагынып сөйләрлек булсын.

Шаулашып чыгып китәләр. Гәрәй, Галия, Галәү калалар.

Г а л и я. Галәү кая китте соң ул, күренми?

Г ә р ә й. Әнә ич.

Г а л и я. Кайда? Күрмим ич. Барысы да, Галәү, диләр, мин күрмим. Нишләп әле син боегып калдың?

Г ә р ә й. Нинди кыз соң бу сары баш?

Г а л и я. Син бит кызлар күңеленең докторы! Кемгә нишләргә кирәклеген өйрәтеп йөрисең. Бар, су кызларын күзлә.

Г ә р ә й чыгып китә.

Галәветдин, син мондамы соң?

Г а л ә ү. Монда, Галия! Син һаман да мине күрмисеңме?

Г а л и я. Күрәм дә кебек, күрмим дә кебек. Ике күзеңнән нур чәчелә.

Г а л ә ү. Минем күзләр түгел ул, Галия! Автобус фарасы яктырта.

Г а л и я. Шулаймыни, Галәветдин! Бигрәкләр ышанучан инде син. Сине бик күрәсем килә бит, Галәветдин! Кайчан күренә башларсың икән?

Г а л ә ү. Күп калмады, Галия! Тиздән төнге унике тула. Беләсеңме, Галия, сиңа күренми йөрү минем үземә ошый. Әгәр дә кешеләр бер-берсен күрмичә генә сөйләшсәләр, бәхетлеләр күбрәк булыр иде. Гәүдә белән гәүдә түгел, җан белән җан гына сөйләшер иде. Фәрештәләр күренми йөргәнгә, кешеләр аларга кызыгалар.

Г а л и я. Боларны син үзең уйлап таптыңмы, берәрсеннән ишеттеңме?

Г а л ә ү. Мин дә уйлый беләм бит, Галия!

Г а л и я. Фәрештәләрнең җенесе юк ич, Галәветдин! Алар колак яфрагыннан үбә белмиләр.

Г а л ә ү. Көлмә инде, Галия! Әгәр дә мин күренә башласам, минем белән шулай сөйләшерсеңме, Галия? Мине пешмәгән дип мыскыл итмәссеңме?

Г а л и я. И минем пешмәгәнем, и минем җебегәнем, дип иркәләрмен.

Г а л ә ү. Кит инде. Алай булмый инде ул.

Г а л и я. Ә син мине кысып кочакларсың да мине эретеп җибәрерсең.

Г а л ә ү. Яныңа килгәнемне сизәсеңме, Галия?

Г а л и я *(Галәүне капшап)*. Бу синме?

Г а л ә ү. Әллә кулларың мине сизә башладымы? *(Галияне кочагына алып.)* Мин шундый да сизәм синең барлыгыңны, Галия! Әгәр дә бүген, туй ясаганда, миңа пар сайларга кушсалар, мин сине генә сайлар идем, Галия! Ул уен туй булмас иде, чын туй булыр иде.

Г а л и я. Галәветдин, бәгырькәем, син күренә башладың бит! Менә синең йөзең. Менә чәчләрең.

Г а л ә ү. Унике тулды дамыни?

Г а л и я. Тулды, Галәветдин!

Г а л ә ү чыгып йөгерә. Аның артыннан «Галәветдин!» дип Галия чаба. Каршысына Гәрәй очрый.

Г ә р ә й. Төнге сәгать уникедә кая чабасың, Галия?

Г а л и я. Галәветдин күренә башлады. *(Чыгып чаба.)*

Г ә р ә й *(агачка элеп куйган гитарасын ала. Чиртеп, «Хәмдия» көенә җыр башлый.)*

Күк тулы йолдызлар, ай кайда?
Янмаган йөрәккә май кайда?
Гәрәйҗанның кара чәче
Яңа агарган чагы.
Гәрәйҗанга сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы.
Җүләр сатып яшәп ни файда?
Бүтәнчә яшәргә җай кайда?
Гәрәйҗанның кара чәче
Яңа агарган чагы.
Гәрәйҗанга сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы.

*(Илүзәне күреп, җырын дәвам итә.)* Тагын килдеңме, салам баш?

И л ү з ә. Тагын килдем чакыргач!

Г ә р ә й. Чакырмадым бит мин сине.

И л ү з ә. Чәчем агара, дип җырладың лабаса. Нигә агарганын мин беләм.

Г ә р ә й. Әйт, нигә?

И л ү з ә. Вөҗдан газабы кичерәсең, Гәрәй абый! Намусына тап төшермәгән кызны бозыклыкта гаепләдең.

Г ә р ә й. Гаепләмәдем мин, сүз җае туры килгәнгә генә әйттем.

И л ү з ә. Гафу үтенмәдең!

Г ә р ә й. Үтендем бит инде, җанкисәгем!

И л ү з ә. Тезләнеп гафу үтенмәдең.

Г ә р ә й *(дүрт аяклап Илүзә каршына килә)*. Зинһар өчен, гафу ит мине, салам баш, Барби курчагы, кычыткан чыпчыгы!

И л ү з ә. Бу сүзләрең өчен гафу үтендермим. Чөнки яратып әйтәсең.

Г ә р ә й. Яратмыйм мин сине, яратмыйм, яратмыйм!

И л ү з ә. Яратасың, яратмаган кешенең башыннан сыйпап иркәләмиләр.

Г ә р ә й. Кайчан, кайчан сыйпадым башыңнан?

И л ү з ә. Складка товар бушата идегез. Мин үтеп бара идем. Син минем исемдә дә юк идең, сыйпадың да...

Син минем сигез яшьтә түгел, унсигез яшьтә икәнлегемне белергә тиеш идең.

Г ә р ә й. Кем белеп бетергән сине. Йә кәләшлеккә сикереп чыгасың, йә «әти» дисең.

И л ү з ә. Ир күпмедер дәрәҗәдә хатынының әтисе дә булырга тиеш.

Г ә р ә й. Бу чаклы башың белән нишләп син университетка кермәдең? Училище бетереп бездә кулинар булып йөрисең.

И л ү з ә. Ә мин пешеренергә яратам. Минем ирем мин пешергән тәмле ризыкны ашарга тиеш. Сөяркәләренең закускасына кызыгырлык булмасын.

Г ә р ә й. Синең программаң әзерләп куелган.

И л ү з ә. Плансыз яшәргә ярамый дип кем әйтә?

Г ә р ә й. Мин әйтәм. Ләкин минем дә планым бар бит. Мин ирек яратам. Мин унҗиде яшьтән үк акча, товар тирәсендә буталам. Ләкин бер тиенлек тә хилафлык кылганым юк. Чөнки прокурор белән судьядан куркам. Ирегемнән мәхрүм итүләре куркыта. Ирегемнән мәхрүм буласым килми. Ирек яратам мин, салам баш! Ә син, мине үзеңә бәйләп куеп, ирегемне алырга телисеңме? Өйләнсәм дә сиңа, аерып җибәрәм бит үзеңне.

И л ү з ә. Юк, аера алмыйсың.

Г ә р ә й. Ник?

И л ү з ә. Балга кунган чебен очып китә алмый.

Г ә р ә й. Бу сүзеңә каршы әйтер идем бер сүз, гафу үтендерерсең.

И л ү з ә. Тезләндереп, диген.

Г ә р ә й. Тезләндереп.

И л ү з ә. Менә шулай. Минем сүзне сөйли башладыңмы?

Икебез бер сүзне сөйләрбез,
Икебез атларбыз бер эздән;
Һәр язны бергәләп язларбыз,
Ямь алып һәр җәйдән, һәр көздән.
Кышларның бозлавык юлыннан
Таймыйча бергәләп атларбыз,
Яшьлектә бергәләп кабызган
Учакны сүндерми сакларбыз.
Ал минем учымны учыңа —
Серләрем кушылсын сереңә.
Йөрәкләр йөрәккә ялгансын,
Наз алып береңнән береңә.

Г ә р ә й. Ахырзаманда хатын-кыз азар, диләр иде, дөрес, ахрысы.

И л ү з ә. Ирләр беткәнгә без гаепле түгел. Йолдызларга кара, Гәрәй абый! Алар безнең мәхәббәтебезнең бөреләнүенә шаһитлар. Исеңдә калдыр, Гәрәй абый! Картайгач сөйләшергә сүз булыр. Оныкларыбызга сөйләрбез. Бая Галя «Горько!» дип кычкырганда, мине үпмәдең. Хәзер бурычыңны түлә. Бит уртамнан үбәргә рөхсәт итәм.

Г ә р ә й. Әй Алла, бар икән күрәселәрем!

И л ү з ә. Яратырсың син мине, Гәрәй абый!

Г ә р ә й. Яратмаслык түгел дә инде син. Үз башыма оештырдым бу пикникны. Үзең җавап бирәсең, дигән иде Айдар Исламович. Кил, бас әле янәшәмә.

И л ү з ә. Нигә, Гәрәй абый?

Г ә р ә й. Кунакка барганда, биек үкчәле туфли киярсең инде. Вьетнам кызына өйләнгән димәсеннәр.

И л ү з ә. Карале, кара, Гәрәй абый, Галәү абый нишләгән ул? Менә сиңа мыштым. Галия апаны кулларына күтәргән. Мине дә күтәр әле, Гәрәй абый!

Г ә р ә й. Кил! *(Илүзәне култык астына кыстыра.)*

И л ү з ә *(тыпырчынып)*. Алай итмә инде, Гәрәй абый, мин бит чегән баласы түгел!

Гәрәй Илүзәне матур итеп кулларына күтәргәндә,
Г а л и я н е күтәреп, Г а л ә ү керә.

Г а л и я. Бәтәч! Төшер, Галәветдин! *(Галәү кулыннан сикереп төшә.)* Сез нишлисез монда?

И л ү з ә. Сез нишлисез соң?

Г а л и я. Без шаярып кына.

И л ү з ә. Ә без чынлап.

Г а л и я. Галәветдин, күрәсеңме боларны?

Г а л ә ү. Кирәкмәгәнне күрмә, Галия! Мине күрсәң, шул җиткән.

Г а л и я. Сөбханалла, Галәветдин!

И л ү з ә. Урынны бушатабыз. Әйдә, Гәрәйчик, мәтрүшкә җыярга! *(Гәрәйне култыклап алып чыгып китә.)*

Г а л ә ү. Эләгә Гәрәй, дип йөргән идем, тәки эләккән. Чуртан балыгы да кармакка эләкми, ялтыравыклы блеснага эләгә шул.

Г а л и я. Телең ачылды синең, әйеме, Галәветдин!

Г а л ә ү. Ачкычы синдә иде бит, Галия!

Г а л и я. Син мине ачуланмассың инде, Галәветдин!
Г а л ә ү. Ни өчен?
Г а л и я. Шушы Гәрәйгә өметләнеп йөрдем бит мин.
Г а л ә ү. Анысын да беләбез.
Г а л и я. Тагын ниләр beләсең, Галәветдин?
Г а л ә ү. Син минем өчен яратылган, шуны беләм.
Г а л и я. Бөтен белгәнебезне әйтешеп бетерик, Галәветдин! Соңыннан гаепләшерлек булмасын. Син инде, Гәрәй ялганына ышанып, мине Галия күрми, дип йөрдең. Мин сине күрдем бит, Галәветдин! Гел күреп тордым. Күрмәгән булып кыландым гына. Ачуланма инде, Галәветдин! Син инде бүтән ышанма Гәрәй ялганына.
Г а л ә ү. Рәхмәт әйт син Гәрәйгә, аның ялганына ышанмаган булсам, син һаман да әле мине күрә алмас идең, Галия! Мин дә бит синең мине күргәнеңне белдем, Галия! Пешмәгән булсам да, мин тиле түгел.
Г а л и я. «Пешмәгән» сүзен бүтән әйтмә, Галәветдин!
Г а л ә ү. Туйны кайчан ясыйбыз, Галия? Озакка сузмыйк, безгә унҗиде түгел.
Г а л и я. Сиңа ничектер, миңа бүген унҗиде.
Г а л ә ү. Кирәкми, яшәрмә, Галия! Син миңа болай күбрәк ошыйсың. Мин Гәрәй түгел бала-чагага тагылып йөрергә.
Г а л и я *(машина килеп туктаган тавышны ишетеп)*. Автобусыңны алып китәләр, Галәветдин!
Г а л ә ү. Автобус тавышы түгел бу, иске «Запорожец» тавышы.

Ул арада Н у р г а л и керә.

Н у р г а л и. Шушындамы?
Г а л ә ү. Син кем?
Н у р г а л и. Нурания мондамы?

Н у р а н и я атылып керә.

Н у р а н и я. Нишләп йөрисең, Нургали?
Н у р г а л и. Ә син монда нишләп йөрисең?
Н у р а н и я. Әйттем ич инде, кунакка барам, дидем.
Н у р г а л и. Мишә буенда кунак буламы? Мишәдә балык кына тоталар. Кемнәр белән килдең?
Н у р а н и я. Ничек инде «кемнәр белән»? Үзебезнең коллектив белән.
Н у р г а л и. Нигә миңа шулай димәдең?

Н у р а н и я. Дисәм, җибәрәсеңмени син?! Йә инде, үз гомеремдә бер гүләйткә чыктым…

Н у р г а л и *(Галәүгә күрсәтеп).* Бу кем?

Н у р а н и я. Үзебезнең Галәветдин ич, автобус шофёры!

Н у р г а л и. Тагын кем бар ирләрдән?

Н у р а н и я. Экспедитор Гәрәй генә. Көнләшмә инде, Нургали, алар бит яшьләр.

Н у р г а л и *(Галәүгә).* Менә яшь чагында да шундый кәнтәй иде ул! Миңа әйтмичә гүләйткә чыккан да киткән.

Н у р а н и я. Ирләрсез, хатыннарсыз гына барабыз, диде Гәрәй.

Н у р г а л и *(Галәү белән Галиягә ишарәләп).* Ә болар?

Н у р а н и я. Алар ир белән хатын түгел бит.

Н у р г а л и. Булмагач, төн уртасында нигә монда торалар?

Г а л ә ү. Абзый, син давай төпченмә. Килгәнсең икән, кунак бул.

Г а л и я. Абзый, читкәрәк китеп ызгышыгыз әле. Кияүгә чыгасым килми башлады.

Н у р г а л и. Без ызгышмыйбыз, без сөйләшәбез. Ызгышсак, утыз алты ел бергә яшәмәгән булыр идек.

Г а л и я. Сөйләшегез, алайса, әйдә, Галәветдин! *(Галәүне култыклап алып чыгып китә.)*

Н у р а н и я. Кеше алдында көлкегә калдырдың. Төнге сәгать бердә килеп төшмәсәң…

Н у р г а л и. Синсез йоклый алмыйм мин.

Н у р а н и я. Машинаң сүнеп интектермәдеме?

Н у р г а л и. «Запорожец» ич ул, «иномарка»!

Н у р а н и я. Син мине күрәсеңме, Нургали?

Н у р г а л и. Нәрсә, абага чәчәге ашадың мәллә?

Н у р а н и я. Үлгәнче биедем, туйганчы коендым. Теге юлы, балыкка килгәндә, «батып үләсең» дип суга кертмәгән идең, бу юлы рәхәтләндем генә. Син кара бу билләремә!

Н у р г а л и. Бил ул кызларда гына була. Кыз чагында бар иде ул билең. Хәзер инде оныгыңның биленә карыйлар егетләр.

Н у р а н и я. Әйдә биибез, Нургали!

Н у р г а л и. Син нәрсә, ычкындың мәллә?

Н у р а н и я. Ычкынасы килә, Нургали! Картаябыз бит, картаябыз.

Нургали. Әллә елый инде.

Нурания. Картаябыз бит!

Үтте дә китте гомерләр,
Чабып узган ат сыман,
Кайда безне сихерләгән
Алсу таңнар, ак томан?
Үтте дә китте гомерләр,
Яшьнәгән яшен кебек.
Яшьлек әйләнеп кайтыр дип,
Алданып яшим кебек.

Шаулашып, су коенырга киткән кешеләр кайта.

Галя. О-о-о! У нас новый кавалер!

Нурания. Он мой! Никому не отдам. Таныш булыгыз, кызлар, бу минем Нургалием!

Бөтенесе дә «Исәнмесез, Нургали!» дип, Нургали белән күрешеп китәләр.

Гөлинә. Кешенең ирләре ир кебек, төнге сәгать бердә эзләп табалар, безнеке ятадыр йоклап. Без йоклыйбызмы бүген, юкмы?

Илүзә. Юк, бүген йоклый торган төн түгел. Галәү абый! Галәү абый!

Галия белән Галәү керәләр.

Галия. Ни булды, нигә кычкырасың?

Илүзә. Мин сине түгел, Галәү абыйны чакырдым. Галәү абый, уйнат оркестрыңны! Кызлар! Сез Гәрәй Хәмитовичны күрәсезме?

Тавышлар. Күрәбез!

Илүзә. Күреп калыгыз. Бүтән күралмассыз. Ул хәзер минеке. Бары тик минеке генә. Әйт, Гәрәй абый, минекеме?

Гәрәй. Йә инде, булды инде.

Илүзә. Юк, әйт. Кычкырып әйт, ишетсеннәр. Без аның белән мәтрүшкә җыярга бардык һәм үбештек.

Гәрәй. Син нәрсә, үбешмәдек.

Илүзә. Син үбәргә уйладың, мин дә каршы килмәдем. Үбешү турында уйлау үбешүдән татлырак, Гәрәй абый!

Гәрәй. Галәү, җибәр инде музыкаңны! Нәрсә йокладың?

Галия. Син аңа кычкырма, Гәрәй Хәмитович! Ул синең хезмәтчең түгел. Галәветдин, уйнат бию көен! *(Нураниягә.)* Биибезме, Нурания апа?

Нурания. Олы кешегә килешмәс, Галия! Нургали дә…

Нургали. Нәрсә «Нургали»… Биергә кымырҗып торасың бит инде.

Нурания. Әллә сизеләме, Нургали? Бераз гына биим дә кайтырбыз, ярыймы?

Илүзә *(Гәрәйне читкәрәк алып китеп)*. Син мине күрәсеңме, Гәрәй абый!

Гәрәй. Күрәм инде, күрәм.

Илүзә. Елмаеп, шатланып, куанып әйт, Гәрәй абый!

Гәрәй *(Илүзәнең башыннан сыйпап елмая)*. Күрәм!

Илүзә. Күрсәң, бүтәннәргә карама, ярыймы. Үкенмәссең, Гәрәй абый! Мин сине дөньяда иң бәхетле кеше итәрмен.

Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая.

Шуны гына көткәндәй, Галәү дә шул көйне кабыза. Бию башлана. Иң кызган чагында гына музыка туктый. Кем нинди хәрәкәт ясаган, шул көе басып кала. Илүзә Гәрәйнең муенына асылынган, Галәү Галияне кулына күтәргән, Нурания – Нургали кочагында.

Пәрдә.

# ШУЛАЙ БУЛДЫ ШУЛ

*(Ике пәрдәле комедия)*

Катнашалар:

Алмаз.
Гөлшат.
Нургали — Гөлшатның әтисе.
Хәлимә — Гөлшатның әнисе.
Әүхәт, Әхәт — Гөлшатның абыйлары.
Фәгыйлә, Фәһимә — Гөлшатның җиңгиләре.
Гамир, Сүрия — Алмаз кунак булган йортның хуҗалары.
Туйга килгән кунаклар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче күренеш

Капка төбе. Утыргыч. Шул утыргычта Гамир белән солдат киемендәге Алмаз утыра. Ачык тәрәзәдән Сүрия карап тора. Вакыт — кич. Көтү кайткан, сыерлар савылган. Йокыга талыр алдыннан авылның гөжләп алган чагы. Гамир сыздырып гармун уйный. Алмаз «Алмагачлары» көенә очына-очына җырлый.

Алмаз. Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап ачыла күңел;
Җырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел.

Г а м и р. Әйт шуны!

А л м а з. Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Чәчәк кебек яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

Г а м и р *(уйнаудан туктап)*. Маладис егет син. Төшеп югала торган түгел.

А л м а з. Булганы белән шул, Гамир абый. Сезнең Дамир да шәп егет.

С ү р и я. Шулай булсын иде инде.

Г а м и р. Пешмәгәннәр, җебегәннәр заманасы түгел бүген. Иртәгә китәм, дисең инде.

А л м а з. Җитәр инде, Гамир абый. Болай да ике көн кунак булдым. Кешедә бит оят дигән нәрсә дә булырга тиеш. Әйеме, Сүрия апа?

С ү р и я. Кайткач нишләргә җыенасың инде? Калхузда эш тә юк хәзер.

А л м а з. Җае табыла аның, Сүрия апа. Планнар зурдан минем, Гамир абый. Башта машина алып җибәрәм, аннан өй салам, аннан өйләнәм.

Г а м и р. Ай-һай-һай... Зурдан икән шул. Авылда яшәп боларны эшләү өчен гомер җитмәс. Син өйләнүдән башла. Иң җиңеле, иң арзаны шул.

С ү р и я. Бозма Алмазны. Хәерче бәндәгә рәтле кыз чыкмый ул.

А л м а з. Дөрес, Сүрия апа. Машина минем хыялым ул, Гамир абый. Минем телем «әннә» дип түгел, «машина» дип ачылган. Машинага мин бернәрсәне дә алыштырмыйм.

Г а м и р. Армиядә дә шофёр идеңме?

А л м а з. Шофёр. Генералны йөрттем.

С ү р и я. Булыр, булыр. Булдыра торганга охшагансың. Әйдә, керегез. Чәй өлгерде.

А л м а з. Син бар кер, Гамир абый. Мин авылыгызны бер әйләнеп кайтам әле. Авылыгыз матур да сезнең, кызларыгыз чибәр түгел.

Г а м и р. Нәрсә, Сүрия апаң да ямьсезмени?

А л м а з. Сүрия апа кызлар түгел ич инде ул.

Г а м и р. Карап йөре, безнең егетләр усал, кыйнап кайтармасыннар. *(Кереп китә.)*

А л м а з. Менә, җәмәгать, шулай башланып китте ул мин сөйлисе роман. *(Көянтә-чиләк күтәреп килүче*

*Гөлшатны күреп.)* Туктагыз әле, җәмәгать... Гафу итегез. *(Гөлшатның каршына чыгып.)* Исәнмесез... Исәнмесез, хур кызы.

Гөлшат, күз кырые белән генә, җирәнгәндәй,
Алмазга карап ала да китә.

Эһе... Чиертмәде бу балык. Чибәр үзе. Ничек бүгенгә хәтле күренмәде икән. Әйе, шулай башланып китте ул мин сөйлисе хикәя. Безнең ротага бер көтү салагаларны китерделәр. Шулар арасында бер татар малае да бар. Танышып киттек бит. Нишлисең, үз татарың бит, сагындыра. Менә шушы авыл егете булып чыкты ул. Без Казаннан кайтканда шушы авыл аша үтеп йөрибез. Салагаларны армиядә нишләткәннәрен беләсез инде. Безнең кебек дедлар, картлачлар инде татарчасы, иманнарын «укыталар» инде аларның. Мин үзебезнең татар малаена тидермәдем. Минем кем икәнне беләләр ич анда. Шулай яшәп менә дембель вакыты җитте. Мин киткәндә, Дамир әйтә, безнең әтиләргә кереп кит, ди. Менә кердем. Җибәрмәделәр. Ике көн сыйладылар. Туйганчы йокладым. Иртәгә китәм... Гафу итегез... Теге чибәр судан кайтып килә. Тагын бер сүз кушам. Чиртмәсә, кармагымны алам да ыргытам. *(Гөлшат каршына чыгып.)* Нигә сәламемне алмадыгыз, чибәр кызый?

Гөлшат аны урап үтмәкче була. Алмаз тагын
аның каршына төшә.

Әллә сезнең телегез юкмы, гүзәлем? Исемегез ничек, матурым?

Гөлшат *(зәһәр итеп карап алып)*. Кит! *(Китеп бара.)*

Алмаз. Ай-яй... Шундый итеп карады, үтерә язды. Кызлар янына якын бармаслык итте. Әгәр дә шундый кызга өйләнеп, хатының шулай итеп караса...

Нургали *(Алмаз янына килеп туктап)*. Нихәл?

Алмаз. Исәнмесез?!

Нургали. Кыз ошадымы?

Алмаз. Нинди кыз?

Нургали. Ике тапкыр каршына чыктың бит.

Алмаз. Ә-ә-ә... Аны әйтәсең икән. Чибәрен чибәр дә...

Нургали. Нәрсәсе ошамады?

А л м а з. Бик усал, ахрысы. Шундый итеп карады.

Н у р г а л и. Минем кыз ул… Нургали минем исемем. Шулай… Әнә тора безнең өй.

А л м а з. Минем исемем Алмаз.

Н у р г а л и. Беләм, Гамир сөйләде. Солдаттан кайтып барасың икән.

А л м а з. Барам шул.

Н у р г а л и. Ярый… Шулай… Әти-әниләрең бармы?

А л м а з. Бар.

Н у р г а л и. Булгач, нигә монда ятасың? Көтәләрдер бит.

А л м а з. Җибәрмиләр. Иртәгә китәм инде.

Н у р г а л и. Иртәгә… Ярый… Кайткач нишлисең инде?

А л м а з. Вәт кызык. Нигә миннән сорау аласыз әле? Күз күрер әле.

Н у р г а л и. Күз ул төрлесен күрә. Кирәкмәгәнне дә. Шулай… Өйләнәсеңдер дә инде.

А л м а з. Уйлаган юк. Өлгерер әле.

Н у р г а л и. Әйе… Шулай… Өлгергәч, өзелеп төшә инде ул. Ярый… Әти-әниләрең кемнәр?

А л м а з. Кемнәр булсын. Председатель түгел инде, эшлиләр.

Н у р г а л и. Ярый… Эшләгәч ярый. Шулай… Минем турыда нәрсә уйлыйсың инде син?

А л м а з. Туктагыз әле, абзый кеше…

Н у р г а л и. Абзый кеше түгел, Нургали абзый. Әйт, ниндирәк кеше инде мин?

А л м а з. Каян белим?

Н у р г а л и. Ярый… Белмәгәч ярый. Шулай… Минем турыда ни уйлыйсың?

А л м а з *(көлеп)*. Каян килеп чыкты бу кеше дип уйлыйм.

Н у р г а л и. Тагын?

А л м а з. Тагынмы? Нигә миңа бәйләнә дип уйлыйм.

Н у р г а л и. Дөрес уйлыйсың. Гамир абыең нәрсә сөйли минем турыда?

А л м а з. Берни дә сөйләми.

Н у р г а л и. Минем кыз турында ни сөйлиләр?

А л м а з. Бернәрсә сөйләмиләр.

Н у р г а л и. Ярый… Шулай… Инде болай… Минем кыз ошадымы сиңа?

А л м а з. Әйттем ич инде...

Н у р г а л и. Әйе... Шулай... Усал ул. Безнең нәселдә юашлар юк. Безнең авыл өч нәселгә бүленгән: Шәйхел нәселе, Хәмәт нәселе, Сафа нәселе. Шәйхелнекеләр менә Гамирлар. Алар — нәселләре белән гармунчылар, җырчылар. Хәмитнекеләр — муллалар, укытучылар, врачлар. Без — Сафа нәселе. Без — эш кешеләре. Усаллар. Безнең бабай ат карагы булган. Син усалдан курыкма, юаштан курык. Бездә хатын аеру, ирне ташлап китү юк. Бездә — тәртип. Армиядәге кебек. Шулай. Безнең өйдә мин ни әйтсәм, шулай була. Минем кыз сиңа берәр сүз әйттеме?

А л м а з. Кит, диде.

Н у р г а л и. Шулай... Ярый... Ни өчен син аның каршысына чыктың инде?

А л м а з. Мин бит аның сезнең кыз икәнен белмәдем.

Н у р г а л и. Белсәң чыкмас идеңме?

А л м а з. Кызык икәнсез сез. Мин бит бернишләмәдем.

Н у р г а л и. Нишлисең киләме соң?

А л м а з. Ничек инде «нишлисең киләме»?

Н у р г а л и. Өйләнер идеңме шул кызга?

А л м а з. Ничек?

Н у р г а л и. Шулай... Шул кыз, әйтик, сиңа кияүгә чыгарга риза булса, өйләнер идеңме?

А л м а з. Ничек инде... Мин аны белмим дә ич әле.

Н у р г а л и. Белмисең, әйе... Шулай... Кем белеп өйләнә... Яши-яши беләсең. Анда да белмисең әле. Шулай...

А л м а з. Бераз йөрергә кирәктер инде ул.

Н у р г а л и. Кирәктер, әйе... Шулай. Әйтик, кызның йөрергә вакыты булмаса? Хәзер үк кияүгә чыгарга теләсә?

А л м а з. Теләгәнен әйтмәде бит.

Н у р г а л и. Әйтер. Мин дә бар бит әле монда... Шулай. Гөлшат ошады дисең инде, алайса. Ошамаслык түгел... Шулай... Ошаса, ал син аны. Бирәм.

А л м а з. Нәрсә? Бирәсез? Ничек?

Н у р г а л и. Бирәм. Тик торганнан түгел. Бирәм. Өч көннән туй ясыйбыз.

А л м а з. Китегез әле. Алай булмый ич инде.

Н у р г а л и. Булдырсаң була. Шулай... Ничек?

А л м а з. Уйларга кирәк монда. Әти-әниләр дә бар. Алар ни әйтер? Киңәшергә кирәк.

Н у р г а л и. Киңәшергә кирәкми. Ник дигәндә... Әйе... Шулай... Сиңа ошаган кызның гаебе бар. Кил мондарак... Шулай... Нинди гаебе бар дип сора. Әйтәм — аны алдаганнар. Казанда укый иде. Шунда бер сволычы алдаган. Хәзер өйдән чыкмый.

А л м а з. Ничек «алдаган»?

Н у р г а л и. Кызларны ничек алдыйлар соң? Шулай... Шулай... Кара аны, бу турыда берәүгә дә ишеттерәсе булма. Өйләнсәң-өйләнмәсәң дә, бу турыда биш кенә кеше белергә тиеш. Иң беренче — син, аннары — Гөлшат үзе, аннан соң хатын белән мин, аннары инде теге алдаучы сволыч.

А л м а з. Кем соң ул?

Н у р г а л и. Каян белим? Әйтми кыз. Яраттым, ди. Теге алдаган да тайган. Мондый нәрсәнең безнең нәселдә булганы юк. Бәреп үтерә идем кызны, әнисе каршы төште. Шулай... Шуннан артыгын белмә, кирәксә, үзе сөйләр. Аласыңмы шундый кызны?

А л м а з. Кыз түгел ич инде ул. Ә нигә аны миңа бирәсез? Авылыгызда бүтәннәр юкмы?

Н у р г а л и. Үз авылыңда ни пешерсәң дә исе чыга. Без безнең нәсел турында сүз чыгуын яратмыйбыз. Сез китәсез дә югаласыз. Шулай.

А л м а з. Кызыгыз ризамы соң миңа чыгарга?

Н у р г а л и. Аның ризалыгын кем сораган. Бер айлык корсагы бар. Әйттем, теләсә кемгә тотып бирәм, дидем.

А л м а з. Корсагы бар, дидегезме?

Н у р г а л и. Бар. Шулай...

А л м а з. Абзый, сез нормаль кешеме?

Н у р г а л и. Энем, мин алай сөйләшкәнне яратмыйм.

А л м а з. Алайса, нигә мине җүләргә саныйсыз.

Н у р г а л и. Санамыйм. Өйлән, аерып җибәрерсең. Рөхсәт итәм.

А л м а з. Безнең нәселдә дә хатын аермыйлар, Нургали абзый.

Н у р г а л и. Ярый... Шулай... Аңлашылды... Яратсаң да өйләнмисеңме?

А л м а з. Үзегез өйләнер идегезме соң?

Н у р г а л и. Юк... Шулай... Инде болай... Юри генә өйләнгән бул.

А л м а з. Ничек инде анысы?

Н у р г а л и. Туйда кияү булып утыр. Туйдан соң ки-

тәрсең дә барырсың. Ни өчен икәнен төшенәсеңме?

Алмаз. Кияү ташлап киткән, дип әйтер өченме?

Нургали. Маладис. Үткен егет, дигән иде Гамир, дөрес икән. Йә, ничек?

Алмаз. Юк, абый. Мин жулик түгел.

Нургали. Кем әйтә сиңа жулик дип. Коткар безне хурлыктан. Әнисе сөйләшкән, төшерттермим дип әйтә, ди. Хурлыгы ни тора. Нургали кызы зинадан бала тапкан, дип сөйләсәләр, хурлыгыңнан үләрсең.

Алмаз. Әйтегез соң, кияүгә чыккан да кияве ташлап киткән, диегез.

Нургали. Алдарсың безнең авыл халкын. Туйсыз ничек кияүгә чыксын. Белмиләрмени шуны. Туй булса… Риза бул. Бушка түгел. Шулай…

Алмаз. Акча түләпмени?

Нургали. Туйда утырсаң, тиешлесен аласың да китеп барасың.

Алмаз. Ай-яй-яй… Акча алдың дип, буаз кызыгызны сылап куяр идегез бугай.

Нургали. Буаз димә, сыер түгел ул. Әгәр кызымны шулай мыскыл итәрлек булсаң… Безнең нәселдә алдакчылар юк, энекәш. Шулай… Әйткәнмен икән — эшлим. Кызыма орындырттырмыйм да. Тиешлесен аласың да китәсең. Мин сине белмим, син мине белмисең, вәссәлам.

Алмаз. Күпме соң инде ул тиешлесе?

Нургали. Үзең әйт. Мин бәясеннән тормыйм. Утыз сигез баш умартам гына бар минем. Тракторым бар. Ике машинам бар.

Алмаз. Машиналарыгыз нинди?

Нургали. «УАЗ» белән «Ока». Шулай…

Алмаз. «Ока»сын бирәсеңме?

Нургали. Җүләр түгел син, малай. Шундый киявем булса, мин… Ярый, әйдә.

Алмаз. Әйтеп куям, Нургали абзый, киявегез булмыйм. Туйда утыруны уйлап карармын.

Нургали. Озак уйлама. Тагын бер әйтәм, бу турыда берәүгә дә…

Алмаз. Бер сүз әйтмим…

Нургали. Шулай… Ычкындырсаң, кара аны, минем икешәр метрлы ике улым бар. Холыклары бик начар.

Алмаз. Анысы аның миндә дә бар абыйлар. Берсе кеше кыйнаган өчен егерме ел утырып чыкты, берсе һаман

да утыра. Алайса, болай, Нургали абзый, кызыгызны минем янга чыгарыгыз. Әйтегез, минем белән сөйләшсен.

Нургали. Нәрсә турында сөйләшмәкче буласың?

Алмаз. Табармын ни турыда сөйләшергә.

Нургали. Безнең сөйләшкәнне әйтмисең. Чынлап өйләнәсең дип белсен. Әтиең риза булды, диген. Тик кулың белән орынмыйсың. Орынсаң, муеныңа тагып җибәрәбез. Шулай... Авылдан читкә дә чыкмыйсыз. Урамда. Кешеләр күрсен.

Алмаз. Машинаны онытмагыз. Аны минем исемгә дә күчерергә кирәк бит әле.

Нургали. Анысы синең кайгы түгел. Туй буласы көнне машина язулары кесәңдә булыр. *(Китеп бара.)*

Алмаз. Әйе... Шулай... Ярый... Нәрсә булып бетәр икән бу галәмәт? Әллә сызаргамы яхшы чакта? Аферист бу абзый. Ә миңа нәрсә. Шулай да шикләндерә. Карбыз йоткан кызларын ябыштырып куюлары бар. Сылап куйсалар нишләргә? Уен эш түгел. Һәй, алайга китсә, мин генәме балалы хатынга өйләнүче. Һәй, беткән баш беткән. Туйда утыруы үзе ни тора.

Беткән башлар беткән, диеп
Әйтәләр күптән.
Безгә дә диңгез тубыктан –
Беткән баш беткән.
Кемнәрне кемнәр кочкан да
Кем кемне үпкән:
Кызлар ни дә хатыннар ни –
Беткән баш беткән.
Өсләр бөтен, тамаклар тук –
Безгә шул җиткән.
Алдагысын Алла белә –
Беткән баш беткән!

*(Нургалиләр өе ягына карап.)* Әкәмәт, тәки чыгарды бит бу моны. Эшләр тирәнгә кереп бара бит әле монда. Уйла, Алмаз, уйла. Эшләт башыңны. Төп башына утыртмасыннар. *(Көянтә-чиләк күтәргән Гөлшат каршына чыгып.)* Су күп эчәсең икән, Гөлшат туташ. Кич белән дә су ташыталар. Шушы бүрәнә өстендә минем белән утырып торырга теләмисезме? *(Гөлшат селкенмәгәч.)* Ярый соң, алайса. Галиябану белән Исмәгыйль шикелле урам уртасында басып кына сөйләшик. Кара, сезнең

телегез юк мәллә ул? Телсез кызга өйләнәммени мин? Минем сезгә өйләнәчәкне белмисезмени әле? Ничек инде ул булачак ирегез белән сөйләшмисез? Карале, әтиегез әллә бер сүз дә әйтмәдеме? *(Гөлшатның ачулы карашын күреп.)* Алай итеп карамагыз инде. Чибәр кызларга усал булу килешми. Усал хатын белән ничек торырмын? Нишләтим, бигрәк тә ошадыгыз бит. Әтиегезгә әйткән идем, бирәм, диде. Матур итеп яшәрбез, Алла боерса. Матур-матур балалар үстерербез.

Гөлшат. Идиот!

Алмаз. Иди-от?.. Телегез ямьсез сүз белән ачылды. Ярый... Яхшы... Шулай... Бөтен ямьсез сүзләрне әйтеп бетердегез. *(Урамнан үтеп баручы берәүгә.)* Исәнмесез! Кеше алдында гына булса да елмаегыз инде. Зерә сез мине мыскыл итәсез. Шәп егет мин. Менә дигән итеп яшәрбез. Мин иртән торырмын да «Карчык, чәй өлгердеме?» диярмен, син «Хәзер, картым, хәзер» дип йөгереп йөрерсең. Кочаклашып аерылышырбыз, кочаклашып күрешербез. Безгә карап бөтен авыл сокланыр.

Гөлшат. Козёл!

Алмаз. Кара, нинди сүзләр беләсең. Казанда күп нәрсәгә өйрәткәннәр икән сине. Урысча гына сиптерәсең. Соң, бәгырькәем, мин козёл булгач, син козлиха буласың ич инде. Между прочим, моннан ике ай элек Казаннан килгән бер салага «козёл» дигән иде миңа. «Козёл» дип әйткән теле белән аяк табанымны ялады. Бар суыңа. Өеңә кайткач, әтиеңә әйт, ул миңа өйләнергә теләми, диген. Ферштейн, козлиха? *(Гөлшат киткәч.)* Кара син аны. «Козёл» дип алдаган Казан козёлына әйтсен. Мин аңа яхшылык эшләргә җыенам, ә ул. Кирәкми. Машиналары да кирәкми. Менә сез, машиналы булам дип, шушы сүзләрне ишетер идегезме? Эшләр шундыйга китте бит әле. Әйе... Шулай... Туктале, нәрсә мин?.. Әйтсә ни. Үгез булмагае чурт булсын, малайларга сөт булсын, әйе бит? Аның шулай әйтүе яхшы да әле. Каршыңда елмаеп торса, йә чыннан өйләнерсең. Алып кайтырсың әни янына буаз кәҗә. Сез инде мине, зинһар өчен, гафу итегез, җәмәгать. Хатын-кызга андый ямьсез сүз әйтергә ярамыйдыр. Нишләтәсең, дөнья бит бу. Алдыйсың да, алданасың да. Алла сакласын, әни әйтмешли. Ну бит үзе дә гаепле, әйтмәсен теләсә нәрсә. «Хайван» дисә дә, түзәр идең әле, «козёл» ди бит. Хәер, козёлы да хайван

инде аның. Ярый, тынычлан, Алмаз. Дөнья бу, әллә нинди сүзләр ишетерсең әле. Юк өчен кайгырма да. Ишәк кайгырсын. Машина кулыңа керәм дигәндә. Иртә кичтән хәерлерәк, әни әйтмешли.

Кичен син хәерче,
Иртән баерсың.
Иртәгесе өчен
Ишәк кайгырсын.
Кичен син өйләнгән,
Иртән аерымсың.
Иртәгесе өчен
Ишәк кайгырсын.

*(Тәрәзә каршына барып.)* Гамир абый... Гамир абый...

Гамир *(тәрәзәне ачып)*. Мин монда, Алмаз.

Алмаз. Мин өйләнәм бит, Гамир абый.

Гамир. Нәрсә, сөйгән кызың көтәмени авылда? Дөрес эшлисең. Башта өйлән, койрыгыңны бозга катырып куй. Машина качмый ул. Менә Сүрия апаң белән машинасыз да яшибез бит әле. Өен дә бергәләп җитештерерсез.

Алмаз. Мин сезнең авыл кызына өйләнәм. Өч көннән туй.

Гамир. Туй? Кәмит малай син.

Алмаз. Мин чынлап әйтәм, Гамир абый.

Гамир. Чынлап? Кемгә? Матур кызлар юк, дигән идең ич.

Алмаз. Табылды.

Гамир. Кем инде ул?

Алмаз. Гөлшат. Нургали абый кызы. Шулай...

Гамир. Әкәмәт, каян күреп өлгердең?

Алмаз. Мин бит егет кеше, Гамир абый. Күрдем дә гашыйк булдым. Үзе дә мине ошатты. Алып китәм, дим, дәшми. Дәшмәү ризалык билгесе бит инде ул. Шулай...

Гамир. Казанда укый түгелме соң ул?

Алмаз. Заочныйга күчәр.

Гамир. Белмим, белмим. Сүрия! Кая әле? *(Тәрәзә янына килгән Сүриягә.)* Ишетәсеңме, Алмаз ни ди. Өйләнәм, ди. Нургали кызы Гөлшатка, ди.

Сүрия. Кит әле?!

Алмаз. Мин әйткәнемне үлсәм дә эшлим, Сүрия апа.

Сүрия. И сез, яшьләр, яшьләр. Бигрәк башсызлар инде. Уен эш түгел бит өйләнү. Кай арада сөйләшеп

өлгерәләр. Нургали бар бит. Ул узып баручы солдатка кыз бирәме? Акча түртеп, укырга урнаштырдылар. Укып яткан җиреннән!

Алмаз. Мин дә укырмын. Туксанга җитмәгән. *(Узып киткән Гөлшатка ымлап.)* Чибәр бит.

Сүрия. Әй! Бездән көләсеңдер әле?

Алмаз. Көлүдән эш узды, Сүрия апа. Нургали абзый риза булса, туйны монда ясап китәм. Булмаса, урлап качам.

Сүрия. И башсызлар, башсызлар. Дөнья шуларга кала бит инде.

Алмаз. Сезнең баш бар иде дә бит, дөньяның рәте юк. Башсыз, бәлки, яхшырактыр ул, ә, Гамир абый?

Гамир. Кем белә инде аны. Кара инде үзеңә. Ул-бу була күрмәсен. Нургалинең малайлары бикниләр, тия күрмәсеннәр. Әти-әниләрең белән сөйләшергә иде. Качмас иде әле Нургали кызы!

Алмаз. Кача, Гамир абый. Мин аның башын әйләндердем. Башы әйләнгәндә эләктереп калырга кирәк. Яратам мин аны. Әниләр белән сөйләшсәң, мәңге өйләнә алмассың.

Сүрия. И Алла... Башсызлар. *(Гамирга.)* Әйдә, ят. Иртән торасы. *(Алмазга.)* Сиңа шунда верандага җәйгән. Кереп ят, йөрмә тилереп.

Тәрәзәне ябалар.

Алмаз. Ышанмыйлар. Ышанырлык та түгел бит. Сез дә ышанмыйсыздыр әле. Юкка сөйли бу дип уйлыйсыздыр. Юк, мин бары тик булганны гына сөйлим. Шулай... *(Урамнан узып баручы Нургалинең каршысына чыгып.)* Нургали абзый, эшләр ниерәк бит әле. Кызыгызның сөйләшәсе килми.

Нургали. Муеныңа асылынганын көткән идеңмени?

Алмаз. Ну бит... Шулай да... Ике сүз әйтте... Икесе дә шундый сүзләр...

Нургали. Түзәрсең.

Алмаз. Түзәрсең дип... Үземне мыскыл иттерергә...

Нургали. Машинаны тигенгә бирәләр дип уйладыңмыни? Бушка килгән машина өчен утыртып та куялар әле. Егет бул, сөйләштек бит...

Алмаз. Берәр җаен табарга иде бит. Туйда да янәшә утырасы бар.

Н у р г а л и. Тап. Егет кеше бул шулай…

А л м а з. Минем мондый кызны күргәнем юк.

Н у р г а л и. Башың яшь. Әллә нindиләрен күрерсең әле.

А л м а з. Кызык сез. Кулыннан тотарга ярамый, тегесе ярамый, монысы ярамый.

Н у р г а л и. Кем әйтә ярамый дип? Тот. Тик өйләнәсеңне генә онытма.

А л м а з. Хет, әйтегез инде үзенә, сөйләшсен.

Н у р г а л и. Янына куып чыгарганым да җиткән. Сөйләшмәсә, исең китмәсен. Бик матур басып тордыгыз. Күрәсе кеше дә күреп китте. *(Гамирлар тәрәзәсенә килеп.)* Гамир!

Г а м и р *(тәрәзәдән күренеп)*. Кем бар анда? Ә-ә-ә… Нургали абый. Ни бар?

Н у р г а л и. Туйга чакырырга килдем. Килегез. Гармуныңны онытма.

Г а м и р. Чын булдымыни инде?

Н у р г а л и. Чын булмыйча. Өйләнешәбез, диләр бит. Яратышабыз, диләр. Нишләтәсең аларны? Шулай…

Г а м и р. Кай арада табышалар…

Н у р г а л и. Бөтенесенә өлгерәләр шул. Килми калма. Хатыныңны иярт, онытма. Аналарын саткыры. *(Китеп бара.)*

А л м а з. Әйе… Шулай… Җиңел түгел шул гомер итүләре, әни әйтмешли. Ничегрәк нитәргә соң? Орынырга яраса бер хәл. Кысып кочаклар идең ул, тыпырчыныр иде, тешләр иде, тырнар иде, аннан җәтмәгә эләккән балык кебек тынар иде. Тынар иде дә кыздырып ашар идең. Ярый… Шулай… Хәерле булсын Хәмидәнең туйлары. Шулай… Шулай итеп, җәмәгать, бер көн үтте, икенче көн җитте. Гөлшат белән тагын бер тапкыр очраштык. Монысында тагын бер мәртәбә козел булдым, бер тапкыр дурак, бер тапкыр сарык. Тагын бер кат әйттем этисенә, йә чыгарма кызыңны яныма, йә сөйләшсен адәм рәтле, дидем. Ярый… Шулай… Иртәгә туй дигән кичне дә очраштык. *(Көянтә-чиләк күтәреп килүче Гөлшатны каршы алып.)* Хәерле кич, Гөлшат. Сөйләш, димим, сөйләшмә. Дөньядагы бөтен хайваннарның исемен тагып бетердең. Тирем калын минем, түзәм мин. Син миңа арыслан, юлбарыс исемнәрен генә әйтмәдең. Каян беләсең, бәлки, мин арысландыр? Карама

алай усал итеп, курыкмыйм. Син барыбер минеке булачаксың. Минем янымa чыгасың килми, әтиең барыбер чыгара бит һәм дә ки бирәчәк тә әле. Карама, дидем. Мин кызлар күргән егет. Татар кызын да, марҗа кызын да. Ләкин дә син уйлама, мин бозык түгел. Начармы, яхшымы — мин чип-чиста егет кеше. Әбием әйтеп үстерде — кызлар каргышыннан курык, диде. Бу безнең туй алдыннан соңгы очрашуыбыз — әйтәсе сүзеңне әйтеп кал.

Г ө л ш а т. Бөтенесен дә беләсеңме?

А л м а з. Беләм.

Г ө л ш а т. Нигә өйләнәсең?

А л м а з. Әйттем ич, ошаттым. *(Гөлшат китеп баргач, әле генә әйткән сүзен кабатлый.)* Бер күрүдә ошаттым... Кара, чынлап әйттем бит бу сүзләрне. Теләсәгез ни әйтегез, ошый миңа бу. Их, артык җире дә булмаса. Яратмаса да яраттырыр идем мин аңа. Әллә ул чынлап өйләнмәгәнемне сизә инде. Хатын-кыз сизгер була, диләр бит. Чынны ялганнан аера, диләр. Алайса, нигә алданган? Һә-ә-әй, алданмагандыр да әле. Үзләре егетләр муенына асылына да, эш узгач, алдандым дигән булалар. Беләбез инде. Иртәгә туй диген, ә. Уйландыра башлады әле.

Туй, туй, туй, туй, туй килә —
Җүләр башка уй килә.
Туйлар ничек үтәр икән,
Ахыры матур бетәр микән?
Туен туйлаган егетне
Нинди язмыш көтә икән?
Туй, туй, туй, туй, туй килә —
Төрле-төрле уй килә.
Туй, туй, туй, туй, туй килә —
Башка төрле уй килә.
Туй узгач, туннар тузармы,
Гомерләр зарлы узармы?
Туйда биегән егетләр
Туйдан соң кул сузармы?
Туй, туй, туй, туй, туй килә —
Төрле-төрле уй килә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

А л м а з. Менә туй көне дә килеп җитте. Шулай... Инде хәзер Гамир абыйларның капка төбеннән Нургали абзыйларның капка төбенә күчәбез. Капканы ачып куйганнар болар. Кешеләр күрсен диптер инде. Мәш киләләр.

Туй, туй, туй, туй, туй килә,
Төрле-төрле уй килә.

Миңа туй кәчтүме алганнар. Шулай... Шулай да әйбәт кеше түгел мин, әйеме. Бер машинага кызыгып... Туктале, ә нәрсәсе начар? Мин бит аны алдамыйм. Ошаттым дип әйткәнмен икән, чынлап та ошаттым. Калганы мин чыгарган бәет түгел. Аннары мин бит ул машинаны эшләп алам. Берәүләр туйда кияү булып утырып хатынлы була, мин – машиналы. Ни начарлыгы бар... Шулай... Туй кәчтүмен салдырып калдырырлар микән? Һәй, калдырсалар тагын. Әзерләнәләр. Ә мин әзер. Солдатка нәрсә аңа. Ятты – йоклады, торды – юынды, шагом марш! Вольно! Смирно! Здравие желаю! Вәссәлам... Чабышалар... Нәрсә сөйләшәләр икән, тыңлап карыйсы килә. *(Читкәрәк китә.)*

Нургалиләр ишегалдында мондый сөйләшү бара.

Х ә л и м ә. Хәерле генә була күрсен.
Н у р г а л и. Булыр. *(Өйгә кереп китә.)*
Х ә л и м ә. Килен! Фәгыйлә! Фәһимә!

К и л е н н ә р чыга.

Ф ә г ы й л ә. Ни бар, әнкәй?

Х ә л и м ә. Башым әйләнгән. Карап чыгыгыз әле, бөтенесе дә бармы?

Ф ә г ы й л ә. Барысы да бар. Бисмилла итеп ашасыннар гына.

Ф ә һ и м ә. Гөлшат җылый да җылый.

Х ә л и м ә. Җылый торган көне. Мин дә җыладым, сез дә җылагансыздыр.

Ф ә г ы й л ә. Без бит юри генә җыладык. Модасы шундый бит. Бу – чынлап...

Ф ә һ и м ә. Бер сүз дәшми. Үзалдына карап утыра да җылый.

Ф ә г ы й л ә. Риза түгел, ахрысы, ул.

Х ә л и м ә. Риза булмыйча. Кем аны көчләп биргән?

Ф ә һ и м ә. Егете болай чибәр күренә. Офитсәргә укый, ди әткәй, дөрес микән?

Х ә л и м ә. Әткәең әйткәч, дөрес булмыймы?

Ф ә һ и м ә. Бигрәк тиз бит.

Х ә л и м ә. Армиядә көтеп торалар, ди. Өйлән дә кире кайт, дип әйткәннәр. Әткәегез шулай ди.

Ф ә һ и м ә. Офитсәр хатыны булу әйбәт инде.

Х ә л и м ә. Сезнекеләр дә генералдан ким түгелләр. Барыгыз, бәлешне карагыз.

К и л е н н ә р кереп китәләр.

Н у р г а л и *(өйдән утыргычлар күтәреп чыгып)*. Кирәкмәгәнне сөйләмә боларга.

Х ә л и м ә. Нәрсә сөйлим ди. Гөлшат җылый, диләр.

Н у р г а л и. Җыласын. Күп көлгәч, бер җылыйсың ул.

Х ә л и м ә. Хәерле булсын, хәерле булсын. Кем уйлаган бит, кем уйлаган?

Н у р г а л и. Беркем берни уйламаган. Берни уйламаганга шулай булган. Баш белән уйламыйлар бит хәзер, арт белән уйлыйлар. Ояты безгә. Сезнең нәсел галәмәте бу. Җилбәзәкләр сезнең нәселдә. Безнең нәселдә мондый хәл юк.

Х ә л и м ә. Безнең нәселнең дә андый азып-тузып йөргән даны чыкмаган.

Н у р г а л и. Менә чыкты. Ахырына хәтле уйлап бетермисең. Миңа чыкканда да бер әйтүем булды, риза булдың.

Х ә л и м ә. И Алла! Сине белмиммени инде мин?!

Н у р г а л и. Күп беләсең шул.

Х ә л и м ә. И-и-и, синең белән торганга рәхмәт юк. Бер рәтле сүзең булмады. Малайларыңны да гел сүктең дә гел сүктең.

Н у р г а л и. Сүкмәдем, яшәргә өйрәттем.

Х ә л и м ә. Кызыңа «кызым» дигәнең булмады. Гел куркытып үстердең.

Н у р г а л и. Курка, бар... Курыкса... Куркытырсың сезне...

Х ә л и м ә. Бардыр инде, бардыр. Бездә дә бардыр, сездә дә бардыр. Дөньяның асты өскә килде.

Н у р г а л и. Асты өскә килгәндә, нигә безнең кыз аста калырга тиеш?

Х ә л и м ә. Хәерле булсын инде. Үзем матур итеп чыктым. Ике улыбыз матур итеп өйләнде. Бердәнбер кызыбыз…

Н у р г а л и. Булды, җебемә. Миннән узып йөргәч, шулай була ул. Казанга китсен, укысын, дип сайрадың. Менә китте.

Х ә л и м ә. Укымыйча да булмый бит. Үзенең дә укыйсы килде.

Н у р г а л и. Укыды инде. Алты фләге балыма бүләк төяп кайтты. Карап чык өстәлеңне, барысы да бармы? Кызыңа да күз сал.

Х ә л и м ә. И Ходаем, и Ходаем!

Ә ү х ә т белән Ә х м ә т керәләр — икешәр метрлы ике әзмәвер.

Н у р г а л и. Кайда йөрдегез? Кунак булып кына киләсез.

Ә ү х ә т. Нәрсә, без дә кирәк булдыкмыни?

Н у р г а л и. Телеңә салынма. Килеп өстәлләрне рәтләп китсәгез, кулыгыз корымас иде.

Ә х ә т. Хатыннар китте бит, шул җитмимени?

Н у р г а л и. Без сезнең хатыннарыгызны үстермәдек. Сезне үстердек.

Ә ү х ә т. Килгәнебезгә рәхмәт әйт, әти. Әллә нәрсәләр кыландырып ятасың монда.

Н у р г а л и. Нәрсә кыландырам, йә, әйтеп кара әле, күсәк?

Ә х ә т. Кызларны болай кияүгә бирмиләр инде. Узып баручы бер шыпана солдатка кыз тоттырып җибәрәсең.

Н у р г а л и. Малчайт! Кем булдыгыз атагызны тикшерергә? Ыштан киеп өлгерделәр дә аталарын тикшерәләр. Күрсәтермен мин сезгә күрмәгәнегезне! Фермер булганнар, имеш. Икмәк үстерәсе урынга ыспикүлән булып йөриләр дә аталарын өйрәтәләр. Үз кызым, теләсә кемгә бирермен. Пуняли?

Ә ү х ә т. Аңладык.

Ә х ә т. Аңладык, әти.

Н у р г а л и. Шулай… Әгәр дә өстәл янында, кунаклар алдында берәр сүз ычкындырсагыз, ыштаннарыгызны салдырып, каеш чыбыркы белән тунармын. Барыгыз,

өйгә кереп торыгыз, чакыргач чыгарсыз. Малакасуслар. Кая барасыз? Әниегез белән кем исәнләшер?

Әүхәт. Исәнме, әнкәй!

Әхәт. Саумы, әнкәй!

Хәлимәне кочаклап исәнләшәләр дә өйгә кереп китәләр.

Хәлимә. Бигрәк каты бәрелдең.

Нургали. Өйрәтмәсеннәр! Син дә өйрәтмә! Әнә кызыңның җилдән туган баласын өйрәтерсең.

Хәлимә. Әйтмә инде шулай дип, әйтмә инде. Капканы ябып торыйк мәллә, атасы?

Нургали. Торсын. Вакыты җиткәч ябылыр. *(Өйдән чыгып капкага таба атлаучы Гөлшатка.)* Кая барасың?

Гөлшат. Белмим.

Нургали. Ничек инде «белмим»? Чыгып барасың — белмисең.

Гөлшат. Йөреп кайтам.

Нургали. Йөреп кайтканың җиткән. Кер өйгә, киен матур итеп!

Хәлимә. Йөрмә, кызым. Нәрсә инде хәзер. Башың исән булсын.

Нургали. Булмаган баш ничек исән була ди?

Гөлшат. Әйтегез абыйларга. Нәрсә алар миңа шулай карыйлар?

Нургали. Ничек карыйлар?

Гөлшат. Мине мыскыл иткән кебек.

Нургали. Түз абыйларың караганга. Бүтәннәр карамасын. Кер өйгә.

Хәлимә *(Гөлшат киткәч)*. Башы әйләнгән инде аның.

Нургали. Ярый... Бар син дә. Матур итеп киен. Тагасы әйберләреңнең бөтенесен так. Өстәл яныннан кузгалма. Фермер хатыннары чапсын. *(Сәхнә алдына килә, карана.)*

Алмаз *(Нургали янына килеп)*. Мине эзлисеңме, бабай?

Нургали. Бабай... Анагызны саткырлары. Озакламый башлыйбыз. Шулай... Мин әйткәннәрне онытмадыңмы?

Алмаз. Яттан беләм. Мин — армия уставын өйрәнгән кеше.

Н у р г а л и. Кеше... Кеше көләгәләре...

А л м а з. Син, бабай, мине мыскыл итмә. Киттем бардым булыр.

Н у р г а л и. Китеп кара. Машина талоны белән акчасы кесәңдә.

А л м а з. Бөтенесен кире бирәм дә китәм. Шулай...

Н у р г а л и. Нәрсә әле кирле-мырлы сөйләшә башладың? Минем малайларны күрдеңме?

А л м а з. Джиптан төшеп, икәү кереп киттеләр, шулармы?

Н у р г а л и. Шулар. Өстеңә егылсалар гына да сытып үтерәчәкләр.

А л м а з. Минем дә ике абыем бар. Берсе кеше кыйнаган өчен егерме ел утырып кайтты, икенчесе һаман да утыра.

Н у р г а л и. Шыттырма, энекәш. Барысын да беләбез. Барып белешеп кайттылар. Бер дә әллә кем түгел. Ишелергә торган өегез, аварга торган капкагыз, егылырга торган әтиең, җылап утыручы әниең бар. Шулай...

А л м а з *(кинәт юашланып калган)*. Әллә?..

Н у р г а л и. Әллә шул менә. Син курыкма. Әгәр чынлап торып өйләнсәң, кеше итәбез үзеңне. Өйләнмәсәң дә сүзем юк. Мин алдаша белмим. Бар, кер безгә. Сиңа кияү кәчтүне алынган. Киен дә түр башына чыгып утыр. Кер, шүрләмә, сиңа тиюче булмас. Кара аны, чыраең сытып утырма. Элеккеге кебек елмайган бул. Өстәлдә аракы булмый — өметләнмә. Әче балны күп эчмә — йоклата. Минем малайлар сүз әйтсә, кылтырап төшмә, бабайга әйтеп, иманыгызны алдырам, диген. Бар.

А л м а з кереп китә. Әкрен генә к у н а к л а р килә. Исәнләшеп кереп китәләр. Г а м и р белән С ү р и я керәләр. Гамир гармун кыстырган.

Г а м и р. Әссәламегаләйкем, Нургали абый?

Н у р г а л и. Уз әйдә. Шулай...

Г а м и р. Мондый туйны күргән юк иде әле.

Н у р г а л и. Күрерсең. Гармуныңны тартып уйна. Казанга ишетелерлек булсын. *(Сүриягә.)* Син җырла, тавышың матур.

С ү р и я. Гөлшатны Дамирыбызга дип торган идек тә...

Н у р г а л и. Өлгермәдегез. Шулай... Узыгыз...

Кунаклар өстәл янына тезелешеп утырышалар. Әүхәт белән Әхәт тә чыгып утыра.

Нургали *(алар янына килеп)*. Нәрсә җәелдегез? Әниегез утырмаган килеш. Утыртыгыз җайлап әниегезне. *(Әүхәт белән Әхәт ишектән чыккан әниләрен түр башына утырткач.)* Тәк. Шулай... Әйтегез анда, кияү белән кызны алып чыксыннар. Гамир, суз әргәнеңне.

Гамир кияү белән кәләшне каршылау көен уйный. Гөлшат белән Алмаз чыгып утыралар. Нургали сүз ала.

Шулай... Ярый... Әйе... Болай, җәмәгать. Киләселәр килде, рәхмәт. Килмәгәннәр үзләренә карасыннар. Шулай... Туй икәнен барыгыз да беләсездер. Шулайрак килеп чыкты. Хәзерге яшьләрне аңлап буламыни ул?! Бер күрүдә яратышалар, бер күрүдә танышалар. Менә бу кунак егете дә күргән безнең кызны, вәссәлам. Безнең кыз да бер күрүдә башын җуйган. Берсе өйләнәм, икенчесе кияүгә чыгам, ди. Теләсәң нишлә. Көтегез бераз, дим, бер-берегезне белгәнче сабыр итегез, дим. Юк. Беләбез, диләр. Риза булдык, нишлисең. Малайлар, Әүхәт белән Әхәт тә, яшьләрнең сүзенә аркылы төшмә, эти, диләр. Аларның да сүзләрен тыңламый булмый. Хәлимә дә әйтә, хәерле булсын, ди. Хәерле булсын, яши-яши белешерләр, Алла боерса. Әйдәгез, ризыклардан җитешегез, әче балдан авыз итегез, җырлашыгыз, биешегез, көлешегез. Гаеп итештән булмасын, хәзинәдә барын өстәлгә куйдык. Киявебез Алмаз исемле. Әти-әниләре — тирә-якта билгеле кешеләр. Туйга килеп җитә алмадылар. Магадан дигән шәһәргә кунакка киткән булганнар.

Хәзрәт. Нәрсә, Нургали, никах укытмыйсызмыни?

Нургали. Юк, алар — камсамуллар. Шулай...

Хәзрәт. Камсамул бетте ич инде ул.

Нургали. Бетермәгәнгә бетмәде. Шулай...

Хәзрәт. Килешми бит, Нургали.

Нургали. Син кем, Галиулла, мулла булдым дигәч тә, хуҗа булма. Курыкма, тиешле сәдакасын алырсың. Яшьләр үзләре әйттеләр, урысча өйләнешәбез, диделәр.

Хәзрәт. Урыслар да туй алдыннан чукына.

Нургали. Йә инде, Галиулла. Остарма инде. Туйның ямен җибәрмә инде. Ашап-эчеп утырыгыз, кунаклар. Әче балдан авыз итегез. Әйдәгез, җырлап бирәм. *(Әче бал салынган җамаякны күтәреп.)*

Ничек килдегез сез безгә,
Батмыенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт куйыйм сезгә?

Тотыгыз әле, тотыгыз әче балны.

Әй нужалар, нужалар шул,
Безнең баштан узалар.
Нужа күрмәгән егетләр
Хатын-кыздан хужы алар.

Яле, ашап-эчеп утырыгыз. Хәзинәдә бары. Бердәнбер кызыбызның туе.

Ф ә һ и м ә. Әткәй, мин дә бер сүз әйтимме?

Н у р г а л и. Иреңнән алда чәчрәп чыкма.

Ә ү х ә т. Әйтсен, әйтәсен барыбер әйтә ул.

Ф ә һ и м ә. Минем әйтәсе сүзем киявебез Алмазга. Алмаз кияү, син Сафалар нәселенә керүеңә бер дә үкенмә. Карап торырга гына усал күренсәләр дә, әйбәтләр алар. Борчылма, Гөлшатыбыз янында биеп кенә йөрер. Менә минем Әүхәтемә генә кара. Карап торырга усалларның усалы, ә үзе миңа ялгыш кына авыр сүз әйткәне юк.

Ә ү х ә т. Ярый, булды, утыр.

Ф ә һ и м ә. Хәзер, Әүхәткәем, бер җыр җырлыйм да утырам.

Сокланып карап туймассың
Зифа буегызга да,
Онытмагыз чакырырга
Бәбәй туегызга да.

Ф ә г ы й л ә. Мин дә бер сүз әйтимме?

Н у р г а л и. Берегез әйтте, җитәр.

Ф ә г ы й л ә. Фәһимәгә ярый, миңа юкмыни? Сеңлебез Гөлшат, син җылама. Дөнья шулай инде ул, әти өендә, әни кочагында гына утырмыйсың. Иң бәхетле парлар сез булырсыз әле, Алла боерса. Гамир абый, безнең туйда уйнаган көйне уйна әле.

Г а м и р. Нинди көй уйнаган идем соң?

Ф ә г ы й л ә *(җырлый)*.

Озата барма, дустым, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам.
Синең серле зәңгәр күзләреңне
Башка күзләр белән алмашмам.

Алмаз урыныннан тора да урамга чыгып китә. Аның артыннан тын калып озатып калалар. Нургали аның артыннан чыга да капканы ябып куя. Алмаз янына чабып килә.

Н у р г а л и. Нәрсә булды? Әллә әче бал килешмәдеме?

А л м а з. Килешмәде.

Н у р г а л и. Шул шул. Аракы эчеп өйрәнгәч, бал килешми.

А л м а з. Минем эчкәнем юк. Минем берни дә эчкәнем юк. Әче балыгызны да эчмәдем. Шулай...

Н у р г а л и. Туктале, син нигә кычкырасың?

А л м а з. Оят булып китте миңа, Нургали абзый.

Н у р г а л и. Нәрсәсе оят?

А л м а з. Ничаклы кеше ышанып утыра.

Н у р г а л и. Утырса ни булган? Бөтен туйларда ышанып утыралар инде ул. Сокланып карап туймассың, дип, бөтен туйларда җырлыйлар. Әйе... Шулай... Берәр елдан карыйсың — сокланып туймаслыклар аерылышкан булалар. Шулай...

А л м а з. Минем бит башка. Мин бит сатылып. Утырам өстәл башында сатылырга куйган товар кебек.

Н у р г а л и. Һай, бигрәк нәзберек икәнсең.

А л м а з. Әни ишетсә, бу малаемнан да рәт чыкмады дияр инде.

Н у р г а л и. Нишлибез инде хәзер?

А л м а з. Белмим, Нургали абзый.

Н у р г а л и. Син, энекәш, әйдә, нитмә инде. Кызымның оятка калдырганы да җиткән. Адәм көлкесенә калам бит. Бөтенесе дә көйләнгән. Машина ачкычы кесәңдә, утырасың да китәсең. Шулай...

А л м а з. Машинагыз да кирәкми.

Н у р г а л и. Алай димә әле син, энекәш. Барысы да кирәк дөньяда. Сиңа нинди ояты? Ояты миңа аның, түзәм бит. Нишләргә кала миңа? Әйдә инде, кереп утыр, түз. Әйбәт кенә бара иде бит әле. Әйдә...

А л м а з. Гөлшат миңа дөресен әйтте. Козёл мин. Козёл гына түгел, ишәк.

Н у р г а л и. Менә инде... Нәрсәгә инде... Чынлап торып уйласаң, без беребез дә кеше түгел. Тирәнгә кермә инде, энекәш. Син чыгып киткәч, андагылар ни уйлый инде.

А л м а з. Капканы ачып куймагыз.

Н у р г а л и. Ярый, ярый, синеңчә булыр. Шулай... Ябып куйдым.

А л м а з. Бар, керә торыгыз. Бераз утырам да керәм.

Н у р г а л и. Ярый, ярый. Тик качма инде, ярыймы? *(Кереп китә.)*

А л м а з. Әйе, шулай... Шулай була инде ул. Безнең авылга театр килгән иде. Шунда «Их безнең җүләрлек, исәпләсәң, үләрлек» дип җырладылар. Чүтеки намус бар икән әле миндә, китереп бәрде бит башка, матур гына утырганда. Әллә әче бал эчеп карыйсы инде. Йоклата, диде Нургали абзый. Йоклап утырсаң, үтәр дә китәр иде. Сезгә, билгеле, көлке инде мине тыңлавы, миңа бер дә көлке түгел.

Капкадан Ә ү х ә т белән Ә х ә т чыгалар. Алмаз янына килеп, икесе ике ягына басалар. Алмаз кечерәеп кала.

Ә ү х ә т. Нәрсә, кияү, баш әйләнеп киттеме?

А л м а з. Болай гына.

Ә ү х ә т. Әче бал ул шундый. Аны белеп эчмәсәң... Татар аракы эчмәгән дип сөйлиләр телевизорда. Нигә эчсен, әче бал булгач.

Ә х ә т. Безнең сеңелне сайладың инде, әйеме?

А л м а з. Туй булгач, сайлаганмындыр инде.

Ә х ә т *(Алмаз иңенә кулын куеп)*. Чынлаптыр инде?

А л м а з. Чынлаптыр инде.

Ә ү х ә т *(икенче иңенә кулын салып)*. Бик ашыгыч булды, ахры?

А л м а з. Ашыгыч булды шул.

Ә х ә т. Карале, кияү, син бик коры сөйләшәсең әле каенагаларың белән.

А л м а з. Ничек сөйләшим соң?

Ә х ә т. Армиядә өйрәтмәделәрмени?

А л м а з. Әллә сез офицерлармы?

Ә х ә т. Генераллар.

А л м а з. Мин — маршал.

Ә ү х ә т. Шулай укмыни? Яле, тотып карыйк беләгеңне. *(Алмазның беләген капшап карагач.)* Болай ярыйсы. Кайсы войскада?

А л м а з. Погонны күрмәдегезмени?

Ә х ә т. Без погон карап йөрүчеләр түгел.

А л м а з. Карагыз әле, сез мине кыйнарга җыендыгыз мәллә?

Ә ү х ә т *(дөньяны яңгыратып көлеп)*. Курыктың мәллә?

А л м а з. Куркырсың да.

Ә х ә т. Курыкма. Тик торган кешегә тимибез без. Әгәр дә инде сеңел белән андый-мондый хәл булса...

Икәүләшеп кулларын Алмазның иңнәренә куялар.

Ә ү х ә т. Андый-мондый хәл булса... Безнең сеңел бераү генә.

А л м а з. Алыгыз әле кулларыгызны, күтәреп торуы авыр. Элегрәк карарга иде сеңлегезне.

Ә х ә т. Өлгер егет булып чыктың. Сөйләштекме, кияү? Әгәр дә сеңелгә бармак белән чиртсәң, менә шушы йодрыкларны иснәрсең.

А л м а з. Ярар. Одеколон сөртеп килегез йодрыгыгызга.

Капка ачылып китә. Аннан, биеп, Ф ә г ы й л ә белән Ф ә һ и м ә чыгалар. Башка кунаклар да аларга кушылган. Г а м и р гармун уйный.

Ф ә г ы й л ә *(биеп, Әхәт янына килә)*. Әйдә, картым.

Әхәт биюгә кушыла.

Ф ә һ и м ә *(Алмаз янына килеп)*. Нишләп монда утырасың, кияү? Бар, чакыр Гөлшатны биергә. Үз туеңда биемәсәң, бәхетең булмый, диләр.

А л м а з *(Гөлшат янына бара)*. Биибезме, Гөлшат? Әйдә. *(Гөлшатның кулыннан тота.)*

Гөлшат, бик саллы итеп, Алмазның яңагына суга.

П ә р д ә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Өченче күренеш

Беренче күренештәге урын.
А л м а з сәхнә алдында басып тора.

А л м а з. Шулай... Шулай булды шул. Саллы гына эләкте абзагызга. Сафаныкылар нәселеннән шул. Күздән Казан утлары күренде. Туйның рәте-чираты китте инде, билгеле. Ярый әле Гөлшатның сукканын бөтен кунаклар

да күреп тормады. Ишегалдында Нургали абзый белән Гөлшатның әнисеннән башка кеше юк иде. Гөлшат миңа тамызды да үкереп җылап өйләренә кереп китте. Аның артыннан әнисе чапты. Нургали абзый белән икәү генә калдык. «Әгәр дә өйләнсәң, хатыныңа кыз бала таптырма», — диде Нургали абзый. «Шулай да бу эшне ахырына барып җиткерик инде, син бүген бездә кун инде, верандада урын җәеп куелган», — диде. Кундым инде, сөйләшенгән бит. Гөлшатны күрсәтмәделәр дә, күрәсем дә килмәде. Иртәгесен... Иртәгесен ни булганны сөйләгәнче, бернәрсә әйтим әле. Менә сезгә сөйли башлаган романның шушы җиренә хәтлесен бер компаниядә сөйләгән идем. Сөйләдем дә туктап калдым. Ничек бетте, ничек бетте, дип сорыйлар. Шуннан әйттем тегеләргә, яле, мин әйтәм, ничек беткәнен үзегез чамалагыз әле, дим. Әй тотындылар сөйләргә. Берсе әйтә, син машинага утырып кайтып төшкәч, абыйлары артыңнан килеп җиткәннәр дә сине кыйнап машинаны алып киткәннәр, ди. Икенчесе әйтә, Гөлшат төнлә торып күлгә сикергән, батып үлгән, ди. Сез Нургали белән үкенгәнсез, ди. Өченчесе Гөлшатны бәхетле итеп күрәсе килә. Икенче көнне алдаган егет кайткан да аны Казанга алып киткән, ди, икенче туйны Нургали Казанда уздырган, ди. Шатлыгыннан сиңа «Ока» машинасы түгел, «Жигули»ен биреп җибәргән, ди. Тагын берсе әйтә, син кайтып киткәнсең, әмма ләкин Гөлшатны оныта алмагансың, газапланганcың һәм дә, чынлап өйләнергә дип, яңадан Гөлшат янына килгәнсең, ди. Болай дип әйтүчегә барысы да каршы чыктылар. Аңгыра мәллә ул, җүләр мәллә ул, шушыннан соң да килеп йөрергә, диләр. Китте бәхәс — очына чыга алмадылар. Ә чынында ул болай булды. Иртәгесен тордым да Гамир абыйларга кайттым. Гамир абый эшкә барырга чыккан, Сүрия апа көтү куып кайтып килә.

Г а м и р. Нәрсә, кияү егете, Нургали кызының кочагы кайнармы?

С ү р и я. Оялтма малайны.

Г а м и р. Оялтырсың аларны. Маладис. Балда, майда йөзәрсең. Түлке анда бер нәрсә ишеттем әле. Әхмәтҗан күреп калган. Кәләш синең колак төбеңә ямаган, ди.

С ү р и я. Сөйләмә инде кеше сүзен. Туйда сөйлиләр инде ул.

Г а м и р. Нургали кызы бер дә туйда утырган кебек утырмады. Алмазга күтәрелеп тә карамады. Зерә син үзеңне яратмаганга өйләнәсең. Нәрсәдер монда ни.

С ү р и я. Ни булсын инде, син дә... Хатын-кыз кебек...

А л м а з. Юк, Гамир абый дөрес чамалый. Ние бар инде анысы. Гөлшатны мин күптәннән беләм ич. Дамир адресын бирде дә хат язышып тордык. Моннан өч ай элек Гөлшат минем янга килде. Шунда ялгышканбыз. Беләсең бит инде, баш юк бит бездә. Гөлшат шуннан ни инде, балага узган. Шулай...

С ү р и я. Сөбханалла!..

Г а м и р. Мондый чакта «сөбханалла» дип әйтмиләр.

А л м а з. Шуннан соң үзгәрде Гөлшат. Ызгышып аерылыштык. Хат та язмады. Монда да сөйләшергә теләмәде. Нургали абзыйга әйттем. Калганын беләсең инде.

Г а м и р. Нәрсәгә дип киреләнде икән соң, үзе килгән янына. Ни җитмәгән?

С ү р и я. И-и-и, алар нәселен беләсең инде. Холыклары көнгә ун үзгәрә.

Г а м и р. Инде ничек?

А л м а з. Ничек дип. Нургали абзый әйтә...

Г а м и р. Нургали абзый түгел инде хәзер. Бабай...

А л м а з. Бабай әйтә: бар да җайланыр, кияү, балага узган хатын холыксызлана, кайтып кил авылыгызга, ди, килеп алып китәрсең, ди.

С ү р и я. Әйбәт булсын инде, әйбәт булсын.

Г а м и р. Шулай да сугуы хакмы?

А л м а з. Булды инде.

Г а м и р. Юк, тормышыгыз булмый инде. Хатын-кыз ир буласы кешесенә кул күтәрдеме, юк инде ул. Сылап җибәрәсең калган үзенә дә.

С ү р и я. Бөтен кеше син түгел, бар, эшеңә соңга каласың. Чәй өлгергән, әйдә, Алмаз улым.

А л м а з. Рәхмәт, Сүрия апа. Сыйландым.

Г а м и р. Бергә яттыгызмы соң?

С ү р и я. Төпченмә хатын-кыз кебек, бар.

Г а м и р. Ярый, сау бул инде, алайса.

А л м а з. Сау булыгыз, Гамир абый. Сау булып торыгыз, Сүрия апа.

С ү р и я. Исән-сау кайтып җит.

А л м а з *(Гамир белән Сүрия киткәч)*. Уф!.. Тәки

ерып чыктым бит. Бу хәтле үк ялган сөйләгәнем юк иде. Өйрәтте бит Нургали абзагыз. Дамирга хат язып салырга кирәк, минем ялганны тоттырмасын. Вот әкәмәтство, үз ялганыңа үзең ышанып куюың бар. Гөлшат баласын тәки үз балам дип йөрерсең. Тизрәк ычкынырга кирәк. Әллә машинасын да алмаска инде Нургали абзыйның. Юк, бер ахмаклык эшләдең, икенче җүләрлек эшләмә. Син «Ока»лык кына хезмәт иттең.

Нургали *(Алмаз янына килеп)*. Кай арада чыгып киттең?

Алмаз. Нишләп ятыйм анда?

Нургали. Әйе... Шулай... Нишләп ятасың... Машина ишегалдында.

Алмаз. Күрдем. Әллә алмаскамы дип тә уйлап торам.

Нургали. Ал, энекәш. Тормышның рәте китте. Машинасы да күзгә күренми.

Алмаз. Аптырамагыз ул хәтле. Балалы кызлар хәзер дөнья тулы.

Нургали. Дөньяда эшем юк минем. Ал син машинаны, ал. Тырыштың.

Алмаз. Шулай сөйләштек бит.

Нургали. Исән-сау кайтып җит. Берәүгә дә сөйләмә инде моны. Оныт... Әйдә, утыртып җибәрәм. Шулай...

Алмаз. Гөлшат нишли?

Нургали. Каян белим? Беләсем дә килми. Әнисе кайнаша шунда. Хатын-кызларсыз гына торам. Шулай... Шулай шул... *(Китә.)*

Алмаз. Шуннан... Шуннан шул инде, киттем кайтып. Машина әйбәт. Кәеф кенә әллә ничек. Бозылган колбаса ашаган кебек. Бара-бара бераз ачылды. Туктап су да коенып алдым. Шуннан бөтенесе онытылды. Кайтам җырлап.

Бу дөньяга ник тудым дип
Үкенмә икән,
Дөнья йомгагы бик җиңел
Сүтелә икән.
Эх-ма, эх-ма-ма!
Аласын ал, йоклама.
Ходай сиңа бирәм дисә
Бирә икән ул...
Сиңа ниләрнең кирәген
Белә икән ул.

Эх-ма, эх-ма-ма!
Биргәндә ал, йоклама.
Бәхет юк дигән булалар,
Булмый димени?
Аккан суга чиләк тотсаң,
Тулмый димени?
Эх-ма, эх-ма-ма!
Бәхет бар ул, йоклама.

Шулай... Җырлап кайтып кердем авылга. Ничек каршы алганнарын сөйләмим инде — миңа кызык түгел, сезгә дә кызык түгел. Шуны гына әйтәм, машинаны каян алдың, дигәнгә, тагын алдаштым, яхшы хезмәт иткән өчен генерал бирде, дидем. Ышандылар, җаннарым. Берәр җиргә чыгып таяргамы әллә дип йөрдем. Таеп кая барасың? Бөтен җирдә бер дөнья. Әни дә кызганыч. Тотындым яшәргә. Бер кыз белән таныштым. Уналты яшьтә генә булса да, белмәгәне юк. Муенга асылына, кызык түгел. Күңел нәрсәдер эзли. Эзләгәндә килә дә төшә бит искә теге. Төшә — нишләтәсең. «Козёл» дигәне дә «бәгырькәем» булып ишетелә. Яңакка сукканы да килеп кочаклаган кебек тоела. Төшкә керә, сабакы. Шулай дигәнгә ачуланмагыз инде, яратып әйтәм, яратмасам, «эт» дияр идем. Көн үткән саен якыная бу миңа. Бер елга якын интектем. Әллә барып күреп кайтыйм микән дип тә уйлыйм. Шүрләп калам. Ә өченчекөн шундый төш күрдем. Сезгә аны сөйләмичә булмый. Гөлшатны беренче тапкыр очраткан урын икән. Гөлшат көянтәчиләгән күтәреп суга бара икән. Дөнья шундый аллыгөлле икән. Миллион сандугач сайрый икән... *(Гөлшат каршына атылып барып.)* Исәнме, Гөлшат?

Гөлшат. Исәнмесез!

Алмаз. Мине таныдыгызмы, Гөлшат?

Гөлшат. Алмаз ич син.

Алмаз. Әйе шул. Үзе. Нихәлләрдә яшисең, Гөлшат?

Гөлшат. Сине көттем.

Алмаз. Ә мин синең өчен килдем. Син шундый итеп атлап киләсең, судан йөзеп барган шикелле.

Гөлшат. Сине күргәнгә шулай ул.

Алмаз. Чынмы, Гөлшат?

Гөлшат. Мин бит гомерем буе көттем сине, Алмаз. Сине очраткач, бу егет минем бердәнберем дип уйладым.

Алмаз. Беренче очрашканда сөйләмәдең, ямьсез сүзләр әйттең, туебызда яңагыма суктың.

Гөлшат. Сине сынар өчен иде ул, Алмаз.

Алмаз. Тегесе дә мине сынар өчен идеме?

Гөлшат. Чынлап яратуы хак булса, ышанмас дип, юри генә әйткән идем.

Алмаз. Чынлап әйтәсеңме, Гөлшат?

Гөлшат. Валлаһи, билләһи. Сине сагыныплар үлә яздым. Син киттең дә югалдың.

Алмаз. Югалмадым мин. Авылда гына идем. Мин дә сине бик сагындым. Мәхәббәтнең мондый икәнен белми идем әле мин. Акылдан шаштыра икән ул. Туйда чакта мин бит синең кулыңнан «әйдә биибез» дип әйтергә тоткан идем. Шундый йомшак, шундый кайнар иде кулларың, шуңадыр инде яңагым ут кебек янды. Яңакның януларына түзеп була, йөрәк януларына түзеп булмый икән. *(Җырга күчә.)*

Чәчәк эзли күбәләкләр,
Күбәләкне көтә чәчәк.
Безгә чаклы эзләгәннәр
Бездән соң да көтәчәк.
Гөлшатым, Гөлшатым!
Сине тапкач мин шатмын.

Гөлшат.
Лачын оча күкләр гизеп,
Сандугачка таңнар кирәк.
Таңны көткән сандугачка
Кунып сайрар таллар кирәк,
Алмазым, Алмазым!
Синсез яши алмасмын.

Икәү бергә.
Табышканга, кавышканга
Бәхет гөле атсын чәчәк.
Безгә чаклы яратканнар,
Бездән соңнар да сөячәк.
Алмазым! Гөлшатым!

Сине тапкач, мин шатмын.

Гөлшат. Синең җырың күгәрчен гөрләве кебек, Алмаз.

Алмаз. Ә синеке сандугач сайравы шикелле.

Гөлшат. Син Таһирга охшаган, Алмаз.

Алмаз. Ә син — Зөһрәгә. Гөлшат, мин бер әйбер үтенеп сорасам ачуланмассыңмы?

Гөлшат. Меңне сора, Алмаз.

Алмаз. «Идиот» дип әйткәнеңә дә үпкәләмим, «дурак» дип әйткәнеңә дә ачуланмыйм. Син миңа «козёл» дип әйтмә инде, ярыймы. Бик нык, бик нык ачуың килгәндә, «айгыр» дип әйтерсең. Ә мин сиңа гел генә дә «сандугачым, карлыгачым» диярмен. Аннары соң туебызда үбешмәдек тә. «Горько» дип әйтүче дә булмады.

Гөлшат. Татарлар туйдан соң гына үбешә бит, Алмаз.

Алмаз. Туебыз узды, әйдә пәп итешик инде. *(Үбешкәч.)* Их, миннән дә бәхетлерәк беркем юк дөньяда. *(Биюгә күчә.)*

Аңа Гөлшат кушыла. Биегәндә Гөлшат югала.
Аны Алмаз эзли.

Гөлшат! Гөлшат! *(Сәхнә алдына килә.)* Шулай булды шул. Шуннан түзмәдем, килдем менә. Нигә килгәнемне дә белмим. Нишләргә җыенганымны да белмим. Әллә нәрсә мине этеп алып килде. Торам менә Гамир абыйлар өе каршында.

«Бәтәч» дигән тавышка борылып карый. Сүрия басып тора.

Сүрия. Бәтәч... Алмаз, син түгелме соң бу?

Алмаз. Исәнмесез, Сүрия апа.

Сүрия. Кая югалдың син?

Алмаз. Югалмадым.

Сүрия. Монда сөйлиләр. Качты, диләр. Эзләтеп тә караган сине Нургали. Әллә кая Себер якларына китеп качкан, ди. Дамирыбыздан да хат килде. Озакламый кайтып җитәм, дигән. Хатының бала тапты. Ир бала. Бигрәкләр дә үзеңә охшаган инде, койган да каплаган. Кердеңме соң әле үзе янына?

Алмаз. Оялам.

Сүрия. Нидән, үз хатыныңнанмы?

Алмаз. Әллә ничек килеп чыкты бит. Акча эшлим дип, Төмән ягына киткән идем дә кайта алмадым.

Сүрия. Бар, кер, аңлатырсың. Хат та язмадыңмы?

Алмаз. Язмаган идем шул.

Сүрия. Һәй, яшисез дә инде уйламыйча. Абыйлары очрамасын инде, кыйнап имгәтерләр. Гөлшат бик үзгәрде. Басылып, юашланып калды. Алып китәргә дип килмәгәнсеңдер ич?

А л м а з. Белмим әле.

С ү р и я. Ничек инде белмисең? Алма кебек балаң бар.

А л м а з. Гөлшат ни әйтер бит. Гафу итмәс.

С ү р и я. Итәр, итәр. Кая барсын бала белән? Кая бара ала хатын-кыз?

Ф ә һ и м ә *(үтеп барганда Алмазны күреп ала)*. Син түгелме соң бу, оятсыз?

А л м а з. Исәнмесез!

Ф ә һ и м ә. Исән булмый нишлик? Нишләп йөрисең монда?

С ү р и я. Нишләп йөрсен, ди. Хатыны, баласы бар.

Ф ә һ и м ә. Исенә төшкәнмени, оятсыз. Хәзер Әүхәт абый белән Әхмәткә әйтеп иманыңны укыттырам.

С ү р и я. Бик нитмә әле син, Фәһимә. Башта сораш. Аннары, син алай судия булма әле. Син килен генә. Гөлшат үзе бар. Гөлшатның әти-әнисе бар.

Ф ә һ и м ә. Булгач, нигә анда кермәгән, нигә монда басып тора?

С ү р и я. Уйлашабыз менә. Бар әле, Нургалине чакырып чыгар әле.

Ф ә һ и м ә. Оятсыз... *(Китә.)*

С ү р и я. Әйбәтләп сөйләш Нургали белән. Гафу үтен. Иелгән башны кылыч кисми. Кияве бит, әллә нишләтмәс. Ну болай бик ачулары килеп йөрде инде. Мактанчык нәселгә җитә калды. Әле авылыбызның мулласы белән сүзгә килгәннәр. Никахсыз кыз бирдең, шуңа да шулай булып чыкты, дигән мулла. Коммунист башың белән кысылма, дип әйтә икән Нургали. Шундый хәлләр. Син дә бераз олыгаеп киткәнсең сыман. Бала атасы кыяфәте кергән. Ярый, мин чәй куя торам. Гафу үтенсәң дә, Нургали белән куркып сөйләшмә. Үзләреннән курыкмаганга каты бәрелмиләр алар. *(Кереп китә.)*

А л м а з. Нургали абзый белән сөйләшербез анысы. Гөлшат нишләр? Аны күрергә дип килдем. Кызык та инде кешеләр, ни сөйләсәң, шуңа ышаналар. Үзем дә ялганларга өйрәнеп беттем. Төмән, имеш. Көтәләр ди анда сине, бар. Чыккан Нургали абзый. Ничегрәк итеп аңлатырга икән аңа? Нәрсә ялганларга? Юк, дөресен әйтәм дә бирәм, Гөлшатны күрәсем килде, дим.

Н у р г а л и. Нишләп йөрисең?

А л м а з. Исәнмесез, Нургали абзый?

Н у р г а л и. Күрешик... Шулай...

А л м а з. Менә килдем әле, Нургали абзый. Гамир абыйларның малае Дамир белән бергә хезмәт иттек бит. Кайтырга тиеш иде, кайтмады микән дип килдем.

Н у р г а л и. Монда буталып йөрмәскә дип сөйләшкән идек бит.

А л м а з. Сөйләштек инде анысы. Сез дә мине Себергә качкан дип сөйләп йөргәнсез.

Н у р г а л и. Тинтәк халыкка төшендерергә кирәк ич. Шулай...

А л м а з. Хәлимә апа ни хәлләрдә соң?

Н у р г а л и. Исән-сау.

А л м а з. Гөлшат ни хәлләрдә?

Н у р г а л и. Балагыз бар... Шулай... Анагызны саткырлары.

А л м а з. Минем әнине нигә сатасыз? Аның ни гаебе бар?

Н у р г а л и. Син инде, энекәш, тизрәк ычкын моннан. Бүтән килеп йөрмә. Гамир малае кайтса, үзе синең янга барыр.

А л м а з. Гөлшатны күрергә ярыймы миңа, Нургали абзый?

Н у р г а л и. Нигә кирәк ул сиңа?

А л м а з. Кирәкми дә...

Н у р г а л и. Кирәкмәгәч...

А л м а з. Кызык ич.

Н у р г а л и. Кызык... Кызык инде анда. Укуын ташлады. Ята өйдә. Кызык...

А л м а з. Ни исемле куштыгыз?

Н у р г а л и. Кемгә?

А л м а з. Нигә инде... Гөлшатның ниенә.

Н у р г а л и. Сиңа нигә кирәк ул?

А л м а з. Кирәк дип... Кирәкми дә... Туйда янәшә утырдык бит. Мин сезнең сүзне тыңладым бит. Гөлшатны күреп кенә китим.

Н у р г а л и. Әллә чынлап күрәсең килә?

А л м а з. Мин шуның өчен килдем, Нургали абзый.

Н у р г а л и. Шуның өчен?

А л м а з. Шуның өчен.

Н у р г а л и. Алай... Ярый... Шулай... Ник туры безгә кермәдең?

А л м а з. Ничек туры керим ди.

Н у р г а л и. Гөлшатны күргәч, ни була инде.

А л м а з. Сорау алмагыз инде, Нургали абзый. Болай да оялам.

Н у р г а л и. Анысы менә ярый, ояла белү ярый ул. Шулай... Тагын бер тапкыр яңагыңа сукмасмы соң Гөлшат?

А л м а з. Сукса суга инде.

Н у р г а л и. Әллә тагын син?..

А л м а з. Күрәсем килә, Нургали абзый.

Н у р г а л и. «Күрәсем килә»... Менә нәрсә, энекәш... Син күңелеңне аздырып йөрмә. Күрсәң дә шул, күрмәсәң дә шул бу дөнья. Беләм дә инде, исеңә төшкән дә инде синең... Өстән генә уйлыйсыз. Асты бар икәнен онытасыз дөньяның.

А л м а з. Бәлки, аның асты өстенә караганда яхшырактыр.

Н у р г а л и. Нәрсә-ә?..

А л м а з. Күрим Гөлшатны. *(Нургалинең текәлеп каравыннан уңайсызланып.)* Нигә инде шулай карыйсыз?

Н у р г а л и. Карыйм әле менә... Шулай... Әллә күреп була бүтән, әллә юк... Шулай... Бар, кер Гамирларга. Урамда болганып йөрмә. Караңгы төшкәч килерсең.

А л м а з. Сезгәме?

Н у р г а л и. Гөлшатның бездә икәнлеген белмисеңмени? Әй, дөньясы... *(Китеп бара.)*

А л м а з. *(Сәхнә алдына килеп.)* Көттем инде Гамир абыйларда караңгы капканны. Күрәсе килә бит, нишләтәсең. Планнар корган булам. Әгәр дә Гөлшат «козёл» дип каршыласа нишләргә дә, әгәр төштәге шикелле «көттем» дисә, нишләргә? Кем белә, бәлки, күренергә дә теләмәс. Караңгы капкач, киттем Нургали абзыйларга. Барам шулай. Капкаларына җитсәм, капка төбендә теге абыйлары утыра. Карап торам боларга, бәйгә куйган усал этләргә караган сыман.

Ә ү х ә т. Нихәл, кияү?! Кил утыр безнең уртага. Сагындырдың.

Ә х ә т. Утыр, утыр, оялма.

Алмаз урталарына утыра. Моны ике яклап кысалар.

А л м а з. Кысмагыз, үтерәсез ич.

Ә ү х ә т. Синең әле яшисең киләмени?

А л м а з. Сезнең дә яшисегез киләдер ич... Кысмагыз, дим, юкса сугыша башлыйм.

Ә ү х ә т. Нәрсә-ә-ә?.. Кем белән сугышасың, чебеш?

А л м а з. Мин спецназда хезмәт иттем. Әгәр дә имгәнсәгез, миңа үпкәләмәгез.

Ә х ә т. Оһо! Шулай укмыни? Яле күрсәт әле морякларга кем икәнлегеңне!

Ике яклап тагын да ныграк кысалар.

А л м а з *(кычкырып)*. Җибәрегез, дим.

Н у р г а л и *(тавышка чыгып)*. Ни бар монда?

А л м а з. Менә болар.

Н у р г а л и *(улларына)*. Нишләп йөрисез монда?

Ә ү х ә т. Менә кияү күрергә дип килдек.

Н у р г а л и. Барыгыз, кайтыгыз өйләрегезгә! Кемгә әйтәләр!..

Ә х ә т. Ә бу?

Н у р г а л и. Анда сезнең эшегез юк. Барыгыз!

Ә ү х ә т. Нәрсә инде син, әти?..

Н у р г а л и. Ике әйттермәгез. *(Әүхәт белән Әхәт киткәч.)* Нишләттеләр?

А л м а з. Кысалар.

Н у р г а л и. Ә син кыстырма, егет булсаң. Көчең җитмәсә дә сугыш. Кысылганны кысалар ул бу дөньяда.

А л м а з. Алар икәү бит.

Н у р г а л и. Булса соң. Телевизор карамыйсыңмыни? Кысалмыйлар бит чаянны. Шулай... Инде болай... Өйгә кермисең булып чыкты. Гөлшат үзе чыгар.

А л м а з. Үзе риза булдымы?

Н у р г а л и. Төпченмә. Көт. *(Кереп китә.)*

А л м а з. Уф! Йөрәк дөп-дөп тибә. Кабырганы авырттырдылар звирләр. Спецназ дигәч тә курыкмыйлар. Сүзне нидән башларга инде? Гел «исәнмесез» дип әйтү дә туйдыра. Теләсә ни булсын, капкадан чыгуга ук кочаклап алам. Беткән баш беткән. *(Капкадан Гөлшат чыккач, сүзен әйтә алмыйча, Гөлшатка карап тора.)*

Г ө л ш а т. Исәнмесез!

А л м а з. Исәнмесез... Исәнме... Исәнмесез, Гөлшат... Мин... Әйе... Шулай... Утырыгыз әле, Гөлшат.

Г ө л ш а т *(утыра)*. Нигә килдегез?

А л м а з *(Гөлшат янәшәсенә утырып)*. Ни... Гөлшат... Сезне күрәсем килде.

Г ө л ш а т. Нигә?

А л м а з. Котлыйм сезне.

Г ө л ш а т. Ни белән?

А л м а з. Улыгыз бар дип ишеттем.

Г ө л ш а т. Шуны әйтер өчен килдегезме?

А л м а з. Ул гына түгел инде, билгеле. Әйттем ич, күрәсем килде. *(Гөлшатның үзенә текәлеп карап торуын күреп.)* Сез Нургали абзый кебек икән. Дәшмичә кешегә карап торасыз. Ни уйларга да белмәссең.

Г ө л ш а т. Нигә килдегез?

А л м а з. Кызык икәнсез сез, бер сорауны әллә ничә тапкыр бирәсез.

Г ө л ш а т. Чөнки җавап бирмисез.

А л м а з. Күрәсем килде, дигәч, җаваптыр инде ул.

Г ө л ш а т. Сезгә нәрсә кирәк тагын? Туйда утырдыгыз, машина алып киттегез.

А л м а з. Машина дип... Мин аны алмыйсы да идем әле. Алып килдем мин аны, калдырып китәм. Миңа ошамасагыз, туйда да утырмый идем.

Г ө л ш а т. Минем кем икәнлегемне белә идегезме? Ник дәшмисез?

А л м а з. Болай ул, Гөлшат... Әйе... Шулай...

Г ө л ш а т. Әти белән бигрәк килешкәнсез, аныңча сөйлисең.

А л м а з. Начар кеше түгел бит ул. Инде болай, Гөлшат. Әйе... Шулай... Син миннән сорау алма. Үткәннәрне тикшерергә дип килмәдем монда. Син кем идең, мин кем идем дип тә килмәдем. Мин төшеп калган малай түгел. Каушатма мине. Сине күргәч, болай да инде әллә нишләдем. Нигә килдең дип бүтән сорама. Сине күрәсем килде. Нигә күрәсең килде дип тә сорама. Күрәсем килде, бетте-китте. Синең күрәсең килмәсә, кереп кит. Болай да инде төшләремә кереп интектерәсең. Мин гаеплемени аңа? Сиңа начарлык эшләгән булсам, гафу ит. Син дә «козёл» дип әйткәннәрең өчен гафу үтен. «Дурак, идиот» дип әйткәннәрең өчен гафу үтенмәсәң дә ярар. Яңакка сукканга да ачуланмыйм. Син чөнки дә белештермичә суктың. Менә шул... Шулай... Мин әйтәсен әйттем, теләсәң нишлә. Сине күрәсем килеп килдем.

Г ө л ш а т. Кайда сез хәзер?

А л м а з. Авылда... «КамАЗ» йөртәм.

Г ө л ш а т. Мин дә авылда менә. Өйдә ятам.

А л м а з. Ә нигә җылыйсың?

Г ө л ш а т. Мине күрергә килгәч, нигә җылаганымны да бел.

А л м а з *(паузадан соң)*. Беләм. Җылама. Җылаган кеше күрсәм, минем йөрәгем бозыла. Казанны сагынасыңмы?

Г ө л ш а т. Юк. Күрәсем килми ул кабахәтне.

А л м а з. Алай димә. Казан – безнең башкалабыз. Аның гаебе юк.

Г ө л ш а т. Сине әллә кая, Төмән ягына качкан дип сөйләделәр. Дамирның әнисе Сүрия апа да әллә ниләр сөйләп йөргән, мине синең янга барып йөргән дип…

А л м а з. Мин аны үзем сөйләдем.

Г ө л ш а т. Нигә?..

А л м а з. «Нигә, нигә»… Нигә икәне билгеле инде. Инде болай… Әйе… Чыннан әйтәм, Гөлшат, мин сине яратам, ахрысы. Төшкә юкка гына кермисеңдер, юкка гына сине күрәсем килмәгәндер.

Г ө л ш а т. Ул турыда сөйләшмик.

А л м а з. Нәрсә турында сөйләшик соң?

Г ө л ш а т. Килгәнеңне әти әйткәч, ачуым да килгән иде. Инде… Рәхмәт искә алып килүеңә.

А л м а з. Нәрсә инде… Сиңа рәхмәт чыгуыңа. Берәр тапкыр мине исеңә төшерденме?

Г ө л ш а т. Синең кайгың булмады. Ачуланма. Нигә туйда утырганыңны сизгәч кенә… Мин керим инде. Син килеп йөрмә инде, Алмаз.

А л м а з. Беренче тапкыр исемемне әйттең.

Г ө л ш а т. Килеп йөрмә. Бөтенесе өчен дә мин сине гафу итәм. Машинаны калдырма, истәлек булсын. Килеп йөрмә. Мин ант иттем. Мин беркайчан да беркем белән мәхәббәт турында сөйләшмәячәкмен.

А л м а з. Без бүтән нәрсәләр турында сөйләшербез.

Г ө л ш а т. Нәрсә турында?

А л м а з. Дөнья булгач, сөйләшергә сүз бетми инде ул. Менә сөйләштек ич әле.

Г ө л ш а т *(урыныннан торып)*. Хуш!

А л м а з. Утырыйк инде, Гөлшат.

Г ө л ш а т. Юк. Мин инде хәзер сиксән яшьлек карчык кебек.

А л м а з. Соң, мине дә сиксән яшьтә дип уйла.

Г ө л ш а т *(елмаеп)*. Чыннан да, тиле, ахры, син.

Тагын бер тапкыр яңагыңа сугарга дип чыккан идем… Хуш! *(Кереп китә.)*

А л м а з. Мин барыбер киләчәкмен, Гөлшат…

Килдем мин. Бер генә түгел, әллә ничә тапкыр килдем. Чыкмады. Дамир кайткач, ул да сөйләшеп караган. Онытсын, дип әйткән. Ул «онытсын» дигән саен, мин кыза гына барам. Аптырагач, хат яза башладым. Аңардан хат килмәде. Хет, ичмасам, карточкаңны җибәр, дип язган идем, улы белән төшкән карточкасын җибәргән. Тик сүз юк. Бер сүз дә юк. Әни күреп алган карточканы, кемнәр алар, дип сорый. Барысын да сөйләп бирдем. Башыңны әйләндермә, бәхетегез булмый, диде әни. Синең бәхетеңә ул бала аркылы төшәчәк, диде. Мин әле ул турыда уйламый идем, Гөлшатның үзе турында гына уйлый идем. Үземне биздерергә тырыштым. Тик барыбер хат язудан туктамадым. Барыбер үземнекен иттем, Гөлшат хат язды. Кыска гына иде ул хат. Хатта очрашканда әйткән сүзләр инде. Тора-бара бүтән сүзләр дә яза башлады. Язмаслык та түгел шул — мин аңа шундый хатлар язам, кайсы хатын-кызның йөрәге түзсен. Бер хатны әле шигырь белән дә яздым. Бер куплеты истә дә калган.

Нигә икән Чулпан йолдыз
Айдан ерак киталмый,
Айдан ерак китмәсә дә,
Ай янына җиталмый?

Шулай булды шул… Хат языша-языша, тагын бер ел үтеп китте. Көннәрдән бер көн Гөлшатның хатында «Сагынам, ахры, мин сине» дигән сүзләрне укып акылдан шаша яздым. Хатны укуга ук киттем авылларына. Анда ни булганын сөйләп тормыйм инде, җәмәгать. Үзегез дә сизенәсездер. Ләкин, чү… Ашыкмагыз… Дөнья без сизгәнчә генә бармый ул. Син уйлыйсың тауның түбәсенә менеп утырдым дип, ә тау уйлый бу адәм нишләп минем итәгемдә буталып йөри дип. Болар очрашып, бәхетле булдылар дип уйлыйсыз инде сез. Шулай булса, ни әйтер идең дә бит, шулай булмый шул. Сөйләве авыр булса да, авылларына килеп төшкән моментны әйтәм. Чөнки анысы сезгә дә кызык тоелыр. Үзем дә аны бик еш искә алам. Әйе… Шулай… Килеп төштем авылларына. «Ока»да түгел, үзем эшләгән «КамАЗ»да. Машинаны калдырдым

да Дамирларның бакча артында, киттем җәяүләп кенә Гөлшат өе ягына. Шунда карасам, каршыма Нургали абзый килә. «Соңга калдың, энекәш, Гөлшатлар яңа гына китте», — ди. «Кая китте?» — мин әйтәм. «Баласының әтисе кайтты бит, шул алып китте», — ди. Минем хәлне аңлыйсыздыр инде, җәмәгать. Сезгә дә бу сүзләрне ишетү җиңел түгелдер. Минем Гөлшатны үлеп яратуым сезгә дә күчкәндер. Күпләрегез минем бәхетле булуымны теләгәндер. Ләкин борчылмагыз, җәмәгать. Барысы да сез уйлаганча булды — Гөлшатлар өе ягына барганда капкадан чиләк-көянтә күтәргән Гөлшат чыкты да…

Гөлшат, иңнәреннән чиләк-көянтәләрен ташлап, Алмазның кочагына ташлана.

*(Гөлшатны кочаклаган килеш залга карап.)* Менә шулай булды шул, җәмәгать. Бәлки, алай да кирәкмәгәндер. Шулай да ун ел яшибез бит әле. «Козёл» дип әйткәне дә юк, яңакка да сукканы юк. Сезгә дә бәхет телим.

Пәрдә.

# ЭЧТӘЛЕК

Әлдермештән Әлмәндәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Ак тәүбә, кара тәүбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Канкай углы Бәхтияр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Моңлы бер җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Әниләр һәм бәбиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Мулла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
Алты кызга бер кияү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 305
Гөргөри кияүләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
Йөрәк маем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 381
Күрше кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 432
Җанкисәккәем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 487
Илгизәр + Вера . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 530
Син мине күрәсеңме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 581
Шулай булды шул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 617

Литературно-художественное издание

**Миннуллин** Туфан Абдуллович

ПЬЕСЫ

Казань. Татарское книжное издательство. 2021
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Миңнуллин** Туфан Габдулла улы

ПЬЕСАЛАР

Төзүчесе һәм мөхәррире *А. Ф. Галиәхмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Корректорлары *Л. Р. Галимова, Г. М. Хәбибуллина*

12 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. № 436 – ФЗ

Форматы 84×108 1/32. Шартлы басма табагы 34,32.

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: (843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**
**http://www.tatkniga.ru**